
# КАЗАН УТЛАРЫ

3. 1993



## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Редакция фонды хисабына иганә акчалары күчерүчеләр арткан-нан-арта бара. Без аларның кайдан, кемнәр булуларын укучыларыбызга һәрдаим хәбәр итеп торырга булдык.

Исегезгә төшерәбез: безгә ярдәм итәргә теләүчеләр хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для фонда редакции журнала «Казан утлары».**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**3**

**(845)**

**1993**

КАЗАН

## *Бу санда*

ДРАМАТУРГИЯ

Ә. БАЯНОВ. Зәңгәр кыңгыраулар. *Драма* . . . 3

ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫ ТӨЗЕЛҮГӘ 30 ел

Н. ӘХМӘДИЕВ. Әлмәт әдипләре . . . . 29
Г. АХУНОВ. Бәйрәм котлавы . . . . . . 32
Ә. МАЛИКОВ. Уяну . . . . . . . . . 33
Г. АФЗАЛ. Әлмәт яклары. *Шигырьләр* . . 36
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Сау бул, язым. *Шигырь* . . . . . . . . . . . . . 41
К. БУЛАТОВА. Елга-сулар ага... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 42
И. ХӨСНИ. Ояттыр. *Шигырьләр* . . . . . 45
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Мәскәү урамында. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . 47
Ф. ИСМӘГЫЙЛЕВА. Шулай да... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 49
Р. БАЙТИМЕРОВ. Сигезьюллыклар . . . 50
Ә. ГАБИДИ. Әти кинәше. *Шигырьләр* . . 52

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Җ. ДӘРЗАМАН. Ник керәсез төшләремә? *Күңел дәфтәреннән...* . . . . . . . . 54

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Х. МИҢНЕГУЛОВ. Азатлык көрәшенең мөнбәре . . . . . . . . . . . . . 122
Солтангалиев эше . . . . . . . . . 136

ДИСКУССИЯ
БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

Ә. НИЗАМЕТДИНОВ. Кузгалды уйларым... . . . . . . . . . . . . . . 152
С. ШӘРИПОВ. Хакыйкатьнең ачысы . . . 157

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА — 75 ЕЛ

«Миллионнарның бәйлә йөрәген...» *(«Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире, Татарстан халык депутаты Мөнир Әһлиуллин белән әңгәмә)* . . . . . . 159

З. РӘМИЕВ. Талантлы язучы, күренекле галим *(Мөхәммәт Галинең тууына 110 ел)* 165

СӘНГАТЬ

Б. УРМАНЧЕ. Казан сәнгать мәктәбе: заман һәм кешеләр... 169

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ
ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Ф. ХӨСНИ. Хәзинә. *Хикәя* 181

Бер сорауга — бер җавап 185
Безнең календарь 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 188

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Драматургия»: драма А. БАЯНОВА «Синие колокольчики».
«К 30-летию союза писателей Альметьевска»: статья председателя союза писателей Альметьевска Н. АХМАДИЕВА, поздравление Г. АХУНОВА, воспоминания А. МАЛИКОВА; стихи Г. АФЗАЛА, С. СУЛЕЙМАНОВОЙ, К. БУЛАТОВОЙ, И. ХУСНИ, И. ГИЛЯЗОВА, Ф. ИСМАГИЛОВОЙ, Р. БАЙТИМЕРОВА, А. ГАБИДИ.
«Проза»: повесть-размышление З. ДАРЗАМАНА «Сны мои, сновидения».
«К истории культуры»: статья Х. МИННЕГУЛОВА «Борец за свободу», статья «Дело Султангалиева», статья З. РАМИЕВА «Талантливый писатель, выдающийся ученый».
«Наша жизнь. Наша литература»: Статья А. НИЗАМУТДИНОВА и С. ШАРИПОВА.
«К 75-летию газеты «Ватаным Татарстан»: интервью с главным редактором газеты, народным депутатом Татарстана М. АГЛИУЛЛИНЫМ.
«Искусство»: статья Б. УРМАНЧЕ «Казанская школа искусства: время и люди».
«Навыки чтения на основе латинской графики.
Интервью с министром народного образования республики Татарстан В. ГАЙФУЛЛИНЫМ.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: «Беседа» — картина художницы Санкт-Петербурга Р. Зиннатовой; известный писатель А. Маликов.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Кояш Тимбикова, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.02.93 ел. Басарга кул куелды 9.03.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 369. Заказ Я-60. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

**Әхсән Баянов**



# ЗӘҢГӘР КЫҢГЫРАУЛАР

ДРАМА ЖИДЕ КАРТИНАДА

Катнашалар:

Айбикә
Асыл
Шоңкар
Әсмабикә
Йолдыз
Тәберде
Гөлбизәк
Әби
Юмарт кул

## Беренче картина

**Җиһазлары ахыргача урнашып та өлгермәгән өр-яңа фатир. Гөлбизәк тәрәзәгә пәрдәләр кора. Айбикә керә. Кулындагы чәчәкләрне вазага урнаштыргач, аларга озак кына сокланып тора.**

Айбикә. Әни, кара әле, сиңа ошыймы?

Гөлбизәк. И-и, тагын шундый чәчәкләр алгансың икән.

Айбикә. Әллә яратмыйсың? Кыңгырау чәчәкләрдән дә матуррак гөл бармыни ул дөньяда.

Гөлбизәк. Соңгы вакытта бигрәк тә зәңгәр дип үлә башладың. Берәр хикмәте бардыр инде.

Айбикә. Чәчәк базарына барсам, бөтенесен карап, бөтенесенә сокланам. Ала башлагач, ни өчендер гел шушысын сайлаган булып чыгам. Сәбәбен үзем дә белмим.

Гөлбизәк. Беләсеңдер...

Айбикә. Ничек диден?

Гөлбизәк. Кияүдән яхшы түгел. Син шушы чәчәкләрне алып кайтсаң, үзгәрә дә куя. Кара уйга кала.

Айбикә. Ул үзе үзгәрде. Бу чәчәкләрне сагынырга мәжбүр итүче ул үзе бугай.

---

Әхсән БАЯНОВ (1927) — *шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм урыс телләрендә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Гөлбизәк. Тынычлыгыбыз бозылыбрак тора шул. Теге өйдә чакта да дөньяның яме китколи иде. Иллә сәбәбе күренеп торадырые. Түшәмнән яңгыр тама: леп-леп, леп-леп. Матур гына тамчылар. Үзләре тамган саен йөрәкне тишкәли, җәрәхәтли бирәләр. Бу өйдә дә шул тамчылар тама бугай.

Айбикә. Өебез яп-яңа, ничек аның түшәменнән су үтсен ди.

Гөлбизәк. Син шулай дисең дә бит.

Айбикә (*сагаеп*). Әллә берәр сүзең бар инде?

Гөлбизәк. Үзем генә калгач дигәндәй, башка уй төшкәли шул.

Айбикә. Кызык булса, әйт.

Гөлбизәк. Күңелем әллә нәрсә сизенгәндәй итә. Миңа иске өйдә калу хәерлерәк булмады микән?

Айбикә. Андый сүзне, әни, бүтән әйтмә, мине рәнҗетәсең килмәсә.

Гөлбизәк. Кызым дим, синсез тора да алмыйм, монда күчәргә нишләптер аяк та тартмады үзе.

Айбикә. Әллә Асыл караңгы чырай күрсәтәме?

Гөлбизәк. Юк, юк, бер дә гөнаһсына керәсе түгел.

Айбикә. Алайса, үзең бездән туйгансың.

Гөлбизәк. Кызым, ничек телең бара.

Айбикә. Колакка ятышсыз сүзләр сөйлисең бит...

Гөлбизәк. Сөйләмәс идем дә... Сез юкта бүген бер акылдан язган кортка килеп китте. Яный, куркыта — сине миннән талап алмакчы.

Айбикә (*шаярта дип белеп*). Әсин бирмә, ычкындырма.

Гөлбизәк. Ярый, кызым, бер әйттем, биш кайттым. Бетте. (*Пәрдәләрне корып бетерә.*) Бигрәкләр дә матурны алгансыз икән. Театрыгызда да мондыйны күргәнем юк.

Айбикә. Без — молодцы, әни. Син хәзер кухняны күзәт. Мин тиз генә юынып чыгыйм.

Гөлбизәк. Бар, кызым, ризыклар өчен борчылма.

**Айбикә ванна бүлмәсенә кереп китә. Звонок шалтырагач, Гөлбизәк ишек ача. Асыл керә.**

Асыл. Йә, ни хәлләр, Гөлбизәк әни? Яңа өйдә күңелләмә?

Гөлбизәк. Күңелсез түгел дә...

Асыл. Искесе сагындырып төслеме?

Гөлбизәк. Шулайрак төсле шул, балам.

Асыл. Алайса, җыен, хәзер китәбез.

Гөлбизәк. Миңа шунда калырга буламы?

Асыл. Ул нинди сүз? Бүгенгә, бер генә кичкә.

Гөлбизәк. Бүген монда кичке аш әзерли идек шул. Айбикә күчеп килгән көнне бәйрәм итәрбез дигән иде.

Асыл. Анда да ачтан үлмәбез — калада бит әле. Эшләрне дә төгәллисе бар. Иделнәрне юып, тәртипкә китереп.

Гөлбизәк. Барысын да эшләдек, балам, өй ялт итеп калды.

Асыл (*уйлана төшеп*). Ну, алайса, яңа хуҗалар килмәсме. Бәхилләшәсе булыр.

Гөлбизәк. Айбикә нишли?

Асыл. Аның спектакльгә әзерләнәсе бар. Калса калыр. Булдымы? Машина белән генә, ялт итәрбез.

Гөлбизәк. Ярый соң. Миннән тормас. (*Китәргә җыенгач.*) Анда сиңа нинди дер әрҗә китерделәр. Балатурда бергә эшләгән иптәшләрең, диделәр.

Асыл. Лабораториядә.

Гөлбизәк. Әйе, лабратурда. Бүләк, диделәр.

Асыл (*бүләкне карап*). Оһо! Магнитофон!

Гөлбизәк. Безнең котлауны тыңлап карасын, диделәр.

Асыл. Шулаймы? Кызык. Сюрпризсыз булмас инде аларның. Ә син, әни, бар, җыен.

Гөлбизәк. Әллә ни җыенасы юк. Ат әйткәндәй, минем җәй дә, кыш та бер төсле. (*Китә.*)

**Асыл магнитофонны электрга тоташтырып, клавишка баса.**

Магнитофон. Син безнең лабораториядә файдалы эшләр калдырып киткән кеше.

Асыл. Плюс — минус, минус — плюс — минем фәрештәләрем, тик алар мине күккә күтәрә алмадылар.

Магнитофон. Безнең өчен сәер күчеш ясап, көтелгән ачышларыңны вак мәшәкатьләргә алмаштырдың.

Асыл. Оһо, бүләккә — менә дигән тәнкыйть! (*Якынрак килеп утыра.*) Мәгәр бит мин заводтан әллә кая китмәдем. Фәнни хезмәткәрлектән, директор ярдәмчесе булып, өскәрәк кенә калыктым. Табигый үсеш түгелмени бу? (*Үзен тыңлап торган Айбикәне күргәч.*) Ә! Сиңа җиңел пар, Айбикә.

Айбикә. Ник туктатасың, кызык бит.

Асыл. Син ишеттеңмени?

Айбикә. Йә, тыңлап бетерик инде.

Асыл. Шул ерунданы... Тыңларбыз әле, бүтән юлы. Гөлбизәк әни белән без хәзер иске йортка барырга сөйләштек.

Айбикә. Нишләп алай кинәт кенә?

Асыл. Яңа хуҗалар белән күрешеп, бәхилләтәсе бар.

Айбикә. Мин алар белән сөйләштем — тәртип.

Асыл. Ну, алайса, ачкычны тапшырырга кирәк.

Айбикә. Тәгаен бүгенме?

Асыл. Тәгаен бүген, Айбикә. Син кал, барасың килмәсә.

Айбикә. Әлсә үзем генә тыңлап бетерәм. (*Магнитофонны тоташтырмакчы.*)

Асыл. Бер исеңә төшсә, синең шул булыр. Әйтәм бит, мәгънәсез сүзләр. (*Магнитофонны тоташтыра.*)

Магнитофон. Яңа постыңның вазифаларын киңәйтә төшеп, тәэминат кешеләре белән дә житәкчелек итә башладың. Безне бөтенләй оныттың, ташладың.

Асыл. Ялгышасыз, мин сезнең янга тиздән, бик тиздән бөтенләйгә кайтачакмын.

Айбикә. Кайтачакмын — яңа сыйфатта, житәкчегез булып.

Магнитофон. Теләгебез шул: яңа өйдә иске дусларыңны хәтерләп яшә. Бәхетле бул. Галәм авазларын бергәләп тыңларга язсын.

Айбикә. Ә син буш сүзләр дисең.

Асыл. Алар минем хәлне аңламыйлар, белмиләр. Ә бит минем үзебез ижат иткән аппаратлар белән галәм сигналларын тыңларга, аларны адәм теленә күчерергә, мәгънәләрен исә халыкларга бүләк итәргә дигән теләгем күптәннән килә. Ә башта ничек кыен иде! Институт биргән хокукны тормышка ашыру буш хыялга әверелгәч, үзем сайлаган фән осшмаларының бусагасыннан да уза алмагач, шушы завод капкасын кактым. Сакчы булып торырга да риза идем — алмадылар. Шул чакта әти һөнәре ярдәмгә килде — заводка тәэминатчы булып кердем. Күрдегез, әкрен-әкрен үз максатыма якынлаштым, лабораториягә үрләдем. Плюс-минус, минус-плюс... Ләкин мин ишетергә тырышкан галәм сигналлары заводка кирәкми, заводка әзер модельләр белән күбрәк аппаратлар эшләп чыгарырга кирәк. Миннән башка һичкемнең үз өреш кертергә нияте юк. Шуңа күрә, лаборатория мөдирлегенә конкурс игълан ителгәч, шул эшне дәгъвалап гариза биргәнмен икән, бик тә зур гаепме шушы? Йә, син ни диярсең?

Айбикә. Мин нәрсә әйтим? Ижат кешеләре арасында мондый гына сәерлекләр бик гадәти хәл. Бераз гына буталыштан соң яңа көч, яңа дәрт белән яңа аппаратлар ижат итәргә күчәрсең, дигән өметтә калам.

Асыл. Ә дуслар әнә өмет өзгәннәр.

Айбикә. Шаярталар.

Асыл. Ничек? Шаярталар? (*Чырае ачылып.*) Кара, шуны да сизми торам — картаям, валлаһи картаям, шаян сүзне аңламый башладым. Әллә нинди мәгънәсез сүзләрдән баш житмәс тирәнлекләр эзлим. Әй жүләр мин, әй дивана! Алдымда хатыным басып тора, ә буш фәлсәфә белән баш катырам. (*Айбикәнең кулыннан элэктереп, кочакламый.*)

Айбикә (*халатын бәйләп.*) Асыл, йәле, туктале.

Асыл. Шушы көнгә хәтле синең болай матур икәненне күрми йөргәнмен бит.

Айбикә. Күп нәрсәләрне ычкындырырсың әле шулай.

Асыл. Юк, юк, ычкындырмыйм, миндә мертвая хватка. (*Хатынын күтәреп өстәлгә утырта.*)

Айбикә (*өстәлдәге тартманы күреп*). Ә бу нәрсә?

Асыл. Болармы? Тыштан гап-гади конфетлар, тик эчләре тулы — дефицит.

Айбикә (*кабып карый*). Ә-ә! Ром! Исерткеч тә булсын дефицит.

Асыл. Исерткеч сыман тоела гына, ә үзе — мәхәббәт, сафлык белән кушылган.

Айбикә (*өстәлдән төшә*). Алары да бездә житәрлектән артык.

Асыл. Чынлапмы? Ә менә бу чәчәкләр? Алары да сафлык галәмәтеме? (*Чәчәкләргә сукккалый.*)

**Звонок. Ишектән Тәберде белән Йолдыз керә.**

Айбикә. Менә, кунаклар. Әйдәгез, түргә узыгыз.

Тәберде. Котлы булсын яңа фатирлар. Йөз ел яшәп, йөз кайгыйның берсен дә кертмәгез. (*Кулында дүртпочмаклы зур гына аквариум.*)

Йолдыз. Йөз елдан соң да.

Асыл. Яшь булсагыз да, зурларча сөйләшәсез, рәхмәт. Тик без... пожалуйста...

Йолдыз. Йөзгә хәтле генә саный беләбез, сатучы кисәге бит әле. Хәзергә.

Тәберде. Кечкенә дип гаепләмәсәгез, бүләгебез шушы иде.

Асыл. Тик без үзебез сезнең янга жыенган идек — иске өйгә.

А й б и к ә. Ул хәтле ашыкма ла. Рәхмәт, Тәберде, рәхмәт, Йолдыз. Менә дигән бүләк.

Т ә б е р д е. Урнаштырыйкмы соң? Әллә иске өйгә алып китәсезме?

А с ы л (*көлеп*). Ничек тә ярар. (*Аслык табып, аны почмакка күчерә.*) Хәзергә куйыйк шушында. Ары күз күрер. Тик без иске өйдә яңа хуҗалар белән күрешергә сүз куешкан идек.

Т ә б е р д е (*аквариумны куя*). Ә син, Йолдыз, балыкларны кире алып китәсеңме?

Й о л д ы з (*кулындагы банканы исенә төшергәндәй*). Ә! Менә алар! Менә, Айбикә апа, икегезгә дүрт балык. (*Банканы куя.*) Үзегез урнаштырырсыз яңа фатирларына.

Т ә б е р д е. Тотып ашамагыз. Үзегез дә шул санга җитегез.

Й о л д ы з. Синең шаяртуың шундый булыр инде.

Т ә б е р д е. Нәрсә, мин шаяртаммы әллә? Чынлап, балыкларга — аквариум, сезгә менә шушы йорт — бездән бүләк.

А й б и к ә. Әйе шул, Тәберде, сез төзегән өй бит, ә?!

А с ы л. Рәхмәт. Сезгә лаеклы булып яшәргә тырышырбыз. Хәзер исә безне машина көтә. Сез дә сыясыз.

**Звонок. Кулына зур төенчек тоткан Әсмабикә һәм Юмарт кул керә.**

А с ы л (*ишек ачылганчы*). Уф, соңладык. (*Ишекне ачкач.*) А-а! Хуш киләсез! Айбикә, күрәсеңме, кемнәр килде безгә?

Ю м а р т к у л. Исәнмесез, хөрмәтле дуслар!

А й б и к ә. Исәнмесез, рәхим итегез. Каян белеп киләсез болай, яңа адресны беркемгә дә биргән юк лабаса.

Ю м а р т к у л. Чын дуслар таба ул. Айга менсәгез дә тынгылык бирмәячәкбез.

Ә с м а б и к ә. Ике канатлы кукурузнигым белән мин дә менеп җитәрмен.

А с ы л. Дөрес, ракета белән аны исәр дә менеп төшәр.

Т ә б е р д е. Ә мин ике кулга ике мастерок тотып... (*Җилпенә.*) Хушыгыз!

А й б и к ә. Сау бул, Икарус дус! (*Кухня ягына китә.*)

Й о л д ы з. Исән калмасаң, мин синең белән ЗАГСка бармыйм.

Т ә б е р д е. Килештек.

А с ы л. Кояшка хәтле очыгыз да яңадан кайтыгыз. (*Шартлатып шампанское ача.*)

А й б и к ә (*кухнядан чыгышлый*). Ура, иптәшләр!

Г ө л б и з ә к (*аның артыннан чыгып*). Әбәү, сизмирәк калдым кунаклар килгәнне. Ачуланмагыз инде. (*Өстәлгә ризыклар куя.*)

А с ы л. Как раз моментында, әни, бик вакытлы, молодец.

А й б и к ә. Әни, син монда олы кеше, әйдә, беренче сүз — синнән.

Ю м а р т к у л. Бик шәп — иң өлкәннең сүзе иң дөрес.

Г ө л б и з ә к. Иң дөресе, дип, ни. Минем инде бөтен сүзем шул: тәрәзәгез җил-кояшка ачык торсын, өй түбәгездән, түшәмегездән яңгыр-су үтмәсен.

Ю м а р т к у л. Шәп! Яңа өйдә тату яшәгез, бәхетле булыгыз, дигән сүз инде бу.

Г ө л б и з ә к. Бүтән сүз белмим, балалар, ачуланмагыз.

К у н а к л а р. Котлы булсын яңа өйдә яңа бәхетләр.

Ю м а р т к у л. Искеләре дә ташлап китмәсен.

Г ө л б и з ә к. Амин!

Б а ш к а л а р. Амин!

**Шампанское күтәрәләр.**

Т ә б е р д е (*аквариумга карап.*) Котлы булсын дигәнгә, сүзсез булса да, балыклар да кушыла.

Й о л д ы з. Алтын балыклар — алтын хуҗаларга.

А с ы л. Дөрес!

Т ә б е р д е. Алар сезнең бөтен йомышыгызны һич карышусыз үтәрләр. Аның белән генә чикләнмичә, бәхетле матур тормышыгызның җанлы бизәкләре, акыллы шаһитләре дә булырлар. Сер таратмас дусларыгыз булып, авызларына су капкандай эндәшмичә яшәрләр. Тик серләрегезне бер-берегезгә ахыргача чишә торган булыгыз.

А й б и к ә. Менә бит безнең күршеләр.

Ә с м а б и к ә. Иске күршеләр.

А й б и к ә. Монда нинди күршеләргә юлыгырбыз инде.

Й о л д ы з. Үзегез әйбәт булгач, сезгә начар кешеләр очрамый торгандыр.

А с ы л. Рәхмәт, кадерле дуслар, зурладыгыз.

Ә с м а б и к ә. Ә без? Менә без нәрсә алып килдек, ә? Бүләге анык булса да (*Юмарт кулга ишарә*), күтәреп килүчесе мин бит әле. Үз кулыгыз белән тапшырасызмы соң?

Ю м а р т к у л. Минем бердәнбер серем шушы, хөрмәтле дуслар, яңа өй белән котлап, дустым Асылның хәләл бичәсе Айбикәгә, аның тәзәлмәс поклоннигы буларак, менә шушы тун гына бүләгем.

Айбикә. Миңа? Сездән? Бүләк?!

Юмарт кул. Кабул күреп, безне бәхетле итсәгез лә.

Айбикә. Сез кем соң? Гафу итегез...

Асыл. Шуны да белмәскә, каладагы иң куәтле кешеләрнең берсе — шушы үзе бит инде.

Айбикә. Хәтеремә төшерә алмыйм.

Юмарт кул. Шатланырсыз дип уйлаган идем мин.

Әсмабикә. Айбикә, малайкаем, син кара әле, кара гына: нинди җәнлек бит! Җылы тәнеңдә тузсын. (*Тунны Айбикәгә көчләп диярлек кидерә.*) Безгә, күктәге лачыннарга, мондый җәнлек тиресе тәтеми ул.

Тәберде. Әкәмәт тә кеше сез, Асыл абый, дөньяда юкны сез табасыз.

Асыл. Мин түгел, табучы — ул!

Юмарт кул. Әйе, әйе, исеме Айбикә булган сәхнә йолдызына кечкенә генә бүләгем.

Йолдыз. Асыл абый белән Айбикә апа шундый бәхетле! Көнләшеп үләрлек.

Айбикә. Синең Тәберденең әллә ниләр эшләр әле.

Тәберде. Галәм кызлары гына кия торган шушы тунны табаргамы? Өметләндермә, Айбикә апа, булмый. Минем кулда таш та ком, кирпеч тә балчык.

Айбикә. Торып кара шул балчыксыз.

Тәберде (*Йолдызга*). Норка тун киясең килсә, менә мондыйларны эзлә. (*Юмарт кулга ишарәли.*)

Айбикә. Иптәшләр, сез Тәберде белән Йолдызның язылышырга гариза биргәнен белмисез бит әле.

Асыл. А! безнең урамнарда тоташ бәйрәм. Әче! Горько!

Тәберде. Бүтән сүз белмисезме, абыйлар?

Асыл. Их, сез киләсен белгән булсак, иске өебезгә киләсе хуҗалар белән көрешергә сүз куешмаган булыр идек. Ну, бераз күтәрләр. Әйдәгез, юл аягына соңгы бокал — яшьләр бәхете өчен. Айбикә белән безнең кебек бәхетле, матур яшәсеннәр.

Юмарт кул. Өй түбәләреннән яңгыр үтмәсен.

Тәберде. Яңгыр ул пүчтәк. Без сала торган өйләргә хәсрәтләр, хаталар да юл тапмый, адашалар.

Асыл. Адаша дигәннән, хөрмәтле дуслар, мин кичә кызыклы бер хәлгә тарыдым бит әле. Адашып килеп кергән бер әби минем кабинетка. Кавказ карчыклары диярсең, кап-кара шәл ябынган. Әҗәл әбинең нәкъ үзе инде менә. Кулында чалгысы гына юк.

Әсмабикә. Чалгысын ишек төбендә калдырып кергәндер.

Юмарт кул. Заводка ничек керткәннәр соң аны?

Асыл. Ул үзен Айбикәнең әнисе дип таныштырган.

Тәберде. Чынлап, кызык бу, шуннан, Асыл абый?

Асыл. Шуннан шул. Шүрәлегә Былтыр баккандай озак кына карап торгач, сезгә миннән ни кирәк дип сорарга мәҗбүр булдым. Кара икра кирәк, ди — бу әби әйтә. Нинди кара икра ул, дим мин монә. Ул әйтә: шул, сез үзегез ашый торган инде, ди. Сез һәм дусишләрегез ашый торган, ди. Кара икрасыз озак яши алмаячаксың, дип әйтә врачлар, хәлем начарайды, ярдәм итмәссез микән, ди. Мин кибетче дә, склад мөдире дә түгел бит, дип карыйм, ишетми дә. Язу язып бирегез дә, үзем барып алырмын, ди. Менә сиңа әби.

Тәберде. Ул әйберләрнең складта булуы хак түгелдер ич?

Әсмабикә. Анысын Асылгәрәй абыең үзе белә инде. Белә дә әйтми генә.

Тәберде. Нишләп?

Йолдыз. Беркатлы да инде син, Тәберде. Дефицит! Ишеткәнең бармы шундый сүзне?

Айбикә. Шуннан, Асыл, ни белән бетте?

Асыл. Ни белән, дип. Язу бирә алмагач, янап чыгып китте. Сүзләрен монда кабатларлык түгел.

Тәберде. Мөгаен, дөрес сүзләр булгандыр.

Асыл. Ярый, прениеләр — соныннан, бүтән юлы.

Йолдыз. Прение, дигәннән. Кичә безнең директор җыелыш үткәрде. Тәнәфес вакытында. Әй сөйли бу, әй сөйли. Тәнәфес узып унбиш минут үтте — һаман сөйли, ишекләрне ачтырмый. Покупательләр ишек дөбердәтә, кычкыра, акыра. Ә безнең мөдир үзләреннән яман бакыра: сезнең мәнфәгатьне кайгыртып, хезмәт күрсәтүне яхшырту чаралары хакында сөйләшәбез ласа, аңгыралар, дип тирги.

Асыл. Сәүдә эшендә төрлесе була. Сезгә төрле яклап эләгә. Бер яктан оргач, ник суктылар дип карап өлгергәнче, икенче яктан тондыралар. Шулай да түзәсез.

Айбикә. Безнең Асыл да үзен коеп куйган сәүдәче итеп тоя башлады инде.

Асыл. Нишләтәсең, сәүдә — минем кара көнгә әткәм-әнкәмнән калган һөнәр.

Юмарт кул. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Айбикә. Саескаен шикелле, үз һөнәрен онытмагае дип шикләнә башладым шул.

Юмарт кул. Сәүдә эшен кимсетеп, без бик алама хәлләргә дучар булдык.

Асыл. Тагын бер алтын сүз. Ярый, хөрмәтле дуслар. Безнең арабызда бүген — бик кадерле, зирәк кеше. Ул безне санга санап килгән, башка сыймаслык олы бүләк белән. Шулай соңгы тамчы суга кадәр бүлешә торган юмарт кешеләр күбрәк булса, дөньябыз тагын да күркәмрәк, мәгънәлерәк булыр иде. Иң яхшы теләкләребез сезгә, хөрмәтле кунагыбыз — сезнең янда без үзебезне тагын да бәхетлерәк, акыллырак, дип хис итәбез. Соңгы тост — сезнең хөрмәткә.

Юмарт кул. Үзегезгә рәхмәт. Сез әйбәт булганга күрә без шәп.

Әсмабикә. Син миңа дусыңның кем икәнен әйт, мин аңа синең кем икәнеңне әйтермен, дигән китап.

Юмарт кул. Без дусларыбызда чагылабыз.

Тәберде. Кара әйберләрнең генә чагылышы булмый.

Юмарт кул. Безне бүген Айбикә белән Асыл яктырта. Әйдәгез, якты кешеләр өчен.

Йолдыз. Якты көнелләр өчен. (*Бокал күтәрәләр.*)

Юмарт кул. Ә хәзер, хөрмәтле дуслар, чират җырга җитте. Җырга!

Йолдыз. Айбикә апага.

Тәберде. Дөрес!

Айбикә. Белмим шул, белмим, уңайлы булыр микән.

Асыл. Иң җайлы чак, иң яраткан җырыңны. Әйдә, шуны тыңлыйк та...

Йолдыз. «Зәңгәр кыңгыраулар», Айбикә апа.

Айбикә. Инде сайланасы да калмады бугай.

Юмарт кул. Алла хакына! Тыңлыйбыз.

**Айбикә пианино янына утыра, уйный һәм җыр башлый.**

*Кырда йөргән чакта, кыңгырау гөл*
*Бүләк иткәннәрең истә гел.*
*Шуннан бирле, сине сагынганда,*
*Кыңгыраулар чыңын ишетәмен.*

*Кушымта:*

*Җирдә, куктә — кая барсам шунда,*
*Уем синең белән очраша.*
*Барча хыялларым чынга аша,*
*Зәңгәр кыңгыраулар чыңласа.*

*Син биеккә очып күздән кичкәч,*
*Чыңлаганын күкнең ишеттем.*
*Күңелемне дәшкән күк гөмбәзен*
*Мин кыңгырау диеп хис иттем.*

*Кушымта.*

*Кыңгыраулар алып килә чыңлап*
*Безнең бергә булган елларны.*
*Икәү генә белгән бәхетләрне,*
*Икәү генә белгән моңнарны.*

*Кушымта.*

Тавышлар. Браво! Шәп! Рәхмәт!

Асыл. Ә без хәзер яшь дуслар белән иске өйдә дәвам итәчәкбез. Кузгала башлыйбыз, яшьләр.

Әсмабикә. Йолдыз белән миңа кагыламы инде бу сүзләр?

Асыл. Тәбердене дә калдырмыйк, Йолдызга күңелсез булыр.

Тәберде. Бер килгәч, Асыл абый, теге бүлмәләрне дә карап китик инде.

Асыл. Эһе, ярый соң. Әйдәгез алайса. Айбикә, хөрмәтле кунак сиңа кала, боектырма.

Әсмабикә. Артистканы өйрәтәсе юктыр инде.

**Бүлмәдә Айбикә белән Юмарт кул гына кала.**

Юмарт кул (*пианинода уйнап карый*). Шундый матур итеп җырладыгыз. (*Йөренеп ала.*) Гаҗәеп моң, искиткеч. Сыктау, юксыну, сагыну. Гүзәл хисләр. «Җирдә, күктә — кая барсам шунда...» (*Пианинода көй чыгара.*) Биредә сез кульминациягә иртәрәк киләсез бугай. Икенче контрапункт төшеп калган сыман. Әмма гаҗәеп музыка. Ниһаять, ниһаять, сезне менә шушылай якыннан ишетер көн бар икән.

Айбикә. Мин сезне хәтерли яздым кебек. Ниндидер банкетта сез минем исемгә кушып гаҗәп янгыравыклы тост әйткән идегез. Сез шул кешеме?

Юмарт кул. Сезнең хакта бер генә тост әйтмәгәнмендер.

Айбикә. Бик еш туры киләме тостлар күтәрергә?

Юмарт кул. Во-первых, күп туры килми. Во-вторых, туры килсә, сезнең исемгә атап әйтми калмаска тырышыла. В-третьих, сезгә шундый тугрылыклы поклонникгыгыз булу ошамыймы?

Айбикә. В-четвертых, мин кайбер нәрсәләрне аңлап бетермим.

Юмарт кул. Мәсәлән?

Айбикә. В-пятых, сезне ни өчен Юмарт кул дип зурлыйлар?

Юмарт кул. В-шестых, бик тә әһәмиятле мәсьәләме инде бу?

Айбикә. Болай, кызык бит.

Юмарт кул. Бик кызык булгач, әйтим, ярдәмчел кеше булганым өчен.

Айбикә. Асылга да ярдәм итәргә уйлыйсызмы?

Юмарт кул. Уйламыйм, эшлим. Во-первых, аны директор ярдәмчесе итеп куйганда файдабыз тисә, во-вторых, заводтагы сәүдә системасын аның житәкчелегенә күчерү минсез эшләнмәде. Кайчандыр уйлап табучы исәпләнгән инженерга шундый эшләр йөкләүнең нинди җайсызлыклар белән бәйләнгәнен аңлау кыен түгелдер. Бөтен кеше, харап итәсез галимне, дип кычкыра. Ә без ышандык һәм ялгышмадык. Иҗат кешесе дигәнебез администратор буларак та, хәтта сәүдә системасында да, бик матур эшләр башкара ала икән. Бик четрекле дигән җирләрне механикалаштырып бетерә язды.

Айбикә. Үз эшенә тизрәк кайтса, тагын да яхшырак булыр иде.

Юмарт кул. Моның өчен аңа сездән дә ярдәм кирәк.

Айбикә. Үзе дә шулайрак сиздерә. Тик мин нәрсәнедер аңлап житкермим.

Юмарт кул. Хәл катлаулырак шул.

Айбикә. Заводта лаборатория җитәкчесе сайлау конкурсына бүтән гаризалар да бардыр. Асыл сездән шул эш буенча ярдәм сорыймы?

Юмарт кул. Алай ук атап әйтми. Ләкин бит без акыллы кешеләр, үзебез дә сизәбез.

Айбикә. Кулыгыздан килер дисезме? (*Пианино янына килеп утыра.*)

Юмарт кул. Бергәләп тотынсак, килер дип уйлыйм. Һәр хәлдә, минем бер тавышым бар.

Айбикә. Ә миннән нәрсә сорала?

Юмарт кул (*көлеп*). Сездәнме? Нәрсә соралам ы? Мине ярату.

Айбикә. Хәлбуки, сез шаян кеше. Шулай да бу темага шаяру...

Юмарт кул (*пианинога таяна*). Во-первых, мин чынлап яратам. Во-вторых, телисә ни әйтегез, тугыз бурзай өстерәп, өегездән куып чыгарыгыз, барыбер сүземне әйтми калалмыйм — яратам мин сезне, Айбикә. Артисткага гашыйк булган яшүсмер шикелле, илаһи саф хисләр белән авырып хыялланам.

Айбикә. Ә мин...

Юмарт кул. Сез дә мине яратырга тиеш, дисәм...

Айбикә. Тиеш, дисәгез...

Юмарт кул. Курыкмагыз, мин сездән бернәрсә дә көтмим, тик җылы караш, якты елмаю.

Айбикә. Сез бит бу өйгә Асылның дусы буларак кердегез.

Юмарт кул (*Айбикәнең ике яңагыннан тотып, аның күзләренә карап тора*). Шушы хәтле гүзәллек, шушы хәтле тирән мәгънәләрне бер генә кеше монополиясенә әйләндерү җинаять ләбаса. А, Айбикә! Кичерегез, мин бүтәнчә түзә алмыйм. (*Үбә.*)

Айбикә (*көч белән ычкынып*). Бетте. Хәзер чыгып китегез. Хәзер үк!

Юмарт кул. Зинһар, ашыкмагыз, ялгышмагыз. Тсс.

Айбикә. Барысы да аңлашылды.

Юмарт кул. Юк, сез бернәрсә дә белмисез. Шул килеш мине куып чыгарсагыз, Асыл рәхмәт әйтмәс.

Айбикә. Асыл фикере кызыксындырса, сез бу эшкә барыр идегезме?!

Юмарт. Асыл үзе кызыксыначак.

Айбикә. Дус дип кунакка чакырган бит. Кемне!

Юмарт кул. Минем сезгә әйбәт тәкъдимем бар.

Айбикә. Беренче тәкъдим — минеке, рәхим итәсез. (*Куллары белән ишеккә юл күрсәтә.*)

Юмарт кул. Сез бу тавышны иregездән куркып кына кузгатасыз бит. Ә ул үзе бөтенләй икенче төрле уйлый. Ул моңа хәтта риза.

Айбикә. Кем? Риза? Тагы нәрсә?

Юмарт кул. Сезнең белән минем дуслыкка иregез каршы түгел.

Айбикә. Асыл хакында моннан да әшәке итеп кемнең дә әйтә алганы юк иде әле. Кабахәтлектә сез — җиңүче.

Юмарт кул. Асыл чынлап каршы түгел.

Айбикә. Сезгә моны исбат итәргә туры киләчәк.

Юмарт кул. Теләсәгез, үзегез сынап карагыз. Һич булмаса, юри. Мине яраткан булып кыланыгыз.

Айбикә. Сезне яраткан булып кылану — үзе бер әшәкелек.

Юмарт кул. Асыл икенче төрле уйлый.

Айбикә. Берәр сүз әйттеме?

Юмарт кул. Әйтмәде, ләкин без бит тиле кешеләр түгел, безнең барлык тойгыларыбыз тәгәл эшли.

Айбикә. Башта үземне мыскыл итмәкче булдыгыз, көчегез җитмәгәч, хәзер — иремне. Ләкин анысында да уңышка ирешмәячәксез.

Юмарт кул. Айбикә! (*Кочаклый.*)

**Айбикә аның кулыннан ычкынып бәрелгәч, өстәл каты селкенеп, савытлар чылтырап ава.**

Айбикә. Асыл! Асыл, дим! Асыл!

*Күрше бүлмәдән Асыл белән бүтәннәр дә йөгереп чыга.*

Асыл. Бу! Бу ни дигән эш?!

Айбикә. Ул сине дә, мине дә әшәке кешеләр дип килгән.

Юмарт кул. Менә шулай булып чыга: ит изгелек, көт явызлык.

Айбикә. Изге ният белән башкаларга мәхәббәт игълан итегез, ә монда сез эзләгән кешеләр юк. (*Тунны алып аның өстенә ыргыта.*) Исегез дә калмасын, җәнлек тиресен үзегез ябыныгыз.

Асыл. Алай ук кызма, Айбикә. (*Тунны идәннән ала.*)

Әсмабикә (*өстәлдәге савытларны рәтләп*). Бөҗәккә үч итеп тунны утка ягалар, димени. Ай җүләр, ай тиле! (*Юмарт кулга пышылдап.*) Үзегезне әйтер идем — шулхәтле ашыкмасагыз.

Юмарт кул. Асыл, хатыныгыз сезне мыскыл итә, үзегез сокланып карап торасыз.

Тәберде. Ә сез аңа кул сузмадыгызмы? (*Юмарт кул эндәшмәгәч.*) Алайса, ник тешсез җәнлек кебек карап торасыз? Ну! (*Ишектән төрткәләп чыгара.*) Тунның бәясен алып та китмәкче! Менә сиңа затлы тун! Күрдеңме, Йолдыз, төшендеңме?

Йолдыз. Күрдем шул, ай, күрмәсәм!

Айбикә. Нинди хурлык! Әнием, ярдәм ит! (*Күзләрен каплап, бөкшәеп утыра.*)

*Беразга тынлык урнаша. Бер мәлне күтәрелеп карасалар, ишек төбендә кара шәл ябынган әби басып тора.*

Асыл (*аптыраштан соң*). Сез... Сезгә ни кирәк?

Әби. Әле генә миңа кызым эндәште.

Асыл. Безнең әниебез өйдә. Ул Гөлбизәк исемле.

Айбикә (*Тәберде аркасына сыена*). Күземә күренәме соң?

Әби. Үз каным, үз сөягем — шундук таныдым.

Айбикә. Юк, юк, сез мине танымыйсыз.

Әби. Мин — синең әниең.

Айбикә. Әйе, минем туган әнием юк, имеш. Беренче әнием өч яшемнән ташлап киткән... Мин Гөлбизәк әнием белән үстем. Ул үз бүлмәсендә ял итә.

Әби. Синең әниең — мин. Гөлбизәк — кардәш апаң гына.

Айбикә. Моннан егерме ел элек хәбәр килде: әниең вафат, диделәр.

Әби. Кызым! (*Кочакламакчы була.*)

Айбикә (*куркып*). Юк, юк!

Асыл. Сез иплäбрәк, әби, югыйсә...

Әби. Син, хәерсез адәм, катнашма, кызым үзе тел белә.

Асыл. Аның беренче дигән әнисе күптән вафат.

Әби. Ә мин менә кайттым — яңа тормыш белән, бөтенләй икенче төрле яшәр өчен.

Әсмабикә. Сез өрәк алайса.

Әби. Өрәк? Шулай дисеңме? Бәлки дөрестер бу.

Тәберде. Фән бит өрәкне кире кага, әби.

Йолдыз. Өрәкләр, пәриләр күптән беткән, безнең заманга калмаган.

Әби. Калган шул. Күзләрегезне ачыбрак карагыз: шайтан да, җен-пәриләр дә, өрәкләр дә — барысы да бар бу дөньяда. Алар тик кешеләрнең үз араларында адәм кыяфәтле булып кына яши башлаганнар да, сезнең белән бергә буталып көн күрәләр. Аларның берсе — синең ирең. Икенчесе — бая чыгып киткән йөнтәс кул.

Асыл. Өченчесе — сез!

Әсмабикә. Сөйләп бетерсен әле, кызык бит.

Тәберде. Таптыгыз кызык.

Әсмабикә. Син чынлап та өрәкме инде, әбекәй?

Әби. Әйе, кеше кыяфәтендә килеп чыктым. Киявем үземнән дә яманрак икәнне белгәч, инде миңа да урын табылыр, дип кайттым. Бер өрәк сыйган җиргә икенчесе дә сыяр.

Асыл. Ишеттегезме, иптәшләр, ни ди бу?

Айбикә. Каушама, теләсә кем мыскыллаганнан үзеңне кешеләр исемлегеннән сыза башласаң, кем генә калыр җир өстендә?

Әби. Синең кебек чын кешеләр.

Асыл. Һәм синең кебекләрме?

Әби. Тагын менә шушы сабыйлар. Күп бит.

Тәберде. Син безне каян беләсең?

Әби. Мин — кызымның әнисе. Аның кемнәр белән яшәгәнен белмәскә хакым юк.

Асыл. Кайчаннан башлап?

Әби. Адәмгә әйләнү теләге тойганнан бирле.

Асыл. Бөек җиңү белән котлыйм сезне, әбекәй. Бик күңелле булды сезнең белән танышу, рәхмәт, сангa санап килүегезгә. Киләчәктә дә кергәләгез, бигрәк тә без өйдә юк чакларда. Ташламагыз. Ә хәзергә хуш булып торыгыз.

Әби. Ул мине куа, кызым.

Әсмабикә. Ярый, ярый, оят белергә вакыт. Бездә аракы юк, мәҗлес

корып утыруыбыз түгел, өй котларга гына килгән кешеләр без. Грамм да юк, төмсенеп йөрмәгез.

Й о л д ы з. Сезгә нишләп оят түгел, күпме яшь яшәгән әби, нинди юлда йөрисез.

Ә б и. Син дә кит дисенме, кызым?

А й б и к ә. Әби, китегез, зинһар.

Ә б и. Кызым да куగач, китәм. Мин сиңа дөрес сүзләр әйттем, калган ягын үзең уйла, кызым. (*Китә.*)

А й б и к ә (*бераз аптырап утырганнан соң*). Әйтегезче, тагын ни дигән сүз булды монысы? Безнең яңа өйне котлап, кемдер мыскыл итә, кемдер яңадан терелә. Ник болай бу?

Й о л д ы з. Әниегез чынлап үлгән идеме соң?

Т ә б е р д е. Бәлки юри генә үлгән булгандыр?

Ә с м а б и к ә. Үз күзең белән күрдеңме?

А й б и к ә. Ул бүтән шәһәрдә яши иде. Гөлбизәк әнием белән җизнәм җирләп кайттылар.

Й о л д ы з. Өрәккә ышанырга туры киләмени инде?

Ә с м а б и к ә. Нишләп ышанмаска? Без үскәндә күп иде ич.

А с ы л. Яшьләргә черек мировоззрениене йоктырма, яме.

Ә с м а б и к ә. Каян килеп чыккан соң алайса үлгән кеше?

А с ы л. Менә шунысын ачыкларга кирәк тә инде.

Ә с м а б и к ә. Менә сиңа өрәк. Безнең өйгә кереп утырмас микән?

Т ә б е р д е. Балконнар буйлап сезнең бишенче кат тәрәзәгезгә үрмәли дә торгандыр инде. Өйдә, куыйк. Айбикә апа, сезгә йомыш та бар иде дә... театрыгызга гына кереп чыгарбыз инде.

А й б и к ә. Сездә дә бер-бер хәл юктыр бит?

Й о л д ы з. Болай гына, сөйләшербез әле, Айбикә апа. Борешмәгез, яме.

Ә с м а б и к ә. Өрәкне бүтән кертмәскә. Хушыгыз. (*Китәләр.*)

А й б и к ә (*уйланып*). Мин анда ниндидер таныш чалымнар күргәндәй булдым... Әни... әни?

А с ы л. Бүген безнең бәйрәм, беренче өрәк күренмәде. Өебез дөньяның үзе кебек шәп, якты. Күтәр башың, елмай. (*Тунны хатынына кидермәкче була.*)

А й б и к ә. Кит, кит, ничек кулың барып тота аласың.

А с ы л. Тунның ни гаебе бар?

А й б и к ә. Мин сине бөтенләй аңламый башладым, Асыл, ниндидер чит нәмәрсә, хәтәр үзгәреш бар синдә. Шул безнең тормышка күчә.

А с ы л. Дөнья катлаулы, Айбикә, гаять катлаулы.

А й б и к ә. Син миңа нәрсәнедер әйтеп бетермисең. Йолдыз белән Тәберде дә ниндидер табышмаклы сүзләр калдырып киттеләр.

А с ы л. Аларның — күңелсезрәк... Йолдыз — синең кебек беркатлы кыз бит, тормыш гел фәрештәләрдән тора дип исәпләп, хур кызы мисалында йөреп, алданган.

А й б и к ә. Алданган?

А с ы л. Ул мәгънәдә түгел, яманрак мәгънәдә. Иптәш кызы белән икесенә дүрт йөз сум растрата ясаганнар.

А й б и к ә. Ходаем!

А с ы л. Соң инде... Иптәш кызы җыйган инде аны.

А й б и к ә. Анысы да түләргә тиештер бит?

А с ы л. Яртысы янга кала.

А й б и к ә. Ни кылана бу халык? Ни җитми? Алдашмыйча, урлашмыйча гына яшәсә, җаны тыныч булыр иде ләбаса!

А с ы л. Тормыш катлаулы, гаҗәп катлаулы шул.

**Звонок. Асыл ишек ача. Шоңкар керә.**

Ш о ң к а р. Хәерле кич.

А с ы л. Сезне кем дип белик?

Ш о ң к а р. Гафу итегез...

А й б и к ә. Ходаем, Асыл, мин акылдан язам бит (*күзләрен каплый*).

А с ы л. Мин сездән сорыйм, мосафир, сез кем?

Ш о ң к а р. Гафу итегез, сез Асыл Акчуринмы?

А с ы л. Асыл Акчурин. Ә сез?

Ш о ң к а р. Мин... Ничек әйтергә...

А с ы л. Үз исемегездән оялмаска тырышыгыз.

Ш о ң к а р. Хәзергәчә, бу исемгә оят нәрсәләр сөйләнмәгән. Мин Шоңкар булам.

А й б и к ә. Аh!

А с ы л. Шоңкар!

Ш о ң к а р. Гафу итегез.

А с ы л. Менә ничек? Шоңкар үзе! Җиде төн уртасында!

Ш о ң к а р. Мин чакырусыз түгел, гафу итегез.

А с ы л. Чакырулы кунак. Кем сезне чакырды? (*Айбикәгә текәлеп тора.*) Исемегезне ишеткәнем бар, әмма моңарчы шуннан ары китәргә теләгем юк сыман иде.

**Ашыгып Әсмабикә керә.**

Ә с м а б и к ә (*керә-керешкә*). Асыл, тизрәк!

Асыл. Тагын... Тагын нәрсә булды?

Әсмабикә. Ул сине хәзер үк килсен диде.

Асыл. Кем? Кем ул?

Әсмабикә. Кем буламыни — Ул! Юмарт кул! Шушы ук минутта. Уйланып вакыт әрәм итмәсен, диде.

Асыл *(аптырау сиздереп)*. Айбикә, син ишетәсеңме? Ә син... Ә сез... Ә бу төн?

Айбикә. Мин бернәрсә дә ишетмим, берни күрмим, акылдан гына язам.

**Асыл Шоңкарга, Айбикәгә, Әсмабикәгә чиратлап караганнан соң артка чигенә. Ухылдап утыра, тагын тора. Зиһенендәге болганыш хәрәкәтләрендә сизелеп тора. Башта усаллык, аннары фикер көрәше, акыртынлап карар өлгерүе күренә. Ниһаять, ул тынычлана.**

Асыл. Болай ярамый. Өебездә кунак. Шатланырга кирәк ләбаса, елмаерга. Без бит аның ниятләрен белмибез. Шунлыктан ул, беренче нәүбәттә, безнең кунагыбыз. Аны, Айбикә, әйбәт кабул ит. Мин кайтканчы, боектырма, газета-журналлар булса да укып торсын. Мин озакламам. Киттек, лачын.

**Әсмабикә белән китәләр. Айбикә белән Шоңкар аптырап шактый вакыт сүзсез торалар. Ниһаять, күзләре чәчәкләргә төшеп, Шоңкар телгә килә.**

Шоңкар. Чәчәкләр! Әйттем бит, әйттем бит мин! Нәкъ мин калдырып киткәнчә! Ә мин әле ялгыштым дип, кételмәгәнчә килеп чыкты дип, курка язган идем. Айбикә! Менә син нинди! Нәкъ элеккечә! *(Айбикәнең чәчләрен сыйпый.)*

Айбикә *(сикереп тора)*. Бу ни дигән сүз? Шоңкар, син түгелмени бу?

Шоңкар. Мин булмыйча. Килеп життем менә. *(Кочакламакчы була)*.

Айбикә. Юк, юк.

Шоңкар. Аңламыйм.

Айбикә. Ә мине аңлый дип беләсеңме?

Шоңкар. Белмим һәм беләсем дә килми. Әйдә, тизрәк җыен.

Айбикә. Кая? Ник?

Шоңкар. Җир читенә, котыпка — боздан өй салып мәхәббәт белән җылытырга, бөтен җайсызлыкларга үч итеп, боз өстендә чәчәкләр үстерергә. *(Өстәлдәге чәчәкләрне ала.)* Менә шушындыйларны! Менә бит, чәчәкләр, кыңгырау чәчәкләр. Һаман исән. Әйткән идем бит минсез барыбер яши алмассың, дип. Рәхмәт. Хәзер киттек, вакыт әрәм итмик.

Айбикә. Шаярма, Шоңкар, шаяра торган нәрсә түгел бу.

Шоңкар. Ә мин шаярамммы?

Айбикә. Китсәм, алып китәр идеңме?

Шоңкар. Менә инде, шуның өчен кайт та.

Айбикә. Урлап, хуҗа югында?

Шоңкар. Ул сиңа хуҗа укмыни?

Айбикә. Законлы ир. Һәм мин аңа гына түгел, үземә дә саф булырга вәгъдә бирдем.

Шоңкар. Мин ул якларын уйлап бетермәгәнмен бугай. Уйлап торырга вакыт бармыни соң!

Айбикә. Мин, Шоңкар, хыянәткә бара алмыйм.

Шоңкар. Мәхәббәтсез хыянәт юк. Яраткан килеш ташлап, син миңа хыянәт иттең.

Айбикә. Киресенчә, син мине аңламадың. Онытмаган булсаң, хәтерлә: авылда унбиш яшемнән синең белән даным чыкты. Анасы юлыннан китте, монысы да бозык хатын булачак, дип хөкем чыгардылар. Кызны анасына карап кочарга кирәк шул дип, сине кызгандылар. Ә син, котың алынып, качтың.

Шоңкар. Армиягә.

Айбикә. Ә аннан соң?

Шоңкар. Аннан соң да сиңа җанымны йолкып бирергә әзер идем.

Айбикә. Сүзләреңә ышанасы килә дә, тик язылышырга гариза биргәч, икенче кабат бармавын, әзерләнеп беткән туйны өзүең... Яраткан килеш ничек эшләргә мөмкин иде шуларны? Туйга дигән балдакларны калдырдың да киттең.

Шоңкар. Хәтерлисеңдер, ашыгыч телеграмма килде: яңа самолет сынарга чакырдылар.

Айбикә. Ялдагы кешене туй алдыннан кем көчләп эшләтсен?!

Шоңкар. Көчләп түгел, минем очуым яхшырак булачак дип таптылар — ничек каршы киләсең шундый чакта?

Айбикә. Мин ул чакта үз гомеремә үзем чик куярга азапландым. Көчем генә җитмәде. Тик шунда минем нинди матур бер тойгым барыбер үлде.

Шоңкар. Гафу үтендем... ничә кабат! Кичермәдең.

Айбикә. Әгәр сизмәгән булсам! Нәсел-нәсәбегезнең кара янган чырайларын күрмәгән булсам!

Шоңкар. Күпме самолет өйрәттем очарга, ә сине...

Айбикә. Җирдә дә, күктә дә һаман күз алдында балкыган зәңгәр күк

кыйпылчыгы мәхәббәттән көчлерәк булып чыктымы?

Шоңкар. Зәңгәр күгем кыйпылчыгы? Ул һаман да өстә, һаман биектә. Ләкин аннан өстә — Айбикә. Күктәге Айбикә синең барлык гүзәл якларыңнан ярагылган. Мин гел шуңа ашкындым бугай.

Айбикә. Җирдәгесе — затсыз, куркыныч...

Шоңкар. Ник алайса, туй өзелеп ел да тулмастан, кияүгә чыктың?

Айбикә. Үч итеп бугай. Кешесе дә синең кебегрәк тоелды. Дөресрәге, сез — капма-каршы игезәкләр. Икегез дә дөньяның иң югары серен ачарга, һич югы яңа йолдыз табарга тырышып саташкан кешеләр. Аерма шул гына, Асыл күктәге Айбикәгә караганда җирдәгесен артыграк күрде. Ул минем анам өргеннән курыкмады.

Шоңкар. Минем ана охшыйсым килмим, Айбикә, гафу ит.

Айбикә. Син дөньяның актык серен галәмгә чыгып, кул белән тотып, капшап карамакчы булсаң, Асыл аны җирдәге килеш тыңламакчы һәм адәмнәргә тәрҗемә итмәкче. Ул шундый куәтле радиоаппарат ясарга хыяллана.

Шоңкар. Ничек итеп?

Айбикә. Ул эфирдагы комачауладан курыкмый торган микродулкыннар хасыйл итүче приборлар ижат итә. Шулар аша ерак дөньялардан сигналлар килә. Син барып күрергә ашкынган мәгънәләр шулай җиргә үзләре төшә. Ул мине дә — күктән табыласы кешене җирдән таптым дип исәпли. Син — күз, ул — колак!

Шоңкар. Колак! Колак ачышлары... һәм алар күп икән, алайса?

Айбикә. Хәзергә күп түгел шул. Завод кешеләре, безгә радиоприборлар кабул ителгән модельләр буенча гына житештерү тапшырылган, ә син теләгәннәре буш хыял дип, Асылга ул эш белән шөгыльләнергә ирек бирмиләр. Производстводан тыш ул приборларны тиешле дәрәҗәдә камилләштереп булмый икән. Ә ул эш белән шөгыльләнүче махсус институтка Асыл ни сәбәп беләндер уза алмады. Хәзер исә заводның үз лабораториясе бар. Асыл шуның житәкчесе булу өчен хаклы-хаксыз көрәш башлады. Соңгы чиккә тотынды, өметсез чараларга...

Шоңкар. Мин дә аңа ярдәм итә алмыйм, нинди өлкә икәнен дә чамалап кына күз алдына китерәм. Дөресрәге, мин аның идеясен тормышка ашмас сыман тоям.

Айбикә. Ә ул киресен әйтә. Мина, Җирдән зуррак матурлык юклыгына ышанган кешегә, Асыл идеяләре якынрак һәм аңлаешлырак. Мин аның белән шуңа күрә тизрәк аңлаштым. Шоңкар, ачуланма.

Шоңкар. Ә бу телеграмма?

Айбикә (*укый*). «Чувствую себя очень плохо, нуждаюсь в твоей помощи, жду тебя, Айбикә». Нәрсә соң бу?

Шоңкар. Синең телеграммаң.

Айбикә. Юк, юк, минеке түгел.

Шоңкар. Хәзер мона ничек ышаныйм, ничек аңлыйм инде?

Айбикә. Һич башым житми.

Шоңкар. Житәр, күпме минем сабырлыкны сынарга мөмкин? Кайда, нинди киемнәр киясең? Киттек. Монымы? (*Дивандагы тунга күзе төшеп.*) Шушыны? Кара, җәй көне — тун. Нигә ул? (*Өйдәге бүтән әйберләргә күзе төшеп.*) Һәм менә бу затлы обстановка. Машинагыз да бармы?

Айбикә. Бар.

Шоңкар. Менә ничек! Менә ни өчен тиз аңлашкансыз.

Айбикә. Шоңкар!

Шоңкар. Ялгышкансың. Рәхимсез көя күбәләге икәнеңне белгән булсам, мин дә мондый шартларны тудыра алган булыр идем.

Айбикә. Шоңкар, вөждансыз!

Шоңкар. Көя күбәләге булып яшәү туйдырган кебек тоелгач, миңа телеграмма суккансың да, ә менә бу тунны күргәч, яңадан бер кат сатылгансың.

Айбикә (*исе китеп бераз утыргач*). Шушы сүзләрне әйтер өчен ничә мең чакрым җирдән кайткансың, рәхмәт, сөендердең.

Шоңкар. Себер тикле җирдән алдап чакыр да син, самолет тизлеген ашыктырып кайтар да, анда да матур җавап көт.

Айбикә. Чынлап әйтәм, Шоңкар, чакырмадым, нинди дер аңлашылмау бар монда.

Шоңкар. Аңлашылмау бар иде, хәзер бетте.

Айбикә. Төшендем, син мине тагын бер кабат харап итәргә кайткансың.

Шоңкар. Ә син мине кирәкмәгәнгә чакырып кайтарып, конфет бирәм, мә, дип, үз янына китердең дә, минем — мәңге акыл кермәс, ышанучанлыгын җиңә алмас сабыйның — яңагына чаптың. Ни өчен? Еллар буе өнемдә һәм төшемдә гел сине күреп хыялланган өченме? Телеграммаң килгәч, синсез яшәлгән көннәремне ташлап, тиле шикелле әсәрләнеп, тынымкөнем бетеп, янына кайткан өченме? Ни өчен?

Айбикә. Мин сиңа бернинди телеграмма җибәрмәдем.

Ш о ң к а р. Ышанам, ышанам, шундый да беркатлы кеше бит мин. Ләкин шунысын өстим, сүздә әллә ниләр әйтеп, әллә ниләр вәгъдә итеп, чынлыкта саф тойгылы кешеләрдән көлә торган адәмнәргә караганда, күккә алып менә торган җансыз механизмнарны һәм үзем кебек беркатлыларны мин артыграк күрәм.

А й б и к ә. Нишлисең бит, безнең кебек җир балаларында андый йөрәк юк, арифметика апа ятларга кушкан дүрт гамәлдән башканы белмибез. Өстәвенә, синең кебек тугры, саф түгелбез — хыянәт итәбез.

Ш о ң к а р *(бераз тынып торгач)*. Менә нәрсә, Айбикә, теге чакта сине ышандыра алмыйча, үземне гомерлек җәзага дучар иттем. Хәзер ул хатаны кабатлый алмыйм. Үзем табынган күкләр зәңгәрлеге белән, син табынган җир яшеллеге белән ант итәм — хәзер синсез, бәхетсез, ялгыз каз сыман каңгырып яшәмәячәкмен. Җирдә йөрүемә, күктә очуыма чик куелсын димәсәң, әйдә, киттек.

А й б и к ә. Гафу ит, Шоңкар.

Ш о ң к а р. Китмисең?

А й б и к ә. Китмим.

Ш о ң к а р. Алайса, син Асылны чынлап яратасың.

А й б и к ә. Чынлап.

Ш о ң к а р. Алайса, син мине...

А й б и к ә. Чынлап яраттым.

Ш о ң к а р. Алайса, ник, ник син мине теге чакта кичерә алмадың? Нинди сәбәп бар иде бит?

А й б и к ә. Сәбәпнең синдә икәнен сизмәгән булсам...

Ш о ң к а р. Нәрсәне сизмәсәң?

А й б и к ә. Син мине бозык каннан яралган дип, анасы табигатеннән ерак китә алмас дип, түбән азатлыкка, эшсезлеккә, җимешсезлеккә дучар булачак кеше, дип курыктың.

Ш о ң к а р. Курыкмадым, дөнья шаһит!

А й б и к ә. Ә мин шул чакта табигать әзерләгән барча аламалыкларны тәнем-йөрәгемнән йолкып ташларга, саф җанлы, чиста тәнле һәм җирдә нәрсәләрдер иҗат итәргә сәләтле кеше булырга, Асыл кебек, синең кебек үз күгем зәңгәрлеген үз кулларым белән сыйпап карарга ант иттем. Антымны боздырырга җыенган һәр адәм дошманыма әверелә килде.

Ш о ң к а р. Ә мин синең сафлыгыңа, бездән югарырак икәнлегеңә шул чакта ук ышана идем. Ә син, минем өчен уйлап, икебезне дә харап иткәнсең.

А й б и к ә. Ышанасым килә, бәлки дөресен әйтәсеңдер. Әйе, әни... Әгәр әни шундый булмаса, мин аның кызы булмасам, нәсел хәбәренең нәрсә икәнен белмәсәм, бәләкәй чуар тавык йомыркасыннан бөркет түгел, бройлер да чыкмаганын, затсыз мескен биядән тулпар туа алмаганын белмәгән булсам, йөрәктәге яшертен кимсенү җәрәхәте туктаусыз сулкылдамаса, бәлки сиңа ул чаклы рәнҗемәгән дә булыр идем.

Ш о ң к а р. Ә мин синең белән, мәхәббәтем белән горурланып яшәдем. Булды. Ниһаять, аңлаштык.

А й б и к ә. Артык соңга калып.

Ш о ң к а р. Хәзер вакыт бетте. Киттек. *(Җитәкли.)*

**Асыл керә.**

А с ы л. Монысы ни?

А й б и к ә *(Шоңкар кулыннан ычкынып)*. Асыл, акыллы бул.

А с ы л *(озак кына карап торгач)*. Менә сезне кеше дип бел, ә? Бу нәрсә дигәнне аңлата соң? Талаумы, җимерүме? Нәрсә бу? *(Беркем дә җавап бирмәгәч.)* Минемчә, караклык, дип атала бу.

А й б и к ә. Асыл, зинһар, кызма.

А с ы л. Гаҗәп тә кызык. *(Йөренә торгач, өстәлдәге телеграмманы күреп ала.)* Ә бу нәрсә?

А й б и к ә. Анысы да табышмак.

А с ы л. Табышмак. *(Телеграмманы укыгач.)* Нинди ярдәм кирәк соң сиңа?

А й б и к ә. Әйттем бит —ниндидер аңлашылмаучылык. Минем телеграмма сукканым юк.

А с ы л. Кызык, синең өчен кем суксын аны?

А й б и к ә. Җирләр, күкләр белән ант итәм, мин түгел.

Ш о ң к а р *(Асылга)*. Айбикәне сынар өчен сез үзегез җибәрмәгәнсез бит?

А с ы л. Шушы изге кулларым белән мин шундый пычрак ялган нәрсә эшләргә тиешме?

Ш о ң к а р *(Асыл бармагындагы балдакны күреп)*. Безнең барып чыкмаган туй ядкәре шушы түгелме, Айбикә? Ә?

А й б и к ә. Үзең ташлап киткән...

Ш о ң к а р. Син шул эшне эшли алдың! *(Асылга.)* Ә хәзер кайтарып бирергә вакыттыр.

А с ы л. Шоңкар, бер кулың белән йөрәгеңне суырып бирсәң, икенчесе белән балдакны алырсың. Мәгәр бүтән вакытта. Ә хәзер...

Ш о ң к а р. Мин риза. Тыныч йокы, Айбикә, борчуым өчен гафу ит.

А с ы л. Төштә сезне күрмәс, дип белегез. *(Телеграмманы Шоңкар кесәсенә сала.)*

Ш о ң к а р. Күрсә дә сезгә әйтеп тормас ул аны. *(Китә.)*

А с ы л. Нинди нахал, ә? Күзеңә төтен өрсәң дә күзен йоммас кешеләрне

күргәнем бар иде, мондыйны ук күрермен дип башка китерә алмаганмын. Оят! Ниндидер жилкуар жиде төндә өенә керсен дә хатынынны житәкләп урамга өстерәсен. Менә сина Шонкар!

Айбикә. Син бит берни белмичә... нишләп шулай дисен? Ул бит... ул... синен белән миннән чистарак.

Асыл (*кәефе китеп*). Ни-че-ек?

**Гөлбизәк кыюсыз гына чыккан да тыныч кына басып тора.**

Айбикә (*аны күреп*). Әни, әнием! (*Гөлбизәкне кочаклый*).

Гөлбизәк. Йокы мазасы бирмәдегез.

Айбикә. Нинди көн бит! Нинди генә сүзләр ишетмәдем! Тик берсенә дә ышанмыйм, мин бүген сина гына ышанам, әнием.

Гөлбизәк. Көнне жил бозар, адәмне сүз бозар. Берсенә дә бирешмә, кызым, нык бул. Тыныч булыйк, кайгырмыйк.

Айбикә. Тыныч булыйк.

Асыл. Ләкин сина, Айбикә, ул канатсыз Шонкарны ничек чакырып китермәвенне исбат итәргә туры килүе бар.

Айбикә. Канатлар хакында бүген сөйләшми торыйк, Асыл.

Асыл (*диванга утыра да тунны кысып кочаклый*). Теләсә ничек анла да, теләсән ничек түз. Һәм без түзәбез, шулай кирәк.

Айбикә. Кем үч ала миннән бу хәтле дә рәхимсез итеп?

Кем? Кемгә начарлыгым тигәне бар бу хәтле хур итеп үч алырлык? (*Гөлбизәкне кочаклап тына.*)

## Икенче картина

**Заводтагы эш урынында Асыл кәгазьләр карап утыра. Йолдыз керә.**

Йолдыз. Хәерле көн, Асыл абый. Чәчәкләрне алып кайттым — тугыз бәйләм.

Асыл. Менә рәхмәт, менә молодец. Утырып тор, сулу ал.

Әсмабикәләр генә, нишләптер, сонладылар. Самолет белән бирәр хәл булмасын тагы.

Йолдыз. Сезнен бөркеткә...

Асыл. Лачынга. Бөркет үк түгел, шулай да барыбер, күкне сөя.

Йолдыз. Лачыныгызга жык та булмас. Экспедиторын әйтсән, анысы үзеннән яман — елан төпиен кискән. Кайтырлар, Асыл абый, курыкма.

Асыл. Син кистереп әйткәч, тынычландык, эшкә күчәбез. Менә бер шәп исемлек — чәчәк бәйләмнәре санынча. Адреслары язылган. Күчтәнәчләр кайткач та, шуларны әйләнеп чыгарсын. Мин бу эшне сина гына ышанып тапшыра алам. Анладыкмы?

Йолдыз. Кемнәр сон алар, нинди изгеләр?

Асыл. Син аларны күрү бәхетенә үзен ирешәчәксен. Өйдә булмаганнарнын хатыннарына калдырырсын. Якынлашып килгән бәйрәм белән котлаучы Асыл абыен икәнен бик матур елмаюынны кушып әйтергә онытма. Анладынмы?

Йолдыз. Чәчәк арасына бәлки сезнен визитканы салырбыз?

Асыл. Баш үзендә. Шулай шул. Тик... юк, алай түгел. Телдән әйтсән, шәбрәк булыр. Күчтәнәчләргә имза куйган төсле... Яман күзләргә эләгүе бар.

Йолдыз. Үзе курка, үзе йолка. Житмәсә, шул хәтле акча түгеп.

Асыл. Дөньяда акча белән исәпләнми торган әйберләр була, Йолдыз акыллым, шуны онытма.

Йолдыз. Имза куймаслык эш булгач, гаепкә алучылар табылыр.

Асыл. Их, балакай, сабый шул әле син.

**Авызы колакларына житкән Әсмабикә керә.**

Әсмабикә. Их, батыр егетләр, их, матур кызлар, исән генә тордыгызмы?

Йолдыз. Әйттем бит әнә. Асыл абый кайгыра башлаган иде инде.

Әсмабикә. Минем өчен түгелдер, балыклар өчендер. Шулай түгелме, Асылгәрәй Асылгалиевич?

Асыл. Шулай ук түгел. Синсез булмый ул — балык та, башкасы да.

Әсмабикә. Ызначит, син мина да норка тун табып бирәсен инде, болай булгач.

Асыл. Юл уныдымы сон?

Әсмабикә. Тонна ярым белуга сырты, ике йөз килограмм севрюга, өч әржә кара икра, ике йөзәр кило судак, вобла. Бөтен эшчеләргә житмәс. Мәгәр алдынгылар, активистлар банкетына, хужаларга күнел ачарлык булыр.

Йолдыз. Жайсыз килеп чыга икән.

Әсмабикә. Асыл абыен, бәлки, сезнен туйга да өлеш чыгарыр, акыллы булсан.

Й о л д ы з. Юкны сөйләмә, Әсма апа. Безнең Тәберде андыйга бара торган түгел. Әйтсәң, җене котыра.

Ә с м а б и к ә. Асыл абыең әйткәндәй, рухи биеклеккә омтыла торган кеше икән.

Й о л д ы з. Сезнең кебек лачын түгел дә, ярый инде.

А с ы л. Йолдыз, бар, склад мөдиренә әйт, грузчиклардан үзе карап ташытсын. (*Телефонда номерлар җыя.*) Лариса Петровна үзе кирәк иде. Лариса Петровна! Сезме? Әйе, кайттылар. Шулай шул, Лариса Петровна, яз бәйрәме хөрмәтенә бераз булды. Осетрина, севрюга, семга... Әйе, кара икра да бар. Күпмешәр әзерләтик? Ярый, Лариса Петровна, кертеп бирерләр. (*Трубканы куя.*) Йолдыз, ишеттеңме? Лариса Петровнага иң башта кертеп бирерсең, яме.

Й о л д ы з. Бар икән, харап. Бер эше юк, үзе килеп алсын.

А с ы л. Директор хатынымы?

Й о л д ы з. Булмагае, патша бичәсе түгел лә.

Ә с м а б и к ә. Вәт дивана, менә әкәмәт. Шундый зур кешеләр Тәберде белән бер чиратта торсыннармыни?

Й о л д ы з. Торсыннар. Торасылары килмәсә, чиратны булдырмау чарасын күрерләр. Эшчеләр хәлен белгәч, эшләре дә әйбәтләнер.

Ә с м а б и к ә (*кычкырып көлә*). Их, сантый, их, дивана.

Тау тишегендә үскән икән бичара.

Й о л д ы з. Дөресен әйтү диваналык була икән, ә?

Ә с м а б и к ә. Соң, шулай булмыйча. Син моны бар, башта Айбикә апаңа әйт. Башта сәхнәдә уйнап күрсәтсеннәр. Ышанучы табылса, бәлки тормышка да күчә язар. (*Көлә.*) Үләрсең сезнең белән.

А с ы л. Лачын, җитте, котыртма сабыйларны. Йолдыз, эшкә керештек. Бар, исән йөр.

Й о л д ы з (*исемлекне алып*). Нормальный адәмнәргә йөреп чыгам, ә түрәләргә күз дә ташламыйм.

Ә с м а б и к ә (*исемлекне карап*). Яле, нинди әүкатьле затлар икән. Ә! Җюри членнары. Ә! Алтын бишектән төшкәннәр!

А с ы л. Уф! Җитте сезгә. Йолдыз, бар, акыллым, минем машинаны ал да...

Й о л д ы з. Теләсәгез нишләтегез, Асыл абый, ә директрисага — крысага бармыйм.

Ә с м а б и к ә. Алайса бит тагын гариза язасы була.

Й о л д ы з. Язам, бүген үк язам, ә совет кызы дигән дәрәҗәне төшермим, көтмәгез. (*Китә.*)

Ә с м а б и к ә. Бичара! Исеме Йолдыз булгач, безнең арттан күккә күтәрелмәкче.

А с ы л (*телефон трубкасын күтәргән хәлдә*). Директор өенә, лачын, синең үзеңә барырга туры килә инде. Бәлки, файдасы тияр.

Ә с м а б и к ә. Рәхмәт. Рәхәтләнеп барам. Бармаска теге.

А с ы л. Сөйләшеп тә утырган булырсың. Ә?

Ә с м а б и к ә. Артыгы белән син дигәнчә булыр. Тик онытма, Айбикәнеке төсле тун минем сөякләремне дә сындырмас, әйеме?

А с ы л. Карарбыз, карарбыз (*телефонга*). Сабир Рәхимович? Акчурин. Әйе. Безнең монда язгы бәйрәм хөрмәтенә. Әйе. Өегезгә илтеп куярбыз. Семга, севрюга, белуга...

**Тәберде керә**

Т ә б е р д е (*ике кул биреп күрешә*). Эшегез күптер инде дә... ачуланмагыз инде.

А с ы л. Нәрсә булды, Тәберде?

Ә с м а б и к ә. Норка тун, дисәң, авыз да ачма, булмый.

Т ә б е р д е. Нәкъ шул хакта. Нәрсә, Айбикә апа шалтыратты мәллә?

Ә с м а б и к ә. Сезгә түгел, пока миңа да отказ.

А с ы л. Әсма апаң бик тә шаян, исең китмәсен. Йә, сине тыңлыйк, Тәберде.

Т ә б е р д е. Шул Йолдыз аркасында инде, үзегез беләсез.

А с ы л. Мин нишли алам?

Т ә б е р д е. Сез бит начальник кеше, чарасын табыгыз инде.

А с ы л. Менә бит, бөтен кеше сүздә бик тә намуслы, эштә дисәң, һәркайсы законны узарга җай эзли.

Т ә б е р д е. Киресенчә, закон кулланырга, дим мин. Бер тәүлек эчендә теләсә нинди башсыз сатучы да дүрт йөз сумлык растрата ясый алмый бит инде. Димәк, карак бар, шуны фаш итәргә кирәк.

А с ы л. Туйга дип җыйган акчагыз бардыр ич?

Т ә б е р д е. Ике йөз сум чамасы бар анысы. Гомергә бер килә торган нәрсәне бозасы килмәгән иде шул.

Ә с м а б и к ә. Матур истәлек калсын дип, эшне судка җибәрү дә күңелле булып чыкмас бит. Олылар кинәшен тот син, энем.

Т ә б е р д е. Миңа, киңәштән бигрәк, ярдәм кирәк иде шул. Ну, Айбикә апа тырышты да...

А с ы л. Ничек тырышты? Акчасы аның да юк иде бит.

Тәберде. Ишеткәч үк кабынып китте. Караклык кебек әшәкелек сезне дә чиркандыргандыр, тиешле кешеләрне фаш итәргә сез дә ашыгырсыз дип өметләнгән идек тә...

Асыл. Гасырлар буе килгән инерцияне ашыгыч кына туктатып кара син, бар.

Тәберде. Ә сез туктатырга уйлап кына да карамагач... Шул булганчык суда үзегез дә балык тотасыздыр әле.

Әсмабикә. Тотмаска теге, дивана мәллә без? Осетра, сазан, севрюга...

Асыл. Шаяртма, намуслы кешенең ышануы бар.

Тәберде. Әсмабикәттәйнең уеныйчыны бергә аның, Асыл абый. Тик белеп торыгыз, үзегезгә дә балык бетеп бара, шул таба алып барасыз дөньяны.

Әсмабикә. Балыгы бетсә, икрасы калыр.

Асыл. Мин сине аңламыйм, Әсма ханым.

Тәберде. Аңлыйсыздыр.

Әсмабикә. Намуслы егет караклыкка чик куймакчы. Баштарак Асыл абыең да тырышып караган иде дә, акыл кергәч, кул селтәде. (*Ишектән әби кергәнен күргәч.*) Әһә, сезнең сөекле әбиегез. Әйдә, хөрмәтле гражданка, түрдән уз. Сагынганыек, ни йомыш?

Әби. Йомышыбыз тилемсә хатыннар сүзеннән дә мәгънәсезрәк түгел.

Әсмабикә. Затлы товарлар тәкъдим итәсезме? Без шундый бүлек — ит, сөт, май, йомырка тонналап кирәк. Сездә ниләр бар? Иллә мәгәр шунысын әйтеп куйыйк, үле җаннар сатып алмыйбыз, азлап та, уптым да.

Асыл. Җанны ул үзе ала.

Әсмабикә. Шушы яшен суккан агач синең әбиең булса. Анасына карап кызын коч, дигән бит китап.

Тәберде. Китап укыган кеше кебек, печтәнләп торган була тагы.

Асыл. Шуннан, әби, ни йомыш?

Әби. Шул инде. Кара икра... кайтмадымы дип килүем иде.

Әсмабикә. Сез, әби, күрмисезмени? Бу бүлмә кибет түгел.

Әби. Күпме акча түләсәм, бу тозсыз хатынны куып чыгарырга булыр икән?

Асыл. Икегезне дә көчләп тота алмыйм, берничә минуттан — киңәшмә.

Әби. Кайттымы икра?

Асыл. Юк.

Әби. Ярый, ышандык. Инде икенче йомышым. Кулыңда әнә — алтын балдак, шуны сатмассыңмы дигән идем.

Асыл. Ювилерторг минем карамакта түгел.

Әби. Мин чынлап сорыйм. Бәясеннән тормам.

Әсмабикә. Шуна житәрлек акча бармы?

Әби. Товар хуҗасы үзе сөйләшә беләдер ич.

Әсмабикә. Акчаң булса, хуҗа риза. Бир әле, Асыл, үзем бәхәс тотам — отылсам, үзем отылырмын, йә, йә, курыкма, талап ала алмас. (*Балдакны салдырып ала.*) Иллә мәгәр акчаң булмаса, шушы актык шәленне салдырам. Ризамы? Йөз илле сум чыгар, әбекәй. Юк, ике йөз тәңкә.

Әби. Хуҗаның рөхсәтен ишетмәдем...

Әсмабикә. Әйе, ике йөз тәңкә. Бу бит гади генә балдак түгел, истәлек бәясе дә бар анда. Матур истәлек. Шулай бит, Тәберде?

Тәберде. Шулай булмыйча.

Әсмабикә. Шулай. Менә балдак. Янәшәгә акчаңны куй.

Әби (*түшеннән төенчек чыгарып, өстәлгә кәгазь акчалар куя*). Исәпләп алыгыз.

Әсмабикә (*исе китеп тора*). Вәт әкәмәт, чын акчалар. Отылдык түгелме соң, Асыл, нишлибез?

Әби (*балдакны тиз эләктереп*). Өч балдак бәясенә... Чыгымламакчы, житмәсә. (*Тиз генә чыгып китә.*)

Әсмабикә. Шул хәерчедә шул хәтле акча булыр дип кем башына килгән.

Тәберде. Эшләмәгән кеше хәзер баерак була ала. Без менә әҗәткә эзлибез.

Асыл. Котырган бәягә сөенә-сөенә алып сыздымы?

Әсмабикә. Хата — минеке, өч бәясенә озаттым, гафу ит.

Асыл. Мин хәзер — өйләнмәгән егет. (*Кулын күрсәтә.*)

Әсмабикә. Истәлек дип көймә тагы. Мин сиңа шушындыйны өч минутта табам да сүзләрен дә яздырам. Ул язулы иде бугай, ә?

Асыл. «Мәхәббәтем» дип язылган иде.

Әсмабикә. Шуннан да тозсызрак сүз табылмаган икән. Җаны теләгән, жылан ите ашаган, шайтаным-бәгърем дип язмыйсызмы тагы. (*Тәбердегә күз кысып, акчаны кесәсенә сала.*) Җитмеш сумын алдым, боларын яшер. Расходлы чагын... Хуш, Асылгәрәй Асылгалиевич. Тунны онытма, тун — синнән. (*Китә.*)

Асыл. Я, Тәберде, без кайда туктадык?

Тәберде. Шул инде, хәлнең ничек икәнен төшенгәч тә Айбикә апа тиз үк ярдәм итәргә булды.

А с ы л. Ягъни? (*Кәгазьләр актара.*)

Т ә б е р д е. Кулыма теге яман тунны тоттырды да мин чаптым комиссионкага.

А с ы л. Тиләләр арасында яши торгач...

Т ә б е р д е. Тик акчасы... сатылгач кына диделәр.

А с ы л. Тиләләр арасында яшәп, үзем дә шашам бугай. Уф!

Т ә б е р д е. Дүрт йөз сумны Асыл абыеңнан сорап тор, диде Айбикә апа.

А с ы л. Тукта, норка тунны... комиссионкага дидеңме?

Т ә б е р д е. Айбикә апа кушты.

А с ы л. Җитте, көчем бетте тыңларга. Гарык иттегез. (*Кәгазьләрен өстәлгә ыргыта.*)

Т ә б е р д е. Сез дә кыза беләсез икән.

А с ы л (*бераз йөренгәч, кабат утыра*). Шулаймы? Шулай дисеңме? Ярый, әйбәт иткәнсез. Молодцы! Ләкин артык борчылмагыз, һич тә зыян юк. Һич тә борчыла торган нәрсә түгел бу. Әйе. (*Телефоннан номерлар җыя.*) Магазин? Директорны тоташтырыгызчы. Тиз, бик кирәк. Рәхмәт, көтәм.

Т ә б е р д е. Әллә чынлап та ярамаган нәрсә эшләдек инде. Бу дөньяда әллә нинди хикмәтләр бар икән.

А с ы л. Сәүдәдә төп хикмәт, Таберде энем, шул гына булачак: түбән адәмнәрне куып, шөгыльләрен компьютерга тапшыру. Машина адәмнән сафрак, хыянәтсез, урлаша белми. Аларга ахыргача ышанырга мөмкин. (*Телефонга.*) Иптәш Абдуллинмы? Акчурин бу, исәнмесез. Әйе, әйбәт, артык та шәп. Шунлыктан сезгә бүген норка тун керде. Керде, керде, яшермә. Чөнки минем хатын үзе... Әйе, Айбикә Акчурина. Әйе, артистка. Әйе, сәхнәдә генә акыллы. Әйе, җүләрләр шунда бит инде. Әйе, миннән башка. Әйе, шуны сатып җибәрә күрмәгез дип шалтыратуым. Ничек соң? Юк, юк, беркемгә сатмадыгыз, иптәш Абдуллин. Әйе, ашыга күрмәгез. Тапшырган егет үзе барып алыр. Бурычлы калмам, курыкмагыз. (*Тәбердегә.*) Бар, чап. (*Тәберде кузгалмагач.*) Ә! Акчамы? Менә, менә ала тор, калганын, тунны исән килеш кулыма тоттырсаң, юнәтербез. Бар, бөтен нәрсә рәтле безнең. Чап!

Т ә б е р д е. Бер аягым монда, икенчесе тегендә, Асыл абый. (*Китә.*)

А с ы л (*Тәберде киткәч, тагын телефонга тотына*). Ярый вакытында беләнде. (*Телефонга.*) Алло, Алексей Павлович? Сезме? Бәйрәмне ничек каршылыйсыз? Безнең сезгә хөрмәтебез бик зур. Шуның билгесе итеп, язны олылап... Бик чибәр бер кыз кертеп чыгар. Әйе, осетрина, семга, севрюга, белуга, судак, сазан, төтәсләгән корбан, икра...

## Өченче картина

**Гөлбизәк оек бәйләп утыра. Айбикә аны арка ягыннан килеп кочаклый.**

А й б и к ә. И әни, юкка бармакларыңны талдырасың да инде. Барыбер киелми рәтләп. Кыш көне чаңгы шуганда гына.

Г ө л б и з ә к. Чаңгы шуганда кигәч тә бик рәхмәт. Күршегә оек сорап керәсе булмагач, бик җиткән.

А й б и к ә. Гомер буе шулай кайгырттың. (*Пианино янына утыра.*)

Г ө л б и з ә к. Күңелеңә авыр алма, кызым, әгәр дип әйтәм, ул әниең бу өйдә каласы булса, мин иске өемә кайтып китәрмен инде. Үпкәләмәм дә, рәнҗемәм дә.

А й б и к ә. Минем әнием бер генә, ул — син. (*Пианинода уйный.*)

**Асыл кайтып керә.**

А с ы л. Булды, көчкә. Хәзер менә үз кулларым белән бүләк итәм. (*Тунны Айбикәгә кидермәкче.*)

А й б и к ә. Асыл, зинһар, кирәкми. Барыбер ул пычрак...

А с ы л. Шушы тун? Минем сумлык тун!

А й б и к ә. Йөнтәс кул кагылган аңа.

Г ө л б и з ә к. Үзең дә инде, кияү, шундый изге ниятеңә алама кешеләрне сукәлдермәсәң.

А с ы л. Карагыз, менә, бернинди бармак эзе калмаган. Тунның бернинди гаебе-гөнаһсы юк. Гомумән дә Юмарт кулның катнашы юк анда.

А й б и к ә. Ул чынлап та синекеме?

А с ы л. Минеке, берсүзсез.

А й б и к ә. Ә Йөнтәскә ни сәбәп белән...

Г ө л б и з ә к. Үзегезне мыскыл иттереп.

А с ы л. Шаярудан китте.

Г ө л б и з ә к. Үз хатыныңның белән шаярырга ирек бирсәң...

А с ы л. Өй котларга бүләксез килү җайсыз дигәч, шушы тунны тоттырган идем, бик сөенеп килде.

Айбикә. Мондый беркатлы шаяру синекечә булмаса да, ышанасы килә. Әйт, чынлап чистамы тун?

Асыл. Гөлбизәк әниебезнең саф күнеле белән ант итәм.

Айбикә. Алайса, ышандым.

Асыл. Кабул ит. (*Кидерә.*) Йә, ни әйтергә кирәк мондый чакта?

Айбикә. Рәхмәт.

Гөлбизәк. Җылы тәнеңдә тузсын.

Асыл. Инде комиссионкага илтмәссеңме?

Айбикә. Илтмәм.

Гөлбизәк. Бөтенесен бер кеше бутый ахры... Моңарчы кияү дә бик акыллы иде, син дә аңардан бик ризаканәгать иден. Яле, киеп кара әле. (*Үзе бәйли торган оекны кидерә.*)

Айбикә (*оекны да кия*). Иркәли торгач, сез мине бөтенләй бозып бетерәсез инде (*көзге янына килә*). Норка йоны белән сарык йоны шәп ярашамы?

Гөлбизәк. Сәхнәгә киеп чыгарлык.

**Алар карап торган көзгедә әби сурәте пәйда була.**

Айбикә (*куркып*). Ай!

**Гөлбизәк ишек катында торган әбигә кызганып та, нәфрәтләнеп тә карап торгач, кул эшен алып, бүтән бүлмәгә чыкмакчы була.**

Әби (*аның юлын бүлеп*). Апа, чак кына туктап тор әле. (*Гөлбизәк туктаса да эндәшми.*) Синең, туганый апа, чак кына да туганлык хисең юкмыни?

Асыл. Менә нәрсә, әби...

Әби. Курыкмагыз, тотып ашамам. (*Гөлбизәккә.*) Син бердәнбер шаһит, әйт, мин кем?

Гөлбизәк. Үзең дә белмәгәнне мин каян белим?

Әби. Беләсең, бик шәп беләсең, таныйсың да син мине. Без синең белән туганнан туган кардәшләр, бер генә яшькә син миннән олырак. Хәтерләмисеңмени, танымыйсыңмыни?

Гөлбизәк. Юлдан язган туганнарым юк, аллага шөкер.

Әби. Син — бердәнбер шаһит, әйт минем кызыма.

Гөлбизәк. Минем кызым үзе бәлигъ. (*Китә.*)

Асыл. Миңа вакыт, Айбикә, эш муеннан. (*Әбигә.*) Ну, безнең вакыт бетте.

Әби. Курыкма, хатыныңны ашамам, китә тор.

Асыл. Айбикә, курыкмыйсыңмы?

Айбикә. Әни өйдә бит.

Асыл. Кагылса, кычкыр. Йә! (*Хатынын үбә дә чыгып китә.*)

Әби. Мин шулчаклы куркыныч кеше булып чыктыммыни?

Айбикә. Үзегез сизмисезме?

Әби. Мин — синең киләчәгең.

Айбикә. Әгәр бүген шуңа ышансам, иртәгә үземне җир йөзеннән юк итәр идем.

Әби. Анам үлгән дип ялгышасың. Мин син исәндә үлә алмыйм. Мин — синең каныңда, җаныңда. Синең кыяфәт белән мин яшәп ятам, синең тавыш, синең сүзләр белән әйтәсе килгән сүзләремне халыкка сәхнәдән кычкырам, барып чыкмаган мәхәббәтемне, бәхетемне даулыйм, төннәремдә, бөтен кешеләр йоклаганда, бөтен кешеләр генә түгел, бөтен Табигать йокыга талгач, синең кайнар кан агышың төсле, синең йөрәк тибешең белән бергә, мин үземнең яшәвем хакында дөньяга аваз салам. Һәм менә мин исән, синең тормышыңда.

Айбикә. Моннан егерме ел элек килгән булсаң, бәлки танып да идем.

Әби. Ул чакта бигрәк тә танымас идең, чөнки бит мин анда үземә бигрәк тә охшамаган идем. Әни дип эндәшү харам иде. Юк, син мине гаепләргә, тиргәргә ашыкма. Гаепләү иң ансат эш. Аңларга тырышып кара.

Айбикә. Әз генә дә белмәгән кешене ничек аңларга мөмкин?

Әби. Шуңа күрә сөйлим дә бит. Үз хакыңда бөтенесен беләсең килсә, атаңанаң кем икәнне яхшы бел. Әтиең дәрәҗәле кеше иде. Ләкин ул сине танымады, тормышын минем белән бәйләмәде.

Айбикә. Һәм син, яңа кешеләр эзләп, кулдан-кулга күчтең. Балаң комачау иде, апаңа ташлап киттең. Хәзер сорап килгәнсең — артык соң түгелме?

Әби. Мин сине ташламадым. Балага начар йогынты ясыйсың, дип, күрше-тирә бергәләп, сине миннән тартып алдылар. Ә мин аларга ачулана алмадым. Хәлемнең ниндилеген чамалыйм, ләкин адәм кыяфәтенә кайтырлык көч табалмыйм.

Айбикә. Нәкъ мин белгәнчә! Һәм шул кан миндә!

Әби. Шуннан соң сине күрми түзәр өчен башка шәһәргә күчеп киттем. Апаңнар шул чакта сиңа мине җирләдек дип әйтергә булдылар. Хәзер син бәлигъ. Бөтенесен үзең хәл итә аласың. Менә күр, мин кайттым.

Айбикә. Нинди максат белән?

Әби. Үземнең егерме ел кылган гөнаһларымны җиңеләйтер өчен, синең бердәнбер хатаңны төзәтергә ярдәм итәр өчен.

Айбикә. Минем? Нинди хатам?

Әби. Асыл сине иң изге нәрсәләргә хыянәт иттермәкче, минем кыяфәткә кертмәкче була.

Айбикә. Анның миндә бер үче дә юк.

Әби. Ул үчләшеп түгел, хәтта яратып, хәтта үзе дә белмичә...

Айбикә. Ә син моны каян беләсең?

Әби. Асылны беләм. Барлык туган-тумачалары, бергә эшләгән иптәшләре аша. Үзем дә күзәттем. Асыл — синең бәхетең түгел. Шоңкар — чын кеше. Сине хәтерләтеп торсын дип, мине үз өенә алды. Мәҗбүриләп, шифаханәгә салды. Хәзер бергә торабыз. Нинди кешене ташлап хата ясагансың. Шуны төзәтергә кирәк.

Айбикә. Мин Асылны яратып чыктым.

Әби. Яратмадың. Яратам дип үзеңне ышандырырга тырыштың. Мин шулай тоям. Миндә бит ана йөрәге.

Айбикә. Ана!

Әби. Ышанмыйсың!

Айбикә. Ышанмыйм да, документларыңны да тикшерәсем килми.

Әби. Паспортым кунакханәдә. Бердәнбер шаһитем — Гөлбизәк. Ул минем кемлегемне сиңа әйтми. Инде үземне бернинди кәгазьсез дә ана итеп таныта алсам гына хатам төзәлгәнгә исәпләнер. Үзең уйлап хәл ит.

Айбикә. Бөтен нәрсә егерме ел элек хәл ителгән. Хәзер бүтән төрле уйга сәбәп юк, әби.

Әби. Бар сәбәп. (*Кесәсеннән балдак чыгара.*) Менә ул.

Айбикә. Балдак? Каян алдың аны? (*Балдакны ала.*)

Әби. Язуын кара.

Айбикә. Таныйм. Ә нишләп ул синдә? Урладыңмы?

Әби. Их, бала, бала. Сатып алдым.

Айбикә. Сатып? Мөмкин түгел!

Әби. Коточкыч бәясе булгач, ирең каршы килмәде, сатты.

Айбикә. Ялган! Син аны урлагансың!

**Айбикәнең кычкыруын ишетеп, Гөлбизәк чыга. Башта читтән генә карап тора.**

Әби. Анаңа шундый сүз әйткән өчен үкенерсең бер заман.

Айбикә. Бөек исемгә башта лаек булырга кирәк.

Әби. Монысы — киләчәк эше. Ә балдак — синеке. Икенче тапкыр кем белән балдак кияргә яраганын онытма, ялгышма.

Гөлбизәк. Әйтәм бит, хәерлегә түгел, әйтәм бит, балаларның менә диген көйле тормышларын җимерергә кайткан ул өрәк.

**Айбикә балдакны карап үрсәләнеп йөри.**

Гөлбизәк. Җирбит, хәзер үк олак, моңарчы кайда йөрсәң, шунда. Хәзер үк.

Әби. Бердәнбер апам! Шаһит булыр кеше!

Гөлбизәк. Шайтанның шаһите юк. Битең-чыраеңны калдырмыйм хәзер. (*Әбине ишек төбенә хәтле кысрыклап китерә.*)

Әби. Үкенерсең, апа, соң булыр. (*Китә.*)

Айбикә. Асыл! Менә нинди анның мәхәббәте! Менә анның — кадерләве! Инде мин ничек итеп җавап кайтарырга тиеш икән? Минем уйнаячак соңгы ролем язмыш эше түгел микән? (*Кулына дәфтәр тотып, укый.*) Дөнья — базар, сатыла барысы, барысы. Җир сатыла, ил сатыла — түлә хакын. (*Бераз уйлангач*). Әни, дөресен генә әйт әле, син теге кара әбине таныдың бит? Ул өрәк кенә түгел, тере кеше. Һәм ул мине һаман үз тормышына өстери, яхшы ният белән гәрчә.

Гөлбизәк. Минем дә күзләрем күрә, гөнаһ шомлыгы. Сине ятим итә алмады, инде бәхетсез итмәсен, дип куркам.

Айбикә. Курыкма, әнием, мин инде үзем исәйгән, көче җитмәс. Ярый, бетте. (*Укый.*) Дөнья — базар, сатыла барысы...

**Звонок. Гөлбизәк ишек ача. Төберде белән Йолдыз керә.**

Айбикә. Ах, сез икәнсез...

Йолдыз. Айбикә апа, мине котла, балачак хыялы белән хушлаштым.

Айбикә. Хушлаштың? Шулай тиз?

Йолдыз. Булды инде, Айбикә апа, төзелешкә күчәм, Төберде янына.

Төберде. Тормыш балачак проектларына төзәтмә кертә.

Айбикә. Тормыш, тормыш... Гомерлеккә китә торган ялгышлар була, берничек тә төзәтә алмыйсың. Сезнең барысы да алда, чын кешегезне тапкан...

Йолдыз. Ә сезнең? Табылмаганмыни?

Айбикә. Акланмады минем ышанычлар. Бөтенләй юк кешегә адресланган хат шикелле, иясез балдак төсле, кире үземә кайта.

Гөлбизәк. Мин берәр нәрсә әзерлим әле, кунаклар да булгач. (*Кухняга китә.*)

Тəберде. Нахальный йөргəн кеше кунак булмый ул, Гөлбизəк апа.

Айбикə. Минə ул — мəхəббəт дигəнем. (*Балдакны күрсəтə.*)

Йолдыз. Ə, балдак! Безнең һаман тапканыбыз юк əле. Асыл абый аркылы алдырыйм дигəн идем. Тəберде якын да китерми.

Тəберде. Изге нəрсəне блаттан башлап булмый бит инде.

Айбикə. Акыллы егет син, Тəберде.

Йолдыз. Акыллы кеше дөреслек эзлəп йөриме? Əсмабикə апа əйтə...

Айбикə. Ничек башланса, шулай китə икəн ул. Минə безнеке төгəллəнеп килə. Туйның ядкəрен үк сатып җибəргəннəр. Тик бəясен генə белмим əле.

Йолдыз. И Асыл абый, мескенкəем.

Тəберде. Кара, нидер язылган... Без дə яздырырбыз микəн?

Йолдыз. Сатмаслык булсаң.

Тəберде (*тəрəзəдəн карап*). Сезнең бакчада Əҗəл əби һаман йөри.

Айбикə. Əҗəл əби һəр йорт тирəсендə йөри инде ул. Бүтəн җирдə күзгə генə күренми. Ə безнеке — күзгə күренеп...

Йолдыз. Йөрсə йөрсен лə. Без сине, Айикə апа, туй мəҗлесенə чакырмакчы булып килгəн идек.

Тəберде. Минə, рəхим итегез (*открытка бирə*). Асыл абый белəн икəүлəп.

Айбикə. Белмим шул, белмим, барыр микəн?

Йолдыз. Ныклап чакырдылар, диярсең.

Айбикə. Шонкар да барса?

Йолдыз. Андый ук дəрəҗəле кеше килмəс шул.

Тəберде. Үзегез карагыз, Айбикə апа, безнең өй иркен.

Айбикə. Бəхетле дə инде сез, күңлəшəм дə инде.

Йолдыз. Безнең шул гына иде йомыш, исəн булып тор, Айбикə апа.

Айбикə. Ярый, сау булыгыз. Рəхмəт чакыруыгызга. (*Тəберде белəн Йолдыз киткəч, тагын укый башлый.*)

*Сатыла милкəт — акча кирəк, кирəк алтын,*
*Дөнья базар, сатыла барысы, барысы, барысы.*
*Өй сатыла, җир сатыла — түлə хакын.*
*Алчы сарык, алчы сыер, алчы ялчы.*
*Булсын гына алучысы — сатам атым,*
*Булсын гына алучысы — сатыла хатын!*
*Дөнья — базар, сатыла барысы, барысы, барысы...*
*Хəзер шаулап миңа кул чап, тамашачы.*

**Айбикə сөйлəгəндə, Асыл тыңлап торган.**

Асыл (*Айбикə туктагач*). Бигрəк усал роль биргəннəр икəн.

Айбикə. Һəм бик тиешле вакытында. «Дөнья — базар, сатыла барысы...»

Асыл. Минем карыным ачты.

Айбикə. Булсын гына алучысы, сатам атым...

Асыл. Мондый да усал роль уйнаганың юк иде. Синең өчен бу сəеррəк.

Айбикə. Дөрес, бу рольне миңа бирмəделəр.

Асыл. Ə кемгə бирделəр?

Айбикə. Сиңа. Һəм син аны минə дигəн итеп башкарачаксың, синең амплуа. Дөрес, кайбер предмет исемнəрен алмаштырырга туры килер. Əйтик, сыер урынына — балдак, ат урынына — мəхəббəт.

Асыл. Нəрсə, мин мəхəббəт белəн сату итəммени?

Айбикə. Ə бу соң менə — нəрсə? (*Уч төбендə — балдак.*)

Асыл. Ə! Нишлəп əле ул синдə?

Айбикə. Бер егет бүлəк итте.

Асыл. Шонкармы?

Айбикə. Кемгə саткан идең соң?

Асыл. Əллə Əҗəл əбигə, əллə Шонкарга. Үзем дə сизми калдым.

Айбикə. Сатканлыгың шул, саткансың.

Асыл. Сатса да берни югалмаган. Минə нинди тагын бар. (*Шундый ук балдак күрсəтə.*) Нинди аерма?

Айбикə. Сиңа — барыбер.

Асыл. Кызык кына — ике балдак, бер мəхəббəт.

Айбикə. Шулкадəр кызык, елыйсылар килə.

Асыл. Артык нечкəреп китмə, күк җимерелерлек гөнаһ юк монда.

Айбикə. Аңа бөтенесе җинел — саттым, алдым.

Асыл. Нишлисең бит, дөнья шулай корылган — бер нəрсə дə бушка бирелми.

Айбикə. Əнə Йолдыз белəн Тəберде бүтəнчə уйлыйлар, бүтəнчə яшилəр.

Асыл. Көймəлəре комга терəлгəнче. Башта мин дə шулай яшəмəкче идем.

Айбикə. Осетра, семга, севрюга... Агай-эне ак мыек...

Асыл. Бер нəрсə дə бушка бирелми.

Айбикə. Директор хатынының елмаюы да.

Асыл. Хəтта чибəр хатыннарның көмеш төсле челтерəп көлүлəре алтын бəясе тора.

Айбикә. Зурладың безнең халыкны, рәхмәт инде.

Асыл. Син миңа үзеңә кара: бушка гына эләкмәдең бит син миңа. Шактый кыйбатка төштең. Спектакльләр беткән саен, башта сине әр-яңа «Жигули» көтеп торса, соңынтын зәп-зәңгәр «Волга» каршы ала торган булды. Шул ук вакытта мин синең сафлык һәм азгынлык турындагы бәйләнчек идея белән газап чигүеңне, җаныңның шул комплекс белән тимерәүләнеп беткәнен тиз төшенеп, хәлеңә керә килдем — бозыклыкка өстерәмәдем, чын сәламәт тормышка алып киттем. Елмаю, иркәләүне дә, сандугачлы таңнарны да күбрәк һәм матуррак күрергә мөмкинлекләр тудырдым, кибетләрдә сәгатьләр буе чират торырга мәҗбүр итмәдем. Синең йөрәгеңнән килгән якты җылылык өчен кем сиңа миннән артык түли алды? Әйе, беркем дә. Әйе, мин барлык ачык авызларга караганда күбрәк сарыф иттем һәм шул бәягә мәхәббәтеңне сатып алдым. Матур яңгырамыймы? Ләкин ялган матурлыкка төрмичә әйткәндә, мәгънәсе шул аның.

Айбикә. Күпме уйланып баш җитмәгән нәрсәне ачтың да бирдең. Шулай икән шул. Шоңкар хаклы икән, сатылганмын икән, сатылганмын. Ә мин, сиңа бернинди исәпләрсез яратып чыктым, дип йөргән идем.

Асыл. Әйе, кыяфәтең фәрештәнеке булса да, чынлыкта син дә бөтенләй үк фәрештә түгел идең — осетра, семга, севрюга да күзләрең гүзәллеген балкытып җибәрә иде.

Айбикә. Көя күбәләге! Менә кем икәнмен? Менә кем! Ә мин җүләр үземне әллә нинди яшел һәм зәңгәр төсләр белән мавыгучы тиле дип күз алдына китереп йөргәнмен.

Асыл. Бу дөньяда мәхәббәт кенә түгел, хәтта йөрәк үзе дә сатыла. Шундый заманга кердек.

Айбикә. Матуррак әкият сөйлә, бәлки ышанырмын.

Асыл. Әкият безнең заманда көчен җуйды. Бүген кешә ышанмаслык хыял иртәгә ертык чалбарга әйләнә. Дөньяга киңрәк карасаң, хәзер изге дигән йолдызлар да сатыла башлады. Әйе, әйе, бүген мин шуларны сатып алу белән шөгыльләндем.

Айбикә. Нәрсәләр ишетәм! Өнемме соң, төшемме?!

**Ишек төбендә Әби басып тора.**

Асыл. Дөньяда үлем генә бушка бүләк ителә.

Айбикә. Нинди кеше белән бер өйдә яшәгәнмен!

Әби. Ялгышасың, аның кыяфәте генә кешенеке, ә үзе...

Асыл. Үзе чынында синең төсле үк...

Әби. Минем төсле үк өрәк.

## Дүртенче картина

**Туй. Мәҗлеснең кызган чагы. Җыр, музыка. Өй янындагы бакчага Асыл ял итәргә чыккан. Зур тәрәзә аркылы кешеләрнең шәүләләре бии һәм өйдән аермачык булып сүзләр ишетелә.**

Тавышлар. Айбикә чыксын! Айбикә берәр роль уйнап күрсәтсен. Үзеңнең иң яраткан ролең.

Айбикә. Иң ятраканын бүген булдыра алмам. Иң яңасын дисәгез...

Тавышлар. Иң яңасын! Иң яңасын бигрәк тә шәп. Тыңлыйбыз!

Айбикә. Сүзсез генә торса да миңа партнер кирәк булачак.

Тавышлар. Анысын үзегез сайлагыз. Тыңлыйбыз!

Айбикә. Алайса менә болай. (*Бераз гына тынлыктан соң сөйли башлый.*)

*Галәм шаһит, ирем — беркайчан да*
*Булмаганча кырыс һәм усал.*
*Синең белән икәү бер булмәдә*
*Калганны ул сизсә, бел, ышан.*
*Шундый шаулы, шундый могҗизалы*
*Көлке-кәмит куяр ул ясап.*
*Тик сценарийны без үзебез язсак,*
*Һәм рольләрне дөрес уйнасак.*
*Яңа алмас безгә андый ызгыш.*
*Шундый тамашага герой итеп*
*Чакырдым мин сине. (Шоңкар алдына килеп баса.)*
*Сынатмаска тырыш.*

Әсмабикә (*түгәрәк әйләнеп уза*).
Кызык, бик тә кызык.
Шоңкар.
Бара торгач, мин актер да булдым.
Тик сүзләрен белмим.
Асыл.
Шоңкардан бигрәк, ул мине
сынамакчы.
Айбикә.
Икенче кат югалтсам мин сине,
Ай күренмәс, кояш та сүнәр.

Шоңкар.
Ә мин тагын эзлим сүзләр.
Айбикә.
Икенче кат син югалтсаң мине...
Шоңкар.
Бу роль генә түгел, хак кәмит.
Вөждан белән сөю низаглаша,
Шул да ләкин бәхет икән бит.
Айбикә.
Син янымда булсаң, җәзалар да
Бәйрәм генә. Һәм мин шат шуңа.
Шоңкар.
Бәйрәмчә тик уйный-көлә белмим,
Мәзәк катыш яшерен сер чыга.
Айбикә.
Ни булса да аерма юк һич тә:
Чынлап сөйсәң, син жиде кат күккә
Үзең белән мине дә алып кит.
Мин яратам сине, алла шаһит.
Алып кит! (*Шоңкар күкрәгенә сыена һәм бераздан, аны җитәкләгән хәлдә, мәҗлескә баш ия.*)

Әсмабикә. Кызык, бик тә, бик тә кызык.

Асыл (*агач төбенә утырып*). Уйнаган, көлгән була халык. Яшим дигән була, ә бөтенесе, бер уйласаң, аквариумдагы балык. Өстән караганда, җир үзе дә шулай күренәдер. Җир дигән нәрсәне, тормыш дигән нәрсәне нинди булса кодрәт елмаеп-көлеп күзәтәдер. (*Залга кереп, Айбикә каршына баса.*) Шуннан, минем инсафлы һәм изге хатыным, бу ни дигән әсәр булды? Ачыклавыңны үтенәм.

Айбикә. Үзең күреп тормадыңмыни?

Асыл. Ачыклавыңны таләп итәм — халык каршында, югыйсә син алар алдында хыянәтче хатын төсле тоеласың бит. Ә син күгәрчендәй саф, синең кемлегеңне белмичә, бу кешеләр минем синең битенә төкерүемне теләп, тын да алмый көтәләр. Синең мавыгучан кеше икәнеңне, чын артистка икәнеңне аңламыйча, әчтән генә барысы да аптырау катыш мыскыллыйлар. Кабатлап әйтәм, синең күңелдә энә очы хәтле дә кер әсәре юк. Син — артистка, гаебең шунда гына. Үзеңне онытып, сәхнәдә дип белеп, гүзәл номер күрсәтеп ташладың. Шулай бит?

Айбикә (*каушап*). Шулай. Кунаклар соравы белән.

Асыл. Рәхмәт. (*Шоңкар янына килә.*) Сезнең исемегез — Шоңкар. Ләкин ул сезгә ялгыш кушылган кебек. Нигә дисәң, беренчедән, чит-ят кеше утарында буталанган кошны бүтәнчәрәк атыйлар. Икенчедән, мавыгып киткән артистканың изге ижат ялтыравын, илһам шәфагын үзегез чөйгән фейерверк дип белеп, тарихи хата ясадыгыз, геройны артык та беркатлы итеп тасвирладыгыз. Өченчедән, бу сезнең түгыз түгел. Менә шушы яшь егет белән кыз өлешенә кул сузган өчен сез алардан һәм уеннан узыбрак киткән өчен бәлки әле миннән дә гафу үтенерсез.

Шоңкар. Айбикә — минем балачак дустым. Сезгә тормышка чыккан өчен генә ул минем белән сөйләшмәскә, аралашмаска ук тиешмени? Шулай булса, гафу итегез.

Асыл. Яшь чакта мондый уеннар килешсә дә, зурайгач әшәкелек төсле тоела.

Шоңкар. Айбикә башкарган тыйнак уенга тамашачы болай ук тәэсирләнеп дикъкать итмәс төсле тоеп, ялгышканмын икән. Гафу итегез. Гафу ит, Йолдыз, гафу ит, Тәберде. Миннән бүтән сүз көтелмиме? Сез ризамы шуңа?

Тәберде. Менә кәмит. Юк, көтелми бүтән сүз, бөтенесе әйбәт.

Йолдыз. Мин дә шулай дип белә.

Асыл (*Айбикәгә*). Ә без киттек. (*Шоңкар яныннан узышлый тагын туктала.*) Минем сезгә кечкенә генә сүзем калды.

Шоңкар. Шулай укмыни?

Асыл. Менә шушындый чакта сынала ир кешенең зирәклеге. Ара өзүнең тиешле формасын табарга тиеш булырбыз. Минем тәкъдимем, бәлки үтенечем булыр.

Шоңкар. Мин тыңларга әзер.

Асыл. Эшкә зыян китермәс өчен, иртәгә кичке алтыларда килсәгез, Айбикә каршы килмәс дип уйлыйм. Шулай бит?

Айбикә (*ургаләп*). Китик, зинһар!

Асыл. Ирләр теленә күчерсәк, бу «мин риза» дигән сүз була.

Шоңкар. Ачуланма, Айбикә, исән бул.

**Мәҗлес шаулап кала. Айбикә белән Асыл китәләр.**

## Бишенче картина

**Өйдә авыр сүзсезлек. Асыл аптырап йөренә. Аквариум янына килеп, балыкларга жим сала.**

Асыл. Гаилә бәхетебезнең телсез шаһитләре. Әгәр телегез булса, бу минутларда ни әйтер идегез икән?

Айбикә (*тынлыктан соң*). Сөйлә-

шә белсәләр, аптыраудан яңадан телсез калырлар иде.

Асыл. Балыклар, балыклар. Кара әле, уылдыклардан яралган вак балыклар да бар иде түгелме соң? Кайда соң алар?

Айбикә. Үзең тап инде.

Асыл. Ничек табыйм, юкка чыккан бит балык балалары.

Айбикә. Үлделәр микән? (*Якын килә.*)

Асыл. Үлде ди... Бөтенләй юк бит. Олылары ашаган. Аерып куярга баш җитмәгән.

Айбикә. Үз балаларын!

Асыл. Әйе шул, өнсез-телсез юаш балыклар да хәтта үз балаларын тотып ашар дип кем уйласын?

Айбикә. Менә сиңа балыклар. Кешеләргә ни кала инде?

Асыл. Кешеләр элек сиздерми ашыйлар иде. Хәзер исә көпә-көндез — үзеңнең йотылганыңны абайламый да каласың. Кем җәһәтрәк, шул йота. Менә сиңа аквариум.

Айбикә. Тын океан!

Асыл. Менә шуны төшенгәнгә күрә бүтәнчә яши башладым да инде мин. Юк ул иман дигән нәрсә, юк ул изгелек — беркемдә һәм беркайда. Исән каласың килсә, көчле бул. Йота бел. Әйе, океан бу тормыш. Шундый бушлыкта берүзем! Хәтта син, хәтта син хыянәт иткәч, миңа нәрсәгә, кемгә исәп тотарга кала? Бөтен галәм каршында бит мин берүзем калдым!

Айбикә. Гафу ит, Асыл.

Асыл. Гафу? Нәрсә өчен?

Айбикә. Кичәгe хәл өчен.

Асыл. Кичәге хәл? Хәмер пары катнашкан тилелек өчен гафу үтенмәскә була. Анда бернинди җитди мәгънә юк иде, сез уйнадыгыз гына. Уңышлы дип булмый, әлбәттә.

Айбикә. Бар иде мәгънә, гафу ит. Тыштан караганда, уен гына булса да, күңелем белән уйный алмадым, чын иде хисләрем. Шулай булгач... гафу ит, Асыл.

Асыл. Син минем эшемә хыянәт иттең. Ә кичәге... анысы (*Айбикәне сак кына диванга утырта да аның аркасына бүләк тунны сала*). Минем сиңа энә очы хәтле дә ачуым калмаячак, Айбикә, әгәр дә...

Айбикә. Сизмәдеңмени соң?!

Асыл. Сиздем дә, күрдем дә. Иң мөһиме, аңладым. Сез, әлбәттә, чын хисләр алмаштыгыз.

Айбикә. Әйе, син мине кичер... Ир белән торган хәлдә шул эшкә бара алганым өчен үземне күралмыйм. Коткар син мине, арындыр шул чирканыч тойгыдан, кичер мине!

Асыл. Мин сиңа ачулана алмыйм, Айбикә, юк андый көч сиңа карата. Үзем кечкенә булсам да, мәхәббәтем бөек.

Айбикә. Минем шуңа ышанасым килә, кичер...

Асыл. Аңа хәтле кечкенә үтенечем бар.

Айбикә. Әйт, Асыл, нинди үтенеч ул?

Асыл. Үтәрсеңме соң?

Айбикә. Үтәрмен.

Асыл. Хәзер тыңла, Айбикә.

Айбикә. Тыңлыйм, Асыл.

Асыл. Беренчедән, бүген үк барып, Юмарт кулдан гафу үтенергә кирәк.

Айбикә. Ул эшләгән кабәхәтлек өченме?

Асыл. Шулай кирәк булганы өчен. Ну, үтенмәсәң, үзең кара. Тик син аның белән килешергә тиеш.

Айбикә. Килешү хакына аның нәрсә таләп итәчәген син инде беләсең.

Асыл. Белмим. Анысы бүген миңа кирәкми.

Айбикә (*янаулы рәвештә*). А-сыыл! Си-и-ин! (*Тунны диванга ыргыта.*)

Асыл. Соңыннан терсәкне тешләргә азапланып, ычкынган бәхеткә уфтанмас өчен шулай кирәк. Бүтән мин сиңа мондый авыр эш кушмам. Булдымы шулай? Ник эндәшмисең?

Айбикә. Вакытлыча гына еланнар булып сөйрәлик тә, аннан соң аккошларга әйләнербез. (*Асыл каршына килеп баса.*)

Асыл. Чынлап изге булырбыз. Аннан соң бары тик намуслы эшләр генә калыр. Монысы шулай. Килештек. Икенчедән, Шоңкар белән дә сөйләш. Ул — үзәктә депутат. Монда да сүзе үтәргә тиеш. Югарырак иптәшләр белән сөйләшеп, жюри председателенә шалтыраттырса, май өстенә бал гына булачак.

Айбикә. Шулаймы? Бүтән сүзең юкмы?

Асыл. Җюриның барлык кешеләре белән мин үзем болай сәламләштем. Берсе теләмәсә, икенчесе аңлар. Мәгәр председатель хәл итәчәк.

Айбикә. Колакларым, сез ялгыш ишетәсез, колакларым!

Асыл. Мин үтенәм.

Айбикә. Шул бәрабәргә хыянәт тә гафу ителә алачак.

Асыл. Үтенәм!

Айбикә. Менә рәхмәт. Менә кайчан бөтенесе берьюлы аңлашылды. Йолдызларга омтылучы! Менә ул! Кемнән гафу үтенәм бит! Йокылардан калып кем өчен газап чигәм, шушы кешене кимсеттем дип, үземне күралмас дә-

рәҗәгә житәм. Менә хәзер бетте дә — пәрдә төште.

Асыл. Бер дә юкка күтәрелеп бәреләсең. Дөнья бу...

Айбикә. Бөтенесе ачык: син мине икеләтә сатмакчы, өчләтә. Менә ни өчен өйгә кайткач тавыш күптәрмәгансың. (*Туфны күтәреп яңадан урынына ташлый.*) Моны да ни өчен Йөнтәс кул исеменнән бүләк иттергәнең ачыкланды — тун бәясенә башта мин аңа сатыларга тиеш булганмын. Эндәшмә, барыбер җавабың юк. Юк!

Асыл. Дөньяда бер нәрсә дә... (*Шоңкар белән Әби кергәч, тыйлыга.*)

Шоңкар (*бераз аптырап торгач*). Мөмкинме соң?

Әби. Кәефең киткән димме соң, кызым? (*Айбикә эндәшмәгәч.*) Ни булды?

Шоңкар (*Асылга*). Сезнең миңа сүзегез бар иде, тыңлыйм.

Асыл. Кире уйладым, хәзер бер сүзем дә юк.

Шоңкар. Алайса, ара өзек. (*Айбикә янына килә.*) Мин синең белән вакытлыча саубуллашырга дип килдем, Айбикә. Йә, исән булып тор инде.

Әби (*Айбикә эндәшмәгәч*). Шоңкар ерак сәфәргә китә.

Айбикә. Кая?

Шоңкар. Яңа машина сынарга.

Әби. Күреп торам, Айбикәне бу кеше белән калдырырга ярамас.

Асыл. Бу кеше нишләгән? Мин бит беркемгә дә хыянәт итмәгән. Ә син, хөрмәтле әби...

Әби. Әллә мин хыянәт иткәнме?

Асыл. Ана өч яшьлек баласын шушы катлаулы тормыш белән күзгә-күз калдырып кача икән, сезнеңчә, ничек дип атала торгандыр бу, ә безнеңчә...

Әби. Шул гаебемне төзәтеп йөрүем.

Асыл. Айбикә исеменнән Шоңкарга: «Мин синсез тора алмыйм, тизрәк кайт!» — дип телеграмма сугу белән генә төзәтерлек хата булгач, бигрәк тә юк икән гонаһларың.

Шоңкар. Нәрсә, телеграмманы син җибәргән идең әллә?

Айбикә. Кем сораган иде, әби!

Әби. Синең нинди уйлар белән яшәвеңне аңлагач, Асылның кем икәнлеге беленгәч... шулай тиеш таптым.

Шоңкар. Мин сиңа ачуланмыйм, әби.

Әби. Ә син, кызым?

Айбикә. Шоңкар, син тагын китәсеңмени?

Шоңкар. Әйе, минем вакыт бетте, Айбикә. Ниһаять, соңгы сүзеңне ишетәсем килә. Хәзер инде, бөтенесе ачыклангач, син ризалашырга тиеш минем белән китәргә.

Айбикә. Шушы хәлдә? Берне ташлап икенчегә? Алайса, минем гомерлек көрәшемнән нинди генә мәгънә кала?

Шоңкар. Бу очышка белеп китәсем килә. Сине үземнеке итеп күрәсем. Зәңгәр күгем кыйпылчыгы җирдә калганлыкка ышанып очасым килә.

Айбикә. Инде син дә гомерлек җәрәхәтемә кагыласың. Барыгыз да мине кеше булу хокукыннан, сафлыкка булган хокукымнан мәхрүм итмәкче. Барыгыз да — Асыл да, бу әби дә, ниһаять, Шоңкар, син дә. Белегез, бүгеннән, менә шушы минуттан башлап, барыгыз белән дә араны өзәм. Берегезне дә белмим, танымыйм.

Шоңкар. Аңладым, Айбикә. Инде хуш.

Айбикә. Ничек? Китәсең? Шоңкар!

Шоңкар. Хуш. (*Китә башлый.*)

Айбикә. Тукта! (*Шоңкар туктагач.*) Сиңа... Әйе, бу — синеке. Син аны теге чакта ук тиешле бәя түләп алган идең. Үзенә кайтарам. (*Балдакны Шоңкарга бирә.*)

Шоңкар. Әгәр дөрес аңласам, мин сиңа рәхмәт әйтергә тиештер.

Асыл. Хәзер үк кире ал.

Айбикә (*Асылга*). Синең анда хакың юк.

Әби. Акчасын үз кулым белән бирдем, Шоңкардан әҗәткә алып.

Шоңкар. Үзем исәндә мин моннан аерылмам, аерылсам, исән булмам.

Айбикә (*Асылга*). Монысы — синеке. Күрәсең, син дә өлешсез калмадың. (*Кулындагы балдагын салып, Асылга бирә.*)

Асыл (*уч төбендәге балдакка карап*). Шулай укмыни инде? Азатлыкка чыктыкмыни?

Шоңкар. Хуш, Айбикә!

Айбикә. Хуш.

**Шоңкар белән әби китә. Өйдә авыр тынлык. Тәрәзәдән жил елавы ишетелә.**

Асыл. Ничәмә ел кем өчен яшәдем, күпме көчләремне корбан иттем! Бозык, бозык хатын өчен!

Айбикә (*диванга бөгелеп төшә*). Әнием, Гөлбизәк әнием, нишләп син минем янда түгел? Җинелдекмени?! (*Елый.*) Җинелдекмени?!

**Төенчекләр тоткан Гөлбизәк күренә.**

Гөлбизәк. Миннән түйдыгыз, ахрысы. Китсен дип, юри кычкырышасыз.

Айбикә. Инде син дә... Әни, ни сөйлисең!

Гөлбизәк. Кара әбиегез аркасында бозылышасыз дисәм, алай сыман да тоелмый башлады. Яңа өйдә мин — иске кеше, сыймыйм бугай. Иске өемдә торып карыйм әле, татулашмассызмы. (*Китә башлый.*)

Асыл. Әни, беркая китмисең.

Айбикә. Син дә ташлыйсың, бердәнберем, соңгы таянычым!

Гөлбизәк (*Айбикәнең чәчләреннән сыйпый*). Ачуланма, балам, сынап карамак өчен китеп карыйм. Әгәр сагынсаң, үз яныма килерсең. Үпкәләми генә кал.

Айбикә. Әни! (*Гөлбизәк чыгып китә.*) Әнием! (*Үз-үзенә урын тапмыйча чәбәләнгәч, киенә башлый.*)

**Тәберде белән Йолдыз керә. Сагаеп кына түргә узалар.**

Йолдыз. Айбикә апам-җаным, ни булды? Асыл абый, нишләвегез бу?

Тәберде. Безнең беләсебез килә, Асыл абый.

Асыл. Бөтенесен белсәң, тормышның кызыгы калмый. Белмирәк яшәгез.

Йолдыз. Бәлки без сезнең хаталарны кабатламаска тырышырбыз.

Тәберде. Гыйбрәт булыр.

Асыл. Гыйбрәт дисәгез... гаҗәп популяр лекция сөйли алам. Түземегез җитсә.

Тәберде. Түзәрбез.

Асыл. Тормыш дип исемләнгән мәгънәсез бушлыкның...

Йолдыз. Мәгънәсезгә үк әйләндемени инде?

Тәберде. Кая китте соң теге... ачыласы йолдызлар?

Асыл. Менә нинди хикәят. Борын-борын заманда, зур дәрья буенда, кыялы ярның ике ягында егет белән кыз яшәгәннәр ди. Берсе ак сарайда, берсе зәңгәр сарайда. Мәгәр, ак сарай белән зәңгәр сарай дошман булганлыктан, ике яшь йөрәкнең йолдызлы мәхәббәтен катгый рәвештә тыйганнар икән. Бер-берсен күрмичә яши алмаганлыктан, егет белән кыз икесе ике кыядан дәрьяга ташланган. Ләкин аларны коткарганнар. Фаҗига кабатланмасын дип, өйләнешергә фатиха биргәннәр боларга. Егет белән кыз, ир белән хатын булып, бергә яши башлаганнар. Ягъни, җаның күпме тели, шул чаклы ярат. Тик ходайның хикмәте, тыю туктагач, ягъни, инде бу вакытта бәрәңге пешереп, идән юып, кер юып иза чиккән ир белән хатынның күзләре башка берәүләргә төшә башламыш, ди. Торабара аерылу дәрәҗәсенә җиткәннәр, ди. Соңгы чиккә килеп төртелгән мәлләрендә сез килеп кергәнсез, имеш.

Тәберде. Ярыйсы ук кызык, имеш.

Йолдыз. Айбикә апа, дөресме шушы хәл?

Айбикә. Шулай гына булса икән! (*Китәргә җыена.*)

Йолдыз. Син кая, Айбикә апа?

Асыл. Егерме еллык сәфәргә.

Тәберде (*аквариум янында*). Балыклар... Карагыз әле, нишләгән бу балыклар? Үлгәннәр бит!

Асыл. Ә без түзәбез әле.

Айбикә. Бүтәнчә түзә алмыйбыз. (*Ишеккә таба атлый.*)

Асыл (*аның каршысына төшеп*). Җүләрләнмә!

Айбикә. Егерме еллык сәфәргә, кара әби артыннан.

Асыл. Гафу ит, ашыкканмын, ялгышлык белән, ачу аркасында.

Йолдыз. Бездә торырсыз, монда кысан булса.

Тәберде. Шушындый тормыш кертеп утыртыр өчен йорт төзүнең нигә кирәге бар? Безнең эштән нинди мәгънә кала?

Айбикә. Әни булып әни түзә алмады, корычтай түзем кеше. Ә мин күпме түздем! (*Тайпылмакчы була.*)

Асыл. Беркая китмисең.

Айбикә. Балыклар хәленә төшәргәме? Ашыктырма. Исән бул, Йолдыз, сау бул, Тәберде. (*Ашыгып китә.*)

**Аның артыннан Тәберде белән Йолдыз да чыга. Асыл идән уртасында катып кала.**

Асыл (*битләрен ике кул белән каплап*). Күзләрем дөрес күрәме соң? Бу нинди тарлык? Ник хәтта сулыш кысыла? Күзләрем, ничек ышаныйм сезгә? Мондый да түбән хурлыкны күрергә тиешмени сез? Ә кирәген ник күрмисез? Айбикә, Гөлбизәк әни... кайда алар? Кайда Айбикә? Айбикә!

**Урамга ташлана.**

## Алтынчы картина

**Төн. Караңгы. Асыл урамнар һәм казып ташланган мәйданнар аркылы тын бакчага уза. Эскәмиягә утыра.**

Асыл. Ах! Киң дөньяга чыгам-чыгам дип талпына торгач, тәмам хәлдән тайды йөрәк, тузды. (*Йөрәген тотып, икенче кулы белән эскәмиягә таяна.*)

**Әсмабикә керә.**

Әсмабикә. Менә син кайда икән. Көчкә таптым.

Асыл. Әһә, бөтенләй үк ялгыз түгелмен икән әле. Әсмабикә, лачыным, йә, нишләп йөрисен монда.

Әсмабикә. Көнозын эзләдем үзеңне.

Асыл. Сөенечле хәбәрен бармы әллә? Сөйлә, лачын, миңа хәзер сөенеч бик кирәк.

Әсмабикә. Хәбәр шәп түгел шул. Менә директорның приказын әләктердем. Жюри утырышы булган икән.

Асыл. Анысын үзем күреп тордым. Мине котларга мөмкин. Мин — лаборатория мөдире.

Әсмабикә. Лабратурия, лабратурия! Тапкан. Котла, имеш. Сине бит нинди зур урыннан төшергәннәр. Син хәзер директор ярдәмчесе түгел икән ич инде.

Асыл. Соң... Икегә ярыла алмыйм бит. Аның каравы, максатыма ирештем, аңлыйсыңмы шуны. Яраткан эшем... (*Йөрәген тота.*) Уф! Йолдызлар белән... радиоаппаратлар...

Әсмабикә. Йолдызлар, имеш, радиоаппаратлар, бала-чага сүзе сөйләп. Ә миңа норка тунны кем табып бирә, болай булгач?

Асыл. Ах, синең кайгың бигрәк тә зур шул.

Әсмабикә. Лачынымны мамыксыз-каурыйсыз калдырып китәсеңмени?

Асыл. Канатларың исән.

Әсмабикә. Канат, канат! Пычагымамыни канат, артың шәрә калгач. Үзең дә... дивана. Шул лабратуриядә кулга тотып булмый торган плюс-минусларны санап ми черткәнче, чумырып алып була торган нигъмәтләр исәпләсәң, ак сакаллы карт иден лә. Нинди өметләр баглаган идем үзенә. Инде бетте, йолдызлар сүнде. Хуш инде.

Асыл. Мине шушы хәлдә калдырасыңмы?

Әсмабикә. Бик авырмыни хәлең?

Асыл. Йөрәк! (*Эскәмиягә баш куеп, җиргә утыра.*)

Әсмабикә. Менә кәмит. (*Асылны күтәреп эскәмиягә утыртмакчы. Көче җитмәгәч, җиргә җайлап утырта.*) Шушында тыныч кына утырып тор. Ашыгыч ярдәм чакырам, хәзер, тыныч бул, кузгалма. (*Китә.*)

## Җиденче картина

**Шифаханә. Асыл караватта ята. Аның янында Айбикә белән Гөлбизәк утыра.**

Айбикә. Минем бүтән сүзем юк бугай, Асыл. Ярый, борчылма, тизрәк терел.

Асыл. Юк шул, бетмәде сүзең. Минем соравым бар, ач әле серенне.

Айбикә. Минем бернинди серем юк, Асыл, үзең беләсең.

Асыл. Әйе, беләм. Үзенне эзләрлеккә кара өрәктән баш тартырга тырышып яшәдең. Буш кайгы белән кайгырып. Шунысын да беләм, туп-туры юлдан киттең. Бик күпләр сиздермичә генә тагы да әшәкерәк гөнаһ эшләсәләр дә, судан пакь, сөттән ак булып, гаиләне җимермичә яши бирәләр. Ә син алай эшли алмадың.

Айбикә. Синеңчә, мин Шоңкар белән яшертен генә очрашып, сине дә яраткан булып уйнарга тиеш идемме-ни?

Асыл (*сызланып*). Каян белим, мин каян белим. Мөмкин иде, дим, мөмкин генә иде дим.

Айбикә. Соравың шул гына идеме?

Асыл. Аңлыйсым килә: Шоңкарны әйтәм, аның сиңа биргән бөтен әйберсе — пар балдак. Ә минем күпме тырышлыкларым, яхшылыкларым... Аз идеме? Син шуларны да исәпкә алмадың.

Айбикә. Барысы, барысы исәптә булды һәм син алар өчен нәрсә таләп иттең? Нинди счет китереп куйдың? Шулар бәясенә кешелегемне тартып алырга түгел идеме ниятең?

Асыл. Әгәр шуңа барганмын икән, бу миңа күкрәк читлегеннән йөрәгемне суырып чыгару белән бер түгел идемени? Шулай булды да ул — күреп торасың. Ә син, гомер юлдашы дигән кеше, иң хәтәр чакта ярдәмче була белмәдең.

Айбикә. Җинаятькә бара алмадым.

Асыл. Кайчан, нинди җинаять?

Айбикә. Димәк, син мине беркайчан да аңлый алмаячаксың.

**Бүлмәгә Әби керә.**

Асыл. Ә! Әнә бәхетсезлекнең башы! Ул җирды безне.

Айбикә. Бәхетсезлекнең башы — үзебездә, җаннарыбызда.

Әби. Дөрес сүзләр. Син аларны Шоңкар белән очрашканнан соң гына

әйтә алдың. Болай булгач, син минем ниятләр изгелеген дә аңладың дип беләм. Инде мине, кызым, анам дип кабул ит.

Гөлбизәк (*куркып*). Кызым, Айбикә!

Айбикә. Курыкма, әни. Бернинди бәхәссез, мин — синең кызың. Күзе күргән барча кеше минем акыл-фигыль белән генә түгел, төс белән дә сиңа охшаганымны әйтә.

Гөлбизәк. Гомер буе дигәндәй, үзем дә шулай дип яшәдем.

Әби (*Гөлбизәкнең иңгеннән тотып, аны үзенә карата*). Ныклабрак кара, апа, күзеңне ачыбрак! Бәлки соңгы кабаттыр, соңыннан үкенерлек булмасын. Таныйсыңмы син мине? Таныйсың бит!

Гөлбизәк. Менә тагы. Ничек танымыйм ди, гомердә бер күргән кортканы.

Әби (*Гөлбизәкне ычкындырып*). Үз туганыннан баш тарткан кешене ходай мәңгелек җәзага тартыр. Тәмугъ кисәве, туганнарча түгел, ят адәмчә дә сөйләшмәдең.

Асыл. Үлгән кеше белән сөйләшә белми шул безнең Гөлбизәк әниебез.

Әби (*Гөлбизәккә*). Син минем бердәнбер кызымны тартып алдың. Шушы зур дөньяда бер кешесез калдырдың.

Гөлбизәк. Теге дөньяда бәхилләшербез, игәч.

Әби. Игәч! Таныдың! Син мине барыбер таныдың. Рәхмәт шуның өчен дә.

Гөлбизәк. Безгә житте, яшьләр сөйләшсен. (*Асылга.*) Исән терел, кияү, бик борчылма.

Асыл. Сүзеңне тыңлармын, Гөлбизәк әни. (*Гөлбизәк китә.*)

Әби. Соңгы сүзең булырмы, кызым?

Айбикә. Сүземне әйттем бит, әби.

Әби. Алайса, миңа да вакыт. Исән булыгыз.

Айбикә. Хәзер кая юл тотасыз?

Әби. Үз дөньяма.

Айбикә. Шоңкар янынамы?

Әби. Шоңкар! Шоңкар юк инде ул. Вафат.

Айбикә. Ни сөйлисез, әби!

Әби. Менә. (*Сумкасыннан алып, телеграмма бирә.*) Очышлары уңышсыз чыккан...

Айбикә (*телеграмманы укыгач*). Шоңкар! Шоңкар! (*Хәлсезләнеп утыра.*)

Әби. Үлгән артыннан үлеп булмый, артык өзгәләнмә. Хуш. (*Китә.*)

**Телеграмманы Асыл ала. Тирән тынлык урнаша. Айбикәнең хәтерендә җыр яңгырый. Һәм ул җыр пәрдә төшкәч тә дәвам итә.**

Синең өчен чәчәк җыям, эзләп син
сөйгәннәрен.
Ишетмим җилләрнең сине тапмадык
дигәннәрен.
Ышанмыйм ул калды ерак, ул юк
дигән сүзләргә.
Сине көтәм, кил яшьлектән,
Кил бүгенге көннәргә.
Синең өчен чәчәк җыям, булмасаң да
янымда.
Килмәсеңне белеп көтәм, көтсәң бераз
ял була.

Синең өчен чәчәк җыям, кыскармый
калмас ара.
Узганнарга мәхәббәтем чәчәкләр илтә
бара.
Ышанмыйм ул калды ерак, ул юк
дигән сүзләргә.
Сине көтәм, кил яшьлектән,
Кил бүгенге көннәргә.

Асыл. Бар, Айбикә, син дә ял ит. Өебезгә кайт.

Айбикә. Их, Асыл, Асыл!

Асыл. Бер ялгызың яшәмәссең бит? Кем белән яшәрсең?

Айбикә. Шоңкар белән.

Асыл. Хыял белән, мәгънәсез юклык беләнме?

Айбикә. Син башыңа китерә алмаган бөек мәгънә белән.

**Айбикә урамга чыккач та җыр аны озата бара.**

ПӘРДӘ

*1972—1983.*

# ӘЛМӘТ ӘДИПЛӘРЕ

1955 ел.

СССР дип аталган гаять зур империянең игътибар үзәгендә Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге: биредә «кара алтын» ятмалары ачылган, хәзер шуларны үзләштерү өчен чын-чынлап көрәш бара. Илгә нефть кирәк! Шуңа күрә хөкүмәт беренчи чыгымнар беләндә исәпләшми.

Менә ул чордагы Шөгер, Әлмәт, Азнакай, Баулы якларының типик пейзажы: тирән-тирән чокырлар, канаулар, тау-тау балчык өемнәре, кырларда — нефть вышкалары, металл чыны, тракторлар гөрелдесе... Төннәрен балкып янган, безнең шагыйрьләр тарафыннан мәдхия җырланган серле газ ялкыннары... Шәһәрләрдә төзелеш краннары. Күз ачып йомганчы торак йортлар, мәдәният сарайлары үсеп чыга. Романтика! Татарстанның горурлыгы, йөз аклыгы, һәм соңарып аңлаган фаҗигасе дә булган «кара алтын»ның тәүге чоры әнә шундый.

Әле ике ел элек кенә шәһәр исеме алган нефтьчеләр мәркәзе Әлмәткә көннәрдән беркөнне «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасының үз хәбәрчесе Әдип Маликов килеп төшә. Килсә ни, дип ис китмәүчеләр дә табылыр, чөнки журналистлар ул елларда Казаннан гына түгел, Мәскәүдән дә еш килә иде. Ләкин Ә. Маликов — журналист кына түгел, яшь шагыйрь дә. Моңа да, булсаңи, аз-маз шигырь язган журналист беткәнмени, диярләр. Әйе, мондыйлар журналист халкы арасында да аз түгел. Ләкин Әдип Маликовның ул чакта килүе һәм биредә яшәп калуы моңа кадәр һәрберсе үз казанында гына кайнаган яшь иҗатчыларны бер йодрыкка тупларга ярдәм итә.

«Кара алтын» фронтына, әлбәттә, Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең дә игътибары көчле. Менә ул чорда идарә рәисе урынбасары булып эшләгән Сибгат ага Хәким һәм җаваплы секретарь Фатих ага Хөснинең Ә. Маликовка язган хатыннан бер өзек. «...Сезнең үзегезнең дә язучы кеше булуыгызны һәм әдәбиятка хөрмәтле карашыгызны искә алып, — диелә ул хатта, — без Сездән безнең уртак эшебездә — әдәбиятның алмашчы көчләрен әзерләү эшендә — язучылар союзына ярдәмгә килүегезне үтенәбез. Бу ярдәм түбәндәгедән гыйбарәт: Сез, шул тирәдәге җитәкче иптәшләр, комсомол активы һәм урта мәктәп укытучылары белән сөйләшеп, нефтьче яшьләр арасыннан әдәбият белән кызыксынучы, шулай ук үзенең дә язу дәрте булган иптәшләрне барлап алсагыз һәм шундый яшьләрдән газета редакциясе каршындамы, мәктәпләр янындамы әдәби түгәрәк эшләтеп җибәрүне оештырсагыз икән...»

Хат 1955 елның 28 сентябрендә язылган. Шәхси теләк һәм өлкән язучыларның үтенече бер-берсенә этәргеч бирә: 1955 елның 15 октябрендә, ягъни хат алганнан соң егерме көн дә узмый, сибәләп торган яңгырга, җыелып яткан күләвекләргә игътибар итмәстән, канаулар аша, кайда сикереп, кайда урап үтеп, итекне суырган кызыл балчыкны ера-ера, каләм ияләреннән берничә кеше М. Горький исемендәге клубка ашыга. Шушы көнне Әлмәттәге әдәбият түгәрәгенең беренче утырышы уза. Әлмәт язучылар оешмасы архивындагы беркетмәләрдән күренгәнчә, анда түбәндәге иптәшләр катнашкан: Ә. Маликов, Г. Фатихов, Мортазина, Шәйхетдинова, Хатамтаева, Шәрифуллин, Ф. Мостафин.

Шушы утырышта ике көн тәртибе карала:

1. Оештыру эшләре.
2. Эш планын төзү һәм раслау.

Оештыру эшләренең йомгагы: Ә. Маликов түгәрәкнең җитәкчесе, Хатамтаева — урынбасар, Шәйхетдинова староста итеп сайлана.

10 ноябрьдә узган икенче утырышта фамилияләр күрсәтелми, бары тик җиде кеше катнашуы гына теркәлә. 20 ноябрь утырышында соңыннан Язучылар берлеге әгъзалары булып киткән рәссам С. Кальметов, нефтьче оператор

Җ. Рәхимовлар катнаша. Төзүче Ш. Бикчурин озакламый беренче әсәрләрен алып килә. Җиденче утырышта токарь Илдар Әхсәновның шигырьләре тикшерелә. Ә 1955 елның азагында шул ук клубта әдәбият түгәрәге әгъзаларының актив катнашлыгында патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичә уза. Кыска гына вакыт эчендә әдәби түгәрәк халыкка үзен танытып, ихтирам казанып өлгерә.



Бүгенге көндә Язучылар берлегенең 23 әгъзасын берләштергән Әлмәт Язучылар оешмасының чишмә башы әнә шул көннәргә барып тоташа. Әдәби түгәрәк әгъзаларының иҗатын чагылдырган әдәби битләр, тиздән шәһәрнең «Хезмәт байрагы», «Знамя труда» газеталарыннан тыш, «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» газеталарында да күренә. Түгәрәккә юл төзү конторасы эшчесе К. Булатова, укытучылар С. Сөләйманова, Э. Мөэминова килеп кушыла. Һәр яңа талант үз тавышы белән түгәрәкне баета, аның көчен арттыра.

1958 ел башында әдәби түгәрәк әдәби берләшмәгә әйләнә, чөнки инде ул әдәби түгәрәк рамкаларына гына сыймый башлый. Берләшмә җитәкчесе итеп Гариф Ахунов сайлана.

Укучыларның гаҗәпләнеп сораулары мөмкин: Гариф Ахунов каян килеп чыкты әле? Хикмәт шунда: 1955 елның кышында яшь язучы Г. Ахунов, күренекле шагыйрь Шәйхи Маннур белән бергәләп, нефть төбәкләрен йөреп чыга. Ә 1956 елның көзендә ул бер еллык иҗади командировкага килә, Ф. Мостафин, Ә. Маликовлар белән дуслаша, әдәби түгәрәк эшендә дә, Әлмәтнең әдәби хәрәкәтендә дә якыннан катнаша. Ә 1957 елны ул гаиләсе белән Әлмәткә бөтенләй күчеп килә.

Нефтьчеләр ягындагы әдәби хәрәкәткә ул башы-аягы белән чума. Әдип Маликовның «Ташчы» поэмасының поэзиягә яңа сулыш алып килүенә шатлана, үзе дә күп төрле очерклар, мәкаләләр бастыра.

Әдип Маликов ул чорда Мәскәүнең Әдәбият институтында читтән торып укый, «Яшь сталинчы» гәзитенең үз хәбәрчесе булып эшли, әдәби хәрәкәтне җитәкләп бару аңа авыр, шунлыктан ул Гариф Ахуновтан, ул чакта Әлмәттәге бердәнбер Язучылар союзы әгъзасыннан, әдәби берләшмәнең җитәкчесе булуын үтенә.

1958—1962 елларда Әлмәттә, Казанда, Лениногорскида яшь язучыларның зур семинарлары үткәрелә, 1959 елны Әдип Маликов, 1962 елны Шамил Бикчурин, 1963 елны Сәҗидә Сөләйманова һәм Энҗе Мөэминова Язучылар Союзы әгъзалары итеп алыналар. 1959 елны талантлы прозаик Рафаил Төхфәтуллин Кенәр якларыннан гаиләсе белән Әлмәткә күченеп килә. Шулай итеп, 1962 елда инде Әлмәттә алты әдип Язучылар Союзы әгъзасы, ә бу исә бер өлкәдә Язучылар оешмасы ачарга мөмкинлек бирә.

1962 елның җәендә РСФСР Язучылар Союзы идарәсенең Әлмәттә Татарстан Язучылар Союзының бүлеген ачу хакындагы карары «Литературная Россия» гәзитендә басылып чыга. Бу эшне оештыруда ул чактагы РСФСР Язучылар Союзы

секретаре Гомәр ага Бәширов бик зур тырышлык күрсәтә, ул РСФСР язучылар житәкчесе Леонид Соболевны бу эшкә күндерә.

Нефть ягы язучылары олы агаларына — Г. Бәширов, Г. Хуҗи, Х. Туфан, С. Хәким, А. Шамов, И. Гази, М. Садри, З. Нури, А. Расих, Г. Әпсәләмовка — Казаннан бик еш килеп, яшь каләмдәшләренә булышкан әдипләргә хәзер дә ихтирам хисе саклыйлар.

Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге рәсми рәвештә 1963 елның 23 мартында ачыла. Аны ачарга Г. Бәширов, З. Нури, Ш. Галиев киләләр. Аның беренче житәкчесе итеп Гариф Ахунов сайлана.

Бүлек ачылып, ике ел үтүгә, «Правда» газетасында, Әлмәт авторларына багышлап, әдәби сәхифә бирелә.

Шул ук вакытта Азнакай, Лениногорск, Сарман, Баулы кебек районнардагы әдәбият түгәрәкләрендә, әдәби берләшмәләрдә дә эш бара. Алар үз сафларыннан шигърияткә, прозага, драматургиябезгә никадәр каләм иясе бирде! Берләшмә членнарының кайберләре әдәбият, тел белеме галимнәре булып киттеләр, кайберләре журналистика өлкәсендә милләткә хезмәт итәләр. Әдәби берләшмәләр үз төбәкләрендә матур әдәбиятны үстерү һәм пропагандалау буенча элек-электән язучылар бирлегенең таянычы булып килде.

1993 елның мартында безнең оешма төзелүгә 30 ел тула. Мөстәкыйль бүлекоешма булып яшәү чорында авторларыбыз татар, рус, тугандаш халыклар телләрендә өч йөздән артык китап нәшер иттеләр. Оешма белән бәйле әдипләрнең әсәрләре элекке СССРда төрле телләрдә һәм чит илләрдә дә дөнья күрде.

Әлмәт оешмасы һәм аның урыннардагы «Гөлстан» (Азнакай), «Чишмә» (Лениногорск), С. Сөләйманова исемендәге «Кызыл каурыйлар» (Әлмәт), «Тугай моңнары» (Мөслим), «Моңсар» (Бөгелмә), Сарман, Баулы, Җәлил әдәбият берләшмәләрендә житлегү чорын кичергән яшьләр Татарстанда танылып өлгерделәр. Ә инде Татарстанның халык шагыйре Г. Афзал (ул Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты да), күренекле драматург Юныс Әминов, Г. Тукай исемендәге бүләк лауреатлары Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, М. Хәсәнов, Г. Рәхим, Г. Исхакый исемендәге бүләк лауреаты Рәшит Әхмәтҗанов, әдәбиятта үзенчәлекле каләм иясе булып танылган тарихи романнар остасы М. Хәбибуллин, тагын кайберәүләрне нефть ягы хезмәт ияләре үзләренеке итеп саныйлар, уңышларына куанып, горурланып яшиләр.

Утыз ел эчендә бу оешманы житәкләгән язучылар исемен дә атап үтәргә кирәктер:

1963—1965 еллар — Г. Ахунов. 1965—1967 еллар — Ә. Маликов. 1967—1968 еллар — Г. Ахунов. 1968—1972 еллар — Р. Фәйзуллин. 1972—1982 еллар — Ә. Маликов. 1982—1987 еллар — Ә. Гаффар. 1987 елдан — Н. Әхмәдиев.

Гаиләнең балалары үсә төшкәч, төрле якка тарала башлый. Әдәби гаиләдә дә нәкъ шулай. Янәшәбездә генә Чаллы шәһәре үсеп чыккач, анда да Язучылар оешмасы төзелде. Шунысы куанычлы, ул оешманы төзү өчен нефть төбәгендә тәрбияләнгән әдипләр нигез ташын тәшкил итте. Э. Касыймов, М. Газизов, Г. Кашапов, Р. Бәшәр һәм тагын бик күпләр безнең якта чыныгу алган әдипләр иде.

Сулар ага, Галиҗәнаб Вакыт тормышыбызга эзен сала тора. Рәхимсез үлем арабыздан бик вакытсыз алып киткән талантлы шагыйрә С. Сөләйманова, драматурглар Ю. Әминов, Ш. Шаһгали, балалар өчен язучы нефтьче галим Ү. Саттаров, прозаиклар М. Хәсәнов, Ш. Бикчурин, Э. Касыймов, Г. Кашаповларның якты истәлеген без хөрмәт белән искә алабыз. Бүген Әлмәт шәһәренең ике урамы С. Сөләйманова һәм Ю. Әминов исемнәрен йөртә.

Үткәнебез турында сөйләү күңелле, әлбәттә. Ләкин безнең тарихыбыз гына түгел, бүгенгебез дә матур. Г. Афзал, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова кебек өлкәннәребез хәзер дә күпләрне көнләштерерлек итеп эшли. Х. Хәйруллин, К. Булатова, Ф. Садрыев, К. Әмиров, Ж. Рәхимов, А. Хәсәновлар исеме киң катлау укучыларга яхшы таныш. И. Гыйләҗев, Ф. Гыйльми, Р. Рәкыйпов, А. Ганиев, Ә. Галиевләр әсәрдән әсәргә үсә бара. Күптән түгел генә Ә. Габиди, Д. Гарифуллин, Р. Вәлиуллин, И. Әхсәнов, И. Хөсни, Ф. Исмәгыйловалар язучылар сафына кабул ителде. Хәзер унлап әдәбият берләшмәсенә йөздән артык кеше йөри.

Билгеле, 30 ел буена Әлмәт төбәге язучылары каләменнән гел шедеврлар гына төшеп торды дигән фикердән мин ерак торам. Чор шаукымына ияреп язылган дежур әсәрләр дә, әдәбиләктән ерак торган халтура да аз тумагандыр. Ләкин боларның беренчесе җәмгыятебезнең рухи фаҗигасеннән килсә, икенчесеннән исә бер генә чор да, бер генә әдәбият та читтә кала алмый. Узган өч дистә елның кыйммәтен рухи искергән әсәрләр түгел, бәлки шушы чорда иҗат ителгән һәм әдәбиятыбыз тарихына үтеп, халыкның күңел түренә урнаша алган чын җәүһәрләр билгели.

**Нур ӘХМӘДИЕВ,**

Әлмәт Язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе.

# БӘЙРӘМ КОТЛАВЫ

Шушы елның 24 мартында Әлмәт Язучылар оешмасы төзелүгә 30 ел тула. Әгәр шушы дәвердә СССР дип аталган державада һәм үзебезнең Татарстаныбызда булып узган катлаулы җитди вакыйгаларны искә төшерсәк, утыз елның нинди зур чор икәнен аңларбыз.

1955 елны бәләкәй генә бер әдәби түгәрәктән башланып, әдәби берләшмә аша узган, ниһаять, профессиональ язучыларын булдырган оешма һичшиксез, игътибарга лаек.

Аның чишмә башында Әдип Маликов, Фазыл Мостафин, Шамил Бикчурин, Сажидә Сөләйманова, Клара Булатова, Энҗе Мөэминова, Сәет Кальметов, Илдар Әхсәнов кебек фидакяр кешеләр торды.

Мин Әлмәткә 1956 елны үзем килдем, ә 1957 елны Татарстан Язучылар союзы идарәсе анда мине махсус җибәрде һәм 1968 елны янадан Казанга чакырып алды. Мин киткәндә, 12 әдип Язучылар союзы әгъзасы булып калды. Ә утыз ел эчендә Әлмәт оешмасы тәрбияләп үстергән профессиональ әдипләрне исәпкә алсак, аларның саны 45 кә җитә. Бу — бик зур сан. Татарстан әдипләренең алтыдан бере дигән сүз. Мин моның белән горурланам.

Әлмәткә — аның авыр елларында — Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Юныс Әминев кебек, халык арасында инде киң танылган, тәҗрибәле зур язучыларның килеп кушылуы безнең оешманың абруен нык күтәрде. Казаннан Азнакайга Мәхмүт Хәсәнов килеп, ул төбәктә әдәби хәрәкәтне җәелдерде. Әлмәттән Лениногорскига күчеп киткән Шамил Бикчурин әдәби берләшмәне җитәкләде, үзе Мәскәүгә укырга киткәндә, эстафетаны Альберт Хәсәновка тапшырып калдырды. Шамил Бикчурин татар әдәбиятына җитди өлеш кертте, Лениногорскида аның исемендәге урам булуын күңел бик тели. Шәһәр җитәкчеләре бу тәкъдимне искә алырлар дип ышанам.

Әлмәт Язучылар оешмасын төрле елларда Әдип Маликов, Равил Фәйзуллин, Әхәт Гаффар җитәкләде.

Безнең оешмага якты күз белән карап, гел ярдәм кулын сузган «Хезмәт байрагы» һәм «Знамя труда» гәзите коллективына, партия эшлекләләре Наилә Закирова, Сания Хәкимова, «Татнефть» берләшмәсеннән Үзбәк Саттаров, шәһәр Советыннан Усман Закиров, әдәбият укытучысы Регина ханымга һәм башка укытучыларга, Әлмәт дәүләт драма театрына, китапханә мөдирләренә, культура сарайларының директорларына, Татарстан китап нәшриятына, «Казан утлары» на, республика гәзитләренә без рәхмәтле булырга тиешбез. Аларның Әлмәт Язучылар оешмасына эшләгән игелекле эшләре күп булды; язучыларга фатир хәстәрләү, илнең төрле почмакларыннан зур әдипләрне чакыру, оешмага ике бүлмәле аерым кабинет бирү, транспорт белән тәэмин итү, әсәрләребезне атна саен әдәби битләргә туплау, хезмәт кешеләре белән танышу мөмкинлеген тудыру, сәхнә әсәрләрен халыкка җиткезү, язучыларны шәһәр Советы депутатлыгына тәкъдим итү, ташчы, инженер, газовик, үз хәбәрче, радио коментаторы итеп урнаштыру ел саен китапларыбызны бастырып чыгару, семинарлар үткәрү алар эшләгән игелекле эшләрне санап кына бетерерлек түгел. Шуңа күрә Әлмәт әдипләренең эше алга барды да...

Бүгенге үзгәртеп кору дигән тотрыксыз, болганчык заманда кайбер тәнкыйтьчеләр, хәтта әдипләр дә хезмәт кешесе турында язылган зур колачлы әсәрләргә ташландылар. Без мондый узып китә торган модага иярмик, хезмәт кешесен олылавыбызны дәвам иттерик. Алтын куллы кешеләрнең кадере беткәнгә, илне алыпсатарлар, мафиозилар, вөҗдансыз шулерлар басканга күрә шушы көнгә калдык. Әгәр игенчеләр, нефтьчеләр, төзүчеләр, терлек асраучылар тырышлыгы булмаса, бөтенләй төп башына утырып калган булыр идек. Әлмәт оешмасы йөзен сакларга — металлны, нефтьне, ашлык көшелләрен сәнгатькә әйләндерә белергә тиеш. Боларның барысы белән адәм баласы эш йөртә бит. Безнең китапларыбызның геройлары кешеләр булды, кеше җаны булды, шулай булып калсын.

Казаннан безнең Әлмәтебезгә өлкән әдипләребездән Гомәр Бәширов, Гали Хуҗи, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Афзал ага Шамов, Ибраһимов Гази, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Гази Кашшаф, Атилла Расих, Мөхәммәт Садри, Зәки Нурилар ярдәм кулын, дуслык кулын суздылар. Мәгънәле заманнар иде ул — иҗатта да, гаиләләребездә дә дуслар идек. Әй, кечелекле агайлар, олы җанлы әдипләр, без сезгә бурычлыбыз.

Әлмәт безгә иҗат канатлары бирде. Мин Әлмәттәге төсле мавыгып, җан ачып яшәгәнемне, иҗат иткәнемне белмим. Әлмәт безнең абруебызны күтәрде.

Әлмәт үстергән биш язучы — Тукай бүләге лауреаты. Әллә ничә язучы — орденнар кавалеры, атказанган мәдәният, сәнгать эшлеклесе. Әлмәттә Сажидә Сөләйманова, Юныс Әминов исемендәге урамнар бар. Әлмәттә яшәгән талант иясе Гамил Афзалга Республикабызның иң зур дәрәҗәсе — Халык шагыйре исеме бирелде. Ә бит бездә алар күп түгел, бөтен Татарстанга бишәү генә.

Әлмәт язучылары монарчы татар халкының йөзенә кызыллык китермәделәр. Дистәләгән китабыбыз зур илдә күп төрле телләргә тәрҗемә итеп басылды, чит илләргә юл алды, эфирларда яңгырады, зәңгәр экранга керде, нәфис фильм булып, спектакльләр булып ил буйлап атлады.

Әлмәт Язучылар оешмасының 30 еллык бәйрәме сафларыбызны барлау булсын, ул безгә тагын да зуррак уңышлар китерсен.

Кадерле дуслар, каләмдәшләр! Барчагызны олуг бәйрәм белән котлыйм, сәламәтлек, ак бәхетләр телим.

**Гариф АХУНОВ,**
Әлмәт Язучылар оешмасының беренче житәкчесе,
Әлмәт нефть чыгару идарәсенең почетлы нефтьчесе.

## Әдип Маликов

*Дөньяда берни дә юктан бар булмый. Әлмәт Язучылар оешмасына бүген 30 яшь дибез икән, ул да бит бәрәкәтле нефть төбәгендәге әдәби берләшмәләр нигезендә барлыкка килде.*

*Арабыздан иртә киткән күренекле прозаик, драматург, публицист Шамил Бикчуринның әдәбиятка ничек килеп керүе турында истәлегемне тәкъдим итәм.*

# УЯНУ

ИСТӘЛЕКЛӘР ДӘФТӘРЕННӘН

Әлмәт Язучылар оешмасы Татарстан нефть индустриясе белән бергә туды, бергә үсте. Без Әлмәткә күченеп килгәндә, ягъни илленче елларда мондагы хәлләр фронт күренешләрен хәтерләтә иде. Төзелеш шау-шуында, үз тавышын таба алмыйча, күпме талантлы яшьләр адашып, югалып йөриде. Очрашасы, барлыйсы, күңелләренә чаткы саласы иде шуларның. Чаткыдан ялкын кабынганын беләбез бит инде. Талант тумыштан килә диләр. Ләкин ул хезмәт җимеше дә. Тиешле игътибар, нииндидер этәргеч булмаса, талант дигән тылсымлы көч йомылып, сүнеп калырга да бик мөмкин.

Казан буенча ук таныш Миңлебай егете Шамил Бикчуринның бирелдәге төзелешләрнең берсендә эшләгәнен белдем. Республика гәзитендә аның ачынып язылган тәнкыйть мәкаләсен дә укыганым бар иде. Адресын табып, киттем Шамилне эзләп.

...Киң һәм озын баракның уртасыннан баштан-башка ярым караңгы коридор сузылган. Ике яктан да ишекләр, ишекләр... Сөйләшкән тавышлар ишетелеп тора. Кемнеңдер гармунда уйнаганы да, балалар елаганы да...

Мин кергәндә, Шамил, жылылык батареясы ягына артын куеп, идәндә бөгәрләнеп ята иде. Чигәләренә аерылып төшкән көлсу чәчләре, зәңгәр күзләре белән Тукташны төсмерләткән егет — шул үзе бит бу! Мин бит Казанда радиода эшләгәндә аны, театр училищесы студентын, Тукайның «Шүрәле»сен укырга микрофон алдына чакырган идем. Аны тыңлаганда урынымда утырып тора алмадым. Булачак артистның эфирдагы Шүрәлесе күз алдыма килеп басты. Бүрәнә ярыгына бармагы кысылган «урман хуҗасы»ның яшелле-күкле тавыш белән «син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм», — дип ялваруы көлке дә,

кызганыч та иде. Бикчурин студиядән чыгып киткәч, диктор Камал апа Саттарова, рәхәтләнеп көлә-көлә, «бу егетнең үз бармаклары да тач шүрәленекенә охшаган», дип калган иде.

Радио бинасында күргәннән соң Шамил тагы да ябыга төшкән. Озын бармаклары гел сөяккә калган дисәң дә ярый.

— Әдип абый! — дип, ул шунда ук мине танып алды. Урыныннан кузгалырга итте, ләкин уфылдап, яңадан ятты: 

— Төзелештә билемне кузгаттым,— диде гафу үтенгән сыман, уңайсызланып.— Врачлар «хандроз» ди. Хандрить итәм, янәсе. Хәзер ышаныч бетте миңа...

Тимер койкада, моңсуланып, ике малай утыра. Икесе дә зур күзле. Кулларында шикәр комы сипкән ипи телемнәре. Әниләре өйдә юк икән.

— Мин бит «прокаженный»,— дип куйды Шамил, түшенкелеккә бирелгән яшермичә,— Үзбәкстанда хезмәт иткәч, ул сүзнең мәгънәсен яхшы беләм мин. Шәһәр гәзитендә хәзер бармак башы кадәр информациямне дә басмыйлар.

— Төзүчеләрнең тетмәсен теткән теге усал мәкаләң өченме әллә? — дип сорадым мин.— Гәзиттә укыган идем.

Шамил аклану ягын каерды:

— Мин бит анда төзүчеләргә таш атмадым. Трест башындагы җитәкчеләрне камчылаганыем. Менә үз сыртыма төште шул камчы. Эш горком бюросына барып житте... Бүреләр, төлкеләр мәҗлесендәге куян хәлендә калдым хәзер.

Шамил ахырдан үртәлеп өстәп куйды:

— Кем көчле, шул хаклы бездә. И, белсәгез иде мондагы безобразияне! Башыгызга төшсә... Гафу, гафу, кызып киттем...

Хатыны Гайшә кайтып кергәнче, Бикчурин белән байтак кына сөйләшеп алдык.

Чирчиктә урнашкан авиаполкта хезмәт итеп кайткач, Шамил Әлмәттәге төзелеш трестына килә. 1953 елның башы була бу. Ул анда трест тулай торагындагы тәрбияче штатына алына. Төп вазифасы исә комсомол оешмасын җитәкләү. Аның эше бит тавык чүпләп кенә дә бетерерлек түгел. Ә нәтиҗәсен тикшерә башласаң, комга сипкән су сыман, берние күренми. Үзешчән сәнгать коллективын күтәрү дә Бикчурин җилкәсенә ята. Трест коллективындагы уңай якларны күпертеп, гәзитләргә мәкаләләр язарга да кирәк. Соңгысы белән һич килешә алмый Шамил. Кая карама — күз буяу, кода-кодагыйлык. Өстәвенә, эшчеләр белән тупас мөгамәлә. Бер урыннан — икенче урынга «очып» йөргән, гаиләләре үзәк шәһәрдә яшәгән шома җитәкчеләр җирле халыкларны санга да сукмыйлар, кешегә дә санамыйлар. Кая ул аларның хәлләренә керү. Түбәннән кергән уйлап табу тәкъдимнәренә «хуҗа»лар арасыннан шунда ук берничә «соавтор» табыла. Иң зур гонорар яки премия аларга тиешле. Иң авыр кара эшләрне авылдан килгән яшьләр, Бигәш, иске Әлмәт хатын-кызлары башкара. Кәйлә, көрәк алар кулында. Ике арадагы конфликт менә шуннан башлана. Күпне күргә, күпне белгә аркасында «абына» да инде Шамил. Туры сүзле, үткен телле тынгысыз егетне төзелеш начальнигы күрәлми башлый. Шәһәр комитетының беренче секретаре, тупас холыклы, халык әйтмешли, «ярым исәр» Тарубаров та аны гафу итми. Бикчуринны бик теләп тотынган эш урыныннан кычкыртып куалар, гади ташчы итеп күчерәләр. Ул югалып калмый. Лепщик һөнәрен үзләштерә, Чупай ташыннан салынган яңа йортларның эчке стеналарын, түшәмнәрен, известь һәм үзле балчыктан «коеп» ясалган чәчәкле орнаментлар белән бизи башлый...

Хатыны кайткач, Шамил ыңгыраша-ыңгыраша булса да торып утырды. Бергәләп чәй эчтек.

— Мин әле бөтенләй беткәннәрдән түгел, тәүбә иттерәлмиләр әле мине,— дип куйды ул көрсенеп.

— Кая әле сиңа бетәргә,— дип, кырт кисте хатыны,— синдәге дәрт әле ун кызга җитәрлек.

— Көлмә, көлмә, хатын!

Чыннан да сугыш елларында чабата киеп, үгез җигеп, җир сөргән, сугыштан соң, студент тиеннәрен саный-саный, башкала казанында кайнаган, аннары Әлмәт татар дәүләт театры сәхнәсендә көлкеле-кызык рольләр башкарып йөргән ир-егетнең мескенләнергә ни хакы бар әле. Ә дүрт ел буе Чирчик авиаполкында «чиләнү», ак ефәк парашютларда зәңгәр упкыннарга очулар!

— Әлмәт барьерларын гына сикереп узарга көч табарсың әле,— дип, мин дә аны үземчә юатырга тырыштым. Горький исемендәге клубта булачак алдагы әдәбият түгәрәге утырышына чакырдым.

— Рәхмәт, рәхмәт, җылы сүзегез өчен,— диде Шамил, ышаныргамы-юкмы дигәндәй, башын кашып,— ничек тә килергә тырышырмын, Әдип абый...

Озак та үтмәде, Шамил Бикчурин чираттагы утырышыбызга килеп тә житте. Клуб китапханәсе бүлмәсендә унбишләп кеше жыелган иде. Кызлардан назлы хушбуй исе анкып тора. Ә егетләрдән... Кулларга, киемнәргә сеңгән мазут, тәмәке исләрен ничек бетерәсең ди. Кызлар инде монсын гына гафу итәрләр.

Беренче сүзне мин Шамил Бикчуринга бирдем. Торып басты. Озын, ябык гәүдәсе, күләгә сыман, чайкалып куйды. Зәңгәр күзләрен идәнгә текәп, әкрен генә сөйли башлады:

— Мин, иптәшләр, монда килер алдыннан гына бер чибәр шофер кызга багышлап шигырь яздым. Янында утырып, кабинадагы кыек көзгедән күзәтеп барганыем үзен. Көлмәгез, бер дә көлке түгел...

Кинәт тонын үзгәртеп, рольгә кереп киткәндәй, артистларча укырга тотынды бу:

*Барганда,*
*гармун тавышына охшатып,*
*Сигнал бирәсең бармак тибрәтеп.*
*Йөртәсең йөгеңне салмак,*
*сакланып,*
*Гүя сиртмәле бишектә тирбәтеп...*

— Замечаниеләрегез булса, әйтегез, иптәшләр,— диде ул, шигырен укып бетергәч. Бер мәлгә барсы тынып калды. «Әйбәт» диючеләр булды. Бер кыз шунда кыяр-кыймас кына сүз кушты:

— Синең бит, Шамил абый, беренче куплетыңдагы рифмаларың бертөсле...

— Юк, алай түгел,— дип, бәхәскә керде автор.— «Тибрәтеп» белән «тирбәтеп»нең аермасы зур. Менә бишек тирбәтә башлагач, аермасын белерсең әле, сеңлем...

Һәммәсе дәррәү көлеп жибәрде.

1955 елның көзе иде бу.

## Гамил Афзал,

Татарстанның халык шагыйре

### Әлмәт яклары

Моңаеп озатам,
Сагынып каршылыйм
Җылы яктан кайткан кошларны.
Кайларга барсам да сагынып кайтам мин
Әлмәттә яшәгән дусларны.

Ак тасма сузылган самолет юллары —
Болытлар өстендә югары.
Болытлы көннәрдә, зәңгәр моң ябынып,
Чайкала Урсала урманы.

Йөрәктә саклаңыр Сарманы, Шөгере,
Талларга төренгән Зәй буе,
Тургайлы таңнарда, суларга иелеп,
Таллары тирбәлә җәй буе...

Мин шаулы гомердә әле күп күрермен
Язларны, җәйләрне, кышларны.
Кайларга китсәм дә
Сагынып йөрермен
Әлмәттә яшәгән дусларны.

### Карт солдат

Без дә шаян идек, без дә яшь идек,
Кыланчык кызларга көлеп, баш идек,
Гүзәлләр гүзәле, сандугач, дидек,
Без дә шаян идек, без дә яшь идек.

Күзләр нурлы иде, ялкынлы иде,
Сүзләр серле иде, акыллы иде,
Күңел уйчан иде, күңел ак иде,
Уйнадык та көлдек, шаян чак иде.

Соры шинель кидек, күн итек кидек,
Мылтык, кылыч тотып походта йөрдек,
Сиратларны кичеп, утларга кердек,
Әҗәлләр күрдек без, тәмугълар күрдек.

Пленга да төштек, пленнан качтык,
Хәтәр юллар үттек, хәтәр юл ачтык,
Без күргән газапны беркем күрмәсен:
Сталин төрмәсен, Гитлер төрмәсен!

Безне ким-хур итү ятларга кирәк,
Хәвефле юллардан атларга кирәк.
Егет икәнеңне акларга кирәк,
Күңелдә горурлык сакларга кирәк.

Бу тыныч елларда җилләрдән сора:
Без үткән юлларда һәйкәлләр тора.
Кабер өсләренә каеннар үскән,
Балалар исәннәр, оныклар исән.

Дөньялар болганды, әнә күр инде:
Кемгә ишек төбе, кемгә түр инде.
Бик күп миллионнарга кара гүр инде,
Кан-яшь сеңгән басу, әнә сөр инде.

Елап туасың да, җырлап үсәсең дә,
Дөнья мәшәкате ирләр иңсәсендә.
Үтә яшел җәйләр, килә соры көзләр,
Уйчанлана йөзләр, моңсулана күзләр.

Авыр еллар булган, солдат медаль таккан,
Картайсам да, олан, хезмәт итеп ятам.
Менә, озын юлдан туган якка кайтам,
Күңелле бу дөнья, имин торсын ватан!

## Күңел кошы

Күңел кошы кунар урын эзли
Өянкеле авыл өсләрендә.
Күңел кошы илһам нуры күзли
Шул авылның айлы кичләрендә.

Картлар үлә, яшьләр китә, дисең,
Тыңламыйча түрә кушканнарын.
Шул авылның сандугачлы кичен
Сөя синең серле дастаннарың.

Әй, сөеник әле бергә-бергә,
Таралсыннар дөнья кайгылары.
Галиябану җырлап киткән җирдә
Башын чайкый зират каеннары.

* * *

Үз вакыты белән яңгыр ява,
Яшел шатлык бәхет өләшә.
Өмет белән яши ватан-ана,
Яфрак белән яфрак серләшә.

Кыйбла якка ак болытлар ага,
Яшь пәйгамбәр булып йөз яшә.

* * *

Үткәннәрне хурлап тормам инде,
Анда минем шаян яшьлек калды.
Үткән юлда күксел томан инде,
Киләчәкне көтеп күзләр талды.

Үткәннәрне мактап тормам инде,
    Сугыш утларында дуслар янды.
Без үткән юл — кара урман инде,
    Елга тугайлары бөдрә таллы.

Басуларда гөжләп иген үсә,
    Рәхмәт әйтеп торам болытларга,
Болыннардан йомшак җилләр исә,
    Дөрес иман кайта оныкларга.

* * *

Без мондыйны гына күрмәгәнме,
Сыер җигеп басу сөрмәгәнме,
Кара таңны кара төнгә бәйләп,
Буш труддень эшләп йөрмәгәнме!

Без мондыйга гына түзмәгәнме,
Михнәт диңгезендә йөзмәгәнме,
Якты киләчәккә өмет итеп,
Сөйгәннәргә чәчәк өзмәгәнме!

Таныш михнәт белән таныш кытлык —
Җиңәрбез, дип яңа чорга чыктык,
Талау белән алдау булмаганда,
Туган җирдә ачка үлми чыпчык.

* * *

Патшаның да хәле авыр икән,
Бөтен халык хокук сорый, иркәм.

Халык ипи сорый көн дә иртән,
Юньле хәбәр ишеткән юк күптән.

Дөреслекне белер-белмәс килеш,
Телдән-телгә йөри имеш-мимеш:

— Бу базарга акча каян җитсен!
— Түләмәсә, пенсиягә китсен!

Берни алып булмый акчаларга.
Алла ярдәм бирсен патшаларга!

* * *

Җиде юл чатында кара урман,
Җен күтәрмәс йөгем иңсәдә.
Җиңем белән танау сөртеп торам,
Җиде башлы дию килсә дә...

## Юлда уйланулар

Юл күрсәтеп баручы юк,
юл күрсәтеп.
Усал язмыш бәрә-ега
гөрселдәтеп.

Намус кирәк, иман кирәк,
ялгышмаска,
Туры юлдан барыйк әле,
Җирән кашка!

Ниләр килеп, ниләр китми
безнең башка,
Табигатьнең гөнаһы юк,
Җирән кашка...

## Сыйнфый көрәш

И шатландык, и сөендек инде
Алпавытның җирен алган белән.
Ә аннан соң имансызлык килде
«Сыйнфый көрәш» дигән ялган белән.

Без бәхетле, иң шәп халык, диеп,
Сөйләнергә кушты куштанлык.
Күпне күргән фәхишәләр кебек,
Алдана-алдана ышандык.

Уйлана-уйлана ышандык та,
Шикләнә-шикләнә инандык.
Ач хәерче белән буш куыкта
Каян килсен инде иманлык!

* * *

Балчыктан да йортлар корып була,
Җир стена була, җир идән.
Үз-үзеңне алдап торып була:
Беркемгә дә, диеп, баш имәм...

* * *

Чәйнәп бетермичә калдыр сүзне,
Серле булып, томанланып калсын.
Серле юллар ашкындыра безне,
Еракларда серле йолдыз янсын.

Киләчәктә бәхет бар ул шөйлә,
Үткәннәрдә түгел, өмет алда,

Сихерчегә ышанасы килә,
    Түрәләргә ышанып булмаганга.

## Кайгы

Яз көнендә моң илендә
    Ак каен, кара каен.
Кара каенны кочаклап
    Еладым, балакаем.

Көз көнендә моң илендә
    Ак каен, кара каен.
Кара каеннар төбендә
    Кайгылы анакаең...

* * *

Карл Маркс сөйли моңын-зарын,
Ачуланып әйтә Ходайга:
— Бөтендөнья пролетарийлары
Берләшергә уйламыйлар да...
Күпме еллар үтте, ачы еллар,
Кешеләргә акыл өләшеп!
Бизнес юк бит,— диләр сукин сыннар,—
Хәерчеләр белән берләшеп!

* * *

Җимерергә, туздырырга,
    таларга өйрәттеләр
Иблистән дә уздырырга,
    алдарга йөрәклеләр.

Әтисен саткан әләкче
    властька кирәк иде,
Төрмәче дә җинаятьче
    тәхеткә терәк иде.

* * *

Ышанып та, алданып та йөрдек,
Дөнья ямьле, кызлар чибәр иде.
Яманын да, яхшысын да күрдек,
Шаян егет мәзәк сөйләр иде.

Еллар үтте. Хәзер ныклык кая,
Нигез ташы итеп салырлык!
Болганчык су кебек еллар ага,
Сабырлыклар бирсен, сабырлык!

### Система

Сәяси система әмер бирде:
— Иң дөрес юл — безнең юлыбыз.
Укымышлы кеше контр була,
Барыгыз да надан булыгыз!

Китап тоткан интеллигент шикле,
Ул күп белә, уйлый төрлесен.
Көрәк тоткан надан кеше — изге,
Көрәк тотып алдан йөгерсен!

### Сыйнфый дошманлык

Дошманлык чәчтек тә, дошманлык урдык,
Дөньялар тулды дошман белән.
Сокланып тормадык, шикләнеп тордык,
Кызыл юлбашчы кушкан белән.

Дошманлык чәчеп, чәчәк үсми икән,
Тилебәрән үләнс үсә.
Тилебәрәннәр күбәйде, иркәм,
Акыллы идек югыйсә...

## Саҗидә Сөләйманова

### Сау бул, язым!

Су өсләре җем-җем көмеш дага —
Кар сулары чаба дәрьяга.
Ташкыннарга төшеп агыйм әле,
Ярсуларга табыйм бер дәва.

Бәхилләшми генә сау бул, язым!
Аерылабыз диеп уфтанма.
Энҗе чыклар булып син кайт әле
Зәй буена җәйге бер таңда.

Күзләремә кайт син, басуларда
Яшь уҗымнар булып яшелләп.
Яңгыр булсаң, сагыну яшьләремнең
Тамчысын да синнән яшермәм.

Араларда йөрер зәһәр җилләр,
Һай, ураулы юллар, ураулы.

Сажидә СӨЛӘЙМАНОВА (1926—1980) — *күренекле шагыйрә, прозаик, әдибә; татар һәм урыс телләрендә дөнья күргән күп санлы китаплар авторы. Әлмәттә яшәде.*

Кайтырыңны әйтеп, тәрәз каксын
Салкын кышның салкын бураны.

Баш орсаң да ташка, булмый икән
Вакыт агымына карышып.
Су юлыннан китеп югалсак та,
Ил җырына кайтып кавышыйк.

Сау бул, язым!
 Әйдә, бер тын алыйк,
Башкайларны салып ярларга...
Су өсләре җем-җем көмеш дага —
Еллар чаба чиксез дәрьяга.

*1976 ел.*

## Клара Булатова

* * *

Елга-сулар ага... ага-ага,
Дәрьяларга төшеп югала.
Дәрьяларга аккан сулардан да
Йөрәгемдә тирән моң кала.

Зәңгәр күктә Зөһрә йолдыз яна,
Таң алдыннан сүнеп югала,
Таңда сүнеп баткан йолдыздан да
Йөрәгемдә якты моң кала.

Елгаларга төшеп сулар алам,
Йолдызларга карап уйланам,
Туган җирем, мин бит бар гамеңне
Йөрәгенә җыйган бер балаң.

* * *

Чыгарабыз диеп җирнең маен,
Җир күкрәге күпме тишелде,
...Зәңгәр газдан күкшелләнде каен,
Чахоткага тарган шикелле.

Керләнмичә калалмаячагың
Бу якларда ачык бит инде,
Сафлык саклыйк дисәң, сеңлем, каен,
Берәр кая качып кит инде!...

---

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә, «Язлар алда», «Җәйләр җитсә», «Гел каяшка карап» һ. б. китаплар авторы.*

Кая качсын?!
                              Тауда жир уелсын,
Иңкүлектә упкын убылсын...
Адәм жаны кыйбла тапмас чакта
Ул кайларга барып сыенсын?!

* * *

Ышансаң-ышанмасаң да
Бер юаныч күңелдә:
Йолдызнамә-фал китабын
Ачыйк әле бүген дә.

Ел башында барысы да
Йолдызнамә юрасын.
Ни булганы булган инде,
Сора ниләр буласын.

Ни булганы булган инде,
Баштан узган төрлесе.
Без хаклык дип ышанганның
Хата булган күбесе.

Дөрес, бәндә хаталардан
Хали түгел түгелен,
Гел хатадан торган көне
Бик авыр шул иленнең.

Искеләрен төзәтик дип
Яңаларын ишәйтеп,
Каш ясыйм дип күз чыгарып,
Куйдык әллә нишләтеп.

...Ел башында йолдызнамә
Юраса да ни генә,
Берүк инде яңа афәт
Янамасын Илемә.

* * *

Гасыр башындагы кебек
Яңадан бәрдерикме
Күктәге гаделлек белән
Җирдәге гаделлекне?

Икесе алар чәкәшкән
Җегәрдән туган чаткың
Көйдереп корытыр тамырдан
Бу илнең нинди халкын?

«Без өстен, Галиҗәнаб»,— дип,
Иягең күккә чөеп,
Кем йөрер китап яндырып,
Кулләрен җилгә сибеп.

Андыйлар, әйе, табылыр,
(Сантыйлар өер-өер)
Чүт шыта башлаган иман
Яңадан гүргә керер.

...Тигезлек-хаклык билгесен
Куярга әле иртә,
Күктәге гаделлелек белән
Җирдәге гаделлеккә.

## Ком сәгате

Ком сәгате... Һәр бөртеге
Гомерләрнең бер көне.
Бөртекләп тормады язмыш —
Дәррәү тотып селкеде.

Әллә жиргә сыенасы,
Әллә күккә багасы.
Безнең гомер сирпелгән җир —
Җир белән күк арасы...

* * *

Әй, кайларга китеп гаип булды
Ак төннәрдә туган ак сирень?
Ак төннәрдән киткән ак сиреньнең
Миңа гына, иркәм, ач серен.

Бер күренде, шул бер күренүе
Бер гомергә торыр мизгелме?
Ак төннәрдән киткән ак сиреньне
Сагынудан җаным өзелде...

Ак сиреньнәр ачкан ак бәхетне
Кая куйдык? Кая җибәрдек?
Ни син, ни мин тотып кала алмадык,
Ни син, ни мин саклый белмәдек.

Ак сиреньнәр бездә сирәк була,
Ак төннәр дә бездә күп түгел...
Яктыртыр дип кара төннәрне дә
Сиреньнәрең көтә бу күңел.

* * *

Кар башына яткан кар аклыгы
Кырау гына түгел икәнен
Белгән кешеләрнең куактагы
Сыкыларга исе китмәвен
Белми идем мин дә, инде менә

Кыл уртасы үткәч гомернең
Акыл аңлый гомер фасылларын
Кабатлаулар мөмкин түгелен.

Акыл аңлый, йөрәк аңлый алмый,
Тыпырчына, «Язда калам», дип,
Аңлый алмый... Үзен һаман алдый:
Яздагыча сөя алам, дип...

## Илдар Хөсни

### Ояттыр

«Ике татар булган җирдә ызгыш бетмәс!»
Телдә йөргән бу гыйбарә хакыйкатьтер.
Тик татарда гына булган мин-минлек бу,
Шуны күреп, тоеп тору аһ, ояттыр.

Оят кынамы соң әле, олы гарьлек,
Болай да бит без татарга дөнья гел тар.
Үҗәтлеген, кирелеген эшкә җигеп
Бертуктаусыз берсен-берсе «ашый» татар.

Аһ, тарихта тиңе булмас кыска хәтер,
И әрнегән йөрәк түре, и күз яше!
Кирәк ләса көн күзенә туры карап
Үҗәтлекне бүтән төшкә юнәлтәсе!

Бүленешле империя кысасында
Азмы йоттың син үзенә җәбер угын,
Таркаулыктан арынмаган, җыелмаган,
Милли аңга тиенмәгән татарлыгым!..

«Ике татар булган җирдә ызгыш бетмәс!»
Милләт өчен нинди төгәл хакыйкатьтер.
Без дә, имеш, көрәшәбез (көлке бит бу),
Чит-ят күзләр каршысында аһ, ояттыр...

Ояттыр!

### Мин — гармун

Сиңа дәшәм, мең авазлы шәһәр!
Күнелеңдә моңга урын тармы?
Чүплегеңдә иңрәп, сыкрап ятам,
Үлем көтеп ятам,
Мин — гармун!

---

Илдар ХӨСНИ (1951) — *Әлмәттә яшәүче яшь шагыйрь, публицист. Көндәлек матбугатта даими басылып килә.*

Аңлый алмыйм, әллә төенләнеп
Буын чылбырларың чуалганмы?
Нигә шулай кирәксезгә санап
Ыргытылган хәтер?
Мин — гармун!

Әллә бүген омтылышлар бүтән,
Яуланасы үрләр буталганмы?
Кичерешләрне ялмап ут алганмы?
Аңлатуың сорыйм!
Мин — гармун!

Булганнарны югалтуы җиңел,
Кайтарулар авыр югалганны.
Имгәтелгән чор бәгыре булып
Исбат итәм моны!
Мин — гармун!

Сиңа дәшәм, мең авазлы шәһәр,
Моңсыз, җырсыз итмә туар таңны!
Моң — вөжданың синең,
Сакла аны!
Таләп итәм моны,
Мин — гармун!

* * *

Карап йөрим чор туздырган
Авылларны.
Сызлаулы, авыру төбәкнең
Җаны — зарлы...
Теле — ярлы...

Моннан да зур олы кайгы,
Хәсрәт бармы?

* * *

Бертуктаусыз инәлмәче:
— Кайда,— диеп, садәлек!
Шәрран ярып кычкырудан
Көннәр китмәс агарып.

Шәрран ярып йөргән чакта
Көнгә ачу кабарып —
Агарырга ирек бирмәс
Илеңдәге диваналык,
Йортыңдагы каралык!

# Илдус Гыйләҗев

## Мәскәү урамында

Ничә йөз ел вакыт үтсә дә,
Бетми икән яра җөйләнеп;
Шомлы салкын кереп күңел өши,
Як-ягыма карыйм шикләнеп:
Почмак саен чиркәү, монастырь...
Тотып алырлар да... күрсәләр,
Тәре үптерерләр төсле көчләп,
Татар икәнемне белсәләр...

## Яшь чишмәсе

Зур рәхмәтле булып яшим
Пушкин белән «әби патша»га:
Узышлый бер кереп чыкканнар
Кырымдагы гүзәл бакчага.
Фәкать шуның өчен генә
Хан сарае исән сакланган.
Истәлеге калган татарның
Гайрәтле вә мәгъруp чаклардан.
«Бакчасарай фонтаны» дип
Язып кына шагыйрь ялгышкан:
Чишмә бит ул... суга әйләнеп
Татар яше ага ялгаштан.
Аны аңлар өчен монда
Килү кирәк башка сурәттә —
Колбиләүче булып түгел шул...
Әрнү саклап җанда, йөрәктә.

## Соңарган ачыш

Өйдән чыгып киткән көнем
Күз алдымда бүген дә;
Әти-әни еламсырап
Калды капка төбендә.
Сизмәгәнмен алар белән
Тагын берәү булганын,
Бишек җырым, тәрбиячем
Яшьле яулык болгавын...
Рәнҗегәндер, ят җирләрдә
Ят сүзләргә төрендем,
Шунда калган икән лә бит
Җаны туган телемнең...

---

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь, «Җир китабы», «Җилкенү» һ. б. китаплар авторы. Азнакай районында яши.*

## Моңсу тараф

Килә-килә тәмам арып бетәм,
Торган җирем ай-һай еракта.
Чукынудан качып безнең ыру
Җәһәннәмгә китеп олаккан...
Нәсел очым синдә калды микән?
Нәрсәң, Казан, шулай тартадыр.
Бәлки, берәр чиркәү нигезендә
Бабам сөякләре ятадыр...
Ятадыр шул... Моңсу тарафыңа
Килеп-китүләре газаптыр.
Үз тарихын белмәгәннәр генә
Шушы газаплардан азаттыр...

* * *

Сезме соң бу, яшьлегемдә
Төн йокымны алган гүзәл?
Бу күзләргә ул елларда
Багышладым күпме газәл.
Һәр карашың йөрәгемне
Үтә иде чагып, өтеп.
Куырылып йомылсам да
Алдым һәрчак теләп, көтеп.
Очраштык та... ник тырышып
Күзегездән эзлим юкны?!
Очкын сүнгән... калган бары
Миннән сезгә күчкән йокы...

* * *

«Сагынырсың әле»,— дигәч
Көлдең генә.
Үзең бүген эзләп таптың,
Килдең менә.
Ниләр генә эшләтим соң,
Ниләр кылыйм?
Көлеп торган булам да бит...
Эчтән елыйм.
Кулны сузсам, сиңа кадәр
Ике саплам
Җеп озынлык. Әмма еллар
Катлам-катлам.
Аларны тишеп үтәрлек
Юк шул энә.
Ә йөрәккә көче житте...
...Чәнчи менә...

## Шул көннән соң

Пыскып яткан учак идем,
Коры утын киттең салып.

Ялкынланып, дөрләп янам
Сине күргән көннән алып.
Качып китимме соң әллә
Мөлкәтемне, илне ташлап?
Ни акыллы, ни җүләр мин
Сине күргән көннән башлап.
Иртә картайганны күреп
Әллә тәңре юри бирде?
Яңабаштан егет ич мин
Сине күргән көннән бирле...

## Фәйрүзә Исмәгыйлева

### Шулай да...

Ирен читең белән көлеп кенә
Нигә соң ул шигырь, дисең дә,
Яшьлек белән генә сизмисеңдер —
Сискәнерсең әле бер — син дә!

Әйе, кеше малга омтылганда
Кирәкмидер шигырь. Шулай да —
Бабайлардан калган гүзәл җирдә
Хиссез булу — гөнаһ бугай ла?!

* * *

Искәрмәстән кичә
төшләремә
минем
килдең бит.
Күзләреңнән
яшерер өчен
шәрәлегем,
яфраклар эзләп
тилмердем мин...

Аһ, бүген дә
төшләремдә
килсәң, диеп,
мине
күрмәгә, —
чаганымнан өзеп
өч яфрак
кертеп куйдым әле
бүлмәмә...

---

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА — *яшь шагыйрә. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Азнакай районында яши.*

## Белдеңме?

Минем сиңа үпкәләвем
Хушлашыр өчен мени?
Юк ла инде!.. кайнарланып
Дуслашыр өчен, димен...

Онытыла шул дөньялар —
Күренсен шәүләң генә!
...«Сөймәм бүтән» диюләрем —
Үтәлмәс тәүбәм генә...

## Җилдән туган...

Кое янында булды бу.
Хәтерләтеп синең тынны
Кайнар җил өрде муеныма.
...Башкаемны чөеп күккә,
Сыендым җил куенына.

Әй сыйпады җил, назлады,
Көрәктәй зур кулы белән!
...Сине хәтерләткән җилдән
Бәләкәч шигырь туды менә...

## Тәрәзәмә төшәр күләгәсе

Син бүтәнне яратсаң да,
Бүтән өчен үлсәң дә син,—
Төннәрегез якты булсын! —
Тәрәзәмдә — күләгәсе...

# **Рамазан Байтимеров**

## Сигезьюллыклар

Байлык эзли кеше, бәхет эзли,
Фән серләрен эзли һәм... таба:
Теләгәнне табу — бу тормышта
Бәхет-шатлык диеп атала...
Бар тапканын кабат җимерергә

---

Рамазан БАЙТИМЕРОВ (1923—1989) — *берничә китап авторы. Бу сигезьюллыклары шагыйрьнең архивыннан алынды.*

Корал коя (Кире кем кагар?).
Барын таба кеше. Тыныч яшәү
Серен кайчан, ничек кем табар?

* * *

Дөнья гүя чиксез карлы тайга,
Тормыш исә гигант бер нарта.
Күзгә күренмәгән җепләр белән
Җигелә дә кеше, әй, тарта.
Төпкә җигелеп тә ичмаса бер
Рәхәтлеккә кемдер туялмый:
Нужа менеп аңа утырган да,
Күсәк белән алга куалый.

* * *

— Ана сөте белән кермәгәнгә
Тана сөте белән кермидер.
Бу балалар өчен башкайларым
Ни ишетми, ниләр күрмидер.
Шук булуның, шаян, наянлыкның
Аңламыйлар чиктән ашканын...
— Алмагачтан алма ерак төшми,
Нәкъ үзеннең алар яшь чагың.

* * *

Җир картаер, яшәү яме калмас,
Тормас иде тормыш яңарып.
Юк, үлемгә ләгънәт укымыйк гел,
Кайчак аңа гимн язарлык.
Һәр искергән әгәр яши бирсә
Мөмкин булмас иде чыдарга...
Тарих шулай колга, патшага да
Тигез, гадел хөкем чыгара.

* * *

Исән чакта искә дә алмадык,
(Үзебезне күбрәк сөябез),
Дөнья куйган иде, гел мактыйбыз,
Күкләргә без аны чөябез.
Җир астында аршин җирдән башка
Үлеләргә берни кирәкми.
Ә кешегә тере вакытында
Тиеш хөрмәт бик еш эләкми.

* * *

*Акмулла зары*

Уйлап торсаң тормыш бик гаҗәеп,
Рәхәт күрми тугры, үз сүзле.
Тик үз җаны, үз файдасы өчен
Кысырыклый көчле көчсезне.
Байлар яши ярлы исәбенә,
Барлар яши талап юкларны.
Аптырыйм: хак-хокук дигән нәрсә
Җирдә әллә мәңге йокларммы?

## Әзһәр Габиди

### Әти киңәше

«Атка менсәң, үрә сикерсә дә
Егылма син, улым;
Кыюларга кичмәс кыялар юк,
Сыгылма син, улым.

Өметеңне сүнмәс йолдыз итеп
Балкыта бел, улым;
Ябырылып кайгы килгәндә дә
Елама, көл, улым.

Табышларың мулдан булсалар да
Һаваланма, улым,
Югалтулар чиктән ашсалар да
Чабаланма, улым.

Башкалар да кайгы татысын дип
Баз казыма, улым.
Син дә бер чыгарсың әле җиңү
Язларына, улым...»

Әткәй, миңа шушы киңәшләрең
Изге дога булды,
Әнә шуңа гомер юлларым да
Уңып кына торды...

Инде хәзер синең киңәшләрне
Бирәм улларыма:
Якты кояш кебек, нурын сипсен
Барыр юлларына.

---

Әзһәр ГАБИДИ (1926) — *шагыйрь, «Без — яз дуслары», «Кошчыгым», «Таң сәгате» һ. б. китаплар авторы. Сарман районының Чукмарлы авылында яши.*

## Безгә дә бит азат яшәү фарыз

Без — эш аты, төптән тартучылар,
Без күнеккән «коеп куярга».
Тик рәхәтен генә безгә аның
Туры килми әле тоярга.

Без — эш аты төптән тартучылар...
Ә алганнар — булды чамалы,
Тапканыбыз читкә агып торды —
Шундый булды инде заманы.

Без — эш аты, төптән тартучылар,
Авыр диеп шыңшып тормадык,
Күпме генә йөкне тартсак та без,
Эшебездән һаман уңмадык.

Партократ — җилкәбездә булды,
Боерды да һаман боерды,
Йөкне үзе бергә тартмаса да
Безнең җелекләрне суырды.

Ураумы юл, сикәлтәлеме ул —
Без булмадык бугай чыгымчы;
Безгә дә бит азат яшәү фарыз —
Кирәк түгел безгә чыбыркы...

Без — эш аты, төптән тартучылар.
Алда — иң авыры юлларның;
Күп яшәдек «Ләббәйкә» дип, инде
Кеше намен тотыйк югары!

## Үзебез булдырыйк

Без бәхетле! — диеп, сукырларча
Яшәгәнбез күпме алданып.
Ә чынлыкта коллардан да начар
Гомер кичергәнбез — казганып.

Алтын-көмешләрне озатканбыз
Тонна-тонна читкә — гел бушка...
Тапкан нефтьне дә «Дуслык» аша
Агызганбыз күпме чит «дус»ка.

Буш көймә бит ерак бара алмый —
Гел чайкалып тора дулкында.
Шуна да без килеп төртелгәнбез
Калкып чыгалмас упкынга.

Кибетләргә керсәң киштәләр буш,
Базарларга чыксаң кесә сай.
Торгынлыктан калкып чыгу өчен
Көтикме соң әллә бер-бер җай?!

Кемнәр генә бүген тамак ярмый,
Кемнәр генә бүген аһ ормый?
Тамак ярып, аһлар орып кына
Бер кайчан да тормыш яхшырмый.

Күпме була инде аһ орырга —
Аңсы юк та, имеш, бусы юк.
Юк икән — юк.
Ләкин шушы юкны
Без үзебез бүген булдырыйк!

...Бөтен көчне бергә туплыйк та бер,
Котылыйк шул хата — языктан,
Бөлгенлеккә төшкән ил-җирне без
Тартып алыйк упкын-сазлыктан!



## Җәүдәт Дәрзаман

# НИК КЕРӘСЕЗ ТӨШЛӘРЕМӘ?

КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕННӘН

### Кереш сүз

Мөхәммәт галәйһиссәлам. Гайсә. Будда. Кришна... Алланың Җирдәге кешеләр арасындагы әлеге пәйгамбәрләре кебек, әле тагын меңнәрчә һәм меңнәрчә илчеләре — кылган изгелекләре, сукырларны күзле итәрлек, чукракларга ишетү сәләтен кайтарырлык, үлгәннәргә кабат җан өрерлек илаһи куәткә ия булучылар хакында хәтта диннәрдән бихәбәр адәми затларга да мәгълүмдер. Аларның гайре табигый рухи куәтләрен бәйнә-бәйнә тасвирлаган риваятьләрне күпләп табарга, мисалга китерергә мөмкин.

Без әле тегеләр, әле бу диндәге яисә Югары Көчкә ышану-иманудан бөтенләй ерак торган кешеләр арасында догалар, өшкерү-имләүләр яисә сүз җегәре вә кул-бармаклардан иңгән, күңелдән сирпелгән илаһи нурлар ярдәмендә әллә нинди сырхаулардан савыктыручы кешеләр турында ишетә торабыз: Джуна Давиташвили, Анатолий Кашпировский, Рамин Гәрәев, Ванга, Иванка... Безгә якынракларыннан, инде дан-шөһрәтләре Татарстан чикләреннән ашып баручы Фарис Галләмов, Наил Хәким, Инзим Наил... Болары — бүгенге матбугат, радио-телевидение күтәреп алган шәхесләр. Әле тагын шундый ук яки көчлерәк тә сәләткә ия, бары берәүләре үзләре теләп, икенчеләре, теләмәсә дә, күләгәдә кала килгән, хәтта Күкләрдән вәхи рәвешендәге вәгазь алучы изгеләребез, Галәмнең, шул исәптән Җирнең дә башка үлчәмнәрендә тереклек итүче зирәк акылга ия булган материаль һәм рухи затлар белән элемтәдә торучыларыбыз, үткәндәгеләрне белеп, бүгенгеләрне биниһая ераклыклардан да күреп, киләчәкне әйтеп торучыларыбыз бар. Кемнәр алар? Безнең чор пәйгамбәрләре — Алланың Җирдә үзе сайлаган илчеләреме? Әллә, киресенчә, Иблис котыртучыларымы?

---

Җәүдәт ДӘРЗАМАН (1945) — *шагыйрь, балалар язучысы «Солдат булдым», «Төнге маҗара», «Гөлназ мәктәпкә бара» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

Әсәрнең журнал варианты.

Ә без үзебез, гап-гади кешеләр, үзебез уйлаган кебек үк гадиме? Фәләнчә гасырлар элек үк кирәксезгә «маймылдан яралып», бер мәгънәсезгә янә мәңгегә юкка чыгар өчен туабызмы бу фани дөньяга?! Әллә, киресенчә, җаннарыбызда асылда алласызлар итеп тәрбияләнгән буынның башына да килмәслек Олы Мәгънә ятамы?

Чыннан да, заманында маймылдан яралып, үсешебез азагында кабат хайван хөкемендә юкка чыгарга тиешле затлармы без? Әллә инде, кайчандыр Хак Тәгаләнең яраткан кызлары һәм уллары, Җирдәге Оҗмахка Күкләрдән әлеге илаһи көчләр белән өртелгән рухыбызны тагын да баетыр, камилләштерер өчен иңдерелеп тә, гаҗәеп мул табигый байлыктан, тәүге заманнарда мул табыннарның бәрәкәтле-нигъмәтләреннән, зәм-зәм суларыннан башларыбыз әйләнеп, гасырдан-гасырга деградацияләнә, үз-үзебезне юкка чыгара барабызмы?

Кешеләр, бигрәк тә балалар арасында чит һәм үзебезнең Галактикадан килгән, Җирнең башка үлчәмдәге параллель Дөньяларыннан безнең мохиткә килеп чыккан акыллы затлар белән элемтәләрнең кинәт күбәюен ни белән аңлатырга? Алла кушуы буенча эшләнәме бу эш, әллә Иблис фәрманы беләнме? Җирдәге күренешләрдән курыксаң, һич югы, башын комга тыгып «яшеренгән» тәвә кошыдай, күзне йомып «качарга» мөмкин. Ә тегеләреннән, күзләрне йомгач тагын да ачыклана, чынбарлыкка гына әвереләә барган «элемтә» хикмәтләреннән ничек котылырга? Ә нигә котылырга? Бәлки, тумыштан ук салынган җан саклау инстинктын, куркуны җиңеп, башланган элемтәне туктатмаска, булдыра алган кадәр тирәнгәрәк керергә кирәктер?

Гомумән, Галәм элемтәчеләренең күпчелеге раслаганча, кешелек дөньясының Җирдәге үсеше һаман да шушы җисми юнәлештә, ягъни Рухи дөньяны, Җанны онытып, аның вакытлыча «кабыгы» хезмәтен генә үтәүче тәнне кайгырту рәвешендә баруы ахыр чиктә аны дөньякүләм һәлакәткә илтә икән, бу фатальлектән котылу юллары бармы?

Бу сорауларга күпмедер дәрәҗәдә җавап бирергә җөрьәт итеп каләмкәгазьгә тотынганда мин үз күзәтүләремә, ышану-инануларыма, кыскасы, шәхси тормыш тәҗрибәмә таянып кына эш итмәкче булган идем. Һәм беренче дәфтәрнең соңгы сәхифәләрен төгәлләп килгән көннәрдә өстәмә көтмәгәндә «ишелеп төшкән», нигездә христиан ышану-инануларына бәйләп язылган, әмма бу фани дөньяга туачак, яшәячәк һәм килгән мәңгелегенә кабат китәчәк һәркемгә кагылышлы без белмәгән, аңламаган һәм әле тиз генә аңлый да алмаячак «Теге дөнья»га бәйләнешле урысча басмаларга күмелергә, махсус экстрасенс курсларында укырга туры килде. Һәм икенче дәфтәрне җиңел генә бер кыш эчендә төгәлләрмен дигән хыялның чынбарлыктан, Саба яклары әйтмешли, бә-ә-әк ерак икәнлеген аңладым. Миңа, күпчелек укучыларым кебек үк, «ликбез» үтәсе бар икән шул. «Коръән», «Инҗил», «Тәүрат», «Бхагавадгита» кебек изге китапларны өйрәнмичә алга китәселәрем юк икән әле...

«Күңел дәфтәре», әлбәттә, укучыны бернигә дә мәҗбүр итми. Мин үзем ышанган-инанган кадәресен генә язам. Ышанмаганнарына исә үз мөнәсәбәтемне белдерә барам. Укучылар арасында, һичшиксез, акыллы киңәш бирүчеләр, хаталарымны төзәтүчеләр дә булыр; барысын да сафсатага санап, тәнкыйтьләүчеләр дә табылмый калмас. Табылыр. Һәм шулай яхшы да булыр. Хакыйкать бары тик бәхәстә генә туа бит...

Күрелгән төшләр һәм аларга бәйле вакыйгалар ничек бар шулай язылганлыктан (ә аларның күбесе заманында яки бүген дә аралашып яшәгән реаль кешеләргә бәйле, үзгәртеп бирү исә вөҗданыма да, язмаларның рухына да каршы килә), әсәрдә кемнедер үпкәләтерлек, рәнҗетерлек урыннар булса, алдан ук ихласымнан гафу үтенәм...

АВТОР.

*Куктә ни булмас дисең,*
*Очсыз-кырыйсыз кук бит ул!*
Г. Тукай

Уйлап карасаң, гаҗәп нәрсә бу гомер дигәнең! Туарга да өлгермисең, шул мизгелдә, әле үзең дә белмәстән, үлемеңә якынлаша башлыйсың. Алдагысы әле бихисап озын, чиксез булып тоелса, вакытны аяусыз санап торган һәр секунд, һәр минут инде кире кайтмас булып, Мәңгелек хакимлегенә күчә бара. Һәм бу дөньяга килеп, аннан китәчәк соңгы сулышка кадәр яшәргә дип тырышабыз, көн итәм дип тырмашабыз, ялгышабыз, абынып авыз-борыннарыбызны канатабыз, шуннан соң инде салкын суны да өреп кабабыз, әмма барыбер ялгышабыз... Әйләнә-тирә мохитне өйрәнәбез, җир астын өйрәнәбез, су астын өйрәнәбез, Галәмне өйрәнәбез... Өйрәнәбез — чөнки бөтен галәмендә акыл ияләре бары тик без генә ич! Җиргә дә, җирдә дә без инде күптән хуҗа. Галәменә дә хуҗа булырга тиеш, димәк! Һәрхәлдә, безнең буынны шулай дип өйрәттеләр, шулай дип тәрбияләделәр. Әби-бабайлар безне бичуралар, шүрәлеләр, җен-убырлар белән куркытты, мәктәп аларны юк дип өйрәтте. Әби-бабайлар Кешене Алла яраткан дип инандырырга тырышты, мәктәп исә, «кеше маймылдан яралган» дип дәлилләргә тырышты.

Кем ничектер, мин үзем йорт ияләренең, бичураларның, җен-пәриләрнең барлыгына ышанып үстем. Ниндидер илаһи көчкә инану, аның барлыгын икрарлау мине куркыта да, бер үк вакытта ышаныч та өсти иде. Бернинди дә Алла-мазарның юклыгы хакында укытучыларым никадәр генә тукымасыннар, башыма нинди дә булса берәр кыңгыр уй килеп, аны гамәлгә ашырырга дип омтылсам, хәтеремә кылт итеп Ул килеп төшә, Ул карап, күреп торадыр сыман тоела. Һәм мин әлеге яман гамәлдән тыелып калам... Һәм олыгая төшкән саен А н ы ң барлыгына, берлегенә иманым ныгый гына.

Ни хикмәттер, үземне белә-белгәннән бирле күккә тартылам, йолдызларга омтылам. Кайчандыр Җиргә шуларның берсеннән иңгәнмендер, кайчан да булса кабат шунда ашармындыр сыман тоела. Шуңадырмы, малай чакларымнан ук тышкы мохитемә караганда эчке дөньям мине ныграк кызыксындырды. Еш кына үземне чолгап алган тирәлек, кешеләр — барысы да томан артындарак кала, үзем исә шуның белән янәшә икенче бер дөньяда яшимдер сыман тоела иде. Һәм бәлки шуның өчендер дә, кечкенә вакытларымда ук инде «бу ни?», «бу нәрсәгә ярый?», «ни эшләтсәң, бу нәрсәгә ни була?» кебек сорауларга җавап эзләү белән бергә, «мин кем?», «мин минме?», «мин нигә мин әле?», «мин мин булмасам, минем урында кем булыр иде?» кебек, беренче карашка, ифрат мәгънәсез сорауларга да җаваплар табарга тырыша идем. Сизеп торам, тилемсә икәнсең, дип авыз ера башладың, кадерле укучым. Ашыкмыйк. Көләргә дә өлгерербез, кем әйтмешли, еларга да...

Без өйдә дүрт бала үстек. Уртанчы сеңелем дөньяга килгәч, ул чакта аң керә башлаган булгандыр инде, бер нәрсәгә игътибар иттем: туып, әле бер атна да үтмәгән, ә ул инде рәхәтләнеп төш күрә — ниндидер хәрәкәтләр ясагандай аяк-кулларын кыймылдата, нидер уйлагандай, каш-маңгайларын җыергалап ала, хәтта уймактай иреннәрен матур кыймылдатып йә елый, йә елмая! Әйе, әйе, у й л ы й, е л ы й һәм е л м а я! Андый чакларда әбием мәрхүмә: «Фәрештәләр белән сөйләшә», — ди иде. Фәрештәләр белән сөйләшә... Бәлки, чыннан да, шулайдыр. Бәлки кеше нарасый чагында, әле аң керергә өлгергәнче, үзенең киләчәк шатлыкларын күреп елмая, үкенеч-кайгыларын кичереп елыйдыр?

Ничек кенә булмасын, шул чаклардан ук инде т ө ш дигән галәмәт мине җитди кызыксындыра башлаган иде. Чыннан да, нәрсә ул төш? Баш миенең кеше йоклаганда да ял итмичә үз эшчәнлеген дәвам итүеме, әллә

моның әлегә кеше үзе дә аңлап бетермәгән башка бер сәбәпләре дә бармы? Мин монда ниндидер фәнни нәтиҗә чыгарырга җыенмыйм. Әмма күзәтүләрем бар. Аларны тагын бер кат хәтердән кичереп, соңыннан ниндидер бер нәтиҗә чыгарырга тырышып карасак, язманың башындагы уйлануларның бөтенләй үк нигезсез түгеллеген күрербез.

* * *

Бәләкәй өйдә яшәгән чагыбыз. Әле мин үзем дә бик кечкенә. Сәкедә уйнап утырам. Шулчак өй стенасының уң як почмагында сул тарафка атлап баручы өч каз пәйда булды. Искиткеч хәл: стена бүрәнәләре өстеннән, шәүләсыман баралар иде ул казлар. Үзләре ап-ак. Томшыклары белән тәпиләре кып-кызыл. Шундый да матур, шундый да горур, шундый да гаярь атлап баралар... Мондый манзараны бары тик хәзерге мультфильмнарда гына күрергә мөмкин. Әмма ул чак экранның да, мультфильмның да, кинотеатр түгел, клубның да нинди нәрсә икәнлеген белми идем әле мин. Ә казларны бик яхшы күреп белгәнгә, шикләнмичә әйтә алам — бик симез, бик көр казлар иде алар. Стенаның бер почмагыннан килеп чыктылар да, салмак кына атлый-атлый, икенче почмагына кереп югалдылар. Ялгышмасам, кыш көне иде бу. Әмма бик салкын вакытларда сарык бәрәне, бозау ише нәрсәләрне өйгә кертү гадәте булса да, казларны өйгә кертмәгәнлекләрен яхшы беләм. «Алар болай да мамыкка төренеп йөриләр, йоклаганда тәпиләрен шул мамык эченә яшерәләр, шуңа күрә, курыкма, туңмый алар...» ди торган иде әти. Шул. Теге казлар күздән югалуга: «Әни,— дим,— әни, теге казлар кая китте?» Әни көлде генә. «Нинди казлар? Утырган җирдә йоклап, әллә төш күрдеңме, ходаем?» — диде ул. Ә теге казларның алпан-тилпән килмичә, тәпиләрен ничектер алмаш-тилмәш югарыдан әйләндереп төшергәндәй атлап барулары ни өчендер бик төгәл булып хәтергә уелган. Шул чакны искә төшереп, күзләремне йомдыммы, бер-бер артлы тезелеп, стена өстеннән шуып кына баргандай, теге казлар үтә. Үзләре шундый зурлар, ап-аклар. Томшыклары белән тәпиләре — кып-кызыл...

* * *

Үземне белә-белгәннән бирле, 6-7 яшемә кадәр мине бер төш эзәрлекли. Беренче тапкыр күргәч, мин ул төштән котым чыгып уяндым. Икенче көнне хәтта урыныма ятарга да куркып йөргәнем хәтердә. Бәләкәй булуыма да карамастан, күңелем дөрес сизенгән икән. Чыннан да, бу төш чагыштырмача еш керә торган булды.

Өй бурасының бер ягына охшаган, әмма почмаксыз тоташ дивар... Шуның уртасындагы кечкенә генә бер тәрәзә яңаклары тирәли, зур еллыкта тезелеп, миңа табан бер үк үлчәмле юан корыч арканнармы, дилбегәләрме сузылган. Ул арканнар мине тирәли узып, каядыр еракка китеп югалалар. (Үсә төшеп, тормышта күргәннәрем белән чагыштырып карый башлагач, мин аларны югары көчәнешле трансформаторлардан килгән электр чыбыкларына охшаттым.) Бөтен җанны, бөтен тәнне үтәли чыгып, ниндидер тоташ гүләү ишетелә. Аны җирдәге бер генә тавыш белән дә чагыштырып булмый. Әнә шул хәзер безгә таныш булган югары көчәнешле трансформатор гүләвен, бозылгач шаулап эшли торган көн яктылыгы бирүче лампа тавышын, бик томанлы, явымлы көннәрдә югары көчәнешле электр үткәргеч корыч арканнардан чәчрәп һавага таралучы электрон очкыннардан ишетелеп торган чытырдаугөжелдәүләрне, чатнама салкын көннәрдә телеграф баганаларының җырлау-зыңлауларын бергә кушып кына да андый үзенчәлекле тавышны хасил итеп булмый торгандыр. Шул рәвешле, мин актык чигенә җитеп

тартылган, аңлатып булмаган тавышлар белән зыңлап торган корыч арканнар коридоры уртасында калам. Арт ягымда тоташ караңгылык. Алдымда — күз күреме җитәрлек ераклыкта якты ачыклык хасил итүче артык зур да, бик кечкенә дә булмаган тәрәзә. Тел белән аңлатып булмый торган әнә шул бөтен җанны, тәнне үз тибрәнешләренә ияртеп дерелдәтә-калтырандыра торган гайре табигый көч теге арканнар уртасында хасил булган «тәрәзә»гә тарта, суыра. Бар җаным, бар тәнем әнә шул тибрәнешләргә ияреп калтырана, әмма аңа бирешмәскә, үз ихтыярында, үз көчендә, үз иркендә калырга теләп, бөтен барлыгы белән карыша, теге кызыктырып, ымсындырып торган «тәрәзә»гә якынаймас өчен тартыша. Үзе ул «тәрәзә»нең аргы ягында, күз камаштыргыч илаһи яктылыктан кала, берни дә юк сыман. Инде бетәм, арканнар хасил иткән әлеге туп-туры, төп-төз «мәгарә» уртасыннан ычкынып, ние беләндер җан чыгар дәрәҗәдә котны алып торган теге «тәрәзә» артындагы алтынсу яктылыкка атылам дигәндә... уянып китәм. Мондый чакларда уянганнан соң да әле тирә-ягым тоташ бушлык сыман. Гәүдә каядыр түбәнгә очып бара кебек, ә йөрәк урыныннан кубардай булып, дулый-дулый тибә — әле һаман да теге «мәгарә» эчендәге тартыштан арына алмый... Дөрес, бөтен тәннең, җанның каядыр түбәнгә, билгесез куркыныч бушлыкка тартылуы хәзер дә булгалый, тик «корыч арканлы тәрәзә» генә күренми. Әмма бөтен гәүдәне ток тоткандай калтырандырып, коточкыч куәт белән «упкын»га сөйрәп төшерергә тырышкан көч һаман да үзен сиздереп куйгалый... Мин боларның ни икәнлеген бары тик әле менә соңгы елларда гына, оча торган тәлинкәләр, аномаль зоналар, Галәмнән килгән билгесез акыл ияләре («килмешәкләр» дияргә телем әйләнми), кешенең үлемнән соңгы, ягъни «теге дөньядагы» тормышы хакында көндәлек матбугатта иркенләп, тәфсилләп язылa башлагач кына аңлый башладым. Бу очракта инглиз галиме Моудиның (безнеңчә «Мәһди»гә тартым) «Үлемнән соңгы тормыш» исемле китабында тасвирланган күзәтүләре аеруча кызыклы. Ул төрле сәбәпләр аркасында вакытлыча клиник үлем кичергән ике йөздән артык кеше белән очрашып сөйләшкән һәм гаҗәп нәтиҗәгә килгән: аларның йөз туксанга якыны, кабат терелгәнче, бер-берләренә искиткеч охшаш хәлләргә дучар булганнар икән. Авыруларның бер ишләре үзен үңәченнән чыгып бара сыман хис иткән. Әмма ул үңәч ни өчендер биниһая ераклыкларга сузыла, аны искиткеч зур тизлектә үтәр өчен дә бик күп вакыт кирәк имеш. Икенчеләре исә моны бик озын, әмма күпчелек очракта бераз гына бөгелә төшкән караңгы туннель кичү белән чагыштыралар. Күпмедер ара үткәннән соң чиста күк рәвешендәге алтынсу яктылык күренә башлый, туннель буйлап «очыш» исә теге нәкъ мин тасвирлаган сыман җан өшеткеч авазлар — зыңлау, гөжләү, гүләүләр астында үтә.

Моудиның тасвирлавынча, кайбер үлеп терелүчеләр, әлеге «туннель»не яки «үңәч»не кичкәннән соң, үзләренең үлеп яткан урыннарына «килеп чыгалар», табибларның аны ничек коткарырга азаплануларын күрәләр, аларның сөйләшкәннәрен, туганнарының илереп елаганнарын ишетәләр. Тик аларны юата гына алмыйлар: җан авазы тере кешеләргә барып җитми...

Бу тикшеренүләргә Моуди тиктомалдан гына тотынмый, әлбәттә. Ул, бик яшьли, үсмер егет чагыннан ук үзендә сәер үзгәрешләр сизә. Төннәрен тәнендә вак дулкыннар йөгерешүен тоя башлый. Тора-бара тәндәге дулкыннар кайчагында бизгәкне хәтерләткән тоташ калтырауга күчә икән. Аптырый булачак галим. Нинди генә табибка мөрәҗәгать итеп карамасын, җавап бер — пациент сау-сәламәт, һәм вәссәлам!

Төннәрнең берендә исә инде урта яшьләрдәге галимебез шундый уңайсыз тойгылардан соң уянып китә дә үз-үзен аңламый тора: ник дип әле түшәмгә терәлеп диярлек, люстра янында «эленеп» тора ул? Йа хода, ә хатыны — бердәнбер,тугрылыклы дип исәпләгән хатыны — сөекле ха-

тыны нинди ят ир белән кочаклашып ята тагын?! Югыйсә, әле кичен генә йокларга бергәләп ятканнар иде ләбаса!

Бераздан соң гына төшенә галим: тәненнән аерылган ич ул, җаны түшәмгә, күтәрелгән дә, гәүдәсенә читтән карап тора...

Менә шул хәлләрдән соң инде Моуди, үзе теләгән чагында, тәүлекнең кайсы вакыты булуына да карамастан, гәүдәсеннән аерылып, төрле «сәяхәтләргә» чыгып йөри ала башлый...

Гомеренең соңгы елларында вакытлыча клиник үлемне мәшһүр шагыйребез Сибгат Хәким дә кичерә. «Мин анда бер булып кайттым бит инде. Гаҗәеп дөнья икән ул, егетләр,— дип сөйләгән ди, имеш, аксакал үз шәкертләренең берсенә, үлем турында сүз чыккач, һич уйламаганда чишелеп китеп.— Ниндидер тар, әмма озы-ын мәгарәдән очып барасың, барасың, барасың да... ямь-яшел болынга килеп чыгасың. Чалт-аяз күк зәп-зәңгәр. Һава шундый да саф, шундый да чиста. Анда бер барып эләккәч, бу фани дөньяга кабат кайтасы да килми...»

Мин ни өчен боларны сиңа сөйләп торам соң әле, кадерле укучым? Тәннән җан аерылып, «туннель кичкәндә» Моуди тасвирлаган хәлләр белән үзем балачакта «бура стенасындагы корыч арканлы тәрәзә»гә тартылганда ишеткән гүләү-гөжләүләр арасында, һичшиксез, уртаклык барлыгын күңелем белән сизенгәнгә язам мин моны. Бар әйтергә теләгәнем әнә шул. Мондый хәл теләсә кем белән булырга мөмкин. Боларның барысын да бары тик «бастырылу» галәмәте дип кенә санау дөрес булмастыр...

* * *

Авылыбызда Чишмә (Шушма) һәм Сагышлы елгаларына көйләнгән берничә тегермән бар иде. Сагышлы елгасындагысы — Морадым бай тегермәне. Без үскәндә, аны Морадым байның улларыннан берсе Миңлевәли бабай эшләтә иде. Буаның түбәнге ягы бик тирән, төбе су кайнап торган казанны хәтерләтә иде. Без казан төбендәге мәтедән төрле уенчыклар әвәләргә, балык тотарга ярата идек. Яр буена басып, буа авызыннан түбәнгә ыргылган су шарлавыгына озын-озаклап сокланып торсам да, кайчан да булса ул ярдан егылып төшкәнемне хәтерләмим. Әмма төшләремдә шул ярдан мәтәлеп тәкатем корый иде. Яр читеннән ычкынып китәм дә очам, очам... Яр читеннән аягым ычкынуга, авырлыгым югалып, күңелдә берни белән дә аңлатып булмый торган хис туа: гәүдәм бөтенләй юк сыман. Үзем ниндидер бер бушлыкка әверелеп, баш әйләндергеч тизлектә зырылдап, бөтерелә-бөтерелә, түбәнгә, төбе күренмәгән упкынга төшәм. Моның ниндидер бер мизгел генә икәнлеген күңел сизеп тора югыйсә. Әмма шулкадәр озак, шулкадәр чиксез булып тоела бу очыш, менә-менә теге күзгә күренмәгән упкын төбе пәйда булыр,менә-менә шуңа төшеп бәрелермен дә, челпәрәмә килеп юкка чыгармын сыман. Һәм әнә шул, төпкә килеп бәреләм, дигәндә генә, бөтен барлыгым белән тартышып, авырлыгымны югалткан теге гайре табигый көчне җиңәм дә... котым чыгып, уянып китәм. Мондый «упкынга атылулар» вакытында бала бер төндә тары бөртеге зурлыгында үсә, диләр. Бу кадәресе дә хак булса, мин, моңарчы Алыпның үзе кадәр булыр идем. 23 яшемә җиткәнче, өйләнгәнче шулай «мәтәлә» торган идем бит мин теге Миңлевәли бабай буасы «казанына»... Тик буем алай ук артмады.

Шул рәвешле мин, малай чактан ук, үземнең кайбер «сәеррәк» якларыма игътибар итә килдем. Мине «сәерлек» дөньясына алып кергән сәбәпләрнең берсе, мөгаен, әкиятләр белән мавыгуым булгандыр. Татар халык әкиятләре тупланган китапларны укып бетерми торып кулымнан төшерми идем.

Атилла Расих белән Адлер Тимергалиның мажаралы повестьларын укый-укый, «чәйнәп», тәмам чүбеккә әйләндереп бетергән авыл малаена

тора-бара яңа бер дөнья ачылды — рус әкиятләрен, рус телендә нәшер ителгән дөньядагы башка халыклар әкиятләрен укый башладым. Күңелемне тоташ биләп алган әкият дөньясы тора-бара тагын да киңрәк, тирәнрәк хыял дәрьясына — фантастикага барып тоташты. Андый әсәрләрне хәзер дә яратып, ианып укыйм.

Дөрес, әкият ярату әллә ни сәерлек түгел-түгелен. Әмма кешедәге кайбер сыйфатларны үстерүдә аларның әһәмияте бәхәссез, күрәсең. Баштарак мине ике нәрсә аптырашта калдыра иде. Беренчесе — сәгатькә карап тормый гына (хәер, аны тагып йөрү безгә тәтеми дә иде) тәүлек вакытын әйтү. Кыр эшләре вакытында өлкәннәрне дә гаҗәпкә калдыра иде бу тәгәллегем.

Моннан сәеррәге — уйнаганда үлән арасында югалган әйберләрне, көтүдән кайтмый калган мал-туарны эзләп табу иде. Күпчелек уеныбыз ул чакта хуш исле бәбкә үләненә күмелеп утырган тыкрыкта уза торган иде. Шунда берәребез бер уеннан икенчесенә күчкән вакытта берәр уенчыгын каядыр үлән арасына куеп калдыра да аның хакында бөтенләй оныта. Кайтырга вакыт җиткәндә, инде караңгы төшкән була, куйган әйбереңне таба алмыйсың. Икенче көнне тагын уенга җыелабыз. Эш кичә югалган уенчык — туп, курчак, «мылтык» ише нәрсәләрне эзләүдән башлана. Эзлибез, эзлибез, табылмый гына бит уенчык. Билгеле инде, мин дә табалмыйм. Шулчак кылт итеп башта нидер кузгалып киткәндәй була һәм мин, телемнән кемдер тарткан шикелле, әйтеп куям, малайлар, уенчыгыгыз миннән фәлән адым читтәрәк, әнә теге әрекмән тирәсендә, дим. Малайлар, кызык өчен, барып карыйлар һәм... югалткан нәрсәләрен, чыннан да, табып киләләр. Япа-ялгызым чакта бу сиземләвем ничектер көчлерәк, тәгәлрәк чагыла иде сыман. Авыл балалары белә торганнардыр, бигрәк тә салкын көзге көннәрдә тана, бозау, сыер ише эре маллар тау итәкләренә, болынлыкларга чыгарган җирләреннән каядыр читкәрәк китеп, «кайтырга оныталар». Шул чакта инде аларны табу малайлар өлешенә төшә. Мондый вакытларда яшьтәшләрем, гадәттә, күмәкләшеп йөрергә ярата. Эзләргә якты көздә чыгып китсәк тә, кайчан кайтып керәсен белеп булмый бит әле... Шулай да мин ялгыз йөрүне кулайрак күрәм. Берүзем чакта ниндидер көч мине үзенә ияртеп китә. Гадәттә, мин «аңа» буйсынам.

Шулай бервакыт, көзнең башы гына иде бугай әле, киттем мин кичкырын теге тыңламас тананы эзләп. Көч әйдәкли, мин барам. Иң элек тау өстендәге урман тезмәсенә мендем — юк. Аннан Улаклы урманы кисентесенә киттем. Йөрәгем җиткән кадәр урман эчендә дә буталдым — юк тана. Караңгы төшә башлады. Күзгә һәр түмгәк — төлке, һәр куак — бүре булып күренә башлады. Улаклыдан Керкәле урманының чиге дә ерак калмый. Шунда киттем. Юк танабыз. Кайтып киттем инде мин хәзер елый-елый үзебезнең авылга. Күңелемә бер уй килеп керде: «Соң, мәйтәм, шыр тиле, шайтаным кушканмы миңа шушылай чурт-чураманыннан тана эзләп йөрергә? Авыл зиратының күптән инде киртә-коймалары урыны-урыны белән череп, авып төшкән, шунда гына барып карасам, ни булган?» Киттем лүрт-лүрт атлап, абына-сөртенә авыл зираты тарафына. Зират янына җиткәч, эчкә тәмам пошаман төште. Шулчак киртә буеннан гына: «Му-у-у!» — дип, өзелеп мөгрәгән тавыш ишетелмәсенме! Аңыма килдем: безнең «Йолдыз» ич бу, мур кыргыры... әстәгъфирулла-тәүбә, көр-сәламәт буласы нәрсә!

Сиземләвемнең бер дөньяви файдасы күршебез Мөнир абзыйга да тиде. Тормышлары таза, йорт-куралары нык иде аларның, Гомер бакый ат үз кулында, арба-чанасы да һәрчак үз ишегалларында булды. Мондый крәстияннең утын сарае, печәнлеге дә буш тормый. Мал-туарлары ишле. Кышка кергәч, аларны суеп саталар да, хәйран гына акча эшлиләр. Шуңа күрә тормышлары да бөтен. Кыскасы, кышкы көннәрнең берсендә Мөнир абзыйлар, сыер суеп, базарда сатып кайтканнан соң булды бу.

Күрше-күлән арасында: «Мөнирләрнең сыер саткан акчасын урлаганнар икән!» — дигән имеш-мимеш таралды.

Шул. Мөнир абзыйның акчасы югалып, хәйран вакытлар үтте. Әллә ничә тапкырлар кар яуды, әллә ничә тапкырлар буран уйнады. Безнең төбәкләр ул чакта күрәзәчеләргә бай иде. Агаебыз, тиз арада, шуларның кайберләренә барып та кайтты. Әмма кешегә сылтап, гөнаһлы булырга кушмаганнар аңа. Югалган малың үз йортыңда, яхшырак эзлә, дигәннәр. Шуннан соң бөтен йортлары белән кубарылып, актармаган урыннары, кермәгән ишекләре, карамаган тишекләре калмады. Акча табылмады. Әрнештеләр-әрләштеләр дә тындылар...

Әтисе белән әнисе өйдә юкта, Сәгыйтьләр ишегалдында да уйнаштыргалый идек. Һәм, кергән саен, минем искә тегеләрнең югалган акчалары килеп төшә, уйларга, эзләргә мәҗбүр итә иде. Каядыр шушы тирәдә, ишегалдында гына булырга тиеш кебек. Күзем абзар-келәт тирәсенә дә, өй ягына да тартмый, һаман — җирдә. Ә җирдә — ап-ак кар инде, аннан акча түгел, озын саплы балтаны да табып алуың икеле. Яз җиткәнне, карлар киткәнне көтәргә кирәктер...

Беркөнне тагын шулай Сәгыйть белән алар ишегалдында уйнап йөрибез. Мөнир абзыйның эштән кайтыр, ә минем чыгып сызар минутлар якынлашып килә иде. Шулчак бастырып, куыш авызы сыман бераз кыйгачлап тезелгән усак киртәлекләргә игътибар иттем. Ниндидер көч мине шул «куыш» авызына керергә котырта башлады. Озак уйлап тормадым, ярым мүкәләп, ярым шуышып кереп тә киттем. Һәм... үз күзләремә үзем ышанмадым: тезеп куелган киртәлекләр арасында... кара бумажник ята иде. Суеп саткан сыерлары кебек тук, симез иде ул «акча капчыгы». Сәгыйть күргәләгәнче, тегене алып куеныма тыктым — Мөнир абзыйны куандырасым килде. Ә йөрәгем күкрәгемнән чыгарлык булып тибә. Бумажникны күргәч, ни әйтер Мөнир абзый? «Ник урладың, маңка малай, ник баштан ук кайтарып бирмәдең?» димәсме? Каеш чыбыркысы белән һәйбәтләп ярмасмы? Анысы да ерак йөрмәс бит әле аңардан...

Шулай уйлана-уйлана куыш авызыннан чыгып килә идем, Сәгыйть ачкан капкадан атын юыртып, «Һайт, аннагызны...!» — дип, Мөнир абзый кайтып керде. Әле ябарга өлгермәгән капкадан чыгып тай, дигән әмер иде бу. Әмма бу юлы мин урынымнан кузгалмадым. Мин аңа, чыбыркысын кысып тоткан килеш ул миңа карап тора. Сәгыйть капка япкан арада куенымнан теге хәерсез бумажникны чыгарып, күрше абзыема суздым. Аны күргәч, абзыемның нидер әйтергә дип ачылган авызы ябылмый калды, чыбыркысы кулыннан төшеп үк китте.

— Каян алдың? — дип кенә әйтә алды. Шулчак йөрәгем өшеп китте. «Каян таптың?» — димәде, «каян алдың?» диде бит...

— Алмадым. Таптым. Әнә тегеннән... — һәм мин куышлыкка төртеп күрсәттем. Ниндидер эш кушып, малаен өйгә кертеп җибәргәч, капыл каушап китүдән калтыранган куллары белән ул кар эчендә ятып беркадәр дымланган акчаларны санарга керешә. Фәлән мең дә, фәлән йөз дә, фәлән сум чыкты (ул чакта 1961 елгы акча реформасына 4-5 ел чамасы вакыт бар иде әле).

— Дөрес чыга, — диде ул. — Кара аны, малайга да, хатынга да, атаңнарга да ычкындырасы булма! — һәм ул аяк астында яткан камчысына карап алды.

Мин, әлеге мәрәкәдән шулай җиңел котылуыма сөенеп, бу юлы бәләкәй капкадан гына чыгып шылдым. Шулай да Мөнир абзый таләпләрен үтәп бетерә алмадым. Бу кадәр серне күңелем сыйдыра алмады — берничә көннән мин аны барыбер әти белән әнигә «тиштем». Кирәкмәгән эшкә тыгылып йөргән өчен әй әрләделәр дә соң үземне! Аннан соң, олы җәнҗал ихтималыннан котылуларына үзләре дә сөенеп бетә алмадылар. «Бәхетең, акчасы исән сакланган да, үзең тиешенә дә кагылмагансың! Шундый итеп укыткан булыр идем арт сабагыңны, гомереңдә дә онытылмаслык булыр иде!» — диде әнием соңыннан...

* * *

12—13 яшьләремдә мин, башымны югалтырлык дәрәҗәдә гашыйк булдым. Мин, адәм рәтле өс-баш киеме дә күрмәгән гап-гади бер сугыш гарибенең малае, укытучы баласына, чәчәк кебек киенгән, курчак кебек пөхтә, зәп-зәңгәр күзле, матур нечкә иренле кызга гашыйк булдым.

С. безнең авылга әнисе белән килде. Ул чакларда мин татар халык әкиятләре белән җенләнеп, аларны яттан диярлек белә идем инде. Һәр укыганым күз алдымнан кабатланмас рәсем булып узганга, малайлык елларымдагы иң көчле мавыгуларымның тагын берсе рәсем ясау иде. Баһадир ир-егетләр дә, нечкә билле, калку күкрәкле, су алып кайтканда билләре сыгылып-тирбәлеп торган сылу кызлар да — барысы да күңел төпкелемә кереп урнашканнар иде инде. Әмма С. ул кызларның берсенә дә охшамаган иде шул. Татар әкиятләрендәге татар кызы түгел иде. «Буратино» әкиятендәге Мальвина инде менә!.. Иске район үзәгендәге урыс мәктәбендә укый иде ул. Җәйге, кышкы каникул көннәрендә безнең арада була, укыганда ял саен диярлек кайтып йөри. Менә шул кыз бөтен йөрәгемне йомарлап алды диярсең. Кайда булсам, нишләсәм дә, уемда — ул гына... Тумас борын, диҗәндәй, баш дигәнем тәмам югалды, бары тик дөрләп янган йөрәк кенә калды! Ике җәем, ике кышым үтте шулай. Язга кергәндә...

Куанычлы төш күрдем. Яхшы укыганым, җәмәгать эшләрендә тырыш булганым өчен мине район үзәгендә узачак пионерлар слетына делегат итеп сайлаганнар, имеш. Шулчак йөрәгемнең ничек талпынганын белсәгез икән сез!? Үзегез дә абайлагансыздыр инде — Ул да булачак иде бит слетта! Шундый матур, шундый зирәк кызның әлеге тантанага килми калуы мөмкин түгел! Очына-талпына Шөгергә барырга җыенам, имеш. Менә слет делегатларын утырткан ачык машина юл сикәлтәләрендә бии-бии Шөгер эшчеләр поселогын узды, тау битендә тәкъва гына утырган мәчетле Иске Шөгер авылын үтте дә, Бәкер тавына күтәрелеп, сабан туе мәйданына якынлаша башлады. Әнә былтырдан калган туры колга белән кыек колга, капчык сугышы өчен көйләнгән «бүрәнә ат». Мәйдан тирәли — ике көпчәкле җиңел арбаларда чаптарлар ярышы өчен түшәлгән юл боҗрасы. Бәкер курортына ял итәргә баручыларның бәлки моңа игътибар да иткәннәре бардыр — тау менгәндә мәйдан сул тарафта кала.

Машина мәйданга житеп килә, ә анда инде башка мәктәп балалары әвәрә килә, имеш. Ә мин, күзләрем авыртыр дәрәҗәдә текәлеп, а н ы эзлим. Машина килеп туктауга, әрҗәдән төшеп, борчаклар шикелле, мәйданга сибелдек. Ә мин а н ы эзләп киттем. У л да делегатлар арасында, безнең авылдан килгән машинаны күзәтеп тора, имеш. Очрашу мизгелләрен сөйләп тормыйм. Яшерен янулардан тәмам гаҗиз булып, эчемдә янган утларымны, күкрәгемә сыймаган хисләремне аңа әйтергә дип талпынам, имеш. Ә ул, гадәттәгечә, авылыбызның иң саф, иң матур салкын чишмәсе сыман һаман чылтыр-чылтыр көлә, миңа сүз әйтергә бирми. «Әйдә, башта куып тот син мине, аннан соң әйтерсең!» — ди. Шулай дип, йөгереп тә китә. Аны куып тотарга өметләнү — минем өчен акылсызлык. Ул мәктәпләрендә генә түгел, районда да оста йөгерешчеләрдән санала. Җил артыннан куд ын ни дә, миңа, спорттан ерак йөргән малайга, С. артыннан йөгердең ни... Әмма минем бирешер чамам юк. Бүген минем язмышым, мәхәббәтем хәл ителә: мин үз сүземне әйтергә, җанымнан якын күреп йөргән кызның җавап сүзен ишетергә тиеш. Яки — яки! С. шундый оста, шундый җитез чаба, табан асларыннан тузан күтәрелергә дә өлгерми хәтта! Мин дә чабам. Менә инде аз-азлап аңа якыная да башладым. Арабыз — кул сузымы гына. Тагын бер ыргым ясасам... Менә бәла! Янәшәбездә генә нindидер бер малай велосипедта бара икән бит. С. кинәт читкә тайпылып, теге малайны «ияреннән» кагып төшерде дә, педальләрне тиз-тиз әйләндерә башлады. Тотарга үрелгән бармакларым багажник тимерләренә генә тиеп калды. Үзе тизләгән

арттыра С., үзе артына борылып карый-карый рәхәтләнеп көлә. Ара ерагайды. Газиз сүзләр әйтелми калды...

Инде слет башланган да икән. Менә слет әләмен күтәрү тантанасы. Аны район мәктәпләреннән иң яхшы саналган өч укучы күтәрәчәк. Беренче булып а н ы ң исемен әйттеләр һәм... өченче булып минем фамилиям яңгырый, имеш! Менә бәхет, менә тантана! Бөтен район укучылары алдында мин а н ы ң белән басып торачакмын!

Инде кич булып, слетның йолдыз-учагын кабызырга вакыт җиткән, имеш. Ике укучы, учакның уртасында, бишесе — биш почмагында ут төргезергә тиеш икән. Без а н ы ң белән уртага туры килгәнбез. Шулкадәр тиз сызды ул шырпыны, учакны шулкадәр тиз кабызып җибәрде. Авызымны ачкан килеш аңа мөкиббән китеп кулымдагы шырпы кабын ачалмыйча интектем, аннары ниһаять, шырпы кабызып та, утыннарга ут элдерә алмый соңардым. Ул килеп булышмаса...

Учак телләреннән меңнәрчә очкын-йолдызлар аерылып, күккә үрли, җемелдәшкән йолдызларга табан ашкына, имеш. Ә без, аның белән кулга-кул тотынган килеш, шул очкыннарга карап, үз хыялларыбызга чумганбыз. Учак яна. Учак телләреннән күккә бөркелгән очкыннар йолдызларга очам дип талпына. Талпына да, күпмедер үрләгәч, җем-җем килеп сүнә, югала. Ә йолдызлар еракта, бик еракта икән шул. Аларга барып җитү мөмкин түгел икән. Янымда басып торган өмет йолдызым асылда әнә шул вакытлыча гына кабынган балачак йолдызының бер очкыны гына икәнлеген аңлау, озакламый мәңгелеккә югалтасымны тоемлаудан бәгырем өзгәләнә, имеш...

Бу төшемне мин апрель урталарында күрдем шикелле. Пионер бәйрәменә айдан артык вакыт бар иде әле. Һәм мин аны ниндидер тыелгысыз ашкыну, тәкатьсез бер талпыну белән көттем. Слетка мине дә җибәрерләр, төшемдә күргәннәр барысы да кабатланыр, төшемдә әйтәлми калган газиз сүземне, һичшиксез, әйтермен сыман тоелды.

Май бәйрәмнәре узды, пионер бәйрәме якынлашты. Һәм... мине слетка делегат итеп сайладылар! Ачык машинага утырган мизгелдән хисләр, кичерешләр, вакыйгалар кабатлана башлады. Әле күптән түгел генә күргән киноны яңадан караган сыман. Машинадан төшкәч очрашулар, юртакларның чабыш юлында куышулар, тотам дигәндә генә аның бер малайны велосипедыннан «кагып» төшереп, үзе утырып китүләре, шул сәбәпле әйтер сүземне әйтәлми калуларым, әләм күтәрүләр, учак кабызулар — барысы, барысы да. Бу — гомеремдә иң бәхетле вә иң кыен көннәремнең берсе булгандыр һәм шул көн минем өчен ике мәртәбә кабатланды. Бөтен нечкәлекләренә кадәр диярлек!

Башкаларыныкы кебек үк, бу төшемнең дә асыл мәгънәсенә бүгенгә кадәр төшенә алганым юк. Моның белән ни әйтергә теләде миңа Табигать? Нәрсә аңлатты? Мәңгегә хәтердә уелып калачак балачак мәхәббәтенең учак очкыныдай кыска гомерле булуынмы? Моның шулай икәнлеген мин инде ул елларда ук аңлаган идем бит югыйсә. Җебек, оялчан идем. Кызларны канатларын күлмәк астына яшереп йөрүче фәрештәләргә санадым. Якын килергә базмадым. Гади җир сүзләре белән дәшәргә кыймадым. Шигъри сүзләр исә әлегә күңелемдә бөреләнеп кенә килә иде. С. кебек чая кызларның үзләреннән дә чаярак, гадәттә, үзләреннән олырак үсмерләрне, бәлки әле егетләрне ярatканнарын кайлардан белеп бетерим ди мин ул чакта?!

Ә тормышта туләем кабатланган теге төшне мин барыбер ни белән дә булса аңлатудан гаҗиз. Монда минем аңым да, акылым да ирешмәслек ниндидер Бөек Сер яшеренгән...

Слетта С. белән соңгы тапкыр очраштык та инде без. Шуннан соң ул бер генә тапкыр да минем төшемә кермәде...

Авылыбызда сигезьеллыкны тәмамлап, Иске Шөгер урта мәктәбенә килдем. Башка авылдашларым-классташларым да байтак иде. Тугызын-

чы класста укый башладым. Чит-ят укытучыларга күнегү ифрат авыр булды.

Менә унынчы класс... Балтасы суга төшкән кешедәй күңелсезләнеп, җаныма урын табалмый йөргән вакыт. Җитмәсә, өзелеп-өзелеп авылны сагынам, җитмәсә, тагын С.не сагынулар бәгырьне телә... Шундый көннәрнең берендә ничектер шулай И. белән сөйләшеп киттек. Ишле гаиләдә үги ана белән яши икән. Кагу-сугулар да булгалап тора икән. Тора-бара дуслашып киттек. С.нең үсмер хәлендә уелып калган кабатланмас сурәте күңелемнең ерак төпкеленә бикләнде. Мин шунда үзем өчен ифрат җайсыз бер сыйфатым барлыгын аңладым. Аралашып киткән кешемә бик тиз ияләшәм, якынаям, юксынудан ихлас газаплар чигәм икән... Әмма кешедән күңелем бер бизсә, бәгыремә утырган салкын боз һичкайчан да башкача эреми икән инде. Баштарак икенчесеннән битәр беренчесеннән курка идем. Армиядән кайтып, «ыштансыз студент» килеш гаилә корып җибәргәч тә байтак еллар, хәер, әле хәзер дә чамасыз чибәр, ниндидер көч белән үзенә тартып, күңелне кытыклап торган хатын-кыз затларыннан читтәрәк йөрергә тырышам. Ялгыш берәрсе күңелгә якынаеп китәр дә... аннан соң аллам сакласын! Төмрәеп торган сөекле газиз хатыныңны кая куярсың?! Хәер, соңгы елларда куркуымның беренче өлеше инде бетә бара — иллегә җитеп килгән ир кайсы кызга кирәк?! Ә икенче өлеше ар-тирә кыймылдап куя: йа ходa, бердәнбер хатынымнан биздерә күрмә, дим...

Бу кадәресе белән бераз алгарак киттем шикелле. И. белән дуслашуым хакында сөйли башлаган идем бит әле. Шул. Һич көтмәгәндә, уйламаганда дигәндәй, кинәт ияләнеп киттем аңа. Ярата башладым. Әмма аның тарафыннан да мәхәббәт казандым дип әйтәлмим. Мәхәббәтемне кабул да итеп бетермәде ул, кире дә какмады.

Унберьеллык мәктәпне тәмамладым. Казан дәүләт университетына укырга кердем. Аннан армиягә алдылар. Хезмәтем Көнбатыш Казагыстан шәһәрләренең берсендә башланды. Казармаларыбыз — кайчандыр легендар Чапаев дивизиясеннән калган ат абзарлары. Караңгы төстәге мастикага буялган идәннәр. Кара одеяллар җәелгән ике катлы караватлар. Томаулы борынга да нашатыр спиртыдай ярып керердәй яман тир, вакса исе... Иркен кырлар-болыннар, әкияти урманнар иленнән килеп кергән табигать баласы күңеленә юылмас юшкын булып утыра иде бу күренеш. Ямансулата, сагыну хисен бермә-бер арттыра иде. Шунлыктандыр инде, өйгә дә, И.гә дә атнасына икешәр-өчәр хат яза торган булдым. Сагыну сагышлары белән мөлдерәмә иде ул хатлар...

Ана күңеле балада, баланыкы далада, дигәндәй, әти-әнидән бигрәк төшләремә И. аеруча еш керә иде. Иң истәлеклесе менә монысы булды. Ул елларда Иске Шөгер авылының ике катлы мәдәният йорты эшли генә башлаган иде әле. Авыл яшьләре белән без төрле тамашалар әзерлибез, концертлар белән тирә-күрше авылларга да чыгып керәбез. Культура йорты директоры Р. абый бик җор кеше, сыңар куллы булуына карамастан, телләрен сул якка әйләндерә дә теттереп гармунда уйный...

И. мәдәният йортының икенче катына урнашкан директор бүлмәсендә, Р. абый янында утыра, имеш. Озын җинле озын кара күлмәктән. Йөзе борчулы. Тырышып-тырышып Р. абыйга нидер аңлата, имеш. Шуннан соң кинәт безнең капка төбе пәйда булды. И. белән мин шундагы эскәмиядә утырабыз. Ул инде ап-ак күлмәктән. Икебез дә шундый шат!

Мин бу төшне ни дип юрарга да белмәдем. Әллә ни хикмәт тә эзләмәдем. Р. абый белән бергәләп концертлар куеп йөргән кешеләр ич без... Шундый серлерәк төш күрүемне И. белән дә уртаклашмый калмадым, билгеле. Ничек күрсәм шулай бәйнә-бәйнә хатка да яздым.

Ниһаять! Зарыгып көткән чираттагы хатым килеп җитте. Кош теле кадәр генә дип булмастыр монысын. Конверты шактый калын күренә. Безнең частьта, хат килгәч, бәхетле хат иясенең борынына атнаның фәләненче көне санынча әлеге конверт белән сугу гадәткә кергән иде. Бу

хат килгәндә атнаның соңгы көне булгандыр, күрәсең, хатны кулыма алганчы, борынымның бузарып чыкканы хәтергә кереп калган. Озын сүзнең кыскасы, түземсезләнеп хатны ачам. Гадәттәгечә түгәрәк, матур хәрефләр буйлап күз карашым белән йөгерергә керешәм. Тик бу ни бу? Гадәти хат башламыннан соң күзләрем, сөрлегеп, туктап кала. Бөтенләй дә мин көткән хат түгел ич бу! И. ут иткән ич монда мине, дөньяда яшәрлегемне калдырмаган. Мин, дигән, сине җүнле генә кешегә санап йөри идем, дигән, ә син, фәлән дә фәсмәтән, минем арттан «койрык» калдырып киткәнсең, дигән. Кыскасы, биргән генә кирәкне! Һәм бик дөрес биргән. Нигәме? Үз хикмәте булган икән шул әлеге төшнең. Әйе, дип дәвам иткән сөеклем, Р. абый мина байтактан битараф түгел, дигән. Син армиягә киткәч, ул мине берничә тапкыр озата да килде. Шаярып кына берничә мәртәбә үбештек тә. Халык арасында имеш-мимешләр дә чыкты бугай. Әмма син бит яхшы беләсең, Р. абыйның җәмгате, балалары бар, мин аңарга кияүгә чыгарга җыенмыйм, дигән. Һәм башкалар, һәм башкалар... Башыма гөрзи белән китереп ордылармыни, миңгерәп киттем хәтта. Көчкә укып чыктым да, дөньяда юк сүзләр белән үземне сүгәргә тотындым: ахмак, сантый, сарык... Соң, күрәләтә кем шундый хат яза инде сөйгән кызына? Шундый хаттан соң кем сиңа рәтле җавап язсын инде, йә? Шул кирәк сиңа, башыңа ни килде шуны язып ятмассың бүтән... Әмма күпмедер гомер узгач, төш белән өн арасындагы тәңгәллек минем күңелгә көя күбәләге булып төште, бәгыремне кимерә башлады. Ул күбәләкнең исеме халыкта «көнчелек» дип йөртелә шикелле. Һәм шул төш димме, ул күңелгә салган «көя күбәләге» димме, И. белән булачак мөнәсәбәтләрне хәл итте — армиядән кайтып, бер очрашып аңлашканнан соң без аның белән мәңгелеккә аерылыштык. Әмма шуннан соң ул озак еллар минем төшләремә кереп изалый торган булды. Адымнар белән барып җитәрлек, әмма кул сузымы җитмәс арадан торып, сүзсез, әмма чиксез үпкәле карашы белән җәзалый торган булды ул мине. Намусына тап төшерердәй бер гамәл дә кылмаган идем, югыйсә... Ә менә шундый төшләремнең тормыштагы әһәмияте турында уйлана башлагач, әлеге төшнең язмышымдагы иң мөһим борылышларның берсен ясарга мәҗбүр иткәнлеген икеләнми әйтә алам.

Дөньяны танып белгәндә, бер-беребез белән аралашканда без — берничә тойгы ярдәмендә эш итәбез — күрәбез, ишетәбез, тәнебез белән тоябыз, әйберләрнең исен, тәмен аерабыз. Әмма еш кына үземне дә сискәнергә мәҗбүр иткән тагын бер тойгы турында сөйлисем килә. (Миндә генәдер димим, бәлки шундый ук тойгыларны сезнең дә кичергәнегез бардыр...)

Армиядә, И.гә бәйле төш күргән чорларда булды бу хәл. (Казагыстанда мин нибарысы өч кенә ай хезмәт иттем.) Солдатларга азга гына бирелә торган буш вакыт. Бу вакытта гимнастеркага ак яка тегәсең, өс-башыңны тәртипкә китерәсең, хат язасың, китап укыйсың. Шулай хат язган чагым иде. Рөхсәт ителмәсә дә, караватка утырып, каршыма куйган урындыкта язам. Гарәп хәрефләре белән. Авылдагы әдәбият укытучыма, Әюпова Рәхимә апага. Шулчак казарма ишеге ачылды (мин аңа аркам белән утыра идем), аннан култык астына гәзиткә төхтәләп төрелгән китап кыстырып, өлкән сержант Барышев килеп керде. Ике катлы караватлар хасил иткән аралыктан узып, ул үз караваты янына килде, теге төргәген култык астыннан алды, тумбочка ишеген ачты һәм, төргәген куярга дип, иелә башлады. Мин сискәнеп киттем. Кәпә-көндез, күзләрем ачык килеш төш күреп утырмыймдыр ла?! Мин ялт итеп артыма борылдым — өлкән сержант чыннан да, иелеп, тумбочкасына төхтәләп гәзиткә төрелгән китап куеп тора иде. Төргәген куйгач ук минем янга килде. Караватка утырган өчен ЦУ («ценные указания». Командирлар әрләвен солдатлар үзара шаяртып шулай дип йөртәләр) бирергә иде исәбе. Әмма гарәп хәрефләре белән «сырлана» башлаган хатны күргәч, минем шундый «сәләтем» барлыгына шаккатып (бию,

мандолинада уйнау кебекләрен күрсәтергә өлгергән идем инде), дустанә шелтәләү белән генә чикләнде. Дөресен әйтим, хезмәтемнең беренче көннәреннән үк кешелеклеге, кечелеклеге, шул ук вакытта акыллы таләпчәнлеге өчен хөрмәт итә идем мин аны. Ул мине тырышлыгым өчен ярата иде. Ә элемтә гаскәрләрендә, аяклардан бигрәк, баш белән бармакларны яхшы эшләтергә кирәк. Арка белән «күрү» сәләтемнең иң көчле чагылышы әнә шул көнне булды. Шуннан соң һичкемне, һичнәрсәне «арка белән күргәнем» юк. Әмма, үзем дә аңламастан, култык астына төргәк кыстырган өлкән сержантны ишектән алып үз урынына кадәр дистәләрчә адым ара узган вакытта ниндидер «локатор» белән күзәтеп утырганым хак.

Күргән төшләремнең истә калган кадәресен кабат хәтеремдә яңартып утырганда (кызганыч, аларны теркәп бару элегрәк уема килмәгән. Килсә дә, теркәп бара алмаган булыр идем, бәлки. Үкенечкә, Гариф Ахунов, Рабит Батулла кебек әдипләребездәге көнләштерерлек төгәллекне Хак Тәгалә миңа биреп җиткермәгән) мин бер нәрсәгә игътибар иттем. Күргән төшләремнең күбесе мине өндәге вакыйгалардан ныграк тәэсирләндергәннәр икән. Күңелле, шатлыклыларына караганда, моңсулары күбрәк булганга, алар йогынтысыннан шактый озак арына алмыйча интегә идем. Кемнәрдер тарафыннан үзем өчен куркыныч нәтиҗәләр чыгарылу ихтималы булса да, мин монда дөресен әйтергә тиеш: өнемдәгегә караганда, төшләремдә реальрәк яшимдер сыман тоела иде миңа. Мисалга шундыйларның икесен китерим.

Армиядән Казанга Октябрь бәйрәмнәреннән соң гына кайтып, укуымны дәвам иттерергә азапланып йөргән вакытлар. Тулай торакта урын калмаган. Стипендия юк. Өстә — старшина формасы. Анысы декан, проректор, ректорлар бусагасын таптап, бүлмә, стипендия «яулар» өчен кирәк. Солдат хезмәтенә киткәнче булган курсташларым Сәгыйть Хафизов (хәзер галим, Башкортстанда яши) һәм Харрас Әюпов (шагыйрь) бүлмәсендә урындыклардан тезеп салган «ятак»та төн кунам. Көннәрем лекцияләрдә һәм проректор бусагасын таптап уза. Тартыш каты бара. Йә «старшина» Дәрзаманов проректорны җиңә, йә проректор — Дәрзамановны. Старшина кителе җиңде бит тәки! Әле үземә генә түгел, армиядән әйләнеп кайткан тагын бер курсташыма да торактан урын алып бирештем. Яз көннәре җитеп, шулай бүлмә алу куанычыннан канатланып йөргән мәлдә... Бөтен бәйрәмне бозды да куйды бер төш.

Язгы көн. Күктә кояш. Күңел күтәренке, кәеф шәп. Ниндидер семинарда искиткеч җавабым белән группадашларымны да, укытучымны да шаккатырып, горур гына кыяфәт белән тулай торакка кайтып киләм, имеш. Тукта! Чү! Ачык тулай торак тәрәзәләренең берсеннән илереп, тилмереп кычкырган аккош тавышы килә. Нигә шулай үрсәләнеп кычкыра ул, кемнәр изалый, кайсы кансызы җәзалый шулай?! Тукталыштан бар куәткә тулай торакка чабам. Йөрәгем ярылыр чиккә җитеп тибә. Мин чабам, тулай торак исә акрын гына читкә бара сыман. Ниһаять, ишек. Аны каерып ачып, коридор баскычына атылам. Чамасыз көчәнүдән аяк тамырларымны авырттыра-авырттыра баскычлар буйлап өскә йөгерәм. Соңгы аралык. Соңгы арата. Ә колагымда — хәлсезләнгәннәнхәлсезләнә барган аккош тавышы... Коридордан җил булып кына узам. Атылып, бүлмә ишегеннән килеп керәм. Әмма соң икән шул инде. Аккошым тынган. Бүлмә, җәйге көндә кар өермәсе уйнагандай, ак йомшак аккош мамыгы белән тулган. Ә егетләр шаркылдап көлешәләр — аккош шулпасы пешерәләр икән...

Шушы төштән калган авыр тойгылар бер генә түгел, берничә еллар эзәрлекләде. Лекцияләрдән кайтып, тулай торак ишегенең тоткасына кулым орынуга, колагымда тилмереп кычкырган аккош тавышы ишетелгәндәй була да, тетрәнеп китәм. Бүлмәгә аңлатып булмый торган эчке бер курку белән якынлашам. Ишекне ачармын да, ак мамыкка баткан

урын-жирне, тынсыз, җансыз яткан аккошымны, миңа карап шаркылдаган бүлмәдәшләремне күреп, йөрәгем ярылыр сыман тоела...

Вакытында мин, шушы төшкә нигезләнеп, бер хикәя дә язган идем. Күпкә күләмлерәк, күпкә хислерәк иде ул. Әмма мине тетрәндергән нәрсә хикәя белән танышкан дусларымны битараф калдырды. Нәрсә турында икәнлеге аңлашылмый диделәр. Аңлаешсыз язманың чүп булып ятмавы хәерлерәк, дип, кулъязмамны чүп чиләгенә тондырдым. Ә хәтер барыбер үзенекен саклый...

Хәзер мин бу төшне табигатьнең үлем алдыннан җан авазы белән безгә дәшүе, үз җаныбызның үзебезгә илереп ялваруы дип кабул итәм. Аккошыбызны — бәхетебез, киләчәк язмышыбыз, киләсе буыннарга тормыш, яшәү чыганагы булган Табигать-ананы шулай шыр кычкыртып мәсхәрәләмибезмени без?!

Әлеге төшем мине табигатькә бөтенләй башкача карарга өйрәтте. Хәтта гади күзгә яхшылап күренми дә торган бөҗәкнең дә безнең кебек үк ж а н и я с е икәнлеген, аңа да бары тик б е р г е н ә г о м е р бирелгәнлеген, безнең бу Җиһанда яшәргә күпме хакыбыз булса, аларның да нәкъ шулкадәр үк хаклары барлыгын аңларга, аларны җәберләмәскә, аларны я р а т ы р г а өйрәтте.

Төшләремнең бер ишләре ак-кара, күп очракларда исә төсле булып керә. Баксаң, бу хәл очраклылык кына түгел икән. Кичерешләргә, аеруча үзенчәлекле вакыйгаларга бәйле төшләр, гадәттә, күптөсле булып керәләр.

Сөйләргә җыенган яңа төшемне миләүшә төсендәге буяу белән ясалган рәсемгә тиңләргә мөмкин. Шундый картиналар була, аны бер генә тапкыр күрәсең, әле анда да күз сирпеп алган буласың, әмма ул инде синең гомерең буена истә кала. Нинди дә хәрәкәт, динамика юк иде анда. Үзеңне гаҗәеп бу табигать күренешенең уртасында дип тә, шул күренеш тасвирланган картина алдында дип тә хис итәргә мөмкин иде.

Чалт аяз көн. Бөтен дөнья миләүшә төсендә. Ул тотенсыман ярым үтә күренмәле томанны хәтерләтә. Кипарислар сыман күккә сонган агачлар, дөресрәге, агачлар сыман биек, әмма урман аланлыкларында, су буйларында гына үсә торган тана койрыгы (люпин) чәчәкләрен хәтерләтүче искиткеч матур куе әрәмә булып үскән үсемлекләр дә миләүшә төсендә, чәчәкләре — аксыл миләүшә, яфраклары — куе миләүшә, кәүсәләре — кара-кучкыл миләүшә... Кайчандыр үзем күргән манзарадан бигрәк, күңелемә күктән, Галәмнең ерак бер төбәгеннән иңгән сурәт булып хәтердә калган ул. Шул гаҗәеп манзараның уртасына басып, таң калып карап тору, минә хәзер күргәндәй хәтердә саклана.

Гаилә корып җибәргәч, кайбер үземне сәерсендергән хис-тойгылар, мин, гайре табигый, дип санаган кичерешләр юкка чыкты, дигән идем. Алай ук түгел икән.

Шуларның берсе — о ч у галәмәте. Төпсез упкын төбенә атылулар, күккә ашулар белән кайчан алышынгандыр, тәгаен белмим. Әмма 40 яшьләргә кадәр төшләремдә мин еш кына о ч а башладым. Төшләрендә очып караган яисә әле хәзер дә ул халәтне кичерә торган кешеләр мине яхшы аңларлар. Ул тойгыларның чынын бары тик галәм гизүчеләр генә татый торганнардыр. Упкынга төшү белән күкләргә очу арасында бер уртаклык бар: аларның икесе вакытында да тән, гәүдә авырлыгын тоймыйсың. Аерма зуррак: беренчесендә һәр мизгелдә бәрелеп үлү куркынычы яnaса, икенчесендә бөтен барлыгыңны аңлатып булмаслык куаныч, шатлык хисләре били. Һәм ул атылу-очышлар күпчелек очракта очкыч машина яки башка җайланмалар белән бәйләнмәгән була. Шунысы кызык, әлеге очыш хисен татып уянганнан соң күңелнең ничектер сафланып, җиңеләеп, чистарып калганын тоясың. Алай гына да түгел, өстеннән очып узган урыннар аермачык булып кабат күз алдына килә. Әйтерсең лә, тән ятакта ял итеп яткан арада җан күкләргә ашып, ерак төбәкләрдән сәяхәт итеп кайткан...

Төшләремдә татыган очыш хисләре бер-берләренә ифрат охшасалар да, очыш алдыннан булган халәт һәм очыш шартлары төрлечә. Бер очракта ничектер кош сыман кулларымны җәеп, талпынып очсам, икенчесендә үземне кинәт күктә хис итәм. Очышларым, нигездә, туган авылым, аның елга-күлләре, урман-кырлары, мәһабәт Урал тауларының чылбыры саналган тәбәнәкле-биекле таулары белән бәйле. Алар өстеннән очып узу яки берара гына тилгән сыман «эленеп» тору шундый рәхәт! Балачак һәм яшьлек елларымда мин аларның күбесен җәяүләп уздым, елгаларында балык тоттым, су коендым, кырларында җир сөрдем, иген урдым, бер эшсез, күңел өчен генә табигать кочагына кереп югалган чакларым да аз булмады. Шунысы гаҗәп, алар өстеннән чынлыкта бер генә тапкыр очып узганым булмаса да, төшләремдә мин аларны югарыдан танныйм: кайсы урман, нинди алан яки тау икәнлеген әйтеп бирергә була.

Очыш хисе капыл башлана. Ул күңелгә бик хуш килсә дә, кинәт түбәнәя яки төшә башласаң, куркыныч. Төшләремнең берсендә, мәсәлән, үзебезнең авыл урамына килеп төшкәнмен, имеш. Очыш тизлегем беткән. Җан фәрман йөгерәм, дүрт-биш адым баргач, җирдән аерылам да, кабат төшәм, тагын йөгерәм... Борылыш артында гына өебез, имеш. Кичке эңгердә уты кабызылган якты тәрәзләре балкый. Әмма очыш тәмамланган, өйгә кайтып җитәрлек хәл калмаган... Мондый чакларда куркып уянасың, йөрәгең күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибә.

Чаңгы киеп... Шөгер урманнары өстеннән, мәктәп елларымдагы мәхәббәтем И. яшәгән йорт тирәсеннән урап узганым бар... Ниндидер билгесез урман, кыя ташлар өстеннән очканда үземә төбәлгән мылтык көпшәсен күргәч, кинәт түбән атылып, котым алынып, куркып уянганым бар... Тирә-якта кара бушлык. Тирә-юньдә эреле-ваклы бихисап йолдызлар. Шулар арасыннан аңлатып булмаслык тизлек белән Җиргә төшеп килгән мизгелне күргәнем бар...

Бервакытны, йомшак кызыл келәмгә утырып, борынгы авыл өстеннән очтым. Аста — түбәләре салам белән ябылган бәләкәй-бәләкәй генә өйләр, ишек алларында кисап-киләләр, чирәмдә бәбкәләрен ияртқән казлар йөри...

Бер халәт турында кабатлап әйтәсем килә: әлеге очышлар вакытында кичергән тойгылар бик озакка хәтердә кала, реаль сәяхәт тойгысын уята. Мондый төшләрнең талантлы рәссамга керүе хәерлерәктер. Ул аларны сәер әсәрләрдә сурәтләп бирер иде.

Төшләрдә очыш хисен 40 яшьләргә кадәр еш кичердем. Соңгы вакытларда исә ирекле очыш ләззәте егылып төшүдән курку тойгысы белән аралаша башлады. Һәр нәрсәнең үз вакыты була, күрәсең. Минем «очыш»ларның да сәгате тулгандыр, вакыты чыккандыр, дигән идем дә... Әлеге кульязманы төгәлләгәндә генә... тагын «очтым» бит, әй! Тәнемнең дип әйтимме, җанымның диимме, кайсыдыр бер күзәнәге бу фикерем белән килешеп җитмәде, күрәсең.

Студент елларымда, иш янына куш булыр дип, аннан соң Татарстан радиосында мөхәррир булып эшли башлаган көннәремдә, гаиләмне 6 квадрат метрлы подвалдан куып чыгармасыннар дип, алты ел чамасы урам себердем. Ул еллар артта калды инде. Әмма... Бу төшем шундыйрак нәрсәдән башланып китте. Эшләп-эшләп, язып-язып та дөньяның очын-очка ялгый алмагач, тагын урам себерү эшенә керешкәнмен, имеш. Йомшак ястык сыман түшәлеп, ап-ак кар явып киткән. Дүртенчедә укый торган кечкенә кызыма да көрәк тоттырдым да икәүләп эшкә киттек. Кәеф шәп. Беләкләрдә көч элеккечә уйнап тора, имеш. Ындыр табагында бөртек җилгәргәндәй кар көрәргә тотындык. Тик... җәй икән бит. Мин озы-ын саплы себеркене кулыма тоткан килеш, өйгә кайтып барам икән. Тик таныш булмаган урамнан китеп, шәһәрнең икенче бер читенә барып чыкканмын. Гаҗәп! Казан түгел ич бу! Мин гомеремдә дә күрмәгән, әмма бик таныш бүтән шәһәр. Асфальт юл янәшәсеннән сөзәк кенә

дамба күтәрелеп китә. Ул күпереп торган яшел чирәм белән капланган. Йөз — йөз илле адымнар чамасы югарыдарак кызыл кирпечтән салынган түгәрәк манарасыман корылма. Манараның ике ягыннан да, аз гына почмак ясап, кызыл кирпеч дивар сузылган. Ә кызымны... онытып калдырганмын лабаса! Өйгә кайтып китте микән? Әллә, мине эзләп, күз яшьләрен түгәме? Тизрәк, тизрәк кайтып житәргә кирәк! Әмма кайта белмим — юлны оныткынмын. Тукта, мондый чакларда оча идем түгелме соң мин? Турник тимеренә эленгән шикелле, себерке сабына ике куллап ябыштым да, йөгереп киттем. «Күтәрелеп кенә китә күр, өемә, балаларым янына илтә күр!» — дип, эчемнән генә себерке сабына ялварам. Берничә адымнан күтәрелеп тә киттек, рәхмәт төшкере! Чытырдатып күзләремне йомдым, ачсам, егылып төшәрмен кебек. Шулай да бер мизгелгә ачтым күзләрне. Ниндидер тирән чокырлар, ерганаклар өстеннән очам икән. Урманны да уздык. Таныш бакчалар. Әмма өйгә кадәр житә алмадым. Күңелемне биләп алган билгесезлек, бушлык, чарасызлык хисеннән сискәнеп уяндым...

Чарасызлык дигәннән, бу хис минем байтак төшләремә хас нәрсә. Мин моның сәбәбен берни белән дә аңлата алмыйм. Бәлки балачак тәрбиямдә ни дә булса житешмәгәндер. Бәлки башка сәбәпләр бардыр. Мин үземне белгәннән бирле үземнән, кылган гамәлләремнән, эшләгән эшләремнең нәтиҗәсеннән канәгатьләнү хисе кичерә алганым юк. Ул хис туса да, балкып алган яшен яктысы сыман гына. Бәлки моның да йогынтысы юк түгелдер... Әмма төшләремдә мин еш кына тозакка килеп эләккән кеше хәлендә калам. Аларның һәммәсе матур гына башланып китә югыйсә. Әйтик, матур гына бинага килеп керәм. Матур гына бүлмәләрдә йөрим. Бермәлне мине нидер ашыктырырга тотына. Кемдер, нәрсәдер эзәрлекләргә керешә. Алдымда бер-бер артлы каршылыклар, киртәләр туа башлый: әйтик, йөгереп барган җирдән тузанга, чүп-чарга манчылып беткән базга килеп төшәм, һавасызлыктан изаланам, аннан мең бәла белән үрмәләп, ниндидер тар аралыкка килеп керәм, инде иркен һавага килеп чыктым дигәндә, түшәм белән түбә тоташкан кыекка барып төртеләм... Урыслар моны «кошмар» диләр. Хәер, биш гасырга якын шушындый кошмарда яши бит инде татар халкы. Казан ханлыгын Явыз Иван яулаган уналтынчы гасырдан бирле. Һәм хәзер дә шундый чарасызлыкларга көн саен диярлек тарып торабыз. Баш мие өндәге шул чарасызлыкларны, төштә генә булса да, конкрет хәл-әхвәлләрдә ахырына житкереп, очлап кына куядыр, бәлки...

Әйтик, үзе бик таныш та, таныш та булмаган авыл. Үзебезнең авыл. Мин инде анда кимендә мең тапкыр булганмындыр. Куанып урамнарыннан үтәм, шатланып өйгә килеп керәм, сөенеп атам-анам белән күрешәм. Күршеләр белән дә очрашырга чыгып китәм дә өебезне табалмый тилмерәм. Авыл да — тозак-лабиринт, бернәрсәнең дә очын табып булмый торган йомык әйләнә... Болары, бәлки, туган төбәктән мәңгелеккә чыгып киткәнем өчен туган табигатемнең миңа мәңгелеккә дучар иткән җәзасыдыр.

* * *

Дус малайларның берсе Риф иде. Без аның белән авылдан икебез ике тарафка чыгып киткәнче сердәшләр булдык. Йөз тапкыр сугыштык (хәер, мин адәмчә тәмләп, һәйбәтләп сугыша да белмәдем), мең мәртәбә дуслаштык. Хәтта безнең күзләребез дә бер үк кызга төшә торган иде. Мин кызларны чын-чынлап яратып китә торган булсам, Риф моны күңелле шаяруга саный. Аннан соң миннән ике өстенлеге дә бар: ул житеш гаиләдән, өс-башы шәп, ни теләсә, шул бар диярлек. Өстәвенә шактый тәвәккәл, минем кебек җебек түгел. Әмма без барыбер дуслар булып кала килдек. Байтак еллар икебезнең бер кызны яратып йөрүебез дә комачауламады моңа...

Кыскасы, Риф белән без гел диярлек бергә булдык, юа, кузгалак, какы, җиләк, чикләвек ише нәрсәләр артыннан кардан яңа ачыла башлаган тауларга, әрәмәле елга буйларына, болыннарга, урманнарга йөри торган идек. Әлбәттә, юл буе — әкият. Никадәр әкият сөйләнгәндер ул юлларда?!.

Инде — төш. Мәш килеп Рифләрдә уйныйбыз, имеш. Шулчак сеңлесе өй базына төшкән икән дә куркуыннан чырыйлап кычкыра, әни, елан бар, елан! ди икән. Карасак, базның стена кырыеннан, чыннан да, елан шуышып бара. Үзе ап-ак. Башында нәни генә алтын таҗы да бар. Еланнар патшасының сөекле кызы! Эчемдә курку катыш сөенеч. Куркам — елан барыбер елан инде ул. Сөенәм — ак елан бит. Ак елан күргән кеше бәхетле була, диләр. Таҗлы ак елан — еланнар патшасының сөекле кызы, дип әкиятләрдә укыганым бар. Аны бәладән коткарсаң, ул гүзәл кызга әверелеп, коткарган егетнең кәләше була, ди... Ак елан бик кызу шуыша, баз стенасындагы оясына кереп качарга ашыга, илереп елаган кызчыкка кагылырга гамендә дә юк. Әмма Рифнең әнисе кызының елаган тавышына йөгереп килде дә, тиз генә базга төшеп, елан өстенә ташланды. Муеныннан эләктереп буа да башлады. Ак еланны! Еланнар патшасының сөекле кызын! «Апа җаным, тимә, ак елан бит ул, патша кызы, кешене чакмый ул!» — дип ялвармакчы булам. Булмый. Өнем юк...

Ә күрше апама үз баласы кадерлерәк шул. Аның өчен еланның ниндие дә — елан...

Буып ташланган бичара ак елан хәзергә көнгә кадәр хәтеремнән чыкмый. Шушы төш белән — һәлак ителгән ак елан белән үз язмышым, халкым язмышы арасында ниндидер бәйләнеш бардыр сыман. Инде ничә гасырлар дәвамында шулай күзгә күренмәгән куллар белән буып килмәделәрмени безнең бәхетебезне? Безне тәхете җимерелгән, таҗы таланган, үзе әсир ителгән Сөембикә ханбикә заманнарыннан бирле матди ярлылыкта, рухи коллыкта асрамадылармыни? Хәер, буардай кулларның бүген дә якаларыбыздан ары киткәннәре юк. Ә яка белән бугаз арасы, элеккечә, Казан белән Мәскәү арасы кебек...

* * *

Күргән төшләремне кабат хәтергә төшереп, төрләргә аерганда, аларны кимендә биш төркемчәгә бүләргә мөмкин икәнлегенә игътибар иттем.

Беренче. **Көндәлек тормышта булган хәлләрнең, вакыйгаларның чагылышы.** Аларның кеше үзе йоклаганда баш миендә кайтаваз булып чагылуы. Менә шундый «кайтаваз»ларның берсе.

Язучылар берлегенә керергә әзерләнеп йөргән көннәрем. «Солдат булдым» исемле юка гына шигырьләр китабым чыккан чорлар. Танылган композитор Ренат Еникеев шул китапчыкка кергән ун шигырьдән бер бәйләм җыр язып куйган. Шуларны аерым җыентык итеп Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иткән. Мөхәррир итеп нәшриятта бөтен хезмәт гомерен эшләгән Сания ханым Сибгатуллинаны белгеләгәннәр. Беркөнне мөхтәрәмә мөхәррирә мине үз катына чакыртып алды. «Җәүдәт энем,— ди миңа Сания апа,— күп шигырьләреңне бу хәлендә үткәрә алмыйбыз, шактыен төзәтергә, кабат язарга туры килер»,— ди. Мин үземне ипле кешегә саныйм. Файдага дигәндә, бер үк нәрсәне ун тапкыр, аннан да артыграк эшләргә риза. Тик бөтен бәла шунда: бердән, бу шигырьләр әле күптән түгел генә аерым китап булып чыккан, икенчедән, җыр булып, радио фондына кабул ителгәннәр. Үзеңчә салган әзер йортны җимереп, күршең теләгәнчә төзергә кирәк, кыскасы... Шулай да тыңлап бетерү лазем — өлкән кеше сүз әйтә.

— Кай җире килешмәгән соң бу шигырьләрнең, Сания ханым? — дим.

«Килмәгән жирләре» күп икән шул. «Алмаз» исемле шигырьдәге «Бияләй ишле-сыңарлы» дигән юлда «ишле-сыңарлы» дигән сүзләр аңлашылмый икән.

— Соң,— мин әйтәм,— бала чакта гына түгел, олыгайгач та, үз ишен тапмаганда, төрле иштән бияләйләр кигән чак була...

— Юк! — дип кырт кисә апам.— Татарда андый сүз юк.

— Тагын нәрсә ярамый? — дип сорыйм.

— «Наза» дигән шигырендә «Сузылып бар буена, чәчәкләр су коена»,— дигән юлларың. Чәчәкләр ничек, бар буена сузылып, су коенсыннар инде, әйә? Су сипкәндә, киресенчә, бөгелеп төшә алар!

Мин, чәчәкләрне су коенучы бала сыманрак күз алдына китереп, язган идем. Тик мөхәррирем тыңларга да теләми. Төзәтергә — вәссәлам!

Сыер дуласа, аттан яман, дигәндәй, мин дә тоякларымны жиргә терәдем хәзер. «Бу китапны мин төзеп китермәдем, чыгарасын чыгардым, бик кирәксә, композитор белән сөйләшегез. Булдыра алса, әнә ул төзәтсен!» — дип, кабат урап килмәслек итеп, урыс әйтмешли, артымдагы күперне «яндырып», чыгып киттем. Оятыма, ишекне дә катырак ябып ташладым шикелле. Нәшриятта, болай гына тынлата алмагач, мине һәйбәтләп акылга утыртырга булганнар. Кулъязманы шигъриятебезнең аксакалы саналган Сибгат ага Хәкимгә биргәннәр. Тетмәне теттереп, йоннарымны җилдә җилгерергә уйлаганнар, кыскасы. Үз фикере өчен утка да керергә әзер кеше иде Сибгат ага. Кыйбласына туры килгәннәрне әләм итеп күкләргә күтәрә, килмәгәннәрне үтәли тишеп чыга. Кыскасы, минем язмышны әнә шул төзтишәр сөңгеләр хөкеменә җибәргәннәр.

Дөресен әйтим, бу кулъязманың Сибгат ага кулына кергәнен баштарак белгән булсам, шулкадәр борчылмаган да булыр идем. Чөнки мөхтәрәм шагыйребез ул елларда радиокомитет каршындагы художество советының җыр текстлары өчен җаваплы әгъзаларның берсе, теге ун җыр аның кулыннан үткән, «танылган шагыйребез Муса Җәлилнең олы хыялларыннан берсе — балаларыбыз өчен махсус җыр цикллары булдыру, аларны музыкага якынайту иде. Бу җырларда мин шул хыялның чынга ашуын күрәм»,— кебегрәк җөмләләр белән хупланган иде. Шуңа тәңгәл диярлек сүзләрне ул нәшриятка да язып китергән. Бәлки, әлеге әчке рецензия Сибгат ага архивының берәр сәхифәсе булып саклана да торгандыр. Бәлки нәшрият архивына теркәлгәндер.

Китап чыкты. Сания ханым Сибгатуллина мөхәррирлегендә, әлбәттә. Әзер китапны күрәләтә кешегә бирмәс бит инде. Күләмле булмаса да, күпмедер көч куелган иҗади хезмәт.

Бу кадәресен мин хәзер сөйләячәк төшемнең реаль җирлектән әллә ни аерылмаганлыгын дәлилләр өчен сөйләдем.

Әйткәнемчә, язучылар берлегенә керергә әзерләнеп йөргән көннәрем. Әмма Татарстан Язучылар берлегенең балалар секциясе алты-җиде еллап инде үз сафларын тулыландырырга ашыкмый.

Шундый көннәремнең берсендә төш керә миңа.

Зу-ур зал (мин аның байтак еллар үтеп, безнең Язучылар берлеге күчеп килгәч кенә, Комлев урамындагы элеккеге хастаханә бинасының иң олы бүлмәләреннән берсе икәнлеген аңладым). Шул үзе зу-ур, үзе биек залның диварлары тирәли мөхтәрәм әдипләребез тезелгән. Юк, тезелгән дип әйтү бик үк дөрескә килмәс. Төркем-төркем булып басканнар. Нәкъ элеккеге тәнкыйть мәкаләләрендәгечә — һәркайсы үз «обойма»сында.

Менә Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, чын арыслан сыман чал яллары иңенә таралып төшкән, нык бәдәнле, шул бәдәнгә торышлы юан таягын кулыннан төшермәгән Нури Арсланов, Мөхәммәт Садри, Нәби Дәүли. Ни өчендер, бер ялгызы — Зәет Мәҗитов. Аның янәшәсендә диярлек — Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Фәрваз Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Әхсән Баян, Хәкимҗан Халиков.

Шул ук тирәдә, әйтсә өнеңне алачак Аяз Гыйләҗев та булырга охшаган...

Батулла да, гадәтенчә, мыек астыннан гына елмаеп, әйтер репликасы өчен уңайлы мизгел көтә...

Аннан ерак та түгел — Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәшит Әхмәтҗанов, Гәрәй Рәхим, (Роберт Әхмәтҗанов, гадәтенчә, бу җыелышка да килмәгән), Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Мингалим, Ризван Хәмид һәм башкалар... Роберт Миңнуллин керфек тә какмыйча Шәүкәт Галиев тарафына карап тора. Төркемдә Марсель Галиев, Фәннур Сафин, Равил Кукушкин. Картлар төркеменә, шакмаксыман әйләнәне йомып, Зиннур Мансуров, Рашат Низамиев, Рәшит Бәшәр кебек сабакташларым борын төрткән...

Менә шул әйләнә уртасында Сибгат Хәким бер ялгызы. Бу җыенда минем язмышым хәл ителә, имеш. Сибгат ага, уртага баскан да, гадәтенчә басынкы, әмма һиндидер аппарат ярдәмендәме, көчәйтелгән йомшак тавыш белән сорый:

— Җәүдәтнең иҗаты хакында кем сүз әйтә ала?

Әлеге йомшак, әмма таләпчән салмак тавыш, бинаһая олы залның диварларында, идән-түшәмнәрендә кайтаваз сыман бәрелә-сугыла йөреп, сүнә, тынып кала. Тагын Сибгат аганың тавышы яңгырый. Бу юлы ул тагын да салмаграк һәм таләпчәнрәк:

— Җәүдәтнең... иҗаты хакында... кем сүз әйтә ала?

Җавап юк. Зал диварларына аксакал шагыйрьнең сүзләре бәрелеп имгәнәләр генә.

Картлар дәшми. Аларның үз гамьнәре. Алар өчен мин артык яшь, язганнарым алардан ерак. Балалар шагыйре белән аралашыр, уртаклашыр чорлары узган... Үпкәләр урын юк картларга, әле шулай җыйналып килгәннәренә рәхмәт. Зәет абый дәшмәс. Шәүкәт абый белән Илдар абыйлар да тел тибрәтми. Аларның үз шәкертләрен үстерәселәре бар...

Батулла да, күзләрен кыса төшеп, мыек астыннан елмаюын гына белә. «Нәрсә, Дәрзаман, ике-өч китап чыгармас борын, язучы буласың киләмени? Менә син минем кебек, язучы булып та, милләтче мөһере сугылып, дистәләрчә еллар әсәрләреңне бастырмый ятуларына түзеп кара!» — диюедер инде...

Кайсы гына төркемгә борылсам да, кемгә генә инәлеп баксам да, күз карашларын тоталмыйм: күзләрен кая туры килде шунда текәгәннәр дә, рәхәтләнеп гәпләшә бирәләр. Уртада Сибгат Хәким басып торганлыгын бөтенләй оныттылар, бугай.

Оныттылар бугай, дигәннән, «г» авазын урысчалап, «оныттың, бугай» дип, Гали Ильясов үзебезнең Гәрәй Рәхим сүзләренә җырлап йөри бит әле. Карале, Лениногорскида Шамил абый Бикчурин җитәкләгән түгәрәккә ничә еллар бергә йөрдек бит. Мине яклап бер генә сүз дә әйтмәс микәнни? Әйтмәс шул, умарта күче сыенырлык сакалын сыйпап, «с» авазын теш арасында бераз сакаулата-сакаулата, әңгәмәдәшләренә әле генә үз авылларыннан ишетеп кайткан керәшен мәзәкләрен сөйли.

Равил Фәйзуллин белән Роберт Миңнуллин, сүзебезне соңрак әйтербез — тәкъдим кәгазе язарбыз, диделәр. Рәхмәт аларга. Тик менә хәзер үк кирәк бит әле ул каһәр төшкән сүз. Берәү дә әйтергә теләми аны, берәүнең дә Дәрзаман дигән кешенең шул төркемнәрнең берсенә килеп кушылуын теләми.

Сибгат аганың соңгы соравы исә, кайтавазның азакКы талпынышы сыман, сүнеп бара шикелле:

— ...кем сүз әйтә ала?..

Язмышың яшьтәшләрең белән сабакташларың кулына калмасын икән ул. Шуннан да читене юк икән.

Аптырагач:

— Зиннур,— дим,— син булса да әйт инде берәр сүз, мин армиядән кайткач, бер группада биш ел укыдык, сабакташ ич син, мине яхшы

беләсең, кирәксә-кирәкмәсә дә чамасыз туры сүзле икәнлегемне дә оныты бетермәгәнсеңдер,— дим.

— Ачуланма инде, Җәүдәт,— ди Зиннур.— Язучылар берлегендә үз язмышымны хәл итәсем бар бит әле минем...

Олы зал. Уртада — шигърият аксакалы, әз генә өмет чаткысы булса да, һәр яшь каләмгә ихтирамлы вә игътибарлы Сибгат Хәким. Әйләнәдә — умарта кортларыдай гөжләп, үз уйларына, үз гәпләренә чумган төрле яшьтәге, төрле иҗат куәсенә ия булган язучылар...

Менә шундый төш. Ул чакта ук инде бүгенгемне генә түгел, күпмедер күләмдә, киләчәгемә дә караганмын икән. Һәр чыккан китабымны укып, үзенчә бәя бирергә омтылган, Казаннан ерак яшәп тә Сарман районының Чукмарлы авыл мәктәбен үзенең әдәби казаны иткән шагыйрь Әзһәр Габиди, язучы Барлас Камаловны һәм Татарстан китап нәшриятында татарча да, урысча да чыккан «Төнге мажара» әкиятен «Казан утлары» журналында башыннан алып азагына кадәр «көйрәтеп» чыккан тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевне, шул ук журналда «Гөлназ мәктәпкә бара» китабын «тунаган» сабакташым Рәшит Бәшәрдән бүтән әлегәчә берәүнең дә иҗатыма тулаем объектив бәя бирергә тырышып караганы юк...

Хәер, юкка зарланам түгелме? Тәнкыйтьче кадәр тәнкыйтьче язганнарыңны күреп алган икән, иҗатың буш түгел, димәк. Күрмәмешкә салышулары монысыннан да читенрәк бит әле аның... Юк, кыйнаутукмауларга каршы түгел мин. Безнең татарда электән килгән йола инде ул...

И к е н ч е. **Көндәлек тормышта булган хәлләрнең, вакыйгаларның агышыннан, аларның нәтиҗәләреннән яки көткән нәтиҗәләрне бирмәүләре сәбәпле, канәгатьсезлек йөзеннән, баш миенең аларны үзе көткәнчә, үзе теләгәнчә «очлап чыгуы», үзенчә төгәлләве.** Мондый төшләр хакында инде укучымның ишеткәне дә бардыр. Әйтик, иң зур ачышларын төштә ясаган галимнәр, иң шәп әсәрләрен төшләрендә язган композиторлар һәм башкалар мәгълүм. Әйтик, күренекле урыс галиме Менделеев үзенең атаклы химик элементлар җәдвәлен иң тәүдә төшендә күргән...

Ө ч е н ч е. **Төшкә, гадәттә, сиңа тегеяки бу мөнәсәбәте булган кешеләр, аларга кагылышлы эш-гамәлләр керә. Бер очракта әлеге булган яки булачак эш-гамәлләр турыдан-туры керсә, икенчесендә алар ниндидер символлар, билгеләр рәвешендә дә булырга мөмкин.** Бер-берләренә охшаш шундый төшләрне берничә мәртәбә күргәч, тора-бара, юрарга да өйрәнәсең.

Мисаллар. Олы кызыбызга өч-дүрт яшьләр чамасы вакыт. Җәй урталарында аларны бөтен бакчалары белән җәйге дачага күчерделәр. Мин, ул елларда радио мөхәррире, ниндидер эшкә уралып, баштагы атналарда кызым янына бара алмадым. Хатын гына йөрде. Барганының берсендә бакча җиләге алып китте бу. Су тидерсәм, бозылыр дип, баргач кына, балага юып бирергә уйлады. Кызыбыз бик матур йөри, тазара да башлаган, дип бик сөенеп кайтты. Мин дә бик куандым, әлбәттә. Әмма шул төнне төш керә бит миңа. Кызым эчен тоткан килеш чүгәләп утырган да, әтием, эчем авырта, дип, өзгәләнеп елый, имеш. Иртән торуга хатынга: «Син җиләкне балага юып бирдеңме?» — дим. Хатын минем бу соравыма бик гаҗәпләнде. Шушындый урынсыз рәнҗетүемә хәтта, гадәтенчә, бераз гына үпкәләде дә. «Ник болай сорыйсың?» — ди. Мин күргән төшемне сөйләп бирдем. Хатыным, миңа бик сиздермәскә тырышса да, нык борчыла башлады. Атна азагы җиткәнне дә көтмичә, бала янына барып кайтты. Төшем рас булып чыкты. Әлеге дә баягы шул хәерсез җиләк инде. Баланы күрү куанычыннан, хәләлем аны юып торырга оныткан икән...

«Ялкын» журналында баш мөхәррир булып эшли башлагач күргән төшем. Хезмәткәрләремнән берсенең «армиягә» китеп, «офицер» дәрәҗәсенә ирешеп йөргән чаклары. Шул хезмәттәшемнең бинибая чая хатыны

килеп, чираттагы җәнҗалларының берсен чыгарып киткәч, мин дә түз-мәдем — икеме, өчме көннән соң кан басымым күтәрелеп, урынга аудым. Кабат аякка басканчы ике атналап вакыт үтте. Инде савыгып, тагын ике-өч көннән эшкә чыгармын дип кенә торганда...

Кирәк бит, шундый төш күрә миңа. Егетләрем эшли торган бүлмә кунаклар — башка редакцияләрдә эшли торган журналист вә шагыйрь ир-егетләр белән шыгырым тулы. Араларында инде азау теше чыгарганнар да, язучы буларак әле танылып кына килгәннәре дә бар. Бүлмәдә колун балта элсәң дә идәнгә төшмәслек тәмәке төтене. Шаулашалар. Көлешәләр. Берсе, күбебезгә яхшы таныш спорт журналисты — Айрат Садыйк, ишекне кергәч тә уң якка куелган язу өстәленә сузылып ук яткан. Янына тезеп куелган өч литрлы өч пыяла банканың берсеннән кырын яткан килеш кенә, олы пыяла кружкага салып, сыра чөмерә...

Уяндым да, карганып ятам. Төшкә кереп азапламасалар тагын. Болай да беләм бит инде аларның, мин югында, сыра мичкәсенә башлары белән чумганнарын! Шулай да, монысы нинди төш булыр икән тагын? Теге, рас килә торганнарыннан түгел микән? Бер җаен китереп, баргач сораштырасы булыр...

Эшкә килеп, бүлмәмне ачып кына өлгердем, җаваплы хезмәткәрем килеп керде. Мин юклыктан файдаланып «бәйрәм иткән» егетләрдән туйганчы бер зарланды, ичмасам!

Төшне егетләргә барыбер сөйләдем. Кайсы шагыйрь кайда басып торган, кайсының өстендә нинди кием, кайсы өстәлгә кырын яткан килеш кенә сыра чөмергән. Шаккаттылар егетләр...

Дүртенче. **Күрәзәче төшләр.** Баштагы өчесенең табигатен әле берникадәр аңлатып булса, бу иш төшләрнең асылын махсус әзерлексез аңлап та, аңлатып та булмый. Һәрхәлдә, мин фәкыйрегез аларны булган кадәр тормыш тәҗрибәмнән чыгып, кәгазь битләренә теркәп кенә калдыра алам.

Бервакытны, кыш җиттеме, авылдагы йортыбызның янганы керә башлады. Төштә ут-янгын күрсәң, көн салкынаясын болай да беләм. Әмма бер кыш эчендә бер үк төш берничә тапкыр кабатлангач, пошаманга төштем. Алай да кыш, мине куркыта-куркыта, бәла-казасыз гына узып китте. Җәйгә чыккач, төшләремә су буйлары, яр буенда балык каптырулар керә башлады. Балык каптыруларның юрамасы җайлы: уянганда яңгыр инде йә яуган, йә яварга җыенган була, көннең икенче яртысында ява. Һава басымы, дымлылык алмашына — кеше организмы исә катлаулы, сизгер, бу үзгәрешләрне тоеп, баш миенең тиешле ноктасына хәбәр итә. Бары тик шул гына, минемчә... Ә менә кышка керүгә, тагын тотынды бит теге хәерсез төш. Аптырагач, шундый-шундый төш керен тинтерәтә, зинһар ут-күздән сак була күрегез, дип әнигә хат язарга мәҗбүр булдым. Казаннан торып каза юрап ятмасана, дип, әни, үземне тиргәп, җавап җибәрде. 1974 ел узганчы керде бу алла каргаган төш. Ә икенче кышны өй барыбер янды. Бик күп көч түгәргә туры килде аны рәткә кертер өчен.

Теге төш тә кереп мине изалаудан туктады. Кышкы көннәрдә еш кына ут күрсәм дә, ул инде безнең авыл, туган нигез белән бәйле түгел иде. Аллага шөкер!

Шуннан соң ун еллап вакыт үтте. Җәйләрнең берсендә, 83—85 нче еллар иде булса кирәк, бераз чиста, саф һава сулап, сөт, катык ашап килсеннәр дип, кызларымның икесен дә авылга кайтарып куйдым. Айдан артык яшәде болар. Аларга авыл ошый, картлар оныкларны ярата. Минекеләр янында сеңелкәшнекеләр дә бар. Тулы бер балалар бакчасы инде.

Шулай балалар өчен куанып, гомердә бер килгән аулак өйгә сөенеп, дигәндәй яшәп ятканда, төшкә тагын янгын кермәсенме! Болдырыбызның бер почмагына ут капкан, ялкыны урамга ук чыккан, имеш! Котым

алынып уяндым. Төшемне хатынга сөйләдем дә, бәласеннән баш-аяк, ул-бу булгалаганчы балаларны алып кайтыйм, дип, шул иртәдә үк авылга элдердем.

Авылга кайтып, берәүгә дә сәлам бирми узганым юк иде. Бу юлы үпкәләп калучылар да булгандыр — алны-артны карамыйча, элдерәм генә! Өй күренгәч, пошаман басылды. Капкадан кереп, исән-имин торган болдырга да узгач, җаным тынычланды. Мәрхүм Шамил Бикчурин әйтмешли, юкка-барга ышанып йөрсәң, шулай була ул, дивана!

Көтмәгәндә кайтып кергәнемне күргәч, балалар сөенеште, әни куркынып калды. Баштарак, балаларны сагынганга кайттым, дигән булдым. Аннан соң инде, сүз иярә сүз чыгып, теге хәерсез төшне сөйләп бирдем. Әни, аны-моны әйтмичә генә, мине болдырга алып чыкты да, әтинең җәй көннәрендә йоклый торган диван япмасын күтәрде — түшәк кырының нәкъ уртасында көйгән шактый зур тишек акаеп тора иде.

Нәкъ минем төшкә кергән төндә балалар телевизор карап утыра икән, әни йорт эшләре белән әвәрә килә, әти болдырда үз диванында ята икән. «Сәгыйдә, янам!» — дигән тавышка бөтенесе урыныннан куба. Беренче булып әни аңга килә. Чыкса әти, исән-имин килеш, кычкыра-кычкыра чәбәләнә, ә диван читендә ут телләре биешә, тирә-юньне төтен баскан. Әни, әлбәттә инде, беренче эш итеп, ятакка тәмәкесен төшереп йокыга киткән әтине «суыта» — беренче чиләк су аның өстенә коела...

Боларны сөйләгәндә, балалар хәзер дә тәгәри-тәгәри көләләр. Минем исә көләр әмәлем юк. Өй тулы бала-чага харап итү, үзләре һәлак булу ихтималы күз алдыма килә дә, эсселе-суыклы булып китәм...

Көндәлек тормышка гына түгел, иҗатыма да кагылышлы күрәзәчел төшләр күргәнем бар. «Гөлназ мәктәпкә бара» исемле шигырьләр бәйләмем башта «Төнге мажара» дигән әкиятем белән бергә чыгарга тиеш иде. Әмма рәссам Рәшит Сафиуллин әкияткә шундый шәп рәсемнәр ясап китергән, шигырьләр аларның композицион бөтенлегенә зәгыйфьлек китерәчәк иде. Моны мин болай да бик яхшы аңладым. Рәссам фикере белән килешсәм дә, нәшрият җитәкчеләре белән бераз тартышасы иттем. Дөрес чамалаганмын — дәлилле торгач, «Гөлназ...»ны «Төнге мажара»дан соң ук «мәктәпкә» җибәрергә булдылар. 2—3 йөз юл әйбер, зур урын да, күп кәгазь дә сорамый. Балалар өчен әйбәт кенә булыр, дип, өметләнеп йөрим шулай. Әмма сизеп торам, кулъязманың хәле мөшкел, алдагы ел планына кертергә бик атлыгып тормыйлар.

Уңышсызлыкларыма хатынның үземнән дә битәр борчыла торган гадәте бар. Йөкле дә вакыты, җитмәсә. Иртәгә план раслана, диясе көнне төш керә миңа. Балалар һәм яшүсмерләр редакциясе мөдире Шамил абый Рәкыйпов миңа әйтә: «Син үпкәләмә инде, Җәүдәт, «Гөлназ...»ының быелгы планга сала алмадык, киләсе елга күләмлерәк итеп чыгарырбыз...»

Иртән уяндым да уйлап ятам: тикмәгә түгел, һай, тикмәгә генә түгел бу төш! Тик ничек җайлап кына аңлатырга шуны, ничек хатынның кәефен җибәрмәскә? Ул бит шул нәшриятта эшли, барыбер беләчәк. Алай иттем, болай иттем, җай китереп әйттем моңа. Шундый-шундый төш күрдем, мин әйтәм, син, зинһар, андый-мондый нәрсә чыга калса, борчылма!

Китте хатын эшкә. Кичен: «Тачма-тач күргәнсез икән, — ди хатын. — Шамил абый бик җайлап әйтте, Җәүдәт үпкәләмәсен инде. Тәслимә, «Гөлназ...»ны планга сала алмадык, өченче елга күләмлерәк итеп чыгарырбыз, диде».

* * *

Татарстан радиосында уналты елдан артык эшләгән идем инде. Шулай бервакытны «Ялкын» журналының җаваплы сәркатип урыны бушады. Газета-журналларда моңарчы да урыннар булмады түгел, әмма

радиодан күчеп киту ye (биш кенә ай булса да, «Татарстан яшьләре» газетасында бүлек мөдире булып эшләп алганмын икән) уема да кереп карамады. Бу юлы күңелемдә нииндидер «корт» кыймылдап куйды. Алай да бу фикеремне берәүгә дә «тишәсе» итмәдем. Айга якын вакыт үтте. Көннәрнең берендә «Ялкын»ның баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова шалтырата: «Җәүдәт, вакыт табып, килеп кит әле! Сөйләшәсе бар. Телефоннан әйтеп булмый»,— ди. Ник чакырганын чамалыйм, тик тарта алырмынмы җаваплы сәркатип эшен? Аннан килеп, үҗәтлегем, үз сүземне сүз итәргә тырышу гадәтем дә бар. Җитәкчем хатын-кыз булганда, холкымның ул ягы да баш калкытуы ихтимал. Дөрес, Роза белән бергә имтиханнар биреп, бер елны бер группага укырга кергән идек без. Укуны башлап, колхоздан бәрәңгеләр алып кайткан арада, мине җилтерәтеп солдат хезмәтенә алып киттеләр. Ул еллардан соң чирек гасыр гомер узган шул инде. Тыйнак, кыюсыз, өстәвенә сөйкемле дә бу авыл кызы хәзер инде Роза ханымга, Роза Рәхмәтулловнага әверелгән. Холкы да шактый кырысланган, утлы табага бастырырга да күп сорамый, диләр. Үзем дә — кайчандыр күн итек, телогрейка, фуражкадан университетка килгән җебек Җәүдәт түгел инде. Ай-һай, борчагыбыз пешәр микән? Әнә шундыйрак борчулар кичереп утырганда, яшен ялтырагандай итеп кенә, башымнан бер уй йөгереп узды: «Бар! Тәвәккәллә, бәлки, тора-бара, үзең үк баш мөхәррир дә булырсың...» Ничек кабынса, шулай сүнде бу уй, әмма ничектер сәер, үзем уйлаганнан битәр, нииндидер эчке тавыш сымаграк хәтеремә нык сеңеп калды ул.

Мине, чыннан да, «Ялкын» журналының җаваплы сәркатибе итеп алдылар. Акрынлап кына булса да яңа эшкә ияләшә башладым. Әмма журнал чыгаруның техник якларын белмәү үзәккә үтә. Үзем исә һаман да күбрәк вакытны язмаларның телен, әдәби эшләнешен камилләштерүгә сарыф итәм. Җитмәсә, балалар язучысы буларак, мәктәпләргә чакырып тинтерәтәләр...

«Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналының баш мөхәррире Венера Ихсанова пенсиягә киткәч, аның урынына безнең баш мөхәррир Роза Рәхмәтулловна күчәчәк икән, дигән имеш-мимешләр йөри башлаган иде инде...

Роза ханым «Азат хатын»га киткәч, безнең «Ялкын» журналында көтелмәгән, минем уема да килмәгән бер хәл булып алды. Унбер кешелек коллективыбыз ике төркемгә бүленде. Халык тыз-быз килә, бер бүлмәдән икенчесенә чаба. Күпчелеге хатын-кыз, пышын-пышын сөйләшәләр, үзләренчә нииндидер планнар коралар. Шуларның өчесе минем янга керделәр дә турысын ярдылар да салдылар: «Әгәр без сине, коллектив исеменнән, баш редакторыбыз урынына тәкъдим итсәк, ничегрәк карыйсың?»— диләр. Әле радиода эшләгән чакта ук «ишетелеп киткән» эчке тавыш түгелме соң бу? «Ихтыярыгыз, мин әйтәм, ерып чыга алсагыз, яхшы. Ерып чыга алмасагыз да начар түгел, барыбер сезнең белән эшлисе, журналны бергәләп чыгарасы»,— дим. «Уен» башланды. Минем өчен генә түгел, әлегә яңа ысулларга күнмәгән ВЛКСМ һәм КПСС обкомнары өчен дә көтелмәгән хәл иде бу. Эшче коллективларда, гыйльми даирәләрдә дә моңа кадәр җитәкчеләрнең чын мәгънәсендә турыдантуры сайланганы юк иде бит әле...

Комсомолның өлкә комитеты, «өлкән комитет» белән киңәшкәннән соң инде, әлбәттә, коллективка сайлау үткәрергә рөхсәт бирде. Безнең олы сабан туйлары кечкенә балалар көрәшеннән башлана бит. Монда да шул: әйдә, бер юлга балалар журналындагы өлкәннәрне көрәштереп карыйк әле, ни белән бетәр икән, дигәннәрдер инде.

Булачак сайлауларның якынча нәтиҗәсе инде ярылып яткангамы, сайлау көне һаман кичектерелә барды. Ул арада икенче һәм өченче кандидатура да пәйда булды. Соңгысы — ерак авылларның берсендә заманында хәрабә хәленә килгән мәктәп урынына заманча Макаренко мәктәбе торгызган, әле 38 яше тулырга өлгермәгән чая, ифрат эшмәкәр,

буйдак мәктәп директоры — минем «Җир авазы» повестендагы төп каһарманымның прототибы (хәзер ул — журналыбызның редколлегия әгъзасы) Әнвәр Хуҗиәхмәтов иде.

Китте «халыкны «эшкәртү», әле тегеннән, әле моннан редакция хезмәткәрләрен фәлән кешегә тавыш бирергә өндәп чылтырату... Эзли торгач, үзләре теләгән тавыш санын җыю җаен да таптылар — редколлегия әгъзаларын да катнаштырырга! Алар инде югары оешма теләгенә каршы килмәс. «Ялкын» фиркаләләре «Яшь ленинчы» («Сабантуй») башлангыч партия оешмасында исәптә тора. Димәк, партоешма секретаре дә сайласын. Комсомол җитәкчеләре хуплаган иптәшкә тагын бер уңай тавыш өстәлә дигән сүз...

Ул арада элеккеге мөхәррирем миңа тавыш бирү ихтималы булган бер ханымны эшкә үз янына алды. Димәк, мине яклаучы тагын бер тавыш югала...

Ниһаять, сайлау көне. Һәркайсыбызга (дәгъвачыларга) үзебезнең сайлау платформаларыбыз белән таныштырырга көн билгеләделәр. Баксаң, сайлауларга кадәр, иң күп вакыт минеке булган икән бит! Бер җыелышта әйткән идем: «Баш мөхәррир булсам, сезне «кысрыклап», үз «яраннарымны» җыймам, читтән җаваплы сәркатип алмам, иң лаеклысын үз арабыздан билгеләрбез, киткән ханым урынына кеше алып тормабыз, аның хезмәт хакын үзебезнекенә өстәрбез; бүлмәләрдә өчәр-дүртәр кеше утырабыз. Баш редакторның кабул итү бүлмәсе урынына җаваплы сәркатип бүлмәсе ясармын, үз бүлмәмне кечерәйтермен, иҗатыгызга ирек куярмын, яхшы башлангычларның һәркайсын хупларга, тормышка ашырырга тырышырмын, дидем; профсоюз килешсә, иҗат көннәре бирү мәсьәләсен күтәрермен, кульязмалар вакытыннан алда кереп барса, фәлән сәгатьтә килегез, дип бәйләнмәм; үзем эт көнендә яшәсәм дә, фатир чиратыгызга катышмам, мохтаҗларга квартира юллау чарасын эзләрмен», — дидем. Асылда, минем сайлау алды платформам иде бу.

Миннән яшьрәк дәгъвачыны да ялкынлылар яхшы белә. Рашат Низамиев «Казан утлары» журналының проза бүлегендә эшли. Алтын таулар вәгъдә итмәде, фатир алулар моңарчы ун-унбиш елга бер була торган иде, ул тәртипне мин генә үзгәртә алмам, диде. Эш, иҗат мәсьәләләренә әллә ни кагылып тормады.

Өченчебез журналны тамырыннан үзгәртергә, тормышка, мәктәпкә якынайтырга тырышачагын әйтте. Алай гына да түгел, Казанга якын бер җирдә «Ялкын» пионерлар лагере ачып җибәрәчәге турында сөйләде. Тагын да кайбер башка уй-фикерләре бар, әмма аңысы әлегә нәни генә педагогик сер булып кала икән...

Сайлауларга санаулы гына көннәр калып барганда, атна-ун көн эчендә миңа бер-бер артлы ике төш керде. Беренчесе. Студент вакытым икән. Җәй. Кызыл Позиция урамындагы тулай тораклар янәшәсендәге тирән ермак төбеннән уза торган тимер юлга якынлашып килəм. Нидер сизенеп, артыма борылып карасам, артымнан олы ике этме, бүреме килә. Мин, куркуымнан, йөгерә башлагач, алар да чаба башлады. Абынасөртенә тимер юлны узып, каршы якка чыктым да, куе үлән үскән текә яр өстенә менеп китмәкче булам. Ә тегеләр артымнан куып җиттеләр дә... университет галимнәре Җәүдәт Сөләйман (идарә әгъзасы) белән Ренат Якушевка әверелеп (алар редакациягә бергәләп йөрергә яраталар иде), миңа әһәмият бирмичә, сөйләшә-сөйләшә китеп тә бардылар.

Икенчесе. «Җәүдәт!» — дигән тавышка уянып киткәнмен, имеш. Өченчесе дәгъвачыбыз, ягъни Әнвәр дустымның тавышы иде бу. Уяндым да аптырап калдым: безнең өй тәрәзәләре бу кадәрле дә киң түгелләр иде лабаса! Дивар тутырып олы-олы ике тәрәзә. Шул тәрәзәләрнең берсе янындагы киң караватта хатыным белән йоклап ятабыз икән. Үзем торгач, аны да уятмакчы булам. Тор әле, Әнвәр килгән анда, чәй куеп җибәр, дим. Гомер булмаганны: «Туйган инде синең ул кунакларыңнан, тор да үзең куй әнә!» — дип, кирелəнә, имеш, хәләлем.

Урамга чыксам, бүрәнә йортыбыз ялан кыр уртасында икән. Чаңгы кигән йөзләгән мәктәп баласы белән Әнвәр безгә ашыга. Шулчак кинода кадр алмашынган сыман була да, балалар (ә алар арасында миңа танышлары да күп) озы-ын бауга тезелгән төрле төстәге өчпочмаклы матур әләмнәр тезмәсе белән безнең йорт кыекларын бизәп йөриләр, ә Әнвәр, безгә кереп тә тормастан, чаңгыларында кире якка китеп бара, имеш.

Төшнең монысы иртәгә сайлау диясе төнне керде.

Иртәдән чалт аяз иде. Кәеф күтәренке. Гәүдәдә шундый җиңеллек, әйтерсең, бөтен гамь-мәшәкатьләремне, уй-хәсрәтләремне күзгә күренмәс җайланма белән суырып алганнар...

Ул көнне хәтта лифт та безнең сайлауда катнашты... Ашханәгә төшке ашка төшеп киткән идем, үзебезнең катта лифт ишеге ачылмас булды. Өстәвенә, ут та сүнде. Дөм-караңгы лифтта япа-ялгызым калдым. Кычкырам. Беренче булып кайсыдыр ханым ишетте. Аннан соң үзебезнең «Ялкын» редакциясе егетләре Ирек белән Ләис килеп җитте. Рәхәтләнеп көләләр, ишек ярыгыннан тәмәке төтене өрәләр, моннан чыкканда кем буласыңны белгән юк, рәхәтләнеп бимазалап калыйк бер, диләр. Кырык минутлап утырырга туры килде. «Тоткынлык»тан котылганда, сайлаулар башланырга ярты сәгатьләп кенә вакыт калган иде инде.

Менә сабакташ көндәшем унынчы каттан төште. Төп дәгъвачыга әверелгән Әнвәр һаман да юк иде әле. Ун-унбиш минут кала, ниһаять, озын гәүдәсен гадәтенчә төп-төз тотып, ул да килеп керде. Егетләрем, ачкан авызларын ябарга да онытып, сүзсез калдылар. Әнвәр, гөрләтеп сәлам бирде дә, җәлт кенә бүрек-пальтоларын салып, каядыр чыгып та югалды...

Сайлаулар башлангач, өчебез дә янә бер кат коллектив белән редколлегия әгъзаларын үзебезнең сайлау алды платформабыз белән таныштырып чыктык. Фотохәбәрчебез кызыклырак мизгелләрне төшерә барды. Аннан соң безгә, дәгъвачыларга, рәхим итеп чыгып торырга куштылар.

Сайлау нәтиҗәсен байтак көтәргә туры килде. Соңыннанрак белдем, көтәрлеге дә булган икән шул. Эш баштан ук каты тартыштан башланган. «Яшь ленинчы»дагы партоешма сәркатибебез дә сайлауда катнашырга дәгъва кыла икән. Бәхәс чыккан: партияне катнаштырыргамы, әллә катнаштырмаскамы? Шунда теге, төшкә кергән «бүреләрнең» берсе — редколлегия әгъзасы сүз алган. Әйдәгез соң алайса, нәшрият профкомын, ДОСААФын, Кызыл Хач җәмгыятен һәм башкаларын да чакырыйк — журнал чыгаруда аларның да күпмедер өлеше бар ич, дигән. Нәтиҗәдә, партия вәкиле тавыш бирү хокугыннан мәхрүм калган.

... Ниһаять, безне — сабакташларны, дусларны, каләмдәшләрне — дәгъвачы көндәшләрне баш мөхәррир бүлмәсенә чакырдылар. Тавыш болайрак бүленгән иде: Әнвәргә — 3, Рашатка — 4, миңа — 8.

Кыскасы, төшләрнең өчесе дә рас кергән булып чыкты.

Бер ел да мөхәррирлек итмәдем, «көйләүле базар мөнәсәбәтләре», дип сөйләшә башладылар. Партия белән комсомол «аерылышты». Малмөлкәт бүләргә тотындылар. Комсомол, матбугат миллионлаган табыш бирә, дип, газеталарны, алар янына без фәкыйрьләрне — 100 меңешәр сум дотацияле «Ялкын» белән «Яшь ленинчы»ны да үз карамагына алды. Комсомол: «Ну байыйбыз хәзер, умырабыз акчаны!» — дип йөргәндә, табыш китерми торган газета-журналларны, гомумән, партия нәшрияты бинасыннан чыгару мәсьәләсе кузгалды. Ул да түгел, элемтә һәм «Союзпечать» үз хезмәткәрләре өчен элеккедән ун тапкыр, типография, кимендә, өч тапкыр артыграк түләү таләп итте. Кәгазь бәясе безнең буй җитмәс дәрәҗәдә үсүен дәвам итте. Журналның дотациясе, ягъни хөкүмәттән бурычка ала торган акчасы, 60 меңнән 300 мең сумга күтәрелде. (Хәзер исә ул 20 миллионнан да артып китә.) Кыскасы, банкрот хәленә төшкән «Ялкын»ны саклап калырга, яшәтергә, яшьнәтергә кирәк иде. Элеккеге мөхәррирләр, ашау байдан, үлем ходайдан, дип яшәсә, миңа

бил бөгеп төрле оешмалар бусагасын таптарга, завод-фабрикалар ишеген кагарга, иганә, гап-гади генә иттереп әйткәндә, хәер теләнеп йөрергә калды. Әмма, шөкер, хәлебезгә керүчеләр дә табылды, кадәри хәл ярдәм иттеләр. Мин бу юлларны язганда, без партия балансыннан төшерелеп, төгәл өч ай үткән, нигездә бернәрсә дә азагынача хәл ителмәгән — кәгазь кайтарылмаган, журналга язылудан килгән керемнән тыш комсомолдан бер тиен дә килмәгән, бөтен илендә бәяләр котырынып үскәндә, журналистларыбызның хезмәт хакларын бер тиенгә арттырырлык мөмкинлек тә юк иде. Ярый әле мин, алдагы хәлләрне чамалап, иганәчеләр тапкан, йөреп-йөреп тә башка юл калмагач, Татарстан Югары Советының ул чактагы рәисе Минтимер Шәймиев булышлыгы белән, алдагы ел өчен 120 мең сорап, шуның 60 меңен юллый алган идем. Әмма бу акчалар да кирәкнең яртысы кадәр генә иде шул әле...

Шуңа күрә, хәзер инде көндәш дәгъвачыларым — дусларым «Ялкын» журналы мөхәррирлегенә сайлана алмый калуларына әллә ни үкенмиләрдер, дип уйлыйм.

Ә партия белән комсомол мөнәсәбәтләренә килсәк, алар килештеләр. Бары тик без, озак еллар дәвамында «Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә һәрвакыт әзер» булган балалар матбугаты гына, үксез кала бирдек. «Иң яхшысы — балаларга!» — дип лаф орган партиябез, флагман кораб янтая башлауга ук, бәйдән ычкынган тормыш дулкыннарына, артык балласттан котылам дип, гадәттәгечә, алдын-артын уйлап тормастан, иң беренче нәүбәттә, яшьләр һәм балалар матбугатын читкә типте.

Партия белән комсомолның республика комитетлары берләштерелгән бюро җыйдылар. Анда, гадәттәгечә, партиянең район һәм шәһәрләрдәге беренче, икенче секретарьлары, райбашкарма рәисләре һәм, берләштерелгән булганлыктан, комсомол комитетларының беренче секретарьлары да чакырылган иде. Яхшы әзерләнгән иде бюро. Югары мөнбәргә менгән һәркем алдан ук язып, әзерләнеп килгән. Һәр чыгышта — комсомолларның партия варислары булулары, аларның киләчәктә дә Ленин юлын дәвам итәселәре ассызыкланды. Райком секретарьларыннан берсе, ул Баулыдан иде шикелле, балалар матбугаты белән яшьләр матбугатының тетмәсен тетте. Имеш, фәлән дә фәсмәтән, имеш, балалар газета-журналлары Ленин темасын, партия сәясәтен бөтенләй онытты. Балалар газетасы бөтенләй барып чыккан — «Яшь ленинчы»ны «Сабантуй» белән алыштырган! Ә яшьләр газетасы («Комсомолец Татарии»), имеш, бөтенләй бәйдән ычкынган, инде партиягә дә тел-теш тидерергә җөрьәт итә башлаган. Чыдасаң чыдап тор, чыдамасаң чыгып тор... Тукта, телгә килеп кергәч, бу гыйбарәнең тарихын сөйләп китим әле. Имеш, элгәрәк заманнарда безнең авылның бер агай Шириәздан исемле икенче бер кордашы белән күрше урыс авылына кәсепкә чыгып киткән. Алай-болай гына эш барып чыкмагач, хәйләгә керешкән болар: керәшен побы дигән булып, өшкереп-төкереп булса да, бераз шикәр-чәйлек эшләп алу икән боларның исәпләре. Берәүнең хатыны сырхаулап яткан чак икән. Им-том итәргә тотынган болар. Шундый да рәвешен китереп чукындыра-өшкерә башлаган ди теге, Шириәздан дигәннең тәкате тәкәнеп, буыла-буыла көләргә тотынган, шул көлүеннән берничек тә тыела алмый икән.

Тегесе тәмам аптырагач:

*Шириәздан, көлдерәсең,*
*Бер пот оннан биздерәсең.*
*Чыдасаң, чыдап тор,*
*Чыдамасаң, чыгып тор!*
*Һых, тфү!*
*Һых, тфү!*

— дип, әфсен укырга мәҗбүр булган ди, имеш.

Монда да шул хәл. «Сабантуй» мөхәррире Роберт Миңнуллин белән янәшә утыра идек. Пышылдыйм тегеңә:

— Әйдә,— мәйтәм,— Роберт, күрсәт әле шуларга егетлегеңне! Белмиләрмени алар безнең, ел башыннан хәер эстәп, газета-журнал чыгаруны?! Син — депутат кеше, Югары Совет Президиумы әгъзасы. Сессияләрдә әллә ни сөйләмәсәң дә, экраннардан гел күрсәтеп торалар. Партия Рескомы әгъзасы буларак та сине бик яхшы беләләр. Әйдә, тәвәккәллә!— дим.

— Юк,— ди Роберт, башын гына чайкый.— Әзерләнми генә сөйли торган гадәт юк минем. Урысча булгач, бигрәк тә...

— Ярар,— мәйтәм,— үзем чыгам алайса. Әмма икебезнең исемнән дә сөйлим. Алай-болай «мөгез» чыгара калсам, бәласе икебезгә дә булыр!

Алдымда яткан кош теле кадәр генә кәгазьгә дүрт-биш өлештән торган план сыман нәрсә сыздым да, тәнәфестә сүз сорап куйганнан соң, менеп киттем теге олы мөнбәргә. Залдагылар елмая, нәрсә әйтер икән бу мескен — бала-чага журналы редакторы, янәсе.

— Хәерле кич, иптәшләр!— дип башладым.— Менә мин дә үз гомеремдә беренче тапкыр бу олы мөнбәргә менәргә җөрьәт иттем әле!— дим.— Менә бу залда бүген дүрт йөзләп коммунист утыра. Бер егерме-утыз елдан күпмегә калыр икән ул сан, сез ничек уйлыйсыз?

Зал гүләп алды.

— Хәер,— дип дәвам иттем мин,— егерме елдан соң да бу залда шушы кадәр үк коммунист утыруы бик ихтимал. Ә менә партия сафлары һаман да элеккечә үк тыгыз калыр микән? Монысына минем шигем бар.

Олы зал тагын зур канәгатьсезлек белән гүләп куйды.

— Бала тугач, ана үз сөте белән балада кемгә мәхәббәт тәрбияли? Әлбәттә инде, үзенә, иренә, әби-бабаларына, туган-тумачаларына, туган туфракка, һавага, кояш сулы чишмәгә... Иманлы хатын булса — Аллага. Әмма һич кенә дә партиягә түгел. Шул ук сабыйны әби-бабасы да тәрбияли. Алар да мәхәббәтне үзләренә, баланың әти-әнисенә, туган-тумачаларына, һавага, кояш сулы чишмәгә, һәм, әлбәттә инде, Аллаһе Тәгаләгә... Әмма һич кенә дә партиягә түгел.

Моңа кадәр партиягә мәхәббәт тәрбияли торган бер генә көч бар иде. Ул да булса — балалар матбугаты. Әмма сез яңа елдан башлап бездән баш тарттыгыз.

Менә монда беренче секретарьлардан бер иптәш,— дип дәвам иттем мин,— комсомол матбугатсыз калды, чөнки алар теләсә ни яза, алар өстеннән партиянең ныклы контролен булдырырга кирәк, диде. Мин аңламадым, ничек инде комсомол матбугатсыз калсын ди? Киресенчә, партия үзе — балалар һәм яшьләр матбугатыннан баш тартты. Шул чакта нәкъ менә комсомол үз канаты астына алды безне, комсомол сыендырды. Партия үзенең яшьләр һәм балалар матбугатын югалтты, минемчә. Монысы бердән. Икенчедән, Баулыдан килгән иптәшне мин аңлап җиткермәдем. Нәрсә, ул, яңа елдан башлап, партия безне читкә типкәнен белми дәмени? Урыста: «Кем тели, тыңлыйсы музыкага да шул түли»— дигән әйтем барын онытып җибәргән микәнни ул?

Һәм мин журналның титул битен ачып, югары күтәрәм:

— Сез беләсездер, элек заман татар китап-журналлары «Бисмиллаһирахман-иррахим» дигән изге сүзләр белән башланып киткән. Аны, революциядән соң «Барлык илләрнең пролетариатлары, берләшегез!» дигән өндәмә алыштырды. Безнең газета-журналлардан партия баш тарткач, «Ялкын» журналы аңа иганә бирүче «Чистай сәгать заводы» һәм «Татарстан кооператорлар берлеге» дигән сүзләр яза башлады. Менә алар, бездән музыка таләп итәргә тиешле оешмалар. Ярар, Чистай сәгать заводы эшчеләре дә, безнең бер сөйләшүдән үк ярдәм кулын сузарга әзер булган директор Цивилин да әлегә зур таләпләр куймыйлар. Ә Кооператорлар берлегендә, шанлы революционерлар турында язмас-

сыз, нэпманнарны сукмәссез, ә бүгенге кооператорларның уңышларын укучы балаларыгызга җиткерерсез, диделәр. Шулай эшләргә тырышырбыз, әфәнделәр, дидек без. Әмма алардан алган иганә генә безнең тишек-тошыкларыбызны ямарга җитми.

Чистай сәгать заводы дигәннән, әле хәзер телемә килде. Әгәр дә партиянең, үзен әйдәүче көч санаган партиянең яшь буынны тәрбияләрлек тә рәте калмаган икән инде, әле мин Чистай аракы заводына да...— Залдагы партия һәм совет, комсомол җитәкчеләре көлешкәнгә тукталып калырга мәҗбүр булдым.

— Ликер-аракы заводына...— дип төзәтте берәү.

— Чистай аракы заводына да мөрәҗәгать иттем,— дидем.— Әгәр дә партия булдыра алмый икән, әнә, дистә еллар буена әти-әниләрен аракы белән агулаган завод балаларны тәрбияләүдә ярдәм итсен! Димәк, иганәчеләр исемлеге янына без, бисмилла урынына, Чистай аракы заводы...

Зал шаулап көләргә тотынды. Әйтерсең лә мин партия рескомы бюросында түгел, укучыларым белән очрашуда булып, аларга мәзәк хәлләр сөйли идем...

— Әйе-әйе, бисмилла урынына «Чистай ликер-аракы заводы» дип язып куячакбыз. Гөнаһысы безгә түгел, сезгә булыр!

Өченчедән, мине тагын бер әйбер хәйран калдыра. Була бит әле шундый кешеләр, бала табалар да, яшь чакта типтереп калырга теләп, бәгырь кисәкләрен ятимнәр йортына илтеп аткаралар. Гомерләр уза, киемнәр туза. Картаеп, эш җегәре, тормыш куәсе беткән ата-ананың исенә теге ташландык «йөрәк парәсе» килеп төшә. Ничек инде, аңа гомер биргән әти-әнисе картаймыш көннәрендә тәрбиячесез калган, ә ул, игелексез, берүзе яшәп, кәеф-сафа сөрсен, имеш! Баулыдан килгән иптәш тә шулайрак хәл итмәкче мәсьәләне. Юк инде, коммунист туганнар! Башта сез үзегез безнең газета-журналны тәрбияләгез, яшәргә, эшләргә мөмкинлекләр тудырыгыз, аннан соң, рәхим итеп, таләбегезне куегыз! Без аларны үтәргә тырышырбыз. Хәтта музыкасын да сез теләгәнчә уйнавыбыз ихтимал. Юк икән — бигайбә.

Гомер бакый эшләгән нәшрият бүлмәләреннән безне чыгарып җибәрергә тырышулар да булды. Монысы шулай ук республиканың партия комитеты җитәкчеләре тарафыннан кузгатылды. Бары тик бу хәбәрне вакытында ишетеп, без, газета һәм журналлар мөхәррирләре, бердәм күтәрелеп, республика җитәкчеләренә бөтен кискенлеге белән үз таләбебезне куйгач кына, бу мәсьәлә үзенең үсешен алмый калды.

Коммунист иптәшләр! Сезнең безне кабат авызлыкларга чакырып ясаган чыгышларыгызга җавап итеп мин, балалар журналының баш мөхәррире, шуларны аңлатырга мәҗбүр...

Үзенең йомгаклау сүзендә КПССның ул чактагы Татарстан рескомы беренче секретаре Рево Идиатуллин, минем чыгышыма берничә мәртәбә тукталып, фиркадәшләрен хуплады. Соңыннан партиянең ничек итеп балалар матбугаты турында кайгыртуын, базар мөнәсәбәтләренә керә башлауга да карамастан, балалар газета-журналлары редакцияләрен ресском нәшрияты бинасында калдырып, алай гына да түгел, бу эш өчен башкалардан, өлкәннәр матбугатыннан әллә ни аерылып тормаган түләү таләп итәчәкләрен әйтте дә, сүзен:

— Йә, ничек, мин хаклымы, иптәш Дәрзаманов?— дип тәмамлады. Аның сорау белән тәмамланган бу җөмләсе партия җитәкчесенең балалар журналистын җиңү тантанасын аңлатырга тиеш иде. Әмма мин, алдын-артын уйлап тормастан, бөтен залга ишетелерлек ачык тавыш белән:

— Хәзергә хаклы!— дип куйдым.

Билгеле инде, башка илләрдә булса, иртәгесен миңа эшкә барып торуның хаҗәте калмас та иде. Әмма мондый аяныч хәлләр булырга өлгермәде. Мине генә түгел, бөтен республикабыз халкын аннан да катлаулырак хәлләр көткән икән...

Күрәзәче төшләр хакында сөйләгәндә, тагын ике төшемә тукталу кирәктер. Аларның берсендә китапка сыймый торган сүз бар, әмма аны төшереп калдырсаң яки йомшаграк башка сүз белән алыштырсаң, төшнең асыл мәгънәсе югала. Шунлыктан, ничек күрдем, шулай язам.

Илебездә үзгәртеп кору сәясәтен игълан иткән КПССның май пленумыннан соң 9 айга якын вакыт үткән — 1986 елның беренче айлары иде шикелле. Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт академия опера һәм балет театрында зур җыелыш бара, имеш. Сәхнә уртасында — КПСС Үзәк Комитеты Генераль сәркатибе, СССР Югары Советы Рәисе Михаил Горбачев. Карасу-көрән костюм-чалбар, ак күлмәк, карасу-көрән галстуктан. Яланбаш. Бельэтажда утырганлыктан, такыр башыннан маңгаенача Курил утрауларына охшап, сибелеп төшкән миң тапларын аермачык күрәм, имеш. Михаил Сергеевич башын чак кына чөеп җибәргән, кулларын билдән түбән кушырган да, тешләргә теләгәндәй, аскы иренен өске тешләренә тияр-тимәс якын китереп, тыңлап тора. Ә халык — умарта күче диярсең, гөжли, шаулый, сәхнәдә сабыр гына тыңлап торган житәкчене тирги:

— Бу ни эш?

— Бу нинди хәл бу?!

— Нишләп илдә тәртип юк?!!

— Син, «торгынлык» дип атаган еллардагы товарлар кая китте?..

Миңа Михаил Сергеевич кызганыч. Мәскәүнең Съездлар сараенда гына түгел, безнең Җәлил театры сәхнәсендә үк җавап тотарлык булгач, эшләре ал да гөл түгелдер шул. Торып бастым да аны яклашам, имеш:

— Җәмәгать — дим, — туктагыз әле, дуламагыз! Үзегезне аның урынына куеп карагыз! 70 ел буе барган хәлләрдән соң аңа да җиңел түгелдер?!

Бу төшне радиода эшләвемнең соңгы елында күргән идем. Уяндым да «аһ» иттем. Йа хода, чыннан да, нинди хәл бу? Сәламәт кешеме соң мин? Каян килеп керә миңа мондый төшләр? Җае чыгып, бу төшне таныш бер журналистка сөйләгәч, ул әллә ни тирәнгә кереп тормады.

— Эштә үстерерләр үзеңне! — диде. Сүзе чыннан да рас килде бит, әй: бер ел дигәндә, һич көтмәгәндә, «Ялкын»га алдылар үземне...

Журналга килеп берничә ай эшләргә дә өлгермәдем, октябрь аенда булса кирәк, төшемдә, Михаил Сергеевич тагын Казанда «күренде». Безнең юлсыз авылларда колхоз рәисләре йөри торган машинада — әле буяулары да кибәргә өлгермәгән УАЗикта иде ул. Машинасын Горький исемендәге паркка каршы яктагы киосклар янына туктатып, тротуарга чыгып басты. Рульдә ул үзе иде шикелле. Башында — карасу зәңгәр эшләпә. Өстендә — җилбәгәй җибәргән шундый ук төстәге плащ. Костюм-чалбары да нәкъ шундый ук төстә. Ап-ак күлмәк, галстук. Бөтен килеш-килбәтеннән пөхтәлек сирпелеп тора. Машинасыннан чыгып, тротуарга басты да бу, карашын югарыга, каршыдагы биек һәйкәл очына төбәп, уйга калды. Мин, аның мәһабәтлегенә, зыялы килеш-килбәтенә, йөзенең нәрсәсе беләндер үзенә тартып торган илаһилыгына мөкиббән киттем.

Шулчак, тротуардан үсеп чыккандай, аның янында безнең радио журналисты Раил Миңнуллин пәйда булды. Раилне мин бик тыйнак, басынкы, әңгәмәдәш белән җиңел аралаша, уртак телне тиз таба торган кеше дип беләм. Ә монда Раилем:

— ...твомать, Михаил Сергеевич, ну что же это такое, в конце концов? Я Вас совсем не понимаю. Народ распустили, страну развалили. Тут не только низа коммунизма, и верха не видно?! — димәсенме?!

Михаил Сергеевич та, Раилгә күптәнге танышына әйткән кебек, җавап кайтарды:

— ... твомать, Раиль Бареич, ну что я один могу делать? Не слушается народ, — диде дә машинасына табан китеп барды.

Бу юлларны мин 1991 елның 17 нче мартында, СССРны саклауга багышланган референдумда тавыш биреп кайтканнан соң яздым. Төптәнрәк уйлап карасаң, аның монысы да рәхәт тормыштан үткәрелгән чара түгел иде. СССР дигән империя җимерелеп, таралып бара. Брежнев конституциясенә язылган «совет кешеләре гомумлыгы» дигән миф чамасыз кабартылган сабын куыгыдай шартлап юкка чыкты: заманында Ленин, халыклар төрмәсе, дип аталган илдә революция ясагач, «милләтләр атасы» Сталин аны олы концлагерьга әверелдереп, башта Хрущев, аннан соң Горбачев шул таш капчык тәрәзәләрендәге тимер пәрдәләрне күтәрә, якты дөньяга тәрәзәләрне ача төшеп, халык әле бер генә йотым сәяси саф һава суларга өлгерде. Шовинизм, тоталитаризм сөременнән арындырылган шушы бер йотым һава да халыкларның милли үзаңнары уянуга этәрде. Милли үзаңның уянуы исә Рәсәй җирендә, Совет илендә беркайчан да эзсез-кансыз гына үтә алмый.

Бу юлы да шулай. Әзербайҗаннар һәм әрмәннәр яшәгән Карабах җире ил буйлап агачак кан елгаларының чишмә башы булды. Һәм туры, һәм күчерелмә мәгънәсендә канлы якшәмбеләр кабатлана башлады. Әфган халкын 9 ел дәвамында аскан-кискән, яндырган-талаган шанлы «тынычлык солдатларыбыз», Тбилиси вакыйгасы көннәрендә, десантчыларыбыз бер гөнаһсыз грузин кызларын үтерделәр. Ул да түгел, үзбәк халкы белән мисхәт төрекләре арасында ызгыш чыкты. Тагын суеш, тагын үтереш... Үзбәкләр тынгач, аларның үзләренә каршы казакълар күтәрелде — кемнеңдер кулы, курчак уйнатучылар осталыгында, төрле милләттәге мөселманнарны бер-берләренә каршы өстерә, берсенең бәхетен, нәни тажлы Ак еланны һәлак иткәндәй, икенчесенең кулы белән будырта иде.

Балтыйк буе республикаларының да язмышы ул көннәрдә кыл өстендә торды: провокация артыннан провокация, үтереш артыннан суеш; ниндидер коткару комитеты салган воткы житә калган — «рус телле» милләтләрнең иминлеген саклыйбыз, дигән булып, танклар, бронемашиналар төп милләт халыкларын мәйданнар, урамнар буйлап куа, изә, сыта...

1552 елны Явыз Иван «килгәннән» бирле 440 ел үтеп, хәсрәтле Татарстан туфрагына аяк баскан урыс «патша»ларының бүгенгесе Борис Ельцин булды. Ул изге йортыбызга бөек рус демократы буларак аяк басты, авыл-шәһәрләребез, колхоз-совхозларыбыз, завод-фабрикаларыбыз, югары уку йортларыбыз белән танышып йөрде. Фән, сәнгать, әдәбият әһелләре белән очрашты. Без аны ихласыбыздан өметләнеп, чын күңелдән алкышлап каршылаган идек. Ул безнең белән бик итагатьле сөйләште, иң кискен сорауларыбызга да төгәл, күзләребезгә туры карап җавап бирергә тырышты. Татарстанның мөстәкыйльлегенә, халкының хөрлегенә каршы түгеллеген әйтте. Кулыгыздан килсә, тулаем алыгыз. Тулаем алырга кулыгыздан килмәсә, өлешчә алыгыз — үзегез тиеш санаган кадәр вәкаләтегезне үзәккә бирерсез. Тик алыгыз, парламент юлы белән генә алыгыз! Татар язучылары исеменнән Ринат Мөхәммәдиев кидерткән татар каләпүшен дә чал башыннан салмады хәтта! Менә бит нинди демократ — кайсы патшаның шулай татар түбәтәен кигәнен күргәнегез бар?! (Хәер, биниһая кыйммәтле Хан бүреге, инде биш гасырлап, урыс патшалары кулында саклана...)

Хәзерге четерекле көннәрдә исә мин тетрәнеп куям. Борис Николаевичның түбәтәй салмавында да бер хикмәт бар икән бит, җәмәгать! Хан таҗыгыз биш гасыр элек үк Мәскәүдә, пыяла япма астында. Бу, әле түбәтәй кия идегез, хәзер инде анысы да Рәсәй таҗы астында калыр! — дигән сүзе булмадымы икән аның?!

Соң, Татарстанда, шул исәптән республика Югары Советында татарлар күпме дә, урыслар күпме? Әлбәттә инде, «өлкән туганыбыз» депутатларның яртысыннан аз гына кимрәк. Ә телен онытып, динен, кыйблысын җуйган татарларыбыз? Алары да хәтсез. Аларга мөстәкыйль

Татарстан кирәкме? Юк, әлбәттә. Аларга бары тик Рәсәй империясе генә кирәк! Авылда билдән дуңгыз тиресенә батып чучка ите житештергән, көне-төне кырдан кайтып кермәгән җөмһүрияттәшләрең дә, туган йортыбызның бөтенлеген кайгырткан Шәймиевләрең, Мөхәммәтшиннарың, Сабировларың берни түгел аларга! Димәк ки, алар Югары Советтагы үз депутатларына мөстәкыйльлекне яклап тавыш бирергә рөхсәт итмәячәкләр. «Татарстан, Рәсәйнең революциягә кадәргегә караганда да күпкә кечерәйтелгән бер губернасы гына булып калсын!» Сүздә — ирек бирелгән. Булдыра аласың икән — ал! Кулыңнан килмәсә — бигайбә!

Әмма 1990 елның 30 августы, бәхеткә, бу пошынуларны чәлпәрәмә китерде. Минтимер Шәймиев җитәкләгән Югары Совет сессиясе Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеге турындагы Декларацияне кабул итте.

Һәм менә хәзер, шул мөстәкыйльлекне тормышка ашырыр өчен ут йотып йөргән көннәрдә, без хөрмәтле Ельцинебыз авызыннан мөстәкыйльлегебезне яклап әйткән бер генә сүзен дә ишеткәнебез юк. Юк, үз кулы белән бер генә нәрсә дә эшләми ул безгә каршы. Моның өчен РСФСР Югары Советында Хазбулатов, Румянцев кебек җәмәгать эшлеклеләре, үзәк матбугатта Жан Миндубаев ише каләм ияләре бар. Әйдә, таласын шулар яраларыннан биш гасыр кан саркып торган татар җанын! Революция елларында мөселманнарны мөселманнар кулы белән яулап алу яраган икән, аның агачлары чәчәк атып, инде мул җимешләрен биргән заманда ник ярамасын ди әле ул ысул?!

СССРны саклап калуга юнәлтелгән референдумга барачак таңда тагын бер куркыныч төш керде миңа. Горький урамына трамвай юлы салганнар, имеш. Мин утырган трамвай Кекин йортына җитәр-җитмәс капыл туктап, артка китте. Уң якта, тимер рәшәткәле койма капкасыннан бер УАЗик чыгып, трамвай юлына менгән. Шофер исә руль артында йоклап утыра! Әмма бу машина капка авызын да саклый икән әле. Капка аша шәхси гараж күренә. Шул ишектән аз гына алдарак, урамга табарак билдән югары өлеше генә калган солдат гәүдәсе ята. Өстендә китель, башында — фуражка. Дүрт-биш кеше шул гәүдә тирәли баскан да, җинаятьчеләрнең эзенә төшәр өчен, милиция килгәнне көтә, имеш. Инде мин үзебез яшәгән Себер тракты урамында, троллейбус тукталышында торам. Ватылып-җимерелеп беткән юлдан акрын гына милиция машинасы килә. Арткы утыргычында — теге бәхетсез солдатның башы. Инде гәүдәсе дә, кителе белән фуражкасы да юк... Тукталыштагы халык «аһ» итә, мескен егетне кызгана, имеш.

Сүз дә юк, куркыныч төш. Төш кенә дә түгел, саташу. Әмма бөтен иле, иле генә түгел, дөньяның яртысы саташканда, кешеләрнең иңрәп елаган, Бөек Акылга иңәлеп ялварган авазлары, күкләргә ашып, Җир шарын урыйлардыр да, безнең күңелләребезгә иңәләрдер, төшләргә керәләрдер.

* * *

Уйлана торгач, тагын бер төш искә төште. Шактый еллар, ат урынына эшләп тә, фатир ала алмыйча, радиодан китеп, «Татарстан яшьләре»нә бүлек мөдире булып күчкән көннәрем иде. (Мин бу редакциядә нибарысы биш ай гына эшләп алдым.) Редакциягә ифрат четерекле бер хат килеп төште. Мамадыш районының «Спартак» колхозыннан иде ул. Хат авыл яшьләре белән җитәкчеләр арасындагы биниһая катлаулы вә чуалчык мөнәсәбәтләр хакында булганлыктан, хәлне урынга барып тикшерергә кирәк иде. Нәтиҗәдә, газетада «Дәгъва» дип исемләнгән күләмле мәкаләм дөнья күрде.

Әмма бу кадәресен мин Мамадыш кунакханәсендә күргән төшемне сөйләр өчен генә яздым.

Куркыныч бер төш иде бу. Йокыдан уянганнан соңдырмы, әллә инде физик күнегүләр ясагачмы, бил тигентен чишенгән килеш, көзгегә карап торам, имеш. Бөтен тәнем кызарып, кызышып тора, ә күкрәгемне карт кычытканнан чактырганнармыни — тоташ чабырып чыккан. Тәнемдәге шул авыру-тапларга карап, котым чыгып торам, имеш. Җитмәсә, чыраем да байтакка олыгайган икән...

Төш минe тәмам пошаманга салды. Ни булыр бу?! Нинди авыру? Әллә соң яман шеш дигән яманнардан-яман чирнең тәнгә чыга торган төреме?

Чамасыз куркырга, миндә теге чир бардыр, бу авыру бардыр, дип, шикләнеп йөрергә яраманлыгын да яхшы беләм. Шуңа күрә дә мин бу төшне мөмкин кадәр тизрәк онытырга тырыштым. Юк. Төшләремнең монысы да хәтеремә фотосурәт сыман нык кереп урнашкан булып чыкты. Дистә елга якын вакыттан соң... 90 нчы елның мартында, баш мөхәррир буларак, «Ялкын» журналы белән якыннанрак таныштыруымны үтенеп, Чаллы мәктәпләренең берсенә очрашуга чакырдылар. Балалар янына дәшкәндә, бармый калган чакларым сирәк. Бу юлы да баш тарта алмадым. Мәктәбе андый-мондый гына да түгел, монда минем биш балдызымнан иң яратканы укытучы булып эшли...

Бер көн эчендә ике мәктәптә гөрләтеп очрашу үткәрдек. Аруын башка чаклардан ким арымаган идем. Әмма башны мендәргә салмас борын ук йоклап китүләр насыйп булмады. Төнне читенсенү, авырыксыну галәмәтләре басты, суларга һава җитми, тын кысыла, әйтерсең лә, бугаз төере капыл гына зурайган да, сулыш алырга комачаулый кебек. Иртән ике яктан да бил тирәләрем чабырып уяндым. Гөманлавымча, кычыткан авыруының башы иде бу.

Берничә көннән көзгедә үземне нәкъ менә теге елларда, Мамадыш кунакханәсендә төшемә кергән кыяфәттә күрдем. Теге чакта «чыраем ник болай олыгайган икән?» дип аптырасам, бу юлы, сурәтләрнең өндәгесе белән төштәгесе тәңгәл килгәнлектән, бу чир ничек шулай дистә еллар алдан төшкә керә алды икән, дип баш ватам.

«Кычыткан» чире башланганчы бугай әле, көзгедәге күренеш тагын бер тапкыр керде төшемә. Бу юлы минем кыяфәт битләрен, муен, күкрәк тирәләрен тирән җыерчыклар ермачлаган, ап-ак чәчләре тар тасма булып башның бары тик арт өлешендә генә калган, ялтырап торган такыр башлы монсумы, әллә инде шунда бераз сырхауракмы бер карт кебек иде... Бу төшемне мин, кызык итеп, каләмдәшем Ләис Зөлкарнәйгә сөйләдем. «Болай булгач, тиз генә үлмибез, Аллаһы боерса, бер җитмешләргә кадәр яшибез икән әле рәхәтләнеп!» — дидем. Ләис көлде. «Тасвирлавыңа караганда, кимендә 90 га кадәр интегәсең бар икән әле!» — диде. Бирсен ходай, мин 110 ел яшәргә дә риза. Сәламәтлек кенә булсын...

Көзгедәге сурәт өченче тапкыр төшкә әле күптән түгел генә керде. Тагын авыруымның көчәячәген күрсәтте, хәерсез. Нәкъ шулай булды да...

Әмма монда көзгенең шулай алдан ни буласын күрсәтүе бер гаҗәп булса, һаман да шул бер үк көзгенең керүе гаҗәп! Өчесендә дә аның рамы-фәләне булуын хәтерләмим. Без бала чакларда авыл өйләрендә була торган, иңе-буе 30 — 40 см. чамасындагы гадәти көзге. Шактый сөремләнгән. Кем белә, бәлки Югары көчнең алдан кисәтүе, әлеге авыруларны китереп чыгара торган сәбәпләрдән сакланырга кушуыдыр бу. Шушы зәхмәттән арына алсаң, туксанга кадәр яшәрсең, диюе булгандыр. Әмма эчке тавышны (бәлки Илаһи тавышныдыр) тыңларга өйрәнмәгән шул без. Тыңлау түгел, аның барлыгын уйларга да күнекмәгән. Ул уй, ул хис-тойгылар, инанулар 70 ел дәвамында совет мәктәпләре тарафыннан күңел түребездән, рухи күгебездән чыгарылганнар шул инде. Имгәтелгән рухларыбызны кабат савыктыру, иман-кыйблабызны кире кайтару, әйһай, тиз генә насыйп булыр микән безгә? Милләтебезнең тәнен манкортлык дигән яман чир, милли гадәт-йолаларыннан, үз халкының

гореф-гадәтләреннән кабара торган «кычыткан авыруы» баскан бу егерменче гасырда бигрәк тә...

* * *

Сугышка, кан коешка бәйле төшләр дә кергәлиләр миңа. Малайлык елларымнан ук керәләр алар, шайтан алгыры! Анысы, мөгаен, бөтен тормышыбызны, әдәбият-сәнгатебезне, көндәлек матбугатыбызны күмеп киткән «патриотик тәрбия» җимешедер. Һичшиксез, бу кадәресе дә бардыр. Хәзер сөйләячәк төшем менә шул тәрбиянең бер җимешедер, бәлки. Ә бәлки...

Кайдадыр партизанлык итеп йөрим, имеш. Ни сәбәптәндер аклар кулына килеп эләккәнмен. (Шунысын да әйтим, гражданнар сугышы елларында безнең Сугышлы авылы еш кына хәрби хәрәкәтләрнең үзәгендә калган. Үзенең атаклы кызыл партизаннары да булган. Хәтта безнең чорда, дүрт дистә еллап вакыт узгач, күршеләребезнең берсе искергән мунча мичен алыштырганда, җиргә түшәлгән олы җәлпәк ташлар астыннан сумалалы чүпрәкләргә һәйбәтләп төрелгән патроннар һәм башка хәрби кирәк-яраклар табылган. Моны күргәч, маңгаена салкын тир бәреп чыккан агаебыз ничек итеп артына утыруын да сизми калган — уенмыни, ничә еллар «дары мичкәсе» өстендә мунча чабынганнар бит!

Кулга төшкән партизаннарның язмышы бер генә инде анық. Мине дә асарга алып киттеләр, имеш. Әллә кая барып, дар әзерләп маташмадылар тагы. Үзебезнең өйгә алып керделәр дә, мич аралыгындагы урындыкка бастырып, муеныма элмәк салдылар... Һай, күңелле хәл түгел икән ул, җәмәгать! Өндә күрергә язмасын! Йөрәк шашып тибә. Хәзер... Менә хәзер!.. Тик түзәргә, бераз түзәргә генә кирәк... Аз гына авыртыр да бетәр... Сабыр булырга, бераз түзәргә генә кирәк...

Шушы төш хәтеремә килә дә, иманеп китәм. Ә бит өннәрендә никадәр халкыбыз, бәһасез зыялыларыбыз, акыл иясе хакимнәребез, мөһәндис-инженерларыбыз, гомер бакый илне туендырып яшәгән ил агасы торырлык крестьян агайларыбыз кичергән бу хәлләрне. Иң соңгы хис — үлем ачысын татыган алар. Һәм барлык «гөнаһлары» туган илне, халыкны, җирне, туган телне сөюдә булган...

...Немец фашистлары белән сугышка бәйле бер төш миңа берничә тапкыр керә инде. Мине таныш булмаган урманга җибәрәләр. Билгеләнгән бер агач төбендә яшерелгән ниндидер бик әһәмиятле нәрсә алып кайтырга тиешмен икән. Әмма вакыты бик уңайсыз — әллә кичке эңгер төшкән чак, әллә инде таң беленеп, кояш әле чыгарга өлгермәгән вакыт... Урман эчендәге тар гына сукмактанмы, арба юлыннанмы йөгерәм. Әйбер яшерелгән агач төбенә җитәрәк, юлның ни өчендер казып көпшәкләндерелгән урынын үтәсе. Шулчак сул якта бер аланчык ачыла. Анда немецлар урнашкан, имеш. Шалаш алдындагы атсыз арбада дүрт-биш немец утыра. Барысы да гимнастеркадан гына. Җиңнәре терсәкләренә кадәр сызганулы. Кулларында — автомат. Шуларның берсе мине күреп ала да, тиешле нәрсәмне алырга өлгермичә үк, мин җан-фәрман йөгерә башлыйм. Фашистларны адаштырып калдырганчы йөгерәм дә йөгерәм. Аннан соң таныш булмаган ниндидер бер авылга килеп керәм. Берничә йорт янынан йөгереп узуга, төш өзелә... Әмма шулкадәрле дә ачык керә ул, һәр өлеше, һәр нәрсәсе шулкадәрле күңелгә уелып кала, рәссам булсам, һич икеләнмичә, шул картинаны яза алырмындыр сыман.

Каян килеп керә миңа бу төш? Нишләп кабатлана ул? Нишләп заданиегә барганда ук мин аны үти алмаячагымны белеп барам? Бәлки сугышта әтием белән булган хәлләрдер бу? Бәлки берәр дусты сөйләгәндер, һәм шул вакытта әтием күңеленә сеңеп, кан белән миңа да күчкәндер? Һәрхәлдә, бу хакта әтидән сорау уе башыма килгәне булмады. Бу

төшне башка бер карт фронтовикның күрүе дә бик ихтимал ич. Ниндидер берәр бик житди задание үтәлми калгандыр да, карт сугышчы шуларны уйлап битәрләнәдер. Шул төшләр әлегә мин аңламаган ниндидер хикмәтле юллар белән миңа да килеп керәдер...

Тагын бер төш. Хатыным Тәслимәнең туган җирендә — Саба районының Сабай авылында икәнмен. Авылның биек бер урынына клуб урнашкан. Мин шул клуб эчендә пыр тузып немецлар белән сугышып ятам, имеш. Берөзлексез автоматлар тыкылдый, колак төбеннән ядрәләр сызгырып оча. Безнекеләр белән фрицлар буталып беткәннәр, кайсының кайда ятканлыгын, кайсының кемгә атканлыгын һич белерлек түгел. Күңелдә тик бер генә теләк — ул да булса мөмкин кадәр тизрәк бу мәхшәрдән исән-имин чыгып котылу... Үзем атам, үзем чигенәм. Менә ишек, менә бусага... Шуннан исән килеш чыгып, ишеккә йозак салсам, сугыш гарасатыннан котылдым дигән сүз... Алга карап, автоматтан ут сибәм дә сикерәм. Ул ачылып китә, мин тышка тәгәрим. Тизрәк, тизрәк! Ишекне ябарга! Яптым. Тизрәк, тизрәк! Атлама тимерне ишеккә аркылы салып, йозак эләргә! Элдем... Аллага шөкер! Мин иректә, мин исән! Маңгайга бәреп чыккан салкын тирне сөртәм, аркага лайлаланып ябышкан гимнастерканы кубарырга азапланам. Автоматны янәшәдәге куаклар арасына томырам да, торып китмәкче булам. Күрче, болдырның бер як уемында мич төбенә салып пешерелгән өч, икенче як нигезендә, түгәрәк дүрт ипи өелеп тора. Бик гаҗәпләндем бу хәлгә. Шушындый авыр заманда кем куеп калдырды икән бу кадерле икмәкне, дим. Берсен алып куеныма тыктым. Калганнары, ничек өелеп торган булсалар, шулай үз урыннарында калдылар...

Армиядә өч ел хезмәт итсәм дә, пистолет вә автоматтан сугышчан патроннар белән атып карасам да, элемтәче булганлыктан, автомат тотып, «һөҗүмгә» барганым, «дошман» белән кара-каршы атышып караганым булмады. Һәрхәлдә, бу кадәресе һөҗүмгә барганда шартлагыч ядрә тиеп бер аягын өздергән, ярты канын яу кырында, чирек канын операция өстәлендә калдырган әтиемнең каны аша миңа күчкән кичерешләредер. Абайлап алган укучыларымның кайберләре: «Күр әле, син бит күкрәге белән дошман амбразурасын каплаган Газинур Гафиятуллин авылдашы, ничек инде немецларны кырып бетерми торып, чыгып качарга җөрьәт иттең?! Куркак! Сатлык!» — диярга мөмкин. Куркуым хак. Бөтен дөньясы исән-имин яшәп ятканда, шул җимерелергә торган клуб эчендәге хәерсез фрицлар белән сугышып, бер кирәкмәгәнгә үләсем килмәве дә хак. Шулай тик торганнан гына кайсыгызның якты дөньядан китәсе килсен икән? Әнә Әфган җиренә кертеп, бер кирәкмәгәнгә ике дистә меңгә якын сөлектәй егетләребезнең газиз гомерләрен өзмәделәрмени? Ахыр килеп, бу бит әле миңа кергән төш кенә. Тормышта татырга язмасын ул кичерешләрне! Ә чынлыкта шул тәмуг юлларын кичәргә туры килсә, кемгә ни буласы, кемнең нинди гамәл кыласы турында бары тик тормыш үзе генә җавап бирә ала.

Ә теге мич төбенең кайнар көле ябышып пешкән җиде ипинең берсен куеныма алуым турында хикмәт чыгарырга мөмкин. Әбием (хатынымның әнисе) ун бала үстергән. Җидесе — кызлар. Шул кызларның берсе — минем хәләлем...

* * *

Балачакта минем иң көчле укытучы-мөгаллимнәремнең дә иң көчлесе — Табигать булды. Аның һәр авазы, һәр аһәңе, һәр моңы мәңге җуелмас булып хәтеремә сеңеп калган. Һәм хәзер дә ул минем күңелемдә мәңге кабатланмас шагыйранә дөнья булып яшәвен дәвам итә.

Безнең Ачы урамы халкының бәрәңге бакчаларыннан соң ук Ачы тавы башлана. Аның түбәсенә менүгә, шактый тигез кыр-басулар җәйрәп

китә. Алар артында — урман. Хәер, кайчандыр серле карурман булган бу хәзинәнең хәзер Улаклы дигән исеме генә калып бара инде...

Без малай вакытларда гына да әле әти белән шул тау итәгендә, уйсурак урыннарында печән чаба торган идек. Хәзер инде тауда авыл көтүе йөри, кайчандыр итәгендә матур булып яшәреп утырган ногыт, кара бөрлегән куаклары да корып беткән. Тау бите мал-туар тояклары белән таптала-таптала ерткаланган, буй-буй сукмаклар булып ермачланган.

Менә шушы тау берничә тапкыр төшемә керде. Соңгысында уяндым да уйланып ятам: туктале, ни булды соң әле бу? Ачы тавының нә итәгендә булсын, нә түбәсендә сыңар агач дип әйтмим, куерак, биегрәк сыңар куак та үсмәгәнлеген бик яхшы белә идем, югыйсә. Ә бүген... Ничә гасырлар элек шушылай булгандыр ул, анысын әйтәлмим. Әмма бик күп еллар элек, әле безнең авыл Сугышлы исемен алганчы, Яңа Нәдер исеме белән аталып килгән заманнарда, бигрәк тә аңа нигез салынган чорларда, авыл һәр яктан урман белән уратып алынган булган, дип өлкәннәр авызыннан күп тапкырлар ишеткәнем бар.

Дөрес, мин төштә күргән Ачы тавын урман белән капланган иде дип булмастыр. Сирәк урман иде ул. Тауның итәгеннән алып, түбәсенә, түбәсеннән хәзерге Улаклы урманына кадәр — бөдрәләнеп утырган усак, юкә, имән агачлары... Агач араларында — кәрешкә, тукранбаш чәчәкләренә уралып беткән биек сусыл үлән. Тау түбәсенең бераз гына иңкүләнеп торган урынында — бәләкәй генә түгәрәк зәңгәр күл. Ә һавасы, һавасы нинди! Андый һава шәһәрдән генә түгел, авылдан да йөзләрчә чакрымдагы урман өстеннән шифалы яңгыр явып узганнан соң гына була торгандыр...

Ачы тавына каршы якта — заманында мул сулы Чишмә елгасының икенче як ярында — Наратлык тавы. Еллар авырлыгыннан ылыслы боталарын түбән игән кытыршы наратлар әле һаман да гомер кичәргә азапланып утыралар ул тауда. Наратлык тавының өстендә дә — иген басулары, басулар артында — урман. Ул урманнар шулай ук, кайчандыр Чишмә ярларына ук килеп терәлгәннәр, дип фараз кылсак... Искиткеч урында урнашкан булган бит безнең авыл! Сайлый белгәннәр бит бабайлар авыл өчен урынны!

Төшемдә авылның үзен күрмәдем мин. Бары тик Ачы тавында үскән агачлар арасында гына йөрдем, тау түбәсендәге түгәрәк күл янында кинәнеп саф һавасын гына суладым...

Авылның төньяк-көнчыгышына китсәң, шулай ук — урманнар. Кислин елгасына каршы барып (дөресе — Сагышлы. Кайбер галимнәр һәм әдипләр, аерым алганда, якташым Җәмит Рәхимов фаразы буенча, авылның хәзерге исеме дә шуннан алынган булырга тиеш), дүрт-биш чакрымлап менүгә, үзәннең ике ягында урманнар белән капланган ике тау пәйда була. Сул якта — Наратчагыл, уң якта — Котсыз урманы башлана. Котсыз урманына мондый исем тикмәгә генә бирелмәгән — ул әле хәзер, соңгы берничә дистә ел эчендә, тәмам таланганнан соң да, гаять шомлы, куркыныч күренә. Заманында ул ерткыч җәнлекләр, елан-аждаһалар белән мыжгып торган, элеккеге кара елларда төрле качкыннар, ат караклары өчен бер дигән сыену урыны булган, имеш...

Без малай чакта иң җиләкле урыннар — әнә шул Наратчагыл белән Котсыз тау итәгендә була торган иде. Үләннәр дә куерак, биегрәк үсә анда. Ә бер ягыннан икенчесенә шәбрәк йөгереп килсәң, сикереп чыгарлык, иң тирән урыны муеннан узмаган, төбендәге чуерташлары күренеп торган саф, керсәң, мизгелендә тәнеңне куырып алырлык, салкын сулы Сагышлыда беләк буе-беләк буе симез керкәләр йөзә. Падишаһлар гына ашый торган балыклар! Ә без, җүнле ыштан да кияргә насыйп булмаган авыл малайлары, шул затлы ризыкны да авыз итеп үстек. Авылдагы хәзерге буын керкәне китаплардан гына укып белә инде. Ул балык бары тик күрше авылның исемендә генә калды. Хәтта эт-мәче, кәҗә-сарык,

үрмәкүч-балык ише нәрсәләргә бәйле мең дә берне белгән галим, университет елларымда укыткан Гомәр Саттаров, ул төбәкләрдә керкә балыгы юк һәм беркайчан да булмаган, дип язып чыкты. Булмаган кая! Сугыштан аяксыз кайткан әтием заманасында күп каптырды инде аларны кармакка. Теләсә нәрсәгә түгел, тере маймычка бик теләп каба ул керкә. Көндезләрен без (Риф, Сәгыйть кебек дус малайлар белән бергә) әти үзе бәйләп биргән кечкенә сөзгеч белән маймыч сөзеп кайтабыз, әти исә аларның суларын алыштыра да, мине ияртеп, кичке савымга баручы апалар белән бергә машина әрҗәсенә утырып, елганың югарырак, авылдан ераграк, суының чистарак урынына китә. Керкә балыгы — бик чиста, пакь җан иясе, пычрак, нәҗес нәрсәләрдән мөмкин кадәр ераграк булырга тырыша икән.

Бервакытны әлеге дусларым белән үзебез генә балыкка барганыбыз да хәтердә. Сөзгеч алып, әти-әниләргә әйтмичә генә... Байтак сөзеп азапландык без. Әмма юкка... Салкын суда тәмам күшегеп, бөрешеп беттек. Тәннәребез, иреннәребез күм-күмгәк булды. Соңгы тапкыр кереп чыгабыз да... Шулчак «дыңк»! иттереп сөзгечкә нидер килеп бәрелмәсенме! Тизрәк ярга чыгарып атарга кирәк: бердән, сөзгечебез кыска, зур балык бөгәрләнерлек түгел, икенчедән, керкәнең тешләре тимер кискеч кебек! Сөзгечеңне өзеп, минуты белән чыгып шылачак! Һап! Сөзгеч ярда. Сөзгечтә — үзе симез, үзе дә-әү керкә балыгы! Беләк буе! Безнең беләк шае гына түгел, озын буйлы Мөнир абзыйныкы кадәр үк булмаса әле... Сикерә, дулый, хәерсез, адәм генә тыярлык түгел. Чак тынычландырдык үзен, аннан соң көчкә күтәреп кайттык. Әтинең дә моның кадәрлесен тотканы булмаган, күрәсең. Шаккатты. Сорамыйча киткән өчен «тәрбия сәгате» уздырырга да онытты хәтта. Ә балыкны үзебездән гел чын балыкчы сыман бүлдертте әти: баштан үзе тигезләп өч өлеш ясады, аннары, беребезне аркасы белән борып бастырды да: «Бусы кемгә? Бусы кемгә?..» — дип кычкыртты. Беребезгә дә үпкәләрлек булмады. Ә Гомәр әфәндебез Саттаров «булмаган ул якларда керкә балыгы» дип ышандырырга тырыша. Һе...

Менә шул. Төшемдә, үзебез керкә тотып йөргән урыннардан да байтак өстәрәк, үзебез җиләк җыярга яраткан урыннарда йөрим, имеш. Ходавәндә! Нинди матурлык, нинди яшеллек, нинди сафлык! Кереп китсәң, билдән — сусыл үлән. Без җәй башларында какы, аннары җиләк, шомырт җыеп йөргән елга буйлары — тоташ әрәмәлек! Чыннан да, ара-тирәколмакка чорналган зирек, тал, шомырт агачлары үсеп утырган бу җирләрне халык әрәмәлек дип йөртә. Әмма чын әрәмәлекне күргәнем булмаган икән шул әле минем. Менә нинди була икән ул әрәмә дигәнең! Ерып чыкмалы гына булмый икән ул. Үсемлекләре дә әллә ничә катлы булып үсә икән. Иң түбәндә — дым исе аңкып торган вак үлән. Вак үлән өстендә — кыяк яфраклы биегрәк үләннәр, аннан да биегрәк — абага кебек киң яфраклы үләннәр... Төрледән-төрле аллы-гөлле чәчкәләр аяк астында бизәкләп чигелгән затлы келәм булып ята. Агачларның берсе икенчесенә сыенып үскән урыннарында шау яфракка, аксыл-сары чәчәккә күмелгән колмак сабаклары аларның берсеннән икенчесенә күчеп, тоташ дивар хасил итә. Төрле кошларның сайравын тасвирларга каләмем көчсез — үзе бер сихри дөнья, үзе бер илаһи симфония. Шушы илаһи көйгә чылтырап агып яткан инеш җыры кушыла. Күңелдә тел белән аңлатып булмый торган җиңеллек, сафлык, рәхәтлек. Бернинди дә борчылу, авырыксыну, арыганлык хисе юк. Бары тик соклану, ошбу гүзәллектән сихерләнү, каршымда ачылган бу илаһи манзарадан тәмам исерү, мәмнүн булу тойгысы гына бар. Тукта, мин инешнең Котсыз урманы ягында йөрим ич әле. Наратчагыл ягына да чыгарга кирәк. Әнә якында гына бу ярдан теге як ярга ятып диярлек зирек агачы үскән. Шул агачны үземә басма итеп (җәй башларында ачы какыга килгәндә дә нәкъ менә шушы урыннан йөрми идек микән әле?!) каршы якка күчәм. Аякларымны тоймадым да — очып кына чыктым бугай. Йа хода, бу якта да шундый ук саделек, сафлык, хозурлык!..

Менә шуңа охшаш төшләр миндә, ирексездән, мин инде кайчандыр бу дөньяда бер тапкыр яшәп киткәнмендер дә, хәзер шул ук таныш урманнарда, болын-кырларда йөримдер, дигән сәер уйларга этәрә. Тагын шунысы да бар: төшләрнең мондый төрләрен күргәндә мин гәүдәмне дә тоймыйм, тән әгъзаларын да күрмим. Һәм иң гаҗәбе, андый төшләр миңа малай чагым булып керә. Һәм аларның нәкъ менә бала күңеле, балачак белән бәйле булуларында шулай ук Табигатьнең бөек серләреннән берсе яшеренгән сыман тоела миңа...

Әле күптән түгел генә төшемдә әлеге Наратчагыл тавында тагын бер тапкыр йөрдем мин, аның түбәсеннән торып, каршы яктагы Котсыз тауларын, аның итәкләрен, Сагышлы елгасының бормаланып-бормаланып калган үзәнен күзәттем.

Күк йөзе чалт аяз. Тотенсымак сыек зәңгәрлек, һавада гына калмыйча, рәшә сыман җиргә дә иңеп, күңелдә беркадәр авыр тойгылар уята, йөрәкне кысылып-кысылып алырга мәҗбүр итә. Һәр тарафта — аяк астында да, уңда, сулда, алда, артта, якында һәм күз күреме җитмәслек ерак арада да — аксыл-соры, эреле-ваклы ташлар. Үлән әсәре дип әйтмим, хәтта туфрак, тузан бөртеге дә юк. Әйтерсең лә, иксез-чиксез киңлекләргә җәелеп киткән таш базына килеп кергәнмен. Каршымда калкып торган Котсыз тавында да нәкъ шундый ук күренеш. Ә түбәндә, елый-елый яше белән бергә күзләре дә кибеп беткәннән соң калган күз чокырыдай, кайчандыр бормалана-бормалана аккан Сагышлы елгасының коры ермагы ята. Аның өстендә буйдан-буйга кайсы очы, кайсы кыры белән яткан тәүмәл-тәүмәл ташлар йоклаган Аждаһа сыртын хәтерләтә. Менә ул уяныр да, дистәләрчә чакрымга сузылган таш гәүдә сыртындагы ташларны бер-берләренә бәреп, очкыннар чыгара-чыгара, шуыша башлар сыман... Күңелдә — табигатьнең бары тик шушы халәтен тою хисе генә. Әйтик эш беләнме, ял итәргәме баргачмы, җирнең моңарчы таныш булмаган берәр төбәге белән очрашкандагы кебек...

Уянгач, уйланмый кала алмадым, әлбәттә. Монысы туган төбәгемнең кайсы вакыты була икән инде? Ерак үткәнеме, әллә киләчәгеме? Мөгаен, соңгысыдыр. Һәм шулай гөманларга үз фикерләрем, дәлилләрем дә бар.

Табигать өчен, Җир-ана өчен кем күбрәк куркыныч: кешелекме, әллә хайваннар дөньясымы? Баштан ук кистереп җавап биргәнче, фикер йөртеп карыйк. К е ш е кем дә, х а й в а н кем (гәрчә без аларны н ә р с ә дип атап йөртсәк тә)? Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә аларга түбәндәгечә билгеләмә бирелә:

«К е ш е. и. 1. Фикерләү, сөйләшү, корал җитештерү һәм аннан хезмәттә файдалана алу сәләтенә ия булган зат, җан иясе, шәхес». Шуннан соң ук әлеге билгеләмә татар әдәбияты классигы Габдрахман Әпсәләмовның «Кеше үзенең бәхетен хезмәт чишмәсеннән таба» дигән юллары белән беркетелә.

«Х а й в а н. и. 1. Үсемлекләрдән кала, хәрәкәтләнү һәм сизү сәләте булган һәрбер җан иясе. Йорт хайваны. Эш хайваны. Ерткыч хайван». Мисалларның берсе Фатих Хөснидән: «Акыллы хайван иде, җаным, ни булды икән бу Актырнакка?»

Йорт хайваннарының нигездә акыллы буларын, күрәсез, мисалдан ук чамаладык. Эш хайваннарының да кем икәнлеген, нигездә, беләбез. «Гомерем буена эшләдем, күтемә бер ыштан да алып кия алмадым!» — дип әйтеп әйткән ди беркөнне ат мескенкәй.

Инде сүзлектән «е р т к ы ч» сүзен эзләп карыйк.

«Е р т к ы ч. и. 1. Башка хайваннар белән тукланучы җәнлек. 2. күч. Чиктән тыш явыз, рәхимсез, аяусыз, кансыз кеше турында.— Нинди ерткыч бу Иргали! Фәтхи Бурнаш...»

Ярар, хуш. Әлеге өч сүзгә билгеләмә бирдек. Хәзер инде әлеге фетнә сорауны кабыргасы беләнрәк куйыйк: кеше хайванракмы, әллә инде ерткыч хайван кешелеклерәкме?

Сүзне «б а ш к а  х а й в а н н а р  б е л ә н  т у к л а н у ч ы  ж ә н л е к»тән башлап карыйк. Ерткыч икән ерткыч. Үзеннән көчсез башка хайваннар белән туклана икән, димәк, туклана. Хак сүзләр, инкяр итәр урын юк. Әмма бәхәсләшер урыннар житәрлек.

Мин бер генә ерткыч хайванның да (балаларына, нәсел-нәсепләренә зыян-зәүрәт салган бүреләрдән кала) кирәгеннән артык азык тапканы, үзе туклана торган җәнлекләрне тоташтан кырып салганы хакында ишеткәнем дә, укыганым да юк. Ниндидер хәлиткеч алышларда, язгы туй йолалары вакытында көчлеләр көчсезләрне үтерүгә кадәр барып житсәләр дә, бер генә кыргый җанварның да үз токымыннан икенче берәүне тотып ашау очракларын белмим. Булган очракта да алар кагыйдәдән чыгарма буларак кына кабул ителергә мөмкин. Бусы булды бер.

Икенчедән, мин, нигездә, бары тик йорт хайваннарының гына үзләренең торак урыннарын пычратуын беләм. Кыргыйларның күпчелегендә чисталык — тән сәламәтлегенең төп кануннарыннан берсе. Менә шуның өчен дә күпчелек кыргый җәнлекләрнең өн эчләре дә, «йорт-кура» тирәләре дә чиста була — син анда ул җәнлек гаиләсенең үз нәҗесен күрмәссең.

Заманында безнең тауларда, бигрәк тә Атау тавы дип аталган иң биек тауда (Атау тавы тирәсендәге үзәннәрдә кайчандыр борынгы заманнарда мул сулы дәрья булган дип фараз ителә, ә аның итәгендә табылып торган күпсанлы кабырчыклар андый фаразга урын калдыра) суырлар (байбак) күп яши иде. Эч майлары үпкә авыруыннан шифа булганлыктан, кызганычка, соңгы елларда аларны күпләп кырганнар икән, хәзер бу җәнлекләр бик сирәк очрыйлар инде. Менә шул суырларның гадәт-холыкларының мин күзәткән кадәресе генә дә искитәрлек. Аларның оя авызында чүп тә, тизәк тә тапмассың — оядан читтә ясалган махсус «бәдрәф»ләре бар аларның. Хаҗәте булганда бары тик шунда гына чыгарлар, шунда гына йөрерләр. Оя авызы янында, аның өске тирәләрендә күпчелек очраган нәрсә — әспе җиләге. Ничек үстерәләрдер, ничек үрчетәләрдер алар бу җиләкне, ул кадәресен белмим. Ничек кенә булмасын, әлеге үсемлекләр оя тирәләренә үзенчә бер матурлык биреп, бизәп торалар. Суырларның азыкка, суга, уен мәйданнарына йөри торган аерым сукмаклары бар.

Уен мәйданы дидем. Менә шул мәйданга суыр халкы бөтен гаиләсе белән чыга. Тезелешеп утыралар да, бала-чагаларын көрәштерергә тотыналар. Нәкъ безнең сабан туендагыча. Баштан иң кечкенәләр чыга. Әй көрәшеп күрсәтәләр дә соң! Арт тәпиләренә басып, алгылары белән билләреннән тотынышалар да алыша башлыйлар. Әле берсе күтәрә, әле икенчесе. Чын-чынлап, ихласларыннан көрәшәләр бит, рәхмәт төшкерләре! Көч сынаша торгач, берәрсенең хәйләсе җиңә — көндәшен күтәреп ала да, йә баш, йә янбаш аркылы күтәреп ата, минсиңайтим! Өлкәннәрнең берсе (әтиләредер инде) таләпчән сызгыра-сызгыра хөкемдарлык кыла. Хәрәмләшмәгез, аяк чалмагыз, җиңү гадел булсын, янәсе. Бөтенесе дә нәкъ безнеңчә, кешеләрчә! Акылсыз дип кем әйтер бу хайваннарны...

Кыскасы, әле бер генә хайванның, бер генә җанварның да моңарчы Табигать-ананы үзенең эшчәнлеге нәтиҗәсендә харап иткәне, үзе яшәгән мохитны фаҗига, планета-күләм һәлакәт дәрәҗәсенә китереп җиткергәне юк. Дөрес, үз чорында аждаһа-динозаврлар әйләнә-тирә мохитны шулкадәрле дә нәҗесләгәннәр, үз нәҗесләренә үзләре үк тончыгып та үлгәннәр, тәмам кырылышып беткәннәр, имеш. Бәлки хактыр да. Бу кадәресе дә безгә олы сабак — Җирдә яши белеп яши, эшли белеп эшләмисең икән, димәк, сине дә шул чамасыз олы гәүдәле, әмма ифрат кечкенә миле динозаврлар язмышы көтә. Әмма... беркатлы бу мәхлукларның табылгалап торган баш сөякләренең бөтенесендә дә диярлек бер чама зурлыктагы тишекләр бар икән. Димәк, аларны фәлән миллиард еллар элек кемнәрдер кырып бетергән булып чыга. Тик кем рәхимсез кырган соң аларны шулай? Кешенең җирдә үзе түгел, эзе дә булмаган бит әле ул вакытта. Хәер, без моңа аз гына соңрак әйләнеп кайтырбыз.

Инде, бик йөгерек рәвештә генә булса да, кешелек тарихына күз салыйк. Кеше, җан ияләре арасында, иң соңгылардан булып формалаша. Аның туа башлаган девереннән алып бүгенгәчә булган эшчәнлеге — табигатькә һөҗүм ясау, аның өстеннән хакимлек итәргә омтылу, үзеннән кала барлык җан ияләрен тоташ кыру, аларның яшәеш мохитен чиксез тарайту, чамасыз кысрыклау. Җир шарының җиде дистә еллар «Советлар иле» дип йөртелгән төбәгендә, ягъни безнең илебездә бу бигрәк тә шулай. Күп гасырлар дәвамында яшәеш кануннары булып формалашкан кеше белән кеше, җәмгыять белән кеше, ниһаять, Күкләр белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләр бер кизәнүдә чәлпәрәмә китерелде, гасыр белән гасырларны, буыннар белән буыннарны, рухи үткән белән рухи бүгенгене тоташтырып торган өрфиядәй нечкә җепләр, кабат ялгап булмас дәрәҗәдә, өзгәләп ташланды. Без барыннан да берьюлы — ышану-инануларыбыздан, гасырлар дәвамында йөз тоткан кыйблабыздан ваз кичтек.

Һәм тотындык... Гомер бакый бабаларыбыз иген иккән бәрәкәтле кыр-тугайларыбыз өстенә олы-олы шәһәр-калалар, завод-фабрикалар китереп салдык. Гомер бакый илләребезне, җирләребезне сугарып, тигезлекләрдә тигез генә, тымызык кына агып яткан елгаларыбызны буып, өйләребезгә «Ильич лампалары» керттек. Нәтиҗәдә, миллионнарча гектар мәйданда ходай биргән мул печәнле болыннарны, бәһасез урманнарны, ничәмә-ничә гасырлар буена йөзләрчә буын кешеләргә туган нигез булып хезмәт иткән никадәрле авылларны, хәтта каберлекләрне мәңгелеккә су төбендә калдырдык. Ә «Мәскәү бабай»га һаман җитмәде, ул «давай»лады гына.

Тик ул таләп иткән байлыкны, шулкадәр игенне каян алырга? Билгеле инде, без газиз җиребезне химияләштерергә тотындык. Яшәсен гербицидлар! Яшәсен пестицидлар! «Коммунизм ул — бөтен илне электрлаштыру һәм химияләштерү»,— дидек.

Төрледән-төрле атом станцияләре, эчәр суларыбызны, сулар һаваларыбызны, җыясы ризыкларыбызны агулап, тәнебезне генә түгел, җаныбызны да зәгыйфьләндергәннәр. Җиңел юл белән генә чит ил акчасын алу өчен «юлбашчыларыбыз» ил-йортыбызны тәмам чүплек базына әверелдергәннәр. Без, капитализмны бетерәбез, бөтен Җир шарында социализм гына түгел, коммунизм төзибез, дип йөргәндә, җитәкчеләребез илне упкын читенә китереп бастырганнар.

Татар кызларын ил буенча таратып, аларны урыс туганнарыбызга урыс милләтен ишәйтү ыстаннары иттекме? Иттек! Үзбәк, таҗик хатын-кызларын, бала-чагаларын, мамык басуларында, табан асларыннан алып чәч төпләренә кадәр гербицидларга, пестицидларга манчып чыгардыкмы? Чыгардык. Шулайрак бара торгач, күптән инде тамырың корый башлаганын аңларга зиһенең җитсә, гербицид белән геноцид сүзләренең бер тамырдан икәнлеген дә төшенә башлавың ихтимал.

Ә өстендә күптән инде тере балыклар урынына презервативлар йөзеп йөргән Кабан, Идел, Нократ белән Чулманыбыз язмышлары??? Исемнәрен үзебездән күптән тартып алдылар инде, хәзер әнә җисемнәре дә «төгәлләнү» алдында тора. Әкиятләрдә күлнең төбен күккә аскан батырга ышанмый идек. Ә үзебез әкият каһарманыннан да гаярьрәк булып чыктык — Арал кадәр Арал диңгезен киптердек — күлнең генә түгел, диңгезнең төбен күккә астык! Мондый «каһарманлыкны» бары тик безнең Бөек Октябрь инкыйлабы тудырган кызыл каһарманнар гына башкара аладыр?!

Илләрнең илләрне, халыкларның халыкларны, үз иленең үз халкын, диндәшләрнең үз диндәшләрен чебен кебек кыру очракларын сөйләп тормыйм. Аларына тарихның ерагыннан да, якыныннан да әллә никадәр мисаллар табып була. Бәс, шулай булгач, хөрмәтле укучым, ничек булып чыга инде: кеше ерткычракмы, әллә ерткыч кешелеклерәкме?!

Эшләр алга таба да шушы тизлек белән барганда, минем әлеге «ташлы» төшемне туган төбәгемнең әллә ни ерак булмаган киләчәге дип юрарга тулы нигезем бар.

Безнең Шөгер яклары — нефть төбәге. Биш дистә елдан артык инде аның тамырларыннан, «кара алтын» дигән булып, хәләл канын суыралар, шул канны кудыртып чыгарыр өчен, дистә еллар буена җир куенына кеше сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган химик сыекча кудыралар. Соңгы елларда ул матдәләр эчә торган су катламнарына килеп кушылды, коеларны, чишмәләрне тутырды. Авылларыбыз эчәр сусыз калды. Урманнар, күзгә күренеп, сулып бара. Кыскасы, туган төбәгемнең газиз табигате үлем белән тартыша.

Җир шарындагы тереклек дөньясы яратылган көненнән камиллеккә омтылып яши. Ул, миллиардлаган еллар дәвамында, гомуми камил бер организм хәленә килгән. Кеше эшчәнлеге тигезлекне бозмаска тиеш. Ул бит үзе дә — арада иң камил зат. Үсеш кануннарына буйсынганда, җирдәге теләсә кайсы җан иясе нәкъ менә аңарда — кешедә — үзенең яклаучысын табарга тиеш иде. Кешелектәге кайбер вәхшилекләрне күргәч, минем күңелдә фетнәле бер фикер туа. Гомумән, кеше үзе Җирдә яралган микән соң? Әллә соң ул Җиргә башка тарафтан китереп ташланганмы? Шуңа күрә үзенең яшел бишеген төбе төшкән ләгән хәленә калдырганмы? Мин үзем соңгы елларда шушы фикерләрнең соңгысы ягынарак авыша башладым...

* * *

Бу төш миңа армиядән кайткач керде. Ат башы чамасы булыр, яшерелгән алтыным бар, имеш. Бер иптәшем белән шуны эзләп киттем. Уйлый торгач, яшергән урыны да искә төште — бөдрә нарат агачлары арасында утырган ун-унбиш кенә йортлык авылда иде бу. Шунда башка өйләрдән үзенең зурлыгы белән нык аерылып торган, борыслары инде каралып беткән бик иске бер йорт бар. Боярданмы, алпавыттанмы калган булса кирәк. Яшерелгән алтын шуның чарлагында иде бугай. Әмма йортның түбәсен сүтеп атканнар, идән, түшәме белән коры стеналары гына калган, имеш. Инде кичке эңгер дә төшкән икән, бәләкәй өйләрнең кечкенә тәрәзәләренә ут элененгән, йортның стеналары арасыннан йолкынып чыккан сүсләр җил искән саен шомлы булып селкенеп, чайкалып куялар. Ә без иптәшем белән мәш килеп алтын эзлибез, ашыгабыз, кабаланабыз, актармаган почмагыбыз, тыгылмаган тишегебез калмады. Юк теге хәерсез алтын — алганнар, харап иткәннәр!

Әнә шундый әрнешү тойгыларыннан уянып киттем. Йөрәк, чыннан да, сулкылдап әрни иде. Әрнеми хәле юк — никадәрле хәзинәдән «колак кактым» бит! Һәрхәлдә, уянгач, төшендә хәлвә күреп тә, кашыгы булмау сәбәпле, ашамый калган Хуҗа Насретдин сыман, чын-чынлап шулкадәрле хәзинә югалткандай кайгырып, озак хәсрәтләнеп яттым. Алай гынамы, шушы төштән соң байтак гомерләр күңелем сыкрап, үз-үземә урын табалмый йөрдем мин. Өенендә чып-чын алтынын җуйган кеше генә шушылай борчыла торгандыр. Әмма тора-бара, күңелгә вәсвәсә салган әлеге сары шайтаннан бигрәк, теге бәләкәй авыл җирсеткәнен абайлый башладым. Ышансаң ышан, хөрмәтле укучым, ышанмасаң юк, сумаладай сары горур кәүсәләрен талгын гына җилдә тибрәтеп утырган мәһабәт наратлар, шул наратлар арасындагы эреле-ваклы өйләр, түбәсе сүтелеп ташланган теге дәү йорт сагындыра икән бит. Нәрсәсе беләндер бик якын, бик кадерле иде ул авыл минем күңелгә. Җирдә булмаган, гомердә тормаган да, күрмәгән дә авылны сагынам... Әмма андый авыл Җирдә булмаган, дип, ялгышмыйммы икән соң? Сәер сорау. Әмма анда нәни генә булса да хаклык та юк түгел. Болай диярге тулы нигезем бар. Хикәятемнең бу өлешен тәгәлләгәнче, бер ат башы кадәр генә түгел,

шуның кадәр кимендә ике тапкыр күбрәк алтын югалтканым бар дисәм, ни әйтерсең, укучым! Ә бит югалттым мин аны, тапмас борын, югалттым...

Анысы болай булды. Армия хезмәтенең соңгы айларын Монголиядә үткәрдем дигән идем бит инде. Шул. Мәшһүр Байкал ярларын узып, без география дәресләкләренең тышлыгында күреп күнеккән озын туннельне узып, күпмедер вакыт тагын да югарырак күтәрелгәч, «Гусиное озеро» дигән станциядә эшелонныбыз туктады. Каравыл начальнигы булганга, мин дә үземнең каравыл солдатларым белән офицерлар белән бергә пассажир вагонында бара идем. Ә батальон — «сыер» вагоннарында... Өч-дүрт сәгатьләп торырбыз әле, юыныгыз, ял итегез, үзегезне тәртипкә китерегез, диделәр. Мин исә юл буена, поезд тукталган саен, ике сәгатьтән ике сәгатькә туры килерлек итеп, каравыл алыштыра-алыштыра тәмам алҗыган идем инде. Каравылны алыштырдым да тизрәк йокларга яту җаен карадым. Йоклап кына киткән идем бугай әле, эшелон начальнигы чакыра, диделәр. Эчемнән генә капитанны сүгә-сүгә, кыяфәтемне бераз тәртипкә китердем дә, вагоннан төштем. Капитан 40—45 яшьләр чамасындагы гади бер кеше белән сөйләшеп тора иде. Мине бераз читкәрәк алып китте дә: «Менә бу кеше синең белән танышырга, сөйләшергә тели»,— диде. Мин шикләнә калдым. Хезмәтем хәрби сергә бәйле нәрсәләрдән башланганга, таныш булмаган кешеләр белән элемтәгә керүемнең азагы хәерле бетмәскә мөмкин иде.

— Гафу итегез, иптәш капитан, мин бу кешене белмим,— дидем.

Командир хәйләкәр генә елмайды:

— Син баш тартырга ашыкма,— диде ул.— Агай тәртипле кеше күренә. Татар кешесе. Иң тәүдә мине эзләп килде. Эшелонда татарларның булу-булмавы белән кызыксынды. Бар икәнлеген белгәч, бик куанды. Иң яхшы, иң акыллы татар егете белән таныштыруымны үтенде. Менә без, старшина белән киңәштек тә, сине тәкъдим итәргә булдык...— Капитан тагын елмаеп куйды.— Тик кара аны, кесәл килене кебек җебеп торма — йомышы җитди бугай аның...

Ярый, хуш. Абзый белән танышып киттек. Кызганычыма, туган авылы да, районы да, исем-фамилиясе дә хәтеремдә калмаган. Тамыры белән Татарстан туфрагыннан икән. Әти-әниләре бай нәселдән булганнар, колхозлашу елларында, «кулак» дип, бу төбәкләргә сөргәннәр үзләрен. Абзый үзе исә монда туган. Вакыты булган саен килеп, ике-өч ел буе әлеге станцияне «саклый» икән. Сөйләвенә караганда, сәбәбе җитди: ике кызы җитеп килә икән агайның. Икесе дә яшьләр, чибәрләр, акыллылар. Менә шуларның берсен кияүгә бирер вакыт җиткән. Әмма агайның бер шарты бар икән: кияү саф татар егете, чит-ят җирләрдә яшәп бозылмаган, Татарстан җиреннән булырга тиеш...

Баштарак, йорт-җирем таза, байлыгым аллага шөкер, сине дә, гаиләңне дә асрарга җитәр, аллаһе боерса, дип кенә башласа да, тора-бара ул мине тәмам үз итә башлады — ачыклыгым, беркатлылыгым белән күңеленә хуш килдем бугай.

— Йөргән кызым бар шул, абый,— дим. (И. белән һаман да хат алышабыз, аралар өзелеп җитмәгән иде бит әле.)

— Ә син, минем кызларның егетләре юк, дип уйлыйсыңмы?

— Университет бетерәсем дә бар. Укый башлаган идем...

Агай, мине култыклап, ераккарак алып китте дә, ярым пышылдауга күчте:

— Беләсеңме, Җәүдәт дус,— диде ул, вата-җимерә булса да татарча сөйләшергә тырышып.— Тикмәгә генә җүнле татар егете эзләмимбит мин. Алтыным күп минем. Балаларымның икесе дә — кызлар. Вәт кайда мәсьәлә. Монда ир-ат башы, ир-ат акылы белән ир-ат кулы кирәк.

Аптыравым йөземә чыкты бугай. Агай, урман кисүдә эшләп, сөялләнеп беткән кытыршы кулларын минем иңемә салды да күзләремә туры карады:

— Син шикләнмә! — диде ул. — Эш житди. Иң мөһиме, син минем күңелемә хуш килдең. Кияү чыга синнән! Укуына төкер! Дураклар укысын! Урнаштыра белеп урнаштырсаң, энә белән кое казымый да аллага шөкрана кылып гомер кичерерсең. Жиде ай гына хезмәт итәсең калган ич инде. Кайтышлый кереп, кунак булып китәрсең. Кызларны күрерсең. Танышырсың. Өеңә кайтып, рөхсәт сорап килерсең дә — вәссәлам! Туй — бездән, алтын белән кызларның берсе — синеке! Теге еллар булса, ике дә уйлап тормастан, алтынын да, кызын да бирьюлы бирер идем. Әмма өйләнми торып, алтынны күрсәтмим. Өйләнгәч, бер чиләк белән күмелгәне — тулаем синеке. Әле икенче чиләге дә бар. Анысын ир балаларыгыз тугач, үзем үләр алдыннан күрсәтермен. Кыздан балаларны, унга тулганчы, әмма кимендә ике малай туганчы таптырасың...

Абзый миңа адресын, үзенең һәм кызларының исемнәрен язып бирде.

— Кызлар татарча белмиләр, өйләнгәч, өйрәтерсең. Жайлап-майлапмы, чыбыркы beләнме — анысы синең эш, ул кадәресенә катнашмам, — дип тә өстәде.

Эшелон кузгалыр вакыт житте. Без агай белән кул бирешеп аерылыштык. Дөресен әйтим, тынычлыгымны алды бит бу очрашу. Гомере буе башы авыл хәерчелегеннән чыкмаган минем кебек бер жебеккә сайлап алырга берьюлы ике япь-яшь кыз, ике чиләк алтын тәкъдим итсеннәр әле!..

Һәм «дембель»нең соңгы көннәренә кадәр агайның адресын сакладым. Кызык өчен генә булса да өйләренә сугылып чыгарга да исәп юк түгел иде. Әмма минем тормыш болай да тоташ мәрәкәләрдән генә торганлыктан (минем кебекләрне урыста «невезучий» диләр), кайтыр көннәр житкәч, теге кәгазьне ертып, кисәкләрен монгол жилләренә очырдым. Бәласеннән баш-аяк! Йә уеннан уймак чыгарырмын. Нишләрмен инде ул кадәр алтын белән, йә? Безнең илдә бит аны дәүләт шырыйшырый тартып алачак, ә үзеңне һәйбәтләп ташкапчыкка илтеп салачак. Аллам сакласын!

Абзый алдында бераз гына уңайсыз инде, әлбәттә. Бүтән кеше белән бу хакта сөйләшмәячәген әйтеп калган иде бит. Ялганчы булуы күңелсез. Әмма ул агай күп нәрсә югалтмады дип уйлыйм мин. Миннән әле бәлки бик тырышканда ярыйсы гына бер кияү чыккан да булыр иде. Әмма шул кадәрле алтынга ия булу...

Нинди алтын-көмеш? Гомумән, кеше рәвешендә яши беләбезме соң без? Бу төшенчәләрне баш миебездән күптән нәжесле себерке белән себереп түктеләр бит инде. Бай тормыш — яманлык, ярлы-тигез тормыш — яшәешебезнең асыл мәгънәсе, дип өйрәттеләр бит. Затлы хәерчеләр заманында төп идеалыбыз шул иде ич безнең. Ә монда — берьюлы ике чиләк алтын! Өстәвенә хатын! Ул чорда кеше башына моннан да олырак бәлане уйлап та чыгара алмас идең әле...

Инде мин төшемдә теге ат башы кадәр алтынны эзләгән авылга кайтыйк. Ул авылның хәтеремә ни өчендер бик якын булып кереп калганлыгы хакында әйткән идем. Төшемә кергән шул көннән бирле ул авылны мин сагынып яши башладым. Моның мәгънәсезлек, кимендә, акылсызлык икәнлеген аңласам да, барыбер сагынып торам...

Икенче курска укырга килгәч, сентябрьнең уннары тирәсендә безне колхозга, бәрәңгегә җибәрделәр. Балтач районына. Арчаны узып күпмедер чакрымнар киткәч, юлның уң ягында... валлаһи әгәр, теге, минем төшемә кергән авыл янынnan узып барабыз лабаса! Йортлары да инде яңа, агачлары янына таштан салынганнары да бар. Теге олы йорт кына юк. Аның урынында таш клубмы, кибетме кукыраеп утыра. Ничек кенә булмасын, урыны да, авылы да — шул! Моны күңелемнән килгән ниндидер бер аваз раслый, иләсләндерә, дулкынландыра. Тулы тизлектә барган машина әрҗәсеннән төшеп каласы, шул нарат лар арасындагы серле авылга кереп, кешеләре белән танышасы, сорашасы-белешәсе килә.

Авылның исеме ничек? Монда чыннан да берәр алпавыт яисә дворян утары булмаганмы? Булса, йорты нинди булган? Яшерелгән алтын турында нинди дә булса риваять ишеткәннәре юкмы?.. Колхоздан кайтканда да башымда бер үк уйлар чуалды. Шулай да, бер тапкыр да килеп күрмәгән, урамнарында йөрмәгән килеш әнә шулай ап-ачык булып төшкә керүе сәер, бик сәер иде... Радио журналисты булып эшли башлагач та ул авыл янынннан берничә тапкыр узып китәргә туры килгәне бар. Әмма аның турында төпченергә кыймадым. Алтын-фәлән турында сорашып утырган арада, берәрсен «органнардан» чакырып китерсәләр, кая барырсың?! Исбатлап кара син аларга күргән төшеңне генә тикшереп, балачагаланып йөрүеңне. Еллары шундый иде.

Моннан соң ике дистәләп ел узды инде. Бу төшемне мин байтак кешегә сөйләп көлдердем. Әмма яшь язучы Аяз Хәсәнов, моны үзенең бер әсәренә кертәсен әйтеп, кисәтеп куйды. Ризалаштым. Ул чакларда күргән төшләрем мине шушы кадәр «эзәрлекләр», үземне дә кулга каләм алырга мәҗбүр итәр дип, уйга да килгәне юк иде...

Ә теге авыл, чыннан да, Арча районына керә, аны «Лесхоз» дип йөртәләр икән. Бу кадәресен миңа язмаларымның әлеге өлеше «Татарстан яшьләре» газитендә чыккач, шул төбәкләрдә туып-үскән бер ханым әйтте.

* * *

Монысы, бәян итү тәртибе белән санап барсак, төшләремнең б и ш е н ч е төркеменә кергәндер.

А л т ы н ч ы с ы — кайчандыр бергә уйнап үскән, укыган, солдатта хезмәт иткән, эшләгән, очрашкан кешеләргә бәйле. Шунысы кызык, мәктәп елларым төшләремә керми диярлек. Күрәсең, алары — табигый тормышта яшәгән, тормышны ничек бар — шулай кабул иткән елларым булгандыр. Ә менә армия хезмәте, университетта укыганнарым хәзер дә төшләремә кереп тинтерәтә. Әйтик, имтихан көнем җиткән, билет алынган, укытучым каршымда җавап көтеп утыра — ә башымда җилләр уйный. Белмим генә бит сорауга җавапны. Аннан соң уянам да үз наданлыгымнан үзем оялып ятам.

Мондый төшләр миңа, гадәттә, оялап керәләр. Студентлар икән — студентлар гына. Андый чакларда без бөтен группабыз белән җыелабыз. Арабызда ятлар булмый. Армия хезмәте икән, хәрбиләргә нәрсә фарыз, барысы да шулар: кием-салымы да, тиешле коралы вә техникасы, командирлары... Чирек гасыр гомер узган бит инде югыйсә, егетләрем төшкә нәкъ элеккечә керәләр... дияр идем, юк, алай ук түгел икән. Олыгайганнар, хәрәкәтләре салмакланган, күз, маңгай тирәләрендә инде җыерчыклар төсмерләнеп килә, чәчләре чалара төшкән. Сөйләшүләребез, аралашуларыбыз исә — нәкъ элеккечә. Өнемдә кайсын гына очратырга туры килсә дә, Татарстаннанмы ул, әллә илнең башка төбәкләреннәнме — бер күз салудан ук танып алырмын үзләрен, исем-фамилияләре белән эндәшермен сыман тоела. Һәм мондый очракларга юлыкканда, асылда ул шулай була да. Солдат боткасын бергә ашаган хезмәттәшләремне мәңге онытасым юк. Тату яшәдек, дус булдык, бер-беребезне җәберләү дигән нәрсәне белмәдек. Ә менә егетләрнең, еллар узган саен, тормыштагыча олыгаеп, олпатланып төшкә керүләре... Монысы инде, мөгаен, гади төш кенә түгелдер. Хәер, төш үзе дә гади бер күренеш кенәме соң?..

Театр дөньясы минем өчен беркайчан да чит дөнья булмады. Әле без малай чакта ук клубта теге мин телгә алган Мөнир абзыйлар ел саен «Галиябану» спектаклен куялар. Мөнир абзый — ул чакларда озын буйлы, мәһабәт гәүдәле ир-егет — Исмәгыйль булып уйный... Шәп уйныйлар иде, шайтан алгыры!

Елга бер мәртәбә, гадәттә, кыш көннәрендә авылга Казан курчак театры килеп китә. Бөтен авылыбыз белән, олысы-кечесе, яше-карты зарыгып көтеп ала идек без бу театрны. Фуат Таһиров, Галия Таһирова, Сәләх Хөсни кебек атаклы артист вә артисткалар килеп, «Аккош белән өмет», «Камырбатыр», «Кисекбаш» кебек спектакльләр күрсәтә. Карап торышка, гап-гади курчакның сәгатьләр буена теп-тере кешеләр кебек яшәүләре-сөйләшүләре, талашу-ызгышулары, сугышу-орышулары, ярашу-сөешүләре мине танга калдыра, тәмам сихерли иде. Казан кадәр Казаннан килгән Фуат Таһиров кебек танылган артистның көндезге белән кичке спектакльләр арасында безнең өйгә килеп, минем сугышта гарипләнеп кайткан, гомере буена авылыбыз халкына пыяла кую, ипи калайлары, чүмеч-комганнар, соскылар, самавыр торбалары ясау, аяк киемнәре тегү белән шөгыльләнгән әтиемнән ботинкаларын, башмакларын төзәттереп йөрүе генә мине ихласымнан суыта иде. Артист кадәр артист гап-гади бер авыл агаена аяк киеме төзәттерергә килсен инде?! Аннан соң бу гаҗәпләнү горурлык хисе белән алмашына — менә нинди кеше икән бит минем әти! Ботинкасын кулына алгач, Фуат абыйның куанычы эченә сыймый. «Ну булдырасың да соң үзең, Харис! Яңасыннан да шәбрәк булган ич бу!» — ди. Шушы очрашулар, шушы сөйләшүләрнең тәэсире икенче кышка кадәр суына башларга да өлгермиләр әле... Үзем дә курчаклар ясыйм, сәхнәнең бизәлешен эшлим, пьесасын үзем язып, сеңелләремә спектакльләрен дә үзем куям. Иң төп рольләрне — Фуат абый башкара алырдайларын гына үзем уйныйм, әлбәттә.

Казанга килгәч, иң беренче караган спектаклем Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Шаулыйлар дулкыннар» спектакле булды. Анда мин төп рольләрнең берсен башкарган Ирек Баһманов уенына гашыйк булып кайттым. Өлкәннәрдән Гали Надрюков, Әнвәр Гобәйдуллин... Алардан бераз яшьрәк Шәүкәт Биктимеров. Ир уртасы артистлар Ринат Таҗетдинов, Әзһәр Шакиров... Равил Шәрәфиев — үзе бер дөнья. Алар катнашындагы һәр спектакль хәтергә сеңеп, башкарган каһарманнары алга таба да минем күңелдә яшәүләрен дәвам итәләр иде. Өстәвенә, Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә озак еллар эшләвем сәбәпле дә барлык артист вә артисткаларыбыз белән якыннан аралашып яшәдем. Менә шуларның шаукымы булгандыр инде, мин төшемдә еш кына алар катнашында шәп спектакльләр күрәм. Аларның берсе дә театр репертуарында юк. Ниндидер башка пьесалар анда, җыр-музыкасы да бүтән. Бер аеруча нык хәтердә калганын гына искә алып үтим. Тамаша Академия театрының элеккеге бинасында бара, имеш. Режиссер тамаша барышын бөтенләй яңача, көтелмәгәнчә хәл иткән. Артистларның бер өлеше — сәхнәдә, икенчеләре — сәхнә алдына да, тамашачылар арасына да чыккан. Спектакль күтәренке рухта бара. Сүзләре берсеннән-берсе йомры — монысы Равил Шәрәфи юморы. Музыка, чыр-чу, шау-шу... Рәис Сафиуллин сузып-сузып баянда уйный, Флера Хәмитова белән Наил Әюпов өздереп-өздереп җырлыйлар. Кыскасы, чын тамаша!

Уянганда байтак кына сүзләре дә хәтеремдә иде әле. Шушы тамаша нигезендә пьеса язу уе да юк түгел иде. Юк, туган, булмый икән. Төштә яраган — монда «батып» бетми икән. Ә спектакле шәп иде, корт чаккыры! Күптән шушылай рәхәтләнеп, онытылып, соңгы күренешенә кадәр бирелеп спектакль караганым юк иде...

Күптән түгел шулар җөмләсеннән тагын бер төш керде. Тамаша сугыш елларының бер кышында бара, имеш. Урамда буран дулый, җил елый. Менә агач коммуналканың коридор ишегеннән бер төркем ир-егетләр белән хатын-кызлар килеп керде. Барысы да киез итек, сырган чалбар, телогрейка йә соры шинель, солдат бүреге кигән. Хатын-кызларда да шул ук өс-баш. Кайберләре генә чалбар урынына — юбка, бүрек урынына мамык шәл бөркәнгән. Бу төркем ниндидер бәйрәмнән кайтып килә иде булса кирәк — күңелләре күтәренке, йөзләре көләч. Шау-гөр

киләләр. Хатын-кызлар ирләргә дәрте бөркелеп-сирпелеп торган мут караш белән багалар, юктан да кызык табып чыркылдашалар. Һәркайсы үз парының беләгенә чытырдап ябышкан — мондый ябык елларда шушындый асыл кошлар гел эләгеп тормыйлардыр шул. Әнә бит, берсенең авызында (Әзһәр Шакиров) хәтта «Казбек» папиросы... Ишекләрне узган саен төркем, сизелми генә, сирәгәя бара, бик табигый рәвештә, пар-пар үз бүлмәләренә кереп, гаип булалар. Ә бүлмәләрдә тамашаның ни рәвешле дәвам итәсен тамашачы болай да аңлап, күзаллап утыра, имеш. Төркем артыннан ялгыз бер ир дә кергән икән әле. Ямьшәеп, яньчелеп беткән бүреген салып кулына тоткан, чәчләре тузгыган, өч-дүрт көн кырылмаган төкләре, салкында үрә басып, керпе энәләре сыман төрлесе төрле якка тырпаешкан, шинеленең чабулары җилбәгәй җибәрелгән. Муеныннан салынып төшкән озын соры шарфының чуклары идәнгә тияр-тимәс сөйрәлә. Барлык төс-кыяфәтеннән Геройның (аны без шулай дип атыйк) нидәндер ифрат әсәрләнгәнлеге, ярсыганлыгы, чыгырдан чыкканлыгы күренеп тора. Кая барыр, кайсы бүлмәгә бәреп керер? Кем янына килгән ул? Әллә инде берәрсе яныннан кайтып килешеме?

Әйе шул, кайтып килеше икән. Башка бөтенләй кайтмаска дип кайтып килеше. Хатыны (мәгълүм артисткабыз, имеш) аны куркынып каршылады. Ул әнә тораташтай катып калган. Аның да өстендә — телогрейка. Бөдрәләнеп торган кара чәчләре иңнәренә таралып төшкән. Ир дулый, ә ханым сүзсез. Күзләрендә — чарасызлык. Әмма ире барып йөри торган «сөйрәлчек себерке»дән үзенең өстенрәк икәнлеген дәлилләмәкче. Һәм ул ашыга-ашыга телогрейкасының төймәләрен ычкындыра башлый. Үз ире каршында булса да, моны эшләү — горур хатын өчен хурлыклы адым, күрәсең. Бармаклары дерелди, каны качкан иреннәре сизелер-сизелмәс кенә калтыраналар. Хатын, өстендәге шактый озын телогрейканы салып ташлап, күлмәктән генә калыйм дисә, аның астында тагын бер кат телогрейка бар икән ләбаса!..

Инде хәзер ир дә хәрәкәтсез калган. Хәзер ул чын мәгънәсендә тантана итә — йөзендә салкын горурлык, иреннәрендә — мыскыллы елмаю. «Йә-йә, карап карыйк, кая кадәр барып чыгарсың икән?» — янәсе. Ә хатынның барып чыгар урыны калмаган инде, иң соңгы «коралын» кулланып булса да, аңа ирен сакларга, кабат фронтка китәр алдыннан гына булса да, «себерке»сенә янә җибәрмәскә!.. Телогрейканың монысыннан да тизрәк арынып, инде күлмәкчән генә калыйм дисә, эчтән тагын бер кечкенә, тәненә бөтенләй сыланып торган телогрейка килеп чыкты!

Тәкәббер ир исә әле хатынының ушларны алырлык йомры тезләренә, матур ботларына, әле төймәләре чишелми азаплаган лифчиксыман телогрейкага карап ала да, ныклы бер карарга килеп, ишеккә юнәлә. Хатын илереп, үрсәләнеп аның артыннан ташлана. Әмма — юкка... Бар көч белән тибелгән ишек шыгырдап ачыла да, гөрселдәп кире ябыла. Хәле киткән хатын, егылып китмәс өчен, ишек яңагына сөялә...

Миңа калса, шактый ук төзек сюжетлы, алай гына да түгел, шактый мәгънәле төш, шулай түгелме?

* * *

Күрә торган төшләремнең җидencче төре — мине куркыта да, пошаманга да сала. Болары якты дөньядан киткән кешеләргә бәйле. Чөнки балачактан ишетеп беләм: вафат кешенең төшкә керүе яхшыга түгел, аларга эндәшү, сөйләшү бөтенләй начар. Мин исә алар белән сөйләшәм, «аралашам». Үлгән кеше белән кул биреп күрешү юньлегә түгел, диләр. Миңа кул биреп күрешергә дә туры килгәне бар.

Вафат кешеләрдән төшемә керүчеләрнең иң беренчесе, әгәр хәтерем ялгышмаса, әниемнең әтисе — Муллахмәт бабам. Мин аны бары тик ифрат акыллы, эшчән, зирәк карт буларак кына беләм. Туганнарымның

бирсен дә аны яраткан кадәр яратмаганмындыр. Шул бабам, ни өчендер, төшемә мине ачуланып керде. Хәтта жикеренде дә әле! Алай гына булса бер хәер, үз янынннан этеп тә җибәрде хәтта. Йөрәгем урыныннан кубып уяндым. Вафатыннан соң байтак еллар узгач, мин инде ир уртасы яшьләренә җиткәч, керде бу төш. Аның рухына ярамаслык гамәл кылганым юк иде шикелле. Нидер булган, димәк. Ни беләндер рухын ачуландырганмын... Хәер, ачуланса да урыны бар икән, моннан дистә еллар элек, аның зиратына баргач, гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташында туган елы булса да, вафат елы күрсәтелмәгән иде. Шунда ук чокып язармын дигән идем дә, вафатының төгәл көнен белмим икән... Калган эшкә кар ява, диләр. Бурычым үтәлмәде. Бабамның төшемә усалланып керүен аңлыйм.

Исәннәр арасында да, вафатлар арасында да төшләремә иң күп кергәне — күршем, сабакташым һәм балачак дустым, әлеге дә баягы, Мөнир абзый улы Сәгыйть. Ул, кечкенәдән, һич тиктормас, ифрат шук булды. Тәпәләшә башласак, Сәгыйть, әлбәттә инде, мине акыртып елата торган иде. Мондый чакларда әниләребез арасында да низаг чыга, ул әрләшүләр кайчакларда атналар, айлар буена сузыла, без исә икенче көнне үк аңлашкан булабыз, дуслашабыз... Шушы күршем, урта мәктәпне бетергәч, байтак еллар Урта Азия якларында йөрде. Хат-хәбәре булмады. Суга чумгандай юкка чыкты да куйды күршем. Ун еллап гомер узгач, сабакташым тагын туган якларга кайтып төште. Олыгайган. Житдиләнгән. Йөзендә, гәүдәсендә, аяк-кулларында уем-уем яра жөйләре аның югалып тору серенә яшерен кинаядер сыман. Саф татарча, әдәби телдә сөйләшә. Безнең телгә «ябышкан» урыс сүзләрен һич кабул итә алмый. Ифрат уңган. Искиткеч эшчән. Башлаган эшен жиренә җиткерми тукмамас. Менә шушы күршем басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек яшь-яшь ир-егет чагында, фаҗигале үлемгә дучар булды. Бу олы кайгыны Сәгыйтьнең туганнары гына түгел, без дә бик авыр кичердек. Вафатыннан соң, төшләремә кереп, эзәрлекли башлады мине Сәгыйть. «Эзәрлекли» дигән сүз, бәлки, урынлы да түгелдер. Аптыраганнан әйтәм инде. Ул, гадәттә, миңа төшләремдә туган авылым белән бергә керә. Йә янымда, йә алдыма килеп баса, йә бераз читтәнрәк, ерактанрак күзәтеп тора. Сүз катмый, артыгын хәрәкәтләнми, әмма аның әз генә астанрак сөзеп караган үткен күз карашын башка берәүнеке белән дә бутый алмыйсың инде. Ул караш — бары тик Сәгыйтьнеке генә. Аптырагач, аның исеменә махсус атап хәерләр дә биреп карадым. Әмма аның мине «эзәрлекләве» дәвам итә...

Нәрсә бу? Балачакны сагынумы? Дусны юксынумы? Әллә инде дустымның яшьли өзелгән гомере өчен үкенеч тойгысымы? Әллә барысы бергәме? Миңа калса, тегесе дә, бусы да. Әмма болар гына түгел. Моның сәбәбе (монысы инде минем соңгы вакытларда инанып яшәгән фаразым) ераккарак, тирәндәрәк, безнең малайлык елларына ук барып тоташа. Сәгыйть аны үзе бәлки онытkан да булгандыр. Ә менә хәтере, рухы онытмаган, гафу итмәгән, күрәсең...

Дүртенчеме, бишенчеме классларда укып йөргән чагыбыз иде. Карлар киткән, жир кипкән. Мәктәптән кайттык та, инде тагын нинди яңа уен табарга икән, дип, каңгырып йөргәндә, бездән бер сыйныф югары укучы Риф тәкъдим ясады. Алар, физика дәресендә үткәннәр: газлар, суытканда — кысыла, жылытканда киңәя, ә инде ябык савытта жылытылса, газ дигәнең, бомба кебек, шартларга да мөмкин, икән. Без бу хәлне шунда ук сынап карарга булдык. Буш консерв банкасы табып алдык. Мин әнинең бездән ераграк яшерергә тырышкан бер шешә керосинын күтәреп чыктым. Барысы да табылды, димәк. Ягулыкка ут төртәсе дә савытны, һава чыкмаслык итеп, томалыйсы гына калды. Иң шәп тәкъдимне Риф кертте: «калын кәгазь белән каплыйбыз да шартлатабыз килкидән бушаган калай савытны!..» Шартлау чыкса, үзебезгә дә зыян тию турында уйлаган да юк... Башлаган эш — беткән эш. Әй, шырпы

алып чыгасы калган икән әле! Мин мич кучкарыннан шырпы алганны сеңел күреп калган икән бит, ташбаш. Җитмәсә, артымнан ияреп чыккан да безнең әвәрә килгәнне карап тора икән. Ут төртү «мәртәбәсе» Рифкә тапшырылды. Бер шырпы сызды бу, икене сызды. Эленми генә бит ут дигәнең. Өченче шырпыны сызган иде Риф, керосин дөрләп яна башлады! Дөрләп янган утны күргәч, өчебез дә өнсез калдык: бөтен тирә-юньдә, келәт башлары, өй түбәләре — барысы да сап-сары салам! Алар яна башласа, өй бүрәнәләре дә «гөлт» кенә итәчәк. Ә урам зур, өйләр бер-берләренә терәлеп үк тора. Янгын чыксамы? Өчебезне берьюлы аякларыбыздан асып, утка гына ыргытачак авыл халкы!

Сеңелем Хәмидә исә, әле бәләкәй генә булса да, бездән акыллырак икән — безнең ут белән шаяруны күрүгә, чәйнек белән су күтәреп чыккан. Ялкынны шул су белән сүндермәкче.

«Ш-шарт! — һ-һайт, анагызны! — Ш-шарт!»

Консерв калаебыз шартлады, дип, күтләребезгә утыра язсак, күршебез Фатыйх абзый икән. Төшке ашка кайткан җиреннән, кулындагы чыбыркысын да куярга онытып, безнең ишек алдына йөгереп кергән. Кайсыбыз кайсы якка чыгып сызганбыздыр да, инде саламнарга үрләп барган ялкынны Фатыйх абзый берүзе ничек сүндерә алгандыр — анысын белмим дә, хәтерләмим дә. Әмма әни эштән кайткач... чын мәхшәр башланды. Өлкәннәр, кайсыбызны кайдан табып, өчебезне дә безнең ишегалдына китереп бастырдылар. Китте кычкырыш, китте сорау алу: бу уенны беренче булып кем уйлап тапкан? Шырпы белән керосинны кем алып чыккан? Кем ут төрткән? Без Риф белән сүз берләштек тә төп бәлане бер бичара Сәгыйть өстенә өеп калдырдык...

Мин хәзер дә бу вакыйганы тетрәнмичә генә исемә төшерә алмыйм, җәзаланам, үз-үземне битәрлим. Үземне гафу итә алмыйм. Сатлыкҗан булуның иң куркыныч нәрсә икәнлеген мин әнә шул елларда аңлап калдым. Шуннан бирле минем аркада, берәүнең дә кыен хәлдә калганы, җәза алганы юк, дип беләм. Әмма вакытында Сәгыйтьтән гафу үтенергә баштарак җүләр горурлыгым комачаулады, аннан батырлыгым җитмәде, аннары... өлгерми калдым — аяусыз фаҗига аны безнең арадан мәңгелеккә алып китте.

Әйе, үз-үзеңнән берничек тә котылу юк икән ул. Еш кына теге дөньядан кайтып, сабакташым, күршем вә дустым Сәгыйть мине генә түгел, сине дә, кадерле укучым, әнә шул хакта кисәтә шикелле...

Вакытсыз дөнья куйган тагын бер сабакташым бар. Анысы — Хәмит. Аның да үлеме фаҗигале. Менә шул Хәмит, вафатыннан соң, берничә мәртәбә керде төшемә. Икесендә дә сөйләшмәдек. Өченчесендә ат җиккән килеш керде бу. Йорты Лениногорскиның Подлесный поселогында, элеккеге иске йортлар урынында, имеш. Йорты ялт, абзар-кура тирәсе гөлт иткән. Монысы да аның холкына бик туры килә — акчаны күп эшләргә, бай яшәргә ярата иде Хәмит. Ишек алдында атын туарды да, мине чәй эчеп чыгарга кыстапмы-кыстый! Инде, ризалашып, ишек төпләренә җиткәч кенә, теге башка чакларда да тизрәк уянырга куша торган «күзәнәк» телгә килде — моның төш, минем өчен куркыныч төш икәнлеген кисәтте. Йорт эченә ияреп керсәм, аннан чыкмый калу ихтималым бар иде, күрәсең...

Вафат кешеләр төшкә керсәләр, сөйләшми генә керә, диләр. Ә Хәмит сөйләште. Нәкъ тере чактагы кебек. Йөз чалымнары, хәрәкәтләре, кыланмышлары әле дә күз алдымда тора. Ялына-ялына йорт эченә чакырулары һаман да колакларымнан китми...

Тәлгат абый — әниемнең энесе, ягъни туганнан туган абыем, — шулай ук фаҗигале дөнья куйган туганнарымнан берсе. Иң яраткан абыем иде ул. Әле җиденче-сигезенче классларда укыган елларымда ук ул мине, киная белән инде, билгеле, мәхәббәт, гыйшык-гашрәт турында түгел, ул чактагы «бөек Юлбашчы Никита Хрущев, игеннәр патшасы кукуруз» турында язарга өнди иде. Мин исә, киресенчә, сәясәткә тыгылмам,

язганнарымда җитәкчеләрнең исемен телгә алмам, дигән идем. Булмады. Татарстан мөстәкыйльлеге өчен көчле дау барган бу көннәрдә миңа да вакыты-вакыты белән сәясәт дөньясына кергәләргә, матбугатта үз фикеремне, җитәкчеләребез турында үз сүземне әйтергә туры килде.

Абыйны, солдаттан кайткач, «ялт» итеп торган солдат киемендә, елмая-елмая, бәлеш ашап утырган хәлендә нык истә калдырганмын. (Без авылда, абый бабайларда, Писмәндә (Лениногорск) яши иде.) Вафатыннан соң ул минем төшемә бер генә мәртәбә, әмма бик үтемле итеп керде...

Безнең Сугышлы авылында туганнан туган апамнарның тагын берсе яши. Менә шуларның өйалларында, чормада кемдер йөри, нәрсәдер эзли, имеш. Менеп карасам, Тәлгат абыем икән. Өстендә — балачактан ук хәтеремә сеңеп калган солдат кителе. Танкист эмблемасы да ялтырап тора. Бәләкәй генә өстәлдә — ашалып бетмәгән ризыгы. Абыем... йа хода, үз-үзенә кул салырга йөри, имеш. Минс күргәч, гадәтенчә, елмаеп, килеп күреште. Кочаклаштык. Каты тәнен аермачык тойдым. Мин үсмер егет чакта, шәһәргә әдәби утырышларга килүемнең берсендә, без аның белән шаярып кына көрәшеп караган идек. Ул чакта мин абыемның тыгыз, язылa-нитә калса, идәнгә генә түгел, тәрәзә аша ук тотып томырырлык көчен-тәнен тойдым. Төшемдә исә бу ныклык тере тән катылыгыннан аерылып та тора иде.

— Нишләргә уйлыйсың болай, абыем? Бу аркан сиңа нигә кирәкте? — дим, төшемдә.

Абыем елмая: «Муеныма күптән сала идем инде мин бу элмәкне, иркәм, бавы гына табылмады», — ди.

Абыем нефть коеларының берсендә, җир асты ремонты вакытында, агуланып үлде. Бу төш исә болай да әйләнгән башны вәсвәсәгә салды. Димәк, скважинада фаҗига чыкмаса, башка төрлесенең дә ихтималы калган? Димәк, абыемның тормышы, ничек кенә матур күренмәсен, билгеле бер вакыты җиткәч, барыбер фаҗигале төстә өзелергә тиеш булган? Һәрхәлдә, аның төшемә кереп әйткән сүзләреннән әнә шундыйрак мәгънә сизелә...

Авылда бездән берничә йорт аша гына үзенең кызы һәм кияве белән Хәлимә әби яши иде. Әтиемнең чыбык очы туганы ул. Минс бик ярата иде. Урманга-фәләнгә, җиләккә-мазарга миннән башка чыкмас, миңа дәшмичә китмәс иде. Бик картаеп, сиксән яшьләрендә генә калдырды бу фани дөньяны. Ул да минем төшемә кергәләде. Әмма моңарчы беркайчан да куркуга салмады. Тик соңгы төшләрнең берсендә әбием минс чын-чынлап хафага төшерде. Үзләренең бакча урталарында, бакчаны буеннан-буена икегә бүлеп аккан Салкын чишмә янында басып тора, имеш. Мин югарыдарак, ул түбәндәрәк торып сөйләшәбез икән. Әбиемнең яшь вакыты — бит алмалары алсулыгын җуярга да өлгермәгән. Бераз уңайсызланып, бераз кызганган да сыман итеп:

— Ипиләреңнең берсен бирерсең инде, Җәүдәт улым, — ди.

Мин, нидән куркуымны да аңламыйча, өйгә табан йөгереп китмәкче булдым. Язмы, көзме бу — җирнең дымсу, салкын вакыты, мин исә яланаяк, имеш. Тизрәк өйгә кайтып җитәргә талпынам, ә инеш яры бик текә, һич менеп җитәрлек түгел. Ашыгам, кабаланам, аякларымның хәле беткәннән-бетә бара. Җитмәсә, яланаякларым тая да тая. Инде хәлем бетте, инде егылдым дигәндә, яр өстенә менеп җитәм дә, өйләребезне күреп, җиңел сулап куям...

Төш юратыр чарам юк. Яраткан әбиемнең төштә сораган бер ипие һаман күңелемне куркытып, бәгырьне телгәләп тора... Ә куркырга урыным бар иде: әтиемнең дә хәле авыр. Сабайда — әбием хәл эчендә ята... Аллага шөкер, әлегә барыбыз да исән-саулар. Картлар әйтмешли, азагы хәерле булсын...

Мәрхүм шагыйрь Зиннур Насыйбуллин белән без байтак еллар Татарстан радиосында бер бүлмәдә эшләдек. Ифрат тыйнак, зыялы,

чибәр, пөхтә кеше иде ул. Яман чир аны арабыздан бик иртә алып китте. Ул көннәрдә үзем дә кан басымыннан урынга егылган идем, җеназасына да бара алмадым.

Вафатыннан соң озак та үтмәде, төшемә керде ул минем. Үзебезнең радио бинасы коридорыннан барганда, каршыма килеп чыккан, имеш. Гәүдәсен матур, төз тотканга, гадәттәгедән дә озынрак күренә. Яхшы итеп үтүкләнгән аксыл костюм-чалбар кигән, чәчләре тигез итеп таралган, галстугы белән пөхтә күлмәк якалары аның кыяфәтен тәмам бәйрәмчә иткән. Гадәттәге ябык чырае да тулыланып, түгәрәкләнеп киткән. Зәңгәр күзләреннән серле нур балкый. Шагыйрь дустымны, бүлмәдәшемне шушылай очратуыма куанып киттем. «Кайчан кайттың әле син, ни хәлләрең бар?» — дим. Ул дәшми, елмая, күрешергә кулын суза. Мин дә кулымны сузам һәм... баш миемдәге кайсыдыр бер уяу күзәнәгем мине кисәтә: «Син нишлисең? Вафат кешеләр белән сөйләшергә, бигрәк тә, күрешергә ярамаганлыгын син белмисеңмени?» — ди. Беләм, бик беләм! Әмма ничек инде дус кешегә кул бирмисең ди?!. Һәм без аның белән күрешәбез, мин аның нык, көчле кулын тоям. Уянгач, күңелдә тагын икеләнүләр, шикләнүләр, борчылулар. Зиннур исә әле моннан соң да тагын ике мәртәбә төшемә керде.

Берсендә, Васильеводагы бакчабызга, урман буендагы зират яныннан барам, имеш. Зиратның эчке ягына да, тышкы ягына да җиңел машиналар тезелгән? Ачык капканың эчке ягында Зиннур тора, мине үз янына чакыра. Көзге киемнән, яланбаш. «Юк, дустым, гаепләмә инде, бу юлы яныңа керәлмим, үпкәләмә, зинһар!» Башымнан шундый уй йөгереп узды. Тукталып, дустыма «рот-фронт»ча гына төйнәлгән йодрыкны күтәреп сәлам бирдем дә, китү ягына борылдым. Зиннур үпкәләде. Ул, мәрхүм, бик нечкә күңелле кеше иде, шатлыгы да, борчуы да шунда ук йөзенә чыга. Бу юлы да шулай булды...

Өченче тапкырында, университет ашханәсенең комплекслар залы башындагы буфетта очраштык. Тик буфет урынында — Кекин гастрономындагы сымаграк азык-төлек бүлеге урнашкан, имеш. Мин нәрсәдер караштырып йөрим. Теләр-теләмәс кенә витриналар каранып йөргәндә, ниндидер бер тартылыш мине күтәрелеп карарга мәҗбүр итте. Зиннур. Ул да азык-төлек алып йөри. Гадәттәге аксыл-соры костюм-чалбардан, яхшы итеп кырынган. Кәефе күтәренке.

— Кайткан идем әле менә,— ди Зиннурым, елмаеп.— Бераз тәм-том алырга исәп...

Үзе һаман елмая. Елмаюында — уңайсызлану катыш тартыну. Һаман да шул элеккеге тыйнак, оялчан Зиннур булып калган икән шагыйребез...

Ни өчен төшләремнең өчесендә өч төрле керде соң әле Зиннур? Хикмәт нидә? Теге дөньяда да тиз генә кабул итмиләрдер, күрәсең, адәми затны. Ниндидер катлаулы сынаулар узадыр ул. Беренчесен уңышлы үткәндер каләмдәшем. Шуңа шат күренгәндер. Икенчесендә катлаулырак хәлләргә юлыккандыр, Җирдә кылган кайбер гөнаһлары өчен җавап тотарга туры килгәндер, шуңа борчулы булгандыр. Дин әһелләре авызыннан «Каләм иясе — Алла бәндәсе» дип ишеткәнем бар. Шунлыктан шагыйрь җаны, ахыр килеп, Күкләр өчен дә шагыйрь җаны дип кабул ителгәндер; ул анда үзенә чын мәгънәсендә лаек урын алгандыр да, хәзер инде, бик сагынганда Җиргә кайткалап, җыелмый калган ризыкларын барлап йөридер...

Ул елларда радиода безнең белән бергә эшләгән өч кешебез бер-бер артлы дөнья куйды.

Шуларның икенчесе — әдәби-мәдәни тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире Рим Кәримов иде. Инсульттан соң байтак вакытлар авыру хәлендә эшләп йөргән иде, мәрхүм. Театр сәнгате белгече, әдәбиятчы, һәйбәт тавышлы сүз остасы иде ул.

Вафатыннан соң ничә көн узгандыр, төшкә керде. Иртән эшкә килеп ятам, имеш. Колагыма таныш тавыш ишетелмәсенме?! Әйе шул, Рим

абый тавышы! Безнең әдәби-драматик тапшырулар редакциясе бүлмәсеннән. Бездән алда килеп, берәр тапшыру эшли микәнни?

Аякларым үзләреннән-үзләре тәрәзә тарафына тарта (ә безнең тәрәзә радио йортының икенче катында). Үрелеп карасам, өстәл өстендә дә, стена буендагы диван тирәли дә магнитофон тасмалары саклана торган кечкенә тартмалар тезелгән (мондый тартмаларда гадәттә җырлар, фонограммалар була). Диванда исә кулларын баш астына куйган Рим абый ята. Аякларын диван култыксасы өстенә чалыштырып салган. Күзләре ярым йомык. Талгын, моңлы тавыш белән рәхәтләнеп, кинәнеп, сузыпсузып, бормалап-бормалап җырлый үзе. Моңлы көйгә җырласа да, кәефе шәп икәнлеге сизелеп тора. Бу фани дөнья газапларыннан котылу шатлыгы булгандыр инде мәрхүмнең...

Остаз язучыларымнан берсе Шамил Бикчуринның вафатына берничә көн кала күргән төшем хакында да язмыйча кала алмамдыр. Мин ул җитәкләгән әдәби берләшмәдә үстем, балалар язучысы буларак билгеле бер шәкел алуымда аның йогынтысы чиксез зур булды.

Ул заманнарда түгел, бүгенге көннәрнең берсендә җыелганбыз, имеш. Арабызда Җәмит Рәхимов, Альберт Хәсәнов, Мәхмүт Газизов кебек язучылар, Зөфәр Абдуллин кебек журналистлар... Ниндидер сәеррәк бүлмә, сәеррәк мохит. Бүлмә һавасында зәңгәрсулык, күңелдә ниндидер моңсулык. Уртада — Шамил абый белән Кунак. Әлеге төшнең сәерлеге әлеге Кунакка бәйле. Фадеевкамы, Маяковскийгамы охшаган мәһабәт гәүдәле бу кеше безнең арага тавышсыз кино заманнарындагы иске тасмадан килеп төшкән кебек иде. Өстендә карасу җирлеккә сирәк кенә аксыл сызык төшкән костюм-чалбар. Чәчләре чалара башлаган. Безнең арабызда ул үзенең элегрәк заманнардан килүе, зыялылыгы, шул ук вакытта тәненең, җисеменең ничектер табигый булмыйча, эфир сымаграклыгы белән аерылып тора.

Менә шушы кеше саф татар телендә (бәлки заманында Шамил абый аралашкан андый татар әдибе дә булгандыр, мин генә белмимдер) безне әдәбият нечкәлекләренә өйрәтә. Сүз — чәчмә әсәрләр хакында. Без — тирәли баскан. Шамил абый — уртада. Шуннан соң артык озак та тормастан, Шамил абый мәңгелеккә арабыздан китеп барды... Әлеге «Олуг кунак» аны үзе янына алып китте кебек...

* * *

Яшермим, әлегә мин төшләремә бәйле сорауларга тулы җавап таба алганым юк.

Беренче кызым туганнан соң мине еш кына бер-берләренә охшаш шомлы төшләр чылбыры эзәрлекли башлады. Әйткәнемчә, студент елларымда ук гаилә корып җибәргәнлектән, берничә ел дәвамында подвал бүлмәсендә яшәргә туры килде. Шунда еш кына төшемдә кызымны «югалта» башладым. Шул вакытларда күңелне биләгән курку хисен мин аңлата да, берни белән чагыштыра да алмыйм. Бала, һич көтмәгәндә, кулдан ычкынып, әллә кая китеп югала, йә ниндидер бушлыкка, караңгылыкка кереп чума, йә бинаһая биеклектән ычкынырга торганда, мин аны коткара алмыйча тилмерәм... Тора-бара мине баламнан аеручы төп көч вазифасын су, аерым алганда, үзебезнең Сагышлы елгасы «үти» башлады. Асылда тар гына бер инеш инде ул. Төшләремдә исә Сагышлы, диңгез сыман, еракларга җәйрәп ята. Шуны кичеп барганда кызым кулымнан ычкынып китә дә миннән ераклаша башлый. Балам артыннан куып тотмакчы булам — юк, дәрманым, көч-җегәрем җитми. Кычкырмакчы булам — өнем юк. Йөрәк шашып тибә, күңелдә берни белән дә тутырып булмый торган бушлык, әрнеш. Котым алынып уянам да, бәби арбасына үреләм. Аллага шөкер, сабый тирән йокыда.

Үз-үземне бик нык кулга алырга тырышсам да, бу сәер төш шактый еш кабатланып торганлыктан, балам өчен, күңелем борчылып калды.

Хатыным да минем бу төшләремә тәшвишләнә башлады. Кызым җиде яшьләргә җиткәч, әлеге төшләр мине эзәрлекләүдән туктады. Аз-азлап, акрынлап кына булса да, баланың гомере өчен болай баш югалтыр дәрәҗәдә курку хисе кими, сүрелә, онытыла барды.

Тик бу тынычлык озакка түгел икән. Икенче кызым туып (ул чакта олысына ун яшь тулып килә иде инде), өч-дүрт ел да үтмәгәндер, кечесе турындагы шундыйрак төшләр кабатлана башлады. Кечкенә кызым белән мине тимер юл аера, имеш: баланы йә вагонда югалтам, йә икебезнең беребез утырып китә дә, беребез өлгерми кала, йә төрле тарафларга юл тотучы поездларга утырган булып чыгабыз... Әмма берсе фоторәсем шикелле димме, киносурәт сыман димме, һәрхәлдә, онытылмаслык булып хәтергә уелды.

Казаннан Дәрвишләр поселогына чыгып, платформада басып торабыз, имеш. Шулчак күктә, табигыеннан бераз гына сул яктарак, икенче кояш пәйда булды. Күкне тоташ сорылык басты, яңа кояш тарафыннан көчле өермә-давыл купты. Озак еллар дәвамында куркытып яшәткәннәренә күрәдер инде, башымнан иң тәүдә «Атом! Тизрәк яшеренергә кирәк!» — дигән уй чагылып узды. Ул арада капыл чыккан өермә бәләкәчемне кулымнан аерып алырга тырыша, йолкыпмы-йолкый. Ул да түгел, балам кулымнан ычкынды да, өермә ихтыярына бирелеп, каядыр күздән дә югалды. Бар көчемә аның артыннан йөгерәм, йөрәгем кага, сулышым каба... Аллага шөкер, югалмаган икән нарасыем! Әнә, әллә ни ерак та түгел, алма бакчасы. Бакчада — караватка. Хатыным шул караватка яткан да иркәли-иркәли сабыебызны имезә, имеш...

Аннан соң да әле байтак «югалткаладым» кызымны төшләремдә — әле уйнап йөргәндә, әле тауда чаңгы-чана шуганда... Алты-җиде яшьләре тулуга, кечкенәбезгә бәйле куркыныч төшләр инде керми башлады. Шөкер!

Әмма, җентекләргә тотынгач (НЛОлар, оча торган тәлинкәләр, ерак Галәмнән килгән зиһенле затлар хакындагы төрле хәбәрләр, язмалар тулып яткан безнең көннәрдә бигрәк тә), бик акрынлап кына булса да, мин әүвәл күргән төшләремнең тикмәгә түгеллегенә төшенәм кебек...

Ул менә нәрсәдән башланды. Моннан ун-унбиш еллар элек туганнан туган апам белән җизнәм Төмән якларында берничә ел дәвамында «кара алтын» чыгарышып, иң кара эшләрдә эшләп кайтканнан соң, уллары вә кызлары Әнис белән Зөлфия миңа берсеннән-берсе кызыклырак хәлләргә юлыгуларын сөйләделәр. Ул тайгага кереп югалтулар, аларны вертолетлар белән эзләп алулар, могҗиза белән генә исән калулар, шуннан соң тәүдә оршышып, аннан ихлас дусларына әверелгән солдатларның аларга бүләкләр биреп җибәрүләре — барысы да маҗаралы, кыйссаи гаҗәп иде. Мин бу хәлләрне алардан кат-кат сөйләттем, әллә ничә мәртәбә, язарга дип утырганнан соң, әллә ничә мәртәбә, бер генә юл да яза алмыйча, өстәл яныннан торып киттем. Дистә еллап вакыт үтте...

Көннәрнең берендә җиде яше тулган кызым Резеда иртән яныма йөгереп килде дә, күргән төшен сөйләргә тотынды:

— Әтием,— ди бу миңа.— Мин бүген төшемдә балконга чыгып тутуозиклар белән уйнадым! — ди.

«Тутуозиклар» дигән сүз шунда ук минем колагыма эленеп калды. Берәүгә дә таныш сүз түгел бу. Капыл бирелгән сорау белән кызымның зиһенен чуарлатудан куркып, сак кына:

— Кемнәр соң алар — «тутуозиклар»? — дип сорыйм.

Кызым миңа көлемсерәп карады.

— Алармы? Бәләкәй генә, яшел кешеләр, мине балконга чакырып чыгардылар. Алар белән бергәләп уйнадым, аннары тагын кереп яттым...

— Өнеңдәме?

— Төшемдә дим ич. Уйнаганым гел өнемдәге кебек булды...

Ур-ра-а! Эврика! Менә икән бит ул язылачак кыйссам!

Әмма өстәл янына килеп утырдыммы — бетте, башым көлләп чистартылган буш казан шикелле чынлап кына түгел, яңгырап тора, миемдәге

«тәрәзә» ачылмый, илһам юк. Әлеге «эврика!»дан соң ярты елга якын вакыт үтте. Октябрь ае. Мин үзем дә, кызым Резеда да шул айда — Бизмән йолдызлыгы чагында туганбыз. Чираттагы ялымны алып, «Васильево» курортына киттем. Баштан ук килешенеп, бәләкәй генә булса да, аерым бүлмә бирделәр. (Ара якын булганлыктан, шимбә-якшәмбе Казанга, өйгә кайтып йөрим.) Октябрь бәйрәмнәре житкәч, кечкенә кызым — Резедам әйтә миңа:

— Әтием, туйдым инде мин бу хатыннар базарыннан (үз сүзләрем икән монысы, тәүбә, әстәгъфирулла!), үзең белән ял йортына алып бар әле? — ди.

Балалар дигәндә — жаным фида. Алып киттем бәләкәчемне. Килде бу, чишенде. Беренче эш итеп каралама хәлендәге кульязма китабымны алмасынмы! (Гомумән, китапсыман эшләнгән каты тышлы дәфтәрләргә язарга яратам. Эшләгән көннәрнең числосын, башлаган вә тәгәлләгән сәгатен, минутын да теркәп барам...) Дәфтәрнең язылып туктаган өлешен ачты бу, числосын карады, бармакларын бөгә-бөгә нидер санап чыгарды да миңа кинаяле караш ташлады:

— Аһ, әтием, ялганчы икәнсең бит син! Әниемә: «Анда баргач, ун гына көн йокы туйдырам, унберенче көнне яңа повесть яза башлыйм!» — дигән идең. Инде егерме бер көн йоклагансың. Йокыңны туйдыру гына түгел, җимертеп бетергәнсең икән бит. Әйдә, утыр, хәзер үк яза башла! — ди бу. Хак әйтә, егерме бер көн рәттән йоклап та йокым туймаган — «Җиләкле көннәр» повесте белән «Айбулат» әкият-поэмасыннан соң аруым чыгып бетмәгән иде әле. Нихәл итәсең бит, баланың акыллы сүзенә ничек каршы киләсең — утырдым. Һәм... ни хикмәт?! Язылып китте бит, әй! Шома гына язылып китте. Бер утыруда машинкада бишалты бит чамасы яздым. Кызымның да күңеле хуш — үзенекен итте, ялкау әтисен эшкә җикте бит!..

Әмма ялдан кайтып, ун көннәр чамасы вакыт үттеме-юкмы — миңа таныш булмаган ниндидер көч мине шимбә-якшәмбе көннәрендә редакциягә, рәсми эш бүлмәсенә әйди башлады. Сөйрәп дигәндәй урыннан торгыза, үзенчә генә йөртә. Читтән идарә ителә торган робот хәлендәрәк каласың.

Кыш җиттеме, шимбә-якшәмбе көннәрдә минем эшкә китеп югалуларыма өйдәгеләр болай да күнегеп беткән. Бу юлы исә мине «у л»мы, «а л а р»мы мәҗбүр итәләр, дөресрәге, әйдәкилиләр иде. Шуңа күрә хатынга ярым шаярып:

— Мине бүген эшкә чакыралар, барып кайтыйм инде булмаса, — дидем дә, җыенып чыгып киттем.

Эш урыныма килгәч, икеләнә калдым: язарга энә очы каләрле дә теләк юк, өстәл янына якын да барасы килми иде. Кире кайтып китәргә дә ашыкмыйм — редакция эшләрен барлыйм, газета-журналлар караштырам, чәй куеп җибәрәм дә, рәхәтләнеп, җөмһүриятебез радиосы тапшыруларын тыңлыйм. Шул рәвешле көн үтте, эңгер төшә башлады. Шулчак, эңгер белән бергә, башыма капыл гына йокы да иңелеп төшмәсенме! Хет шул мизгелдә идәнгә сузылып ят та тәгәрәп йокыга кит! Бүтән чара калмагач, тезелеп торган урындыклар өстенә аудым. Яту белән йокыга да киткәнмен. Уянсам — төп-төгәл егерме минут вакыт үткән. Салкын су белән юынып килдем дә, бисмилламны әйтеп, эшкә утырдым. Беренче эш итеп, санаторийда язганнарны укып чыктым. Үземә ошады. Менә дигән башлам! Афәрин, Резеда кызым, мине оялтып дөрес эшләгәнсең!.. Менә шулай башым-аягым белән ничек эшкә кереп батканымны үзем дә сизми калганмын. Күпмедер онытылып эшләгәч, кемнеңдер тәрәзә аша үтәли карап торышыннан сискәнеп киткәндәй булдым. Редакциябез бинаның түгызынчы катында лабаса — кем карасын ди сиңа шушы кадәр югарылыктан?! Мин ирексездән борылып тәрәзәдән югарыга «карап», дөресрәге, күз карашын хәтерләтүче нурлар килгән тарафка текәлдем. Әлбәттә инде, анда мин берни дә, бер кемне дә

күрмәдем. Әмма кемнеңдер күзәтеп торганлыгын тою хисе барыбер кимемәде. Һәм мин тагын, ниһаять, үземчә уңышлы гына дәвам иткән кыйссам дөньясына кереп баттым. Гаҗәп, чәчмә әсәрләр язганда элек тә алдан ниндидер план төземичә, аның чишелеш юлларын алдан билгеләмичә генә яза идем. Вакыйгалар ничектер үзләреннән-үзләре туа, күз алдына килеп баса да үз ихтыярына буйсындыра, үз артларыннан ияртеп китә иде. Ә монысында, язарга тотынуга, бөтен вакыйгалар кино экранындагы сыман бер-бер артлы күз алдына килә дә, соңра мине дә үз эченә алып, шул дөньяда яшим, реаль итеп күрәм. Шуларны теркәп барырга зиһенең җитсен дә каләмең генә өлгерсен! Төнге унберләрдә «әйтеп тору» капыл өзелә, зиһеннең башланган җөмләне төгәлләп куярлык та куәсе калмый.

Дөрес, атна арасында эштән калып та, өйдә гаилә йоклап беткәч, аларның мыс-мыс сулыш алган авазларын тыңлап та бераз язылды. Язылмады түгел. Әмма бу кадәресе «ябык тәрәзә» белән, «соры матдә»нең «күкләр» белән багланышыннан башка гына уза иде шикелле.

Ә шимбә белән якшәмбедә бөтенләй башка хәл — өйдән кузгалырга «фәрман» килә, син көндезге ун-унберләрдә ишектән чыгып китәсең, дүрт-биш тукталыш җәяү барып, автобуска утырасың да уникеләргәберләргә эшкә килеп җитәсең. Шуннан соң — радио, чәй, газета-журналлар, егерме-утыз минут йокы... Кичке дүртләрдән алып төнге унберләргә кадәр дөньяңны онытып язу...

Ниндидер көч ярты ел дәвамында үз «әсирлегендә» тотты шулай, ярты ел дәвамында баш күтәрми диярлек җигелеп эшләргә мәҗбүр итте. Һәм һәр кичне (бу тойгы бигрәк тә аяз көннәрдә бик көчле була торган иде) күктән кемнеңдер мине күзәтеп торуын сизә идем. Бигрәк тә эш көнен, дөресрәге, төнен төгәлләп, урамга чыккач бу хис аеруча бер көчәеп ала, мин ирексездән, кемнедерме, нәрсәнедерме күрергә теләп, күккә, серле нурлар иңгән тарафка күтәрелеп карарга мәҗбүр була идем.

Тагын шунысы гаҗәп, «фәрман»ны тыңламаганда, «ул»мы, «алар»мы вак-төяк җәза бирүдән дә тайчанмыйлар икән (вак-төяге булгач, кирәк санаганда җитдие дә булгалый торгандыр, мөгаен). Ул җәза дигәнең чыннан да вак-төяктән гыйбарәт, әмма игътибарлы булып, бер җепкә тезсәң, ни өчен икәнлеген дә тиз аңларга була.

Әйтик, бер шимбәне теге «фәрман» мине эшкә барырга әйдәкли, мин моны бөтен барлыгым белән сизеп торам, ә хатынның никтер җибәрәсе килми — әллә инде кайбер йорт эшләрендә булышасы бар, әллә инде берәр ярамасрак гамәлем белән шикләнергә урын калдырганмын. Шулай беркөнне эшкә бармый калдым. Шуннан соң башланды да инде. Кухня ишегеннән чыгып киләм. Ап-аек, кем әйтмешли, авызга йөз грамм да кергәне юк. Тупсаны узып киттем дигәндә, ниндидер бер хикмәт белән тайчанып китәм дә ишек яңагына килеп бәреләм. Озак та үтми, бер сәбәпсездән ачык ишек кырын маңгай белән «сөзеп» үтәм...

Эшкә җәяү барганда көн саен яныннан узып йөри торган электр баганасына килеп бәреләм. Рәхәтләнеп узып китәрлек бит югыйсә — аршыннан артык ара! Адым саен тез, терсәк ише буыннарның бәрелеп торуын, абыну-сөртенүләрне әйтеп тә тормыйм.

«Җәза»ның иң җитдие шул атна уртасында, сыкылы салкын көннәрнең берсендә «гармунлы» озын автобуста эшкә барганда булды. Салкын һавада бу машина ишекләренең, күгән майлары куеру сәбәпле, бик авырдан ачыла торган гадәтләре бар. Бу юлы да шулай. Тукталышка килеп җиттек, ишек ачылмый гына бит, зыңлап тик тора. Мин перчаткамны салдым да, гадәтемчә, ишекнең урталай бөкләнә торган күгәне турындагы ярыгына уң кулымның күрсәткеч бармагын тыгып тарттым. Ишек күгәне белән өске тимер арасында тагын ике-өч илле булыр ярык бар иде югыйсә. Ишек бик кисәк ачылып китте, мин бармагымны тартып алырга өлгерми калдым. Аның каравы ишек өлгеррәк булып чыкты — бармакның тырнаклы буын тиресе ишек өслегенә «сыланып» калган иде.

Андый яра гадәттә бер атна эчендә төзәлә. Ә бу — айга сузылды, хәерсез. Шуннан соң инде мин, әлеге «Бизмән йолдызлыгы» дигән кыйссамны тәгәлләми торып, шимбә-якшәмбе көннәрне эшкә бармаска базмадым.

Язганнарымның бу кадәресен укыганда ниндидер киная эзләргә ашыкма, укучым. Мин моны ихласымнан язам. Тик барысын да җентекләп, тәфсилләп бирә алмыйм. Бу очракта «Бизмән йолдызлыгы» кыйссасын яңабаштан сөйләп чыгарга туры килер иде чөнки. Әмма әлеге кыйссаны язу дәвамында, үзем дә сизмәстән, мин бернәрсәгә инандым: атеистлар авыз кырыйларыннан күбек чәчә-чәчә инкяр иткән Югары Көч бар ул, бар! Һәм, телибезме-юкмы, ышанабызмы-ышанмыйбызмы — без аңа буйсынулы, һәм без һәрдаим аның игътибар үзәгендә, күз уңында. Һәм без, татар халкы, тарихыбызның кайсыдыр бер борылышында әлеге Югары Көчнең, безнеңчә әйтсәк, Алланың каргышына, ачы каһәренә тап булганбыз. Елмаерга ашыкма, укучым. «Бизмән йолдызлыгы»нда тасвирланган вакыйгаларның күбесен (ышанасыңмы син минем сүзләремә, юкмы — анысы синең иркеңдә) минем зиһенемә Ул салды. Югыйсә, алдан бөтенләй башка әсәр язарга ниятләвемне инде мин сиңа әйткән дә идем. Әсәрне кулдан тәмамлап, машинкада ак кәгазьгә төшергәндә, «Ялкын» журналының 1990 нчы елгы октябрь санында XX йөзнең күренекле рәссамы Н. Рерихның (аның чит галәмнәрдән килгән зирәк затлар белән элемтәдә булуы, шуңа бәйләнешле картиналар язуы да мәгълүм) 1914 елда ясалган «Казанны буйсындыру» дигән картинасыннан күчермә баскан идек. Менә бу көннәрдә, елга якын вакыт узгач, башыма әлеге фикер килгәннән соң мин имәнеп киттем — рәсемдә басып алучыларга, күктә кылыч болгап, Югары Көчләрнең (бәлки Кара Көчләрнеңдер?) булышлык итүе тасвирланган иде. Әлеге картинаны язганда Рерих зиһененә дә бу фикерне бәлки Ул салган булгандыр?!

Һәрхәлдә, без — татар халкы, Алла каршындагы гөнаһларыбызны белгәннәребез гыйбадәтләре, догалары белән, белмәгәннәребез изге эшләре, саф күңелләре, ихластан инанулары, шәхси тырышлыклары белән юарга, аның мәрхәмәтен казанырга, борынгы шанлы асылыбызга кире кайтырга тиешбез. Хәрәкәттә — бәрәкәт дип, белми генә әйтмәгәннәрдер борынгылар. Милләтебез бары тик алга таба хәрәкәтләнеп кенә тәрәккый итәргә мөмкин.

Бераз гына алдарак җиде яшьләре тулганчы төшләремдә баштан кызым Гөлназны, аннан соң Резеданы югалтып изалануым хакында язган вә бу төшләрнең тикмәгә генә түгеллегенә төшенә башлавым турында әйткән идем. Һәм унтугыз яше тулган көннәрдә Гөлназ күргән бер төш, озак еллар билгесезлектә токкан хәл-әхвәлләргә беркадәр ачыклык керткә сыман.

Беркөнне иртән торды да Гөлназ, хыялый гына түгел, нindидер дини дип әйтимме, изге дип әйтимме, бер төш күрүе хакында сөйләде.

— Без синең белән күккә ашканбыз, имеш, әтием,— ди кызым.— Син бәләкәй генә. Нindидер шар эченә утырганбыз да, күктә килеш гаҗәеп манзарага мөкиббән киткәнбез, имеш. Югарыда, безнең белән бер тигезлектә, сигез манаралы мәһабәт мәчет. Хәзерге Кремль өстендә икән ул. Матурлыгын сөйләп кенә аңлатырлык түгел. Алтын айлы манара очларыннан күккә сихри нурлар бөркелә. Ә тирә-юнендәге күк күе миләүшә төсендә. Күңелдә — тел белән аңлатып булмаслык гаҗәеп күтәренкелек, әйтеп бетергесез шатлык... Ә аста, түбәндә, бик кечкенә, кырмыскалар кадәрле генә булып, кара фраклар, цилиндрлар кигән кешеләр йөренә, бөркәүле затлы арбаларга җигелгән мәһабәт пар атлар уза, кайберәүләр, күктәге бу илаһи тамашага карап, хәрәкәтсез калган...

Шушы төшен сөйләгәннән соң ул капыл гына, бер сәбәпсездән болай дип тә өстәп куйды:

— Ә беләсеңме, әтием, бәләкәй чакта төшләремдә мине еш кына нindидер көч эләктереп ала иде дә бөтерчек сыман шундый зур тизлектә

әйләндерә иде, мин, авырлыгымны югалтып, каядыр аска, түбәнгә атыла идем. Шундый курка идем!..

— Нишләп аны элегрәк бер дә сөйләмәдең соң, кызым?

— Күргән бөтен төшне дә сөйләп тормыйлар бит инде...

Менә шул чакта минем аны төшләремдә еш кына югалтып, эзләп талпынуларым, коточкыч югалту, күңел бушлыгы хисләреннән үзәкләрем өзелеп уянуларымның сәбәбе ачыклангандай, кереп адаша торган лабиринтлардан алып чыгучы ишекнең ачкычы табылгандай булды. Кызым шул «бөтерчек» эченә эләккән төннәрдә югалта торган булмадым микән мин аны? Нәкъ шулай булуы бик ихтимал ич моның! Соңгы вакытларда кайберәүләрнең рауван җаннары тәнне — кешенең тышкы кабыгын калдырып, чит илләрне генә түгел, хәтта Галәмне гизеп кайтулары, шул чакта якыннарының күңел бушлыгы тоюларын, билгесезлек, курку хисләре кичерүләре хакында күп язалар. Минем кызларым белән дә шуңа охшашрак хәлләр булмагандыр дип кистереп кенә кем әйтә ала?!

Аннан килеп, Гөлназ бала вакытта да, үсмер чакта да безнең Сугышлыга кайтып йөрергә ярата иде. Ни гаҗәп, кайткан саен аңа авыл күгендә пәйда булган (безнең тирәдә космодром түгел, аэродром да юк) төрле сәер очкычларны күрү насыйп икән. Бер кайтуында ул күктә пәйда булган биш түгәрәк саргылт «ай»ны иптәш кызлары белән бергә күзәткән. Аларның әйләнәләре сыра бөкесенеке сыман сырлы, бер өлеше белән аз гына бер-берләрен каплап, дуга рәвешендә күктә эленеп торалар икән. Алдагысының зуррак, арткарак күчкән саен «ай»ларның кечерәя барулары аларның бер-берләреннән билгеле бер аралыкта торулары хакында сөйли. Күпмедер вакытлар шулай «эленеп» торганнан соң, алар бер-бер артлы «сүнеп», күздән юк булганнар.

Икенче кайтканда ул шул ук иптәш кызлары белән теге «керпегә охшаган» (Гөлназның үз сүзләре) «биш ай» торган урыннан ук диярлек кызгылт-сары шар очканын күзәткән. Шушы кызгылт-сары шар артыннан кинәеп киткән утлы эз кала, ул эз җиңелчә генә калтыранып калган сыман икән.

Өченчесендә, соңгысында, шундый ук шарны Казанда, төнлә тәрәзәдән генә күзәткән. Ул чакта мин, гадәтемчә, эштә идем. Өйдә утырсам, бәлки мин дә бу сәер тамашаны күрү бәхетенә ирешкән булыр идем...

Шул. «Бизмән йолдызлыгы» исемле әсәремне төгәлләүгә, теге, мине эшкә әйдәүче көч бетте. Кемнеңдер күктән торып күзәтүе дә тоелмас булды. «Миссиям үтәлде бугай, бүтән дәшмиләр»,— дидем мин гаиләмә шаяртып. Әмма бөтенләй үк тынычлыкта да калдырырга ашыкмадылар бугай. Гаҗәеп төшләр ешайды. Аларны көндәлек тормыш белән дә, укылган китаплар, мәкаләләр, күрелгән кинолар белән дә бәйләве читен. Шунысы кызыклы, ул төшләр тулы бер вакыйганы тасвирлаган фильмнан алып, кайберләре кыска-кыска гына видеоклипларны да хәтерләтәләр. Ул «фильмнар», гадәттә, төсле була. Ләкин ул төсләр һинд киноларындагы кебек аермачык ярылып ятмый, бәлки беркадәр тоныграк, соргылтрак. Эротик күренешләр дә очраштыргалый. Әйтик, «Ява»га тартымрак мотоциклда бер егет белән кыз элдертә. Тирә-якта яшеллеккә күмелгән таулар. Яшеллек офыкка якынлашкан саен хыялый зәңгәрлеккә күчә бара. Ә теге пар асфальт юлдан һаман оча гына. Кинәт — кискен борылыш, борылыш артында ук — текә яр, аста — тирән елга җәйрәп ята. Мотоцикл борылырга өлгерми кала — очарга теләгәндәй, ярдан югары ыргыла да, ал тәгәрмәчен бераз гына югары чөеп, акрын гына түбәнәя башлый, аннан соң су баганасы күтәреп, төпкә чума. «Әрәм булдылар! Нинди матур пар иде!» — дим, имеш. Юк икән, мотоцикл чумган урыннан әнә ярга табан ниндидер җитез хәрәкәтләр сизелә, су өсте җиңелчә генә өермәләнеп ала, эреле-ваклы һава куыклары күтәрелә. Менә ярга терәлеп диярлек ике ялангач гәүдә калка — атлет сынлы егет белән ифрат сылу гәүдәле кыз, җитәкләшеп, ярдан күтәрелә башлыйлар.

Егет үз дәрәҗәсен белеп, төз, горур атларга тырыша, ә кызның киресенчә, бөтен гәүдәсе уйнаклап, һәр адымы саен тиешле әгъзалар тиешле вакытта бик килешле генә дерелдәп-дерелдәп куя. Менә алар ярдан менеп киткәләр дә, әрәмәлеккә кереп, күздән гаип булалар...

* * *

Баштанаяк бүтән бер дөньяга күмелеп барганымны сизеп, хезмәттәшләрем баштарак миңа көлемсерәп карый торган булып киттеләр. Артымда чыш-пыш килеп, көлешеп алудан да тартынмыйлар. «Баш мөхәррир «ычкынып» бара!» — янәсе. Ә үзләре оча торган тәлинкәләр, ерак цивилизацияләрдән килгән зирәк затлар, йорт иясләре, бичуралар, шуңа охшаш башка нәрсәләр турында нинди генә язмага тап булмасыннар, барысын да миңа күтәреп киләләр. Һич кенә дә көтмәгән, уйламаган җирдән бер белмәгән кешеләр кереп, «күкләр темасы»на кагылышлы әллә никадәр яңа мәгълүмат калдырып чыгып китә. Илнең әллә кайсы почмакларыннан, журнал эшчәнлегенә рәхмәт әйтеп, хатлар ачыла. Аларда да шул як матбугатындагы кисемтәләр салынган: оча торган тәлинкәме, шул тәлинкәдән чыккан сәер затлармы, биороботлар белән очрашу мажараларымы... Кыскасы, кемдер мине нәрсәгәдер әзерләүне тизләтә, ашыктыра. Күңел боларның барысын да язып, теркәп барырга кирәклеген тоя, әмма ниндидер бер көч кулга каләм алырга ирек бирмичә туктатып, тыеп тора. Килгән кисемтәләр, язмалар да уйламаган җирдән ничек килеп керсәләр, шулай ук көтелмәгәнчә юкка да чыгалар.

Бездән югарырак дәрәҗәдәге цивилизацияләрнең булуына, аларның безне даими күзәтеп торуларына минем инде болай да шигем калмаган, шунлыктан «оча торган тәлинкә фәлән җиргә төшкән, фәлән кеше Галәм илчеләре белән элемтәдә тора икән», — дигән хәбәрләр инде мине алай шаккатырмыйлар. Мине бу мәсьәләнең асылы, фәлсәфәсе ныграк кызыксындыра, күбрәк шул ягы уйландыра.

Ә Галәм фәлсәфәсе дигәнең биниһая катлаулы нәрсә булырга охшап тора. Аның эченә тирәнрәк үтеп керергә омтылган саен, мин бер нәрсәне төшенә бардым: диннәр, шул исәптән ислам тарихын, аларның өйрәтмәләрен, фәлсәфәсен, асылын белмәү кешене аяк-кулсыз гына түгел, ике күзсез, зиһенсез дә итә икән... Шуларны тирәннән белми торып, Галәм фәлсәфәсен аңлау да ифрат читен икән. Шул өйрәтмәләрне яхшы белсәк, рауван җаннар тәшкил иткән теге дөньяның бу дөнья белән ни өчен торган саен ешрак элемтәгә керә баруын аңлавы да әллә ни кыен булмас иде... Шулай да Галәм сабагының үз өлешемә тигәнен мин уңышлы гына үзләштерә идем шикелле.

Кичләрнең берсендә учларымда ниндидер көч, ә күңелемдә ниндидер яңа сәләт барын тойдым. Ә башымнан: «Син кешеләрне дәваларга, савыктырырга тиеш» — дигән уй йөгереп узды. Йа хода, миңа экстрасенс та (кеше тәненә кагылмыйча, кул-бармаклардан чыккан күзгә күренмәс илаһи нурлар белән дәвалаучы) булырга язган микәнни?! Күптән үз-үземнән көләргә җай чыккан юк иде, көлдем ичмасам бер рәхәтләнеп. Бар дөньяга танылган Джуна буласың килмиме тагын?! Уйлабрак кара әле, Дәрзаман, ныграк уйлап кара, үзеңне пәйгамбәр итеп тә тоймыйсыңмы?! «...көлегез! Файдасы күп, белегез!» — дип җырлыйлар бит. Чыннан да хак икән — уч төпләремне кычыттырып, иреккә чыгарга торган теге нурлар сүнеп калдылар сыман, мин дә тынычлана төштем.

Әмма күрәселәрем моның белән генә бетмәгән икән әле. Төннәрен, йокларга ятып, күзләремне йомдыммы, күз алдымда ниндидер биек таулар шәүләсе туа да, ике тау түбәсе арасында ниндидер нурлар балкышы башлана. Күзләрне ачкач югала бу, йомуга — тагын шул ук хәл. Карап ята торгач, ирексездән күңелгә бөек Тибет таулары, андагы илаһи Шамбала дәүләте килә. Күз алдымда ни өчендер нәкъ менә шул таулар,

шул дәүләт өстендә уйнаган нурлар гәүдәләнә шикелле. Монысы — күңелле мажара, йокы алмаганда, сәгатьләр буена карасаң да арытмый. Ә менә башкасын... һич тә күңелле дип булмый. Төннәрен йә йокыга киткәнче, йә йокыдан капыл уянып, күзгә аксыл-кара җирлектә битлек каплагандай йөзләр күренә. Алар кара бушлыкта пәйда булалар да сиңа якыная башлыйлар. Матур гына елмайган йөзләр кинәт кенә бозыла, чытыла, тилемсә кыяфәт алып (әйттем исә кайттым!), куркыныч хәлгә килә. Менә шушы чырайларга күнегүе читенрәк. Билгеле бер әзерлегең, эчке ныклыгың булмаса, «гакылдан язам бугай» дип тә уйларга мөмкин. Болары инде — Галәм белән элемтәнең ныгытып башлану галәмәтләре, минемчә. Бу кадәресен беркадәр соңрак белдем. Әле тагын шунысын әйтергә онытып торам икән: нурлы таулар яисә теге куркыныч чырайлар (хәер, аларны «куркыныч» яки аннан да начаррак сүзләр белән атарга ярамый. Аларны бары тик кызганырга, яратырга, аларга теләктәшлек итәргә генә кирәк икән. Бу кадәресе миңа шулай ук аннан соңрак мәгълүм булды.) Берзаман миңа теге бушлыктан Сынар Күз карый башлады. Әйе, әйе, күз! Хәтта йомылып-йомылып та ала торган күз! Ләүхелмәхфүзенә язылган булса, аларын да күрәсең икән әле анын...

Тик нурлы тау шәүләләре, чырай-битлекләр, миңа сынап карый торган Галәм күзенең ни аңлатканлыгын мин белми идем әле.

Шунлыктан, тәүдә минем үземә аңлаешлырак нәрсәләр турында сөйләшү дөресрәк булыр шикелле. Һәм сүзебезнең шушы мизгеленә кадәресе минем үз-үземне аңлый башлаган балачагымнан алып, 1990 елның 30 августына — Татарстан җөмһүриятенең мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул иткән көнгә кадәр булса, соңгы өлеше шуннан соңгы 1 ел да 3 ай һәм әле шушы әсәр язылгандагы кайбер вакыйгаларны эченә алачак. Ягъни, әйтәсе килгәнем шул: Татарстан җөмһүриятенең мөстәкыйльлеге өчен көрәш кызган, катлауланган саен, Югары Көчнең (Көчләрнең?) миңа булган тәэсир йогынтысы да көчәя барды. Бу хәлләргә бәйле вакыйгаларның кайсы турыдан-туры диярлек, кайсы киная рәвешендә төшкә керә башлады.

Шуларның берсе турыдан-туры Җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлегенә һәм беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев язмышына бәйле. Минтимер Шәймиев, чорның демократик көчләре аңа «партократия вәкиле» дигән ярлык тагарга бик теләсәләр дә, ул — асылда, төрле районнарыбызда, бераздан Татарстан республика Министрлар Советында һәм бары тик иң соңыннан, Президент булып сайланыр алдыннан гына, берара КПССның Татарстан республика комитеты беренче секретаре булып эшләгән кеше. Шуңа күрә дә, коммунистлар партиясе алга сөргән сәясәт илдә җимерелә башлап, коммунист җитәкчеләрнең эшләре хөртиләнә башлагач, Шәймиевкә аеруча кыен иде. Бер яклап, җиде дистә ел дәвамында күнегелгән партия дисциплинасы чабудан артка сөйри, икенче яктан, милли хәрәкәт дулкыны аны алга барырга, милли лидерлыкка мәҗбүр итә, ә хәбәрдарлык елларында кабат аякка баскан «Иттифак» татар милли бердәмлек партиясе белән яңа оешкан ДПР («Россия демократик партиясе») центристлык — җөмһүрияттә яшәгән барлык милләтләрнең язмышын кайгырту сәясәте өчен аны адым саен консервативлыкта, партократлыкта гаепли, демократик үзгәрешләрнең тәгәрмәченә тыгылган таяк дип бәяли, соңгы вакытларда карагруһлар рупорына әверелгән «Вечерняя Казань» кебек гәзит, аның шәрәфенә чәнечкеле «мактау»ларны яудырганда, кара буяуларны кызганмый.

Хәер, мин сөйләргә теләгән вакыйгалар булып узган көннәрдә Минтимер әфәнде ТССР Югары Советы рәисе иде әле. Татарстан җөмһүрияте мөстәкыйльлеген ныграк даулаган саен, «демократик үзгәрешләр» дигән сүзне авызыннан өзмәгән дә, куймаган да ил Президенты Михаил Горбачев белән ул чакта РСФСР Югары Советы рәисе Борис Ельцин, сүз берләшкәндәй, икесе ике тарафтан безнең мөстәкыйльлек хәрәкәтен кимсетә, хәтта кайчакларда ачыктан-ачык хурлый башладылар. Җитмәсә,

үзебездәге күпчелек урыс депутатлары, һәм алардан да уздырып, кайбер татар манкортлары: «Мөстәкыйльлекме, әллә Россиядән бүленеп чыгумы?» — дигән провокациячел сорау куеп, татарлар белән урыслар арасын ясалма рәвештә бозарга, хәлне катлауландырырга керештеләр. Менә шушындый шартларда эшләргә, яшәргә, җөмһүрият мөстәкыйльлеген алга сөрергә кирәк иде Минтимер Шәймиевкә.

Ул айларда элеккеге Союздаш республикалар берсе артыннан икенчесе, СССР Президентын да бары тик халык депутатлары съездында гына сайлауны үрнәк итептер инде, үз Президентларын Югары Совет сессияләрендә сайларга тотынганнар иде. Әмма ике Югары Совет рәисе — Шәймиев белән Ельцин башка юлны, чын демократик сайлауны — гомумхалык сайлауларын кулай күрде. Әлеге һәр ике җитәкче өчен дә бу — сират күпереннән кечү, әмма бердәнбер гадел юл иде. Сайланган сурәттә алар инде халыкның үзе сайлаган җитәкчеләре булачак иделәр. Нәкъ менә шул көннәрдә аеруча кыен хәлдә калды да инде Минтимер әфәнде. Әмма хәл төзәтмәслек түгел иде әле. Дөресрәге, үзе белеп, күрә торып ясаган четерекле адымы — ягъни, Россия Президентын татарстанлылар да сайласын, дигән тәкъдиме Минтимер әфәнде Шәймиевнең тактикасы, киләчәккә стратегиясе иде булса кирәк.

Җөмһүриятнең мөстәкыйльлек өчен кискен көрәше нәкъ менә шул көннәрдә — танылган язучы, «Иттифак» милли бәйсезлек партиясе рәисе, Татарстан халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова сәяси ачлык игълан иткән сәгатьләрдә башланды, минемчә. Милләтара хәл кинәт кискенләште, килеп туган хәлне ашыгыч рәвештә татар халкына аңлату кирәк иде. Һәм мин моны элеккеге коммунистик тоталитарлык елларында да милләт язмышы турында үз сүзен курыкмыйча әйтә алган абруйлы әдипләребез әйтер дип көттем.

Җитмәсә, кергән төшләр дә күңел тынычлыгы вәгъдә итми. Менә шуларның берсе. Монысы да көрәзәчел шартларда — бар нәрсә дә ачык күренә торган серле караңгылыкта керде. (Сүз уңаенда гына шунысын да әйтим, КПСС өлкә комитетының газит-журнал басмаханәсе балалар журналын тотудан баш тартып, «Ялкын»ның матди кыенлыклар аркасында ябылу куркынычы тугач, Минтимер әфәнде мине ике тапкырында да тоткарлыксыз кабул иткән һәм журналны яшәтүдә зур ярдәм күрсәткән иде.)

Минтимер әфәнде янына нинди дер җитди эш белән килгәнмен, имеш. Тик, ни хикмәттер, кабул итү бүлмәсе шул ук урында калса да, кысанланган шикелле. Кабул итүче сәркатип элек затлы өстәл артында утырса, хәзер ул кизү солдат сыман аягүрә басып тора, иде.

— Эчкә узыгыз, Минтимер Шәрипович хәзер килә, — ди бу миңа.

Бүлмә эчендәге үзгәрешләр дә күзгә бәрелерлек. Ишектән керүгә үк, берсен «Т» хәрефенең түбәтәе сыман куеп, өстәлләрне каршы стенага табан тезгәннәр. Түбәтәй-өстәлгә, ягъни ишек төбендәгесенә өсләренә май, май өстенә кызылмы, карамы уылдык ягылган өч телем күмәч куелган. Башка өстәлләр янында, мәҗлес табынындагы кебек, шыгрым кеше. Барысы да алып гәүдәлеләр... Өстәл өсләре тап-такыр булса да, кәефләре шәп: шау-гөр киләләр, бәхәсләшәләр. Әллә, мәйтәм, бераз гына «нитеп» тә алган инде болар?! Шулай дип уйларга да өлгермәдем, Татарстан радиосында эшләгән елларымнан ук таныш бер җитәкче агай, каяндыр ярты стакан чамасы «зәмзәм суы» чыгарып, миңа сузды:

— Мә, дускай, — ди. — Сал шуны, күңел ача тор! — ди. Аны-моны уйлап тормастан, салдым да җибәрдем бит тегене, хәерсез! Салып кына куюым булды, ишектән Минтимер әфәнде килеп керде. Кәефе шәп, күңеле күтәренке, йөзе көләч. Күрче, матур итеп елмая да белә икән бит әле безнең кырыс җитәкчебез! Әйтәм бит, шундый сөйкемле итеп елмая ул, әйтәсе сүзе дә шулай күңелләрне эретеп җибәрерлек якты, җылы булыр төсле. Тик, ни хикмәттер, бүлмәдәге тук чырайлы халык аны тыңламый, үз сүзләре сүз. Алай гына да түгел, кайсыдыр районнан

килгән әвен гәүдәле бер урыс житәкчесе (халык депутаты инде, әлбәттә) хужа каршына чыгып, иләмсез кулларын селти-селти, кемнедер әрләргә, битәрләргә тотынды. Шундый итеп битәрләдә теге депутат, Югары Совет рәисебез үз урынына барып утырды да иягенә таянды. Әле бая гына балкып торган йөзен әрнү галәмәте алыштырган.

— Нишләмәк кирәк менә мондый кешеләр белән?!—диде ул үзәге өзгәләнеп.—Әйтеп-әйтеп тә аңламагач, тагын ничек аңлатыйм инде боларга, ә Дәрзаман?!

Кирәк бит, үз исемем белән эндәшкәндә дә Югары Совет рәисе кадәр Югары Совет рәисенә бер кәлимә сүз әйтә алмыйча тор инде! Бик әйтер идем, гаебем зур—теге таныш райком секретаре кырлы стаканга салып биргән «яшел елан сөте» комачаулый...

Бу төш минем болай да тынгы тапмаган күңелемә яңа вәсвәсә салды... Нинди фал болар? Югары Совет рәисе белән бергә Татарстаныбызны нинди сынаулар, нинди имтиханнар көтә тагын?

Югары Советның икенче сессиясе башланыр көннәр иде бу. Шунлыктан аның утырышларын мин җентекләп карап барырга (телевидение тапшыруларыннан), таныша алмаганнарын хезмәттәшләремнән сораштырырга, гәзитләрдән укырга тырыштым. Аллага шөкер, бу сессиядә алай пошаманга төшерерлек берни дә булмады. Ә төш барыбер күңелне борчый. Теге, май өстенә уылдык ягылган өч телем күмәчнең дә мәгънәсен табасы бар иде бит әле... (Соңрак исә: «Иртәме-соңмы, Татарстан да, башка Союздаш республикалар һәм Россия кебек үк, тигез хокук яулаячагына ишарә бу»,—дигән фикергә килдем.)

«Йә, Дәрзаман,—диде шулчак теге сирәк-мирәк кенә үзен сиздерә башлаган эчке тавыш.—Вакыт житте. Күрергә, ишетергә теләгән ул сүзләреңне халыкка бу юлы син үзең әйтергә тиеш!»

Әмма вакыт соң, көн-көн ярымда гына андый җаваплы мәкаләне язып өлгертү—ифрат читен мәсьәлә, аның һәр җөмләсе урынында булырга тиеш иде. Аннан килеп, кайсы мөхәррир урнаштырырга батырчылык итәр андый ашыгыч язманы?

«... ул сүзләрне халыкка бу юлы син әйтергә тиеш!»—дип тәкърарлады эчке тавыш үҗәтлек белән.

Һәм мин яздым.

Ә ул чакта «Татарстан яшьләре» газетасының мөхәррир вазифаларын үтәүче Миңназыйм Сәфәров, әзерләнгән башка язмаларны кичектереп тору исәбенә булса да, «Азатлык мәйданында—ачлык» дип исемләнгән мәкаләмә, һич икеләнеп тормастан, киң урын бирде. («Т.Я.» № 61, 1991 ел.).

Син ул көннәрне яхшы хәтерлисеңдер әле, кадерле укучым. Азатлык мәйданындагы ачлык безнең алдыбызга озак, урау юллар белән килде. Республикабыз кунагы Б. Ельцинны алкышлар белән каршылавыбыз да, аның безгә ни күләмдә мөстәкыйльлек вәгъдә итеп китүе дә яхшы мәгълүм сиңа. Без, татарлар, ачык күңелле—могътәбәр кешеләрнең мөхтәрәм сүзләренә ышанырга өйрәнгән халык. Мөстәкыйльлекне ни кадәр кирәксә, шулкадәр итеп алыгыз, дигән иде ул. Минем кебек үк беркатлы булмаган кеше аңларга тиеш иде югыйсә: бер генә патшаның да моңарчы басып алынган халыкка үз ирке белән азатлык, мөстәкыйльлек биргәне юк. Моның өчен, чыннан да, туры мәгънәсендә көрәшергә кирәк. Шул исәптән, иң беренче нәүбәттә, парламент юлы белән дә. Соңга табарак мин фәкыйрегез дә аңладым: нәкъ шушы көрәшне истә тотып вәгъдә иткән дә инде безгә хөрмәтлебез Борис Николаевич мөстәкыйльлекне! Урыс милләтеннән булган депутатлар аз түгел ич безнең Югары Советта! Тагын, татар булып та, урысча уйлаганнары күпме! Алалсагыз, алып карагыз, янәсе.

Менә шушы шартларда СССР бөтенлеген саклау турында референдум үткәрү мәсьәләсе килеп туды. Җөмһүриятебезнең максаты—Союз килешүендә турыдан-туры катнашып, аны төзүчеләрнең берсе булырга

һәм РСФСР белән дә мөнәсәбәтләрне тигез хокуклы дәүләтләр буларак төзелгән килешүләр нигезендә алып бару иде.

Союз референдумында җөмһүриятебез анық файдасына тавыш бирел, М. Горбачев үзенең теләктәшлеген белдереп, Союз килешүенә имзалар салыр вакыт җиткәч... СССР Президентының Татарстан җөмһүриятен кәкре каенга терәтеп калдырганлыгы мәгълүм булды — «9 + 1» (Союздаш республика һәм Президент) килешүе барлыкка килде. Гадирәк әйткәндә, бу — Горбачев белән Ельцин арасында идарә итү даирәләрен бүлешү иде. Ягъни 9 союздаш республика Горбачев канаты астына керә, ә без, элеккеге автономияле республикалар, өлкәләр һәм аннан да ваграклар — Ельцинның йомарланган учына. Һәм асылда бу шулайрак килеп чыкты да. Горбачев һәм Ельцинның элеккеге 14 автономияле республика җитәкчеләре белән очрашу вакытында бары тик М. Шәймиев кенә корыч ихтыяр күрсәтте, Союз килешүенә ТССР бары тик СССР субъекты, аны төзүчеләрнең берсе сыйфатында кул куячак, ә РСФСР белән мөнәсәбәтләр исә шуннан соң ирешелгән килешү нигезендә барачагы хакында кистереп, ачыктан-ачык әйтте.

Әмма Россия федерациясе безнең мөстәкыйльлекне танырга ашыкмады гына түгел, моны эшләргә уйламады да. Киресенчә, безнең Азатлык кошыбызны әсир итәрдәй җәтмәләрне бере арты икенчесен үрә торды. Аларның берсе — СССРны саклап калу турындагы референдумны әйткән идем инде. Анысы үтә нечкә җепләрдән үрелгән, гади күзгә генә бик күренерлек тә түгел иде. Әмма икенчесе — РСФСР Президентын сайлауга бәйлесе, ашык-пошык әвәләгәне баш очыбызда капыл — ТССР Югары Советының 13 майда (1991) үткәрелгән кичке утырышында, депутатларның күңел күзләре әлеге җәтмәне күрмәс хәлгә җитеп арыган вакытта пәйда булды. Һәм депутатлар, мөстәкыйль Татарстан җөмһүриятендә суверен РСФСР Президентын сайлау турында карар кабул итеп, әлеге җәтмәне үз куллары белән үк үз өсләренә капладылар. Татарстан дәүләтендә икенче бер чит дәүләт президентын сайлау һәм ТССР, һәм РСФСР конституцияләренә, шул исәптән ТССРның суверенлыгы турындагы декларациягә каршы килә. Шунлыктан, телибезме моны, юкмы, сайлау уңай нәтиҗәләр биргән тәкъдирдә, без юридик яктан РСФСРның бер өлеше генә икәнлегебезне танырга тиеш булачакбыз. Менә шул сәбәпле, әлеге карар Югары Совет Рәисе белән бер төркем депутатлар арасында фикер аерымлыгы барлыкка китерде. Ә Фәүзия Бәйрәмова исә әлегә карар кабат каралып, юкка чыгарылганга кадәр сәяси ачлык игълан итте.

Әйе, Фәүзиянең дистәләрчә фикердәшләре белән бергә ачлык тотуы биш гасырлык әсирлек йокысыннан айный алмаган татарны азга гына булса да уятып, айнытып җибәрде. Азатлык мәйданына дистәләрчә мең халык агылды. «Азатлык! Азатлык!! Азатлык!!!» дигән кайнар сүзләр Казан каласы күгендә генә түгел, бөтен җөмһүрият өстендә яңгырап торды.

Урыс шовинистларының исә беркайчан да йоклап ятканнары булмады. Бу мәсьәләдә уянып, айнып торасылары юк иде аларның. Татар милли хәрәкәтендәге һәр җөй, һәр тишек, һәр чатнаган урын алар өчен табыш, казаныш булды. Нәтиҗәдә, бу ике хәрәкәтнең дә тәнкыйть уты бер ноктага — Шәймиев шәхесенә төбәлде. Фәүзия Бәйрәмова, Марат Мөлеков кебек халык җитәкчеләре аны йомшаклыкта, Мәскәүгә юл куюда, татарлар мәнфәгатен сатуда гаепләсә, «өлкән туганнарыбыз», киресенчә, аны Россиягә хыянәттә, партократия мәнфәгатьләрен яклауда гаепләделәр. Ә Мәскәүгә бары тик шул гына кирәк иде дә. Татар белән урыс бер-беренә каршы мәйданнарга йодрык төйнәп чыксамы?! Һәй, чыксыннар гына! Урамнарда кан гына коелсын! Шуннан соңмы? Омон гаскәриләре иманын киячәк Татарстанның! Милләтен-фәләнен дә аралап тормаячак, танк башмаклары, бронетранспортер көпчәкләре бөтенебезне бергә рәттән җир белән тигезләячәк. Җиде дистә ел дәвамында үз халкын

үзе үк кансыз рәвештә миллионлап кырган Мәскәү түрәләренә берничә дистә мең урыс гомере нәрсә ул?! Төптәнрәк уйлап карасаң, безнең күбебез маңкорт булган кебек, алар да ни урыс, ни татар ич хәзер. Мәдәниятләре, дин-йолалары да калмаган рәтләп, әдәби телләре дә. Шулай булгач, үзләрен генә чын урыс санаган мәскәүлеләргә ни сан ул халыкка?! Мондагыларын, татар белән беррәттән, кырып салсалар, бар Рәсәйне генә түгел, дөньяны шаулатып женазаларын үткәрерләр дә Урта Азия, Кавказ, Балтыйк буе республикаларыннан сөрелгәннәрен кайтарып тутырырлар. Менә нәрсә өчен кирәк ул үз куенында гына түгел, гасырлар узу белән ашказанында калган Татарстан «бүленмәс» Россиягә! Менә ни өчен үзе дә таркалудан курка Союз империясен таркалырга мәҗбүр иткән Россия империясе! Менә ни өчен кан кардәшенең дә хәләл каны кызганыч түгел, тамырында — казнокрад, канында — партократ, сүздә исә демократ булып күренергә азапланган кайбер Рәсәй түрәләренә.

Ә безгә, әле җанында, канында милли рухы тәмам сүнәргә өлгермәгән татарларга, Татарстанны исән-имин саклап калу кирәк иде. Авыр шартларда, денсез һәм милләтсез коммунистлар партиясе белән тигезсез көрәштә туып, үсеп, халык арасында хөрмәт-абруй казанган Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» татар милли бердәмлек партиясе һәм «Суверенитет» комитеты нәкъ менә шушы максатлардан чыгып, урыс шовинистларына, Мәскәү түрәләренә һәм аларның татарга каршы алып барган карагруһчыл сәясәтенә каршы аяусыз көрәш ачтылар, әле һаман да күп гасырлык изелү йокысыннан айнып җитмәгән, исәңгерәгән татар арасында көне-төне аңлату эшләре алып бардылар. Әлбәттә инде, безнең коллык халәтебезгә беренче башлап Явыз Иван явы сәбәпче булса, соңгы җиде дистә елда безне коммунистик идеология богаулап торды. Милли азатлык хәрәкәте дә, инде әйткәнемчә, татар маңкортлары белән урыс «демократлары», дөресрәге, шовинистлары да бер кизәнүдә шул партократия җимешләрен себереп түгәргә, өр-яңа үз лидерларын күтәрергә омтылдылар. Тик татар милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләре, «демократлар» белән берләшсә, бу беренче сәгать үк татар халкы өчен кара төнгә әвереләчәк иде. Ни өченме? Менә ни өчен: ул көннәрдә Югары Совет Рәисе Минтимер Шәймиев белән Министрлар Кабинеты Рәисе Мөхәммәт Сабиров кебек тоталитар режим казанында кайнаган, Мәскәү белән дә, башка республикалар белән дә йөзләрчә һәм меңнәрчә күзгә күренмәс җепләр белән бәйләнгән, шул ук вакытта эчләрендә татар җаны җылынган, татар йөрәге типкән урындагы җитәкчеләргә, димәк, халыкка да җитди йогынтысы булган бу кешеләребезне югалту шовинистлар өчен бәһасез бүләк булачак иде. Татарстан җөмһүрияте Президентын сайлаулар якынлашкан көннәрдә бигрәк тә шулай. Бу урынны бер ычкындырсак, икенче тапкыр инде мәңгегә күрмәячәгебез көн кебек ачыкланды. Россиянең кабат «канатлана» башлаган кара кошы мәңге дә безне үзенең үткен тырнакларыннан ычкындырачак түгел иде.

Кыскасы, безгә Шәймиевне Президент итеп сайларга, соңыннан аны якларга һәм сакларга кирәк иде. Бәхеткә, Шәймиевнең көндәшләре — татарлары да, урыслары да, тиешле кадәр тавыш җыя алмыйча, теркәү исемлегеннән «коелып» калдылар. Әмма Шәймиевкә каршы көчле эш алып барылганга күрә, аның да тиешле тавыш җыя алмау куркынычы туды. Өстәвенә, Россия Президенты Ельцин да бездән сайланса... «Хуш, мөстәкыйль Татарстан! Бәхил бул, суверинетет!» — дияргә генә кала иде...

Җитмәсә, сайлауларга да санаулы көннәр генә калып бара. «Вечерняя Казань», «Советская Татария» кебек газеталар ходаның һәр бирмеш көнендә чаңнарын бары тик Мәскәү каланчасына карап какканга, бер өмет — эчендә рухы, җаны калган татар халкында һәм татарны олылаган кешеләребездә иде. Аларга хәлне аңлатырга, җөмһүрият Президентын сайлауларда бердәм катнашырга һәм аны яклап тавыш бирергә чакырып оран салырга кирәк! Һәм бу «Иттифак» партиясе рәисеннән, йә булмаса

Татар Иҗтимагый Үзәге рәис — координаторларының берәрсеннән, яки «Суверенитет» комитеты рәисеннән котелде...

Һәм тагын эчке тавыш: «Ни котәсең, Дәрзаман? Сиңа да кулга каләм алу кирәк!» Әле яңа гына язып чыккан идем бит. Дөрес аңлашылыр микән? «Дөресен язсаң, аңлашылыр».

«Ялкын» журналының урамга чыгарып ташланган үксез бала хәлендә калганлыктан, акчасызлыктан чын-чынлап янып яткан көннәре. Йөгерергә, чабарга, иганәчеләр табарга кирәк...

«Бер атнада гына «Ялкын»ың янмас. Син язарга тиеш. Әле Татарстан радиосыннан сөйләү дә мотлак».

Һәм мин «Мөстәкыйльлек юлы — изге юл» дигән исем белән Татарстан халкына мөрәҗәгатемне («Т. Я.» № 67, 1991 ел.) яздым.

Радиодан чыгышым, газетадагы мәкаләм халык күңеленә ни кадәр тәэсир иткәндер, анысын инде бер ходай үзе генә белә. Менә шушы сайлаулар дип ут йотып йөргән көннәрдә кергән төш.

Сәхнәдә кыллы музыка уен кораллары концерты бара. Гаҗәп, музыкантлар — Татарстан телевидениесе операторлары, имеш. Үзләре хоккейчылар киеменнән. Бар кыяфәтләре — хоккейчыларча. Шар таяклары урынына, кулларында — электрогитаралар. Шәп уйныйлар! Авызларын ерасера, бөгелә-сыгыла, сикерә-сикерә уйныйлар. Нишләсәләр дә килешә, чөнки ачылмаган пәрдә артында тыңлый бит аларны халык. Концертта Башкортостан, Мари иле, Мордва, Чувашия республикаларыннан килгән кунаклар да бар; алар сәхнә артында кайсы кубызда, кайсы кашыкта, кайсы тәлинкәдә, кайсы барабан урынына як-якка сөяп куелган кием шкафына учлары белән шапылдата-шапылдата, безнең хоккейчы оператор музыкантлар уйнаган дәртле татар көен җөпләп торалар, имеш.

Ә мин сәхнә артындагы урындыкта аяк өстенә аякны атландырып утырганмын да, аларга кушылып, канатлана-канатлана мандолина чиртәм. Тез тиңентен күтәрелгән чалбар балагыннан чыгып торган аяк балтырына игътибар да иткән юк, икс катлы пәрдә артында утырам ич! Тукта, чү! Нәкъ шушы халәтемдә пәрдәләре ачылган сәхнә уртасында, залда шыгырым тулы халык каршында калганмын лабаса! Каушаудан, катырак чиртеп, мандолинамның бер кылы өзелеп китте. Әмма сер бирергә исәп юк, уйнавымны беләм. Шул арада сәхнәгә, кулына тоткан кулъязма битләрен югары күтәреп җилпи-җилпи, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан килеп чыкты. Яңгыраган көйгә үзе бии, үзе шатланып кычкыра:

— Без җиңдек, без җиңдек! — ди. Куанычыннан еламый гына.

Шушы урында уянып киттем дә, белгән догаларымны укып:

— Амин, каләмдәш, юраганың юш килә күрсен, җиңә генә күрик, мең тапкыр Амин! — дидем. Бу төш күңелемә, рухыма ышаныч өстәде.

Һәм, чыннан да, сайлаулар Татарстан Президенты файдасына үтте, ә җөмһүриятебезнең төп халкы, бу шарт үз ирегенә куелган булса да, Рәсәй Президентын сайлауда катнашмады — Рәсәй Президенты безнең җирдә үтмәде!

Сәясәт — сәясиләр эше булганга, язган мәкаләләрем җитәр, кабат иҗатка, язасы әйберләремә әйләнеп кайтырмын, дигән идем. Хатынымның әнисе әйтмешли, алай гына булмый икән шул әле. Төнге бер белән өч арасында уятып, күзләрне ачтырмыйча гына, төрле «мультфильмнар» күрсәтергә гадәтләнгән галәм боеручыларым миңа кабат 10-15 секундлык кына тамаша күрсәтеп алмасыннармы!

Күз алдымда миләүшә экран пәйда булды, өстән аска таба, икс иллеләп киңлектә соры тасма төшә. Экранның югарыгы сул почмагыннан диагональ буенча, аз гына кыеклатып, хәрби фуражка ачыла башлады. Кокарда астында — хәйләкәр кысылган күзләр. Борын һәм балачактан ук рәсемнәрдән күңелләргә сеңгән мыеклар. Сталин! Соры тасма экранның астына төшеп җиткәндә, Сталин башы бөтен экранны биләп алды. Шундый да шат! Менә ул, төтен бөркеп торган тәрепкәле кулын, иркен бер хәрәкәт белән, читкә җәеп җибәрә. Әйтерең бармы, шәп,

кирәгеннән артык яхшы иде бу мизгелдә иптәш Сталинның кәефе! Маршал Жуков мемуарларына таянып фикер йөртсәк, бу хәрәкәт, бу ишарә, төтен бөркеп торган тәрепкә — барысы да Сталин кәефенең әйбәтлеген раслый торган дәлилләр. 3 — 5 секунд саен кадрлар үзгәреп торды. Сөртелеп төшкән Сталин фуражкасыннан ниндидер таныш корылма өсләре күренә башлады. Металл кою комбинатлары икән. Аннары әләм, сөңге, чалгы, тагын әллә нинди нәрсәләр пәйда булды. Ураммы, мәйдан дип әйтимме — шыгрым тулы халык. Кулларына, аермачык әйтеп булмаслык, төрле кораллар күтәргәннәр. Диңгез дулкыннары сыман бер тарафтан икенче тарафка тирбәлеп, чайкалып торалар... Хәзер инде шушы халык — эре планда. Үзәктә — кинооператор. Ул, өчаякка бастырылган камерасының тоткасын әйләндерә, аны акрын гына уңнан-сулга күчереп, күрәшкә күтәрелгән гавамны тасмага төшереп калырга ашыга. Гавам исә бөтен экранны томалый. Шуннан соң... микрофильм тәмам.

Башка вакытларда шулай микромультиклар карауга ук йоклап китә торган идем. Әмма бу юлы шактый уйланып яттым. Урман сукмагы буйлап арт тәпиләрендә сикерә-бии кайтып килгән керпе малае гына түгел иде шул монысы. Заманында Рәсәйне генә түгел, бөтен дөньяны тетрәнергә мәҗбүр иткән Иосиф Виссарионович, шатлыгы эченә сыймаган Иосиф Виссарионович Сталинның үзен күрсәттеләр!

Башымда уйлар өермәсе бөтерелергә тотынды. Мин элегрәк тә Рәсәйдә чын демократиянең тернәкләнеп китүенә бик шикләнеп карый идем. Инде күктәге химаячеләрем зиһенемә шушындый сәяси эчтәлектәге кыска «документаль фильм» да иңдергәч, шигем калмады — Горбачев демократиясе маршал Язов битлеге астындагы диктатура белән алмашыначак!

Курыкканга куш, койрыгы белән биш дигәндәй, беркөнне ике хезмәткәремнең икесе дә берьюлы мәгънәләре белән бер-берләренә охшаш төш күргән булып чыкты. Берсен Ирек Нигъмәти сөйли: «Бик олы бер буш бүлмәдә гади урындыкта Горбачев утыра, имеш, — ди.— Үзе каш астыннан гына уңга-сулга карана, үзе, яныП-пешеп, кызыл борыч кузагы ашый. Ә аңардан югарырак караңгылыктан, хәйләкәр елмаеп, Ельцин карап тора, имеш...»— ди.

Һәм, чыннан да, бу көннәрдән соң хәрби диктатура озак көттермәде — Президент Кырымга чираттагы ялга киткәч, 19 август төнендә (1991), дәүләт перевороты була язып калды.

Ельцин исә, ГКЧПны яклауларын сылтау итеп, буе җитә алган кадәр союздаш һәм үз карынындагы автономияле республикаларның үз сәясәтенә туры килмәгән җитәкчеләрен тиз рәвештә эшләреннән азат итәргә һәм хөкемгә тарттырырга ашыкты. Әмма Татарстан халкын тиз генә тезләндереп булмаячак иде инде.

Төшемне сөйлим әле. Имеш, хәрби самолетта очарга тиеш икәнмен. Салонда гына түгел, очкычның кабинасында, командир кәнәфиендә утырам. Уң ягымда — икенче очучы. Янәшәмдә тагын бер очучы бар, әмма аның башы ни өчендер кабинаның уң як тәрәзәсе өстенә беркетелгән скафандр эчендә.

Аэродром миңа бик таныш та, таныш та түгел. Күтәрелеп китәсе юлга терәлеп үк диярлек, сул якта, өстен куе агачлар каплаган текә яр кала икән. Боларның берсенә генә канат очың тиеп китсә, очкычының йомычкалары гына коелып төшәчәк...

Каршымда — приборлар тактасы. Алар миңа бик таныш та, таныш та түгел кебек. Аеруча өчесе истә калган: нәни генә сигнал лампочкалары, шулар өстенә 161 ле саны сугылган. Очып китәр өчен мин шуларны тоташтырырга тиеш икән. «Тоташтырырга!» — дигән әмер алам. Тырышам, тик бер кызыл ут кабынмый. Кузгалып китәбез. Очкыч йөгерешен тизләткәннән-тизләтә бара. Юл тасмасы инде тәмамланып килә. Бетте. Алда — упкын. Хәзер шунда мәтәләчәкбез, имеш. Инде, упкын читеннән мәтәләм, дигәндә генә, очкычым кабат югары күтәрелә башлый. Әмма без әле һаман текә яр чите янәшәсеннән очабыз. Җирдәгеләрдән әмерләр

яңгырый, әмма мин аларны аңламыйм... Очабыз да очабыз. Менә мин белмәгән ниндидер биек таулар өстенә килеп чыктык, калкып торган таш кыяларга бәреләм-бәреләм, дип шикләнгән арада, тар үзән-тарлавыклар аша уздык, шуннан соң ниндидер шәһәр өстенә чыгып, очкычның канатлары сыярлык кына тар урамнар буйлап йорт түбәләре арасыннан уза башладык. Түбәндә — кар. Шул карлы урамнар буйлап төркем-төркем әрмән вә әзербайҗан халкы агыла. Салкын булуга карамастан, өсләрендә — бары тик гимнастерка. Яланбашлар түбән иелгән, кулларында — винтовка, автомат... Алда — сугыш кыры, имеш. Анда, кыр тутырып, ике ыру халкы сугыша.

Менә кинәт өченче ут та кабына. Очкычым, үкереп, югарыга атыла да, «үлем элмәге» ясап, җир ягалый оча башлый. Менә монысын инде турылап та, тигезләп тә, кабат җиргә куна торган итеп тә булмас кебек... Юк, алай да гомерем бетмәгән икән әле. Очкычым үзе җиргә төшеп кунды. Караңгы төшкәнче без шушы таныш булмаган аэродромда утырырга тиешбез икән, бары тик төнлә генә кабат очып китә алачакбыз, имеш...

Әйе, хәтта Балтыйк буе, Кавказ арты республикалары вакыйгалары яктылыгыннан чыгып караганда да, тамагына сөяк булып торган Татарстанны тәмам «йотып җибәрү», чыннан да, тимер чикләвек булып чыккан Президентыбызны «ватарга» азаплану Россия өчен шулай ук шактый мәшәкать тудырды. Хикмәт шунда: Татарстан халкы, аның Югары Советы да үз Президентының ГКЧП көннәрендә әлеге фетнәгә катнашмау сәясәтен дөрес дип тапты, аңа ышаныч белдерде.

Нинди генә гаепләр ташларга азапланмасыннар, Рәсәйнең кайбер түрәләре нинди генә куәтле сүзләр белән Татарстанны һәм аның җитәкчеләрен сүкмәсеннәр, Татарстан Президентын яклап та, саклап та калырга кирәк иде! Бу көннәрдә күктәге химаячеләрем мине сәяси яктан нык активлаштырып, уйлау, алдан сиземләүне (интуиция) кинәт көчәйтеп җибәргәнлекләрен тойганлыктан, шушы кичләрнең берсендә мин үземә төшлек салып яттым. «Йа илаһым, җөмһүриятебез мөстәкыйльлеген, аның беренче Президентын нинди язмыш көтә? Шуларны мин аңларлык ишарә җибәрсәң иде!» — дидем. Һәм миңа менә шушындай төш керде.

Өстәлем өстендә яшел ачык хат ята, имеш. Урыны-урыны белән төс әле куерыбрак, әле сыекланыбрак китә, күрән төскә керә, бормалы-сырмалы зәңгәр каюлар тасмаларга әверелә, аннары ул тасмалар зәңгәр күлләвекләргә барып тоташа. Югарыдагы сул почмак зур кызыл түгәрәк хасыйл итә. Боларның барысы да миңа СССРның географик картасы хакында сөйли иде. Икенче кадрда да — шул ук ачык хат, әмма теге кызыл ноктадан, ягъни СССРның башкаласы Мәскәүдән, төрле тарафка вак кына бөҗәкләрме, җәнлекләрме ашкындыргыч бер талпыну, күз карашы гына иярерлек тизлек белән читкә сибелә, күбесе көнбатыш тарафка хәрәкәт итә иде. Һәм өченче, соңгы күренеш. Теге түгәрәк кызыл бөҗра эчендә үзәнлек барлыкка килгән, имеш. Әнә шул кыялар бөҗрасының көньяк-көнбатыш тарафында өч кыядан гыйбарәт капкалар тора, имеш. Урта-кыя... чү, кемне хәтерләтә соң әле бу кыя-капка? Ельцин ич! Борис Николаевичның нәкъ үзе! Безнең Язучылар берлегендә дә нәкъ шундый мәгърурanә кыяфәт белән утырган иде бит ул. Әнә шул кыя-капка янында, бөҗра тышында, баягы үзәктән өерелеп качып барган кара таплардан үзенең үлчәме белән нык аерылып торган, эре гәүдәле бүре сымаграк бер ялгыз җәнлек утыра.

Менә кыя-капка зур итеп авызын ачты. Өркеп, үзәктән качып барган нокталарның күбесе, кире борылдылар да, өерелеп, кыя-капка авызы аша теге казансыман үзәнгә агыла башладылар. Кыя-капка янәшәсендә утырган теге җанвар да, дәү итеп, авызын ачып тора. Соңгы кара тап та кыя-капка авызына кереп юк булды, ягъни теге казан сыман үзәнлеккә барып төште. Кыя-капканың да, теге җанварның да — икесенең дә авызлары әле һаман ачык тора. Беренчесе — берәрсе адашып калмады микән, икенчесе — берәрсе ялгышып кына булса да, миңа килеп кермәсме, дип

көтә кебек. Юк икән, берни юк. Болар икәү үзләре генә калган. Шулчак кыя-капка капыл гына борылды да... Теге җанварның башы аның авызында калды...

Шушы урында уянып киттем.

Күрәсе төшемнең алдан ук максатын әйткәнгә, күзләремне ачарга, урынымнан торырга ашыкмыйм. Төшне тагын бер мәртәбә күңелдән кичерергә, андагы гамәл-хәрәкәтләрне янә бер мәртәбә шәрехләп чыгарга кирәк иде. Хуш... Әгәр, җөмһүриятебез язмышын төшлеккә куюымны исәпкә алсак, бик яман нәрсә килеп чыга түгелме соң? Ельцин башлы кыя-капка авызында безнең Татарстан калган булып чыга түгелме?.. Әмма Татарстан җөмһүрияте башка дәүләт җирләренә дәгъва белдерми бит. Димәк, кыя-капка янындагы җан иясен СССР Президенты дип карарга гына кала иде...

Илдәге вакыйгалар минем фаразларны раслый торды. Бер атна элек кенә үзәк фигура булган М. Горбачев, кечерәеп, бәләкәйләнеп, төссезләнеп калды. Ул инде, ил Президенты булудан бигрәк, үзенә бер тамчы су сыман охшатып ясалган марионет-курчакны хәтерләтә иде.

Татарстан җөмһүриятенең беренче Президентыннан исә, әлеге сират күперен кичкәндә үтә сизгерлек сорала иде.

Бу көннәрдә татар матбугаты белән урыс матбугаты капма-каршы позициягә бастылар. Татарстанда чыга торган урыс газеталары «Долой Шаймиева!» дигән плакатларны күбрәк басарга тырышсалар, татар газеталарында: «Руки прочь от суверенного Татарстана!»— дигән транспарант сурәтләре урын алды. Рафаэль Хәкимов, Тәлгать Бариев кебек милләтпәрвәрләрнең «Молодежь Татарстана» гәзите битләрендә басылган акыллы, саллы, дәлилле мәкаләләре күпсанлы шовинист журналистларга каршы чыкты.

Татар журналистларына бердәм күтәрелергә, җәмәгатьчелекне уятып җибәрерлек адым ясарга вакыт иде.

— Син дә тәвәккәлләргә тиеш, Дәрзаман!— диде эчке тавыш.

— Тиешен тиеш тә бит. Тегендә илтеп тыксалар... Мин бит — сәясәтче түгел... Бер дә уйламаганнан муенны элмәккә тыгасы килми...

— Авылдашың Газинур Гафиятуллинны, шагыйрь Муса Җәлилне онытма, Дәрзаман. Аларның үз җаннары үзләренә газиз булмагандыр дисеңме әллә...

Болай гына тартышуым инде. Эчке тавышка буйсынмый хәлем юк. Ә менә төшләремдә... соңгы берничә айда гына да мин үземне берничә мәртәбә сәяси тоткын итеп күрдем. Ул төшләрне тоташ бер җепкә тезсәң, совет концлагеренда гомер кыскарткан затның нурсыз вә тетрәндергеч тормышын, газаплы күңел кичерешләрен күзалларга була.

«ГКЧП көннәрендә», ягъни СССР таркалган чакта, миңа төшнең тагын бер кәттәсе керде. Күктә авыр кургашын болытлар йөзә, имеш. Мин, ни хикмәттер, гадәтемчә, очарга талпынам, авырлыгымны җуеп, рәхәт җиңеллек тоярга омтылам, инде акрын-акрын гына биеклеккә күтәрелеп барам. Күңелемдә — рәхәт иркенлек, очыш бәхете. Гомердә булмаганча, озак очам мин бу юлы, гомер булмаганча, биеккәрәк, югарырак омтылам. Аһ, тизрәк таралсын иде бу тоташ сорылык, чиста галәм киңлекләренә, аның балкып янган йолдызлары тарафына тизрәк барып чыгасы иде, янәсе! Шулчак кинәт, аркан борылган килеш, җиргә төшеп киләм икән. Монысы мине чын-чынлап куркуга салды. Чөнки, белүемчә, җиргә арты белән төшкән парашютчының да хәле мөшкел.

Алланың рәхмәте, мин Җиргә алай каты бәрелмәдем. Берара ярым сөйрәлеп, ярым йөгереп артка табан бардым да җай гына тукталдым. Каршымда таныш булмаган аланлык, аяк астымда биек үлән иде. Инде борылып, аланлыкның әтрафларын карыйм дисәм, йөрәгем убылып төшкәндәй булды — тагын зонага килеп чыкканмын: каршымда чәнечкеле тимерчыбык белән ныгытылган коймалар, сакчы каланчалары. Капка баганасына төрмә камерасы ачкычлары эленгән. Ачкычлар өстендә — талон

тартмалары. Тартмалар өстенә саф татарча: «Җаның теләгәнне сайла!»— дип язылган. Шул ук сүзләр күзгә күренмәгән йомшак бәрхет тавыш белән радиодан да кабатланып тора, имеш.

Менә шушы төштән соң татар журналистларын җыеп сөйләшергә булдык. Фикерне, иң беренче булып, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова күтәреп алды. Тиз арада баш мөхәррирләрне һәм бүлек мөхәррирләрен, башка журналистларны чакырырга килештек. Йөгерә-чаба халык туплый торгач, байтак халык җыелды.

Минем уйларымны укыгандай, Роза ханым Туфитуллова, гадәтенчә, елмая-елмая:

— Әйдә, Җәүдәт, үзең җыйдың халыкны, җыелышны да үзең алып бар инде,— дип, дилбегәне минем кулга тапшырды.

— Хәер, дидем мин — ни өчен җыйналуыбызның сәбәбен кыскача гына тагын бер мәртәбә аңлатып чыккач,— нигә дип боларны сөйләп торам соң әле мин? Сәясәт мәсьәләләрен сез болай да көн саен яктыртып торасыз. Бу кадәресе сезгә яхшы мәгълүм. Сүз озайтып тормыйча да аңлашыла лабаса: бүген Татарстандагы президентлык постын югалтуга юл куйсак, иртәгә инде мөстәкыйльлегә белән бергә, Татарстаныбызны да мәңгелеккә җуячакбыз...

Аннан соң Роза ханым өстәде:

— Мин ир-егетләребезне батыррак булырга, курыкмыйчарак эш итәргә, уртак бер фикергә килеп, журналистларның Татарстан халкына һәм җөмһүриятебезнең халык депутатларына мөрәҗәгатен кабул итәргә кирәк саныйм,— диде.

Кыска гына бу җыелыш, гөлт итеп кабынып алган кайнар бәхәсләрдән соң, мөрәҗәгать текстын әзерләүне миңа, Рашат Низами белән Флера Низамовага һәм «Молодежь Татарстана» газетасы хезмәткәре Венера Якуповага йөкләде. Кыска гына, әмма ифрат олы җаваплылыкны үз өстенә алган әлеге текстны Флера Низамова белән яздык. Рашат Низамиев кайбер төзәтмәләр кертүне кирәк тапты. Илдус Илдархановка безнең фикерләрдәге кискенлек ошап җитмәде. Текстның тырпаеп торган «мөгезләрен» бергәләшеп сындырдык. Мөрәҗәгатьне шул ук Флера Низамова, Венера Якупова һәм «Шәһри Казан» газетасы хезмәткәре Нәҗибә Сафина урысчага да тәрҗемә иттеләр.

Иртәнге тугызларда башланган эш кичке алтыларда гына тәгәлләнде. Текстларны йөгерә-йөгерә редакцияләргә өләшеп чыктык. «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан», «Шәһри Казан», «Сабантуй» газеталары, «Ялкын», «Идел», «Салават күпере» һәм «Сөембикә» журналлары коллективлары мөрәҗәгатьне берсүзсез кабул иттеләр. «Чаян» журналы, коллективларында эшләүчеләрнең күбесе урыс һәм яһүдләр булып, «Татарстанның мөстәкыйльлеге» дигән фикердән читтә калырга мәҗбүр булды. «Молодежь Татарстана» газетасы, шул ук сәбәпләр аркасында, мөрәҗәгатьне үз укучыларына шәрехләү рәвешендә генә тәкъдим итте. «Советская Татария» газетасы, төрле хатлар һәм мөрәҗәгатьләрнең күплегенә сылтанып, Югары Совет сессиясендә Президент һәм президентлык язмышы хәл ителми торып, безнең мөрәҗәгатьне үз сәхифәләрендә урнаштырмый торырга булды.

Алга таба сөйләп тормасак да була... Безне рәсми төстә яклаучылар күп түгел иде. Мин, мөрәҗәгать текстын учыма кыскан килеш, Камал театры каршындагы мәйданга ашыктым. Аны митинг каршында укуны шулай ук миңа йөкләгәннәр иде.

Безнең куанычка, Югары Совет сәяси яктан нык нигезләнгән зирәк карар кабул итә алды.

Монда язылганнардан: «Күр әле син, бер Дәрзаман гына йөргән ләбаса мөстәкыйльлек даулашып»,— дигәнрәк нәтиҗә чыга күрмәсен. Аллам сакласын! Хәтта татар халкының мөстәкыйльлек өчен күпгасырлык көрәшендә минем дә бер зәррә өлешем бар дип әйтү дә күп булыр. Сөйләгәннәрем бүгенге сәясәтне тарих өчен, әлеге дәфтәргә теркәү теләген-

нән туды. Куплаган әдипләребез, галимнәребез, сәнгать әһелләребез, журналистларыбыз даулы бу көннәрдә Татарстан мөстәкыйльлеге өчен тартышның эчендә кайнадылар, Ирек мәйданының үзәгендә булдылар. Татарстан халык депутатлары, язучылар Фәүзия Бәйрәмова, Разил Вәлиди, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, галим Рүзәл Йосыпов, җырчы Вафирә Гыйззәтуллина... Депутат әдипләребез ялкынлы, дәлилле чыгышлары белән Татарстан парламентында бәйге тотсалар, Ринат Мөхәммәдиев исә Татарстан азатлыгын Рәсәй парламентында да яклады. Фәнзаман Баттал, Гомәр Бәширов, Әхәт Гаффар, Әмирхан Еники, Әбрар Кәримуллин, Рашат Низамиев кебек әдипләребезнең үткен күзләреннән парламент, аерым депутатлар ясаган бер генә хата да читтә калмады кебек.

Азатлык колонналарының башында йөргән Роберт Батулла бу көннәрне яктырткан көндәлекләренең кайбер сәхифәләрен укучыларга тәкъдим итте инде. Мөстәкыйльлек идеясен безнең заманда яңа куәт белән беренчеләрдән булып җилкән итеп күтәргән, битләргә бәреп искән ачы, кискен җилләргә каршы барып, хәтта ачлык тоткан көннәрендә дә аны екмыйча алга баруын дәвам иткән Фәүзия Бәйрәмова, утлы-ялкынлы мәкаләләре белән матбугат сәхифәләрендә яшен кылычыдай ялтырапялтырап китсә дә, әдәби мәйданда үзенең саллы сүзен әйтмәде әле. Анысы, мөгаен, азатлык өчен көрәш мәйданына Фәүзия ханымны алыштырырлык яңа, яшь көчләр килгәчрәк булырдыр. Аның күп кенә фикерләре бу язмадагы байтак нәрсәләрнең, бәлки, капма-каршысы булыр. Кыскасы, ул көннәр хакыйкатен ачар өчен бик күпләрнең истәлекләре кирәк булачак әле...

* * *

Сәясәт дөньясына мин үзем әнә шулай эчке тавыш, эчке сиземләү, әлегә кадәр миңа берничек тә сиздереп йогынты ясамаган Югары Көч әмере белән килеп кердем шикелле. Шушы вакыйгалардан соң кабат үз дөньяма — журнал эшенә әйләнеп кайттым, карасы кибеп бетә язган каләмемне кулга алдым. Әмма...

Сәяси вакыйгаларга бай көннәр никадәр генә киеренке, никадәр генә катлаулы булмасыннар, мине үз карамагына алган Югары Көч (бәлки, Көчләрдер) билгеле бер юнәлештә һаман да әкрен генә, ашыкмыйча гына, әмма гаҗәеп бер үҗәтлек, искиткеч саклык белән алга этәрүне дәвам итте. Һәм ул үсеш берсеннән-берсе сәеррәк, берсеннән-берсе катлаулырак хискичерешләр, әлегә мин аңлап та, аңлатып та бетерә алмаган төрле информацияләр килү белән алмашып барды.

Т ө ш. Имеш, ниндидер, бер караңгы бушлыкта нигезен бөҗрасыман түгәрәк тәшкил иткән эреле-ваклы аксыл-саргылт таулар тезмәсе. Тирәли ак халатлы кешеләр баскан. Хәтеремә шундый сан уелып кала — «Алланың баш мие 895 центнер». Үзең дә күрәсеңдер, укучым: без моны аңлаудан гаҗиз, чөнки без Алланы матди хәлдә күз алдына китерә алмыйбыз. Әгәр дә инде без аны берьюлы бөтен Җиһанда, һәр тарафыбызда, Коръәндә әйтелгәнчә, илаһи дип гөман кылабыз икән. Ул тереклек кылган дөньядагы 895 центнерны... аңлап җиткерү мөмкин түгел! Бу санның, урынын һәм вакытын белеп кулланганда, галәм ияләре белән элемтәдә бер «ачкыч» булуы да бик ихтимал. Тик Галәм киңлегендәгеләр белән элемтәдә торучы кешеләрнең дә мин белгән кадәресе бу саннарның нәрсә икәнлеген миңа шулай ук әлегә аңлатып бирә алганнары юк...

Күрәчәкләрем моның белән генә чикләнмәгән булып чыкты. Аларны бәян итүгә, ягъни төшләр дәфтәренең икенчесенә күчкәнче, бер-бер артлы күргән ике төшне сөйләп үтү урынлы булыр сыман. Мин аларның икесендә дә үземчә тирән мәгънә күрәм.

Б е р е н ч е с е. Мин хәрби мәйданга килеп чыкканмын, имеш. Анда исә өйрәнү тревогасы игълан ителгән вакыт икән. Барысы берьюлы ачылган

ишекләрдән бер-бер артлы әле буяулары да кибәргә өлгермәгән техника чыга башлады: танклар, бронетранспортерлар, катюшалар, минометлар батареясына охшаган нәрсәләр... Капкадан чыгалар да, фланглар буйлап, киңәя, тарала баралар. Машиналарның ачылган капкачларыннан калын-калын кыска көпшәләр тырпаеп, ут ачалар. Тоташ гөрселдәү, төтен... Капка төбендәге часовойларның берсе, бил каешыннан капыл гына граната суырып, каршындагы ут машинасына томыра. Йөрәгем туктап калгандай була. Провокация ич бу! Аллага шөкер, гранатасы чын түгел икән, дөпелдәп бәреләдә шалтырап җиргә килеп төшә. Ә техника фланглар буйлап тарала да тарала. Чү, өйрәнү тревогасы гына микән бу? Казанны боҗра эчендә калдырып баралар түгелме?

Командирларның берсе «Советская Россия» газетасы битендәге рәсемне күрсәтеп тора. Ә рәсеме гади генә түгел, телевизор экранына охшаш, имеш. Алгы планга ике кеше баскан. Икесенең дә өстендә аксыл плащ. Икесе дә яланбаш. Икесе дә чал чәчле. Сул яктагысы — Ельцин. Уң яктагысын танып бетермим. Әмма Шеварднадземы, аңа охшаганмы ниндидер олы җитәкче кебек. Арткы планда — таулар. Анда сугыш бара. Анда — сугыш. Монда — камалыш...

Икенчесе. Адашудан җаным бәргәләнә, имеш. Ниндидер бик таныш тыкрыктан йөгерәм, кирәкле урамны табалмыйм. Тыкрыгым шаулап аккан елгага килеп терәлде. Казан-су булырга тиеш иде бу. Ярлары бетон белән ныгытылган, агымы көчәйгән, шаулап-гөрләп, тау елгасыдай ургыла... Әмма Иделгә табан түгел, киресгә, чыганагына табан ага, имеш.

Мин дә тыкрыктан борылам һәм Казан Кремленең елга ягы тарафына килеп чыгам. Иркен сулыш алып куям — эзләгән урынымны таптым бит, дим. Әнә, дивардагы капка ягына, кеше буе җитәрлек биеклеккә «Казан-су урамы» дип, саф татарча язу кадаклаганнар.

Кремль урнашкан калкулык хәзергедән биегрәк, шунлыктан аның Казан-су ягы капкасына алып менә торган баскычлары да текәрәк икән. Шул баскычтан, сикерә-уйный, ап-ак күлмәкле кыз бала төшеп бара, каршысына исә, аз гына иелә төшеп, Борис Ельцин менеп килә, имеш. Яшеллеккә күмелгән табигать җиңелчә генә зәңгәр өрфия белән өретелгән. Һаваның зәңгәрсулыгы тирә-юньгә сихри төсмер өсти. Кремль диварларына, аяк астындагы чирәмгә, әйләнә-әйләнә үсеп утырган агач-куакларга, кирегә агып яткан Казан-суга илаһилык бөрки кебек. Бу күренешләр Кремлебез капкасына якынлашып килүче Ельцинның ак чәчләренә дә зәңгәрсулык, серлелек салган кебек. Төшереп була торган булса, Россия телевидениe каналы яки кинохроникасы өчен бер дигән тарихи кадр! Янынnан йөгереп үткән ак күлмәкле минем кызга башта ул игътибар да итмәде шикелле, тик бераздан туктады, сабыр гына борылып, уң кулын алга сузды да:

— Бар, сеңелем, бар! Йөгер рәхәтләнеп! Вакыты җиткәч, тагын кая йөгерәсен үзем күрсәтермен! — диде.

Шул ук аз гына алга иелә төшкән олпат гәүдә. Шул ук үз дәрәҗәсен белеп кенә ясалган салмак адымнар. Менә ул ике кулы белән, яшел капкаларны ачып (элек булгандыр ул капкалар, хәзер — юк), ары уза да, эчке якка кереп югала...

Мин бу төштә бүгенгебезгә вә киләчәгебезгә бәйләнешле олы мәгънә күрәм: адашкан җан... Үзәне тарайтылып, ярлары ныгытылган Казан-суның ярсулы агышы. Кирегә — үзенең асылына, чишмә башына омтыла ул. Татарча аталган Казан-су урамы. Уйный-йөгерә Кремль баскычларыннан төшеп барган ак күлмәкле кыз бала. Шул ук баскычлардан аңа каршы менеп килүче олпат гәүдәле ялгыз чит дәүләт патшасы. Ул патшаның ак күлмәкле татар кызчыгына әйткән сүзләре:

— Бар, сеңелем, бар. Йөгер рәхәтләнеп! Вакыты җиткәч... үзем күрсәтермен!

Бу сүзләр минем колакта әле дә набат булып яңгырый...

*Беренче дәфтәр тәмам*

# АЗАТЛЫК КӨРӘШЕНЕҢ МӨНБӘРЕ

*«Яңа милли юл» дөньяның караңгы вә чуалчык юлларында бик күпләренә милли юлын күрсәтә торган Тимер казык йолдызы булып килә алгандыр».*

Гаяз Исхакый

Инкыйлабтан соң чит илләрдә чыккан татарча газета-журналлар арасында «Яңа милли юл» мөхтәрәм урынны алып тора. Ансыз татарның мәдәниятен, милли-азатлык көрәшен һәм, гомумән, тарихын тиешенчә күзаллап та, бәяләп тә булмый. Ул халкыбызның энциклопедиясе, көрәш елъязмасы кебек. Нәкъ менә шуңа күрә дә татар мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүче чит мәмләкәт галимнәре «Яңа милли юл»га еш мөрәҗәгать итәләр, аны, ышанычлы чыганак буларак, бик теләп файдаланалар. Бездә дә соңгы вакытта аннан аерым материаллар укучыларга тәкъдим ителә башлады. Әмма әле, кызганыч ки, укучыларның гына түгел, күпчелек татар белгечләренең дә «Яңа милли юл» хакында күзаллаулары бик тонык. Шуны күздә тотып, без бу мәкаләдә журнал хакында аерым белешмәләр бирергә, кайбер фикерләр әйтергә җөрьәт итәбез.

«Яңа милли юл» мәшһүр әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый исеме белән тыгыз бәйләнешле. Ул бу журналны нигезләүче, аның баш мөхәррире һәм төп авторларыннан берсе. Дөрес, мәҗмуганың 1—19 нчы саннарында журналның «мәсъүл редакторы К. Русак» диелгән. Бу — Гаяз Исхакыйның йә үз кушаматы, яисә рәсми якны күздә тотып куелган башка берәр зат. Чөнки журналны оештыручының һәм тәүге саннарыннан ук аны җитәкләүченең Гаяз Исхакый булуы шөбһәсез. Мәҗмуганы чыгаруга шулай ук баш мөхәррирнең «Учительская школа»дан ук якын дусларыннан берсе булган Гомәр Тәңреколый да (Терегулов) үзеннән зур өлеш кертә.

Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакый 1927—1939 елларда, нигездә, Варшау, Берлин калаларында яши, Ерак Шәрыкка да шул чорда, ягъни 1934—1936 елларда сәяхәт кыла. Бу еллар — эмиграциядәге милли-азатлык һәм сәяси хәрәкәтнең көчәеп, тагын да оешып киткән дәвере. 1928 елның 28 июнендә Варшауда Гаяз Исхакый инициативасы белән Идел-Урал комитеты корыла. Ике елдан соң, ягъни 1930 елда Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Әзәрбәйҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли-азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора.

Бөек әдип фикеренчә, хәзерге заманда матбугатсыз халык телсез, вәхши халык кебек. Иҗтимагый-сәяси көрәштә вакытлы матбугатның ролен шәхси тәҗрибәсендә тирәнтен аңлаган Гаяз Исхакый 1928 елгы Варшау корылтаенда газета-журналлар чыгару бурычын бөтен кискенлеге белән куя. Бер төркем милләттәшләренең матди һәм рухи ярдәме белән ул үзе «Милли юл» мәҗмугасын чыгаруга керешә. Аның беренче саны 1928 елның 23 декабрендә, ә икенчесе 1929 елның 15 гыйнварында дөнья күрә. Журнал 1930 елга кадәр айга ике мәртәбә «Милли юл» исеме белән чыга, ә инде алга табан ул «Яңа милли юл» атамасын ала һәм, кагыйдә буларак, айлык мәҗмугага әверелә. 11 еллап вакыт эчендә журналның барлыгы 136 саны дөнья күрә, шуның берничәсе — куш саннар (1929 — № 20—21, № 22—23; 1933 — № 8—9; 1935 — № 9—10; 1938 — № 8—9...). Текстлар — гарәп графикасында. Тышлык битләрдә латин хәрефендәге сүзләр, атамалар һәм белешмә характерындагы немецчә текстлар да күзгә ташлана. Мәҗмуганың теле татарча. Әмма кырымтатар, төрек һәм кайбер башка төрки телләрдә бирелгән өзекләр, текстлар да бар. Журналның форматы — 24 х 16,5 см.

Күләме — 15 көнгә бер чыкканда — 16 шар бит (куш саннары — 26 битлек), айлык саннары 1930—1932 елларда — 26, ә алга таба, кагыйдә буларак, 32 битлек. Арада 38, 42 битлек саннар да очрый. Мәҗмуга юка тышлыкта.




Журнал, нигездә, Берлинда (Штеглитз, Микведштрассе, 14) нәшер кылына. Аның 1929 елгы 20—21 нче куш санында шушындый белдерү бар: «Мәҗмугамызның башкарма йортын (идарәханәсен) Берлиндан күчерергә туры килде. Әлегә төпле бер башкарма йорт табылганга кадәр «Милли юл» өчен йибәреләчәк акча, хат, мәкалә вә башкаларны түбәндәге адреска йибәреп торуларын бөтен укучыларымыздан үтенәмез» (Биредә Гаяз Исхакыйның Польшадагы адресы күрсәтелә). «К. Русак» исеменең Гаяз Исхакый атамасы белән алышынуы, күрәсең, матди һәм кайбер башка факторлар белән бәйле булса кирәк. Мәҗмуганың 1929—1930 еллардагы берничә саны Варшаудагы ике адрес белән дөнья күрә. Ә инде журналның 1930 елның ноябреннән алып ахырга, ягъни 1939 елның октябренә кадәр чыккан саннары Берлинда (Шарлоттенбург, 1. Постфак № 8) нәшер ителә. Монда гарәп хәрефләре белән китаплар, газета-журналлар чыгаручы «Виктория» дигән махсус нәшрият булуы мәгълүм. Гаяз Исхакыйның «Дулкын эчендә» исемле биш пәрдәлек пьесасы да шунда нәшер ителә (1938). Биредә кайбер башка төрки халыкларның да китаплары, аерым газета-журналлары чыгуы билгеле. (Бу елларда Берлинда мөселман мәчете дә эшли.)

Журналның матди хәле шактый кыен була. Ул чит илләрдәге милләттәшләребез ярдәме хисабына яши һәм шуна да аны Гаяз Исхакый «Милләт баласы» дип атый. Мәҗмуганың 1930 елгы 11 санында мондый белдерү бар: «Финляндиянең хәмиятле (игелекле. — Х. М.) милләтчеләре тарафыннан мәҗмугамызның дәвамына, үсүенә ярдәм өчен, җыйнап җибәрелгән ике йөз доллар акчаларын алдык. Бик зур юклык эчендә, бөтен мәшәкатьләргә чумып алып барган мәҗмугамызның ихтыяҗы бик зурдыр. Аның дәвамы, үсүе берничә фидакарьнең генә җилкәсенә йөкләнергә тиеш түгелдер. Шуны аңлап үзләренең милли бурычларын үти белгән Финляндиянең хәмиятле милләтчеләренә рәхмәтләремезне белдерәмез вә башка йирләргә таралган милли даирәләремезнең дә болардан үрнәк алуларын өмет итеп каламыз («Милли юл» башкармасы)». Журналның 94 нче (1935, № 12) санында да мәҗмуганың ярдәмгә мохтаҗ булуы искәртелә: «Бик күп авырлыклар бирлә үзенең юлын какшатмыйча алып килә торган мәҗмугамызга матди вә мәгънәви ярдәмдә булу — һәр милләтдәшнең вазыйфасыдыр». Кайбер саннар хәтта мәҗмуга хезмәткәрләренең үз көчләре белән үз машиналарында да

жыела. Бер санда, журналның соңга калып чыгуы әйтелә дә, ахырда болай языла: «Мәҗмугамызның бу саны үз көчемез берлә тугдырган үз машинамызда тезелеп, укучыларымызга тәкъдим ителәдер» (1936. № 9). Матди як ничек кенә кыен булмасын, журналның хакы әбүнәчеләр (подписчиклар) өчен әллә ни артык куелмый: бер елга — 3,5, алты айга — 2 доллар.

Мәҗмугадагы материалларның авторлар даирәсе шактый киң һәм төрле. Алар, нигездә, эмиграция нәтиҗәсендә дөньяның төрле почмакларына, аеруча Кытайга, Япониягә, Төркиягә, Финляндиягә, Алманиягә, Ляһстанга (Польшага), Румыйниягә сибелгән татарлар. Авторлар арасында без Сания Гыйффәт, Закир Кадыйри, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Ләбиб Каран кебек билгеле каләм әһелләрен дә, Финляндиянең Вәли Әхмәд Хәким шикелле мәшһүр имамын да, Ерак Шәрык милли хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, «Милли байрак» газетасының мөхәррире Рокыя Мөхәммәдишне, Тампере татарларының мәдәни тормышын оештыручы булган Мәхрүсә Вафаны һәм башкаларны очратабыз. Журнал эшен оештыруга, рәсми хакимият оешмалары белән мөнәсәбәтләрен коруга мәшһүр галим Рәшит Рәхмәти Арат та шактый ярдәм күрсәтә. Мәҗмугада «Котлы Мөхәммәд», «Бикбулат», «Лотфулла угылы», «М. Уфа» кебек исемнәр белән басылган мәкаләләр дә байтак.

Журналдагы шактый күп санлы материал Гаяз Исхакыйның үз тарафыннан язылган. Һәр санда диярлек баш мөхәррирнең берәр, хәтта икешәр мәкаләсе очрый. Алар, нигездә, күләмле, саллы, баш мәкалә рәвешендә бирелгән. Аерым материаллар да, гәрчә аларның авторлары конкрет күрсәтелмәсә дә яисә кушаматлар белән бирелсә дә, Гаяз Исхакый каләменә карый. Моны бу мәкаләләрнең тел-стиле, фикерләү рәвеше ачык күрсәтеп тора. Кыскасы, «Яңа милли юл» журналын Гаяз Исхакыйның милли-азатлык өчен көрәш мөнбәре, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни эшчәнлегенең елъязмасы дип тә атарга мөмкин.

* * *

Ә соң мәҗмуганың идея-тематикасы, эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Әйткәнебезчә, 11 еллап вакыт эчендә журналның 136 саны дөнья күрә. Бу — якынча 4 мең бит дигән сүз. Шуңа күрә бу кадәр зур күләмле һәм төрле характердагы, эчтәлектәге материаллар хакында тәфсильле фикер йөртү бу очракта мөмкин дә түгел. Сүз бары тик журналның төп юнәлеше, үзәк тематикасы, төп рубрикалары, кайбер бүтән мөһимрәк яклары хакында гына барырга мөмкин.

«Милли юл»... «Яңа милли юл»... Бу атамалар үзләре үк мәҗмуганың төп юнәлешен күрсәтеп торалар. Милли тарих, халык язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге — менә журналның гомуми тематикасы. Мәҗмуга — милли тормыш агышын, аңа мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләрне гадәти теркәүче, гәүдәләндерүче генә түгел, ә милләтнең алга барыр юлын билгеләүче, яктыртучы, оештыручы көч тә. Журнал исеменең «Милли юл»дан «Яңа милли юл»га әйләнүе дә очраклы түгел. Яңа вазгыять, яңа халыкара шартлар төрки-татар язмышына яңачарак якын килүне, аның барыр юлын ачыграк, максатны конкретрак куюны таләп итә. Төп максат — милләтләрнең азатлыгы, тигезлеге өчен көрәш, һәр халыкның үзенең бәйсез дәүләтен төзү. Журналның 1933 ел 10 санында Спинозаның мондый сүзләре теркәлгән: «Ирек — бер көч димәктер. Бу көч һәр халыкның үзен-үзе саклау, үзен-үзе үстерү көче; боңа (моңа.— Х. М.) һәрбер мәхлук та (җан иясе дә.— Х. М.) табигате илә омтыла».

Мәҗмуга битләрендә һәм төркестанлыларның, һәм украиннарның, һәм кавказлыларның, һәм күп кенә башка халыкларның азатлык, бәйсезлек өчен көрәше эзлекле рәвештә яклана; барың да хөр булганда гына мөстәкыйль дәүләтчелеккә ирешү мөмкинлеге күрсәтелә. Мәҗмуганың тышлыгында еш кына «Ирекле ил уен таратучы журнал» дигән сүзләр очрый. Бу — гадәти лозунг кына түгел, ә текстларның эчтәлеге, рухы белән ярашкан төп идея дә.

«Яңа милли юл» журналының һәр санында диярлек тышлыкта түбәндәге сүзләр язылган: «Идел-Уралның истикъляльна (азатлыгына.— Х. М.) хезмәт итүче, илнең һәм халыкның матди вә мәгънәви барлыгы һәм аның киләчәге тугрындагы фикерләрне эченә алган һәрбер язма өчен мәҗмуга битләре һәркемгә ачык». Журналда Идел-Урал, «Идегәй» дастанындагы кебек, татар дәүләте, Идел-йорт рәвешендә күзаллана, аның бәйсезлек яулап алуы, мөстәкыйль тормыш коруы бөтен эшчәнлекнең, көрәшнең асыл максаты итеп күрсәтелә. Әмма әле чынбарлык башка: «Идел-Урал, татар халкы Мәскәү хакимияте, Сталин режимы астында. Бу хәл журналның тышлык рәсеме белән дә искәртелә: «Идел-

Урал» хәритәсе (картасы)*, ә ул зинданда, читлек эчендә. «Яңа милли юл» сүзләрендәге «л» хәрефенең озын сызыклары нәкъ әнә шундый символик мәгънә тудыруга ярдәм итәләр дә.

Шулай итеп, мәҗмугадагы материалларның сайланышы, урнаштырылышы, идея-тематикасы, иң беренче чиратта, халкыбызның барыр юлы, бүгенгесе һәм үткәне, милли бәйсезлек, мөстәкыйльлек өчен көрәше белән бәйле.

Журналның һәр санында диярлек агымдагы халыкара хәлгә күзәтү бирелә һәм шул контекстта төрки-татар язмышы карала. Бу төр мәкаләләргә (алар, нигездә, баш мөхәррир тарафыннан язылган) киң колач, фикер тирәнлеге, көчле публицистик аһәң хас.

Мәскәү хакимияте, аның кул астындагы матбугат органнары дөнья җәмәгатьчелегенә илдәге объектив хәл, аеруча милләтләр язмышы хакында берьяклы хәбәр бирү белән генә чикләнә. Әмма шуңа да карамастан, «Яңа милли юл», бар булган рәсми, басма (бигрәк тә төрки җөмһүриятләрдәге) мәгълүматларны җентекле тикшереп, СССРдагы әхвәл, төрки-татарларның хәле турында даими рәвештә материаллар биреп килә. Аларда совет хакимиятенең урыслаштыру сәясәте, халыкның диненә, тарихи хәтеренә каршы көрәше, ә3әрлекләү эш-гамәлләре кискен тәнкыйтьләнә. «Дин вә милләт,— диелә бер мәкаләдә,— халкымызның большевиклар дәверенә кадәр иң мөкаддәс дип белгән рухи барлыгы иде, һәм шуның берлә ул үзен 300 елдан артык саклады, киләчәккә өмидне әзмичә яши иде. Бүген дин вә милләт большевикларның иң курыккан каршылыгы булып тора» (1935. № 2. 2 б). Шул ук санда без «совет статистикасының ышанычсыз» булуы (11 б.), уку йортларында «урыс тарихы»ның гына өйрәнелүе (15 б.) һәм башка шундый тәнкыйди фикерләр белән дә очрашабыз.

Журнал төрки-татар халкының күренекле уллары хакында да материаллар биреп бара. Мәсәлән, мәҗмуганың 1933 елгы дүртенче саны Исмәгыйль Гаспралының, Габдулла Тукайның үлемнәренә 20, «Тәрҗеман»ның чыга башлавына 50 ел тулуга багышланган. Гаять тирән эчтәлекле, суретләргә, мәгълүматларга бай сан! Журналның 1936 елгы июль-август саннары (№ 7—8) тулысы белән Риза Фәхретдин хакында. Шулай ук «Яңа милли юл»да Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдерәшит Ибраһим, Йосыф Акчура, Фуад Туктар һәм татарның башка олуг затлары турында да мәгълүматлар шактый. Шунысы мөһим: аларның эшчәнлеге заманга, милли үсеш перспективасына нисбәтән карала. Мәсәлән, Мәрҗанинең тууы халкыбыз өчен кояш чыгу белән чагыштырыла. Аның «милли-дини ачык фикерле төшенчәләре,— диелә бер мәкаләдә,— бүген мең бер төрле авырлык эчендә яши торган халкымызга золымның чиген белмәгән дошманга каршылык күрсәтү өчен кирәкле булган гамәлләрнең берседер... Мәрҗани хәзрәтнең соңгысыз («үлмәс» мәгънәсендә.— Х. М.) хезмәтләрендән илһам алып, аның безгә калдырып киткән милли-дини иманыннан куәт алып, бүгенге көндәге һичбер нәрсәдән өрекмичә, башка дин вә милләт кардәшләремез берлә бергә үземезнең милли вә сәяси корытылышымызны таләп итәбез» (1935. № 12. 3 б.). Риза Фәхретдиннең тарихи ролен билгеләп, Гаяз Исхакый болай яза: «Риза хәзрәт безнең Идел-Урал дәүләтенең мөстәкыйль яшәве өчен кирәк булган иң зур гамәлләрнең берсе булган мәдәни истикъляльлымызны (бәйсезлегебезне.— Х. М.) ныгыткан вә безнең киләчәк мөстәкыйль дәүләтемезнең төп баганаларын вакытзаманның какшатуындан, урыс-улакның (чапкынының; баскынының.— Х. М.) җимерү-ватуындан сакларлык хәлгә китерергә иҗтиһад (тырышлык.— Х. М.) иткәндер» (1936. № 7—8. 4 б.).

«Яңа милли юл» халык тарихындагы, мәдәниятендәге истәлекле вакыйгаларны даими рәвештә яктыртып тора. Мәсәлән, журналның 1938 елгы өченче саны тулысы белән «Милләт мәҗлесенең егерме еллыгына багышлап» чыгарылган. Анда 1917—1918 елгы тарихи вакыйгаларга анализ ясала, «Милләт мәҗлесе»нең халык язмышындагы, барыр юлындагы әһәмияте күрсәтелә. Билгеле булганча, бу юбилей уңае белән 1938 елда Варшауда Бөтендөнья төрки-татар корылтае уздырыла. Журналның бу санында юбилей хакында бай материаллар урнаштырылган. Алар арасында Гаяз Исхакыйның Варшау радиосыннан алтынчы февральдә ясаган чыгыш тексты да бар.

Мәҗмугадагы бер өлеш мәкаләләр чит мәмләкәтләрдәге татарлар, аларның иҗтимагый вә мәдәни хәлләре хакында. Бу юнәлештә аеруча Финляндиядә һәм Ерак Шәрыкта яшәүче милләттәшләребезнең тормышы киң яктыртыла. Мәсәлән, бер хәбәрдә (1937. № 4. 9—11 бб.) 1937 елның 22 гыйнварында Нагоя

---

* Г. Исхакыйның «Идел-Урал» китабы 30 нчы елларда татар, урыс, француз, поляк, япун телләрендә чыгарыла.

каласында яңа мәчет вә мәктәп ачылу тантанасы хакында сүз бара. Шунысы кызыклы: күп санлы милләттәшләребез һәм Япония рәсми кешеләре катнашкан бу кичә татар телендә уздырыла. Аерым якташларыбыз япон телендә дә сөйлиләр. Бу истәлекле вакыйганы Япония матбугаты да игътибардан читтә калдырмый.

Журналда әдәби материалларга да урын бирелгән. Анда без фольклор, классик шигърият үрнәкләре белән очрашабыз. Күпчелек әдәби текстлар Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Мансур Арысланбәк һәм кайбер башка мөһаҗир татарларга нисбәтле. Күләмле әдәби әсәрләр күзгә ташланмый. Мәҗмуга шулай ук татарларның һәм гомумән төрки халыкларның мәдәният тарихына мөнәсәбәтле мөһим язма истәлекләр хакында да мәгълүматлар биреп бара («Олуг Мөхәммәд ханның солтан Морадка язган мәктүбе», «Ибне Батутаның Алтын Урда хакында биргән мәгълүматы» һ. б.).

Тугандаш төркестанлылар, кырымлылар, төрекләр һәм башка халыкларның тормышын яктырту — журналның даими рубрикасы. Еш кына аларның чит мәмләкәтләрдә чыккан вакытлы матбугатына күзәтүләр бирелә. Мәсәлән, кырымтатар телендәге «Әмәл» журналына (Ул Румыйниянең Күстәнҗә каласында айга бер мәртәбә чыга. Әүвәл гарәп хәрефләре белән, 1939 елдан — латин), «Истикъляль» газетасына («Милли Әзербәйҗан истикъляль фикерен таратучы, айга өч тапкыр латин хәрефләре берлә Берлинда чыга»), Франциядәге айлык «Яшь Төркестан» журналына һ. б. басмаларга күзәтүләр ясый.

Билгеле булганча, 1935 елның 1 ноябреннән Мукден каласында «Милли байрак» исемле атналык татарча газета чыга башлый (гарәп графикасындагы бу басма 1945 елның урталарына кадәр нәшер кылына. Барлыгы 440 саны дөнья күрә)[1]. Аны оештыручы, нигезләүче дә — Гаяз Исхакый. Һәм «Милли байрак», һәм «Яңа милли юл» үзләренең мәсләкләре, рухлары белән үзара бик якын. Шуңа күрә алар бер-берсенә еш урын бирешеп торалар. Мәсәлән, «Яңа милли юл»да (1935. № 12.) «Милли байрак»ның беренче санына җентекле күзәтү урнаштырылган, Гаяз Исхакый тарафыннан язылган «Максадымыз», мөхәррир Оркыя Мөхәммәдиш һәм кайбер башка авторларның мәкаләләре дә шактый тулы бирелгән. Мәҗмугада татарча чыккан бүтән газета-журналларга да күзәтүләр очрый. «Яңа милли юл» (аны, кыскалык өчен, еш кына «Милли юл» дип тә йөртәләр), чит мәмләкәтләрдәге татар матбугатын, иҗтимагый хәрәкәтен рухи яктан житәкләүче көч буларак, газета-журналларга үзенең киңәш-тәкъдимнәрен дә белдерә, аларның уңай башлангычларын хуплый. Мәсәлән, Мукденда 1935 елның декабреннән башлап «Шәкердләр таңы» исемле «төрек-татар шәкердләренә ана телен онытдырмау вә аны тәрәккый итдерүче айлык мәҗмуга» нәшер кылына. «Яңа милли юл» бу журналны ике еллыгы белән котлый, аның шәкертләрне, балаларны милли рухта тәрбияләүгә өлеш кертүен билгеләп үтә (1938. № 2. 27 б.).

«Яңа милли юл» чит ил галимнәренең төрки-татарга мөнәсәбәтле хезмәтләрен дә үз укучыларына тәкъдим итеп бара. Менә журналның 1937 елгы беренче саны. Анда алман галиме Г. Менденың «Русия төркиләренең милли көрәшләре» исемле немец телендәге хезмәтенә кыскача күзәтү ясала һәм ахырда мондый фикер әйтелә: Ул (ягъни бу китап. — Х. М.) «милли аңымызның үсүен вә милли көрәшемезнең төрле дәверләрен тасвир итеп, милли таләпләремезнең нидән гыйбрәт булуын аңлаткан гыйльми бер китап...» Бу хезмәт «алманча белгән һәр кешенең өстәлендә булырга тиеш».

Мәҗмугада татарча, төркичә яңа чыккан китаплар хакында күпләгән мәгълүматлар табарга мөмкин. Мәсәлән: Финляндиядә Сания Гыйффәтнең «Тормыш көзгесе» исемле 4 пәрдәлек драма әсәре басылды. Анда илдәге халыкның авыр язмышы күрсәтелә (1937. № 7); Мукденда «Төрек-татар әлифбасы» дөнья күрде (1935, № 12) һ. б.

Журналда, гәрчә күп булмаса да, аерым сурәтләр, фоторәсемнәр һәм төрле иллюстратив материаллар да бар. Мәсәлән, Нагояда төзелгән татар мәчете; «Милләт мәҗлесе»нең 20 еллыгыннан фоторепортаж; Варшаудагы Тукай кичәсе; Ризаэддин Фәхретдинов хатларының күчермәләре һ. б. Мәҗмуга тышлыгында еш кына күренекле каләм әһелләренең рәсемнәре урын алган, Габдулла Тукай (1931. № 4), Йосыф Акчура (1935. № 6), Исмәгыйль Гаспралы (1931. № 6), Кырым халык шагыйре Мөхәммәд Ниязи бәк (1931. № 11), Муса Акъегетзадә (1931. №

[1] Карагыз: Х. Миңнегулов. «Бер ана йортының балалары...» («Милли байрак» газетасының беренче саны турында) (Татарстан яшьләре. 1990. 27 декабрь.) Шунысын да искәртик: Гаяз Исхакый 1953 елда Мюнхендә «Милли байрак» исемле журнал да чыгарырга ниятли. Әмма, авыру сәбәпле, тиз арада Төркиягә кайтып китәргә мәҗбүр була.

11), Габдерәшит Ибраһим... (1931. № 12), Ризаэддин Фәхретдин (1936. № 6) һ. б. Журналның 1931 елгы дүртенче санын Сөембикә манарасы да бизәп тора.

Журналның 1931 елгы җиденче-тугызынчы саннарының тышлыгында күрер күзгә бик күркәм сурәтләр бар. Аларның берсе «Ляһстанда (Польшада.— Х. М.) татар атлы гаскәре» (1660 ел) дип исемләнгән. Анда атка атланган бер яшь, чибәр татар гаскәрие тора. Икенчесе — «Наполеонның татар гвардиясе». Өченчесе — «Татар сугышчысы» (XIV йөз). Һәр өч сурәт тә «Ляһстан мөселманларының милли музәханәләрендән алынган».

Мәҗмуганың тышлыгы хакында сүз барганда янә бер хосусияткә игътибар итү зарури. Аның күп саннарында яшәеш, милләт, бәйсезлек, көрәш, бердәмлек, белем турында гыйбрәтле сүзләр, афористик фикерләр теркәлгән. Эпиграф ролендәге бу текстлар журналның эчтәлеге, рухы, төп юнәлеше белән ярашып, керешеп торалар, билгеле бер дәрәҗәдә мәҗмуганың «визитка» вазыйфасын да үтиләр. Мәсәлән, «Милләт мәҗлесе»нең 20 еллыгына багышланган махсус санның тышлыгында Г. Тукайның «Өмид» шигыреннән «Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә»,— дип башланган дүрт юлы язылган. Тышлыктагы өземтәләрнең шактый өлеше Р. Фәхретдингә, Ш. Мәрҗанигә, К. Насыйрига, Й. Акчурага, Г. Тукайга мөнәсәбәтле. Ә инде кайберләренең авторлары күрсәтелмәгән.

Журналның теле, нигездә,— инкыйлабка кадәрге татар язма теле. Совет чорында безнең телебезгә күпләп кергән урыс сүзләре мәҗмуга текстларында сирәк очрый. Ә инде гарәп-фарсы алынмалары, киресенчә, күп. Төрек теленең йогынтысы көчле. Көнбатыш Европа телләреннән турыдан-туры яисә төрек аркылы алынган сүзләр дә күзгә ташлана (обжиктиф — объектив, култур — культура, паник — паника, групп — группа, программ — программа, комитә — комитет һ. б.). Хәзер безнең телебездә элек актив кулланылып, аннан «иске» дип читтә калдырылган сүзләрне, гыйбарәләрне кабат әйләнешкә кертү бара. Бу процесста «Яңа милли юл» һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдәге вакытлы матбугат, басма сүз теленә мөрәҗәгать итү зыян итмәс иде. Тагын шунысы бар: авторлар, аеруча Гаяз Исхакый, гәрчә алар Идел-йорттан читтә яшәсәләр дә, татар теленең шивәләреннән шактый мул файдаланалар... Үкенеч ки, СССР-Германия пакты һәм Икенче бөтендөнья сугышы башлану нәтиҗәсендә милләт өчен игелекле эшләр алып барган «Яңа милли юл» журналы 1939 елда эшен туктатырга мәҗбүр була. Аның хезмәткәрләре төрле якларга тарала. Баш мөхәррире Лондонда һәм Парижда бераз яши дә аннан Төркиягә күчеп китә.

* * *

«Яңа милли юл» рәсми рәвештә «сәяси, әдәби, гыйльми, икътисади, милли мәҗмуга» дип йөртелгән. Аның эчтәлеген, идея-тематикасын кыскача гына күзәтү дә бу сүзләрнең чынбарлыкка туры килүен ачык күрсәтеп тора.

Журнал ябыла. Әмма ул башкарган эшләр, ул салышкан милли-азатлык юлы өзелеп калмады. Гаяз Исхакыйның үзе, аның көрәштәшләре, варислары тарафыннан дәвам иттерелде һәм иттерелә. Алар арасында Гали Акыш, Тимербәк Дәүләтшин, Надир Дәүләт, Рифат Тәби кебек чит илләрдәге милләттәшләребезне дә, Идел-йорттагы күп санлы иҗтимагый-сәяси эшлеклеләрне һәм аерым каләм әһелләрен дә күрсәтергә мөмкин.

«Яңа милли юл» үз чорының, читтәге милләттәшләрнең мәнфәгатьләрен генә түгел, ә бөтен татар халкын, аның киләчәген күздә тотып та эшләде. Мәҗмуганың баш мөхәррире 1938 елда болай дип язган иде: «...Милли юл»ның эшләрен, үзе ышанып күтәргән милли байрагының вакытлы булу-булмавын киләчәгемез күрсәтәчәк вә киләчәк буыныймыз гына аның хезмәтләренә дә, эшләренә дә бәһане бирә беләчәкләр» (1938. № 1. 1 б.). Хәзерге югарылыктан «Яңа милли юл» алып барган эшнең бөеклеге, тарихи әһәмияте чыннан да ныграк та, ачыграк та күренә. Империяләр җимерелә, халыкларның ирек, милли-бәйсезлек өчен көрәше дәвам итә. Бу — табигый канун. Аны бернинди көч тә туктата алмый.

Гаяз Исхакый, аның фикердәшләре хыялланган, үз эшчәнлекләренең асыл максаты итеп куйган азатлык, бәйсезлек татар халкы тормышында бүген гамәли төс ала бара.

Узган ел халкыбызның бөтен дөнья корылтае булды, Милли мәҗлес сайланды. Идел-Урал буе халыкларының конфедерациясен төзү дә яңадан көн тәртибенә килеп басты.

«Яңа милли юл»ның 1932 елгы икенче санында титул биттә мондый юллар бар: «Бер милләтне юк иткән нәрсә — ул милләтнең үз-үзенә булган ышанычының югалуыдыр». Гаяз Исхакый һәм аның көрәштәшләре бу яктан безгә үрнәк булып торырлык. Алар нинди генә кыен хәлләрдә калсалар да, киләчәккә өмет-ышанычларын саклаганнар, милли-азатлык көрәшен дәвам иткәннәр, милләт каршындагы үзләренең изге бурычларын булдыра алган кадәр үтәгәннәр. Үләренә өч көн кала Гаяз Исхакый үзенең ышанычлы ярдәмчесе Гали Акышка: «Мин төрек-татар халкының иреге өчен бөтен гомерем буена көрәштем... Тәңре сезләргә ватаныбыз Идел-Урал азатлыгын күрергә насыйп итсен»,— дигән сүзләрне әйтеп калдыра.

«Яңа милли юл»,— бер яктан, тарихны, милли-азатлык хәрәкәтен өйрәнүдә мөһим чыганак. Икенче яктан, журналдагы күп кенә фикерләр, аның юнәлеше бүгенге иҗтимагый, сәяси һәм мәдәни хәрәкәткә, милли тәрбиягә аваздаш. Шуңа күрә аны ныграк өйрәнү, андагы материалларны укучыларга мөмкин кадәр тизрәк, тулырак җиткерү зарури. Җөмһүриятебезнең Милли китапханәсендә «Яңа милли юл» журналының һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдә басылган татарча газета-журналларны, китапларны туплау, булдыру һәм алардагы материалларның библиографиясен төзү шарт. Әрмәннәр, грузиннар, таҗиклар һәм элеккеге СССРдагы кайбер башка халыклар моны инде күптән эшләде.

Журнал укучыларга без «Яңа милли юл»дан берничә материал тәкъдим итәбез. Аларның берсе — мәҗмуга тышындагы өземтәләрдән кайбер үрнәкләр. Икенчесе — Гаяз Исхакыйның «Унынчы елымыз» дигән мәкаләсе. Бу материал журналның төп мәсләген, рухын, эшендәге кыенлыкларын ачык күрсәтә һәм мәҗмуга хакындагы безнең мәкаләне, күзаллауларыбызны тагын да тулыландыра, тирәнәйтә төшә. Өченче материал Ризаэтдин Фәхретдиннең үлеме уңае белән язылган. Анда Гаяз Исхакыйның бу бөек затка, «милли каһарман»га мөнәсәбәте, Риза казыйның мәдәният тарихындагы, милли хәрәкәттәге роле ачык чагыла. Мәкалә авторы татар халкының төрки дөньяда тоткан тарихи урыны хакында да гаять кызыклы фикерләр әйтә. Соңгы материал — ул елларда Шанхайда яшәгән һәм иҗат иткән Мансур Арысланбәкнең[1] «Милли намаз» шигыре. Дөрес, бу әсәрдә кайбер шигъри җитешсезлекләр бар. Әмма ул 1905—1907, 1917—1918 еллардагы әдәби традицияләрне дәвам итү һәм милли көрәш, азатлык рухын калку гәүдәләндерүе белән игътибарга лаек. Әлбәттә, бу материалларда һәм гомумән «Яңа милли юл»да бәхәсле яклар, аерым кимчелекләр дә бар. Әмма без аларга тарихи факт, күренеш итеп табигый рәвештә карарга тиешбез. Кабул итү һәм бәяләү дә шактый дәрәҗәдә укучыларның хәзерлегенә һәм зәвык-ихтыяҗларының, мәнфәгатьләренең үзенчәлегенә бәйле.

Текстларны, нигездә, оригиналдагы язылу рәвешләрен саклап бирергә тырыштык.

Шәт, алла боерса, әгәр дә журнал укучылары кирәк дип тапса, «Яңа милли юл»дан һәм читтәге мәмләкәтләрдәге кайбер башка газета-мәҗмугалардан, китаплардан да аерым материаллар тәкъдим итәрбез.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
филология фәннәре докторы.

[1] Сугыштан соң, нигездә, Төркиядә яши һәм 1978 елның 20 апрелендә шунда ук вафат була.

# «Яңа милли юл» журналының тышлыгындагы кайбер эпиграфлар

«Ил ул — халыкның үтмешеннән калган, бу көнгесенә корылган, киләчәге өчен сакланган бер барлыкның учагы» (1932. № 3).

Күк булып күкрәр һавада хәр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары...

**Габдулла Тукай** (1932. № 5)

«Таланган халык, изелгән ил синең ярдәмеңне көтә. Илнең ирке өчен көрәшүчеләр сафына кер. Аларның эшләрен ныгыт!» (1932. № 7)

Алга, туган, алга! Җиңгәнгәчә,
Ил юлында тиңсез тартышка!
Бергә, туган, бергә! Үлгәнгәчә
Ирек өчен изге тартышта!

Ирек сөйгән батыр бабайларның
Сөякләре әле чермәгән.
Күңелләрне яккан ирек уты
Йөрәкләрдә әле сүнмәгән!

Ил юлында канлы тартыш өчен
Алган кылыч мәңге ташланмас.
Иркен алган изге туган илнең
Коллык көне тагын башланмас!

(«Ирек җыры» дип исемләнгән бу текст журналның 1932 елгы 7—10 нчы саннарында строфалап бүлеп-бүлеп бирелгән).

«Илсез халык юк; халыксыз ил юк. Ил берлә халык берләшеп, аерылмаслык бер бөтенлек ясаганда гына тормышны корып була. Онытма: Син кем? Синең илең кайда?!» (1932. № 11).

«Халкың бүгенге коллыкда калмаячагына, аның күтәреләчәгенә һәм ямьле киләчәгенә ышан да, бу — син тырышкан чакта гына була алачак итеп эшлә. Онытма: эшнең булып-булмавында син дә мәсъүл! (җаваплы.— Х. М.)» (1932. № 12).

«Милли берлек һәм милли парлык мәсьәләләре — болар һичбер вакыт икенче урынга калдырыла торган мәсьәләләр түгел».

**Гыйсмәт паша.** (1933. № 2)

Авыру, азабдагы ул илләрнең
Сөякләре сыкрый, сызлана;
Йөз еллардан бирле ирек юлын
Йөрәкләре каиный, эзләнә.

**Сания Гыйффәт** (1933. № 3)

«Тарихны тормыш яза. Син дә үз өлешеңне яздырырга онытма!» (1933. № 5)

«Илле ел элгәре башланган «телдә, фикердә, эшдә берлек!»нең мәгънәсе бүгенге көндә «сәясәтдә берлек! димәктер».

**Гаяз Исхакый** (1933. № 6)

«Узган көн кире кайтмый. Югалган һәрбер көн киләчәктә бер бушлык тудырачак» (1933. № 7).

«Бер милләтнең көче — бер үк теләккә, бер үк юл берлә баруда! (1933.— 8—9).

«Кеше өчен иң гүзәл юаныч — мотала́гә (уку, өйрәнү.— Х. М.), иң яхшы иптәш — китаплар».

**Ш. Сами** (1937. № 1)

«Бәгъзе бер күтелмәгән кебек нәрсәләргә гаҗәп итеп вә ис китеп торулар дөнья китабыны күрмәү сәбәбендәдер. Дөнья китабыны моталәгә кылучылар (укучылар, өйрәнүчеләр.— Х. М.) өчен дөньяда булган эшләрнең һәрбере гади вә табигый хадисәләрдәндер (вакыйга-хәлләрдәндер.— Х. М.)».

**Ризаэддин Фәхреддин** (1937. № 6)

«Хакыйкатькә мөстәнәд булган (нигезләнгән.— Х. М.) фикер шулкадәр куәтледер ки, миллионнарча акчаның, йөз меңнәрчә гаскәрнең, туп вә мылтыкларның көче йитмәгән нәрсәләргә аның көче йитә. Фикерсез миллионнарча кешенең хәйран булган мәсьәләсене фикерле бер кеше хәл итә, фикерсез миллионнарча

кешене фикерле бер кеше җиңеп, аларны башка юлга кертә. Шуның өчен дә һәркем ул гали (бөек; хак.— Х. М.) фикерне тәгъзыйм вә аңа хөрмәт итә».

**Ризаэддин Фәхреддин** (1937. № 9)

«Төрки барның күрке бар дигәндәй, мин үзем саф төрки телен яратам».

**Каюм Насыйри** (1937. № 10)

«Бу дөньяга килеп тереклек кыйлудан максуд (максат.— Х. М.) ни нәрсә,— аны белдермәк кирәк. Тәрбиянең башы — ошбудыр».

**Каюм Насыйри.** (1937. № 11).

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә,
Син дә, вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.
Юк, түбән калмас бу җан: фитърәтдә гали[1] булган ул,
Кисмәк өстендә — кара кош иттифакый[2] кунган ул!

**Габдулла Тукай** (1938. № 3)

## 10 нчы елыбыз

*(Яңа милли юл. 1938. № 1 (118). 1—5 бб.)*

Бу санымыз берлә «Милли юл» үзенең унынчы яшенә аяк басадыр. Вә артында калдырган тукыз еллык эш йөге берлә бергә киләчәк елгы милли хезмәтенә керәдер. Бүген без тукыз ел эчендәге «Милли юл»ның эшләрен тикшерергә, аның шул кыска гомерендәге хезмәтләрендән хисап бирергә теләмимез, аның эшләгән эшләре, милли тормышымызда калдырган эзләре хакында сүз сөйләүнең әле вакыты да түгел, урыны да түгел. Аның күтәргән милли байрагы бүгенге мөһаҗәрәтемезнең (күчкән кешеләребезнең.— Х. М.) вакытлы мәсьәләсе генә булмаенча, бөтен Идел-Урал төрек-татарының киләчәге мәсьәләсе булганга, аңа кыйммәт бирергә, бәһа бирергә бүгенге мөһаҗәрәтемез тулы көенчә сәлахийатдар (әзер; компетентлы.— Х. М.) да түгел. «Милли юл»ның эшләрен, аның үзе ышанып күтәргән милли байрагының вакытлы булу-булмавын киләчәгемез күрсәтәчәк вә киләчәк буыныбыз гына аның хезмәтләренә дә, эшләренә дә бәһаны бирә беләчәкдер. Без, «Милли юл»ны тугдыручылар, дәвам итдерүчеләр, «Милли юл»ның фикерен киң катлавымызга таратырга тиеш диеб ышанучылар, үземезнең көчемез, куәтемез ирек биргән кадәр шул юлга тукыз ел хезмәт иткән кеби, унынчы елында да шул милли эшкә җигеләмез. 11 нче, 12 нче елларымызны да күздә тотып, шуны дәвам итдерүне дә милли бурыч санап, һәрбер авырлык алдында вазыйфамызның башында булырга хәзер торамыз. «Милли юл» мәҗмугасы чыгарыла башлаганда без милли эшемезнең киң планыны корып, мөһаҗәрәтемезне үзенең мәгънәви тормышында тирә-юнендән мөстәгъни (хаҗәтсез; бәйсез.— Х. М.) итүне, мөһаҗәрәтемез өчен кирәкле (2) булган мәгънәви азыкларны тәэмин итүне күздә тоткан, киң рәвешдә милли нәшрият эшемезне алып баруны төшенгән идек. Ләкин мөһаҗәрәтемезнең җәгърафый якдан бик таркау булуы, рәсмән (рәсми рәвештә.— Х. М.) оешмаган хәлдәлеге, иске мөһаҗирлек ганганәсе (гадәте, традициясе.— Х. М.) вә андан калган һичбер матди-мәгънәви мирасларның булмавы безгә үземезнең эш планымызны теләгәнемез рәвешдә киң итеп алып барырга мөсагадә итмәде (мөмкинлек бирмәде.— Х. М.). Без милли вазыйфамызның форсаты кадәресен генә барлы-юклы көчемез берлә үтәп, милли хезмәтемезнең вәҗибларын (бурычларын.— Х. М.), соннәтиләрен (традицияләрен.— Х. М.), мөстәҗибләрен (үтенечләрен канәгатьләндерүне.— Х. М.) — барысын да киләчәк форсатка калдырып килергә мәҗбүр булдык. Бу эшләрдәге кимчелекләремез, йитешсезлекләремез «Милли юл»ның яшәеш шараитындан (шартларыннан.— Х. М.) килеп чыккан обжиктиф (объектив.— Х. М.) манигъләр (киртәләр.— Х. М.) булганга, киләчәк буыныбыз «Милли юл» хакында фикерен йөреткәндә, әлбәттә, бу юксыллыкларыбызны күзендән ерак тотмас.

«Милли юл» үзенең милли эшләре өчен, тел, тарих, культур, дин ягындан кардәш берәр мәмләкәтдә оя була алмады, истикъляллэрын кулда иткән кандашларымыз арасында арка таяначак бер агым таба алмады[3]. Бөтен эшен, бөтен авырлыгын үз өстенә генә йөкләде. Зиһният ягындан да (фикри яктан да.— Х.

[1] Фитърәтдә гали — тугмыштан олы (Х. М.).
[2] Иттифакый — очраклы гына (Х. М.).
[3] Монда, әлбәттә, иң беренче чиратта Төркия күз уңында тотыла (Х. М.).

М.), техник ягыннан да тәмамән башка Аурупа өлкәләренә сыгынырга мәҗбүр ителүемез бу йитешсезлекләремездә бик зур роль уйнады. Шуңарга күрә бүген кулда ителгән бөтен барлыкларымыз барысы да үземезнең көчемез, үземезнең Идел-Урал төрек-татарларының матди-мәгънәви ярдәмләре берлә генә вөҗүдкә килгәндер. Үзенең тукыз еллык авыр юлын үтешендә «Милли юл» фәкать үзенең илдәшләренә генә мәдъюн (бурычлы.—Х. М.) калгандыр. «Милли юл» милләтнең генә баласыдыр. Дөньяның дүрт тарафына таралган илдәшләремезнең мөһаҗәрәт тормышы-тартышында бик авыр вазгыятьләрдә яшәгән милләтдәшләремезнең вакыт (вакты.—Х. М.) форсат булып, «Милли юл»га матди-мәгънәви ярдәмгә йитешүе үзе үк «Милли юл»ның мөһаҗәрәтемез алдында кыйммәтене күрсәтә торган вакыйгадыр. «Милли юл» байрагының халкымызның күңеленә үз икәнлеген исбат итә торган җанлы бер дәлилдер. Халкымызның үзенең үзлеген сакларга, үзенең барлыгын, берлеген нинди авырлык эчендә югалтмаска тырышуыны күрсәтә торган, үзенең теләген гәүдәләндерергә омтыла торган бер көч икәнене исбат итә торган сөенечле бер вакыйгадыр. «Милли юл» үзе дә язулары вә фикере берлә, шөбһәсез, халкымызның аерым-аерым шәхесләренең, групп(а)ларының җил кайдан килсә, шунда таба оча торган бер тузан халендән чыгып, милли гәүдәләнүенә сәбәп булгандыр. Дөньяның караңгы вә чуалчык юлларында бик күпләренә милли юлын күрсәтә торган (3) Тимер казык йолдызы булып килә алгандыр. Җәгърафый таркау, мәгънән (мәгънәви.—Х. М.) оешмаган милләт балаларымызда оешу, берләшү фикеренең үсүенә, киңәюенә, тирәнәюенә сәбәп булгандыр вә бөтен мөһаҗәрәтемезнең милли байрак әтрафында тупланып, милли хәрәкәтемезнең еллар үткән саен үсә килеп, гәүдәләнеп, бер милли байрак булып җитеп, сәяси бер кыйммәткә хаиз (ия.—Х. М.) булуына ярдәм иткәндер. Тукыз елда сәяси бер көч итеп хәзерләп җиткергәндер.

Телсез кешенең фикерен, уен аңлап булмаган кеби, матбугатсыз халык да үзенең теләген, омтылышын беркемгә дә аңлата алмыйдыр. Үзе ни кадәр үзлегенә баглы халык булса да, милли матбугаты булмаган халык тирә-юнендән хөрмәт күрә алмаенча, өченче, дүртенче дәрәҗәдә вәхши халыклар исәбенә индереләдер вә аның берлә беркем дә хисаплашуны кирәкле тапмыйдыр. «Милли юл» мөһаҗәрәтемезнең тәрҗеман әфкяре дә (бередә «фикри яктан аралашу чарасы» мәгънәсендә.—Х. М.) булып, Идел-Урал төрек-татарыны телсез, җансызлык дәрәҗәсенә түбән төшерүдән саклады. Аның ана теле булып, халкымызның дәрдене, кайгусыны, омтылышыны ана телендә сөйләде, уйлады, үзенең уе, фикере берлә күршеләрен, дустларын, дошманларын хисаплашырга мәҗбүр итде. Безнең Идел-Урал төрек-татарының милли мәсьәләсен дөньяның сәяси базарына чыгарды вә анда аңарга бәһа куйдырды. Бүгенге көндә «Милли юл» үзенең унынчы яшенә аяк басканда, без Аурупаның төрле мәмләкәтләренә, Якын Шәрыкга, Ерак Шәрыкга таралган меңләрчә-меңләрчә милләтдәшләремезне мәгънәви йебләр берлә бер-берсенә бәйләнгән итеп вә бер милли кыйблага таба хәрәкәт итә торган оешкан бер мәдәни көч итеп күрәмез. Һәрбер йирдә аны сәяси бер барлык булып җиткән хәлдә, сәясәт дөньясында очратамыз. Аның омтылышы-теләгенең дөньяның бик күп тарафларына ингыйкясына (чагылышына.—Х. М.) шаһид буламыз. Боларның барысында да азмы-күпме «Милли юл»ның хезмәтенең эзен сизеп, Идел-Урал төрек-татарының сикълэт изафисенең (бередә «дәрәҗәсенең» —Х. М.) көндән-көн үсә баруыны күрәмез. Аркамыздан килә торган «Милли байрак» кеби гәзитәмезнең туууыннан, дәвам итүендән, үсүендән сөенеп, безнең бу хәрәкәтемезнең йимешле икәнене эшемез, көчемезнең кысырга китмәвенә тагы бер мәртәбә ышанып, эшемезгә дәвам итәмез.

«Милли юл»ның кызыл урыс баскынлыгында яшәргә мәҗбүр булган илемездә никадәр тәэсир ясавын күрер өчен, андагы бик күп чын коммунистларның да истикъляя (бәйсезлек.—Х. М.) юлына кереп китүләре, истикълялчы булып хөкемләргә бирелүләре, буржуа (4) милләтче булып, үлемгә хөкем ителүләрен күздән кичерү җитәдер. Болар «Милли юл» күтәргән истикъял байрагының никадәр җанлы, никадәр җазиб (үзенә тарта торган.—Х. М.) икәнлеген күрсәтә торган дәлилләрдер. Большевик хөкүмәтенең еллар буе туктамаенча үзенең коммунист фиркасене милләтче гонсырлардан (элементлардан.—Х. М.) әрчергә мәҗбүр булды; бу — милли хәрәкәтнең никадәр киң катлавымызны каплап алуын күрсәтә торган эшләрдер. Большевиклыкның зәгыйфьлеге арткан саен бу милли хәрәкәтемез куәтләнә барачакдыр. Советларның золымы, җәбере арткан саен халкымыз истикъляддан башка кортылу юлы юклыгына ышанычын, иманын ныгытачакдыр. Мәҗмугамыз унынчы яшькә аяк баскан көнләремез, тарихи дошманымыз руслыкның башбаштаклык эчендә чәйкәлгән (чайкалган.—Х. М.) кызыл русчылыкның чыкмаз тыкрыкга кереп, кая барачагын белмәенчә аптырап калып, кай

тарафдан йомрык (йодрык.— Х. М.) килә диеб паник(а) эчендә яшәгән көнләренә тәсадеф итәдер (туры киләдер.— Х. М.). Бу безгә алган юлымыздан бер карыш да тайпылмаенча, милли кыйбламыздан адашмаенча, эшемез, көчемезне тагы артыдырырга, байрагымыз әтрафында туплануымыз, берләшүемезне тагы куәтләндерергә мәҗбүр итәдер. Без дә элекке юлдан язмаенча барырга бисмилла әйтеп яңа елга керәмез. Милли максадымыз бу елда бөтен милләттәшләремезнең иманлыларын милли байрагымыз әтрафына туплап, сәяси куәтемезне артдыру, хәрәкәтемезне тагы да активлашдырудыр. Большевик җимерелү берлә өстемезгә йөкләнәчәк милли вазыйфаларымызга хәзерләнүдер. Бу хәзерләнүемездә без һаман иске юлымыздан барачакмыз, искедә булган кеби, Идел-Уралның истикъ-лялына кавышуын төп максад итеп куеп, бу хәрәкәтемезне, элекдә булган кеби, киләчәкдә дә төрек культур берлеге даирәсендә алып барачакмыз. Вә һәрбер төрек өлкәләренә кардәшчә карап, төрек өлкәләренең берсенең зарарына булган агымлар берлә мөнәсәбәтдә булышудан озакда (еракта.— Х. М.) калачакмыз. Эчемездән, тышымыздан төрек берлеген саклаячакмыз. Уртак дошманымызбаскынчы руслыкга каршы кортылыш тартышы алып барганда, безнең кеби руслардан җәберләнгән, көчләнгән вә бүген истикъляллары, кортылулары өчен тартыш ачкан прометей (бу очракта «тоткын» мәгънәсендә.— Х. М. милләтләрнең милли дәгъваларына хөрмәт итеп, алар берлә җәбһә (көрәш; фронт.— Х. М.) берлеген сакларга тырышачакмыз. Боларның да һич берсенең зарарына хәрәкәт итмәячәкмез. Без озын гасырлар урыслар берлә тартышып, җан чикешеп килгән Идел-Урал төрекләре — озын тарихымызда урысларның даимән алдауларына очраганга, урысларның һәрвакыт биргән сүзләрен бозуларына шаһид булганга, аларның һичбер агымлары, фиркаләре берлә сәяси тәмасәдә (мөнәсәбәттә.— Х. М.) булынмыймыз, сәяси (5) мөҗадәләмездә (бәхәсебездә.— Х. М.) алар берлә сафдаш булудан качачакмыз. Вә аларның һичбер группа(а)ларына ышанмаенча, үз милли эшемезне үз башымызга гына эшләргә тырышачакмыз. Соңгы вакытларда мөһаҗәрәтдәге русларның төрле агымлары, фиркаләре үзләренең көчсезлекләрен күреп, безнең төрек кабиләләренең әле берсенә, әле берсенә сарылып, якынлашкан булып, алдашу юлына керергә теләүләрен хис иткәнен күреп торганга, бөтен милләттәшләремезнең бу эшкә дикъкатен җәлеп итеп һәрбер йирдә төрле төскә буялган руслардан еракда торуларын тәүсыя итәмез (киңәш итәбез.— Х. М.).

Бу эш елымыз — мәҗмугамызның унынчы елы — халкымызга, илемезгә кортылу китерә торган бәхетле ел булса иде дип бөек тәңремезгә ялварып, милли вазыйфамызга дәвам итәмез[1].

## Мөфти Ризаэддин хәзрәт

*(Яңа милли юл. 1936. № 7—8 (101). 2—6 бб.)*

Мәҗмугамызның бу нөсхәләрен мәрхүм мөфтиемез Ризаэддин хәзрәткә багышлап чыгарамыз.

Ризаэддин хәзрәт үзенең илле еллык хезмәтене һәрвакыт ачык итеп алып барганга вә аның бик күп әсәрләре калганга, аның хакында тулы мәгълүмат бирү бер дә уңайсыз булмаска тиешдер. Ләкин мөһаҗрәтемезнең илемез берлә ачыкдан-ачык мәдәни мөнәсәбәт йөртүенә большевик хөкүмәтенең манигъ (каршы.— Х. М.) булуы безнең бу мәдәни эшемезне тулы көенчә алып барырга киртә булып киләдер вә безне бары мөһаҗәрәтдә (эмиграциядә.— Х. М.) табуы мөмкин булган мәрхүмнең әсәрләре, язулары вә мәктүбләре (хатлары.— Х. М.) берлә генә кифаяләнергә (чикләнергә; канәгатьләнергә.— Х. М.) мәҗбүр итәдер. Бу гайре табигыйлек мәрхүм хәзрәтемезгә каршы булган милли вазыйфамызның ярты-йорты гына үти алынуына, шул бөек милли хезмәтчемезне бөтен зурлыгы, олуглыгы, киңлеге, тирәнлеге берлә милләтемез алдында тулы көенчә күрсәтә алмавымызга сәбәп буладыр. Болар бөтен мөһаҗәрәтемез өчен уртак манигъләр булып, «Милли юл»ның үз көче берлә генә аны үтәп китәрлек имкяне (мөмкинлеге.— Х. М.) булмаганга, кирәк мәрхүм хәзрәтнең дустлары, кирәк милли кыйммәтләремезне тулы итеп күрәсе килгән милләтдәшләремез шул мәҗбүри

[1] Мәкалә ахырына «Милли юл»идарәсе» дип куелган. Әмма ул баш мөхәррир Гаяз Исхакыйның үзе тарафыннан язылган.

ноксанларымыз (кимчелекләребез.— Х. М.) өчен безне гафу итәрләр дип өмид итәмез.

«Милли юл» кулында булган имкян, урталыкда булынган әхвалнең мөсагадәсе (ярдәме.— Х. М.) даирәсендә бөтен мөһаҗәрәтемез өчен фарыз кифая булган шул милли фарызны үтәргә, боның берлә бөтен мөһаҗәрәтемезне зур бер милли гөнаһдан коткарырга тырышды, ләкин эшләгән эшемез берлә Риза хәзрәт хакында анлатыласы, белдереләсе, языласы нәрсәләр тәмамән тутырылды дигән фикердә түгелмез. Билгакес (киресенчә.— Х. М.), кулымыздагы материалның азлыгы, рәсми мәгълүматымызның житешмәслеге бик күп кирәкле нокталарның (нөктәләрнең — фикерләрнең.— Х. М.) ачылмаенча калуына да сәбәп булды. Бәлки мәрхүм хакында кайбер мәгълүмат тулы көенчә бирелмәү берлә генә калмыйча, хаталар да кереп киткәндер. Боларны төзәтүләр, боларның ачык булмаганларын ачык итеп язуларны киләчәккә калдырамыз вә мәкаләләремездә очраган хаталарны белгәнләрдән тәсхих итүләрен (төзәтүләрен.— Х. М.) үтенәмез. Эшемез зур бер милли вазыйфаны үтәү булганга, бөтен тәсхихларны «Милли юл»ның киләчәк нөсхәләрендә нәшер итәргә тырышачакмыз. Фәкать бу тәсхихлар, мәрхүм мөфти хәзрәтемезнең тәрҗемәи хале, эшләгән эшләренең тарихы, әсәрләренең язылышы, басылышы якынлары, әкърибалары (туганнары.— Х. М.) мөхиты тирәсендә булырга тиешдер. Мәҗмугамызга иштиряк иткән (катнашкан.— Х. М.) мөхәррирләрнең карашлары берлә мөназарә (бәхәс.— Х. М.) төсендә булмаска тиешдер (3). Мәрхүм мөфти Ризаэддин хәзрәт безнең уяну дәверемезнең бик зур бер симасы (шәхесе.— Х. М.) булганга вә аның эшләгән эшләрен яктырту сәяси фикерләр башкалыгына карамаенча, аның дәвердәшләренең уртак вазыйфаларыдыр. Бу олуг милли хезмәтчемезгә хөрмәтән шул бөек вазыйфамызның житдилегене игътибарда тотып, бөтен язучыларымыздан вак-төяк шәхси капризларга бирелмәенчә, минем фәлан сүзем калмасын, минем фәлан җөмләмнең фәлан сүзе юл башында булсын, фәлан йирдә кечкенә өтере генә куелмасын, нокта төртелсен кеби вак-төяк шартлар берлә житди эшне ваксытмауларын вә табигый көенә генә уртак эшкә ярдәм итүләрен рижа итәмез (үтенәбез.— Х. М.).

Кайбер матбугадагы җитешсезлекләр мәкаләләремезнең йирләшдерелүендә үземез теләгәнчә итеп идарә итәргә имкян бирмидер, бондый ноксанларымыз милләтемезнең матди фәкыйрьлеге берлә баглы эшләрдер. Каләм тибрәтүчеләрнең шуларны игътибарга алып хәрәкәт итүләрен, мәрхүм мөфти Ризаэддин хәзрәтнең үз йөзен үз төсендә күрсәтергә, танытырга кирәкле булган нокталарына (урыннарына, фикерләренә.— Х. М.) гына әһәмият биреп, вак-төяк житешсезлекләремезне бармак аша карап мөгамәлә итүләрен рижа итәмез.

* * *

Мәрхүм Ризаэддин хәзрәт, безнең Идел буе төркенең (төркиенең.— Х. М.) фикри хәрәкәтене бер тарафдан Курсавилар, Мәрҗанилар, Габделкаюм Насыйрилар берлә, икенче яктан Идел-Урал истикъляльы (бәйсезлеге.— Х. М.) агымы берлә баглаучы бер тарихи шәхсыятьдер. Аның кыйммәте безнең үткәнләремезне белер өчен генә түгел, киләчәгемездәге барачак юлымызны, кыйбламызны тәгъйин итәр (ачыклар.— Х. М.) өчен дә бик зурдыр. Риза хәзрәт мәрхүмнең истикълял тарафдары булуы, шәхсыятене хөрмәтләндерә торган бер эш булса, аның шул сәяси истикъляльны таяндыра торган мәдәни истикъляльмыз өчен гомерене сарыф итүе, милли мәдәниятемезне ныгыту, тазарту өчен илле ел бер буйдан эшләве шул истикъляльның (азатлыкның.— Х. М.) яшәве өчен кирәкле зәминне (җирлекне.— Х. М.) хәзерләве һичбер язып бетермәслек бер милли хедмәтдер.

Безнең Идел-Урал дәүләте төзүемез вә безнең Идел-Урал истикъляльын вөҗүдкә чыгаруымызның шартлары искедәге Каратау (Черногория.— Х. М.) мәмләкәте, хәзерге Албания мәмләкәтенең истикъляльындагы шартларга тәмамән башкадыр. Идел-Уралда мөстәкыйль милли дәүләт яшәр өчен, аны үзбашына яшәтә беләчәк матди вә мәгънәви вазгыяте тәэмин ителгән булырга тиешдер. Идел-Уралда әллә ничә гасырлар зур-зур төрек дәүләтләренең мөстәкыйль яшәве (Хәзәр, Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан ханлыклары) үзендән-үзе бонда мөстәкыйль бер дәүләт төзелешкә (4) һәр бакымдан (карашдан.— Х. М.) имкян (мөмкинлек.— Х. М.) зурлыгыны күрсәтә торган дәлилләрдер. Руслар алганның соңында дүрт йөз ел эчендә кыйлган җәбер-золымлары берлә Идел-Урал төрек-татарының мәдәниятен җимерә алмадылар. Халыкның фикерендә үзен-үзе тәмамән башка бер мәдәният баласы, башка бер халык итеп күрүен аз гына да кимәтә алмаулары үзендән-үзе Идел-Уралда мөстәкыйль төрек мәдәниятенең яшәп ки-

лүенә аяклы дәлилдер. Мәрхүм Риза хәзрәт гомере буенча менә шул мәдәниятемезнең истикъляльны сакларга тырышкандыр. Гомере буенча аның мәдәниятенең бүленмәгән бер өлеше булган мөселманчылыкны черетүдән саклар өчен Идел буе мөселманының динчелегенә ябышкан ишанлык, мөтәгассыйблык (фанатизм.— Х. М.) кеби төрле-төрле паразитлардан пакьларга тырышкандыр. Озын тарихлы милли мәдәниятемез үз эчендә генә кысылып калып, буылып китеп һавасызлыкдан корымасын, коргаксымасын өчен, ул безнең төрек мәдәниятенең төбен, тамырын саклап, аны гарәб мәдәнияте белән ашлау кирәклегене аңлап, шуны билфигыль (чынлыкта.— Х. М.) татбикъ итәргә (бәйләргә, яраклаштырырга.— Х. М.) керешкәндер. Шул эшдә бик зур үрнәк булып, Аурупа мәдәниятенең кәләпүшле, калфаклы көенчә милләтемез эченә сугылуына сәбәпче булгандыр. Боларның икесе берлә дә милли мәдәниятемезне сипләп, аның үсүе куввәтене, аның җилгә-давылга каршы таяну көчене ныгытырга хезмәт иткәндер. Боның берлә Риза хәзрәт безнең Идел-Урал дәүләтенең мөстәкыйль яшәве өчен кирәк булган иң зур гамәлләрдән берсе булган мәдәни истикъляльмызны ныгыткан вә безнең киләчәк мөстәкыйль дәүләтемезнең төп баганаларын вакыт-заманның какшатуындан урыс улакның (чапкынының; баскынының.— Х. М.) җимерү-ватуындан сакларлык хәлгә китерергә иҗтиһад иткәндер. Мәрхүм Риза хәзрәтнең хезмәте ялгыз безнең өчен, Идел буе төрке өчен генә түгелдер. Бөтен төрек илләренең сәламәтлеге, бөтен төрек кабиләләренең уртак мәдәниятләренең мөхафәзәсе (сакланышы.— Х. М.) өчен кирәкле булган бер хезмәтдер. Бу юлда мәрхүм Риза хәзрәт фикри төшенчәсе, эше берлә төрекчә булган кеби, калдырган мирас ягыннан да уртак төрекчелекнең мәгънәвиятене яратучысы сакчысыдыр.

Идел елгасы безнең төрек илләре берлә рус илене җәгърафый бүлүче бер чик кенә түгелдер. Идел елгасы төрек мәдәнияте берлә рус мәдәниятен бер-берсендән аера торган мәгънәви бер чикдер. Идел буе төреге үз илен Идел-Уралны гына рус һөҗүмендән саклаучы бер төрек-татар гаскәре генә түгелдер. Ул уртак төрек мәдәниятен рус мәдәниятенең һөҗүмендән саклаучы төрек мәдәниятенең сакчысыдыр. Казан, Әстерхан ханлары мөстәкыйль чакда бөтен төрек илләре Төркестан, Кырым, Кавказ, Сибирия, Госманлы империяторлыгы русларның (5) һөҗүмендән генә түгел, үзләренең милли мәдәниятләре дә тулы мәгънәсендә мөхафәзә астында (саклауда.— Х. М.) булгандыр. Руслар төрекләрнең чикләре Идел елгасыны кичеп чыкканның соңында гына Сибирия, Кырым, Кавказ, Төркестан, Төркия мәмләкәтләренә һөҗүмгә кичкәнләр. Бондан соң гына бөтен төрек илләрен генә түгел, уртак төрек мәдәниятен дә хәтарәле вазгыятькә (куркыныч хәлгә.— Х. М.) сукканлардыр. Бөтен төрек илләренең сәяси истикъляллары (бәйсезлекләре.— Х. М.), төрек мәдәниятенең үзенең үзлегене тулы көенчә саклый белүе кәнәдә (чынлыкта?— Х. М.) Идел буе төркиенең сәяси истикъляльны алуына, уртак төрек мәдәниятен Идел буе төркенең кылычы берлә саклавына баглыдыр. Шуның өчен Риза хәзрәтнең Идел буе төркиенең мәдәниятен ныгытырга чалышуы хәтарәле урындагы бер кальгане (крепостьне, каланы — Х. М.) ныгытырга тырышуы кеби бер эшдер. Аның калдырган мәгънәви азыклары киләчәк гаскәремезнең мәгънәви ачлык вә сусавыны кандырыр (басар.— Х. М.) өчен ясаган хәзерлекләредер. Дошманга каршы торганда мәкавәмәт итәр (каршы торыр.— Х. М.) өчен биргән коралларыдыр. Менә шул ноктадан чыгып мәрхүм мөфтиемез Риза хәзрәт гомерендә бер мәртәбә дә дошманга каршы утлы корал кулланмаган булса да, руслар тарафыннан сугыш сафы башында шәһид ителгән мәрхүм мөфти Чәләби Җиһан кеби үк, төрек милләтенең мөхтәрәм мөҗаһидыдыр (көрәшчеседер.— Х. М.). Безнең милли тормышымызны коруда бик зур хезмәт иткән Исмәгыйль бәк Гаспралы, Йосыф Акчура, Каюм Насыйри кеби безнең милли йортымызны корышучы, төзешүче милли мөһәндисемездер (инженерыбыздыр.— Х. М.). Мәрхүм Чәләби Җиһанның Истанбул дарелфөнүн талибәсе (студенты.— Х. М.) булып фәсле булуы, Йосыф Акчураның Париж дарелфөнүн шәкерде булып, башында шапкасы булуы, Габделкаюм Насыйриның ил җимеше булып, башында камчат бүрек булуы, авыл мәдрәсәсендә генә тәхсыйль (уку.— Х. М.) күргән Риза хәзрәтнең башында чалма булуы боларны бер-берсендән аера торган нәрсәләр түгелдер. Боларның эчләре, рухлары, омтылышларының берлеге, кыйблаларының бер тарафдалыгы боларны бер милли көч иткәндер, бер милли көч итеп безгә таныткандыр. Киләчәк тарихымызга да болар бер милли юлның юлчылары, бер милли кыйбланың (кабиләнең?— Х. М.) имамлары булып, бер йорт төзүнең мөһәндисләре булып безнең милли тарихымызга керәчәкләрдер вә безнең яшьлегемезгә (яшьләребезгә.— Х. М.) үрнәк булып китәчәкләрдер. Боларның барысы да безнең киләчәгемездә милли газизләремез булып әйләнәчәкләрдер.

Мөфти Риза хәзрәтнең аермасы шундадыр ки, ул бу дәрәҗәгә, монтазам (рәтле; тәртипле.— Х. М.) мәктәп күрә алмаенча, үз тырышлыгы, үз казынуы берлә генә ирешкәндер. Үз-үзен идарә итә белүе берлә генә дөньяның җилле-давыллы җирләрендә, кызыл руслыкның иксез-чиксез вәхши золым-җәбере алдында башын югарыда тота алып, соңгы сулышына кадәр үзенең иман иткән (6) милли сафы башында калгандыр. Бу мәдәни җәсарәте (батырлыгы, кыюлыгы.— Х. М.) берлә чит халыкларны хәйрәткә (гаҗәпкә.— Х. М.) калдырып, безнең Идел-Урал төрегенең мәгънәви кыйммәтен тагын күтәргәндер. Төрек балаларында төреклек горурымызны охшап, милли вазыйфасыны тулы көенчә үтәгән милли каһарманымыз булып алланың рәхмәтенә кавышкандыр.

**Гаяз ИСХАКЫЙ**

## Милли намаз

*(«Яңа милли юл». 1935. № 12. 25—26 бб.)*

И туган, син күп изелдең, инде йитде, тор, уян!
Үтде төн һәм таң да атды, кычкырып әйт син азан!

Моң белән әйт син азанны, яңгырасын милли аваз!
Бар төрк-татар уянсын, без укыйк милли намаз!

Тиз чыгар балкып кояш, Идел-Уралга нур явар,
Дүрт гасырлар зөлмәт иткән вәхши руслар да таяр.

Ач тарихың, ас хәритәң[1], Асияне тек(ә)ләп кара!
Чин дивардан[2] Алтай үтеп Ак Идел буена таба.

Һәм дә Байкал, Каспий үтеп, тугры Босфорга кара!
Кама буйлап бар Казанга, (күр)... әнә Алтын-Сарай!

Бакчы анда дәрьяларга, нинди зур күлләр дә бар..!
Бәһасы юк киң болынлар, нинди бай таулар да бар...

Күрче анда: нинди вак парчаланган өлкәләр,
Төрле исемләр тагып ул өлкәләрне йөртәләр...

Йә санап чык, күпме анда төрле мәзлүм кабилә?!
Казакъ, үзбәк, татар, башкорд, болгар, кыпчаклар илә.

Юк, алай түгел иде, тик безнең күзне бөркиләр,
Һәммәсе алар бер исемдән парчаланган[3] — төркиләр!

Төркия, кырымлылар, Кавказ, әзербәйҗанлылар,
Шәркый-гарби төркестанлы — һәммәсе бер туганлар.

Ул Сарайда иң элек канун төзегән хан Батый,
Шул кануннарны бүгенчә әҗнәбиләр кулланды[4].

Ул Сарайда сөрде хәким[5] хан бабаң таҗын киеп,
«Булмасын кол башкаларга бер төрек баласы!» диеп

Аңладың милли намазың?. Бар азад ит милләтең!
Кыйбла дип тан(ы)сын җиһан бердән төреклек дәүләтен!

**Мансур АРЫСЛАНБӘК.**
Шанхай.

---

[1] Хәритә — карта
[2] Чин дивар — бирелә «Кытай стенасы» күздә тотыла.
[3] Парчаланган — таркалган, бүленгән.
[4] «Шул кануннарны бүгенгә кадәр чит илләр куллана».
[5] Ягъни Сарайда (Алтын Урдада) патшалык итте.

# СОЛТАНГАЛИЕВ ЭШЕ

## Икенче утырыш

*(1923 елның 10 июнь иртәсе)*

Фрунзе. Иптәшләр, Солтангалиев эше безнең өчен сәяси ягы белән гыйбрәтле. Ул безнең милли сәясәтебезнең дөрес булмавы нинди фаҗигаләргә китерергә мөмкин икәнен ачып сала. Фикер алышу вакытында чыгыш ясаган иптәшләрнең икеләнүләре, шик-шөбһәләре мәсьәләнең гаять катлаулы булуын күрсәтә.

Ләкин мәсьәләнең асылына күчкәнче, мин аның нинди яссылыкта куелуына карата бер искәрмә ясамакчы булам. Мин докладның партия Үзәк Комитеты тарафыннан түгел, ә Үзәк Контроль Комиссиясе исеменнән ясалуын күпмедер күләмдә кимчелек дип саныйм. Әгәр шулай эшләнгән булса, авырлык үзәге саф сәяси мәсьәләләргә төшкән булыр иде, ә хәзер безнең фикер алышу суд залын хәтерләтә. Фактлар күз алдында, шуңа күрә эшнең хокукый ягына кин тукталып тору урынсыз булыр иде. Тагын бер нәрсә. Докладны Үзәк Контроль Комиссиясе ясаганга, без монда җентекле анализ да, сәяси һәм икътисади хәлләргә аек бәя дә ишетә алмадык. Шулай ук солтангалиевчелекне китереп чыгара торган сәбәпләр һәм шартлар да ачылмады.

Хәзер эшнең асылы турында. Мин Солтангалиев эшен Башкортстанның һәм Татреспубликаның эчке проблемалары итеп кенә карамыйм. Аның тамырлары тирәнгә китә. Партиянең XII съезды, Татреспубликадагыча, партиянең үз эчендә төркемнәр сугышы Грузиядә дә булды, дип күрсәтеп үтте. Украинада да шуңа охшаган процесслар бара. Берничә елдан монда да шундый кискен көрәшләр чорын узарга туры килмәгәе.

Мондый күренешләрне тудыра торган бик тирәнгә киткән тамырлар бар. Аларны табарга һәм корытырга кирәк. Сәбәпләрнең иң мөһиме — бөекдержавачыл бөекурыс шовинизмы. Урыннардагы сәламәт көчләр моңа битараф кала алмыйлар һәм кулларыннан килгәнчә аңа каршылык күрсәтәләр. Төрле халыкларның икътисади хәле, алар арасындагы тигезсезлек фактлары да бу хәрәкәтне кыздырып тора. Ниһаять, җирле халыклар арасында милләтчелек сөреме булуын да инкарь итәргә ярамый.

Авырлык үзәге нәкъ менә шушы ике нәрсәгә төшә. Шунысын да әйтергә кирәк, партиябезнең XII съезды, үзенең тезисларын кабул иткәндә, урыннарда милләтчелек рухы белән көрәшергә кирәкми, дигән кешеләрнең сүзләренә колак салмыйча, бу көрәшнең зарурилыгын танып, бик дөрес итте. Без тикшерә торган эш моңа ачык дәлил. Шулай да ашыгып уйланылмаган нәтиҗәләр ясарга ярамый. Солтангалиев эшендә зарарлы һәм хәвефле тайпылышны билгеләп үтеп, мондый күренешләр белән көрәшүне йомшартсак, дөрес булмас иде. Ләкин аны кирәгеннән артык күпертү дә ярамый. Бу эш бөекдержавачылык белән көрәшүнең нинди мөһим бурыч булуын тагын бер кат күрсәтә. Урыннарда милли яңарыш, икътисади тигезлек һәм башка проблемаларны хәл итүне партия үз кулына алса, моннан барысы да отачак.

Ләкин урыннарда милли тайпылышлар белән көрәш оештырганда бик нык уйлап һәм үлчәп эш итәргә, мондый төркемнәрнең асылын ачарга, аларны өйрәнергә кирәк. Партиянең аларга мөнәсәбәтен анык кына билгеләр вакыт җитте. Сәетгалиев һәм Ибраһимов кергән төркемнең хаталары күп булса да, алар безнеке, коммунистларныкы. Алар ачык авызлык күрсәтергә, ялгышырга мөмкиннәр, ләкин бу кешеләр, һичшиксез, дөрес коммунистик юнәлешне эзлиләр. Солтангалиев тарафдарларына килгәндә, күп очракта алар да дөрес сәясәт үткәрделәр булса кирәк, ләкин асылда монда башка нәрсәләр дә күзгә ташлана.

---

Дәвамы. Башы 2 санда.

Минем өчен солтангалиевчелек, аерым алганда, аның уң тармагы, коммунизм байрагы астына яшеренгән вак буржуаз идеологиянең чагылышы.

Бу агымның төп сәяси билгеләре менә шулар. Ләкин бу әле, Ибраһимов әйткәнчә, Солтангалиевнең карашларын уртаклашучыларны партия сафларыннан куарга дигән сүз түгел. Күп кенә иптәшләр әле чын коммунистлар булып китә ала. Алар гына түгел, ә ерак төбәкләрдә хәзер җәмәгать фикерен калыплаштыручы зыялылар да безнең сәяси эшчәнлегебез объекты булырга тиеш. Аларны үз ягыбызга тарту — безнең бурыч.

Ләкин төп ышаныч яшьләрдә. Алар ялгышырга, бутарга мөмкиннәр, тик тиешле игътибар күрсәткәндә, алар партиянең ышанычлы резервына әвереләчәкләр. Әгәр без бу бурычны уңышлы үтәсәк, эшебезнең 3/4 өлеше файдага булачак. Моңа исә партия-тәрбия эшен тирәнәйтеп кенә ирешеп була. Мин башка юл күрмим.

Көн тәртибенә шундый мәсьәләне куеп, безнең Политбюро зирәклек һәм алдан күрүчәнлек күрсәтте. Бу хәл шулай ук ҮКның һәм Политбюроның XII съезд карарларын гамәлгә ашыруга зур игътибар бирүенең дә дәлиле. Милли җирлектә партия эчендәге низаглар алга таба тынар дигән өмет уяна. Барысы да киңәшмәнең икенче өлеше нинди карарга килүгә бәйле булачак.

Солтангалиевнең үзенә килгәндә, шәхси эш буларак, мин аңа аерым әһәмият бирмим. Үзәк Контроль Комиссиясе резолюциясен хуплarбызмы яисә катырак чаралар күрербезме, эш анда түгел. Иң мөһиме — без гамәлдә тиешле сәяси нәтиҗәләр ясарга һәм урыннарда мондый кешеләрнең булмавына ирешергә тиешбез. Аларга карата теге яки бу карарны чыгарганда, без бу кеше качармы яисә калырмы, дип шикләнмәслек булсын иде. Ә бүген, кызганыч ки, мондый сорауларга урын кала әле, ул гына да түгел, күп кенә шундый бәндәләр партиянең җаваплы урыннарына эшкә билгеләнә. Моңа чик куяр вакыт җитте. Ә без моңа артта калган халыкларның мәдәни һәм милли мәнфәгатьләре өчен көрәштә рульне кулыбыздан ычкындырмасак кына ирешә алабыз. Сәяси күзлектән карaганда, Солтангалиев эшенең төп бурычы һәм төп асылы да нәкъ менә шунда.

Орджоникидзе. Иптәшләр, мин кичә ип. Рыскуловның чыгышыннан соң нәүбәткә язылган идем. Миңа калса, ип. Рыскулов, Солтангалиевкә һәм солтангалиевчелеккә карата үзенең анык кына фикерен житкерәсе урында, мәсьәләне үзенең «сулларына» каршы борды. Мин аны Солтангалиев белән бәйле рәвештә гаепләргә җыенмыйм, ләкин, ничек кенә булмасын, Солтангалиев аның белән элемтәгә керүне кирәк тапкан, аның ике хаты әле дә ип. Рыскулов кесәсендә ята...

Солтангалиевнең чыгышы Ибраһимов теләгәнчә файдаланылмаска тиеш. Ул монда мөселман крестьяннарын сыйнфый билгеләр буенча бүләргә тәкъдим итә. Мин моның хакында шактый хәбәрдар. Мисалга, Чәчәнстандагы бүленешне генә китерәм. Анда крестьяннарны аеру муллалар хакимлегенә китерде. Төркестанда да шушы принциплардан чыгып эш итсәк, нәтиҗә аяныч булачак. Якутиядә дә якутларны катламнарга бүлгәннәр иде, моннан нәрсә килеп чыкты. Әгәр болар кабатланып торса, без бөтенесен югалтачакбыз. (Урыннан тавыш: Хәзер анда баш күтәрмиләр).

Миңа калса, Солтангалиевнең чыгышын безнең милли сәясәтебездәге хаталар белән аңлатырга, яисә аны бөекдержавачылык җимешләре генә дип бәяләргә тырышучы иптәшләр мөселман массаларына зур йогынты ясаган кәмалчылар Төркиясен онытып җибәрә. Нинди генә сәясәт алып барсак та, алар безгә каршы көрәшүдән туктамаячаклар. Төрек агентлары булмаган бер генә мөселман төбәге дә юк һәм моны иптәшләр яхшы белергә тиеш. Алар безгә каршы котырынган агитация алып баралар (Тавышлар: Дөрес).

Мин ип. Каменев белән сөйләштем. Ул миңа, Солтангалиев Казанда безнең сафларда сугышты, Колчакка каршы отрядлар әзерләде, диде. Бу бернәрсә дә аңлатмый, чөнки алдынгы карашлы теләсә кайсы мөселман зыялысы Колчакның кара реакциясенә каршы барачак, ул аны кабул итми. Әзәрбайҗанда муссаватчылар хакимлеген бәреп төшерүдә большевикларга үтә чыккан панисламистлар, пантөркистләр һәм иттихатчылар да ярдәм итмәдемени? Безгә ул чакта кәмалчы төрек офицерлары да булышлык күрсәтте, алар хәтта безнең белән бергә революцион комитетта да утырды. Шулай булгач, теге яки бу мөселман зыялысының урыс реакциясенә генә түгел, ә инглиз илбасарларына да каршы көрәшүе бернәрсә дә аңлатмый. Бу әле коммунист булу дигән сүз түгел. Бу безнең юлдашлар гына дигән сүз әле. Тагын бер мисал китерәм. Әзәрбайҗан мөселман укытучылары семинариясендә укучылар Совет власте урнаштыруның беренче елында Наримановныкын түгел, ә Мостафа Кәмал значогын тагып йөрделәр. Мөселманнар

яши торган районнарда безнең белән төрек офицерлары һәм өлешчә мөселман зыялылары арасындагы инглизләргә һәм аларның яраннарына каршы блок алга таба да яшәргә тиеш түгел. Төркиянең идарәче даирәләре сүз саен, без сезгә Әзәрбайҗанда, Төркестанда, Дагстанда Совет власте урнаштырырга мөмкинлек бирдек, дип шапырыналар. Миңа калса, Солтангалиев, безнең милли сәясәтебез ни дәрәҗәдә дөрес булуга карамастан, Совет властен гомумән кабул итми торган төркичеләр яклы, панисламист, пантөркист зыялыларның берсе. Бөтен мөселман зыялылары Совет яклы, алар арасында контрреволюционерлар юк дип үз-үзебезне тынычландыру соң дәрәҗәдә ахмаклык булыр иде.

Билгеле, Төркестанда һәм башка төбәкләрдә безнең милли сәясәт гарип рәвештә үткәрелде. Төркестанда чакта мин моңа үзем шаһит булдым. Үзбәк вокзалга килә, урыс коменданты аны платформадан куа. Ни өчен болай эшлисең, дигәч, ул: бөтен сартлар корчаңгы, аларны платформага кертергә ярамый, ди. Моны хайванлык дип атамыйча ни дисең? XII съезд милли төбәкләрдә безгә милли сәясәтне ни рәвешле алып барырга икәнен аерымачык күрсәтеп бирде. Аның карарларын намус белән үтәгәндә 2—3 ел буе сулларга да, уңганнарга да эш житәчәк, тик алар солтангалиевчеләр генә булмасыннар. Ип. Куйбышев тәкъдим иткән резолюциядә ерак милли төбәкләрдә чын коммунист-интернационалистлар үстерү кирәклеге турындагы юллар заманга аваздаш һәм бик мөһим. Иптәшләр, әлегә кадәр безнең күп кенә өлкәләрдә һәм бигрәк тә мөселманнар яши торган төрки районнарда, кеше үзен коммунист дип саный, ә үзе ни өчен коммунист булуын, коммунизмның нәрсә икәнен белми. Ул, мәсәлән, шәхсәй-вәхсәйне гадәти нәрсә дип раслый. Моның өчен партиядән чыгарсалар, минем нинди гаебем бар, дип аптырый.

Сул һәм уң коммунистлар турында сөйлиләр. Мондый бүленеш дөрес түгел, дип саныйм. Мисал өчен, шәхсәй-вәхсәй вакытында мөселманнар арасында сул һәм уң коммунистлар нәрсә соң ул? Аларның бер өлеше шәхсәй-вәхсәйгә төрлечә ярдәм күрсәтергә кирәк диләр, икенчеләре аның вәхшилегенә каршы мәдәни көрәш җәелдерергә өндиләр. Без үзебез вак милләтләрдән чыккан һәм алар арасында эшләгән коммунистлар, урыс иптәшләргә бөекдержавачыл шовинизм шаукымы белән көрәштә ярдәм күрсәтергә тиеш. Ләкин шул ук вакытта без үзебезнең милләтчеләрне дә кыйнарга тиешбез. Солтангалиев мисалы моңа дәлил булса кирәк. Уңнар арасында уң коммунистлар да, коммунист булмаган уңнар да бар. Соңгыларының, ягъни солтангалиевчеләрнең, партия белән бер уртаклыгы да юк. Беренчеләре белән килешеп эшләргә, икенчеләре белән рәхимсез көрәш кенә алып барырга мөмкин.

Мануильский[1]. Иптәшләр, мин чыгыш ясарга җыенмаган идем. Ип. Куйбышев тәкъдим иткән резолюция — төгәл һәм анык. Солтангалиев эшенең криминаль өлешен искә алмаганда, партия башка чаралар тәкъдим дә итә алмый. Ләкин миңа Солтангалиев эше үзе түгел, ә аңа бәйле чыгышлар гыйбрәтле булды. Мин монда, беренче чиратта, Рыскулов, Халиков һәм Енбаев иптәшләрнең нотыкларын күздә тотам. Бер милләт коммунистларының вәкиле буларак, бу чыгышлар миндә Солтангалиев эшеннән битәр зуррак шөбһә уяттылар. Ип. Халиков монда безгә Башкортстан хәлләре хакында сөйләде. Ул Петерснең бу төбәккә килеп урындагы иптәшләрне башкорт милләтчелеге белән көрәшергә чакыруы хакында әйтте.

Ип. Халиков, XII съезд карарларына нигезләнеп, башлыча бөек рус шовинизмы белән көрәшә. Мин бу очракта ип. Халиков башкорт милләтчелеге, ә урыслашкан Петерс урыс шовинизмы белән көрәшсәләр максатка ярашлырак булыр иде, дип уйлыйм...

Ә бездә, кызганыч ки, моның нәкъ киресе. Хәзер, бүгенге шартларда, Солтангалиев эше нәрсәсе белән аерылып тора соң? Мин монда партиянең XII съезды карарлары урыннарда милли стихияне кузгатып җибәрде, дип раслыйм. Мин моны бер милләт коммунистларының вәкиле буларак әйтәм. Милләтчеләр республикаларда XII съезд резолюциясен бөекурыс шовинизмы белән көрәшү өчен юллар ачкан хартия буларак кабул иттеләр. Күпмедер күләмдә бу дөрес тә. Ләкин XII съезд карарларын милләтчеләр өчен үзенә күрә «ирекләр хартиясе» ясасак һәм бу юнәлештә инициативаны элек изелгән халыкларның коммунистларына бирсәк, без милли стихияне үз кулыбыздан ычкындырачакбыз.

Партия Үзәк Комитетының бу мәсьәләне куюына мин гадәттән тыш шат. Солтангалиев эшенә без артык зур әһәмият бирдек кебек. Әгәр милли республикаларда күбрәк чокчынсак, без моңа охшаш дистәләгән эш казып чыгарыр идек. Мин Украина мисалына таянып, берничә факт китермәкче булам. 1920 елда бездә дә фракция эчендә милли төркем оештыру омтылышы булды. Ул чакта без

дә шундый ук чараларны күрдек, ягъни берничә кешене партия сафларыннан чыгарып аттык һәм партиянең таркаулыгын булдырмый калдык. Ә 1921 елда, Польша белән чиктәш төбәкләрдә кайбер иптәшләр шифрлы хатлар ярдәмендә баш күтәргән элементлар белән элемтәгә керергә маташтылар. Сүз уңаенда, монда бер иптәш Солтангалиевнең гамәлләрен үзенчә аңлатырга маташты: имеш, элек тә контрреволюцион көчләр белән сөйләшүләр алып барылды һәм тарихи инерция буенча алар хәзер дә сакланып калды. Мин моны аңлыйм да кебек. Тик әйтегез әле, ни өчен бер үк партиядә торучылар үзара шифр белән аңлашалар? Кырымнан килгән иптәш моны аңлатмады. Украина басмачылары арасында шундый хат алышу булуын ачыклагач, без нишләдек? Без бу җәһәттән ҮКтан катырак булдык һәм бу коммунистларны атарга хөкем иттек. Соңыннан билгеле булганча, ялгышмадык.

Крестьян чуалышлары белән әледән-әле очрашып торган безнең волость комитетлары банда башлыклары белән элемтә тоталар. Болар расланган фактлар. Алар бандитларның көрәшендә актив катнашмыйлар, ләкин аерым атаманнар белән элемтәдә торып, бу контрреволюцион хәрәкәтләргә тарафсызлык саклыйлар. Бу нәрсә белән аңлашыла? Крестьян стихиясенең югары аппаратка түгел, ә башлыча түбән буын эшлеклеләренә йогынтысы, басымы белән. Ләкин шушы җирле крестьян стихиясе безнең бүгенге кинәшмә кебек дәрәҗәле учреждениегә басым ясый башлаган һәм аның кайтавазы монда кадәр үтеп кергән икән, мин шик-шөбһәләремне уртаклашмыйча кала алмыйм. Партия Үзәк Комитеты үзенең бөекурыс шовинизмы белән кискен рәвештә көрәшергә тиеш. Иптәшләр, бу сезнең эш. Ә без, читтә урнашкан төбәкләрдәге коммунистлар, беренче чиратта үз милләтчелегебез белән хәлиткеч көрәшкә күтәрелергә тиеш. Безгә реформаларга мөнәсәбәттә либераль буржуазия җибәргән хаталарны кабатларга ярамый. Алар бер ташламаны каерып алдылар да, шуңа нигезләнеп, хөкүмәткә каршы сугыш башладылар. Бездә дә шул ук хәл кабатлана. Конституция өстендә эшләүче комиссияне генә алыйк. Кайбер милләт вәкилләре, XII съезд карарларын яклаган булып, үз сәясәтләрен уздырырга маташмыйлармыни? Ирексездән күңелдә борчылу туа. Безгә, коммунистларга, мондый тайпылышлардан арынырга кирәк. Җирле милләтчелек белән көрәшү милли коммунистларның төп сугышчан бурычы булырга тиеш. Без үз милләтчелегебезне тәмам юк итик — төп мәсьәлә шулай тора. Минемчә, Солтангалиев эшеннән бер бик мөһим сабак алырга кирәк, ягъни итекчегә итеген калдырырга, икенче төрле әйткәндә, урыс иптәшләр үз милләтчелекләре белән үзләре көрәшсеннәр. Вак милләтләр коммунистлары, Солтангалиев эшеннән сабак алып, үзләрендәге эчке милли тайпылышларга каршы сугыш ачсыннар.

Мохтаров[2]. Иптәшләр, кайберәүләрнең чыгышлары тәэсирендә минем турында берьяклы фикер калмасын өчен тикшерелә торган мәсьәләнең аерым өлешләренә тукталмакчы булам. Каменев һәм Куйбышев иптәшләр әйткәнчә, кинәшмә үзара аңлашуга юл ачарга тиеш. Мәсьәләгә берьяклы гына якын килгәндә һәм темадан читләшкәндә, моңа ирешеп булмавы да мөмкин.

Соңгы вакытларга кадәр Солтангалиев татар эшлекле даирәләрендә революционер-большевик буларак мәгълүм һәм киң танылган иде. Ул Кызыл гаскәрдә, башка күп кенә пролетар учреждениеләрдә иң җаваплы урыннарда эшләде. Ип. Орджоникидзе уйлаганча, аның аерым гаскәри частьлар төзүдә катнашуы да очраклы хәл булмады. Ул зур эшчәнлек алып барды һәм төрле шикләнүләргә урын калдырмады. Моңа кадәр ул күп төрле хезмәтләр башкарды. Мәскәүгә алыгач, Милләтләр Эшләре буенча Халык Комиссариаты Коллегиясе әгъзасы, Федераль Җир Комитеты рәисе вазифаларын башкарды. Бу фактлар үзләре генә дә аның партиядә очраклы кеше булмавы хакында сөйли. Аңа күп тапкырлар шундый зур ышаныч белдерүне күреп торган өстенә, татар, башкорт һәм башка милләт эшлекләренең Солтангалиевка йөз чөереп караулары бик сәер булыр иде. Без аның контрреволюцион эшчәнлегенә кискен рәвештә каршы чыгабыз, ләкин шулай да аның революцион эшен инкарь итә алмыйбыз. Ул безне шәхесләр буларак үстерүдә зур көч куйды, без аның артыннан бардык.

Шәхсән мин үзем аның эшчәнлеген тумыштан милләтче булуы белән бәйләмим. Инде монда әйтелгәнчә, мондый теория дә, гамәл дә юк. Үзәк Комитет Солтангалиевнең моңа кадәрге эшчәнлегендә контрреволюция булмавын үзе дә раслар дип уйлыйм. Аның Совет властена каршы гамәлләре фәкать соңгы чорларда гына калыплана башлаган, ахры. Советларның X съезды һәм партиянең XII съезды арасындагы чор да моңа җирлек бирде, дип уйлыйм. Владимир Ильич язганча, безгә чит булган совет аппараты Советларның X съезды карарларын барлык үзбилгеләнүләрне юк итү дип кабул итте. Мондый аһ-зарлар

дулкыны барлык ерак төбәкләргә дә килеп җитте. Ә монда, үзәктә, милли республикалар мәсьәләләрен үткәрү катлауланды һәм гаять кыенлашты. Моңа мисаллар шактый. Татреспубликада җир реформасын уздыруны гына алыйк. Гадел таләпләрне канәгатьләндерү өчен хәтта Политбюрога кадәр барып җитәргә туры килде. Ул чакта юкка гына Наркомземның һәр ишегенә милли мәсьәлә буенча партия программасыннан өзекләр ябыштырып чыгарга кирәк димәделәр. Шул рәвешле бу чорда зур ыгы-зыгы чыкты. Билгеле вазифасына бәйле рәвештә Солтангалиев тә гаять көчле басым астына эләкте. Шушы катлаулы шартларда ул юлдан язарга бик мөмкин иде. Мин моны Солтангалиевнең гаепләрен аклау өчен әйтмим. Тагын бер кат кабатлыйм, без аның җинаятьләрен кискен хөкем итәбез.

Солтангалиев эше белән бәйле рәвештә Татреспубликада милләтчелекнең булуы хакында монда бирелгән бәяләргә тукталам. Минемчә, бу дәлилсез яла ягу. Ул нәрсәгә нигезләнә соң? Солтангалиевнең татар эшлеклеләренә хат язуынамы (шунысын да әйтим, безгә ул басмачылар хакында бер генә сүз дә язмады), Солтангалиевнең Татарстан вәкиллеге йомышчыларын үз максатларында файдалануынамы, әллә татар эшлеклеләренең элеккеге революцион эшчәнлеге чорында аның белән очрашуларынамы? Ирексездән, бу гаеп җитди нәрсә түгел дигән тәэсир кала. Ә гаеп бик авыр бит. Еллар буена партия белән бер сафта атлап, гаять кыен шартларда милли республикада эшләрне җайга салуга ирешеп кенә калмыйча урыс интәшләр белән үзара аңлашу урнаштырганда, артта калган татар крестьяннарының Совет властена карата уй-фикерләрен уңай якка үзгәрткәндә һәм, ниһаять, Казандагы ике командирлык татар курсларында белем алган егетләр тулы составта Бохарада басмачыларга каршы сугышканда һәм алар югары бүләкләргә һәм мактауга лаек булганда, мондый сүзләрне ишетү бик авыр. Секретарьлар йөзендә ҮК безнең эшчәнлекне күп тапкыр хуплады, моны ип. Сталин да расла‍р. Шуңа күрә мин башта безнең эшчәнлегебезне яхшылап тикшерергә һәм фәкать шуннан соң гына нәтиҗә ясарга кирәк, дип уйлыйм. Ә кайбер иптәшләр урынлы-урынсыз безгә ябышырга торалар. Алар барысын бер өемгә өяләр. Мисал өчен, монда ни өчендер сулларның һәм уңнарның элекътәге көрәшен өстерәп чыгардылар һәм аны тикшерә торган мәсьәлә белән бутарга маташтылар...

Миңа калса, болай эшләргә ярамый. Чөнки бу ике төркемне тәшкил итүче кешеләр һәммәсе дә партия сафларында калалар һәм аларның контрреволюция белән һич тә уртаклыклары юк. Тема буенча сөйләгез, дип ип. Каменев бер чыгыш ясаучыны бүлде дә инде, шуңа күрә мәсьәләдән читләшеп булмас. Шулай да мин уңлык һәм суллык турында берничә сүз әйтми булдыра алмыйм.

Бухарин, соңга калып булса да, XII съездда үзенең ялгышын җүләрлек дип атап бик яхшы эшләде. Ләкин аның милли мәсьәләгә карата карашлары күп еллар дәвамында Шамигулов кебек кешеләрнең башын әйләндереп килде. Алар милли мәсьәләдә үзләрен Ленинга каршы куйдылар. Без Татарстанда ленинча эш иттек. Безнең арада каршылыклар партиянең X съездыннан соң, «суллар» төрле милләтләр арасында социаль-икътисади аерымлыкларны санга сукмый башлагач тирәнәйде. Безнең хаклы булуыбызны партия бик дөрес билгеләп узды. Шушы ук X съездда Төркестандагы кебек кавалерия атакалары системасы тамырдан ялгыш дип бәяләнде. Фәкать шуннан соң гына «суллар» үзләренең хаталарын таныган булдылар.

Киңәшмә барышында без болар белән җентекләбрәк танышырбыз, дип уйлыйм. Мин фәкать Сәетгалиевнең белдерүенә генә тукталмакчы булам. Ул монда 1921 елда үзен, Мәскәү ялчысы буларак 24 сәгать эчендә Татреспубликадан сөрделәр, дип зарланды. Мондый сүзләрне елмаймыйча тыңлап булмый. Чөнки без Керзон илендә яшәмибез ич. Мин сезгә эшнең чынлыкта ничек булганлыгы турында сөйләп бирмәкче булам. Бу фактлар белән Татреспублика өлкә комитетының архивында теләсә кайсы минутта танышырга мөмкин. Эш шунда ки, өлкә комитеты да, партия конференциясе дә Сәетгалиев җитәкләгән хөкүмәт составын сәләтсез дип таптылар һәм эш мәнфәгатьләреннән чыгып аны кайбер иптәшләр белән яңарту турында карар чыгардылар...

С ә е т г а л и е в. Моны яклап конференциядә ничә кеше тавыш бирде?

М о х т а р о в. Күпчелек.

С ә е т г а л и е в. 46 — каршы, 52 — хуплап.

М о х т а р о в. Саннар җыю сезнең эш. Шуннан соң икенче көнне ип. Сәетгалиев ике төркемгә дә керүче татар коммунистларын җыя һәм уңнарны да, сулларны да урыс коммунистларына бердәм булып каршы чыгарга чакыра.

С ә е т г а л и е в. Ялган.

Мохтаров. Мин моны документлар белән раслый алам. Ул урыслар татар эшлекләләрен бертуктамый алыштырып торып, республика белән үзләре идарә итәргә телиләр, дип котыртты. Үзен принципиаль кеше дип санаган коммунист менә шулай бер яктан икенчесенә ташлана аламы? Уннар дип аталучылар, бу — партиягә каршы һәм милләтчеләрчә була дип, аның чакыруына кушылудан баш тарттылар. Алга таба эшләр болай булды. Сәетгалиевнең бер яраны ип. Касыймов өлкә комитетының бу карарына каршы съездның партиясез делегатлары арасында агитация алып барды һәм принципсыз коммунистларның чын йөзен ачты. Шуннан соң өлкә комитеты Сәетгалиевкә Татреспубликадан чыгып китәргә боерды. Кайда монда «Мәскәү ялчысы» һәм «24 сәгать»?

Иптәшләр, сүземнең ахырында тагын бер кат белдерәм. Татреспубликада безгә басмачылар белән баш катырырга вакыт юк. Безнең бу эштә катнашуыбыз һәрвакыт сыйфат ягыннан да, сан ягыннан да югары булган кызыл көч белән билгеләнәчәк.

Скрыпник[3]. Иптәшләр, монда куелган Солтангалиев турында мәсьәлә гади шәхси эш кенә түгел, ул партия сәясәтенә кагыла. Шушы эштән файдаланып, монда безнең партиянең сәясәтен үзгәртергә күп кенә омтылышлар булды. Мин монда шәрыкътә эшләүче иптәшләрнең чыгышларын ишеттем, алар үзләренең иске гөнаһларын искә алып бер-берсеннән үч кайтару белән шөгыльләнделәр. Минемчә, бу көрәш, ызгышларны читкә куеп та торып булыр иде. Ләкин Солтангалиев бу эштән сәясәт ясап, шәрекъ республикаларында эшләүче җитәкче кадрларның составын үзгәртү өчен маташа кебек. Ип. Ибраһимов монда хәтта һәр кешедән аерым-аерым нинди тәре белән чукынуларын сорарга тәкъдим итә. Әгәр ике генә бармак белән чукынсаң һәм Солтангалиевнең барлык элеккеге омтылышларыннан ваз кичмәсәң, син дошман һәм партия сафларында торырга лаек түгел. Бу маташуларның нәрсәгә китерәчәген күрер өчен пәйгамбәр булу кирәкми. Россия коммунистлар партиясенең XII съезды мәсләге белән килешмәүче иптәшләр бу очракны гамәлдә башка юл сабу өчен файдаланмакчы булалар.

Троцкий. Бик дөрес.

Скрыпник. Чынлыкта эшләр шулай тора. Тулаемы белән партия тоткан юлны өнәмәүчеләр, заманында азчылыкта калганлыктан, бу очракны үзләре өчен гүзәл чәчәкләр үстерүдә файдаланмакчы булалар. Мина калса, моңа ирек бирергә ярамый. Әгәр без партия мәсләген ачыклау мәсьәләсенә кагылганбыз икән, ҮКның һәм Үзәк Контроль Комиссиясенең Солтангалиев эшен нинди яссылыкта куюын карарга кирәк.

Партия тормышына кагылышлы һәр җитди мәсьәләне коммунистлар тикшерүенә чыгару кирәк, билгеле. Ләкин Политбюродан һәм Үзәк Комитеттан сорарга рөхсәт итегез: милли мәсьәлә буенча партиябезнең сәясәте турында мәсьәләдә без нәрсә белән эш итәбез? Ике мәгънәсезлек — бөекдержавачылык шовинизмы һәм җирле милләтчелек белән. Партия корабының руле Политбюрода һәм ул аны уңга да, сулга да borгаламаска тиеш. Мин Солтангалиев эшен бу киңәшмәгә кую безнең юлны чуалтмагае дип куркам.

Ип. Ленин үзенең әлеге басылмаган, ләкин бик тә мәгълүм хатында бөекдержавачылык шовинизмы белән нәтиҗәле көрәш алып баруны беренче чираттагы бурыч дип билгеләде һәм ул Сталин доклады буенча XII съездда кабул да ителде. Шушы җәһәттән мин борынгыларның бер йоласы хакында искә төшермәкче булам. Берәр бинаны сала башлаганчы, алар аның нигезенә нинди дә булса җинаятьчене яки колны корбанга чала торган булганнар. Әгәр безнең партия сәясәте өчен муафыйк булса, кан коюдан курыкмаска кирәк...

Солтангалиев эшенә бәйле рәвештә тагын бер сорау туа. Без милли тайпылыш белән эш итәбезме, әллә тайпылышны бозу беләнме? Үзәк Контроль Комиссиясе Шәрекъ республикаларында милли тайпылышлар булуын таныды, монысы уртак күренеш. Ләкин Солтангалиев эшендә без яңа факт — бу тайпылышның гарип чагылышы белән бәрелешәбез. Чыгыш ясаучылар күренешләрнең монысын да, тегесен дә җәяләр эченә алып сөйләделәр. Үзәк Контроль Комиссиясе белән ризалашкан булдылар, ләкин чынлыкта аңа каршы чыктылар. Мин, Солтангалиев эше һәммәбезгә мәгълүм җирлектә туып үсмәде, дип исәплим. Ул партиябез сәясәте кысаларына һич тә туры килми. Ә монда чыгыш ясаучы кайбер иптәшләр, Солтангалиев эшен XII съезд карарлары китереп чыгарды, дип расламакчы булалар, ул гына милли стихияне тудырды, дип лаф оралар һәм бу күренешнең киләчәктә дә милли республикаларда котылгысызлыгын дәлилләп маташалар.

Бу — партиянең мәсләген бозып күрсәтү. Безнең әлегә кадәр бөекдержавачылык шовинизмыннан котылганыбыз юк. Кичә бер иптәш монда, милли респуб-

ликаларның кирәклегенә шикләнгән кеше бар, дип әйтте. Делегация буенча минем иптәшем Мануильский исә елмаеп: «Ул Мануильский булмас»,— дип белдерде. Ничек кенә булмасын, милли республикаларның яшәвен кирәксез һәм зарарлы хәл дип исәпләүчеләр җитәрлек әле. Моны бөекдержавачылык шаукымы дип бәяләргә кирәктер. Бу очракта, тайпылышларга каршы көрәшеп, без таякны бөгеп җибәрмәскә тиеш. Бөтен кешене һәм барлык нәрсәләрне тигезләргә ярамый. Солтангалиев эше фәкать бер тайпылышның чамадан тышлыгын гына күрсәтә һәм аның объектив кыйммәте дә шунда. Партия тоткан юлга ревизия ясауның хаҗәте юк.

Партиянең мәсьәләгә какшамас булып калырга тиеш. Безгә, Үзәк Контроль Комиссиясе резолюциясендә билгеләп үтелгәнчә, җирле коммунистларның җирле милләтчелеккә каршы урыннарда көрәш алып барырга дигән сүзләрен программа дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк. Бөекдержавачыл шовинизм шаукымы белән көрәшнең көчәйтелергә тиешлеген күрсәткән XII съезд карарлары да тайпылышсыз төстә гамәлгә ашырылсын. Аны юк итүгә ирешсәк, без солтангалиевчелекнең тамырына да балта чабачакбыз. Солтангалиев эшен шулай аңларга кирәк. Ип. Фрунзе, киләчәктә без Украинада да, башка төбәкләрдә дә милләтчелек күренешләре белән очрашачакбыз, дип дөрес әйтми.

Фрунзе. Очрашачакбыз әле.

Скрыпник. Куркытмагыз, ип. Фрунзе. Хаинлеккә алып бара торган милләтчелек тайпылышы солтангалиевчелек тантана итүче бөекдержавачыл шовинизм яшәгәндә, шушы җирлектә милләтчелек туганда гына шытып чыгарга мөмкин. Мин милләтчелектән дә, бөекдержавачылыктан да котылырбыз һәм солтангалиевчелекнең тамырына балта чабарбыз, дип ышанам.

Тагын бер нәрсә турында әйтмәкче булам. Аны гамәлгә ашыру өчен, ип. Хуҗанов әйткәнчә, партия җәмәгатьчелеге кирәк. Монда ишеткәннәрдән чыгып фикер йөрткәндә, күп кенә урыннарда бу көч юк икән. Сүзләр күп булды, ләкин чын ихластан әйтелгәне генә сирәк очрады. Без, украиналылар, күп шауладык, күп кычкырдык, буза куптардык, ләкин ничек кенә булса да партия мәсләгендә калдык. Әгәр шәрекъτән килгән иптәшләр сәяси сүз уйнатуларны бер читкә куеп торсалар, нәтиҗәле партия эшчәнлеге өчен сәламәт җирлек туачак. Ул чакта алар үзләренең һәр сүзләрен һәм гамәлләрен Троцкий белән Сталинга ишарәләп сөйләмәсләр һәм кылмаслар дип уйлыйм.

Рыскулов. Мин монда чыгыш ясаучы кайбер иптәшләрнең минем нотыгыма кагылышлы кайбер фикерләренә белешмә биреп китәр өчен сүз алдым.

Иң элек суллар турындагы мәсьәлә буенча. Кайберәүләр мине сул коммунистларны тәнкыйтьләде дип аңлаганнар һәм автоматик рәвештә уңнарның җырчысы ясап куйганнар. Мин монда карата үз фикеремне белдерергә тиеш, дип саныйм. Мин үземне сулларга кертәм һәм моны шәхси гаризам белән генә түгел, ә бөтен гомерем белән дә раслый алам. Мисалга минем 1919 елдагы эшчәнлегемне генә алыгыз. Күптән түгел чит илдә чыга торган «Дни» газетасында минем 1919 елда ач халыкны коткарып калу өчен, нинди милләттән булуына карамастан, һәр хәлле кешедән артык азык-төлекне тартып алырга тәкъдим итүем хакында язып чыктылар. Ләкин урыс милләтендәге тимер юлчылар кереп оялаган Үзәк Башкарма комитет аны кире какты. Моңа охшаш мисалларны мин тагын да китерә алыр идем. Үзен сул дип атаган кеше үз эшчәнлегенә генә сылтанмыйча, социаль чыгышына да басым ясый. Ә мин сулларны ничек аңлыйм. Мин сул булмаска, алар белән көрәшергә кирәк, димим бит. Сулның да төрлесе бар. Мәгълүм принципиаль мәсләктә торучы һәм үзләренең карашларын ачык чагылдыручы суллар була. Әйтик, шәрекъ яшьләре. Без сафларыбызны шулар хисабына тулыландырырга тиеш. Яшьләр феодализм калдыкларына, карагруһ руханиларга, буржуазиягә каршы көрәшә. Ләкин партия сафларына очраклы рәвештә килеп кергән, үзен сул коммунист дип атап автономияләрне бетерергә, көнендә коммунизм төзергә өндәүче суллар да бар. Бу инде суллык түгел, ә контрреволюция, Совет властена кизәнү. Мондый кешеләр Төркестанда буа буарлык. Кичә генә уң булып йөргән кешеләр дәрәҗәле эшкә урнашу өчен бүген сулга әверелсә, боларны ихлас коммунистлар дип һич тә атап булмый. Ә мондый фактлар җитәрлек, аларга каршы көрәшергә кирәк. Басмачылар хәрәкәтен кузгату өчен җан атучы сулларның да тамыры корытылырга тиеш. Партия позициясендә торучылар, хезмәт халкына таянучылар — болар бөтенләй башка нәрсә, аларга тел-теш тидермик. Мин үземне дә шулар рәтенә кертәм.

Менә сезгә тагын бер факт. Җыелышны ачар алдыннан үзен сул дип йөрүче Сәетгалиев, Солтангалиевне яклаучылар үз фикерләрен ачыктан-ачык белдермәячәкләр дигән булып, Солтангалиев мәсьәләсен көн тәртибендә икенче пункт

итеп карарга тәкъдим ясый. Моны ничек анларга? Монда җыелган күренекле партия һәм Совет җитәкчеләренең барысы да куркак һәм икейөзле булып чыга түгелме соң? Бу тәкъдим фәкать нәфрәт кенә уята. Монда утыручыларның һәммәсе дә Үзәк Комитетка мәгълүм һәм безнең арадан контрлар эзләү — үзе контрлык. Бу бәндә үзенең чыгышында азык-төлек җыюдагы тырышлыклары белән мактангач, мине автономияләрне бетерүгә каршы чыгуда гаепли. Боларның барысы да фәкать карьеризм галәмәтләре генә. Әгәр аларның сүзен тыңлап Төркестанда автономияне юк итсәң, басмачылар хәрәкәтенең коточкыч киң колач алачагында тамчы да шик юк. Мондый җыелышларга үзегезнең татар эшләрен, татар низагларын чыгару һич тә ярамый. Солтангалиев эшенең Шәрекъкә, чын Шәрекъкә һәм Урта Азиягә бер катнашы юк. Монда мин, имеш, сул коммунистлар Шәрекъкә эшкә килмәскә тиешләр, дип әйткәнмен. Мине дөрес аңламаганнар. Мин, Шәрекъкә килгән суллар анда да үз мәсләкләрендә калып һәм шартлар белән исәпләшмичә, контрреволюциягә юл ачарга мөмкиннәр генә, дидем. Чыннан да мондый сулларга бездә урын юк. Әгәр иптәшләр партия юлыннан тайпылмыйча чын коммунистлар сәясәтен үткәрсәләр, моңа кем каршы төшсен?

Уңнарга килгәндә, мин аларны да, уң тайпылыш гөнаһлары булганнарны да бөтенләй якламадым. Җирле уң коммунистлардан басмачылар ягына качучылар да җитәрлек булды. Монда Госманхуҗаевның исемен телгә алдылар. Ул минем белән эшләмәде, Бохарадан булса кирәк.

Троцкий. Үзәк Башкарма комитет рәисе.

Рыскулов. Госманхуҗаев белән уртак эшем булмады. Бәлки, башкалар очрашканнардыр да. Вәлидине 1920 елда күрдем, без Үзәк Комитет куйган мәсьәләләр хакында киңәштек. Ул чакта Вәлиди югары урын били һәм Үзәк Комитет аның белән исәпләшә иде. Вәлиди Башреспубликага җитәкчелек итте. Вәлидинең элек кем булуын белмим, Үзәк Комитет аңа ышаныч күрсәткәнгә, без аның кайчан да булса начар юлга кереп китәчәге хакында башыбызга да китереп карамадык.

Миннән, син ни өчен Солтангалиевнең кылган гамәлләрен фаш итмәдең, дип сорыйлар. Билгеле, аны хөкем итәргә кирәк һәм Үзәк Контроль Комиссиясенең резолюциясе дөрес. Миннән башка да моны эшләүчеләр күп һәм бу җәһәттән Үзәк Комитет үзенең карарын чыгарган инде дип уйлап, мин сүз боткасы куертмадым. Үземнең кем икәнемне һәм үтә кызыл коммунист булуымны күрсәтү өчен генә мин «Солтангалиевне атарга кирәк» дип тавыш куптара алмыйм. Бу сабыйлык булыр иде. Әйткәнемчә, мин Үзәк Контроль Комиссиясенең резолюциясе белән килешәм һәм монда беренчи йомшаклык күрсәтелергә тиеш түгел. Ләкин Солтангалиевне ул хат алышкан кешеләр белән бутау һәм барысын бер өемгә өю ярамый. Сак булырга кирәк. Бәлки карашлары Солтангалиевнеке кебек үк булган кешеләр дә табылыр. Ип. Скрыпникның, барлык автономияле республикаларда һәм өлкәләрдә эшләүче барлык җитәкче кадрларны алыштырырга, сулларны төрмәгә утыртырга, ә уң тайпылыш күрсәтүчеләрне юк итәргә кирәк, дигән сүзләренә килгәндә, мин моны чынлыкта милли мәсьәлә буенча партиянең XII съезды карарларын өзү дип бәялим. Үземнең съездда ясаган чыгышымда да, хәзер дә бу карарлар бик дөрес һәм чынбарлык таләпләренә җавап бирәләр, дип әйттем. Ләкин урыннарда хәлләр гаять катлаулы булганга, мин алар сүздә генә калырлар, дип шикләнәм. Җирле аппаратларда съезд карарлары белән килешмәгән кешеләр күпчелек тәшкил итә. Моңа тагын суллыкны һәм минминлекне дә кушсаң — бу XII съезд карарларының тәмам йомылып калуын аңлата. Бу карарлар буш сүзләргә әвереләчәк һәм барысы да кәгазьдә генә калачак, ә чынлыкта урыннарда беренчи үзгәреш тә булмаячак. Шуңа күрә үз инануларың хакында сөйләү һәм аларга тугры калу, крестьяннарга вак буржуага, зыялыларга мөнәсәбәттә дөрес сәясәт алып бару бер нәрсә, ә монда автономияләрне бетерергә кирәк дип кычкыру һәм шуннан чыгып партиянең XII съезды карарларына бөтенләй туры килмәгән нәтиҗә ясау — икенче нәрсә, дип уйлыйм. Һәм мин монда суллар буларак чыгыш ясаучы эшлекләләргә, шәрекътә сезне (Ибраһимовны да, Сәетгалиевне дә) һәм сезнең суллыкны да белмиләр, дип әйтергә тиешмен. Безгә үзебезнең сулларны тәрбияләү кулайрак булачак.

Рәис. Мин ип. Рыскуловның кайбер фикерләренә карата искәрмә ясарга тиеш. Мин аның көн тәртибендәге мәсьәләләрнең урыннарын алыштырырга кирәк дигән сүзләрен аңлап җиткермәдем кебек. Ул аны кемнәрнедер тотарга, электерергә җыену белән аңлата дигән тәэсир кала. Әгәр бу тәкъдимдә мондый тәсмер булса, мин аны һич тә кабатлатмаган булыр идем.

Петров[4]. Иптәшләр, безне, җирле милләт вәкилләрен, бигрәк тә мине, Солтангалиев мәсьәләсе битараф калдыра алмый. Мин Милләтләр эше Халык Комиссариатында җаваплы урын биләүче һәм, гомумән, безнең революциядә, бигрәк тә Татреспубликада күренекле роль уйнаучы атаклы милли эшлекленең антикоммунизмда, Советка каршы хәрәкәттә гаепләнүе һәм партиядән чыгарылуы турында телеграмма алгач, тәмам аптырап калдым. Мин хәтта, Үзәк Контроль Комиссиясе ялгышмаганмы икән, дип шикләнеп тә куйдым. Үзәк Контроль Комиссиясе докладыннан соң шикләрем акланмады. Мин Үзәк Контроль Комиссиясенең дә, Үзәк Комитетның да бик дөрес карар чыгаруларына ышандым...

Солтангалиев эше буенча тиешле анализ ясалганмы, юкмы икәне Үзәк Контроль Комиссиясе докладыннан күренмәде, ләкин ул эшләнгән булырга тиеш, тик бу анализ киңәшмә игътибарына гына җиткерелмәде. Солтангалиевчелек мәсьәләсен тикшергәндә, без бу агымга кушылган теге яисә бу иптәшнең шәхси йөзен читләтеп үтә алмыйбыз. Минем карашымча, солтангалиевчелекне тудыручы сәбәпләрнең иң мөһиме — безнең партия учреждениеләрендә милли сәясәтне дөрес итеп үткәрә белмәү. Милли мәсьәлә буенча X съезд карарлары да, партия Үзәк Комитетының күрсәтмәләре дә урыннарда танымаслык булып бозыла. Һәм мин моны солтангалиевчелекне тудыручы сәбәпләрнең берсе дияр идем. Көн тәртибенең икенче мәсьәләсен тикшергәндә моңа игътибар бирелер дип өметләнәм. Үземнең фикерләремне раслар өчен мин Мари өлкәсенә кагылышлы берничә фактка тукталмакчы булам.

Бездә милли сәясәт дөрес үткәрелмәде. (Хәзер ул ничек уздырыладыр, белмим, мин хәзер башка губернада эшлим.) Шушы хаталар нәтиҗәсендә, бездә аңлашылмаучанлык даими килеп чыгып торды. Үзәккә якын урнашкан өлкә булуыбызга карамастан, без ялгыш артыннан ялгыш ясадык. Моңа үзәктә утыручы җаваплы кешеләрнең милли сәясәтне белмәүләре дә сәбәпче булды. Безнең Мари өлкәсендә килеп чыккан бер гауга аздан кына короллы бәрелеш белән тәмамланмады. Аңа нокта куяр өчен безгә ҮКның җаваплы инструкторы ип. Кубякны җибәрделәр. Партия комитетының тантаналы утырышында ул тантаналы төстә безнең партия тормышында милли сәясәтнең бернинди әһәмияте юк, без аны халык массаларының мәхәббәтен яулап алыр өчен генә кулланабыз, дип белдерде.

Троцкий. Моны кем әйтте?

Петров. Моны партия Үзәк Комитетының җаваплы инструкторы ип. Кубяк әйтте. Бу белдерүнең җыелган халыкка ничек тәэсир итүен сөйләп тормыйм, ләкин утырыш тәмамлануга ук мари халкы вәкилләре, без партиянең милли сәясәтен бөтенләй башкача аңлыйбыз, дип шаулаша башладылар. Җаваплы хезмәткәрнең югары партия органы исеменнән шундый белдерү белән чыгыш ясавы автономияле республикалар һәм өлкәләр партия оешмаларының бөтен эшчәнлеген юк дәрәҗәсенә калдыра. Нәкъ менә шундый белдерүләр солтангалиевчелекне тудыра.

Киңәшмәдә төп игътибар Солтангалиевнең шәхесенә түгел, ә солтангалиевчелеккә бирелергә тиеш дип уйлыйм. Солтангалиевне җәзага тартудан солтангалиевчелек яшәүдән туктаса, мин бу резолюция өчен ике куллап тавыш бирер идем. Ләкин, урыннарда дөрес милли сәясәт үткәрмәгәндә, бу күренеш сакланып калачак. Дөрес сәясәт булмаса, аның урынына солтангалиевчелекнең башка формалары киләчәк һәм без җыелып һаман шул бер балык башын чәйнәргә мәҗбүр ителәчәкбез.

Ербанов[5]. Иптәшләр, мондый зур һәм җаваплы җыелышта мин беренче тапкыр чыгыш ясыйм. Бурят-Монгол автономияле өлкәсе вәкиле буларак, фикер алышуларны бик зур игътибар белән күзәттем. Солтангалиев эшенә теге яки бу республикаларда бара торган процесслардан чыгып кына бәя бирү җитеп бетмәс дип уйлыйм. Мин безнең партия оешмаларында милли тайпылышлар бар һәм аның тамырлары тирәнгә китә диюче иптәшләр белән тулысынча килешәм.

Без автономияле республикаларда һәм өлкәләрдә, аерым алганда, әйтик, Бурят-Монгол өлкәсендә, марксизмны тирән аңлаучы кешеләрнең аз булуын онытмаска тиеш. Күпчелек төбәкләрдә чын мәгънәсендә коммунистик, марксистик партияләр юк, дип әйтергә батырчылык итәм. Без барыбыз да диярлек вак буржуа, милли рухтагы зыялылар даирәсеннән килдек. Шуңа күрә бездә «уңга», «сулга» тайпылулар һәм сөрлегүләр булмасын өчен Үзәк Комитет урыннарда марксистик мәсләкнең ничек саклануын даими күзәтеп торырга тиеш.

Революциянең фәкать алтынчы елында гына мондый гаять эшлекле карарның чыгарылуы гаҗәпкә калдыра. Бу мәсьәләләрнең барысы да әле 1918 — 1919

елларда ук, ягъни автономияле республикалар һәм өлкәләр оештырылганчы хәл ителергә тиеш иде. Ә хәзер безгә, урыннардагы җаваплы кешеләргә, үтә кыен шартларда эшләргә туры килә. Җирле халыкның күпчелеге милләтчелек рухында тәрбияләнгән һәм вак буржуа психологиясе белән агуланган. Зыялыларыбыз — үтә чыккан милләтчеләр, өстәвенә руханилар басым ясый. Шуңа күрә без, яшь милли кадрлар, үз казаныбызда кайныйбыз. Үзәк Комитет аерым автономияләрдәге шартларны исәпкә алган анык күрсәтмәләр бирми. Һәм болар барысы да безне үтә кыен хәлләргә куя.

Мин монда үзара аңлашу юк дип әйтергә теләмим, ләкин элемтәләрнең йомшак булуын танырга кирәк. Үзәк Комитет урыннардагы хәлләрдән тиешенчә хәбәрдар түгел, ул төбәкләрдәге төркемнәр хакында начар белә. Шуңа күрә Үзәк Комитет, партия оешмаларындагы тәҗрибәне өйрәнеп, һәр республикада һәм өлкәдә ныклы тәртип урнаштырырга тиеш. Шунсыз һич мөмкин түгел. Без адым саен төрле катлаулы мәсьәләләр белән очрашабыз. Әйтик, зыялылар белән безнең мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш? Бу чиктән тыш кыен сорау. Бурятия өлкәсендә ул бер төрле, ә Татарстанда бөтенләй башкача. Дин мәсьәләләрендә дә шул ук хәл. Кабатлап әйтәм, үзәктәге иптәшләр моңа житди игътибар бирсеннәр иде. Моның өчен Үзәк Комитет каршында махсус орган булдыру максатка ярашлы булыр иде.

Мин тагын бөекдержавачыл шовинизмга да тукталмакчы булам. Дәлилләрдән башлыйм. Ип. Кобозев йөзендә Ерак Көнчыгыш ревкомы милли сәясәтне үткәрүдә төрле бозуларга юл куя. Мәсәлән, өлкәләрне берләштерү мәсьәләсен күтәргәч, безне империализмда, милләтчелектә, басып алуда һәм башка гөнаһларда гаепләргә тотындылар. Безне Япон империалистларына тапшыру өчен Байкал тимер юлын кулга төшерүдә гаепләделәр. Мин бу мисалны үзәкнең урыннарда эшләүче кешеләр белән тиешенчә шөгыльләнмәвен күрсәтү өчен генә китердем. Дөрес, ип. Сталин да, Троцкий да, башкалар да мондый мәгънәсез нәрсәләр әйтмәделәр, ә менә Кобозев кебек җавапсыз иптәш телен тыя белми. Безнең Советка каршы зыялыларыбыз, ломаларыбыз, диндар хезмәткәрләребез моны күтәреп кенә алдылар һәм үз мәнфәгатьләрендә файдаландылар. Әгәр алга таба да шулай эшләсәк, халык: «Бетсен коммунистлар, бетсен Совет власте», — дип кычкыра башлаячак.

... Тупас кына әйткәндә, безнең өлкәләрдәге һәм республикалардагы коммунистик оешма әгъзаларын ике төркемгә бүләргә була. Беренчесенә милли зыялылар белән элемтәләрен өзеп бетермәгән, белепме-белмичәме милләтчеләр җырын җырлаган милли рухтагы коммунистлар керә. Икенчесе «сул»га авышкан һәм үзләрен чын марксистлар дип шапырынып йөргән бәндәләрдән тора. Үзәк Комитет аларның икесе белән дә рәхимсез көрәшергә тиеш.

Мине Ибраһимов кебек кешеләрнең чыгышлары гаҗәпләндерә. Минем Милләтләр эше Халык Комиссариатында булганым, иптәшләрне тыңлаганым булды. Татарлар төркемендәге низаглар хакында да белә идем. Ибраһимов, Солтангалиев үзенең сәясәтен Мәскәүдән торып үткәрде, Татарстаннан килгән язмалар Мәскәүдә языллды, монда кул гына куелды, дип сөйләде. Ип. Ибраһимов, сез моны белә торып нигә Үзәк Комитетка хәбәр итмәдегез? (Тавыш: ҮКта материал бар). Солтангалиевнең партиядә тору-тормау мәсьәләсен күптән куярга кирәк иде.

Ниһаять, өлкә һәм республика партия оешмаларында тимер тәртип юк. Үзәк Комитет урыннардагы башбаштаклыкларны бетерү өстендә эшләргә тиеш, чөнки алар ыгы-зыгы чыгаралар, төрле төркемнәр тудыралар. «Уңнар» да, «суллар» да кирәкми. Коммунистлар партиясе бер генә, әгәр XII съезд карарларын үтәмисең икән, син безнең сафларда булырга тиеш түгел. «Уң коммунист», «сул коммунист», Троцкий тарафдары, Бухарин иярчене, дип дөнья болгатырга кирәкми.

Н и м в и ц к и й[6]. Иптәшләр, монда төп мәсьәлә Солтангалиев эше түгел, ә солтангалиевчелек. Мин солтангалиевчелекне уң тайпылыш белән тиңләмим. Ул — партияне эчтән таркатып, аны үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга маташучы контрреволюцион оешма. Моны без авыз тутырып әйтергә тиешбез. Солтангалиевнең бөтен эшчәнлеге аның барып чыккан милләтче булуын күрсәтә. Без аның идея ягыннан вәлидичеләр белән тыгыз бәйләнгәнен беләбез. Иптәшләр аның әле революциягә кадәр үк контрреволюцион газетада хезмәткәр булуын, Вәлиди белән берлектә Шәрык халыкларының аерым коммунистлар партиясе программасын эшләүдә катнашуын әйттеләр инде. Ул Вәлидинең БҮБК кә мөрәҗәгатен эшләүдә дә катнашты. Солтангалиевнең бөтен эшчәнлеге хаталану гына булудан ерак тора. Ул гомере буе сафларыбызны таркатырга тырышты һәм Совет властена каршы көрәште. Моны, яңа икътисади сәясәт нәтиҗәсендә баш

калкыткан урыс шовинизмының кайтавазы гына, дип әйтеп булмый. Солтангалиев корткычлык эшен уйлап, планлы алып барды. Вакыт җитмәгәнгә, мин монда аның бөтен гонаһларын ачып биргән барлык материалларны да бәян итә алмыйм. Әйтелгәннәре дә җитеп ашкан.

Урындагы һәр чыгыш, һәр адым нәкъ менә шушы төркем күзлегеннән, Солтангалиев күзлегеннән, милли низагларны киңәйтү күзлегеннән, коммунистлар партиясе белән көрәшү һәм аны таркату күзлегеннән чыгып бәяләнде. Чакырылмаган кунак сыйфатында (ә аңа беркем дә чакыру җибәрмәде һәм, шул исәптән, без дә) Башкортстанга съездга килгәч, ул ин элек партиясезләр белән бергә үз тарафдарларының утырышын уздырды һәм анда җыелганнарга үзенең шовинистик фикерләрен һәм карашларын җиткерде. Соңрак ул үзенең бу ярannарыннан акча җыеп җибәрүләрен сорады. Ә алар моның кадәр акчаны кайдан табарга тиешләр иде соң? Дәүләт казнасыннанмы? Ирексездән күңелдә шундый сорау туа, чөнки саклык кассаларындагы процентлардан гына моның кадәр акча табуы шикле. Бу хәл безнең совет аппараты эшен дә көйсезләндермичә калмагандыр. Мин монда бер нәрсәгә басым ясарга тиеш: безгә Контроль Комиссиясе резолюциясен, һичшиксез, тулыландырырга кирәк. Бу резолюция берьяклы. Һаман бер балык башын чәйнәп, «бөекдержавачыл шовинизм, бөекдержавачыл шовинизм» дип сөрән салуга чик куярга кирәк. Ип. Орджоникидзе монда йөз процентка хаклы. Эш бөтенләй башкача тора. Безгә урыннарда нинди шартларда эшләргә туры килүен сез күз алдыгызга да китермисез. Үз коммунистларың мохитында эшләү бер нәрсә, ә менә басмачылар белән, Вәлиди белән бердәм фронт төзергә әзер торган контрреволюционерлар чолганышында эшләү бөтенләй икенче нәрсә. Мондый шартларда үзең дә сизмәстән төрле хаталар, тайпылышлар ясавың мөмкин. Әгәр без Үзәк Контроль Комиссиясе резолюциясе белән генә чикләнеп калсак, солтангалиевчелекне кискен төстә хөкем итмәсәк, бөекдержавачылык шовинизмы белән никадәр генә көрәшсәк тә, бу хәрәкәтне тамырыннан йолкып ташлый алмаячакбыз. Без моны аңларга тиеш. Аннан килеп, Үзәк Контроль Комиссиясе резолюциясен монда чыгыш ясаган иптәшләрнең кайберләре үз мәнфәгатьләрендә файдаландылар да инде. Аларның берсе таякны бөгеп кенә калмады, сындырып ук чыгарды. Ул хәтта Солтангалиевне бөекдержавачыл шовинизм корбаны диюгә кадәр барып җитте, аны партия сафларында калдырырга мөмкин, дигән фикер уздырды. Ип. Петровның чыгышын нәкъ менә шушы рухтагы нотык дип билгеләп була. Нотыкчыларның күпчелеге солтангалиевчелекне законлы күренеш дип бәяләде, партия сафларында басмачылар белән элемтә тотучы кешеләр булуга гадәти бер факт итеп карадылар. Мин моны һич тә аңлый алмыйм. Мондый йомшаклык — җинаять ул. Без мондый элементларга партиядә урын юк дип ачык һәм кистереп әйтергә тиешбез. Мин теге яки бу республикадагы эшлекләләрне тулы составта тикшерергә һәм барлык уңнарны куарга тәкъдим итмим. Мин фәкать безнең партия солтангалиевчеләрдән арынырга тиеш дип уйлыйм. Шунсыз урыннарда коммунистик элементлар тәрбияләргә дигән өндәмәләр буш сүзләр генә булып калачак. Коммунистик рухлы, ләкин әле чыныгу алмаган яшь эшлекләләр Солтангалиев кебек зур стажлы коммунистларга хөрмәт саклыйлар. Алар хәтта, Ленин белән бергә, аның сурәтләрен дә бастыралар. Без яшьләрне күзгә күренеп торган мондый коммунистлардан араларга тиешбез. Алар үсеп килүче буынны агуламасын өчен бөтенесен дә эшләргә кирәк.

Шулай итеп, әгәр без хәзер тиешле катылык күрсәтмәсәк, солтангалиевчелек кебек күренешләр белән ярты елга бер тапкыр очрашып торачакбыз, җыелышып акыл сатачакбыз, ә бер адым да алга китеш булмаячак.

Тагын бер төзәтмә кертмәкче булам. Кичә монда ип. Халиков үзенең чыгышында Үзәк Комитет вәкиле ип. Петерс, Башкортстанда бернинди урыс шовинизмы юк, ә фәкать башкорт милләтчелеге генә яши, дип белдерде. Иптәшләр, бу дөрес түгел һәм мин моңа кискен каршы чыгам. Ип. Петерс конференциядә башкорт эшлекләләренең Үзәк Комитетка хат җибәрүләре һәм анда үзләренең урыс коммунистлары тарафыннан эзәрлекләнүләре хакында бәян итте. Ләкин конференциядә моны инкарь итеп яисә дөресләп чыгучы бер генә кеше дә булмады. Алга таба ип. Петерс бу шикаятьнең материаллар һәм фактлар белән расланмавын әйтте. Ул бездә урыс шовинизмы юк дип һич тә әйтә алмый иде, чөнки өлкә комитетының урыс шовинизмы һәм җирле милләтчелек белән көрәшү турындагы резолюциясен эшләүдә үзе дә катнашты...

Троцкий. Иптәшләр, Солтангалиев эшен көн тәртибенә беренче мәсьәлә итеп кертеп без бик дөрес эшләдек, дип уйлыйм, чөнки фикер алышулар вакытында кайбер иптәшләрнең мәсьәләгә хокукый яктан якын килүе ачыкланды. Аерым

алганда, ип. Нимвицкий Солтангалиевнен агитация өчен акчаны кайдан алуы белән кызыксынды. Иптәшләр, без судта түгел, без мәсьәләне сәяси яссылыкта карарга тиеш. Күпләр моны дөрес аңлый.

Монда, Солтангалиев кем ул, дип баш ваттылар. Бу күренеш милли тайпылыш кынамы, әллә турыдан-туры хаинлекме? Солтангалиев, эшчәнлеге контрреволюцион төс ала башлагач, кулга төште. Монысы шиксез. Бу хаинлек нинди жирлектә үсеп чыкты соң? Безгә төрек илчелеге үзенең агентын җибәрдеме? Ул агент, коммунист булып кыланып һәм безнең ышанычка кереп, контрреволюция белән шөгыльләнә башладымы? Әгәр эш шул рәвешле торса, мондый киңәшмә җыеп баш катырырга кирәк тә булмас иде. Мәсьәлә башкача тора. Солтангалиев безнең партия сафларында торган хәлдә милләтчелек юлына басты, шушы фикерендә үҗәтләнде һәм, фракция көрәше чорын атлап, дәүләткә хакимлек итүгә кадәр барып житте. Эшнең асылы шунда. Солтангалиев һәм аның идеяләре нәкъ менә шуңа күрә куркыныч та. Алар безне эчтән таркатып, Совет властеның тамырына балта чаба. Киңәшмә солтангалиевчелеккә күренеш буларак бәя бирергә тиеш. Солтангалиевнең җинаятьләрен суд карасын, тиешле җәзасын бирсен, ә без аны хаинлеккә китергән сәбәпләрне ачарга тиеш. Алар икәү. Беренче сәбәп — татарларның һәм, гомумән, изелгән милләтләрнең коточкыч авыр хәле. Бу елларда без аларның тормышларын аз гына булса да юлга сала алмадык. Шуның нәтиҗәсендә вак милләт халыклары безнең режимга ышанмыйча карыйлар, аны якламыйлар. Икенче сәбәп — Солтангалиев тирәсендәге иптәшләр аңа вакытында тиешле кисәтү ясамадылар, узындырдылар (Тавыш: Дөрес). Менә сезгә дәлилләр. Кайбер татар эшлеклеләре монда Солтангалиевне яклап килгәннәр иде. Минем янда ип. Енбаев һәм башка иптәшләр булды. Без аңлашырга тырыштык. Ул чакта мин аларга, Солтангалиев эшендә хата да булырга мөмкин, дигән идем. Әйтик, аны пычрату өчен кемдер ялган хатлар язган, ди. Бу очракта документларны җентекләп тикшерергә кирәк. Алар моңа каршы: «Бәлки, татарлардан тәрҗемә дөрес булмагандыр?» — дип сорау бирделәр. Мин тәрҗемәне тикшерүне үтенеп тиешле учреждениеләргә мөрәҗәгать иттем, ләкин җинаятчел хатлар урыс телендә язылган булып чыкты. Яхшы. Бу йә хата, йә дөрес, дип уйлыйм. Әгәр дөрес булып чыкса, без 1918 — 1919 елларда гражданнар сугышы законнары буенча Солтангалиевне атып үтергән булыр идек, мөгаен, дим. Алар да моның белән килеште. Шуннан соң мин ип. Енбаевтан: «Бер минутка гына булса да Солтангалиевне басмачылар белән элемтәдә торучы итеп күз алдына китерә аласызмы?» — дип сорадым. Ул кырт кисеп «юк» дип җавап бирде. «Карашларыгыз туры килә идеме?» — дим. Ул: «Гомумән алганда, туры килә иде», — диде. Мин аңардан: «Аның мондый җинаять эшләүгә барып житүенә ышанмыйсызмы?» — дип сорадым. Ул: «Мөмкин түгел, юк», — дип җавап бирде.

Иптәшләр, дөрес аңлавыгызны үтенәм, мин Енбаевны солтангалиевчелектә гаепләргә теләмим. Ә менә аларның вакытында аны туктата алмаулары бик кызганыч. Алар, бөекдержавачылык шовинизмы белән көрәшеп, җирле милләтчелекне бөтенләй оныттылар. Солтангалиев эше — шуның нәтиҗәсе. Аны мин упкын кырыеның чиге белән чагыштырыр идем. Чөнки бу чиктән бер генә адым тайпылсаң да, барысы да ишелә башлый. Киңәшмәнең резолюциясендә дә ул чагылыш табарга тиеш.

Алга таба мин ип. Фирдәвес сүзләренә тукталмакчы булам. Ул: «Солтангалиев белән күпләр хат алышты һәм монда бернинди гөнаһ юк», — диде. Мин дә моңа кушылам. Хат алышу гына Совет хөкүмәтенә хыянәт итү дигән сүз түгел әле. Аның белән хәбәрләшеп торган иптәшләрнең барысы да дошман түгел. Алар ялгышырга, юлдан тайпылырга мөмкиннәр, ләкин алар, белепме-белмичәме, дошман тегермәненә су койдылар. Шуңа күрә мин мондый иптәшләргә алга таба да үз урыннарда калу кирәкме икән? — дип сорыйм. Аларга: «Әйе, мин моңа кадәр хәвефне күрмәдем, Совет власте дошманы белән элемтә тоттым», — дип хәзер үзләрен чолгап алган мохиттән чыгарга һәм партиягә якынрак районнарга күчәргәдер? Кайбер иптәшләргә бу хакта уйлап карау һич тә комачауламас иде. Болар бар да «суллар» хаклы дигәнне аңлатамы соң? Бу сорауны алар үзләре күтәрде. Алар хәтта суллыкны ниндидер өстенлекләр бирә торган индульгенция дип тә аңлыйлар булса кирәк. Эш киресенчә тора, бу хәл фәкать сулларның никадәр хәвефле икәнен һәм алар белән көрәшергә кирәклеген генә күрсәтә. Монда бу фикерне «суллар беркайчан да сатмыйлар» дигән булып безгә сеңдерергә маташтылар. Кичәге бәхәсләр балалар уенын хәтерләтте. Берәүләр, «уңнар»дан фәлән иптәш басмачыларга качты, дип төкерек чәчә, икенчеләр, «суллар» хаинлек белән шөгыльләнде, дип тарткалаштылар. Әгәр 1918 — 1919 елларда «суллар» һәм «уңнар» чиратлашып дошман ягына качсалар, хәзер моны

башлыча «уңнардан» күтәргә була, аларның кайберләре партия кайда бетеп, дошман кайдан башланганын оныта башладылар.

Т а в ы ш. Бу һәрвакыт шулай булды.

Т р о ц к и й. Монда «һәрвакыт» диләр. Мин 19 нчы елдагы хаинлекләр статистикасы белән шөгыльләнергә теләмим. Безгә бүгенге мәшәкатьләр дә бик житкән. «Суллар үзебезнеке», диләр. Риза, ләкин «үзебезнекеләр» эш-гамәлләре белән уңнарга ярдәм иткән очракта нишләргә? «Үзеңнекеннән дә ныграк пычратучы һәм сатучы юк»,— дигән француз мәкале бар. Кайберәүләр яхшы ният белән дөньяның астын өскә шундый әйләндерергә мөмкиннәр ки, аларның бу «изгелекләрен» төзәтү өчен бөтен гомер дә житмәячәк. Ип. Шәмигуловның да «үзебезнеке» булуында шик юк. 19 нчы елда миңа Уфада ҮК кушуы буенча бер партия низагын тикшерергә туры килде. Губерна комитетында, әгәр ялгышмасам, ип. Шәмигулов та бар иде.

Т а в ы ш. Дөрес. Һәм Вәлиди.

Т р о ц к и й. Вәлиди ул утырышта булмады, аны соңрак чакырттылар. Дөресен әйтим, мин Уфадаң бик ярсып кайттым һәм иң кискен чаралар күрергә тәкъдим иттем (Аларның кайсылары күрелде, кайсылары кире кагылды). Ул чакта мин шәмигуловчылыкның нәрсә белән янавын аңлап бик нык борчылган идем. Әйткәнемчә, бу безнең эчке куркыныч. Алар, суллар, сатмаячаклар, дошман ягына да качмаслар, ләкин бу үтә кызыл бәндәләр халыкның күп өлешен бездән биздерәчәк... Монда шик юк. Һәрвакытта да һәм барлык дуслар да дошманнан яхшы булмаска мөмкин.

Ип. Мануильский сөйләгәндә мин чәчләремне йолкып бетерә яздым. Аның чыгышы урыс-украин теленә күчерелгән шәмигуловчылыкны хәтерләтә. Мануильский икеләнергә юл калдырмыйча: «XII съезд карарлары яхшысын яхшы да, ләкин сез крестьян чуалышлары чыгардыгыз»,— ди. Күргәнегезчә, бу стихия хәтта безнең киңәшмәгә дә басым ясый. Моннан тыш ул: әгәр XII съезд карарлары бөек урыслар кулы белән уздырылмаса, барысы да җимереләчәк, дип куркыта. Болар аның үз сүзләре. Иптәшләр, XII съезд карарларын ип. Мануильский кебек бозарга һич тә ярамый...

М а н у и л ь с к и й. Ип. Троцкий, съезд резолюциясен бозучы башкалар да бар.

Т р о ц к и й. Мин бу минутта шушы трибунадан торып партиягә зур зыян салучылар хакында сөйлим. Ип. Мануильский нәрсә диде? Сез, бөек урыс иптәшләр, XII съезд карарларын үзегез генә үтәгез инде, ди. Ләкин бу съезд резолюциясенең асылын кире кагу түгелмени? Соңгы съездда крестьян стихиясе турында мәсьәлә буенча бәхәсләрнең нинди яссылыкта алып барылуын исегезгә төшерегез. Бөек Россия турында сөйләгәндә «крестьян стихиясе» белән бәйләнешкә кермәсә, аның белән дөрес мөнәсәбәтләр урнаштырмаса, пролетариатның сынагыгын аңлыйлар да кебек. Ләкин сүз Әзербайҗанга һәм Төркестанга кагылса, шушы ук күренешне «йөгәнсез крестьян стихиясе» дип атыйлар. Ләкин ике сыйныф арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыру турында кайгырту бу ике республикада да шушы ук социаль катламнарга юнәлдерелгән. Боларга тагын милли кыенлыклар гына килеп өстәлә. Без милли мәсьәләне беренче тапкыр гына күтәрмибез. Хәзер илдә чагыштырмача тотрыклы хәл һәм партия тынычлап, ашыкмыйча гына милли мәсьәләнең төрле якларын тикшерә ала. XII съезд карарларының асылы һәм әһәмияте шунда. Ә монда безгә: «Крестьян стихиясен йөгәненнән ычкындырмагыз», «урыслар, съезд карарларын үзегез үтәгез»,— дип акыл саталар. Мәсьәләне болай куярга ярамый.

Монда ип. Сәетгалиев (ул да үзебезнеке) безгә үзенең ип. Ленинга тәкъдим иткән сорауларын укыды. Башта ул ип. Ленинның җавапларын хәбәр итәргә теләмәде (күрәсең, аның ип. Ленин белән яшерен эшләре булган һәм алар икесе дә бер фракциядә торганнар) (көлү). Ләкин бөтен киңәшмә сорагач, укырга мәҗбүр булды. Сез Сәетгалиевнең төрле хәйләкәр сораулар биреп, ип. Лениннан: «Әйе, сез хаклы, ип. Сәетгалиев»,— дип әйттерергә теләгәнен сизгәнсездер дип уйлыйм. Бу ысулын ул бүген миңа карата да кулланды. Аның тел төбеннән: «Әгәр сез, ип. Троцкий, минем фикерләремне уртаклашмасагыз, начар компаниягә эләгәчәксез»,— дигән нәрсәне аңлап була иде.

Ип. Сәетгалиев Лениннан үзе теләгән җавапларны ала алмады. Милли республикалар яшәргә тиешме, дигән сорауга ул «әйе» дип җавап бирә. «Озакмы?»— дигәнгә исә, мөгаен, беркадәр шикләнеп булса кирәк: «әйе, озак»,— ди. (Көлүләр). Урыс коммунистлары җирле коммунистларга мөнәсәбәттә педагоглар ролен башкарырга тиешләрме, дигән өченче сорауга ул кистереп: «Юк, ярдәмчеләренә караган кебек карарга тиешләр»,— ди. Игътибар итегез! Ләкин

монда чыгыш ясаган ип. Нимвицкийнын тоны ярдәмче тонына бер дә охшамаган.

Нимвицкий. Мин Солтангалиевкә ярдәм итәргә теләмим.

Троцкий. Мине аңларга теләмичә сез миңа шулай җавап бирәсез икән, башкорт иптәшләренең анардан нинди җавап ишетәчәкләре күзгә күренеп тора. Һәм, ниһаять, дүртенче сорау (Сәетгалиев өчен ул иң кызыклысы булса кирәк). Ул милли сәясәттә үзенен дөрес караштa тору-тормавы белән кызыксына. Ип. Ленин аңа: «Ике фракциянен эшчәнлекләре хакында да төгәл фактлар китерегез»,— ди. Нәкъ менә шуңа күрә ип. Сәетгалиев ике ел буена бу хат хакында әйтмәгән дә. Мондагы иптәшләрнен кайберләре: уннар яки суллар белән булу, кадрларны исәпкә алу һәм эшкә билгеләү буенча законсыз ике бүлекнең кайсысында тору, һичшиксез, кирәкме, дип сорадылар. Хәтерегездә калган булса, Сәетгалиев тә үзендә шундый ук кадрлар бүлеге булуын таныды. Шулай булгач, партия уставында каралган кадрлар бүлегеннән тыш, Солтангалиев житәкләгән контрреволюцион кадрлар бүлеге һәм Сәетгалиевка якын торган кадрлар да бар икән. Монда чыгыш ясаучы Хыдыралиев, Икрамов, Хуҗанов шушы ике бүлекнең кайсысында торырга дигән сорауга бик дөрес җавап бирделәр. Берсендә дә катнашырга ярамый — аларның мәсләге безнең юлга туры килә. Ни өчен?

Мин монда «суллар» һәм Нимвицкий кебек иптәшләргә аларның бу милли республикаларда коммунистлар тәрбияләү эшенең кыен булуын бәяләп бетермәүләрен әйтергә тиешмен. Анда социаль мәгънәдә генә түгел, ә бөтенләй катып калган мохит саклана. Бу төбәкләрдә житештерү көчләре дә, промышленность та үсми, ә кайбер районнарда, киресенчә, кими бара. Кыенлыкларның нигезе шунда.

Хәлләр шулай торганда суллык та, уңлык та тиешле нәтиҗә бирми, ә менә РКП белән тыгыз элемтәдә тору, иртәме-соңмы, уңышларны тәэмин итәчәк. Шуңа күрә без үзебез өчен, бая әйткәнемчә, «алда упкын» дип чик булдырырга тиеш. Нәкъ менә шуңа күрә без тормыш төбеннән чыккан милли коммунистлар белән бик сак мөгалләмә итик. Турысын әйтим, Башкортстанда яки теләсә кайсы башка республикада түбән катламнан күтәрелгән һәм безнең белән бәйле булган ихлас күңелле коммунист шул районлагы тимер юлчыдан ун тапкыр кыйммәтрәк. Ни өчен? Чөнки соңгысын Мәскәүдә тәрбияләргә кирәк, аннары тиешле урынга күчерергә, ә башкорт коммунисты — бөтенләй икенче нәрсә. Без аның аркылы урында тирән элемтәләр урнаштырабыз һәм бу бәйләнешләр киләчәктә зур нәтиҗәләр бирәчәк.

Мин республикаларда һәм өлкәләрдә үзләренен хатыннары, әниләре һәм башка туган-тумачалары аша зур җир мәйданнары кулга төшергән һәм җирле халык белән көрәшүче урыс кулаклары белән бәйләнеп беткән менә дигән эшчеләр, шул ук тимер юлчылар булуын әйтеп тормыйм. Бу да бик җитди фактор. Еш кына пролетариат хакимияте һәм иске колонизаторлык сүтеп булмый торган төенгә укмаша. Шуның өчен без оста итеп сәяси маневр ясый белергә тиешбез. Менә шундый катлаулы шартларда партия нинди хәлдә кала соң? Монда кайбер иптәшләр, аерым алганда ип. Ербанов, Үзәк Комитетны күрсәтмәләр бирмәүдә гаепләде. Ләкин мин аның сүзләре урынсыз дип беләм. Чөнки үзәктән торып һәр очрак өчен боерыклар әзерләп утырырга мөмкин түгел, шартларны исәпкә алып, моның белән урындагы партия оешмалары шөгыльләнергә тиеш. Әлегә кадәр үзәк уңнарны суллар белән һәм киресенчә чиратлаштырып алыштырып торды. Шуның нәтиҗәсендә республикаларда чын коммунистик агымнар туа башлады. Ләкин бу агымнар уңнарны да, сулларны да турайтырлык дәрәҗәдә көчле түгел әле. Урыннарда алдынгы карашлы милли эшлеклеләр дә шушы ук маневрга өйрәнергә тиешләр. Ә бу — чын сәнгать. Бүгенге киңәшмә бу юнәлештә яңа сәясәтне тизләтергә ярдәм итәргә тиеш. Үзләренең милли җирлегендә актив маневр ясап, безнең милли эшлеклеләр дә партия сәясәтенең әле бер, әле икенче ягын алга сөреп, уңнарны да, сулларны да тиешенчә файдалансын иде. Киңәшмәбезнең төп максаты да шушы. Без урыннардагы милли «суллыкны» җиңәргә, Солтангалиев эшеннән файдаланып «уңлык» авыруыннан котылырга тиеш. Менә шуннан соң тегe яки бу якка авышмыйча чын милли сәясәт үткәреп булачак.

Безнең бүгенге киңәшмә милли мәсьәләне XII съезд каравына чыгаруның никадәр вакытлы булуын күрсәтә. Элек моңа шикләнеп караганнар да хәзер ышанганнардыр дип өметләнәм. Политбюро әгъзасы буларак, миңа төрле милли эшлеклеләр белән очрашырга туры килде. Алар еш кына: «Сез шуңа игътибар итегез әле, үзәктәге күп кенә җаваплы хезмәткәрләр XII съезд карарларын фәкать тышкы сәясәт өчен генә кирәк, дип раслыйлар»,— дип миңа сорау бирәләр. «Моны сезгә кем әйтте?»,— дип сорыйм. Нигә сез бу хакта рәсми рәвештә

белдермисез, фәлән-фәлән партия әгъзасы фәлән көнне һәм фәлән урында XII съезд карарларын практик әһәмияткә ия түгел, ә тышкы сәясәт өчен генә кабул ителде, дип Үзәк Комитетка хәбәр итмисез? Моны кем һәм кайда шулай сөйләп йөри? Күптән түгел мин башкорт эшлекләләре белән шул хакта сөйләштем. Мин аларга: «Һич тә шикләнмәгез, әгәр берәр җаваплы хезмәткәр мөһим принципиаль карарларны халыкның күзен буяу өчен генә чыгарылган нәрсә дип аңлатса, Үзәк Комитет аны партиядән чыгарырга тәкъдим итәр һәм Үзәк Контроль Комиссиясе моңа ризалык бирер иде»,— дип әйттем.

Көн тәртибендәге икенче мәсьәләне тикшергәндә без урыннарда коммунистлар тәрбияләүгә зур игътибар бирәчәкбез. Ип. Икрамов үзенең бик әйбәт чыгышында моңа бик дөрес тукталды. Безгә бу юнәлештә икеләтелгән көч белән эшләргә кирәк. Ләкин вакыты җитмәгәнгә мин аны әлегә калдырып торам.

Сүземне тәмамлаганда тагын бер нәрсәгә тукталам. Кайбер милли эшлекләләр белән сөйләшкәндә мин аларның юк кына нәрсәгә дә бик тиз үпкәләүләренә игътибар иттем. Бүген монда ип. Орджоникидзе «сартлар бар да караңгы» дип урысларның үзбәкләрне Ташкент вокзалына кертмәүләре турында сөйләде. Шуннан соң үзбәкнең моңа ничек хәтере калачагын күз алдына китерү кыен түгел. Бер башкорт коммунисты да бу җәһәттән миңа менә болайрак сөйләгән иде: Үзәктәге коммунистлар без милли сәясәтне ничек үткәрергә кирәк икәнен беләбез диләр, ә үзләре башкорт төрмәсенә кергәч, монда сасы, дип борыннарын тотып тышка йөгерәләр». Монда чыгыш ясаган Петров — мари. Ул да безгә шуңа охшашлы хат язып җибәрде. Аның мари өен ничек атаганы хәтеремдә калмаган, ләкин ул урыс коммунисты, сасыдан куркып, өйгә керми, ди... Бу дөресме соң? Чыннан да шулай булгандыр, бәлки. Мондый өй эченә мари коммунисты да кермәскә мөмкин. Ләкин бу очракта милли җирлектә ризасызлык тумас иде. Болар бар да милли мәсьәләдә гадәттән тыш сак булырга кирәклеген күрсәтә. Тирмәдәге авыр истән күптән азат булган башкорт яки марига да сасылык ошамаска мөмкин. Ләкин ул — үз кеше. Ә менә халыкның гореф-гадәтләрен, телен белмәгән урыс эшлеклесенә тирмәдәге һава авыр тоелса, бөтенләй башка. Бу милли мин-минлек, Совет властена кизәнү очрагы. Менә шуңа күрә милли республикалардагы җирле яшьләрдән чын коммунистик кадрлар әзерләү — партиябезнең төп бурычларыннан берсе.

Сталин. Мин монда чыгыш ясаган иптәшләрнең нотыкларына карата үземнең фикерләремне белдерү өчен сүз алдым. Солтангалиев эшенә бәйле рәвештә мәсьәләнең принципиаль ягына килгәндә, мин аны көн тәртибенең икенче өлешендә ясаячак докладымда яктыртырга тырышачакмын.

Беренче чиратта киңәшмәнең үзе турында. Кемдер монда (исемен оныттым), бу киңәшмә гадәттән тыш вакыйга, диде. Бу дөрес түгел. Безнең партия өчен аны яңалык дип әйтергә ярамый. Совет властеның яшәү чорында бу киңәшмә — дүртенчесе. 1919 ел башына кадәр 3 киңәшмә булды. Ул чакта аларны чакыру өчен мөмкинлекләр бар иде. 1919 елдан соң, без баш-аягыбыз белән гражданнар сугышына кереп чумган 1920 — 1921 елларда, киңәшмә җыерга безнең мөмкинлекләребез булмады. Сугыш тәмамлангач, хуҗалык төзелеше белән шөгыльләнә башлагач, милли республикаларда һәм өлкәләрдә партия эше тәгәлрәк алып барыла башлагач, мондый мөмкинлек яңадан туды. Мин урыннарда сәясәт алып баручылар һәм бу сәясәтне эшләүчеләр арасында үзара аңлашуга ирешү өчен Үзәк Комитет бу чараны бер генә тапкыр файдаланмас, дип уйлыйм. Без моның белән генә дә чикләнеп калырга уйламыйбыз. Конкрет карарлар кабул итү өчен аерым республикалар һәм өлкәләр буенча да киңәш-табыш итү максатка ярашлы булачак. Мәсьәләне шулай куйганда гына Үзәк Комитет та, урындагы иптәшләр дә канәгать калырлар, дип уйлыйм.

Монда кайбер иптәшләр минем Солтангалиевне яклавым, аның яшерен хаты белән танышып та бернинди чара күрмәвем турында сөйләделәр. Чыннан да, мин аның Әдһәмовка язган хаты белән таныштым. Ә менә ип. Әдһәмов үзе ни өчендер дәшми, уйлап карасаң, ул бүген бөтен кешедән күбрәк сөйләргә тиеш иде кебек. Мине монда Солтангалиевне тешем-тырнагым белән яклауда гаепләделәр. Әйе, мин аны соңгы минутка кадәр яклап һәм саклап килдем. Һәм моны үземнең бурычым дип санадым һәм саныйм. Ләкин мин аны мәгълүм бер чиккә килеп җиткәнче генә якладым. Солтангалиев шушы чикне узгач, мин аңардан баш тарттым. Аның беренче яшерен хаты Солтангалиевнең партия белән араны өзүе хакында сөйли. Чөнки ул Үзәк Комитет әгъзалары турында дошманнар хакында язган кебек яза. Мин аның белән очраклы рәвештә Политбюрода очраштым. Ул Җир эшләре халык комиссариаты исеменнән Татреспублика мәнфәгатьләрен якларга дип килгән иде. Ул чакта мин аны бик нык кисәттем, аның яшерен хатын

партиягә каршы документ дип атадым. Вәлиди оешмасы рәвешендәге хәрәкәт оештырырга маташуда гаепләдем һәм болай булса аны яклаудан баш тартачагым турында әйттем. Ул унайсызланды һәм үзенең Әдһәмовка язган хатында партиягә, Советка каршы бер генә сүз дә юк иде, дип аклана башлады. Ул мина чын коммунист булып калачагы хакында сүз бирде. Ә бер атнадан соң Солтангалиев икенче яшерен хат яза һәм Әдһәмовтан басмачылар һәм аларның лидеры Вәлиди белән элемтәгә кертүен, ә хатны юк итүен сорый. Шулай итеп, ул мине оятсыз рәвештә алдады һәм мин Солтангалиев белән араны өздем. Шушы сәгатьтән соң ул минем өчен дошманга, партия сукбаена әверелде. Берничә тапкыр үтенсә дә, мин аны кабул итмәдем. Фактлар шундый. Сул иптәшләр мине 1919 елда Солтангалиев белән әшнәлектә, аны яклауда гаепләделәр. Чыннан да, мин аны партия өчен саклап калырга тырыштым. Чөнки Шәрык республикаларында зыялылар димим, ә укый-яза белүчеләр дә бармак белән генә санарлык. Ничек аларны якламыйсың ди? Кирәкле кешеләрне череп таркалудан саклау өчен тырышмау җинаять булыр иде. Ләкин һәр нәрсәнең чиге була. Ә бу чик, Солтангалиев коммунистлар партиясе сафыннан дошман лагерена атлагач, упкынга әверелде. Шул вакыттан башлап ул партия өчен яшәүдән туктады. Нәкъ менә шуның өчен төрек илчесе аңа партиябез Үзәк Комитеты әгъзасыннан кадерлерәк кешегә әверелде.

Мине ип. Шәмигулов та, әйтеп торган өстенә, Вәлидине яклауда, аны партия өчен саклап калырга тырышуда гаепләп чыкты. Әйе, мин, чыннан да, Вәлидине якладым, ул төзәлер, дип өметләндем. Андыйлар гына түгел, бөтенләй чеп-чи контрреволюционерлар да төзәлә иде бит. Моңа мисаллар җитәрлек. Мин ул чакта: Шәмигулов мәсьәләне үтә беркатлы хәл итә, дип уйладым, аның киңәшен тотмадым. Дөрес, Шәмигуловның фаразлары бер елдан соң акланды. Вәлиди төзәлмәде, ул басмачыларга китте. Ләкин аны бер ел партиядә тотудан оттык. Әгәр 1919 елда Вәлидине юк иткән булсак, Мортазин[7], Әдһәмов, Халиков һәм башка иптәшләр ул очракта безнең сафларда калмаган булырлар иде.

Тавыш. Халиков калыр иде.

Сталин. Бәлки ип. Халиков калган да булыр иде, ләкин безнең күп кенә иптәшләр Вәлиди белән киткән булыр иде. Сабырлыгыбыз һәм зирәклегебез аркасында без менә нәрсәгә ирештек...

## Искәрмәләр:

1. Мануильский Дмитрий (1883—1959)—1903 елдан РКП(б) әгъзасы, Украина җитәкчеләренең берсе, РКП(б) ҮК әгъзасы. Соңрак Коминтерн органнарында һәм дипломатик эшләрдә эшли.

2. Мохтаров Кашшаф (1896—1937)—1918 елдан РКП(б) әгъзасы, 1923 елда Тат. АССР ХКС рәисе. Соңрак Мәскәүдә төрле җитәкче эшләрдә. 1929 елда «Солтангалиев эше» буенча кулга алына. Үлем хөкеме 10 ел хезмәт белән төзәтү лагерена алыштырылган, 1930 елдан җәза вакытын Соловки махсус лагеренда уза. 1937 елда шунда атып үтерелә.

3. Скрыпник Николай (1872—1933)—1897 елдан РКП(б) әгъзасы. 1923 елдан Украина җитәкчеләреннән берсе, РКП(б) ҮК әгъзалыгына кандидат. 1933 елда үзен-үзе үтерә.

4. Петров И. П.—Мари Автономияле Өлкәсен оештыру дәверендә Вакытлы революцион комитет рәисе, 1917 елдан РКП(б) әгъзасы.

5. Ербанов Михаил (1889—1938)—1917 елдан партия әгъзасы. 1923—27 елларда Бурят-Монгол АССР ХКС һәм ЧБК рәисе. Соңрак бүтән җаваплы вазифалар башкара. Репрессия корбаны.

6. Нимвицкий Борис (1885—1969)—1905 елдан РКП(б) әгъзасы. Гражданнар сугышы елларында Уфа губернасында җитәкче вазифаларын башкара. 1922 елдан—РКП(б)нын Башкортстан ӨК секретаре. 1923 елда аннан чакыртып алына.

7. Мортазин Муса—Башкортстанның күренекле хәрби эшлеклесе, 1919 ел башларында З. Вәлиди белән бергә кызыллар ягына чыга, гражданнар сугышында актив катнаша. Хәрби академия тәмамлый, корпус командиры була. 1937 елда атып үтерелә.

# КУЗГАЛДЫ УЙЛАРЫМ...

Хрестоматияләргә «җиз иләк» аша гына үтеп кергән әдәбиятны укып үскән һәм «айт» дигәнгә, «тайт» дип кенә җавап бирергә өйрәнгән безнең буын өчен бүген чыга башлаган әсәрләрне укыйм да, хәйран калып утырам. «Сәясәт бер дә тотрыклы нәрсә түгел икән»,— дим, ул патшаларның үзләре идарә иткән вакытындагы бер дулкын кебек икән, һәрвакыт үзенең ярларын чәбәкләп тора. Тынып торган чаклары да булгалый. Ярлары, инде аның, крәстиян белән эшчеләр кебек тоела. Рәсәй патшаларының карашына яраклы рәвештә халкыбыз тормышының чагылышы әдәби әсәрләрдә дә үзгәрә тора. Тик шунысы гына уртак: Петр патша заманнарыннан алып бүгенге көнгә кадәр крәстиян һәм эшче халыкны «алар үзләрен кол хайван хәлендә дә бик яхшы хис итәләр» дип күпләр эчтән куаналар. Шулай булмый ни — һәр чорның шуңа гына яраклашкан акыл ияләре икенчеләрен кысрыклый бара бит. Төрле юллар белән югары үрләгән белемсез «зыялылар» үз фикерле, кыю шәхесләрне яратмый, җаны-тәне белән күрә алмый, җаһиллек чәчәк ата. Матбугат руле тирәсен зәвыксыз, үз фикере булмаган, сәясәт җитәкчеләре сүзеннән чыкмаган ялчылар баса. Сирәк-мирәк килеп чыккалаган «ак чәүкәләрне» (урыста ул «белая ворона») юк итәргә дә күп сорамыйлар. Ватан сугышы елларында укып йөргәндә, бер партада утырган иптәшем Ядгәр исемле малай тышсыз бер китап алып килгән иде. «Укырга ярамый торган китап»,— диде ул аны. Шуңа күрә без бигрәк тә кызыксындык һәм кат-кат укыдык бу китапны. Ул «Фәхрине үтереп ташладылар...» дип башланган иде. Шулай булса да, ни өчен укырга ярамый торган китап икәнен аңламадык ул вакытта. Үсә төшкәч, күпме эзләсәм дә бу китапны китапханәләрдә табып булмады. Тик «җылы җилләр» искәч кенә, бу китапны табып, тагын да бөртекләп укырга туры килде. Ул Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы икән. Менә бит заманалар ничек үзгәрә!

Язучы Фоат Садриевның «Таң җиле» романы да шулай ук үтереш белән башланып китә. Тик вакыйгалар ямьле Ык буе авылларының берсендә бара. Әсәр хәзерге тормышны күрсәтүгә багышланган.

Мин тәнкыйтьче дә, язучы да түгел. Мин — әдәбият сөюче, укырга яратам, уйланам, хозурланам. Укыган әсәрдәге геройлар белән бергә яшим: көләм, хәтта җылыйм да, күңелем йомшак, чөнки хәзер без үскән чордагы эпизодларны чагылдырган әсәрләр күбәеп китте. Менә «Казан утлары» журналының 1992 ел 10 һәм 11 саннарында Фоат Садриевның «Таң җиле» романы басылып дөньяга чыкты. Әсәр бүгенге көндә булган вакыйгалар белән, чигенешләр ясап бара, үткәннәр дә мавыктыргыч итеп бирелгән. Төп герой Нуриасма — һәр авылда яшәгән «ак чәүкә» кебек, халык күзенә дә, җитәкчеләр күзенә дәерактан күренеп торган аерым бер тип. Ул гомум популяциядән ерак торган, үзгәрми торган, бирешми торган узаман итеп сурәтләнгән. Гомеренең соңгы вакыты килеп җиткәндә ире Сәгыйдулласын аздырган, гомер буе бергә фермада эшләгән иптәше Хәдичәгә бәхиллек бирә, чөнки ул монда үзенең гаепле икәнен таный. Ә авыл халкын талаучы спекулянт Бәрия, ире Сәгыйдулланың сеңлесе булса да, бәхиллек ала алмады. «Авыл тарихында бәхиллек бирмәү хәлләре бик сирәк була торган хәл иде»... Бәриянең болай булу сәбәпләрен аңлау дәрәҗәсенә үсеп җитмәгән Нуриасма. Заманның, Сталин сәясәтенең җимеше икәнен аңласа, бәхиллек биргән булыр иде. Хәер, балаларының таралып бетүе сәбәпләрен дә аңлаган булыр иде әле, таң җиле иртәрәк исмәде шул.

Нуриасма — изге ана. Нәселдән килгән эшсөючәнлек аның балалары Фәрит, Шәрифҗан, Илсөяр, Мизхәт каннарында да бар. Нуриасманың үз сүзләре белән әйтсәк «адәм баласының кендеге, әнисе карыныннан өзелү белән, җиргә тоташырга тиеш» дип тәрбияли ул, «эш атлары» әзерли. Каты да була белә, гаделлек тәрбияләргә дә тырыша.

Торгынлыкның гөрләп торган муллык заманнарында ата-ана үз баласын тәмле ашарга, күп йокларга, эшләмәскә өйрәтте. «Үзебез бик интегеп үстек, балаларыбыз рәхәтен күрсеннәр», янәсе. Хатын-кыз, кортка-сартка, әби-бабай чәй белән генә хушланмадылар, «мәе» булмаса, аш — ашка, чәй — чәйгә саналмый башлады. Нуриасма бу юлга никадәре генә керергә тырышмаса да, көчле агым үзенекен итә, елганың икенче ярына туры чыгу мөмкин түгел.

«Бөтенесенә шәһәр гаепле, балаларымны шәһәр урлады»,— дип яшәгән Нуриасма соңгы вакытларда моның сәбәбе ниндидер бүтән нәрсәләрдә икәнен аңлый башлый. Балаларын читкә үзе дә куалашкан икән ләбаса ул. Авылда ач-ялангач килеш көрәк-сәнәк тотып, бил бөгәргә хокук бар, ә яшәргә мөмкинлек юк. Җиденче классны бетергәч, Фәрит техникумга укырга кермәкче була, авылга агроном булып кайтам, дип хыяллана. Шуна колхоздан китәргә рөхсәт сорап, Нуриасма райком секретарена кадәр барып житә. Әмма теләгенә ирешми. «Теләсәң нишлә, улым»,— ди ул кул селтәп. Бернинди документсыз авылдан чыгып кача мескен бала. Әнә кая барып чыкты, күмер вата. Ярый, ватсын, ил өчен анысы да кирәк. Ә татарча белмәүче ике кызы? Шәрифҗанның өч баласы. Шәрифҗанын бигрәк тә нык жәлли Нуриасма. Өч ел авыл хуҗалыгы институтына имтихан бирергә барды, өчесендә дә урыс теленнән үтмәде. Күп тырыша торгач, хәрби училищега җибәрделәр, марҗага өйләнде, анысы урыс теленнән имтихан алып тормаган үзе тагы. Өйләнешкәч, парлашып бер генә мәртәбә кайталар, анда да Нуриасманың йөрәгенә кан савылып кала. Татарча сөйләшә башласалар, «ка-ка»гызны туктатыгыз»,— дип үпкәли, марҗа килен...

Илсөяре врач булам, диде, урыс мәктәбендә укып, теләгенә иреште. Тик, институт бетергәч, үзебезгә түгел, әллә кая Урал ягына җибәрделәр. Шунда бер үзбәккә тормышка чыкты, шунда төпләнделәр. Кияү дә әйбәт, фатирлары да әйбәт, тик балалары гына ни татарча, ни үзбәкчә юньләп белмиләр. Соң шулай булгач, Нуриасманың төпчек баласын авылда калдырырга хакы юкмыни? Хәдичәнең Суфиясен әрмән алып киткән кебек, аның Мизхәтен дә берәрсе алып китсенмени? Ата-бабаларыбызның телен, гореф-гадәтләрен белүче, моңын-җырын аңлаучы оныклары шушы нигездә дөнья көтәчәгенә ышанып үләргә хакы юкмыни аның? Бусына тагын кемнән рөхсәт сорарга? Чыгып бетмәгән жаныбызны әз генә булса калдырыгыз, үзебезчә яшәргә, ана телебездә сөйләшергә, үзебезчә җырларга-биергә рөхсәт итегезче, дип салган уртак сөрән бөтен ил буенча яңгырамыймени?! Анда бит татар балалары тавышы гына түгел. Юк, җитте, нәселнең соңгы тамырын корытырга ирек бирмәячәк ул!..»

Дөньяда ук тәмуг утлары кичеп, оҗмахка керерлек авыл карчыклары Нуриасма, Разия, Мәһинур, Мөсаллия, Гыйзденисаларның иң зур бәхетләре — үзләренең авылларына җирләнүләре, ата-бабалары белән янәшә булулары.

...Урак өсте. Матур табигатьле Ык буйлары. Кылны кырыкка ярыр вакыт булуга карамастан, төрле дәрәҗәдәге түрәләрнең орчыгы үзенә кирәген эрләп тора. Колхоз рәисе Хөснуллин уңны-сулны белештерми эш атларын җигеп, фаҗигале юлга керә. Аннары коры гына котылу өчен, үрмәкечтәй ау корып, төрле юллар эзли. Рәхимлек күрсәтү төсендәге усаллыкларның төрле вариантларын файдаланырга тырыша. Машина, телефон, ит-май, ашлык аның карамагында, йөгергәләп торучы хыянәтчеләр хыянәт хакына бәхет эзлиләр, вакытлыча аны табуга да ирешәләр. Ул сәясәт белән күтәрелгән, житәкчелек абруен татыган, халыкның фаҗигасеннән тәм таба, үзенә хөрмәт казануда остара һәм башкалардан өстен булу өчен бөтен көчен сала. Кылганнары өчен беркем алдында да җавап бирми. Ваемсыз ашап-эчү аркасында ерткыч кыяфәтенә кергән, юан түгәрәк гәүдәсе алга тәгәрәгәндәй, тар маңгае өстендә җирән чәчләр артка сыпырылган, бөрешкән кендек тишеге хәтерләтүче кечкенә күзләр. Кызыл калын иреннәре туктаусыз хәрәкәттә, иреннәре белән бергә түгәрәк яңагы гына түгел, бөтен бите селкенеп тора. Кәтүк кебек эчкә баткан борыны гына хәрәкәтсез. Колхозның партком секретаре тәлинкә тотучыга әверелгән. Ә тегесе үз сүзләре итеп язганны да дөрес укый алмый бит, тотлыга-ялгыша. Рәмзинең үлеменә сәбәпче булып та, аның якыннары алдында, халык каршында үзенне акларга теләү өчен, шушы гөнаһны эшләү өчен ни дәрәҗәдә намуссыз булырга кирәк?!

Рәмзине үтереп ташлаганнар. Дөресе шулай. Шушы авылдагы иң оста, уңган кешелекле кешенең үлеменә кемнәрнең нинди дәрәҗәдә гаепле булуы романны

укучыга ачыклана бара. Язучы укучы алдына ачык итеп тасвирлаган күренешләр — хушлашу-бәхиллек бирү, юу, озату, кумүдәге картлар тәбәрак укуы, кабернең дүрт почмагына чүгәләп салават әйтү... Безнең халыкның күмү йолалары. Борынгыдан килгән мондый йолаларны хәзер кайбер авылларда коммунистик динсезлек белән яшәп картайганнар белмиләр. Эш атлары фани дөньядан да иртәрәк китә. Хәснуллин кебекләр исә озаграк яшәүчән була, шулай булгач, алар нинди йола тәртипләрен белсеннәр ди...

Җәйнең көне-төне эштән ыңгырашкан печән өсте вакытында бер җирләү йоласында булырга туры килде. Кабер казучылар җимерек койма аша кереп кабер казыганнар, турыга гына казып бетергәч, авылга кайтып әйттеләр, машина белән мәрхүмне каберстанга алып бардылар, кыеш капканы көчкә каерып ачып керделәр, җирләделәр, балалары берничә сүзне җылый-җылый әйткәләде дә, авылга кайтып киттеләр. Мәрхүмнең өчесен үткәрүдә, ниһаять, «китап сүзләре» ишетәселәре килде. Авылда мулла юк икән, әнә фәлән корткa укый, диделәр. Өстәлне әйләнеп утырып тыңлый башлыйбыз дигәндә, нишлибез, минем укый торган дәфтәр өйдә калган, ди бу корткa. Тиз генә «Жигули»гә утырып алып та килә, дәфтәрдән карап укып та чыга. Хәерләр өләшенә. Мәрхүмнең яхшылыкларын күпләп искә алалар. Каяндыр берсе, җаен туры китереп, сүзне Горбачев, Ельцин, Гайдар, кыйммәтчелек, юклык турында башлап җибәрә. Кайда нәрсә бар, кем нәрсә әйткән, берсен-берсе бүлдереп сөйли башлыйлар, туктатмалы да түгел. Әрмиядә үлүчеләр, имгәнеп-тукмалып кайтучылар да калмады... Бу корткалар барысыннан да хәбәрдар икән ләбаса, дип уйлыйсың.

Чү, укучым, ә соң бу корткаларның, картларның бала-чагасыз калуларына, динсез һәм денсез булуларына, озакламый татар авылы юкка чыгуларга, телнең урыслаша баруына, (безнең якта башкортлаштырырга тырышуны да өстәп), йолаларыбыз, уеннар, җырлар, гадәтләребез үзгәрүгә кем гаепле булуы да романда сизелеп-сизелеп кала. Мөселман дөньясын юкка чыгаруга корылган борынгыдан килгән урыс сәясәте моны башкару өчен нинди генә ялтыравыклы итеп тә, куркыныч итеп тә, ачка интектереп тә, ялангач калдырырга тырышып та, тагын әллә ниләр кыйландырып та тырыштыра, хәтта бер җәмгыять икенче белән алышынгач та дәвам итә. Менә кемнәр өстеннән таң җиле истерәсе бар. Билгеле, Батыршалар, Солтангалиевләр, Бәйрәмовалар, Айдар Хәлимнәр, Яушевлар кебек кыю, асыл ирләребез һәм кызларыбыз тормыш дөреслегенә әйдәп, күзләребезне ачарга ярдәм итәләр. Минемчә, автор үз геройлары аша тормышыбызның бу өлешен укучыга уйлау өчен ирекле калдыра.

Фоат Садриев үз романының буеннан буена бөтен әйтәсе килгән фикерләрен ике капма-каршы образ: Хәдичә белән Нуриасма образлары аша укучыга житкерергә тырыша. Болар һәр авылда, һәр фермада бар. Язмышлары — ачы, бәхетсезлекләре — уртак, икесен дә бер үк гаделсезлек китереп кыса, аларның котылу яки хәлне җиңеләйтү өчен тырышулары гына төрле. «Юк, алай түгел, болай ул»,— дип әйтә алмады алар, сәбәпләре күп иде. Әйтеп кенә кара! Шулай бервакыт, сыерын җигеп сабан сөрергә бармаган өчен, бригадир бер малайны, бәдрәфтә качкан җиреннән тотып алып, каеш чыбыркы белән суктыра. Бер кат күлмәктән, ачлы-туклы малай ни эшләсен соң! Бүген дә исән алар, берсен-берсе гаепләмиләр, әйтерсең лә шулай кирәк булган. Ә шул ук яшьтәге, тук бригадир малае өй эшләрендә әнисенә ярдәм итеп, өйдә ята. Бүген килеп бу ике малай икесе дә авылыбызда механизаторлар, үзләре бабай кеше булдылар.

Язучы Фоат Садриев табигать күренешләре белән героеның уй-хисләре, тормышының бәйле булуын да бирергә омтылган. Авыл белән шәһәрне дә бер-берсенә капма-каршы итеп бирергә тырышкан, шәһәрнең авылны йота башлавын тоемлаган. Нуриасманы Мизхәт белән Зөбәрҗәтнең алдагы тормышы куркуга салган. Зөбәрҗәт — шәһәр кызы, Мизхәт — авыл малае. Әсәрдә бүгенге тормыш белән үткәндәгесе хатын-кыз мәхәббәте белән ир-ат яратуы тормышчан яктыртылган, урлашуга гына корылган хезмәт белән җаны-тәне белән эшкә чумып үз-үзләрен онытканнарга аерым басым ясалган, изге, ярдәмчел кешеләр белән үзләрен генә кайгыртып күрәләтә кеше талап ятучылар да урын тапканнар. Минем уемча, әгәр язучы геройларының бер-берсеннән аерымлыкларын парлап бирмәсә, уңышлы образлар китереп чыгара алмас иде. Укучының хәтеренә төшерим: әсәрдә кыска гына урында чагылып киткән, эшкә аяусыз Буран Разия, гарип язмышы белән көчкә-көчкә җан асраган Маһинур кебек әбиләр авыл саен җитәрлек. Бүгенге авылда эшләүчеләрнең киләчәге шулай булу күз алдына килеп баса, күңелләрне тетрәндерә. Күмәк хуҗалык өчен гомер буе көчләрен жәлләмәгән кешеләр шул дәрәҗәдә яшәгәч, киләчәктә аерым хуҗалыклар «чәчкә

атып», һәрбере үз жаен үзе караса, аның бүтәннәрдә эше булмаячагы бик куркыныч булачак.

Хәйран калып карап утырам, телевизор экранында бер малай президент Ельцинга хосусыйлаштыру чегы биргән өчен рәхмәт әйтүен күрсәтәләр. «Мин,— ди,— бер авыл сатып алачакмын, ди, бөтенесе миңа эшләячәкләр»,— ди. Бүгеннән үк шундый уй-хисләр белән янып үскән буын кешесенең киләчәктә кем булачагы күренеп тора инде.

Бу урында үземнең дә бәләкәй чакларым күз алдыма килә. Шулай гаиләбез белән — жиде кеше аш эчтек (ашау түгел, эчү, вак-вак бәрәңге кисәкләре һәм шулпасына әзрәк он жибәрелгән). Ишек яңакларына тотына-тотына бер арык кына апа кеше килеп керде һәм кулын сузды. «Эчеп бетердек шул инде, әй, иртәрәк кергән булсанчы»,— диде картинәй, күзләрендәге яшен сөрткәләп. «Әнә, песиегез эчмәгән бит»,— диде ул, һәм көтеп тә тормастан, песиебезгә бүленгән ашны савыты белән күтәрде һәм эчкәч әйләндерә-әйләндерә теле белән ялап куйды, рәхмәтләр укыды. Кесәсенә ничәдер бәрәңге салгач, әкрен генә, иплəп кенә чыгып китте. Ходай мондый күренешләрне яңадан кабатламасын иде.

Әсәрдә гаилә белән торучы хатын-кызларга ирләре белән чәкердәшеп, сөешеп яшәү өчен дәва булырдай, акыллы киңәшләр алырдай урыннар бар. Мисал өчен анда Сәгыйдулланың Нуриасмадан ни өчен читләшүе турында язылган. Әйтергә кирәк мондый «чир» белән хатын-кызларның күбесе авыруга дучар була һәм ул хәл күпләре өчен бик зур бәхетсезлекләр, фажига белән бетә. Кайбер яшь жилкенчәкләр гәзитләргә язалар, укучылардан киңәшләр сорыйлар. Кешенеке-кештәктә, дигән халык мәкален онытмаска кирәк, нинди кеше ни әйтмәс. Менә укып карыйк әле: «...Сәгыйдулла белән тора башлаганда, ул теге чактагы кайнар һәм серле тойгының яңаруын, дәртләндереп үз гәүдәсендә уйный башлавын сизгән иде. Аннары ничектер тормыш бер төрлегә әйләнде, куанычы-шатлыгы кимеде. Ярата идеме ул Сәгыйдулланы? Белми. Аңа тартылган чаклары булса да, сиздермәде, яшерде. Ирен кысып кочаклыйсы, үбәсе, бөдрә чәчләреннән сыйпыйсы килгән чаклары булса да, ул аларның һәммәсеннән дә үзен-үзе тыйды, әлеге теләкләрен эченә бикләп: «Мин аны ятатам бит»,— дип яшерен генә куаныч тапты. Сәгыйдулласы хис-тойгыларын белдерә, аны иркәли башласа да, ул эченнән әйтеп бетергесез рәхәтлек кичерүенә карамастан, шуны яшерде, иренә юри битарафлык күрсәтте, гыйшык-мыйшык уйнау кебек нәрсәләрдән өстен торучы зат булып кыланды, аны читкә тибәрде. Ул Сәгыйдулланың да үзенә суына башлавын сизде...»

Шушы урында өстәп, менә бу турыда язмасам тулы булмас кебек тоела. Иртә белән эшкә барганда бер апа кеше мине туктата да, болай ди: «Әнвәр абый, беләм, син сер саклый торган акыллы кеше, киңәш бирегезче, ничә көннәр инде үземә урын таба алмыйм. Сәбәбе: ирем бер хатынга иярәшкән, белдем, күрдем, Алладан гына сабырлык сорадым. Ни эшлим, ирем белән берәр нәрсә эшлимме, әллә теге хатынны үзем хөкем итемме? Уф, йөрәккәем...» Мин башта аптырап калдым, аннары аңа тынычланырга куштым. Мөмкин кадәр ачыклап сөйләвен үтендем, сораштым, берсен дә яшермә, дидем. Сөйләде. Киңәш бирдем: «Ир кеше зур гына сабый бала кебек ул. Ул синең тарафтан иркәләнүне, яратуны, сөелүне өмет итә. Ә син, үзең әйткәнчә, суынгансың, битарафлык кылгансың. Үз чиратында ул назны читтән эзләп табарга мәжбүр булган. Матурым, беләсеңме, нәрсә, телдән тел уза, кулдан кул уза, диләр, болай үзеңчә эшләсәң, гомергә жуя алмаслык яра ясарсың... Болай итәек. Син көзге алдына килеп, әледән-әле үз-үзеңне, ничек булдыра аласың, шулай, бизәнү-төзәтү чарасын күр, тәмле-тәмле исләр бөркелеп, һушны алырлык булсын. Көлеп торсын йөзләрең, кырык эшең ташлап, йөгереп килеп каршы ал, иркәлә, назла, сөй, үзең дә сөелерсең. Сусаган юлчыдай сиңа тартылар күңелләре, назланырга ашкыныр йөрәге, чәчкәгә тартылган күбәләктәй сине эзләр һәрчак күзләре. Башка бер сүз әйтмичә, миңа карап торды-торды да: «Чынмы, әллә нишләттең, абый... Әледә сиңа киңәш иткәнмен, рәхмәт»,— диде... Соңыннан, иңен-иңгә терәп, (авылда култыклашып йөрү гадәткә кермәгән бит), чәкердәшеп, ниләрдер сөйләшә-сөйләшә үткәннәрен берничә мәртәбә күргәләдем һәм: «Сөбханалла, тьфү-тьфү, күз тимәсен үзләренә, татулашканнар икән»,— диярга туры килде. Сөендем.

Әйе, тормыштан алынган әдәбият кына озын гомерле була, аны халык ярата, үзенеке итә, чөнки анда үзен таба, үзен тапмаса да, яшәү өчен сабак ала.

Минем уйлавымча, язучы үзенең романы белән бүгенге көннең кадак башына сугар өчен, чүкече белән тагын бер селтәнәсе калган. Эш менә нәрсәдә: романның башындагы беренче бүлемендә үк Нуриасманы Ык буеннан кайтышлый Мосаллия белән очраштыра, ул кибеттән кайтып килә икән. Июль ае өчен бер стакан

көнбагыш мае, өч йөз грамм дөге алып кайтып килеше. Он беткән, булмаячак та, ди. Бу гына әле бүгенге көннең кадагына сугу дигән сүз түгел. Кибеткә кереп чыгарга кирәк иде. Ә соң шикер комы тулып ята микәнни? Авария булды хәбәрен дә ачык ишетмәгән үзе. Чынында Хәдичәләргә кергәч, үкереп елап Гарифжанның хатыны Хәлимә килеп: «И әнкәй, хараплар булдык бит!» — дип кенә йөрәкләренә төгаен шом сала. Менә шушы арада кибеттәге «зилзиләне», карлыганнар коелып ятуын, җимеш-җиләкнең шикәр комы юклыктан варенье була алмыйча әрәм булуын, бу хәлнең халыкка тәэсирен, моңа кадәр виноград плантацияләренең юкка чыгарылуын, аракының иң югары дефицит товарга әйләнүен тасвирлаган бер кисәк язасы булган. Бу минем шәхси фикерем. Мин монда үземнең күршемнең ни өчен крыжовник, карлыган, кура җиләге, алма агачларын кисеп ташлавын, эре-эре сусыл бакча җиләкләре түтәлләрен казып ташлавын язар идем. «Ничек кулың күтәрелде гөрләп торган бакчаны юк итәргә?» — дигән идем, ул ике дә уйлап тормастан: «Варенье тамак туйдырмый, хәзер малны күпме асырасаң да була, иң мөһиме — курмы, курмы кирәк, күрше! Күпме чөгендер алыр идең син дә менә бу агачларың урынына?!» — дип, минем күңелгә дә шом салды. Ә нигә, ул дөрес әйтмимени? Итнең килосы нинди югары бәядә икәне һәркемгә көн кебек ачык ич: Күпме сорасаң, шулкадәр «кәгазь» тоттыралар.

Тагын шул. Безнең әдәбиятта сәясәт җитәкчеләре, колхозның партком секретаре бөтен әсәргә тон биреп тора торган иде. «Таң җиле»ндә ул колхоз рәисенә укыр өчен кәгазь бирүче генә булып чыкты. Монда да уйланырга урын бар. Ирексездән укучы күңелендә бер сорау туа: колхоз фермаларында эшләүчеләрне көчләп диярлек партия сафына алалар иде. Ә Нуриасма нишләп читтә йөргән? «Ак чәүкә»гә партиясезлек килешеп бетми, югарыдагылар аның аша калганнарга ничек басым ясаганнар икән?

Ярый, бигайбә. Еллар үтәр, вакыт үткән саен мондый, тормыштан алып язылган әсәрләребезнең рухи бәһасы арта төшәр. Шунысы мөһим, үзеңнең хәлеңнең ничек икәнен күршеннән сора дигәндәй, бүгенге тормышыбызның чагылышын синдәге әдәби әсәрләрдә ачыграк күрәбез, хөрмәтле «Казан утлары».

**Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ.**
Башкортстан, Туймазы районы,
Югары Бишенде авылы.

# ХАКЫЙКАТЬНЕҢ АЧЫСЫ...

Тормышчан вакыйгаларга нигезләнеп, укучыны ышандырырлык итеп, камил тел белән язылган әсәрләр уңыш казаналар. «Казан утлары»нда басылган «Таң җиле» романы — шуның ачык дәлиле. Әйе, Фоат Садриевның авыл тормышына бәйләп язылган әсәрләренең дөньяга чыгуы авыл кешесенең уйларын, гамәлләрен ышандырырлык итеп яза белүе — авылда яшәүче автор икәнен ачык күрсәтеп тора.

Роман беренче битеннән үк үзенә җәлеп итә, көтелмәгән фаҗигале хәлләр укучыны мавыктыра һәм әсәрне бер тында укып бетерәсең. Автор биредә ана рухының бөеклеген, аның балаларына мәрхәмәтен, шәфкатьлелеген, изгелеген, гаиләдәге тугрылыгын ачып бирүгә төп игътибарны юнәлтә. Язучы үз теләгенә ирешкән, диясе килә. Романда Нуриасманың кыз вакыты да, аның кияүгә чыгып, балалар тәрбияләве һәм, ниһаять, өлкән яшьтәге ана буларак, балаларының гаилә корып, матур итеп тормыш итүләренә үзен җаваплы санавы да ышандырырлык итеп бирелгән. Нуриасманың бөтен гамәле, тормышы табигать белән бергә үрелеп бара. Болыннарны, кырларны, Ык буйларын яратуы, таң ату мизгелләренә соклануы һәм аларны йөрәгә аша уздыруы Нуриасманың киң күңелле, олы җанлы ана булып җитешүенә уңай тәэсир ясаган.

Җитмешенче-сиксәненче елларда эчүчелек аркасында авылларда бик күп фаҗигаләр булуын хәзер беркем дә инкарь итә алмый. Гарифҗанның исерек килеш машина руле артында йөрүе, шуның нәтиҗәсендә Рәмзинең үлемгә дучар ителүе, Бәриянең азып-тузып йөрүе дә ышандыра. Нишләмәк кирәк, болар барысы да безнең тормышның чынбарлыгы һәм шул чынбарлыкның әдәбиятта чагылышы.

Рәмзинең үлемендә турыдан-туры колхоз рәисе Хөснуллинның гаебе булса да, ул «судан коры чыга». Бу җинаятьне тикшерүгә билгеләнгән кешенең дә үз намусын артка ташлап, хокукый таләпләрне санга сукмыйча, төрле юллар белән шофер Гарифҗанның «аек булуын» исбатлауга ирешә. Автор мондый хәлләргә йомгак ясап болай дип яза: «Юк, ул (колхоз рәисе Хөснуллин (С. Ш.) ялгыз түгел! Халык җилкәсендә кәеф-сафа корып, җинаять өстенә җинаять кылып, үз башларын гына саклап яшәүчеләр менә шушы идарә йортыннан алып Мәскәүгә кадәр бер-берсе белән бәйләнгәннәр». Әйе, аянычка күрә, мондый колхоз рәисләрен торгынлык елларында да, аннан соң да һәр районда очратырга мөмкин.

Ләкин әсәрдә килешәсе килмәгән бер урын бар. Үсмер чакта бергә уйнап үскән, сугыш елларында хатлар алышкан Сәгыйдулла турыга Нуриасма янына кайта һәм ул, баланың кемнән икәнен дә сорамыйча, өйләнә. Бик нык яратса да, бөтенләй сорашып тормастан Сәгыйдулланың балалы Нуриасмага өйләнүен күңел кабул итми. Ә бит малайның әнисе Нуриасма фатирдашы Газия иде. Нуриасма бу баланың язмышын ачыклап сөйләп бирсә, Сәгыйдулла каршында аның мәрхәмәтле һәм шәфкатьле кыз буларак абруе тагын да күтәрелер иде.

Соңгы елларда басылган кызыклы әсәрләр арасында Мәдинә Маликованың «Фидая» романы да бар. Аның романнары бер-бер артлы журналларда басыла, нәшриятта китап булып та чыга. Ул төрле профессия кешеләренә мөрәҗәгать итә. Элегрәк язылган романнары врачларга, артистларга, гомумән алганда шәһәр зыялыларына багышланган булса, «Фидая» әсәрендә республикадагы бер районның, шул районга караган берничә авылның, колхозның тормышы, район житәкчеләренең, колхоз рәисләренең эшләре, мәшәкатьләре, аларның үзара мөнәсәбәтләре эзлекле, һәм, иң әһәмиятлесе, укучыны уйланырлык итеп тасвирланган.

Фидая — кызы белән яшьләй тол калган чибәр хатын, райбашкарма рәисенең урынбасары. Аңа, башка вазифалар белән бергә, районда сәламәтлек саклау эше йөкләнгән. Ул гына да түгел, Фидая Кормаш авылында хастаханә төзүгә житәкчелек итә. Төзү әйберләренә кытлык булганлыктан, хастаханә төзүне вакытында тәгәлләү өчен Нурханова кύп кыенлыклар кичерергә туры килә.

Авторның Фидаяны бик күңелсез хәлләргә дучар итүе ышандырамы? Әйе, ышандыра һәм әсәрнең уңышлы булуы да, һичшиксез, вакыйгаларның эзлекле рәвештә язылуында. Төзелеш идарәсе житәкчесе Мирхуҗин белән Фидаяның каенлыкта якын мөнәсәбәткә керүләрендә яратып йөргән Давытының салкын битарафлыгы, Тависның исә төзелешне әйбәт алып баруы һәм аның җылы карашы сәбәпче була. Шушындый катлаулы эчке кичерешләрдән соң, ихтыяр көче сынган, яшь, ирсез хатынның Мирхуҗин кочагында хәлсезләнеп калуы артык гаҗәпләндерми.

Әсәрдәге вакыйгалар барышында Фидаяның эшлекле хатын булуына, элекке тормышында, ир белән яшәгәндә кара таплар булмавына ышанасың. Аның райбашкарма рәисе урынбасары хезмәтен башкаруы да каршылыклы фикерләр уятмый.

Чыннан да, безнең гамәли тормышта, күп кенә районнарда хатын-кызларның партия райкомнарында идеология секретарьлары булып эшләүләрен, башкарма комитетларда җитәкче вазифасын башкаручыларны еш очратырга мөмкин иде.

Күп әсәрләр авторы, тәҗрибәле язучы Мәдинә ханым Маликова Фидаяга карата рәхимсезлекне, миһырбансызлыкны ныграк күрсәтмәгәнме? Менә шушы сорау уйланырга мәҗбүр итә.

Автор Фидаяны күңелсез ситуацияләргә кертмичә, эшлекле, әхлаклы, намуслы җитәкче итеп күрсәтсә, безнең әдәбиятыбызда татар хатын-кызларыннан яңа, уңай герой барлыкка килер иде. Әмма чын тормыш катлаулырак шул! Фидая язмышына дучар булучы хатын-кызлар да еш очрый. Минемчә, авторның укучыга җиткерергә теләгәне, бигрәк тә хатын-кызларга әйткән фикере шул: күркәм җенеснең җитәкче вазифаларына күтәрелүе мактауга лаек, әмма аларның итәкләрен җыеп йөрүләре кыйммәт...

Әсәрдә башка хатын-кызларның язмышы да бик матур тәмамланмый. Баллыболын авылында кулына камчы тотып, ирләрчә гайрәтләнеп йөрүче колхоз рәисе Ниса Таштимированың да гөнаһы ачыла. Беркемгә дә сиздермим дип, авырын өендә генә төшерсә дә, соңыннан хәлләр катлаулана. «Таш Ниса» үзен янгынчылардан Кормаш хастаханәсенә илттерә. Кайгы өстенә афәт өстәлә. Шул төндә Нисаның йорты, барлык әйберләре белән янып, көлгә әйләнә. Үзе дә өй эчендә калгандыр, дип уйлыйлар һәм Фәтхерахман карт ясин чыга. Бер төн эчендә Нисаның бик авыр хәлгә калуын колхозчылар гаҗәп хәл итеп кабул итәләр. Кинәт булган бу хәлләр, чыннан да, гайре табигый, әмма әсәрдә чынбарлык итеп бирелгән.

«Таш Нисага», авторның рәхимсезлеге нык сизелә. Чынбарлыкта колхоз җитәкчесе вазифасын башкаручы хатын-кызлар, сирәк булса да, бар. Соңгы елларда алар күренми инде. Бу романны укыгач: «Колхозга җитәкчелек итү хатын-кыз эше түгел, сез табигатьтән бирелгән үзегезнең вазифаларыгызга тугырыклы калсагыз, яхшы булыр иде»,— дигән фикер көчәя.

Соңгы өч елда уңышлы язылган хикәяләрнең берсе «Зәйтүнәкәй-акчарлагым» (Фәрит Гыйльми) дисәм, һич тә ялгыш булмас. Җырларда җырлана торган исеме белән җәлеп иткән хикәянең җисеме дә күңелне кузгатырлык.

Бернichә җөмлә белән хикәянең эчтәлегенә күз салыйк. Торгынлык еллары дип истә калган елларның берсендә Казаннан районга олы хуҗа Тимершин килә. Бу хәл, шул елларга хас булганча, бөтен районны аякка бастыра. «Уңыш» колхозы рәисе авылның активын җыеп көтеп тора. Мәктәп директоры яшь егет Равил интернат бинасы төзү өчен олы хуҗадан ярдәм сорарга өмет итә. Баксаң олы җитәкче Тимершинның эш турында кайгысы да юк, ул районга ял итәргә, бушанырга гына килгән. Аны хөрмәтләү өчен райкомның беренче секретаре, колхоз рәисе биеп тора. Олы кунак каен урманындагы «күз яшедәй чиста сулы» күл янындагы кунак йортына урнаштырыла.

Язучы, үзенә генә хас хикәяләү алымы белән, зур булмаган әсәрдә ышандырырлык вакыйгаларны тасвир итә.

Чыннан да, дистә еллар элек кенә без үзебез мондый хәлләрнең шаһиты идек. Гогольнең «Ревизор» әсәрендә Хлестаковны каршы алган кебек, Өлкә Комитеты секретарьларына да гамәлдә булмаган эшләрне ал да гөл итеп күрсәтүләр яшәде. Югарыдан килгән кунакларны хөрмәтләү максатында махсус йортлар, мунча, сауналар төзеп, аларны кыйммәтле җиһазларга төрү модага кергән иде.

Укытучы кыз Зәйтүнәнең кунак йортына олы җитәкчегә чәй тәкъдим итүче сыйфатында чакырылуы, соңыннан өч җитәкче ирнең аны кыстый-кыстый коньяк эчертергә тырышуларында һәм, ниһаять, чибәр кызның Тимершин белән ялгыз калгач, аңа ныклы каршылык күрсәтүләрендә логик эзлеклелек сакланган. Зәйтүнә бирешми, намусын саклап кала. Хатын-кыз өлкәсендә күпне күргән хуҗа гарьләнә һәм, «кызың кыз түгел иде» диеп, колхоз рәисенә янау ташлый.

Зәйтүнә, үз намусын саклап калучы буларак, тантана итәргә тиеш иде. Башка автор аны, бәлки, шулай тәмамлар иде. Әмма Ф. Гыйльми татар кызларына хас горурлыкны калку итеп күрсәтүне максат итеп куя. Кунак йортын карауч карчыкның «өстерәлчек» дип нахакка сүгүенә чыдый алмыйча, «пычырак дөньяга» нәфрәтләнгән хәлдә, Зәйтүнә сулышына буылып йөгерә дә, йөгерә.

...Ә бераздан... каен ботагында чайкалган кеше гәүдәсен күргән сыерлар сәерсенеп үкерергә тотына. Әйе, автор хаклы: без яшәгән чорда мондый бик тә күңелсез, аянычлы хәлләрдән кешеләр генә түгел,— хайваннар да гаҗәпләнерлек булды.

Автор хикәяне мавыктыргыч итеп язган. Вакыйгаларны уратыбырак язып, хикәянең чишелешенә дә «уравычрак юллар» аша килү ысулын куллана. Монысын инде авторның иҗат итү осталыгы дип карарга кирәк.

**Сәлих ШӘРИПОВ,**
Бөгелмә шәһәре.

# «МИЛЛИОННАРНЫҢ БӘЙЛӘ ЙӨРӘГЕН...»

«Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире, Татарстан халык депутаты **Мөнир ӘҺЛИУЛЛИН** белән әңгәмә.



*— «Ватаным Татарстан» газетасының чыга башлавына март аенда 75 ел тула. Иң әүвәл аның «чишмә башы»на күз салсак иде. Менә шул чакларыннан көч, гайрәт алып, ул халкыбызның яратып укыла торган газетасына әверелде дип беләм.*

— Чыннан да, Рашат туган, ничәмә-ничә буын кешеләренең яратып укыган, халкыбыз тарихының 75 ел буена елъязмасы булган газета турында сөйләшүне аның «чишмә башы»ннан башласак дөрес булыр. Әйе, «Эш» исеме белән нәшер ителә башлап, төрле елларда исемен үзгәртә-үзгәртә, бүгенге көндә «Ватаным Татарстан» исемендә чыгып килә торган газетабызга 75 ел тулды. Бер караганда нәрсә инде ул 75 ел — меңнәр, миллионнар белән исәпләнгән тарих өчен?! Ләкин тарих сәхифәләре еллар агышыннан җыела, туплана бит. Ә инде татар матбугаты тарихы өчен 75 ел һич тә аз түгел. Шушы еллар эчендә халкыбыз тормышында никадәр сөенечле дә, аяныч та хәлләр булып узды. Тарих агачының бер яфрагы буларак, алар безнең газета битләрендә ярылып ята.

Редакциябездә газетабызның музее бар. Аны басмабызга 60 ел тулган көннәрдә оештырган идек. Менә шушы музейның стендларын, андагы инде саргая төшкән газета тегелмәләрен караганда илнең, халкыбызның 75 елда үткән тормышы яңадан күз алдыбызга килеп баса.

Музейга килеп керүгә, гарәп хәрефләре белән чыккан «Эш» газетасының беренче саны — фотокүчермәсе күзгә ташлана. 1918 елның 12 мартында дөнья күрә ул. «Эш» газетасы Казан губерна Советының мөселман бүлеге һәм партиянең Казан губерна советы мөселман секцияләре бюросы органы булып чыга башлый. Аңа күренекле публицист Хәсән Урманов җитәкчелек итә.

1918 — 1993 елларның 12 март арасы. «Эш» — «Ватаным Татарстан»ның 75 еллык тегелмәсендә барлыгы 21780 сан. Бу үзе генә дә йөзләрчә томлы китап бит!

Татарстан АССР төзелгәч, 1920 елның 2 июленә газета «Татарстан хәбәрләре» исеме белән чыга башлый. 1922 елда, матбугат көнендә, газетага «Татарстан» исеме бирелә. 1924 елның маеннан — «Кызыл Татарстан». 1951 елның августыннан — «Совет Татарстаны». 1960 елның сентябреннән — «Социалистик Татарстан». Күпсанлы газета укучыларыбыз тәкъдиме белән, 1992 елның февраленнән ул «Ватаным Татарстан» исеме астында чыга. Аның оештыручылары — Татарстан Югары Советы Президиумы, Татарстан хөкүмәте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

Газетабызның «чишмә башы» турында сөйләгәндә, бер үзенчәлекне дә әйтим әле. 1921 елда Фәтхи Бурнаш, газетабызның редакторы булу белән бергә, газетага кушымта рәвешендә «Безнең юл» дигән әдәби журнал да чыгара башлый. Соңыннан ул аерым журналга әверелә, бүген инде «Казан утлары» исеме белән чыга. Үткән ел 70 еллыгын билгеләп үткән сезнең журналның да «чишмә башы», күрәсез, бүгенге «Ватаным Татарстан» газетасына барып тоташа. Шулай итеп, бүгенге бәйрәм — сезнең журнал белән дә уртак бәйрәмебез ул.

*— Әйе, килешәм. Әмма бу очракта, дөреслек тулырак булсын өчен, бераз гына аңлатма бирүне кирәк табам. «Казан утлары» журналын 1922 елда чыга башлаган*

*«Безнең юл» белән чикләү совет чорына хас күренеш иде. Ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, татар халкының әдәби-сәяси журналлар чыгару тарихы ераккарак — гасыр башына ук, ягъни «Әлгасрел-җәдит», «Шура», «Аң» кебек басмаларга барып тоташа. Сезнең бәйрәмне безнең журнал өчен генә түгел, ә бәлки бөтен татар матбугатының, әдәбиятының уртак бәйрәме, дияр идем. Белүемчә, газета тирәсендә һәрчак язучылар, шагыйрьләр кайнап торган...*

— Әйе, газета беренче көннәрдән үк үз тирәсенә шул еллардагы язучыларны, олы әдипләрне туплый. Атаклы әдип Галиәсгар Камал — «Эш» газетасының тернәкләнеп китүенә иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе. Хәтта газетаның исеме берничә тапкыр аның кулы белән язылган. Галиәсгар ага Камал «Эш» газетасында рәссам, публицист, сатирик, тәрҗемәче булып катнаша.

Галиәсгар Камал, бу елларда вакытлы матбугатта эшләгәнен искә алып, болай дип яза: «Гражданнар сугышының кызган чоры. Деникин, Колчак һәм башка бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин кыска әсәрләр, шигырьләр язып, көн кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә куныш эшли идем».

Ул елларда Г. Камал аеруча актив иҗат итә, йөздән артык тезмә әсәр бастыра. Бу турыда искә алып, Афзал Шамов газетаның 1968 ел, 7 март санында болай дип язды: «Материаллар озынча тар кәгазьләрдә кулдан язылган, иң матур, иң пөхтә язылганы Галиәсгар Камалныкы. Аның кульязмаларында пычранган юлларны очратмассың. Ул караламалар белән мәшәкатьләнми, турыдан-туры акка яза. Аның кульязмасын наборщиклар тарткалашып алалар иде».

1919 елның язында «Эш» газетасының редакторы итеп Вәли Шәфигуллин билгеләнә. Ул «Әүлия» псевдонимы белән шигырьләр дә бастыра, әдәбият-сәнгать проблемаларына багышланган мәкаләләрендә, публицистик чыгышларында әдәбият һәм журналистиканың үсеш юлларын билгели.

Гомумән, бик күп язучылар «Эш» газетасы белән даими элемтәдә торалар. Бу җәһәттән Галимҗан Ибраһимовның 1918 ел, 7 ноябрь санында урнаштырылган мәкаләсе игътибарга лаек. Ул анда газетада әдәбият-сәнгать, мәдәниятнең халыклар арасында дуслыкны ныгытырга тиешлеген ассызыклаган. «Тел, әдәбият, шигырь, мәдәният — болар һәммәсе үзләренең рухларын үзгәртергә, башка милләтләргә дошманлык, милли тәгассып урынына дуслык, туганлык, кардәшлек рухы белән сугарырга, халыкны шул рухта тәрбия итәргә тиешледер»,— дип язды.

Газета ул чорда чыккан әдәби җыентыкларга, пьесаларга, театр-спектакльләргә игътибар итә. Аларга рецензияләр биреп бара. Драматург Кәрим Тинчурин «Эш» газетасына күп яза. «Эш» яшь әдәби көчләрнең — Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов, Бари Рәхмәт, Мансур Крымовның әдип булып үсеп китүләренә юл ача.

1921 елда «Татарстан хәбәрләре»нең редакторы итеп журналист һәм язучы Фәтхи Бурнаш билгеләнә. Ул 1921 — 24 елларда газетага җитәкчелек итә. Музеебызда беренче редакторлар арасында Галимҗан Нигъмәти иҗатына багышланган стенд бар. Ул 1926 — 28 елларда «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы булып эшли. Соңыннан күренекле тәнкыйтьче, әдәбият галиме, профессор булган бу әдип иҗат мәйданына газета хезмәткәре буларак килеп керә.

Бүген без төрле елларда газетабызның редакторы булып эшләгән Вәли Шәфигуллин, Фәтхи Бурнаш, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти, Сафа Борһан, Исхак Еникеев, Фаяз Ризванов, Һади Габдрахманов, Ибраһим Үзбәков, Галим Рябков, Шәмси Хамматов, Рәис Сабировларның исемнәрен олылап телгә алабыз. Аларның һәркайсы үзе турында якты истәлек калдырып, һәркайсы газетаны сугышчан һәм кызыклы итү өчен янып-көеп эшләде.

— *Бүгенге көн биеклегеннән торып караганда газетаның табышлары, югалтулары нидән гыйбарәт?*

— Бик авыр сорау бу. Гомумән, бүген үткән юлыбыз, тарихыбыз, әдәби мирасыбыз яңача бәяләнә бит. Шуңа күрә безгә бүгеннән торып тарихка хөкемдар булу бик кыен. Дистә еллар элек газетада чыккан язучыларыбызның кайбер әсәрләре, тәнкыйть мәкаләләре бүген башкача бәяләнә. Газета битләрендә төрле чорларда әдәбиятка, мәдәниятка, телебезгә кагылышлы шактый бәхәсләр була. Араларында аерым шәхесләргә кусәк күтәреп язылганнары да аз түгел. Бусы да тарих. Ул вакытта аерым шәхесләргә караш та бүгенгедән кискен аерыла. Бер генә мисал китерим. «Кызыл Татарстан»ның 1929 ел, 26 апрель санында Галиәсгар Камал, мәсәлән, үзенең 30 еллык әдәби хезмәтен бәйрәм итү уңаеннан Гаяз Исхакыйдан килгән котлауны кабул итә алмавы турында яза.» Минем 30 еллык хезмәтемнең 12

елы совет дәүләтендә үтте,— ди ул әлеге мәкаләсендә.— Ул 12 елның кин мөмкинлекләр бирелү ягыннан башкалардан чагыштырмаслык аермалары бар. Шуна күрә Гаяз әфәнделәр күтәргән «ирек»нең минем өчен һич кирәге булмавын, үземнең андый «ирек»ләрнең чын дошманы булуын белдерәм». Гаяз Исхакыйның мирасы халкыбызга кайтарылган бу көннәрдә әлеге хатка карата, әлбәттә, башкача бәя бирү сорала. Ләкин бу хат ничек туган? Чынында Г. Камалның Г. Исхакыйга мөнәсәбәтен чагылдырамы ул, әллә шул чордагы аерым көчләр басымы астында язылганмы? Күп нәрсәне ачыклыйсы, өйрәнәсе бар. Газета тегелмәләрен өйрәнү бүген безгә күп нәрсәне яңача аңларга ярдәм итәчәк әле.

Әлбәттә, 75 елда газетаның табышлары да, югалтулары да аз булмагандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, ул — татар әдәбиятын, мәдәниятен, телен үстерүгә зур өлеш керткән басма. Хәтта авыр сугыш елларында да газета ябылмады. Сугыш елларында «Кызыл Татарстан» газетасында журналистлар бармак белән генә санарлык булган. Редакциянең кечкенә коллективы, зәһәр салкыннар башлангач, типографиядә урнаша. Алар, шундый авыр шартларда да газетаны вакытында чыгарганнар...

*— Күргәнебезчә, заман җилләре шаукымы белән, газета берничә тапкыр исемен алыштырган. Нәрсә бу — заманга яраклашумы, тормыш агышына иярүме, әллә идеологик көчләрнең басымы астында гайре табигый үзгәрешләр нәтиҗәсеме? Исеме үзгәрү белән җисеме дә үзгәрә килдеме аның?*

— Һич шик юк, газетаның исеме үзгәрүдә шул заман йогынтысы зур булган. Шәхсән мин үзем газетаның исемен еш алыштыруга каршы. Әйтик, «Ватаным Татарстан» дип исемен үзгәрткәндә дә күп бәхәсләр булды. Бигрәк тә Югары Совет карары белән Татарстан Совет Социалистик Республикасы Татарстан Республикасы итеп үзгәртелгәч, газета укучыларыбыздан күп хатлар агылды. Араларында: «Җөмһүриятнең исеме үзгәрде, ә сез һаман да социалистикка ябышып ятасыз»,— дип гаепләүчеләр булды.

Балага исем куюга ата-ана, гадәттә, җаваплы карый. Ә бирердә халкыбызның баласы, шундый олы газетаны яңа исем белән чыгару турында сүз бара. Укучыларыбыз теләген дә исәпкә алмый мөмкин түгел иде. Исемгә конкурс игълан иттек. Күпчелек укучыларыбыз «Ватаным Татарстан» исеменә тукталды. Җөмһүриятебездәге бүгенге үзгәрешләргә бик аваздаш дип саныйбыз бу исемне. Чөнки үзенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшче Татарстан үз территориясендә яшәүче күп милләтле халыкның уртак Ватаны ул. Бер үк вакытта Татарстан җиде миллионлы татар халкының рухи Ватаны да. Бу турыда аксакал әдибебез Әмирхан Еникидән, матуррак итеп, күңелгә үткәреп әйтеп булыр микән. «Һәр халыкның кайларда гына яшәвенә карамастан, үз Ванаты һәм үз рухи каласы була. Әйтик, урысның Россия дигән Ватаны һәм Мәскәү дигән каласы бар. Әрмән һәм грузин, үзбәк һәм таҗикларның да шундый рухи калалары бар. Билгеле инде, татар кешесенең дә кайларда гына яшәмәсен ул, Татарстан дигән Ватаны, Казан дигән рухи мәркәзе булырга тиеш»,— дип язды ул газетабызда.

Бөтен татар халкының рухи Ватаны нәкъ менә Татарстан булганга, Бөтендөнья татар конгрессы җөмһүриятебездә үтте. Бөтен татар халкының уртак трибунасы булган газетаны «Ватаным Татарстан» дип исемләү дә табигый яңгыраш тапты. Газета 1991 елның 8 августы да гомумтатар газетасы буларак теркәлде дә.


Әлбәттә, хикмәт исемне алыштыруда гына түгел. Аның бурычлары, мәсләге дә үзгәрде диярлек идем. Яшерен-батырын түгел, «Социалистик Татарстан»ны чыгарган елларда без республикадан читтә яшәүче татарлар тормышын бөтенләй диярлек яза алмый идек. Хәтта көлкеле хәлләр дә килеп чыкты. Сиксәненче еллар башында Ульяновск өлкәсенең бер татар авылында зиратларның начар хәлдә булуы турында мәкалә басылган иде. Ул мәкаләне район житәкчеләре күреп, Ульяновск өлкә партия комитетына хәбәр иткәннәр. Ә алар исә партиянең Татарстан өлкә комитетына. Анда исә безне башка республиканың эшләренә «тыкшынуда» гаепләп, шактый кыздырганнар иде...

Хәзер исә «Ватаным Татарстан» газетасы җөмһүриятебездән читтә яшәүче милләттәшләребезнең тормышын чагылдырган «Милләттәшләр авазы» дигән махсус сәхифә чыгарып килә. Аны республикадан читтә дә ун меңнән артык гаилә алдыра.

*— Сезнең газета әдипләр өчен һәрчак иҗат мәйданы, публицистик трибуна булды. Газета-журналлар шактый үрчеп киткән заманда язучылар белән дуслыгыгыз ни дәрәҗәдә саклана? Яшерен түгел ич, безнең язучы халкы кыю, усал фикерләрне*

*беренчеләрдән булып күтәрә. Үзенең язма фикерләрен шулай ук кыюлардан саналган басмаларга бирергә тырыша.*

— Газетабызның 75 еллык тарихына күз салсаң, аның битләрендә әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә урын һәрчак түрдән булганын яхшы күрәсең. Татар язучыларыннан безнең газетада эшләүчеләрнең исемнәрен әйтеп кенә китсәк тә гаять озын исемлек килеп чыгар иде. Шулай да, бүгенге юбилейдан файдаланып, аларны телгә алып китик әле. Г. Камал, С. Җәлал, М. Гали, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Ш. Усманов, Г. Толымбай, М. Җәлил, Һ. Такташ, Г. Кутуй, Ш. Камал, Г. Бәширов, Б. Рәхмәт, Г. Кашшаф, Ф. Хөсни, Г. Галиев, Ә. Исхак, С. Хәким, Ә. Камал, Г. Иделле, Х. Ярми, И. Туктар, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, Ә. Айдар, М. Садри, А. Әхмәт, Н. Арслан, С. Шакир, Ә. Давыдов, С. Рафиков, С. Сабиров, З. Мәҗитов, Ф. Мусин, Б. Камалов, Ә. Баян, Д. Зөбәерова, Ш. Маннапов, З. Мансуров, Ф. Бәйрәмова, Р. Әхмәтҗан һәм башкалар төрле вакытларда редакциянең үзендә эшләделәр, газета эшендә автор буларак та катнаштылар.



Рәсемдә *(сулдан уңга): газетаның мөхәррире, язучы Фатих Сәйфи-Казанлы, журналист Мөхәммәт Гали, мөхәррир урынбасары Гомәр Толымбайский, 1926—27 елларда мөхәррир булган Галимҗан Нигъмәти, драматург Кәрим Тинчурин редакциядә.*

Бүген, әлбәттә, газетабызда чыныгу алган күп язучыларның иҗатына иркенләп тукталырга мөмкин булыр иде. Менә Гадел Кутуйны гына алыйк. Аның беренче мәкаләсе «Татарстан» газетасында 1924 елның 13 февралендә басылып чыга. 1928—30 елларда газетаның мәдәният бүлеге мөдире булып эшли. Бик күп репортажлар, тәнкыйть мәкаләләре, фельетоннар яза. Язучы-публицистның иҗат үзенчәлеген аңлатып, ул болай дип яза: «Язучы, гадәттә, хәбәрче күрә алмаган, тота алмаган күренешләрне күрә. Ул унбиш юл белән генә аңлатып узган һәм укучы күзеннән югалыр дәрәҗәгә киткән вак хәбәрне дә әһәмиятле итеп күпертә ала. Журналист-язучы вакыйганың тышкы ягын гына күрсәтмичә, вакыты белән генә укучыны сискәндерерлек дәрәҗәдә көчле итеп вакыйганың эчке ягын да тасвир итә. Шуның аркасында ул үзенең... әдиплек иҗатына да шиләкләп-шиләкләп азык ала». Искиткеч гыйбрәтле сүзләр. Юкса бит әле кайбер язучылар арасында шундый фикер дә яши: газетада эшләү язучының телен корыта, аның иҗатына тискәре йогынты ясый, янәсе.

Әйе, күп кенә олы әдипләребез нәкъ газетада эшләп тормыш тәҗрибәсе туплаганнар, үзләренең әсәрләренә азык тапканнар. Казанга килеп журналист эшчәнлеген газетада башлап җибәргән Муса Җәлил турында да шуны әйтергә мөмкин булыр иде. Шагыйрь 1922 елның көзендә Казанга килә. «...Үземнең шигырь көчемә нык ышану мине Казанга канатландырды. Анда язучылар белән күрештем. Укырга инде вакыт соң иде. Мин «Татарстан» газетасы редакциясенә күчереп язучы булып кердем»,— дип язды Муса Җәлил соңыннан бу турыда

«Кызыл Татарстан» газетасына үзенең олы ихтирамын М. Җәлил 1940 елда газетаның юбилее уңае белән шаяру төсендә язылган шигырендә әйтеп биргән:

Каләм батырлары, алдынгылар
Утыралар табын түрендә,
Стаканда ташкан сыра төсле
Куанычлар ташый күңелдә...
Чәчәк итеп сибәм табыныгызга
Котлау сүзләренең бәйләмен,
Котлы булсын, «Кызыл Татарстан»,
Данлыклы һәм матур бәйрәмең.

Публицист шагыйрь Һади Такташ та газетабыз белән тыгыз бәйләнештә була. Казанга килгәч, ул төрле вакытларда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр була. Ул Татарстан районнарында, авылларда, Идел буе шәһәрләрендә, Донбасста була.

Һ. Такташның матбугатка, аерып алганда «Кызыл Татарстан»га олы ихтирамы, 1927 елның октябрь аенда газетаның 2000 нче саны чыгу уңае белән язылган «Онытылган тәбрик» шигырендә ачык языла. Ул, моннан 65 ел элек язылса да, андагы теләкләр бүген дә бик актуаль яңгырый. Шунлыктан без аны тагын бер кат искә төшерик әле.

Ике меңне тутыргансың, «Кызыл Татарстан»,
Ә мин
Бүген генә аны ишеттем,
Дөнья куып, бәгърем, йөри-йөри,
Тәбрикләргә сине кичектем!
Сәлам булсын сиңа!
Ак битләрең
Тыгыз юллар белән каралсын,
Һәрбер битең тарих булып калсын!
Исемең эшче илдә дан алсын.

Айга күптән инде миллион тулган,
Ә ул үзе аны оныткан,
Бүген саташкан ай, кыш дип белеп,
Төн уздырган күктә толыптан.
Ай кебек син ялгыз читтә калма,
Битләреңә
Миллионнарның бәйлә йөрәген,
Миллион күзләр синең биттә йөрсен —
Шушы минем сиңа теләгем!

Гомумән, әдипләребезнең газетабызга олы рәхмәт хисләре белән язылган истәлекләре күп. Редакция музеенда дистәләгән әдипләрнең газетага рәхмәт сүзләрен язып тапшырган китаплары саклана. Шулардан берничәсен булса да укып китик:

«1934 — 1935 елларда газетаның культура бүлегендә эшләү халык поэтик иҗатын өйрәнү өлкәсенә кереп китүемә ярдәм итте.

**Хәмит Ярми».**

«Мине вакытында журналистлык һөнәренә өйрәткән һәм шуның белән матур әдәбиятка керергә ярдәм иткән «Социалистик Татарстан»га чын күңелемнән рәхмәт әйтеп шушы әсәремне бүләк итәргә булдым. Ихтирам белән **Г. Бәширов».**

«Социалистик Татарстан» газетасы музеена. Бергә үстек, бергә яшәдек, бергә уртаклаштык. Ни дисәң дә үз газетабыз, үз телебездә!

**Сибгат Хәким».**

Утызынчы елларда «Кызыл Татарстан»да әдәби сәхифәләр чыга башлый. Менә шушы әдәби сәхифәләр газетабызда дистәләрчә ел чыгып килде һәм хәзер дә инде ул, газетабызның «Әллүки» кушымтасы булып, һәр жомгада чыгарыла. Аны тарих, тел, әдәбият һәм сәнгать мәкаләләренә багышланган махсус газета дип тә санарга мөмкин. Бездә бүген Язучылар берлеге әгъзалары Әхәт Гаффар, Рафис Гыйззәтуллин, Миргалим Харисов җигелеп эшлиләр, күркәм иҗат итәләр.

*— Ирешелгәннәр беркайчан да чик була алмый. «Әллүки» дигән әдәби кушымтагызны тагын да яхшырту, кызыклырак итү өчен нишләргә кирәк? Бу хакта уйланасызмы?*

— Нигездә, әдәбият, сәнгать, тарих, тел мәсьәләләренә багышланган «Әллүки» чыгарылышы һәр җомгада татар өенә килә торган кунак ул. Күчтәнәчләре дә төрле-төрле. Әмма шулай да иң зур күчтәнәч — якын күргән, ихтирам иткән җырчы яисә язучы белән күрешеп сөйләшү шатлыгы бит ул. 1993 елда «Әллүки» һәр язучыны, артистны, җырчыны халыкка тагын да якынайту өчен тырышачак. Аларның һәр яңа, үзебез яхшы дип тапкан әсәрен укучыга ирештереп бару белән беррәттән, сәнгать әһелләре тормышына багышланган сәхифәләр биреп барырга уйлыйбыз. Кем белән очрашу кадәресе укучыларыбыз ихтыярына бәйле. Соңгы вакытта прозаиклар сүлпәнләнде, дияр идем. Матур-матур хикәяләргә мохтаҗлык зур.

*— Сез бүген республика газеталары арасында иң күп тиражның берсен җыйдыгыз. Моның сере нәрсәдә икән?*

— Газетабызның тиражы быел 110 меңнән артык. Әлбәттә, матбугатка язылу бәһаләренең артуы безгә дә үзен нык сиздерде. Без дә шактый гына укучыларыбызны югалттык,— ләкин шулай да иң олы тиражлы газеталар сафында калдык. Моны кайберәүләр газетаның тарихына бәйлиләр. Кешеләр, янәсе, бер ияләнгән газетаны алалар инде ул, диючеләр дә бар. Әлбәттә, традицияне инкарь итеп булмый. Шулай да бөтен нәрсәне аңа гына кайтарып калдырырга ярамый. Без, журналистлар, яхшы беләбез: газетаны 3—4 ай эчендә кеше укымаслык итәргә була. Аның битләрендә иң кызыклы яңалыклар, төрле хәбәрләр, кешеләрне борчыган проблемалар, рухи азык алырдай әдәбият-сәнгать әсәрләре урын ала икән, укучы аңардан аерылмаячак. Һади Такташ та «миллионнарның бәйлә йөрәген» дип юкка гына әйтмәгән бит. Без быел җәй җөмһүриятебезнең күп кенә районнарында булып, газета укучылары белән очрашулар үткәрдек. Анда газетабыз турында бик кызыклы фикерләр, тәкъдимнәр әйтелде. Бик күп яңа темалар таптык. Минемчә, редакция журналистлары укучыларның газетадан нәрсә көткәнен белеп, тоеп яшәргә тиеш. Ул вакытта үзенең укучыларын югалтмаячак.

*— Һәм соңгы сорау. Сезнеңчә, татар телендә нәшер ителә торган газета-журналларның арта баруы татар укучысы, ягъни мөштәриләребез өчен файдагa булдымы, әллә...*

— Мин бу сорауга һич икеләнмичә җавап бирә алам. Әлбәттә, милли газета-лар-журналларыбызның артуы татар укучылары, татар халкы өчен файдалы. Газета-журнал укучыларыбыз кайсы басманы якын итәләр, шуны сайлап алалар. Дөрес, һәр гаилә татар телендә чыга торган барлык басмаларны алдыра алса шәп булыр иде. Ләкин бүгенге кыйммәтчелек заманында күпләрнең андый мөмкинлеге юк. Аннан соң без татар телендә бердәнбер олы газета — «Социалистик Татарстан» газетасы гына булган заманнарны яхшы хәтерлибез. Ул вакытта газета битләрендә төрле фикерләргә ирек куелмады. Хәтта шушы газета әле башка язмаларны, башка басмаларны нәрсә турында, ничек язарга кирәклеген өйрәтеп тора иде. Әлбәттә, бүген дә теге яки бу мәсьәлә буенча газета битләрендә бәхәсләр булуы табигый.

Ләкин мине икенче нәрсә борчый: яңа газеталарның ачылуына карап, татар матбугатының гомуми тиражы артмады. Менә бер мисал китерим: быел «Ватаным Татарстан» — 110 мең, «Шәһри Казан» — 20 мең, «Татарстан Хәбәрләре» 21 мең тираж белән чыга. Менә шушы өч олы газетаның тиражы «Ватаным Татарстан»ның былтыргы гомуми тиражы кадәр генә. Без җиде миллион татар бар дип сөйләргә яратабыз. Ә инде өч газетабызның тиражы 152 меңнән артмый. Күпме инде бу шулкадәр халыкка? Ким дигәндә 1 миллион тиражы булырга тиеш безнең газеталарыбызның. Менә шулар эчне пошыра, шулар күңелне борчый. Хәер, газетага гына түгел, журналларыбызга да кагыла бу. Союзның таркалуы республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләргә татар телендә чыга торган газета-журналлар алдыруны нык авырлаштырды. Әйе, милли матбугатыбызны саклап калуда кыенлыклар күп. Һәрхәлдә, без боларны бергәләп хәл итәргә тиешбездер.

«Ватаным Татарстан» газетасы үзенең 75 еллык юбилеена ныклы адымнар белән килә. Бүгенге мөмкинлектән файдаланып, мин «Казан утлары» журналы аша газета укучыларыбызны тагын бер кат олы юбилей белән котлыйм. «Ватаным Татарстан» газетасы аларның һәрчак якын дусты, киңәшчесе булып калыр.

Әңгәмәне **Рашат НИЗАМИЕВ** үткәрде.

# ТАЛАНТЛЫ ЯЗУЧЫ, КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ

МӨХӘММӘТ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Халкыбызның катлаулы тарихын, рухи мирасын бернинди идеологик чикләүләрсез генә, хакыйкатьтә барынча гына тикшерү һәм зиһенгә алу, асыл кыйммәтләр үлчәвеннән үткәрү заманнары житте. Ничек булган — шулай: кызартмыйча, каралтмыйча, агартмыйча өйрәнергә. Электә гадәтләнгәнчә, теге яки бу күренешне жәһәт кенә калыпка салып, ярлыклар ябыштырып узарга ярамый.

Мәгәр җиңел эшләрдән түгел бу дөрес бәя бирү дигән нәрсә. Аеруча каршылыклы чорда яшәп катлаулы рухи мирас калдырып киткән каләм ияләренә.

Менә быелның мартында шактый дәрәҗәдә яңача бәяләүне сорап торган әдәби мирас иясе талантлы әдип Мөхәммәт Галинең тууына йөз ел тула. Юбилей уңае белән бу әдипнең тормыш һәм иҗат юлына караган кайбер мәгълүм һәм күпләргә әлегәчә мәгълүм булмаган фактларны искә төшереп үтик.

Мөхәммәт Гали (Галиев) хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Балык Бистәсе районы Олы Елга авылы мулласы гаиләсендә 1893 елның мартында туа. Иртән намаздан кайтышына әтисен — Вәли хәзрәтне, шулай итеп, сөенеч, бер генә түгел, хәтта ике сөенеч көтеп торган: угыл дөньяга килү һәм сыерларының үгез бозау китерүе. Янәшәсендәге якын туганы Мөхәммәт абзый («Сатыш Мөхәммәт абзый»), кайтып кергәч тә, баланы камыш намазлыкка куеп азан әйтә һәм үз исемен бирә: Мөхәммәт. Гадәтенчә бәхет һәм тәүфикъ теләп дога да укылган, баланың уң колагына да өрелгән. Әти-әнисенең ир бала үстерү турындагы актлык өметләре җимерелми кала түгелме?

Тормыш матур башлана кебек — бәйрәм көндә.

Ул заманнарда мулла угылларына үсеп җитеп мәшһүр мәдрәсәләрдә гыйлем эстәп, аталары кебек (яисә алар урынына) имам-мөдәррис булу бәхеткә саналган, алардан шуны көткәннәр. Әмма егерменче гасырга килеп кергәч, күпләгән мәхдүмнәр (мулла угыллары) башка юллардан атларга мәҗбүр булдылар. Революцияләр, канлы сугышлар, иҗтимагый бәрелешләр, террорлар татар дөньясының да астын өскә китерде. Уяну, каршылыкларның гаять кискенләшүе, күп нәрсәгә дөрләп кабынган өмет һәм дә күп кенә өметләрнең чәлпәрәмә килү дәвере булды бу егерменче гасыр.

Мөхәммәт Гали башта туган авылы мәктәбендә, унберенче яшенә чыккач, Сатыш мәдрәсәсендә сабак ала. Әмма ундүрт яшьлек чагында әтисе үлеп китә. Шулай да ул белем алуын дәвам итә: 1910 елда шәкертләр хәрәкәтендә катнашуы өчен Сатыш мәдрәсәсеннән куылгач, Казанга килеп Күл буе мәдрәсәсендә укый башлый. 1912 елдан ул — Оренбургның мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте. Әмма, «тик тормаганлыгы» өчен аннан да чыгарылган ул.

Гасырыбызның унынчы елларында, мәгълүм ки, көндәлек татар матбугаты битләрендә яңадан-яңа әдәби исемнәр пәйда була. Мөхәммәт Галинең иң беренче бастырган әйберсе — «Авыл тормышыннан» исемле хикәясе «Йолдыз» (24.V.1911) гәзитендә М. Г. (Жулгадан) имзасы белән күренеп ала. Әмма яшь авторның иҗаты чынлап башланып китүе 1914 елга — әлеге «Хөсәения»дә укыган чорына карый. Кыска гына вакыт эчендә аның житди эчтәлектәге «Җиләккә барганда», «Авылдагылар», «Бер әбинең зары», «Сабан туенда» дигән хикәяләре («Аң» журналы,1914—1915) дөнья күрә. Аларны бастырып чыгаруда яшь авторга мәдрәсәнең татар әдәбияты мөгаллиме, танылган тәнкыйтьче Нәҗип Гасрыйның (Мәүлямбирдиевнең) ярдәме тигән. Ошбу әсәрләр үзләренең җыйнаклыклары, теленең гади һәм җиңел аңлаешлылыгы, халыкчанлыгы белән, татар авылы тормышы, гореф-гадәтләренең матур бирелеше белән бүген дә яратып укыла. Хәер, совет заманындагы тикшеренүләрдә аларның кимчелекләре дә табылды: иҗтимагый мотивлар йомшак күрсәтелгән, имеш.

«...Язулары йөрәктә бер эз калдырган, алда матбугатыбыз дөньясының төпле иҗтыяҗларыннан берен үтәүдә файдалы әгъза булыр дигән бер өмид,

хәтта ышаныч уйгаткан исемнәрдән» саналган (Г. Ибраһимов, 1915 ел) М. Галигә язмыш тиздән иҗат эшенә чынлабрак керешүгә зур киртә китереп чыгара. Беренче бөтендөнья сугышы кабынып, ир-атлар яу кырына җибәрелә башлыйлар. Яшь язучыга да шул нәрсә «елмая». Ләкин аңарда әлеге «изге сугыш»ка бару теләге булмаган. Нишләргә? Чит җирләргә китеп эзне суытырга кирәктер кебек. Һәм ул китә дә: Украина, Әстерхан, Баку якларында эшли, төрекмән җирләре, Бохара әмирлеге белән таныша, хәтта Кытайга яисә Әфганстанга да барып чыгарга җыена. Тик барыбер аның эзенә төшәләр һәм «качкынны» Чарджоу тирәсендә тотып алып, Оренбургка озаталар. 1916 елның февраленнән ул инде сугыш барган җирдә — Австрия һәм Румыйния фронтында окоптагы солдат бу мәхшәрдә күргән-кичергәннәрен соңыннан «Карпат» исемле повестенда чагылдыра. Авыруы сәбәпле фронттан азат ителгәч, ул ике ел чамасы туган авылы Олы Елгада мөгаллимлек итә, аннары укырга ниятләп яңадан Казанга килә. Монда кайбер танышларының димләве буенча, журналистлык эшенә тартыла һәм гомеренең унике елын төрле газета редакцияләрендә («Кызыл Армия», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре», «Безнең байрак», «Крестьян газеты») хезмәт итеп уздыра. Нәкъ менә шушы заманнарда ул яңадан иҗат мәйданына кайта, ләкин аның күп вакыты, җегәр-куәте газеталарны оештыру эшенә, заманының идеологик көрәшенә хезмәт иткән очерклар, мәкаләләр, хәбәрләр язуга сарыф ителә билгеле. (Имзалары: М. Гали, Әүхәди, Тәхәви, Гыйбди, М., Г. һәм башкалар). Әдип үзе дә бу елларда бар көчен көндәлек матбугат ихтыяҗларын үтәүгә җигүен әйтә. Тик шулай да М. Гали хикәяләр язуга да беркадәр вакыт таба алган. Аңлашыла ки, аның мондый жанрдагы әсәрләренә дә революциядән соң чынбарлык күренешләре килеп керә. «Сәмигыл карт», «Мин дигәнчә булмады», «Базарчылар», «Рәхмәтуллин Шаһи» кебек хикәяләрдә үзәк образларга күңел күтәренкелеге хас. Алар бик тиз революциянең файдасын аңлап алалар, актив тормыш позициясенә басалар (иллюстративлык та күренә). Хәер, элекке авылны сурәтләвендә М. Галинең җанлы детальләргә, авыл көнкүрешен күз алдына бастыра торган тасвир һәм күренешләргә мөрәҗәгать итүен дә күрми мөмкин түгел. Егерменче елларда язылган әдип әсәрләре арасында иң уңышлыларына тормыш материалы булып революциягә кадәрге татар авылындагы хәлләр хезмәт иткән. «Яңгырсыз елларда», «Пожарныйлар» хикәяләре реалистик тормышчанлыклары, гади авыл малайлары образларын яратып, белеп сурәтләүләре белән хәтердә кала.

Ниһаять дикме, Мөхәммәт Галигә дә югары уку йортына кереп уку мөмкинлеге туа һәм 1931 елда ул Татарстан совет язучылары җәмгыяте идарәсе тәкъдиме белән (аңа Г. Нигъмәти кул куйган) Казан дәүләт университетының география бүлегенә кабул ителә. Шунда укыганда әдәби иҗат эшеннән дә аерылмый. Бу дәвердә колхозлашу вакыйгаларын эченә алган пафослы очерклар һәм хикәяләр бастыру белән беррәттән, сюжеты революциягә кадәрге тормыш материалына корылган җитди әсәрләр иҗат итәргә дә омтыла. Аларда Беренче бөтендөнья сугышы фаҗигаләре, яу кырындагы аянычлы хәлләр, язмышлар оста сурәтләнгән, кан-коешның адәм баласы табигатенә гаять ят булуы, рухиятен рәнҗетүе, патша офицерларының кешелекеезлеге, шәфкатьсезлеге күрсәтелгән.

1933 елда Казан университетын тәмамлаганнан соң, М. Гали Казан педагогия институтында экономик география укыта башлый, рабфакта, совпартмәктәптә, техникумнарда да дәресләр бирә, иҗат эшен дә дәвам иттерергә омтыла.

Адәм баласының язмышы йомычкага охшап калган чорда Мөхәммәт Галигә дә борчулар чыгып торган. 1932 еллардан ул үпкә хастасы белән авырый башлый. Билгеле ки, аның язучы буларак активлыгы да беркадәр кими. 1937 елда аңа моны искә төшерәләр. Язучылар берлеге әгъзасы булса да, пассив әдәби балласт, милләтчелек сөременнән аерылып бетмәгән, имеш, «халык дошманнары» белән бәйләнештә, имеш... Октябрь аенда аны Союздан чыгарып ташлыйлар, газета мәкаләләрендә (мәсәлән, Хан Җәмилнекендә) зур «гаепләре» фаш ителә. Ул урыныннан чыгарылып эшсез дә йөри. Шулай ук кайбер зыялыларның, фикердәшләренең тырышлык нәтиҗәсендә.

1939 елда аның әдәби эшчәнлеге башлануга егерме биш ел тулу хөрмәт белән билгеләп үтелә. «Язучылык буенча соңгы елда күбрәк әдәбият тикшерү өлкәсендә эшләргә керештем... Мин күбрәк көнүзәк эшләр белән кызыксынучы язучы. Хәзерге вакытта иң актуаль мәсьәлә булып әдәби мирасны барлау һәм татар әдәбияты тарихын төзү мәсьәләсе тора. Бу эш күбрәк безнең шикелле картрак язучылар өстенә төшә. Мин үземдә бу юлда эшләрлек көч сизәм. Ул өлкәдә эшләрлек материалым бар», дип сөйли ул тантаналы җыелышта. Аның иҗатында моннан соң әнә шул әдәбиятны тикшерүнең өстенлек алуын күрәбез дә инде без. 1946 елның гыйнвареннан башлап ул яңа төзелгән СССР Фәннәр академия-

сенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли: әүвәл әдәбият секторының кулъязмалар бүлеге житәкчесе, бер елдан шул ук секторның кече фәнни хезмәткәре. Үзенең тормыш һәм ижат юлын 59 яшендә әнә шундый «кече фәнни хезмәткәр» сыйфатында гына тәмамласа да (ул 1952 елның 16 маенда вафат була). М. Галинең әдәби мирасы да, гыйльми мирасы да шактый бай һәм күпкырлы. Ул 38 еллык каләм хезмәтендә кырыклап хикәя һәм ике повесть бастырган әдип буларак үзенең укучыларын тапты. Аның таланты белән аеруча унтугызынчы гасыр ахыры — егерменче гасыр башы татар авылы тормышчан чагылышын тапты. (Дөрес, заманында Г. Кашшаф аның революциягә тикле хикәяләрендә хәтта импрессионизм күренешләрен дә күрергә тырышты, моны кимчелеккә чыгарды). Билгеле, совет чынбарлыгын тасвирлаган хикәяләрендә, гәрчә язучының күренешләрне, кичерешләрне образлы тасвирлавы хак булса да, реаль тормыштагы катлаулылыкны, кешеләр язмышын гадиләштеребрәк, жиңеләйтеребрәк күрсәтү хосусиятен әйтеп китми мөмкин түгелдер. Хәер, бу аның замандашларыннан кайсы гына әдипнең ижатында чагылмады икән!

Утызынчы еллар ахырында һәм кырыгынчы елларда М. Гали әдәбиятның башка төрләренә дә мөрәжәгать итте. Мәсәлән, аның өч сәхнә әсәре язганлыгы мәгълүм. Алар арасыннан «Каюм Насыйри» исемлесе (Х. Уразиков белән бергә ижат ителгән) 1945 елда Татар дәүләт академия театрында куела һәм, атаклы галим-мәгърифәтче образын тудыруда беренче тәжрибә генә булса да, тамашачылар тарафыннан жылы каршылана. М. Галинең «Печәнчеләр, яки бәхет эзләгәндә» (1936) һәм «Имана» (1939) дигән пьесалары, кулъязма хәлендә генә калып, хәзергесе көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының кулъязмалар хәзинәсендә саклана. Боларына да тормыш материалы егерменче гасыр башы татар авылыннан алынган. «Печәнчеләр»дә Гөлжиһан — Тимери мәхәббәте, кызны алдап алып китеп Урта Азия кешесенә сатып жибәрү һәм аның куркып Идел суына ташлану күренешләре истә калырлык рәвештә сурәтләнгән. Ләкин аларны, дөресен әйтик, М. Галинең драматургиядәге зур казанышы итеп санап булмый: образлар тиешле үсештә бирелми, кичерешләргә катлаулылык, киеренкелек житми, сюжет төзелешендә таркаулык бар. Бу авторның яңа жанрдагы тәжрибәсезлегеннән килә булыр. Тагын бер сәбәбе — М. Галинең «социаль заказ»га (партиянең идеологик күрсәтмәләренә) жавап йөзеннән язуы. Тоталитар чор әдәбиятында, без яхшы беләбез, революциягә кадәрге чынбарлыкны сурәтләүдә сыйнфый көрәшкә бәйле якларны иң беренче планга куеп бирү өстенлек итте.

Аның гыйльми эзләнүләре әдәбият белеменең төрле тармакларына карый (66 исемдәге фәнни хезмәте бар). Бигрәк тә классик драматургыбыз Галиәсгар Камалның тәрҗемәи хәле һәм күпкырлы ижаты кызыксындырган галимне. Нәтиҗәдә, күпсанлы мәкаләләр, «Галиәсгар Камал» дигән монографик хезмәт (Казан, 1941) языла. Соңгысы хәзер дә фәнни кыйммәтен югалтмаган. Анда галимнең бик күп истәлекләргә, документаль материалга таянып эш итүе, Г. Камал мирасына әтрафлы бәя бирергә омтылышы ачык күренеп тора. Ул Г. Камал «Әсәрләр»енең ике томлыгын да төзеде (Казан, 1950—1951).

Мөхәммәт Гали, һәм язучы, һәм галим буларак, бөек Тукаебыз тормышын һәм ижатын да үз итте. Шәкерт чагында (Күл буе мәдрәсәсендә укып йөргәндә) ул Тукайны берничә мәртәбә күреп тә кала, ә берчакны, яшь шагыйрь Габдулла Хариска ияреп, аның янына «Болгар»ның 41 нче номерына да бара.

М. Гали, 1928 ел башында шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта булып, анда күргәннәрен-ишеткәннәрен кызыклы очеркында тасвирлады. «Печән базары...» поэмасы турындагы мәкаләсе, «Тукайның Уральскидагы тормышы» исемле хезмәте, балалар өчен «Шагыйрьнең тормышы» исемле очеркы. Тукай турында жыйган истәлекләре — болар бөек шагыйрьнең, аның бай ижат мирасын өйрәнүчеләр өчен һәрвакыт мөрәжәгать итәрләргә тиешле кыйммәтле чыганаклар. Галимнәргә генә түгел, күңеленлә әдәбиятыбызга мәхәббәт йөрткән гади татар баласына да кызыклы алар. Тукай әсәрләренең «Академик басма» дип аталыштагы ике томлыгын төзү һәм бастырып чыгару да М. Галинең якыннан катнашуы белән гамәлгә аша.

Мөхәммәт Галинең XVIII гасыр татар әдәбиятын, Өмми Камал китабын, И. Хәлфин, Ш. Мәржани, Г. Мәхмүдев, Акмулла, С. Рәмиевләр ижатын тикшереп язган, бүген дә фәнни әһәмиятләрен жуймаган мәкаләләре бар. Әдәбият тарихчылары аларга еш мөрәжәгать итәләр.

М. Гали тәрҗемә эшеннән дә читтә калмый, татар поэзиясе антологиясе өчен материаллар әзерли. 1930 елларда 424 битле «Популяр энциклопедия сүзлеге» төзи (басылмый кала).

Гомеренең соңгы елларында М. Галине аерата Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле һәм әдәби-гыйльми эшчәнлеге үзенә тарта. Югарыда искә алынган пьесаны тудыру белән чикләнмәстән, күләмле проза әсәре язуны максат итеп куя. Башта «Бөек мәгърифәтче» дип аталган бу роман, бәлкем язып тәмамланган да булыр иде, әмма вакытсыз үлем комачаулый. Әүвәлге өлешләре «Каюм Насыйри» исеме белән әдип үлгәчтен үк «Совет әдәбияты» журналында басылдылар. (Соңыннан «Каюмның балачагы» дигән китап итеп чыгарылды.) Аларга карап фикер йөртсәк, язучының бу олугъ максатын башкарып чыгачак булып та ирексездән тукталып калуына офтанып куясың. Әдипләребез турында роман-повестьлар болай да сирәк языла.

Күрдек ки, Мөхәммәт Гали — иҗаты революциягә кадәрге чорда башланып та, утыз биш елы совет вакытына туры килгән, аның да иң күп өлеше «бөек юлбашчы» Сталин хакимияте елларында үткән әдип. Ул да үзенең хикәя, очерк һәм пьесаларында социализм төзелешләрен, колхозлаштыруның «тарихи әһәмиятен», сыйнфый көрәшне теге яки бу дәрәҗәдә «социалистик реализм» ысулы белән чагылдырырга тырышты. Әмма бу якларны гына күрсәк, шуларга гына күзебез төшсә, тар күңеллелек, кешелексезлек күрсәтербез, бу — мәсьәләгә гаять берьяклы килү булыр иде. М. Гали иҗатында татар авылы тормышын, сугыш фаҗигаләрен реалистик сурәтләрдә, җиңел аңлаешлы, образлы тел белән гәүдәләндергән, урыны-урыны белән җылы юморга өртелгән әсәрләр дә бар. Нәкъ менә шулар һәм әдәбиятыбыз тарихын тикшерүгә керткән хезмәтләре Мөхәммәт Галинең әдәби мирасын бүген дә яшәтә. Ул мирас халкыбызга әле киләчәктә дә әйбәт хезмәт итәр.

**Зөфәр РӘМИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

## Бакый Урманче

# КАЗАН СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ: ЗАМАН ҺӘМ КЕШЕЛӘР



Б. Урманченың автопортреты. *1924 ел.*

*Быел август аенда бөек рәссамыбыз Бакый ага Урманченың фани дөнья белән бәхилләшкәненә ике ел тулды. Әмма аның вафатына әле дә һич ышанасы килми, ул һаман безнең арабызда, гомер бакый шулай булып һәм еллар узган, ерагайган саен ул безгә һаман якынаер гына төсле тоела.*

*Рәссамның күп меңнәрчә экспонатлы архивында әле беркайда да басылмаган язмаларыннан гына да без үзебезне һаман борчып, кызыксындырып торган әллә күпме сорауларыбызга җавап табар идек.*

*Укучыларыбызга тәкъдим ителгән бу истәлек-мәкалә рәсем сәнгатебез тарихын шактый киң яктырта.*

*Казан сәнгать техникумында Бакый агага ярты елга якын гына укырга һәм соңрак өч ел эшләргә туры килә. Шул өч ел эчендә татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салып калдырырга насыйп булган аңа. Техникумда эшләгән дәверендә ул «Чабата үрүче карт», «Чиләк тоткан кыз», «Фонарь кабызучылар», «Шүрәле», «Татар кызы», «Кичү», «Бикбулатов портреты», «Сепаратор янында» кебек бер карауда мәңгегә истә кала торган әсәрләрен иҗат итә.*

*Мәкаләне редакциягә* **Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ** *әзерләп китерде.*

Ахырыләмер, 1919 елның гыйнварендә мин Казан сәнгать мәдрәсәсенең бусагасыннан уздым. Мәдрәсәнең ниндидер туарылгалрак чагы иде. Сугыш. Бер ел эчендә ике революция. Хуҗалыкның зәгыйфьләнгән заманы. Сәнгать белән маташырга шәраит артык мөсагадә[1] итми. Ләкин сәнгатьтә академизм һәм классицизмга каршы булган сул группа һәммә эшләрне үз кулына алуга бөтен көчләрен сарыф итә иде.

Школада ничә еллар директор булып эшләгән карт рәссам Медведев эшеннән чыгарылган. Аның урынына, «Свободные Архитектурно-художественные мастерские» дип аталган, ягъни революцион мәдрәсә, гали мәдрәсәгә директор булып яшь архитекторлардан Гаврилов килгән. Педагогларның күбесе яңа. Искеләрдән зур абруе булган Николай Иванович Фешин калган. Павел Петрович Беньков аклар белән Себергә киткән. Павел Александрович Радимов (элеккеге директор Медведевның кияве) читкә тибәрелгән. Ачлыктан качып Мәскәү, Петер-

[1] Мөсагадә — мөмкинлек.

бурттан килгән мөгаллимнәр — Шестаков, Комаровлар эшли. Шулай ук мәркәздән килгән студентлар да бар. Җыелышлар, студентларның комитетларын сайлау булды. Программа, дәрес тәртипләрен төзүдә, методик комиссияләрдә студентлар үзләре катнаша. Хуҗалык итүгә, иске тәртипкә каршы хәрәкәт бара иде. Әүвәл иске урыс мәктәпләрендә гаскәриләрдәге кебек тәртип булган. Мөгаллимнәр, түрәләр — чиновниклар, ә шәкертләр — тәбәга[1], кара халык.

Революция — искелекне җимерү, яңа тәртип төзү. «Мастерские» дип аталуларында да бераз романтика бар. Элек зур осталарга барып өйрәнү өчен сәләт-таланттан башка берәр төрле ценз-рәсми кәгазь дә кирәкмәгән. Өйрәнчек үзе теләгән маэсторга барып, үзенең теләгән гарыз итә. Оста теләсә ала, теләмәсә юк. Шәкерт башканы эзли. Шәкерт белән остазның ризалыклары бөтен мәсьәләне хәл итә. Димәк, бөтен эш оста белән өйрәнчекнең үз кулында, түрә белән кара халыкның мөнәсәбәтендә түгел. Менә шул ике якның да теләген канәгатьләндерер өчен остаханә булган. Ләкин Советлар илендә остаханәне хөкүмәт, халык хөкүмәте асрый.

Урманче, әлбәттә, шул ыгы-зыгыга катнашып йөрде. Фешин белән бергә предмет-программа ясау комиссиясендә утырып, халык вәкиле буларак катнашты. Мөгаллимнәр сайладык. Алар үзләренең кандидатураларын яклар өчен эшләреннән күргәзмә ясадылар. Без — бер группа — Василий Кириллович Тимофеевны сайладык. Ул үзенең бик киң колачлап, декоратив рәвештә язылган «Чегәннәр» дигән таблосын куйган иде. Василий Кириллович бу мәдрәсәдә бик күп еллар мөгаллимлек итте. Күп татар балалары аңардан дәрес алдылар.

Бу елларда студентларның контингенты бик чуар иде. Яшь ягыннан да, белем ягыннан да. Гаҗәп, революциягә кадәр шушы школада укыганнарның кайберләре бик наданнар иде. Мәсәлән — Мазунин. Өлкәнрәкләрдән аңлы, белемле, кызык студентлар бар иде. Пузанков дигәне яшь вакыттан иконалар язган, Владимирдан. Новоселов — Вятка губернасыннан. Күп җирләрдә булган, студияләрдә укыган, бик ягымлы, аңлы егет иде. Казан кызлары да байтак иде. Күбрәге белемгә сусаган, укуны тансыклаган кешеләр булганлыктан, тырышып укыйлар иде.

Бер кызык вакыйганы искә алмыйчан булмый. Школада әле, борынгыча, рәссамнар өчен кирәкле буяу, кәгазь кебек әйберләрне сатучы кибет бар иде. Ләкин инде анда бик аз нәрсә калган иде. Буяулар юк. Каян табарга? Пузанковның кул астында буяу изүне оештырдык. Аның чиркәүләрдә иконалар язып йөргәндә алган буяу хәстәрләү осталыгы күп файда итте безгә. Казан кибетләрендә булган бөтен пигментларны алдык, җитен маен табуы шулай ук кыен булмагандыр. Җитен мае булмаса, киндер һәм көнбагыш мае да ярый. Пузанковның тырышлыгы аркасында, буяу изәр өчен 3—4 таш такта һәм курантлар табылды. Бер бүлмәдә буяу изә торган остаханә ясадык. Остаханәдә эшләүгә карап, буяу ала торган булдык. Кәгазьдән тюбиклар ясауны да Пузанков өйрәтте. Пузанков соңыннан Казанда калып, сурәтләү эшендә яңа материаллар ачты.

Мин Казан сәнгать мәдрәсәсендә озак булмадым. Гаскәри хезмәт өчен Мәскәүгә күчү мәҗбүрияте ачылгач, Мәскәүдә ВХУТЕМАС[2]ка керү юлларын эзләдем. Бәхетемә каршы, ПУРР[3] мине укырга җибәрде. ВХУТЕМАСның нәгышь факультеты деканы Ф. Ф. Федоровский мине берсүзсез кабул итеп, Древин остаханәсенә куйды.

Казандагы кебек, монда да татарлардан һәм, гомумән, төрки халыкларыннан берәү дә юк иде.

Казанда нәгышь белән янәшә скульптура буенча Григорий Козлов кул астында эшли башлаган идем. Бу гаҗәп йомшак күңелле, мөлаем большевик мөгаллимнең җитәкчелегендә өйрәнү бик якты истәлек булып калды. Мәскәүдә дә мин ике факультетта өйрәнә башладым. Скульптура факультетының деканы Голубкина үзе авыру булганлыктан, аның остаханәсенә йөреп өйрәнергә шунда доцент булган скульптор Борис Данилович Королевтан рөхсәт сорадым. Ул академический рәсемнәремне күрергә теләде. Күрсәткәннән соң, үзенең кул астында эшләргә рөхсәт итте. 3—4 ел чамасы аның җитәкчелегендә скульптураны дәвам иттердем.

---

[1] Тәбәга — буйсынган, кул астында булган.
[2] ВХУТЕМАС, ВУТЕИН — рәссамнар әзерли торган югары уку йортлары.
[3] ПУРР — Революцион хәрби Советы политидарәсе.

Мәскәүдәге биш елдан артык гомеремнең шәхси ягын калдырам. Мәкаләм татар рәссамнарына гаид[1].

1926 елның язында ВХУТЕМАСны тәмамлап, диплом яклар алдыннан Казанга кайттым. Бер-ике көн үземнең көнкүреш мәсьәләләре белән шөгыльләнгәч, мәгариф нәзарәтенең баш инспекторы Дауд Яналиевка бардым. Ул, минем каршылыгыма карамастан, Казан сәнгать техникумына мөгаллим һәм укыту бүлегенең мөдире — завуч итеп тәгаенләде. Эшкә кабул итәргә күндерде. Дауд Яналиев миңа Мәскәүдән үк якын таныш иде.

— Дауд, мин диплом да алмаган бит әле,— дидем.

— Синнән диплом сорамыйбыз, эш сорыйбыз,— диде.

Техникум директоры Мазунин Казан сәнгать школасын революциягә чаклы тәмамлаган, ләкин сәнгать остасы булып эшләмәгән, сугыштан соң большевиклар партиясенә кереп, түрә булып киткән иде. Тиздән ул Мәскәүгә күчте. Анда «Известия» газетасында ретушь белән шөгыльләнә дип ишеттем. 1937 елны аны Митрей Жилов[2] өендә очраттым. Сәяси хаталары булгандыр, хәле шәп түгел иде.

Директор итеп сәнгатькә һич мөнәсәбәте булмаган Мазулевский дигән берәүне куйдылар. Ул яман кеше булмаса да, эшне белмәгәнлектән, бернәрсә эшләмәде, кәгазьләргә кул гына куя иде. Бөтен эш минем җилкәмә төште. Хыялымда — педагогия хезмәте һәм гомер тәртибендә сурәт сәнгатеннән мәхрүм булган татар яшьләрен өйрәтү иде. Шуңа һич көчемне кызганмастан, сәнгать техникумын тәртипкә китерү эшенә керештем. ВХУТЕИНнан, хөрмәтле профессорларым кулыннан рәхмәтләр әйтеп диплом алуым да онытылган иде. (Миңа яклаусыз гына диплом бирергә карарлары булганын соңыннан, 1957 елда белдем һәм дубликатын алдым.)



Б. Урманче үзенең Казан сәнгать мәктәбендә укучы шәкертләре арасында. Утырганнар *(сулдан уңга)*: Барый Дәминов, Бакый Урманче, Мирсәй Әмир, Зәки Мөхәммәтшин. Басканнар: Гата Йосыпов, Шакир Мөхәммәтҗанов, Мөкаддәс Рәхмәтуллин. *1928 ел.*

Рәссамның архивыннан.

Техникум, чыннан да, бик кызганыч хәлдә иде. Чынлап эшләүче юк. Казанская Императорская Художественная школа өчен махсус салынган гаҗәеп бинаның эче вәйран хәлендә иде. Үзәктән җылыту юк, шәһәр челтәрләреннән алына

---

[1] Гаид — кагылышлы.

[2] Д. Жилов — революциягә хәтле Казан сәнгать техникумын тәмамлаган. Н. Фешин укучысы.

торган яктырту юк, кайсыбер бүлмәләрдә генә вакытлы кирпеч мичсыман дүмгәкләр бар. Күп бүлмәләр ягылмый. Борынгы мөгаллимнәр бүлмәләре бөтен коридор белән томаланган. Казан сәнгать мәдрәсәсе бу хәлдән чыгарга тиеш, егетләр-кызлардан нык профессиональ хәзерлек алган рәссамнар, сәнгать осталары әзерләргә, дигән уй минем бөтен аңымны биләгән иде. Минем уйларымны белгән кебек, завхоз булып эшләгән, үзе шул техникумның студенты булган Чегодаев дигән бер егет кайбер нәрсәләрне урлап, алган акчасын бирмәстән качты. Эзләтеп карадым, табалмадылар. Шуннан соң бер тәҗрибәле, өлкән яшьтәге завхоз таптым, аның белән икәү бинаны тәртипкә китерә башладык.

Бәхеткә каршы, шул чакта техникум кассасына байтак акча керде. Ул болай булды. Революциягә кадәр патша хөкүмәте Питрәчтә керамика мәктәбе ачкан булган. Ул 3—4 ел эшләп, әле нәтиҗәгә ирешә алмый калган. 1914 елда дөнья сугышы башлангач, осталары фронтка китеп, мәктәп вакытлы рәвештә ябылган. 1924 елларда аның бөтен җиһазын Казанга — сәнгать техникумына китереп ташлаганнар. Ул шулай яткан.

Минем сәнгать мәдрәсәсе идеалы бик киң булганлыктан, бу әйберләрдән файдаланып, керамика бүлеге ачарга ният иттем. Казанда сөйләшүләрем нәтиҗә бирмәгәч, бөтен материалны үзем белән алып, Мәскәүгә ВСНХның[1] керамика һәм пыяла Главкына киттем. Аның башында профессор Философов тора икән. Ул мин укыган сәнгать институтының керамика факультетында укыткан иде. Мин доклад ясадым, керамика бүлеге ачып җибәрү өчен нинди җиһазлар барын күрсәттем (язуда).

— Безгә сатыгыз боларны,— диде профессор, мине гаҗәпкә калдырып. Димәк, безнең кулыбызда кыйбатлы мал бар икән.

— Юк, хөрмәтле профессор, сез безгә ярдәм итегез керамика бүлеге ачарга,— дидем.

Байтак сүз булганнан соң, профессор:

— Ярый, ярдәм итәбез. Ләкин ул остаханә техникум каршында булса да, техникум бүлеге булмас. Безнең идарәдә булсын, безнең каршыда җаваплы булырсыз,— диде. Мин шуңа күндем.

Эшне башлап җибәрергә егерме мең сум акча бирергә булдылар һәм аны тиздән безнең техникум бухгалтериясена күчерделәр дә.

Инде оста табарга кирәк иде. Кайдан? Кеше эзли башладым, институтның керамика факультеты мөдире булган Филипповка киттем. Ул Мәскәүдә берәүне дә күрсәтә алмады. Керамика факультетыннан диплом алган студентлар ул юлдан китмәгәннәр, күрәсең. Мәсәлән, ташкентлы Тависиев керамикадан һич ни эшләмәде, нәгышь, стан нәгыше белән гомер итте. Томскида бер оста бар, ул Венада укып, өйрәнеп кайткан кеше, ихтимал килер, диделәр, адресын бирделәр.

Бу кешегә мин хат язып чакырдым. Аннан шундый җавап килде: фәлән кадәр эш хакы, күченер өчен өч вагон, бөтен юл расходларын түләргә һәм Казанда өч бүлмәле өй. Моны без тәэмин итә алмадык, әлбәттә.

Башка юллар эзләргә кирәк иде. Әгәр ул чакта минем хәзерге белем һәм тәҗрибәм булса, җиңел хәл иткән булыр идем. Ул вакыт минем керамикадан белемем бөтенләй юк иде. Укырга махсус әдәбият таба алмадым. Зур теләк кенә бар миндә.

Болай карар кылдык. Питрәчтә чүлмәк осталары бар. Шулар арасында, әлбәттә, шушы керамика мәктәбендә эшләгәннәре дә калгандыр.

Иң әүвәл шул мәктәптә бераз дәресләр алып барган бер һәвәскәр рәссам табылды. Аның ярдәме белән бер останы таптык. Мич салынды. Анда ялгышлар булып, балчыкны яндырганда уңайсызлыклар чыкты. Университетның химия факультетында соңгы курста укый торган ике егетне чакырып, эш тәкъдим иттем. Боларга шундый вазифа йөкләдем: оста (Питрәчтән килгән, ул бик начар укый-яза белә) үзе белгән рәвештә төрле керамика әйберләре ясый. Муфель пичендә, борыннан калган химикатлардан файдаланып. Һич тарсынмыйчан яшьләрне чүлмәк түгәрәгендә эшләргә өйрәтә. Ә химик егетләр аның эшләгәнен карап, һәрбер эшен тырышып язып баралар һәм нәтиҗәләрен фәнни тикшерәләр.

Үзем бөтенесен тикшереп барам. ВСНХның акчасыннан уңышлы файдалану буенча завхоз һәм бухгалтер белән юллар эзлибез. Безгә жылы кирәк, якты кирәк. Шул акчадан экономия ясап, акыл белән файдаланып, техникум бинасын жылыту һәм яктырту системаларын да төзәтергә кирәк. Керамика остаханәсенен

---

[1] ВСНХ — Башында С. Орджоникидзе торган Халык хуҗалыгы Югары Советы.

урыны техникум бинасы эчендә булу да уңайлы. 1928 елда инде техникум бинасы тәртипле жылына һәм яктыртыла иде.

Шул килеш дәвам иткән булса, бу остаханә гажәп уңышларга ирешеп, күп сәнгать әсәрләре әзерләп, күп осталар үстереп, зур бер ижади фабрикага әйләнер иде.

Шулвакыт кемнеңдер явыз кинәше, коткысы белән безнең бинага театр техникумын да китереп урнаштырдылар. Эчке тәртип бозылды. Бу шаукымлы халык, бигрәк тә хатын-кызның күп булуы, аларның туктаусыз тормышларыннан роман ясаулары безнең остаханәләрдә басылып эшләүнең тынычлыгын харап итте. Ике техникумга бер директор, бер бухгалтерия — экономия, имеш.

Сәхип Мортазин директор булганда яманлыгын күрмәдем, акыллы кеше иде. Бичара 1937 елларда бәхетсезлеккә очрады. Әмма театр техникумының завучы Залкинд дигән берәү һәр эшкә тыгыла торган, һәр эшне «белә» торган, һич тиктормас, интриган кеше иде. Соңыннан Мәскәүгә күчте. Иконалар жыя иде. Бу кешегә тукталуның сәбәбе — ул шушы дәвер өчен характерлы булган типларның берсе иде. Үзе юрист икән, Казанның Духовная Академиясында хокуктан дәресләр биргән. Әллә чукынган яһүди булганмы? Казанда Державинның һәйкәлен урыныннан алуда да Залкиндның катнашы булган икән, дигән сүзләр йөрде. Кыскасы, аның сәхнә сәнгатенә һичбер мөнәсәбәте юк иде. Ник ул татар театр техникумының укыту-өйрәтү эшләренең башына куелган? Татарча да белми, әлбәттә.

Минем мөгаллимнәр арасында янә шундый, ягъни һәр эшкә керешә торган берәү булды. Ләкин ул бик намуслы, һичбер интрига ясый алмый, ясамый да иде. Бу — Михаил Михайлович Хомяков, Казан университеты профессоры М. Хомяковның улы. Нинди белем алганлыгын мин белә алмадым. Тарих-филология факультетын тәмамлаган булса кирәк. Аяклы энциклопедия. Нинди эшне тапшырсаң, шуны эшләргә тотына. Бигрәк тә методикаларны үзгәрткән вакытта ул, әлбәттә, шуның алдынгысы була иде. Дальтон-план, бригада системасы янсә башка бер ысул белән программа төзәргә кирәк булса, Михаил Михайлович һич карышусыз шуңа керешә. Эстетикадан дәрес бирергә кеше кирәк булса, ул әзер. Нәгыйшь технологиясеннән кеше таба алмасак, ул аны да ала. Бу — шагыйрь Мәхмүд Бөдәйлинең Наркомздрав булган заманы, ул ук юстиция наркомы иде. Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин, дәвере шундый — революция!

Программага татар әдәбиятын керттем. Бу һичбер уңайсызлык кылмады. Телсәләр, руслар да керәләр иде. Практикада бу ничек алып барылгандыр, исемдә калмаган. Кыскасы, һичбер уңайсызлыгы булмады. Татар әдәбиятын язучы Садри Җәләл укыта иде.

Югарыда язылганча, техникумның хужалык эшләре нинди начар хәлдә булса, укыту-өйрәтү эшләре дә әллә ни тәртиптә түгел.

Дөрес, футуризм тарафдарлары сирәгәеп, мөгаллимнәр арасында Федотов, Кашаев, Сокольский кебек, вакытында бик сул булып йөргән реализм тарафдарлары да йомшарганнар иде. Шигырь, театр, сынлы сәнгатьтә футуристларның эше социализм кору өчен халыкны революцион рухта тәрбия итә алмыйчан, коры искене жимерүдән генә гыйбарәт иде. Шулвакыт борынгы, XIX гасыр сәнгате, передвижникларны реставрация кылырга теләүче бер көчле оешма корылды — АХРР (Ассоциация Художников Революционной России). Бу оешманың башында П. Радимов, А. Григорьев, Карев, Христенко кебек сәнгатьтә борынгы юлларны яклаучылар булды. Боларның акыллысы, салмак холыклы, дөньяны абайлый алучы, чын зыялы, Казан университетында тарих-филология факультетын тәмамлап, Казан сәнгать школасында рус әдәбияты мөгаллиме булган шагыйрь, соңыннан рәссам булып киткән Павел Александрович Радимов иде. Бу кеше, чыннан да, акыл-уй иясе иде. Заманында Тукай шигырьләрен дә тәржемә итте.

Бу оешма тиздән зур көч алды. Казан сәнгать мәктәбенә йогынтысы көчле булды. Игътибарлы мөгаллимнәрдән А. Тимофеев, П. Беньков, хәтта Кашаев да шушы оешмага кереп, алар белән АХРРның Казан бүлекчәсе көчәйде. Бу хәрәкәттә реакцион элементлар да бар иде, әлбәттә. Ләкин бу хәлнең социаль-политик якларын тикшерү ми[illegible]ем вазифам да, кодрәтем дә түгел. И. Репин боларның рухани аталары иде. Космин, Бродский да шунда. Ләкин шуның белән бергә, бу «уңнар» рус сынлы сәнгатенең корифейларыннан булган В. Серов, Врубель кебекләрне анафемага бирделәр. Импрессионизм яраксыз модернизм булып тәлкыйн[1] ителде. Архитектурада борынгы классицизмга кайттылар. Клас-

---

[1] Тәлкыйн — төшен[illegible]е[illegible], аңлату.

сицизмга — борынгылыкка борылыш шулкадәр куәтле булды ки, корыла башлаган павильоннарны җимереп, алар урынына борынгы ордерларда төзелгән яңа павильоннар салдылар. Шул ук вакытта милли архитектура формалары күренә башлап, әзербайҗан, грузин, үзбәк архитекторлары милли төзелеш рәвешләрен күтәреп, ВСХВда аларның павильоннары яңадан ясалды.

Татарстан павильонын Мәскәү архитектура институтының мөгаллиме Исмәгыйль Гайнетдинов ясады. Бу һәр тарафтан төпле уйланып, урынын, функциясен абайлап төзелгән бина, татар халкының төзелеш формаларын тарихи тергезеп ясалган бина, татар милли архитектура стилен яңа корылыш шартларында торгызуның беренче адымы һәм, чыннан да, уңышлы адымы иде. Әгәр Исмәгыйль шуннан башка бер әсәр дә калдырмаган булса да, аның бөек татар төземчесе дип аталырга хакы бар. Кызганыч ки, бу бина ВДНХ оештырылган вакытта җимерелде. Бу бина һәр тарихи формалардан һәм яңа төзелеш кануннары таләбеннән хасыйл булган бер шедевр иде. Соңыннан И. Гайнетдинов татар опера театрын, елга портын һәм вокзалын корды. Һәрберсендә бу төзүченең даһәсе[1] эз калдырган.

20 еллардагы яңа алымнарга кызыгу дәвереннән соң, 30 елларда зур үзгәрешләр, революцион темп белән юлдан-юлга күчүләр булды. Техника, инженерия алга чыкты. Сәнгать, бигрәк тә сынлы сәнгать, сурәтчелек, инженериягә комачаулый торган балласт булды, ахры.

Казан сәнгать техникумы да туздырылып, аның Грузинская урамындагы (хәзерге К. Маркс урамы) бинасын авиация институтына бирделәр. Техникумның хуҗалыгы җимерелгән, керамика остаханәсенең бөтен уникаль, кыйммәтле җиһазлары тимер ватыклары итеп утильгә бирелгән иде. Графика факультетының туып кына килгән чагы. Зур кыенлыклар белән, студентларга өйрәнү өчен җыелган ташбасма әйберләре һәм бик кыйммәтле, бөтен Советлар илендә ике генә данә булган офорт станогы шулай ук таратылып, тимер ватыгы итеп юкка чыккан иде. 1929 елның көзендә мин Казаннан ирексез китеп, 1933 нең ахырында яңадан кайткан вакытта[2], Сәнгать мәктәбе Гоголь урамындагы, борынгы Казан өязе идарәсе булган бинада урнашкан иде. Миңа үземнең эшләрем буенча яңа директорны күрергә кирәк булды. Мескен генә кеше икән. Аның сәнгатькә һичбер мөнәсәбәте юк, һичбер эшкә сәләте дә, профессиональ белеме дә юк. Хакыйкатьтә сәнгать мәктәбе үзе дә юк иде. Йөрәгемә кан савырылды, күземә яшь тулган иде. 4—5 ел эчендә Казан сәнгать учагы колатылган.

Ә мин шушы олугъ зәвык белән ясалган, архитектура әсәре буларак Казанның бөтен биналарыннан аерылып торган төзелеш әсәрен, бозылган төшләрен вакыт мосагадә иткәндә төзәтеп, шунда Идел-Чулман халыкларын өйрәтә торган сәнгать мәгъбәде — мәдрәсәсе булуын теләгән идем. 1913 елларда тышыннан сокланып, бер генә тапкыр эченә кереп күргән, соңыннан 1919—1920 елларда шуның остаханә һәм дәресханәләрендә кинәнеп эшләгән һәм дәрес алган чакларым искә төште. Авыр салмак имән ишекләрен ачкач, сине каршылаган гаҗәп уйма арысланнар, төрле төстәге витраж тәрәзәләрдән төшкән нурларга ышыкланып яткан, авыр азаптан котылырга тырышкан Самсон фигурасы, уңайлы көтепханәсендә нәфис сәнгать хакындагы китапларны карап-укып утыруның рәхәтлеге, остаханә һәм актлар залында тагылган сурәтләрдән алган әсәрләнү, шәкертләрнең еллык күргәзмәләрендә сөенеч һәм көенеч тойгыларының күңелне дулкынландырулары... Боларның барысы да шушы Урта Идел халыклары яшьләрен, кызларын иҗади шаукымнарга сөрсен, диган күңел белән, бинаны элекке хәленә, уку-өйрәнү тәртибен иң югары дәрәҗәгә ашырырга, диган уй белән эшкә керешкән идем.

Алда ашкындырырлык, күңелне шашындырырлык перспективалар бар иде. Иртәнге 7-8 дән кичке сәгать 11 ләргә кадәр эшләп, төшлектә генә өйдә булып, кайвакыт остаханәмдә кунып та кала идем. Казан сәнгать школасында архитектура мөгаллиме булган Мюфкенең гаҗәп бөек зәвык белән төзегән бу бинасы[3] һәм аның эчтәлеген Казанның иң сокланырлык сәнгать учагына әверелдерү уе мине рухландыра, кичен өйгә кайтсам, иртән ашкынып шунда ыргыла идем.

Минем уемча, һәм иҗади, һәм идарә, һәм дә тәрбия итү эшенә монда бөтен мөмкинлек бар иде. Дүрт бүлек ясарга уйлыйдыр идем: нәгышь, уйма белән керамика, төзелеш, графика. Шуларның барсына да инде нигез салынган иде.

---

[1] Даһәсе — гение.

[2] Автор 1929 елның 13 августыннан 1933 елның декабренә хәтле Черек күлдә, Бутырка төрмәсендә була һәм Соловки лагерена сөрелә.

[3] Хәзерге КАИ бинасы, К. Маркс урамы, 60 йорт.

Бары архитектураның бездән аерылуы мөмкин иде. Чөнки ул чакларда архитектурада ялгыз конструкция, рационализм, инженерия хөкем сөрә.

АХРР яшьләрнең күңелен казана алмады. Мәктәпләргә йогынты ясый алмады. Мәскәү сәнгать институты студентлары АХРР хәрәкәтенә искелек дип карадылар.

Хуш. Хәзер инде шул 1926—29 елларның кыска дәвере эчендә нилэр эшләнде?

Әлеге техникум эшләрен идарә итү миңа 1926 елда тапшырылды, дидек. Карыйм: борынгыча ук татарлардан бер студент юк! Бары дүрт егет ирекле укучы (өйрәнүче) булып йөриләр: Мортаза Габдуллин, Дәүләтшин, Әхмәтшин, Юсупов.

Бик эчем пошты. Ник болай? Бөек Октябрь революциясенең тугызынчы елы. Милләтнең, татар культура хәятенең шулкадәр тансыклап көткән сурәтчеләре кайда? Казан сәнгать мәдрәсәсе ирекле белем алу урынына әверелгәннән соң да татар яшьләре читтә, үги булып йөриләр.

Минем билгеләнү июнь-июль айларында булса кирәк. Димәк, тиздән техникумга кабул итү имтиханнары башланачак. Дауд белән татар яшьләрен техникумга җәлеп итү турында киңәшләштек. Яшьләр һәртөрле техникумнарга керә. Күбрәк авылдан киләләр. Үзенә күрә бу кызык дәвер. Күп профильдәге техникумнар ачылды. Күбесе кайсы техникумга барырга икәнен дә әле бик ачык белми. Мәгариф комиссариатына баралар, аннан техникумнарга юнәлдерәләр.

«Татарстан» гәзитенә игълан бирдем. «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналында сәнгать техникумының фоторәсемнәрен кушып мәкалә бастырдым. Шулай итеп, техникумга өндәү башланды. Дауд балаларны урнаштыру вазифасын алып барганлыктан, яшьләр әүвәл аңарга баралар иде. Әгәр шулар арасында кайсының сурәт ясарга мәйле һәм сәләте булса, Дауд аларны миңа юнәлтә торган булды. «Бакый абыйны» сорап килә иделәр.

1926 елда, һич булмаган белән чагыштырганда, байтак укучы алдык. Ун кеше тирәсе булгандыр.[1] Шулар арасында Казахстаннан Мәэмүн Сутюшев, Башкортстаннан Атбасар Идрисов, Мирсәй Әмир, Акмәчеттән Солтан Борондуков, Стәрлетамактан Рәхмәтуллин, Оренбургтан Газизова. Бер гаҗәп хәл буларак, Пешпәктән (Фрунзе) килгән Шакир Мөхәммәтҗанов Казан университетының медфакын ташлап, сәнгать техникумына керде. Башта минем янга кергән иде. Медфакны ташлама, дип үгетләп карадым. Юк, техникумга килде. Бик сәләтле иде, бик намуслы. Тумыштан сәнгатьнең оригинал һәм прогрессив формаларын ятатучы. Үзенең эшләрендә дә шул сизелә. Миңа карата хөрмәтле һәм дустанә иде. Шул яхшы мөгамаләсен мин Соловкидан кайткач та дәвам иттерде. Күп еллар Татарстан нәшриятында баш сурәтче буларак хезмәт итте. Бу хезмәт аның кулында булу бик лаек иде. Бер үк вакытта аны иҗади ерагайтты, ахры. Мондый мөләем, саф күңелле, пакь аңлы кешеләрне мин сирәк очраттым.

Яңа алган шәкертләрнең күбесенең әзерлеге (һәм гомумбелем, һәм сәнгатьтән) түбән иде. Боларны кабул иткән вакытта да миңа бик гайрәт итәргә туры килде. Татарлардан күбрәге — авылдан. Аларга мәктәптә үк яхшы рәсем дәресләре алган, гомумбелемдә дә тәртипле шәһәр мәктәпләрен тәмамлаган студентлар белән бер дәрәҗәдә укып бару кыен булды. Шунлыктан мин Наркомпросның профбелем бүлеге мөдиреннән рөхсәт алып, мондый белеме житешмәгән балалар өчен аерым группа ясап, репетиторлык өчен университет студенты Суфия ханым Туишеваны чакырдым. Атнага өч тапкыр икешәр сәгать укыйлар иде. Бу чара бик уңышлы булып чыкты. Тырыш, укуга сусаган яшьләр уку елы ахырындагы имтиханнарга кадәр үк сыйныфташларын куып җиттеләр. Кыскасы, Императорская Художественная школа бинасында, революциягә кадәр бусагасын да атламаган татар яшьләре белем ала башлады.

«Вольнослушатель» тәртибен күчерүне мәгъкуль күрдек. Аның урынына һәвәскәрләр өчен ял көне курслары, студия ачтык. Вакытын кая куярга белмичә йөргән шалопайлардан котылу нияте белән бу студиядә өйрәнүне түләүле ясадык, бу мөгаллимнәргә дә азгына булса да файда итте. Ул чакларда сурәтчеләр иҗади союзы юк. Бер группа техникум тирәсендә, башкалары гәзитләрдә, театрларда эшлиләр. Профсоюзның сәнгать секциясе аларны оештыра иде. Сонрак Татхудожник дигән оешма булды.

---

[1] Әгәр берәр хәлне арттырып язган булсам, мине дәлилләр белән төзәтсеннәр. (Б. Урманче искәрмәсе).

Инде әлеге дүрт иректе өйрәнчекләрнең язмышын хәл итәргә кирәк иде. Дүртесен дә чакырып алдым. Алдымда утырдылар.

— Егетләр, ник укымыйсыз, болай селкенеп йөрисез? — дидем.

— Бакый абый, безнең хәл мондый. Стипендия алмыйбыз, тамак туйдырырга шәһәр буенча вак-төяк эш эзләп йөрибез. Торырга урыныбыз да юк, шунлыктан имтиханнарга әзерләнә алмыйбыз. Имтихан бирмәгәч, безнең стипендия алыр хакыбыз юк. Менә шулай артта калдык...

— Укырга телисезме соң?

— Телибез, шулай булмаса, ни эшләп монда йөрер идек, — диделәр.

— Егетләр, әгәр әйткәнегез дөрес булса, мин сезгә бүгеннән башлап стипендия бирәм. Начар булса да, гомуми җәмәгать торагына урнаштырырбыз. Укырга һәркөн йөрисез. Артта калган дәресләрне үтәү өчен бүген ук тәртип ясыйбыз, һәр сабактан үзегез сроклар куясыз һәм шул тәртипне мин мөгаллимнәргә бирәм. Вакытында мөгаллимнәр сезнең әзерлекне тикшереп, миңа әйтерләр. Әгәр сүзегездә тора алсагыз, үзегез дә бәхетле булырсыз, мине дә сөендерерсез. Бәс, иртәгә беренче стипендияне алырсыз. Миңа сабаклар тәртибе, кайчан, кайсы имтиханны бирәчәгегезне язып, кул куеп кертерсез һәм шуннан соң тулай торакка барып урын алырсыз. Әгәр вәгъдәне үтәмичә, беренче сабакта ук бирәр чатак булса, мин ул кешене техникумнан бер көн эчендә куам. Сез, егетләр, кечкенә бәбиләр түгел, аңлагансыздыр, — дидем.

Дәүләтшин дигәне сүзендә тормады. Һаман йоклый икән. Ләкин үзе сау. Эшкә өйрәнмәгән. Зур тавышлап, куып чыгардым. Оренбурына кайтып китте. Башкалары бурычларын үтәделәр. Курстан курска күчеп, уңышлы рәвештә техникумны тәмамлаганнар. Ул вакыт мин Казанда түгел идем инде.

Мортаза Габдуллин соңыннан, Ленинградта Академия курсын уңышлы узып, диплом ала. Казанга кайтып, татар драма театрының баш сурәтчесе булып, байтак спектакльләрне бизәгән. 1936 елда Мәскәүгә күчеп, анда эшләде. Кызганыч, яшьли саркомадан вафат булды. Миңа хөрмәте бар иде.

Әхмәтшин техникумны уңышлы тәмамлап, Томскида татар педагогия техникумында рәсем мөгаллиме булып киткән иде. Бу техникум ябылгач, Казанга кайтып, берничә урта мәктәптә рәсем дәресләре укытты.

Йосыпов бик талантлы график иде. Гаскәргә алынып, ПВОның Самарада чыга торган гәзитәсендә рәсемнәр ясый һәм шунда кала.

Куылган Дәүләтшиннан башкалары, техникум курсын узып, җәмгыятькә файдалы эштә булдылар.

Беренче курска алынганнардан һәммәсе диярлек кеше булдылар. Сутюшев Мәэмүн Академтеатрның баш сурәтчесе булып, уңышлы постановкалар ясап, пенсиягә чыкты. Исән-сау, Казанда яши.[1]

Мөхәммәтҗанов Шакир. Бик сәләтле график булып, Татарстан нәшриятында күп еллар баш рәссам булып эшләде. Гүзәл зәвыклы, яхшыны яманнан аера белә торган ага рәссам булып танытты үзен. Әйткәнемчә, яшьләй вафат.

Мөхәммәтша Кәримов (Чиләбедән) музей эшенә китеп, әүвәл Казан музеенда, соңыннан Мәскәүдә эшләп, Революция музеенда уңышлы хезмәт итте. Музейнең баш сурәт остасы булып, реставрация эшендә зур абруй казанды. Хәзер пенсиядә, Мәскәүдә тора.[2] 20 нче еллардан калган эшләремнең исән саклануына мин тулысы белән аңа бурычлы.

Мусин китап графикасы өлкәсендә эшләде, Тукайга ясаган рәсемнәре дә бар.

Газизова техникумны тәмамлаганнан соң, туган җире Оренбурга китеп, уңышлы рәвештә нәгышь эшләре белән шөгыльләнә.

Бу урында техникумда укып, сәнгать мәйданында эшләгәннәрдән Хәнбәл Алмаевны һәм инде олугъ яшенә ирешкәч, техникумда укырга, белем алырга ният итеп, шуны эшкиндерә алмаган Яхшыбаевны искә алырга кирәк. Бу кешене бик кызгандым, вакытында белем алган булса, театр сурәтчесе булып, татар-башкорт культурасына игелеге күп тигән булыр иде.

Хәнбәл кызык, үзенә аерым бер холыклы егет иде. Аның сеңлесе Рабига медфакта укып, Оренбурда табиб булып эшли, диделәр. Хәнбәл музыкант та иде, скрипкада уйнады, 1950 елларда Сәмәркандтә, дәдәсе Гыймад Алмаев өендә очраттым. Скрипкасын әле үзе белән алып йөри икән. Бик чарыс[3] иде. Бервакыт дәрескә килми йөрде.

---

[1] 1990 елда вафат.
[2] 1990 елда вафат.
[3] Чарыс — кыргый, үткен.

— Хәнбәл, ник дәрескә дөрес йөрмисең? — дим.
— Шәһәрдә йөрим, — диде.
— Ни калган анда сиңа?
— Менә инде, Бакый абый, мин бит художник, дөньяны, шәһәр халкын тамаша кылам. Ясар өчен күрергә кирәк бит, — диде.

Икенче тапкыр сеңлесе Рабига миндә портрет-этюдка позировать итеп утырганда күз яшьләре белән сөйләде. Бүлмәдә икәү торалар икән. Бүлмәдә тычканнар бар, ди. Алардан саклапып, Рабига өстәл өстен, азык-төлекне җыеп китә. Ул өйдән киткәч, Хәнбәл юри өстәл өстенә ипи валчыклары таратып китә икән. «Зинһар, Бакый абый, Хәнбәлгә әйтегез, туктасын, тычканнарны качырсын», — дигән иде.

Хәнбәлне ачуланырга булдым. Ләкин ул хәйләле көлемсерәп: «Ничек инде? Тычканнарга да ашарга кирәк бит», — диде.

Шушы Алмаевларга минем симпатиям булды. Рабига гади татар кызы киемендә миңа нәгыйшь өчен позировать иткән иде. Ул портрет «Татар кызы» исемендә Мәскәүдә, Шәрык сәнгате музеенда саклана[1]. Яхъя белән Рәүф Алмаевлар — Саратов губернасы Сайман авылының Җәлал хәзрәт уллары. Барсы да «Мөхәммәдия» дә укыдылар. ГПУда эшләгән Әхмәтҗан Алмаев та шул фамилиядән.

Солтан Борондуков. Бу егет Акмәчеттән (Кызыл-Орда) икән, соңыннан белдем. Скрипка уйнаган. Мин Ташкентта эшләгән вакытта, педагогия институтының рәсем-графика факультетында эшләгән. Ләкин ни өчендер ул вакыт мине күрмәде. Соңыннан Казанда һәм Ташкентта очраштык, өендә кунак иттс. Солтанның шигырьләре дә бар икән. Яшьли вафат булды. Хатыны Рокыя ханым шигырьләрен миңа җибәрергә вәгъдә иткән иде. Ләкин җибәрмәде. Угыллары бар, Ташкентта торалар. Бу үз халкын бик сөйгән гаиләнең тормышы мине һаман кызыксындыра, кызгандыра.

Латыйпов. Керамиканы бик яраткан иде. Кайда китте — хәбәре булмады.

Баһаутдинов. Моның исемен дөрес атадым микән? Бик сәләтле егет иде. Өфедә эшләде, дип ишеттем.

Әхмәтморад Рахманкулов. Троицкида (Яманкала) ишле һәм билгеле Рахманкуловлардан. Бу фамилиядән игътибарлы хәзрәтләр, язучылар (Әхмәдтаҗетдин, Шәриф) һ. б. бар. Әхмәтморад техникум тәмамлаганнан соң Өфедә сурәт мөгаллиме, аннан соң Мәскәүдә ВГИКның мультипликация бүлеген тәмамлап, Казанда кино эшендә, Худфондта, телевидениедә, Мәскәүдә татар драма театрында эшләде. Кыскасы, сурәт остасы буларак, культурабызда урыны бар. Әлегә хәтле дусларча, туганнарча аралашып яшибез.

Нури Арсланов. Бу данлыклы шагыйребез Казан сәнгать техникумында белем алды. Казахстаннан килгән. Беренче эшелон студентларының берсе. Яшь вакытында беркадәр сурәт остасы буларак та эшләде. Соңыннан шигыре өстен чыгып, хәзер Нури — татар поэзиясенең корифейларыннан. Миңа бик күңелле Нуриның мин мөгаллим булган заманда техникумга укырга керүе[2].

Икенче могътәбәр язучыбыз мәрхүм Мирсәй Әмир техникумның шул вакыттагы хәятыннан матур истәлекләрен дә язып калдырды[3]. Мин киткәч, бу техникумда Әмирхан дустым Еники дә укып йөргән икән.

Кайберәүләре, ихтимал, онытылгандыр. Новосибирскидагы Н. Хомков, Сызраньдагы Д. Ховanский кебек шәкертләрем белән әле дә хатлашып, хәбәрләшеп торам.

Ләкин минем әйтергә теләгәнем — сурәтчелек һөнәрен күтәрүдә Казан сәнгать техникумының 1926 елдан башлап татар культурасына игелек китерә башлавы. Кайберәүләр бу язганым мактану дип тәлкыйн итүләре дә мөмкин. Халыкка файда китерерлек эш белән бераз горурлану гөнаһ дип уйлыйм. Мин үземнең бурычымны халык алдында үтәргә тырыштым. Әгәр электән базис, ягъни 1919 елда татарлар өчен дә юл ачылган Казан сәнгать школасы булмаса, 1895 елда әлеге сокланырлык бина салынмаган булса, Бөек Октябрь революциясе школа тирәсендә булган христиан дине пәрәвезен үчермәгән булса, мин техникумның мөгаллиме дә, укыту бүлеге мөдире дә булмаган, димәк, шул 1926 елда, татар яшьләре өчен бу гаҗәп бинаның ике арыслан саклый торган авыр имән ишеген дә ача алмаган булыр идем.

Кайвакытта ишек ача белүче дә кирәк бит. Шул мин ачкан ишектән тех-

---

[1] Хәзер Татарстан сынлы сәнгать музеенда саклана, «Яшел күлмәкле кыз» дип атала.
[2] 1991 елда вафат.
[3] М. Әмир. Хатирәләр урманы. Казан, 1982, 108—128 битләр.

никумнын аудитория һәм остаханәләренә ыргылып кергән яшьләрдән беренче эшелон буларак, әнә шул югарыда аталган осталар чыкты. Аларның барсы да бер дәрәҗәдә түгел. Аннан соң заманның ихтыяҗы сәукы[1] буларак, болар стан сәнгате әһелләре булмадылар. Ул вакыт стан сәнгате кирәксез, әһәмиятсез эш кебек карала иде. Шунлыктан — 30 еллар шаукымнары. Сурәтчелек һәм стан сәнгатенә йөз белән әйләнү 1934 елда, нарком Бубнов чагында башланды.

Ул болай булды. Бу фәкыйрь шулвакыт оештырылган зур күргәзмәгә 1926—28 елларда ясалган эшләре белән катнашты. Миннән башка ул күргәзмәгә эшен куйган татар егете булдымы, эше кабул ителдеме икән? Бу күргәзмә Мәскәү Тарих музееның икенче катында иде. Бөтен Мәскәү, Ленинград һәм өлкәләрдән күп кеше катнашты. 1930 елларның башында ясалган җимерүдән соң хөкүмәт сынлы сәнгатькә карата яна сәясәт тотты, ахры. Мин Соловкидан кайтып килгәндә Мәскәүдә Дмитрий Лопатниковта туктадым. Ул элек минем чакыру белән Казан техникумында мөгаллимлек кылган иде. Техникум таралганнан соң Казанны калдырып, Мәскәүдә төпләнгән. Мәскәүдә зур күргәзмә ясарга теләүләрен миңа ул әйтте һәм эшләрне алып барып күргәзергә тәклиф итте[2].

Мин, Казанга кайтып паспортларны рәтләгәч, Федотов һәм Халтурин дигән укытучылар ярдәме белән аларның төрле диаграмма, плакатлар ясый торган бригадасында бераз акча эшләп алдым. Шул акча белән Мәскәүгә җыендым. Ничек булса да, Мәскәүдә урнашырга күңел беркеттем. Сакланып калган 4—5 нагышь һәм 5—6 кытай туше белән ясалган рәсемнәремне табып, Мәскәүгә юнәлдем. Җюрига тапшырдым. Барысын да алганнар һәм экспозициягә куйганнар иде. Башкортстанда ясалган ат рәсемнәре, Казанда ясалган бурлаклар, йөк ташучылар бар иде. Бу рәсемнәр уңышлы булдылар. «Комсомольская правда» газитенең 1934 ел 26 июнь санында «Атлар» рәсеменең репродукциясе басылып чыкты, әле күргәзмә ачылмаган, бу аннан агаһландырып кую гына иде. Минем өчен бу, әлбәттә, зур бәхет булды. «Творчество» журналында, шул күргәзмәнең графика бүлеге хакындагы мәкалә минем «Бурлаклар» рәсеме белән ачылды (1935 ел). Рецензия көткәннән артык. Бу күргәзмәдән соң оформительлек дәвереннән стан сәнгатенә (нагышь, стан графикасы) юл ачылды. Күргәзмәдә катнашкан меңләп автордан 200 не сайлап, шуларга заказ биреп эшләтү — матди ярдәм итү өчен «Всекохудожник»ка исемлек тапшырылды. Бу фәкыйрегез шул 200 сурәтче арасында иде. Мин договор төзеп, аванс алдым. Моңар кадәр Д. Лопатников белән шабашкага йөри идек. Оформительләрдән босслар бар. Алар төрле бәйрәмнәр чагында бөтен районнарны бизәү эшен алып, подрядчиклар сыман, вак-төяк кисәкләрен төрле рәссамнарга бирәләр иде.

Лозунглар озын булганлыктан, аларны һәр җирдә язып булмый, киң идән кирәк. Көндез андый зур идән булган җирләр — клублар. Анда халык йөри. Шунлыктан «лозгун»нарны (шаргонда шулай атала иде) төнлә белән, кеше йөрмәгәндә озын коридорларда яисә физкультура, бию залларында яза идек. Төнлә алар кибеп өлгерә, иртән җыеп алалар. Лопатников белән без шулай байтак эшләдек. Бу заманда сурәтчеләр шул бизәүләрдән хасыйль иткән акчага яшәделәр.

1935 елның башында инде мин үзем бер объект алдым. Боткинская шифаханәсен 1 май бәйрәме өчен бизәү эшләрен, ягъни фасадка зур портрет ясау, демонстрация колоннасын сурәтләү һ. б. фасадка тагып куяр өчен 20 $м^2$ зурлыкта Никита Хрущев[3] портретын ясадым. Моның миңа кыенлыгы юк иде. «Лозгун» язуы да кыен булмады. Колоннаны сурәтләү бераз авырлык китерде. Минем бу эштә тәҗрибә юк иде. Язулары җиңел, ә плакатларны мин яхшы яза белмим икән, Е. Седова килеп карагач:

— Сез бит картина язасыз, плакатны броска, гадирәк, гомумиләштереп язарга кирәк,— дип аңлатып китте.

Седова — ВХУТЕМАС буенча минем курсташым. Райкомда бөтен районны сурәтләү, демонстрацияләрне бизәү эшләрен алып бара торган комиссияләр бар иде. Шунда без «булдыра» торган сурәтләргә башлык итә, үзе теләгән сурәтчеләргә эш бирә икән. Шул комиссиянең әгъзасы буларак, бу объектны миңа бирергә Е. Седова ярдәм иткән иде. 15 көн буена тәүлегенә икешәр сәгать кенә йоклап эшләдем. 1 Майның иртәсендә эшләремне тапшырып өйгә кайтырга

---

[1] Сәукы — барышы.
[2] Тәклиф итү — кушу, әмер итү.
[3] Ул вакытта ВКП(б)ның Мәскәү шәһәр комитеты секретаре.

чыксам, Ленинград шоссесы буенча ак эскәтерләр ябылып, төрле тәмле нәрсәләр белән тулган өстәлләр тезелгән. Ак халат кигән сатучылар инде сәүдә итәләр иде. Бер-ике сәгатьтән транспорт, трамвайлар туктаячак булганлыктан, мин ашыктым. Беренче килгән трамвайга утырып, өйгә киттем. Тизрәк йоклыйсым килде. Мин уянганда 2 майның төштән соң вакыты иде инде. Шулай да була икән!

Сурәтчеләрнең күп эшләгән һәм акча казанган чаклары 1 Май һәм Октябрь бәйрәмнәрен бизәүдә булды. Кайберәүләр шул бәйрәмнәрдә эшләп алган акчага көн күрәләр иде. Кызыл мәйданны бизәү — ничә еллар буена ике бертуган Стернберглар кулында булды. Бай яшәделәр, чын босслар иде. Провинциядә дә шундый хәл. Шунлыктан ул вакытта станок сәнгате, нәгыйшь икенче планга күчтеләр. Алар тамакны туйдыра алмый иде.

1934 ел күргәзмәсеннән соң станок сәнгате үзенең борынгы урынына менеп алды. Ике зур күргәзмә — «Донбасс в живописи» һәм «Индустрия социализма» сурәтчелек дөньясына зур үзгәреш керттеләр.

Бу фәкыйрь әлеге 200 кеше арасында булганлыктан, 1935 елда «Всекохудожник» белән договор ясап, шул елның көзендә Донбасска, Кадиевкага «Дореволюционный барак шахтеров нацмен» дигән темага картина өчен этюдлар язарга сәфәргә китте. (Кадиевка тормышы аерым язылыр, ул аерым мәузугъ[1].) Аннан ике картинага материал җыеп кайттым. Берсе «Татар шахтерларының барагы», икенчесе — шахтер кызның портреты, ул «Лампалар йөртүче» дип аталды.

Ул заманда остаханәләр юк. Ничек булдырасың, шулай язасың. Өй кысан, урын юк. Халык өйдә юк вакытта киндерне ятак (карават) өстенә гәзитәләр җәеп, шуның өстенә куеп язам. Ике картинамны да жюри яхшы кабул итте. Аларның хәзер кайда икәннәрен белмим. Инде мин «лозгун»нар язмастан, станок нәгыйше белән яши башладым. Скульптурага әле һич мөмкинлек юк иде.

1936 елгы «Индустрия социализма» күргәзмәсенә договорны «Ишембайнефть»кә бару өчен төзедем. Җәйге бер-ике ай шунда узды. Ишембайның үзендә бер ай чамасы эшләгәннән соң, «Ишембай вышкаларының этюды», «Ишембай пейзажы», «Агыйделдән агач чыгару» дигән әсәрләрем туды. Шуннан соң Макар районына китеп, Исәкәй дигән авылда туктап, бераз этюдлар яздым, рәсемләдем. «Колхоз фермасы» дигән картина шунда язылды. «Ишембай» да, бу «Колхоз фермасы» да кабул ителделәр. Бу арада вак-төяк график эшләр дә эшли идем. Мәскәүдә ул вакыт «Коммунист» гәзите, «Яшьләр техникасы» һәм «Дәһриләр» журналлары чыга иде. Рәсемнәрне шуларда бастырдым. Шушы вакытларда «Шәрык музее» минем берничә эшне алды. 1934 елда дүрт-биш эшемне Татарстан музее алган иде.

Бу вакытларда Казанда ничек булганын анык белмим. Анда «Татхудожник», АХРР эшләде, скульпторлардан Садри Ахун бар иде. Мин Мәскәүдә тора идем. Шул вакыттагы татар сәнгатенең ни хәлдә булуын кыяфәтләү өчен хәзер мәгълүматым җитмәстер. Ләкин бу заманның характерын аңлату өчен 1939 елдагы бер вакыйганы искә алып китәсем килә.

Мәскәүдә, РСФСР мәгариф министрлыгының сәнгать бүлеге мөдире булырга кирәк, Ральф фамилияле кеше мине чакырып болай диде:

— Татарстан сәнгать һәм әдәбият декадасына әзерлек бара. Җыр-бию ансамблен киендерү өчен безгә Казаннан менә шушы эскизларны җибәргәннәр. Минем исәбемчә, бу бик ярлы күренә. Үз фикерегезне әйтсәгез иде.

Эскизларда чынлап та татар халкының кием-салымы бик яман хәлдә сурәтләнгән. Авылның урта хәлле һәм фәкыйрь халкы чабаталы, алъяпкычлы, тула оеклы, кәвеш, читек кигән рәвештә күрсәтелгән. Йолкыш рәсемнәр иде.

— Әлбәттә, мондый киемнәр бар. Ләкин татар халкының киемен моның белән генә күрсәтү сәхнә ансамбле өчен уңышлы булмас, — дидем.

Ральф:

— Әгәр вакыт табып, берничә эскиз ясап безгә күрсәтә алсагыз, мин бик шат булыр идем, — дигән мәгънәдә миңа гарыз итте.

Берничә көннән Ральф белән очраштык. Минем эскизым Ральфка ошады. Ул тәмам канәгать булуын изһар итеп, шул вакыттагы Татарстан филармониясенең директоры Николай Габдуллинга минем белән 16 эскизга договор төзергә тәклиф итте. Ул эскизлар хәстәрләнгәч, җәмәгатьчелеккә күргәзү, тәмам кабул итүне рәсмиләштереп, костюмнарны тектерә башлау чарасына керешергә тиешле идек. Ральф белән бергә Казанга бардык.

---

[1] Мәузугъ — тема, эчтәлек.

Ул вакыт сәнгать бүлегенең башлыгы Назаров дигән бер кеше иде. Аның кабинетында эскизларны элеп куйдык. Петр Сперанский, Петр Дульский, Сутюшев, Әбҗәлилов, тагы кемнәрдер булдылар, исемнәре хәтеремдә калмаган. Ральф кыска гына кереш сүз әйтте. Мин үземнең эшләремне гарыз иттем.

Иң әүвәл мәрхүм Дульский сүз әйтте. Сүзенең мәфһүме[1] — рәсемнәргә сәнгать бағымыннан игътиразым юк. Ләкин бу киемнәр бит пролетариат, эшче халык киеме түгел. Без байлар киемен үрнәккә алырга тиешмени? — дигәндәй булды.

Аннан соң Сперанский:

— Рәсемнәр һәйбәт. Мин каршы була алмыйм. Ләкин ни өчен моны Мәскәү кешесенә тапшырдыгыз? Без дә эшли алыр идек, — дигән мәгънәдә сөйләде.

Шуннан соң миңа сүз әйтергә кирәк иде.

— Киемнәрнең пролетариат киеме, буржуа киеме булырга тиешлеге минем компетенциядә түгел. Бу хакта иптәш Ральф аңлатса кирәк. Мин үзем белгән татар халкы фасонында ясадым. Әмма Сперанскийга ни җавап бирергә инде? Петр Тихонович, сез бит ничә еллар татар театрында эшлисез. Шул вакыттан бирле татар халкы кием-салымын эшләргә мөмкин булгандыр бит? Филармониянең Мәскәүгә тәкъдим иткән эскизлары кабул ителерлек булмаган бит. Ул игътиразны филармониягә юнәлдерүегез дөрес булыр. Мине гаепләмисездер, — дидем.

Ральфның җавабы болай булды:

— Бер халыкның кием формалары — ул бөтен халык сәнгате. Киемне кисүчеләр һәм тегүчеләр буржуа түгел. Ул пролетариат кулы, эшчеләр кулы белән ясала. Ул — эшче халык һөнәре.

Минем белән исәп-хисап та ясамадылар, ягъни гонорар түләмәделәр. Яктан төрле сүзләр, җиңел уйлы кешеләрне өркетә торган гайбәт таратыла башлаганны сизендем дә, тагын берәр бәла булмасын дип, Мәскәүгә кайтып киттем. Эскизларымны да шул килеш Казанда калдырганмын. Берничә елдан соң, төрле вакыйгалар узып, шәкертләремнән берәү әйтте, ул рәсемнәрдән бозып булса да файдаланганнар, һәм минем имза күчерелеп, Ибраһимов дигән берәү кул куйган икән. Хәерле булсын, сәргәрдан[2] булып йөргән заманнарда ул хәтле генә эшләр югалмады.

Бу вакытларда Мәскәү һәм Ленинград сәнгать институтларында белем алучы яшьләр бар иде. Боларның мин белгәннәре һәм уңышлы иҗади эш күрсәткәннәре — Чыңгыз Әхмәров һәм Әнвәр Ишмаметов. Татар сурәт сәнгате культурасына үз өлешләрен тәкъдир итәрлек дәрәҗәдә үтәделәр. Әнвәр Ишмаметовның Казанга килеп эшләргә теләге бар иде. Сабантуе темасына һәйбәт картина да язган иде, ләкин ни сәбәптәндер, Казанда төпләнә алмады. Мәскәүдә, гадәттәге сурәтчеләр кебек, заманына күрә кирәге булган таблолар язып, мәгыйшәт итә. Яхшы остаханәсе, яхшы өе бар. Гаилә тәрбия итә[3].

Чыңгыз Әхмәров әле Мәскәүдә, әле Казанда эшләп, соңыннан Ташкентта урнашты. Профессор булды, югары уңышларга иреште. 1926 елда әле сурәтчелек культурасы булмаган татар халкының 50—60 ел эчендә Чыңгыз Әхмәров кебек XX гасыр-масштабы белән үлчәгәндә югары дәрәҗәгә ашкан осталар җитештерә алуы горур булырлык бер хәл түгелме?

Соңгы рәссамнар — сурәт осталары хакында мәгълүмат сәнгать белгече С. Червонная китапларында тупланган. Ләкин бөек илебезнең башка республика һәм регионнарында эшләүче татар рәссамнарыннан аның китапларына керми калганнары да бар.

---

[1] Мәфһүме — эчтәлеге.
[2] Сәргәрдан — аптырау, баш әйләнү.
[3] 1989 елда вафат.

FATЬJX XƏSNI

# XƏZINƏ

**Xikəjə**

Spektakl' вaşlanьrqa jartь səqət qaldь digəndə genə, вaş roldə ujnajacaq Saвirnьŋ isenə «qьlt» itep вer nərsə kilep təşte. Komandir вulьp kieny əcen şljom qajan alьrqa?

— «Ax!» dip qujdь Saвir. Anьŋ avzьnnan kinət əzelep cьqqan вu «ax» səxnədəgelərneŋ вitlərenə gyjəki utlь çil вulьp kilep вərelde, alar вarsь da вer julь Saвirqa əjlənep qaradьlar. Truppada rezissjorlьq dəqvasь qьla torqan Zahrettinef, kyz acьp jomqancь, Saвirnьŋ qarşьna kilep вastь:

— Nigə axьldisьŋ? Taqьn nərsə çitməde?

Zahrettinef Saвirnьŋ kyzlərenə turь itep qarap tordь. Bəlki ənə şul turь qaraş вeraz jardəm itkənder, Saвirqa nicekter çiŋelrək вulьp kitte. Ul qaзa-lanmьjca qьna səjlənde:

— Barsь da вar, tik menə вer nərsəne onьtqanвьz ic вez, jegetlər.

— Nərsəne?

— Komandir вulьp kieny əcen şljom qajan alaвьz?

Bik az qьna vaqьtqa вarsь da tьndьlar, ujcanlandьlar. Jəzlərgə çiddilek вərep cьqtь, kyzlər kəzge tən şikelle kinət salqьnajdьlar.

Tьnlьqnь zaldaqь xalьq вozdь. Xalьq spektaklneŋ tizrək вaşlanuьn sorap, pьr tuzьp qul caвarqa totьndь. Qullarь вulqan keşelərneŋ ajaqlarьnda вar — qullar tik tormaqac, ajaqlar qьna nişləp tik torsьnnar. Qul caвu-larqa ajaq вelən tьpьrdavlar kilep quşьldь. Ber syz вelən əjtkəndə, zal qort ile təsle gəzləde. Xalьqnьŋ şljomda eşe juq, xalьq tyzemsezlek вelən kətə həm kətkən nərsəsen taləp itə ide. Monь işetkəc rezissjor Zahərttinef-neŋ jomşaq qьllarь caq qьna şartlap əzelmədelər. Ul, вəjdən ьcqьnqan jəş arьslan təsle, kinət quzqalьp, aşьqьp-aşьqьp jərergə totьndь həm səxnə artь ədəвe turьnda вətenləj onьtьp, Saвirnь qatь syzlər вelən şeltələrgə kereşte:

— Çeвep jərisen, kakoj cort artist sin. Yzeŋ turьnda yzeŋ qajqьrt-maqac, sine şajtanьm qajqьrtьrmeni. Bolamьq вulma, ujla, taqьn un minut vaqьt вirəm.

— Min xəzer genə ujlap qajan şljom taвьjm, di. Sineŋ вaşьŋda aqьlьŋ вarmь, juqmь?

— Beznen ваşьвьzda aqьlьвьz вar, şljomьвьz qьna juq, — dip aculanь qatьş tərtep çəvap qajtardь Zaherttinef həm acudan anьn in вaşlarь ysə вaşlaqan şikelle вuldь. In вaşlarь şul caqlь ystelər, xətta ul səxnəgə sьjьp tora almьj вaşladь həm tiz-tiz atlap сьqьр kitte.

Səxnədə qalqannar yzara kiŋəşləşə вaşladьlar. Qajsь anь, qajsь monь təqdim itte. Kyp kenə əjвət təqdim taвьldь, ləkin nacar qьna вulsa da вer şljom da taвьlmadь.

Zaherttinof вərelep-suqьlьp taqь kilep kerde. Bu julь ul şaqtьj uq acьlqan ide.

— Tuqtaqьz əle, iptəşlər, qarap qarьjq əle, вerərse şljom kiep kilməgənme ikən? — dide ul, pərdənen вer citen kytərep, səxnə aldьna сьqьр вastь.

Anь kyrgəc, xalьq taqьn da nьqraq tuzqi təşep, qul caвarqa totьndь. «Tizrək qьlanьqьz, irtəgə вəjrəm tygel ic», «əllə juq isə qojmaqьqьznьn əcye çitməgənme?» digən cəneckele syzlər anьn вaşьna вozlь janqьr вulьp javdьlar.

— Tьnьc вulьqьz, iptəşlər, xəzer spektaklne вaşlьjвьz, — dide ul, az qьna tьnьp torqan вulьp, zaldaqь xalьq østennən kyz jørtep сьqtь. Ləkin zaldaqь keşelər вarsь da вaş kiemnəren salьp utьrqanlьqtan, ul ezləgən nərsə monnan da taвьlmadь.

Zaherttinef kiredən pərdə artьna cumdь. Bu — aqtьq ьşanьcьnьn synye ide. Axrьnda ul artistlar aldьna kilep, keşelərgə rux вirə torqan ujьncaq həm çьlь tavьş вelən вelderde:

— Jarar, şljomsьz da ujnarвьz. Tege jьllarnь partizannar øcen şljom kiy şart tygel, çiny genə şart ide. V kontse kontsof, вeznen øcen də çiny genə şart.

Anьn вu caqьştьruь qьtьrşь сьqtь. Səxnədəgelər ana ni dip tə çəvap вirmədelər həm вu «qьtьrşь caqьştьru» keşelərnen jəzlərenə вərep сьqqan вorcьlu ezləren də jua almadь.

Saвir taqьn вer mərtəвə «ax» dip əjtergə avzьn aсqan ide, ləkin ul вu julь əjtep ølgermi qaldь, səxnə artьna altmьş, altmьş вiş jəşlər camasьndaqь вer qarcьq kilep kerde. Manqajьna çiьrcьqlar сьqqan həm javlьq qьna minenə qarap, Minleвikə dip əjtergə də вik mømkin ide, ləkin сьnlaв raq tikşerə torqac, ul minsez вikə вulьp сьqtь. Həm ul qarcьq anь-monь kətep tormьjca, işektən kerye вelən yk syzgə kereşte:

— Tьnlap, tьnlap toram da, taqьn вer tьnlap qujam. Aldanraq əjaq kienergə kirək ide, вalaqajlarьm. Xalьqnь alaj kəttererga jaramьj, xalьq вit ul sezgə teatr ujьnь tygel. Yzem şulaj alama вulsam da, əjtməgənem вulьn, qolaqlarьm sav minem, nərsə turьnda pьşьldaqanьqьznь işetep sun mina — Xəвiвçamal əвiegezgə kilmədegez? Minem Şərəfettin ulьm komandir ide вit, вicaraqajьmnьn xatlarьn da, yzennən qalqan qajвer

kiemnəren də kyz almam təsle itep saqlap toram. Əgər menə kyzegez-вaşьqыz aqajыp, juqaltыp qaldыrыrlыq bulmasaqыz, əjdəgez, ulsmnь kyrgən kek bulsrmыn, kienep ujnaqыz, вyregen də, kirək bulsa, вytən kiemnəren də вirep toram.

Səxnədəgelər kinət acыlыp kittelər. Xəвisçamal qarcыqnыn sul jaq janaqыndaqы zur mine alarqa təmle qaвartmaqa oşap kyrenə вaşladы. Xətta, çinel səjəkle Zahertinef qarcыqnь qocaqlap uq aldы:

— Сыnlap əjtəsenme, Xəвisçamal əвi? Birep torasыnmы?

— Sinen anan belən вergə qəmer itkən keşe вulam min, ujnap səjləşergə vaqtыm da juq, annarь taqыn seznen belən ujnap torыrqa вeraz sonqaraq ta qaldыm вuqaj inde.

Ul işekkə вorыldы həm taqыn вer qat jəşlərgə əjlənep qaradы:

— Əj, sezne, unmaqannar, aş peşergənsez, ə toz salыrqa onыtqansыz. Baş qaşыp torunыn vaqtы tygel, jə, qajsыqыz minem belən вara?

— Min вaram, Xəвisçamal əвi, — dip, Saвir anыn artыnnan iərde.

Biş minut ta vaqыt ytməde, Saвir, qызыl joldыzыna tuzan da qunmaqan jana şljom belən jana gimnastjorka həm taqыn nilərder kytərep alыp qajttы. Avыzqa yze «cəcrəp kergən» вu вəxet əcen ozaqlap вer qunыrqa kirək ide, ləkin vaqыt qыsqa вulqanlыqtan, quanunы ikence planqa qaldыrыp tordыlar. Saвir, qarşыsыna kəzge qujыp, tiz-tiz genə kienə вaşladы. Ləkin ul, ni caqlы aşыqsa da, Xəвisçamal qarcыqnыn вu şljom belən gimnastjorkanь nicek pəxtə itep saqlavыn iptəşlərenə səjləmicə вuldыra almadы:

— Əj, əj ecendə sandыq, sandыq ecendə çəjmə, ecendə aq javlыq, javlыq ecendə aq kəqəz, kəqəz ecendə menə вu şljom, Xəвisçamal qarcыq əcen вu əjberlərnen nicaqlы qəderle вuluвn şunnan yzegez ujlap cыqarыqыz inde.

— Kyrəsen, ul anы ulы təse itep saqlыj torqandыr, anыn ulы Şərəfi tege jыllarnы, grazdannar suqыşы vaqtыnda ylep qalqan ic, — dip çəvapladы aradan вerse.

Taqыn вeraz ыqы-zыqы kilep alqannan son, xalыqnыn qul caвыь astыnda, pərdəne acыp çiвərdelər. Sufljor, ojasыnnan вaşыn cыqarыrqa qurыqqan jomran təsle, вudkasыnnan cыqar-cыqmas pыşыldarqa totыndы. Spektakl' вaşlandы.

*
* *

Xəвisçamal qarcыq aldaqы rəttən urыn alыp, spektakl' вetkənce hic tə quzqalmыjca, şul urыnda utыrыp qaldы. Qajsыdыr вer ozыn tellese ana:

— Xəвisçamal tyti, sina namazlыq əstendə genə utыrыrqa kirək ide inde, ə sin jəşlər urnыn alыp, monda utыrasыn, — digən ide, вu syz Xəвisçamal qarcыqqa вer də oşamadы.

— Min yz urnыmda utыram. Əgər sin, aqыllыm, kluвqa simыj вaşlaqan ikənsen, ənə uram вik irken, uramqa cыqыp utыr, — dip aculanыp çavap

qajtardь ul. Spektakl' hic tə ketelməgən rəveştə jaxşь ytte. Ujnavcьlar, ʙigrək tə, komandir rolendə ujnavcь Saʙir səxnədə yzen ƣajət irken tottь. Xəʙiʙçamal qarcьqnьꞑ aꞑa, ʙarь tik aꞑa ƣьna tekələp qarap utьruь Saʙirnь çьlьttь, ʙaşqa vaqьtta hic tə kicerergə turь kilməgən təmle ʙer xis ʙelən tutьrdь. Bu rajonda jaꞑaraq eşce ʙulƣanlьqtan, Saʙir Xəʙiʙçamal qarcьqnь həm anьꞑ ulь Şərəfine rətləp ʙelməsə də, yz anasьn jaxşь ʙelgənlektən, ul, Xəʙiʙçamalnьꞑ nərsə ujlavьn ʙer cama ʙelən sizenə həm ʙu sizeny aꞑa əllə nicaqlь ecke kec ʙirə ide. Xəʙiʙçamalnьꞑ kerfek tə qaqmьjca qarap torнь ujьnnьꞑ vaq detallərenə də nьq qьna tə'sir itte. Məsələn, cişmə ʙujьnda qьzьl armieslərneꞑ jal itep jatularьn surətləgən ikence pərdədə, Saʙir yze də sizməstən, qulьn kytərep çiʙərde. Monda qulnь kytərmicə də qotьlьp ʙula ide. Ƣomumən, qul kytəry nicekter artьq həm jəmsez kilep cьqtь. Saʙir monь yze də sizde, ləkin soꞑƣa qalьʙraq sizde. Ənə şul minutta Saʙirnьꞑ kyzləre alƣь rəttə utьrucь Xəʙiʙçamalƣa kilep təşte. Xəʙiʙçamal «minem ulьm alaj tygel ide» digən sьman itep ʙaşьn cajqap utьra ide.

Spektakl' ʙetep, pərdə təşkənnən soꞑ, xalьq ʙik ozaq qul captь həm, xətta qajʙer «nьƣraq isergənnəre» tege də ʙu, «Saʙir vo ujnьj!» dip səjləngələp tə aldьlar. Spektaklneꞑ jaxşь ytye ujnavcьlarda da jaxşь ez qaldьrdь. alar ujnьj-kelə jərep, dekoratsiələrne, østəl østenə çajelgən aşjavlьqlarnь həm «joldьzlarnь» çiьştьra ʙaşladьlar. Zaherttinef yzeneꞑ rezissjorlьq qanatlarьn çiьp ʙeterməgən ide əle, Saʙirƣa qarap, ʙojrьq tavьşь ʙelən əjtte:

— Qara anь, Saʙir, Xəʙiʙçamal qarcьqqa şljom ʙelən gimnastjorkasьn irtəgə irtyk iltep ʙir. Rəxmət əjt, qart keşeneꞑ şuꞑa kyꞑele ʙula anьꞑ.

Ləkin alar rəxmət əjtergə də, qart keşeneꞑ kyꞑlen taʙarƣa da ølgermədelər, qart keşe Xəʙiʙçamal yze kilep kerde. Ul ƣajət dərəçədə acьq jøzle, xətta, şatlьqtan anьꞑ maꞑƣaj çiьrcьqlarь da, sul jaꞑaƣьndaƣь mine də juƣalƣan tøsle ide. Ul işektən kereşli yk søjlənə-søjlənə kerde:

— Juq, sez miꞑa tygel, min sezgə rəxmət əjtergə tieşle, ʙalaqajlarьm. Sez ʙygen minem kyz aldьma minem Şərəfettin ʙalaqajьmnьꞑ nəq yzen kiterep ʙastьrdьƣьz. Sezneꞑ tøsle ul da şulaj ʙaşьn artqa taşlap, onьtьlьp kelə torƣan ide. Rəxmət, çannarьm, əgər Şərəfettinem isən ʙulƣan ʙulsa, ul yze də rəxmət əjter ide. Ujьn-kelkene ʙik jarata torƣan ide mərxym.

Xəʙiʙçamal qarcьq tьnьp, citkə qarap tordь. Anьꞑ iꞑ ʙaşlarь tirʙəldelər, ul kyzləren keşegə kyrsətmicə, əkren genə çьlьj ide. Jəşlər taƣьn ujcanlanьp qaldьlar. Ləkin ʙu ʙəxetle həm gyzəl ujcanlьq ide.

Berazdan soꞑ qarcьq quzƣaldь da, qujnьnnan aq javlьq cьƣarьp, şljom ʙelən gimnastjorkanь şul aq javlьqqa pøxtələp tørə ʙaşladь. Ə yze həm søjlənde:

— Ulьmnьꞑ tøse itep saqlьjm min alarnь. Menə ʙu joldьzlь ʙyrekne s... gən sajьn ulьmnь kyrgən tøsle ʙulam. Minem ulьm da sezneꞑ şikelle ... ide, ujnarƣa, ʙaşьn artqa taşlap kelərgə jarata torƣan ide...

# Бер сораута — бер җавап

— *Җөмһүриятебездә татар балаларын ана телендә укытуда алга китеш бармы?*

— Былтыргы уку елы белән чагыштырганда, быел татар милли мәктәбе сизелерлек ныгыды — саны 1049 дан 1114 кә җитте. Шул исәптән, урта мәктәпләребез 401 дән 435 кә, ТБУМнарыбыз 111 дән 126 га, башлангычларыбыз 537 дән 553 кә күтәрелде. Шуның белән бергә, былтыр катнаш мәктәпләрнең 164 ендә татар класслары ачылган булса, быел алар 201 мәктәптә эшли башлады. Хәзер катнаш мәктәпләрнең 763 татар классында 11173 бала ана телендә укый. Милли мәктәпләребездә: башлангычларда — 5437, ТБУМнарда — 4967, урталарда — 55035 укучы белем ала. Гимназия тибындагы татар уку йортлары былтыр 20 булса, быел 41 гә житте, аларда укучылар саны 4280 нән 9105 кә күтәрелде. Шулай итеп, туган телендә укучы татар балалары саны быел 85717не тәшкил итте. Бу — мәктәп яшендәге балаларыбызның (256075) 33,5 проценты дигән сүз. Былтыр татар телендә укучылар гомуми санга карата 28,2 процент кына иде.

Милли мәгариф челтәренең абруе күтәрелүен түбәндәге саннар аеруча ачык күрсәтә: туган телендә белем алучы балаларыбыз ике ел эчендә гомуми санга карата авылларда — 54,1 процентган 61,9 га, шәһәрләрдә — 3,8 дән 10,9 процентка күтәрелде. Шуның нәтиҗәсендә һәр өч татар баласының берсе барлык фәннәрне туган телендә үзләштерә.

Билгеле, татар мәгариф челтәре тулы көченә һәм нәтиҗәле эшләсен өчен әле бик күп тырышасы бар, ләкин милләттәшләребез аңында уңай якка борылыш башлануын, милли үз аң уянуының торган саен үзен ныграк сиздерүен күрми мөмкин түгел.

Бу уңайдан татар бакчаларында һәм катнаш бакчаларның татар төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр саны ике ел эчендә 5 меңгә артып, хәзерге көнгә 49465 кә житүен дә искәртү урынлы булыр.

Татар мәгариф челтәрен киңәйтү һәм үстерү тиз арада укытучылар һәм тәрбиячеләр әзерләүне арттырырга мәҗбүр итә. Шушы максатта 1991 елдан башлап КДУның татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре факультетына студентлар кабул итү арттырыла килә. Чаллы désинститутында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды, Алабуга пединститутының Лениногорск филиалында татар теле, музыкасы, татар мәктәпләре өчен чит тел укытучылары әзерләү башланды. Казан пединститутында татар мәктәпләре өчен физика, химия, математика, биология, география, музыка, җыр укытучылары әзерләүгә дә хәзер күбрәк игътибар бирелә.

Татар теле укытучылары әзерләү өчен КДУ, Арча һәм Казанның Беренче, Чаллы педагогия училищелары каршында колледжлар, Минзәлә педучилищесе каршында — колледж челтәре барлыкка китерелде. Быелгы уку елында педучилищеләрнең татар төркемнәренә укырга кабул итү 260 кешегә арттырылды.

Әлбәттә, милли мәгариф челтәре укытучыларына һәм тәрбиячеләренә ихтыяҗ чагыштыргысыз зуррак, чөнки Татарстан шәһәрләрендә әлегә татар балаларының тугыздан берсе генә ана телендә укый. Якын киләчәктә ата-аналарның күпчелеге милли мәктәпкә мөрәҗәгать итә башласа, хәлнең тагын да кысанлашуы ихтимал. Безнең әле республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә ярдәм итәсебез бар ич.

Туган телебездә укыту һәм тәрбияләү киңәйтелгәндә барлык фәннәр буенча татарча дәреслекләр, методик кулланмалар һәм киң куллану китапларын бастыруны да арттырырга кирәк.

Соңгы биш елда 200 исемнән артык дәреслек, 140 тан артык исемдә методик кулланма нәшер иттек. Сүзлекләр, белешмәлекләр, диктант һәм иншалар, күнегү җыентыклары, күргәзмә әсбаплар, программалар да байтак дөнья күрде. Хәзер бу эшкә «Мәгариф» нәшриятебезнең җиң сызганып тотынуы четерекле мәсьәләләребезне хәл итәргә булышыр, дип уйлыйм. Татарча дәреслекләргә һәм кулланмаларга заказлар елдан-ел үсә бара: 1989/90 уку елында алар 526 меңне тәшкил итсә, 1993/94 елларга заказ ике мәртәбә күбрәк җыйналды.

Безнең әле урыс мәктәпләрендә укучы татар балаларына махсус туган тел һәм әдәбият китаплары, җөмһүриятебезнең барлык укучыларына яраклы туган як тарихы һәм мәдәнияте дәреслекләре әзерләвебезне һәм бастыруыбызны, Татарстанның урыс, чуваш, удмурт, мари, мордва мәктәпләрендә дә республикабыз-

ның төп халкы телен өйрәтүебезне дә онытмыйк — бу эш милли мәгариф челтәребез сулышын киңәйтүгә тәэсирле ярдәм булып тора.

Урта махсус һәм югары уку йортларыбызда татар телендә белем бирү кертелә башлады. Шушы эш тәмам юлга салынгач, милли мәгариф челтәребез тулы канлы, сәламәт бер система тәшкил итәр, милләтебезнең яшәеш тирәлеге дә сафлана төшәр, дип уйларга кирәк.

Татарстаннан читтәге милләттәшләребез дә милли мәгариф челтәребезне үстерергә омтыла, ләкин бездә әлегә андагы үзгәрешләр турында төгәл мәгълүматлар юк.

**Васыйл ГАЙФУЛЛИН,**
педагогия фәннәре докторы, профессор,
Татарстан җөмһүрияте халык мәгариф министры.

♣♣♣♣♣♣♣♣

*Алдагы санда укыгыз*

## Һ. Атласый турында архивлар ни сөйли?

1929 елның мартында Атласов кулга алына. Тентү вакытында аңардан Солтангалиев хаты һәм өч мең томлык шәхси китапханәсе тартып алына. Соңрак, Сталинга адресланган хатында (1935 ел) Атласов үзенең Бөгелмәдә кулга алынуы һәм солтангалиевчелектә гаепләнүе хакында яза. «Солтангалиев белән таныш булсам да, солтангалиевчелекне якламадым. Бөек урыс шовинизмы киң җәелеп, тирән тамыр җибәрде, дип уйлавым белән мин милли мәсьәләдә үземә аерым бер мәсләктә тордым. Мин, пролетариат диктатурасы, бөек урыс хакимлегенә чик куйса да, урысларның башка милләтләр өстеннән хакимлек итү институтын бетерә алмады, дип исәпләдем»,— дип яза ул.

1934 елның апрелендә Мәскәүдән милли республикаларга мөселманнарның бәйсез «Туран дәүләте» төзү өчен яңадан агитация башлап җибәрүләре, шул эшне оештырудагы үзәкне табу, фаш итү һәм юкка чыгару турында ОГПУ күрсәтмәләре җибәрелә. Казан ГПУчылары үзләре өчен абруй казаныр сәгать җитте дип исәплиләр, «үзәк» — Татарстанда һәм аның башында Атласов тора, дип карар кылалар.

Атласов тирәсендә торучы шымчылардан өчесе аеруча активлык күрсәтә. Менә шундый донос-әләкләрдән кайбер өзекләр...

## Шаһиморат Зәйни

Шаһиморат Зәйни (Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов) 1913 елның мартында элекке Оренбург губернасының Бозаулык өязе (хәзерге Тоцк районы) Кондызлытамак авылында мулла гаиләсендә туа. 1933 елда Ташкентта икееллык педагогия институтын һәм 1936 елда Казан театр техникумын тәмамлагач, Бөек Ватан сугышына кадәр Республика халык иҗаты йортында эшли. Сугыш башлангач, Ш. Зәйни фронтка китә һәм алгы сызыкта торып Мәскәүне, Сталинградны дошманнардан яклауда катнаша. Шулай ук ул Европа илләрен гитлерчылардан азат итешә. Сугыштагы батырлыклары өчен күп кенә орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Ш. Зәйни жиде елга якын Халык иҗаты йортында эшли. 1953 елда инвалидлык буенча пенсиягә чыга.

Әдәби иҗат эшен курчак театрлары өчен пьесалар язудан башлый. Аның бу жанрдагы беренче әсәре — «Шүрәле» исемле өч пәрдәле драма-балладасы 1938 елда языла һәм Казан дәүләт курчак театрында куела. Шуннан соң иҗат ителгән «Мәч-Мәчин» (1938), «Айтуган» (1941), «Кечкенә партизаннар» (1947), «Таң — Чулпан улы» (1956), «Бәхет кошы» (1956) пьесалары да курчак театры сәхнәләрендә күп еллар буе уңыш белән бара.

Илленче еллар ахырыннан башлап Ш. Зәйни үзешчән сәнгать коллективлары, халык театрлары һәм профессиональ театрлар өчен әсәрләр яза башлый. «Энже бөртекләре» (1948), «Хәзрәт үгетләргә килә» (1955), «Тугыз гашыйк» (1957), «Хәят» (1958), «Таң жыры» (1960), «Дәһшәтле минутлар» (1961), «Йөрәк давыллары» (1962), «Уеннан уймак» (1963), «Гөмбәз асты серләре», «Әй әшнәләр, әшнәләр!» (житмешенче еллар) әнә шундый әсәрләрдән.

Ш. Зәйни башка милләт драматургларының әсәрләрен дә күп тәржемә итә.

1980 елда ул Казанда вафат булды.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татар язучыларының күптәннән яшәп килгән матур гадәтләре бар. Алар, яңа ел башында бергә җыйналып, үткән әдәби елның нәтиҗәләрен чыгаралар, эшкә йомгак ясыйлар. Быел әнә шундый җыелыш язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында 29 гыйнвар көнне булды. Әдипләр аерым жанрлар буенча чыгышлар тыңладылар. Проза әсәрләре хакында Фоат Галимуллин, шигърият буенча Ркаил Зәйдуллин, драма әсәрләре турында Рабит Батулла, балалар әдәбияты хакында Җәүдәт Дәрзаман, Татарстанда яшәүче урыс язучылары иҗаты турында Владимир Корчагин сөйләде. Аннары әдәби иҗатка һәм язучыларның тормыш-конкурсенә кагылган байтак кына кызыклы чыгышлар тыңланды.

Ел йомгаклары утырышында Татарстан премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ОЛЫ ӘДИПНЕҢ КАЙТУЫ

Февраль аенда Татарстан хаксызга туган иленнән сөрелеп, чит-ят җирләрдә гомер кичергән, әмма туган халкының язмышы турында кайгыртып яшәгән татар әдәбияты классигы, аталы прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый рухы белән яшәде. Шул уңай белән «Казан» милли-мәдәни үзәгендә аның бай әдәби мирасына, тормыш һәм иҗат юлына багышланган «Кайт әле монда, Ватанга» дигән күргәзмә ачылды. Күргәзмә ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Гаяз Исхакый мирасын халыкка кайтаруда зур тырышлык куйган филология фәннәре докторы профессор И. Нуруллин, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Л. Гайнанова, бөек галимнең шәкерте Х. Исмәгыйлев, туганнары С. Шәрипова, Т. Исхаков, композитор Ә. Бакиров һәм башкалар сөйләде.

Шул ук көнне «Казан» милли-мәдәни үзәгендә Гаяз Исхакыйның тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция ачылды. Аны Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Милли мәдәният музее, Татар «Мирас» фонды үткәрде.

Конференцияне кереш сүз белән Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов ачты. Аннары «Гаяз Исхакый һәм татар тарихы», «Татар милли әдәби теле формалашуда Г. Исхакыйның роле», «Г. Исхакый һәм XX йөз татар әдәбияты» дигән һәм башка темаларга галимнәрнең докладлары тыңланды, фикер алышу булды.

Күргәзмәне ачуда һәм конференция эшендә Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм Татарстан Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин катнашты.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР, ЯҢА ӘГЪЗАЛАР

Язучылар берлеге идарәсенең 22 февральдә булган чираттагы утырышында олуг әдибебез Гаяз Исхакый исемендәге премияләрне бирү турында мәсьәлә тикшерелде. Утырышның бердәм карары белән олы бүләкләр татар милли хәрәкәтенә, мәдәниятебез тарихына багышланган публицистик мәкаләләре өчен әдәбиятыбыз аксакалы Әмирхан ага Еникигә, «Сөембикә», «Кол Шәриф» поэмалары, «Иман янарткандa» исемле публицистик китабы һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге өчен Әхмәт Рәшиткә, татар әдәбияты классик әсәрләрен редакцияләү һәм матбугатка әзерләүдәге хезмәтләре өчен мөхәррир Рәис Даутовка бирелде.

Шул ук утырышта И. Ихсанова, Н. Кәримова, Ф. Мөслимова, Ф. Әһлия, Ф. Галиев, З. Зәйнуллин, З. Хәким, В. Юныс, М. Әмирханов, Г. Сәгыйровлар Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

## ТАТАР ГЕНЕРАЛЛАРЫ ОЧРАША

Татар халкының күренекле уллары хәрбиләр арасында да җитәрлек. Без моның шулай икәнен Бөек Ватан сугышы тарихыннан да яхшы беләбез. Бүгенге көндә исә милләттәшләребез арасында күпме генерал һәм адмирал бар? Бу сорауга җавап бирү элегрәк кыен иде. Җәмгыятебездәге үзгәртеп кору, милли үзаңның уянуы татар хәрби эшлеклеләренә үзара күрешеп танышу, рухи туплану мөмкинлеге бирде.

20 февральдә Мәскәүнең «Президент-отель» залларының берсендә элекке СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче татар генераллары-адмиралларының (алар исемлектә 40 чамасы иде) очрашуы булды. Очрашуны оештыруда зур тырышлык күрсәткән данлы якташыбыз, армия генералы Мәхмүт Гәрәев мәҗлесне котлау сүзе белән ачып җибәрде.

Ватанны саклаучылар көне уңаеннан үткәрелгән әлеге очрашуда Татарстан Республикасы вице-президенты Василий Лихачев та катнашты һәм чыгыш ясады. Ул татар генераллары һәм адмиралларына җөмһүриятебез Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән бәйрәм тәбриге һәм истәлекле бүләк — Чистайда эшләнгән «Командирские» сәгатьләре тапшырды. Татарстан Юга-

ры Советы Президиумы исеменнән хәрбиләрне Президиум әгъзасы, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис котлады. Татар журналистлары, шул исәптән журналыбызның баш редактор урынбасары Рашат Низамиев мәҗлестә катнашучыларга «Казан утлары»ның юбилей саннарын, милли матбугат басмаларын бүләк иттеләр.

Мондый да колачлы һәм тарихта беренче тапкыр буларак узган мәҗлес-очрашуны оештыруда татарның күренекле эшмәкәре Наил Халикеев зур тырышлык, ярдәм күрсәтте.

Очрашуда депутатлар, галимнәр, язучылар һәм журналистлар катнашты. Москонцерт артисты Роза Хәбибуллина башкарган милли җырларыбыз кунаклар күңеленә бик тә хуш килде.

## Г. КАМАЛ ТЕАТРЫ — МӘСКӘҮДӘ

Татар Дәүләт академия театры февраль башында Мәскәүдә бер атналык гастрольдә булып кайтты. Алар анда, Вахтангов исемендәге театр бинасында, Т. Миңнуллин әсәре буенча эшләнгән «Илгизәр + Вера» һәм яшь драматург М. Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Казан егетләре» спектаклен күрсәттеләр.

Гастроль уңаеннан үткәрелгән тантанада театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов, Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев, Татарстан премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Мәскәү мәчетенең баш имам-хатыйбы шәех Равил хәзрәт Гайнетдин һәм драматург Т. Миңнуллин чыгыш ясадылар.

## ШИГЪРИЯТ АНТОЛОГИЯСЕ КИЧӘСЕ

19 февральдә «Казан» мәдәни милли үзәге каршындагы «Шәрекъ клубы» тагын бер истәлекле кичә уздырды: ул милли мәдәни тормышыбызда зур вакыйгага — Татар шигърияте антологиясе басылып чыгуга багышланган иде. Ике том булып дөнья күргән бу олуг китапны чыгаруга галимнәребез, шигырь белгечләре, шагыйрьләр һәм редакторлар коллективы (Ф. Зөлкарнәев, Г. Гыйльманов, Х. Әюпов) күп көч куйган. Бу турыда антологияне төзүче шагыйрь Гәрәй Рәхим һәм нәшрият директоры Х. Әшрәфҗанов әтрафлы итеп сөйләделәр. Алар бу китапны бүленмәс фонд өчен, Милли китапханәбезгә аның директоры шагыйрь Р. Вәлиевкә тапшырдылар.

Кичәдә мең еллык шигърият җәүһәрләребез нәфис сүз осталары А. Арслан, Р. Сабиров, артист А. Хафизов, җырчылар А. Туишева, А. Фәйзрахманов, И. Биктаһиров, З. Хәйретдинов һәм «Сорнай» ансамбле җырчылары, уен кораллары катнашлыгында шигырь, җыр, «Кыйссаи Йосыф»тан инсценировка рәвешендә тарихи моң булып яңгырады. Шагыйрьләрдән И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Гатаи, Х. Әюпләр чыгышы, шигырьләрен укуы, ахырда галимнәрнең, нәшрият мөхәррирләренең сәхнәгә чакырылып, баш июләре — болар бар да тамашачыларда, шигърият сөючеләрдә онытылмас тәэсирләр калдырды.

## «ИМАН» БӘЙРӘМЕ

Мөселманнар өчен изге Рамазан ае башлану уңаеннан, 20 февральдә К. Тинчурин исемендәге театр бинасында «Иман» бәйрәме үткәрелде. Анда БДБ илләренең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары диния нәзарәте мөфтие Тәлгать Таҗетдин вәгазь сөйләде. «Җәмгыяте хәйрия» рәисе, язучы Мәдинә Маликова, Г. Тукай музее директоры Фәрит Яхъя һ. б. чыгыш ясады.

Бәйрәмнең икенче өлешендә концерт булды. Анда Рамил Миндияр, Исламия Мәхмүтова, Гөлзада Сафиуллина һ. б. күренекле артистлар чыгыш ясады, махсус музыка мәктәбе укучысы Рөстәм Зарипов скрипкада уйнады, ә «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, шагыйрь Шамил Маннапов үзенең шигырьләрен сөйләде.

## ГАЗЕТА БӘЙРӘМЕ

Мамадыш районында чыга торган «Нократ» газетасының беренче саны дөнья күрүгә шушы елның февралендә 75 ел тулды. Шул уңайдан, шәһәрнең мәдәният йортында район хакимияте һәм халык депутатларының район Советы Президиумы башлыклары, редакция һәм типография хезмәткәрләре, күпсанлы хәбәрчеләр һәм матбугат ветераннары, килгән кунаклар һәм данлыклы якташлар, Ш. Маннур исемендәге «Агымсу» иҗат берләшмәсе әгъзалары һәм предприятие-учреждение, колхоз-совхоз җитәкчеләре катнашында зур тантана уздырылды.

Район хакимияте башлыгы, Татарстанның халык депутаты Илгизәр Ибраһимов, заманында шушы газетада үзенең тәүге язмаларын бастырган күренекле прозаик, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Россиянең халык депутаты Ринат Мөхәммәдиев, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафин (ул журнал редакциясенең һәм баш мөхәррир — Татарстанның халык депутаты Равил Фәйзуллинның шәхси котлавын игълан итте), Татарстан дәүләт киностудиясенең баш мөхәррире Әхмәт Гадел, Казан дәүләт университетының журналистика факультеты деканы, татар журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әгъзәмов, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире урынбасары, тарих фәннәре кандидаты Сәмигулла Хәйретдинов, районның Кече Кирмән авылында яшәп иҗат итүче шагыйрь Рафаил Газизов һ. б. иптәшләр юбиляр адресына тәбрикләү сүзләре белән чыктылар, бүләкләр тапшырдылар.

Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, Бөтенсоюз татар җыры смотр-конкурсы лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлнәзирә Талипова, баянчы-җырчы Рәсимә Яруллина һәм башка бик күпләр якташларына онытылмаслык кадерле мизгелләр бүләк иттеләр.

# РӘССАМ РӘМЗИЯ ЗИННӘТОВА

Журналыбыз тышлыгының беренче битендә сез бу юлы хатын-кыз рәссам Рәмзия ханым Зиннәтованың «Сөйләшү» исемле әсәрен күрәсез.

Рәмзия ханым Зиннәтова Санкт-Петербург каласында яши. Рәссамнәр берлеге әгъзасы. Казан зыялылары — сәнгать сөючеләр аның иҗатын бик артык белеп тә бетермиләр әле. Юкса Рәмзия ханым Казанда туып үскән, биредә художество училищесы тәмамлаган рәссам. Аның беренче әсәрләре белән Татарстан тамашачылары бары тик 1991 елгы «Татар-91» күргәзмәсендә генә таныша алдылар. Аңа кадәр инде Р. Зиннәтова, Дания, Германия кебек илләрдәге абруйлы халыкара күргәзмәләрдә катнашып, үзен танытып өлгергән иде. Аның әсәрләре Казанның сынлы сәнгать музее тарафыннан да сатып алынды.

Рәмзия ханым Зиннәтова — график-рәссам. Ул Санкт-Петербург сынлы сәнгать Академиясенең Репин исемендәге сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтының графика бүлегендә укып белем алган. Биредә укып чыккан күп кенә татар рәссамнәре (Ф. Әминов, Р. Гыйлаҗев, С. Бәхтиярова, М. Вәлиев, Р. Нуруллин, В. Рәхмәтуллин, М. Мөниров һ. б.), соңыннан Казанга кайтып төпләнергә теләсәләр дә, РСФСР Рәссамнәр берлегенең Татарстан бүлегендә аларны кочак җәеп каршы алучы булмый. Юкса, берлек әгъзалары булган татар рәссамнары биредәге бүлекнең яртысын да тәшкил итмиләр. Шуңа күрә яшь рәссамнар Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа кебек шәһәрләргә китеп барырга мәҗбүр булалар. Шул ук Санкт-Петербург каласында гына да тамырлары Татарстанга тоташкан утызлап рәссам яши һәм уңышлы иҗат белән шөгыльләнә. Аларны дөнья таный.

Бу сүзләребез тулысы белән Рәмзия ханым Зиннәтованың иҗатына да карый. Аның да үзенчәлекле таланты Татарстан сәнгатенә хезмәт итәргә лаеклы, безнеңчә. Рәмзия ханым милли рухын җуймаган: аның эшләрендә һәрвакыт татар халкының милли үзенчәлекләре ачык төсмерләнеп тора.

«Сөйләшү» исемле әсәр рәссамның «Самавыр янында» дигән график линогравюралары сериясеннән. Катыргыга уелган рәсемдә гади генә көндәлек тормыш чагыла: бер йортта яшәүче ике хуҗабикәнең мөнәсәбәтләре сурәтләнә. Күзгә керәмкерәм дип торган яшь хатын килен кешедер, ә аның күләгәсендәрәк калган әби, мөгаен, кайнанадыр. Бу очракта «килен кеше — ким кеше» тәгъбирен онытып торырга туры килә. Киленнең торышы-кыяфәте — ризасыз чырае, иреннәрен кабартуы, башын борып, бәйсез-буйсынусыз карап торуы әлеге сөйләшү-аңлашуны башлап җибәрүче дә килен үзе икәнен әйтеп тора. Ул, күрәсең, нәрсәдәндер канәгать түгел. Һәр ике хатынның да холкы-табигате искиткеч төгәл ачыла. Бер якта татар хатын-кызларына хас түземлелек, икенче якта — тыелгысыз хис-тойгылар кайнарлыгы. Хәтта аларның яулык бәйләүләре, каш сызыклары да күп нәрсә аңлата. Киленнең кулларында ялкау мәче ята. Ул, бер күзен кыса төшеп, безгә карый һәм безне дә кайнана белән килен арасында барган әңгәмәне тыңларга чакыра сыман.

Рәмзия ханым Зиннәтованың, рәссам буларак, милли образлылыкны тоя белүе, татар милли сәнгатенең төсләр һәм ритмик үзенчәлекләрен тирән аңлап иҗат итүе бик куанычлы. Рәссамнең «Татарстаным», «Казан» исемле график серияләре, башка күп кенә әсәрләре дә шул хакта сөйли.

Соңгы вакытта Рәмзия ханым майлы буяулар белән эшләүгә зур игътибар бирә. Ул хәзер ислам дөньясын чагылдыруга багышланган әсәрләр иҗат итү белән мәшгуль.

Гүзәл **ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,**
сәнгать белгече.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосурәте.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Әдип Маликов.

**Д. Бунтуков** фотосурәте.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — РУХИ ЮЛДАШЫБЫЗ

Мөхтәрәм милләттәшләр!

1993 елның икенче яртыеллыгы өчен (июль, август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айлары) «Казан утлары» журналына язылу башланганын хәбәр итәбез. Илдә туктаусыз үсә барган кыйммәтчелек, әлбәттә, журналга язылу бәясендә дә чагылмый калмый. «Казан утлары» журналының бер саны быелның беренче яртыеллыгында әбунәчеләр өчен 20 сум торса, икенче яртыеллыкта ул 30 сум тәшкил итәчәк. Димәк, ярты елга (алты айга) язылу бәясе 180 сум булачак. Журналның индексы — 73210. Ул Үзәк каталогка да кертелгән.

Шунысын да искәртәбез: киоскларда ваклап сатуда журналның бәясе иркле булачак.

«Казан утлары» яктырак балкысын, мөхтәрәм милләттәшләр!

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: I

на 1993 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ ______ место ______ литер ______

на газету / журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | 180 руб. 00 коп. | Количество комплектов: | I |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1993 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

Билгеле булганча, илдә икътисади хәлләрнең һаман кискенләшә баруы сәбәпле, 1993 ел өчен газета-журналларга язылу ил күләмендә бары тик алты айга (ярты елга) гына үткәрелгән иде. Хәзер без «Казан утлары» журналына 1993 елның икенче яртыеллыгына, ягъни калган алты айга язылу башлануын белдерәбез.

Алдагы еллар тәҗрибәсен истә тотып, журналыбызны алдырырга теләүчеләргә булышу максатыннан, без мөштәриләребезгә (журналга язылучыларга) әзер әбунә кәгазен (абонемент бланкын) тәкъдим итәбез. Укучыларыбызга, үзләренең тулы адресларын язып, исем-фамилияләрен күрсәтеп тутырылган әбунә кәгазен өзек-өзек сызыклар буенча кисеп алырга һәм почта-элемтә бүлекләренә тапшырырга гына кала.

### ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

# ЯҢА КИТАПЛАР




Яратып укыла торган китаплар бер-бер артлы дөнья күрә. Безнең китап киштәләребез байый, алай гына да түгел: күңелебез байый, рухыбыз ныгый. Халкыбызның рухи тормышында кабатланмас урын биләгән Хуҗа Насретдин турындагы әсәрләрне дә без бик сагына башлаган идек инде. Менә, ниһаять, алар дөнья күрде. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яңа җыентык «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» дип исемләнгән. Аңа халык иҗатының иң кызыклы җәүһәрләре тупланган. Китап шулай ук рәсемнәр белән дә бизәлгән.




Соңгы елларда редакцияләр дә, нәшриятлар да кеше күңеленә хуш килердәй әсәрләр бастыруны төп максат итеп куялар, үз эшләрендә шундый халыкчан юнәлеш тоталар. Шамил Маннаповның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Ачы какылар» исемле җыентыгы моны тагын бер мәртәбә раслый. Матур-матур җырлары һәм шигъри әсәрләре белән танылган әдипнең хикәяләре һәм хатирәләре тупланган бирегә. Ә юмор яратучылар өчен «Булмас димә, дөнья бу...» һәм «Ибрай абзый хикәятләре» дигән махсус бүлекләр дә бирелгән.

Бу китапларны якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, түбәндәге адрес буенча соратып алырга була:

**420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 3 нче йорт, «Төрки китап» кибете, «Книга-почтой» бүлеге.**

Бәясе 20 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог